

ФӘРИТ ЯХИН

# *САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР*

# БЕРЕНЧЕ ТОМ

**Яхин Ф.З.**
Сайланма әсәрләр: Проза.— Беренче том.— Казан: Моя электронная книга, 2006.— 483 б.

Бу томга авторның, кайбер тәүге проза әсәрләреннән алып, 1980-1990 елларда язылган, 2000 нче елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан “Ак әбиләр догасы” җыентыгына кертелгән хикәя һәм повестьлары тупланып бирелде. Томлыктагы кайбер повесть һәм романнары беренче тапкыр дөнья күрә һәм әдипнең башлангыч чоры иҗат дәверен укучыга тулы күз алдына китерергә ярдәм итә. Язучының иҗат үзенчәлекләре, темаларны сайлап алу һәм ачып бирү осталыгы башкалардан шактый кискен аерылып тора, әсәрләре татар әдәбиятында яңа әдәби күренеш булдылар, укучының дикъкатен яулый алуы белән дә сокландыра.

© Яхин Ф.З.

## АК ӘБИЛӘР ДОГАСЫ

*Хикәя*

Мең тугыз йөз җитмеш өченче елның җәе бик эссе килеп, иген һәм үләннәр генә түгел, хәтта урман һәм агачлар да июль башыннан саргылт-кызыл төскә керде. Ил өстенә ачлык куркынычы төшеп, көннәрнең яме бозылды, маллар да җәйләүдә кипкән үлән эзләнеп, арыкланганнан-арыклана бардылар. Корылык һәм ачлык бәласеннән котылу мөмкин түгел кебек иде инде. Коткарса, бары тик могҗиза гына коткара ала. Ул да булса — яңгыр, атна буе явып торган яңгыр гына...

Корыган чишмә һәм елга үзәннәре комга әверелгән шундый көннәрнең берсендә ак әбиләр тау-сырт өстенә җыелып Коръән чыга икән дигән хәбәрдән Дүсем авылы тынып калды. Заманында Әүлияләр зираты һәм Әүлияләр чишмәсе белән дан тоткан тауда икән алар!

Без, малайлар, тау итәгенә йөгерештек. Могҗизаны үз күзебез белән күрәсебез килә иде. Мәктәптә «Алла юк!» дип, өйрәтсәләр дә, өйдә «Аллаһы әкбәр!» дип, өстәл янында амин тотып үскәнлектән, Аллаһы тәгаләнең кодрәтенә ышана идек без.

Тау сыртында ак әбиләр: Сәкинә, Нурлыхода, Икълимә, Мәүлидә һәм тагын

ун-унбиш абыстай, актан киенгән, намазлыкларын җәеп салып зекер әйтәләр һәм Коръән чыга иделәр.

Без тау итәгеннән ары күтәрелмәдек. Мыштым гына күзәтеп тордык та, кире үз очларыбызга таралышып, яңгыр көтә башладык. Ак әбиләр догасы яңгыр яудырачак!

Ләкин күктә хәтта ак болыт әсәре дә күренми иде.

Ак әбиләр, көннәр буе ураза тотып, дога кылып, шул тау башында кыйбла тарафына йөз сөртүләрен дәвам иттеләр. Бер көн, ике көн, өч көн үтте. Яңгыр килмәде. Безнең, авыл малайларының, күңеле икегә ярылды. Бер яртысы — дәһри, динсез, икенчесе әле һаман пакь һәм иманлы хәлендә иде. Могҗизага бик тә, бик тә ышанасы килә иде.

Дүртенче көн инде. Без капка төбенә өелгән бүрәнәләр өстендә утырабыз. Моннан догадагы ак әбиләр яхшы күренеп тора. Ә күктә исә сыңар болыт әсәре дә юк.

Дәһрилеге белән танылган ата коммунист, тәбәнәк буйлы, башын пеләшкә кырдырган, гомер бакый култык астына кызыл папка кыстырып йөрүче Гыйльметдин абзый безнең янга килеп утырды һәм:

— Юк эш, ишетер, бар, көт. Намаз укып, ураза тотып кына яңгыр чакырып булса, электән шулай эшләрләр иде. Гарәп чүле күптән гөлбакча булыр иде,— дип, җайлы-җайсыз сөйләнгәләп куйды.

Без эндәшмәдек. Мин генә, бераздан соң телгә килеп:

— Гыйльметдин абзый, шулай...— дип сүз башлаган идем, янымда утыручы абыем касыгыма шундый итеп төртеп куйды ки, сыным катты, телсез калдым.

«Бу баланы Алла сукты!»— дип, уйладымы, әллә үз сүзеннән үзе өректеме, Гыйльметдин абзый җәһәт кенә урыныннан купты, безгә карап куйды һәм ашыгып үз очларына таба китеп барды.

Ә без могҗиза көтеп кала бирдек. Күктә болыт әсәре дә күренмәде. Әмма өмет белән тулы җаннарны Гыйльметдин абзый вәсвәсәсе дә шактый чайкалдырган Һәм түккән иде. Күңелебез бозылып калды. Шулай сәерсенеп утырганда урам буйлап җен туен йөгертә-йөгертә җил үтеп китте. Ул тузына, кәгазь вә чүпләрне биеккә-биеккә бөтереп күтәрә, әле еландай нечкәреп югарыга ашкына, әле түбәнәеп, юанаеп китә.

Ишеткәнебез бар иде, мәгәре шушындый җен туена килеп эләксәң, күтәреп ала да, еракка-еракка илтеп, үтереп ташлый икән...

Без бүрәнәләргә ябыштык. Җен туе безнең яныбызга якын да килмәде, югары очка таба менеп китте. Әмма ул үзе артыннан яңгыр исе, дымлы һәм җиңел һава калдырган иде. Безнең сулышлар иркенәеп китте, авызлар ерылды.

Әмма ул көнне дә яңгыр булмады. Ак әбиләрнең дүртенче көн ураза тотып, эсседә, тау сыртында һаман да догада булулары сәбәпле, алар өчен күңелләребез сызлый иде. Теләкләре кабул булмас микәнни? Үтенечләренә күкләр колак салмас микәнни?

Югары очтан Абзалый абзый төшеп килә иде. Башындагы киез эшләпәсен салып, кесәсеннән ак чүпрәк чыгарып маңгаен сөртә-сөртә безнең янга килеп утырды.

— Хәлләр ничек, угланнар? — диде ул, күңелдәгесен теленә чыгарып.— Ра-

диодан бер дә яңгыр булыр дип әйтмәделәр. Игеннәр көя, басулар каралып килә икән. Болайга китсә, бәласе күп булыр,— дип, башын күтәрмичә генә сөйләде дә, утырган җиреннән торып, юлын дәвам итте. Юыла-юыла агарып беткән кәчтүм-чалбары, чалбар балакларын кыстырып куйган оекбашлары, йомшак башмаклары, киез эшләпәсе һәм дә кызу-кызу адымнары аңа бик килешеп тора иде. Әйтерсең лә йөзьяшәр карт ул.

Бүген көтү, ни сәбәптәндер, иртәрәк кайтты. Сыерны абзар астына куып керттем дә читән араларыннан әрекмән җыеп кайттым. Әнкәй:

— Кигәвен ашап бетергән малкаемны,— дип, йомшак тавышы белән иркәли-иркәли сыер сауды.

— И малкай, сөтең һаман кими, җәйләүдә дә тукланыр әйбер юктыр инде,— диде.

Мин аңладым һәм тагын әрекмән җыярга киттем. Ашасын әле.

Капчык тутырып кайтканда, кич иңгән иде инде.

— Күп бирмә, эче китәр,— дип әйтте әткәй.— Он ялатсаң иде аңа!

Малларга түгел үзебезгә дә он бетеп килә инде. Шунлыктан мондый сыйдан малкаебыз мәхрүм калачак. Мин моны аңлый идем. Аңа бераз әрекмән бушаттым да өйгә кердем. Йокларга вакыт җитеп килә иде инде.

— Бүген дә яңгыр яумас микәнни? — дип әйтеп куйдым мин чәй янында.

— Яңгыр җилләре искәли, булмас микән, төнлә явып китәр төсле,— диде әткәй, минем сүземне игътибарга алып.

— Яхшы булыр иде. Озакка китте бит,— диде әнкәй, әткәйнең әйткәннәренә кушылып.

Могҗизаны минем күрәсем бик килә иде. Чәйдән соң ишек төбенә, болдырга чыгып утырдым. Яңгыр җиле исеп куйды. Ерактан гөрелдәгән тавыш ишетелде һәм дөнья тынып калды. Минем күңелгә курку йөгерде. Нишләп ялгызым гына болай батыраеп утырам соң әле?! Абый әллә кайчан яткан бит. Өйгә кереп, юрган астына тәгәрәдем. Җылы, бик җылы иде. Изрәп йоклап киткәнмен.

Иртәгесен мин уянганда, кояш шактый биеккә күтәрелгән иде. Абый өйдә юк. «Бүген дә яңгыр яумаган икән!» — дип уйлап куйдым. Битемне юарга ишегалдына чыктым...

Чыктым һәм сәерсенеп калдым. Туйганчы, тәмам сеңдереп һәм гөрләвекләр йөгертеп, бөтен дөньяны суга батырып яңгыр явып үткән иде. Гүяки җир йөзендә барысы да алмаштырып куелган. Һава саф һәм чиста, кошлар шатланышып тавыш бирә, агачлар һәм куаклар кабаттан яшәү дәрте белән тураеп киткәннәр. Кичә сары булып күренгән урманга да бүген ямь-яшел иде.

— Һай, могҗиза!

Яланаяк кына урамга йөгердем. Бүрәнәләр өстенә басып, Әүлияләр тавы сыртын күзәттем. Анда кеше юк иде. Ак әбиләрнең догасы кабул булды бит!

Берничә көн рәттән килеп шулай яңгыр яуды. Хәтта кечкенә-кечкенә болытлар да авыл өстендә явыштырып китә торган булдылар.

Игеннәргә корылыктан шактый зыян килгән икән, шулай да аларга да яңгырның файдасы тиде, тәмам корып-янып бетүдән сакланып калдылар. Әмма дә бәрәңгегә шәп булды инде. Күкрәп үстеләр. Маллар да көтүдән тук кайта башладылар.

Доганың кайчан зыянга булганы бар? Ак әбиләр күрсәткән могҗизадан соң безнең — балаларның да күңелләре ныгып калды. Бу тормышта үзебезгә ышанычлы терәк барлыгын күрдек. Аны мәңге югалтмаска иде...

Бу вакыйгадан соң шактый күп сулар акты, дөньяда олы-олы кискен үзгәрешләр булды. Ак әбиләрнең күбесе инде ахирәткә күчтеләр. Әмма алар биргән сабак һаман да күңелемдә саклана минем. Аларга рәхмәтем зур! Әгәр дә ул ак әбиләрнең Ходайга ялваруы белән могҗиза булмый калса, хәлләр яманга, бик яманга чыгачак иде бит.

*1993.*

## СОҢАРГАН ОСТАЗ

*Тарихи хикәя*

Котбетдин әр-Рази хәзрәтләренең Сарайга килгәненнән алтынчы елында Үзбәк хан көтмәгәндә вафат булды. Шөһрәте белән уң-сулны дер селкетеп торган олуг тәхет иясенең кабергә керүенә үк мирасын бүлешү башланып, көннәр хәвеф эчендә туа вә бәндәләрне тетрәндерә башлады. Ханның Җанибәк белән Танибәк исемле угыллары арасында оят вә үзара хөрмәт хисе калмады. Бүген булмаса, иртәгә ике яктан да гаскәр күтәреп, ут уйнатып, кылыч айкап, бер-бер ахмаклык эшләп ташлыйсылар иде.

Котбетдиннең бәгыре көйде. Тирә-якта шөһрәтле вә мактаулы Алтын Урдада бара иде шул бу хәлләр. Әле кайчан гына Танибәк аның каршында тез бөкләп дәрес ала иде. Зирәк вә сизгер булуы белән сокландыра торды. Хәзер остазы сүзенә колак та салмый, киңәш-табыш та итми башлады. Угланнар ут белән генә түгел, тәхет вә баш белән дә уйный иделәр, аңлаган кеше генә моның нинди аяныч хәлләрдән икәнлеген сизенеп тора.

Иделдә боз соңарып күтәрелде, сулар каралып ташыды. Җәй башларында су улаклардан басуларга йөгерде, буа һәм ермакларны бүсеп чыкты, иңкүлекләрдәге чәчүлек җирләр ташкын астында калды. Болгар иленнән арырак көнчыгышка таба җәелгән нугай башы җәйләвендә Агыйделгә килеп кушылган Чулман дәрьясы хакында исә “хәтәр күперде” дип сөйләде сәүдәгәрләр. Элек бу вакытларда базар кайнап тора иде инде. Быел Гыйрак, Һират вә Рум ягыннан сәүдә кораблары килә алмады. Кәрвандагы бер дөя хакы, былтыргы белән чагыштырганда, унына бәрабәр тора башлады. Бәркә ханнан бирле урнашып калган кануннар какшады. Бигрәк тә салым вә ясак күләме артты, хак вә бәя үсте. Халык арасында “казнаны Танибәк талап, Җаек суы артына качкан икән” дип сөйләделәр. Җанибәк исә аның иярченнәрен аулады. Котбетдин үзенең дә исемлек башында торганлыгын аңлады. Үгет-нәсыйхәт биреп, сөекле укучысы Танибәккә ярдәм кулын сузмакчы булды. Ут белән уйнамасын, күңелен тындырсын, абыйсы Җанибәк белән дуслашсын, диде!

Инде икенче кичәне Котбетдин әр-Рази шигырь язуга, бәетләр тезүгә багышлады. Төрки вәзен белән шигырь төзү аңа җиңел вә рәхәт иде. Бала чактан күңеленә сеңеп калган угыз теле аның анадан килгән мирасы булып, фарсы вә гарәп исә үзенең иҗтиһат җимеше иде бит. Ничәмә-ничә тарихи, дини вә фәлсә-

фи дәфтәр һәм китапларны гарәптә, кайвакыт фарсыда төпләгән, теркәгән, төзәткән олуг остаз өчен кабаттан төркигә кайту ничектер күптән хәтереннән чыккан бала чагын күңелендә яңарттырды. Яратып укыган әсәреннән берсе Низами хәзрәтләренең «Хөсрәү вә Ширин» дастаны иде. Шушы борынгы тарихи язмышлар белән Алтын Урда хәлләренең тәңгәллеген күреп, Котбетдин әр-Рази башта курка калды, аннан соң бу хакта шәкерте ханзадә Танибәккә аңлату кирәклеген төшенде. Искәндәр Зөлкарнәйн хәзрәтләрен голамәи Ариста рухи азык белән тукландырып, ничек итеп илаһи каһарман ясаган булса, Котбетдин дә Танибәкне шул рәвешле шәхес дәрәҗәсенә күтәрергә өметләнде. Әмма Танибәк вак җанлы, артыгы белән кайнар һәм киңәштән үзен өстен саный торган шаһзадә иде шул. Алай да зирәк һәм эшлекле булуы сәбәпле, остазы күңелендә аңа ышаныч вә сөенеч тә яши бирде. Боларны уйлап, Котбетдин авыру кешегә ярдәм кулын сузмаган табип кебек сизде үзен.

Җәй уртасы җиткәндә Котбетдин дастанны тәмам итү алдында иде. Җәйләүгә чыккан Сарай шәһәре таифәсе шаулашып, тузан күтәреп, кубарылып кире кайта башлады. Барчасының да күңелләре кузгалган, күзләре аптыраш вә хәерсезлек белән акайган иде. Тәхетен Җанибәк ташлап качты дигән хәбәр тиз арада таралып өлгерде. Шәһәрне Танибәк урдасы камап алган иде. Сарай сугышсыз бирелде. Тәхеткә менеп утырган яңа ханны котларга бай сәүдәгәрләр һәм галим-голамә кичкә таба җыела башлады. Танибәк тәбрик сүзе белән килгән Котбетдинне дә кабул итте. Остаз һәм шәкерте шаһзадә очраштылар.

— Йа остазым! — дип фәрман кылды Танибәк хан.— Син хәзер миңа нәрсә әйтерсең?

Котбетдиннең акылы кайнады, күңел кошы күкрәк читлегендә бәргәләнде. Ничек җавап бирсә дөрес булыр икән?

— Син минем тәхет каршында булырсыңмы? — диде шаһзадә, үзалдына канәгатьлек табарга теләп.

Озакка сузарга ярамый иде. Котбетдин әр-Рази әле ахырына кадәр ирешмәгән дастанны аңа сузды:

— Бу сезнең игътибарыгызга тәгаен кылынган иде,— диде ул, түбәнчелек белән.

Танибәк хан каләм иясе Бәркә Фәкыйһка ым какты. Тегесе җәһәт кенә Котбетдин кулыннан дәфтәрне алды һәм укый башлады. Аны хан түземсезләнеп бүлдерде:

— Кирәк җиреннән укы!

Бәркә Фәкыйһ буйсынды, Аллаһы тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм сәхабәләргә дан җырлау урыннарына күз йөртеп кенә узды да, үз табышына сөенеп, Танибәк исеменә аталган юлларны укып китте. Ханга шушы кирәк иде.

— Бүләгең белән олыладың, тугрылыклы булуың өчен сөендерү ләзем булыр үзеңне,— диде Танибәк, яшь йөзенә ирлек төсе чыгарып.

— Ханым, дастан әлегә ахырына ирешмәде,— дип өстәде аңа Котбетдин. Бу сүзләре бал тәпәненә дегет кашыгын китергән кебек булса да, яшь хан үзен бөтенләй башкача тотты. Әллә олыларча уйлый алмый иде, әллә остазына хөрмәте зур идеме?

— Хәзергә монысы да җитәр! Тәмамын көттермә, вакытны аз талап ит, ки-

чәләребездә укып сөендер!— дип белдерде ул.

Котбетдин шул рәвешле Сарайда калды. Язылган һәр бүлекне хан тыңларга ашыкты. Әмма Җанибәкнең, тәхетне даулап, ауга киткән җиреннән олуг гаскәр белән кайтып килгәнлеге беленде. Шәһәр халкы Танибәк ягыннан Җанибәк тарафдарына әверелде. Сарай бушап калды. Танибәккә бер чара бар, ул да булса — тәхетне ташлап качу иде.

Бу хәл Котбетдинне тетрәндерде. Дастан язу белән артык мавыгып, Хөсрәү белән Шириннең мәхәббәт тозакларын сөйләү белән дәртләнеп, тормыштан артка калган, хакыйкатьтән читләшкән икән шул ул. Бу вакытта әсәре Фәрһаднең Ширингә гыйшкын сурәтли иде.

Хәбәрне аңа Танибәкнең бахши-кәтибе Бәркә Фәкыйһ китерде. Тизлек белән җыенырга һәм Сарай таифәсе белән кузгалырга кирәклеген хан фәрманы буларак җиткерде. Котбетдин монда кала алмый иде.

Танибәк хан йорты белән бергә Җаек ягына таба кузгалды. Җанибәкнең Болгар иле белән куа килүеннән өректе ул. Җаек буендагы Алатау җәйләвенә чатырлар корып урнаштылар. Котбетдин, киңәш тотып, ханның катына барды, әмма кабул кылынмады. Хәле авыр, диделәр. Ә чынлыкта Танибәк, үз туганы Җанибәктән хурлыклы рәвештә сугышсыз качуыннан соң, остазының күзләренә туры караудан ояла һәм үз йөзеннән үзе чиркана иде. Котбетдин моны аңлады. Кире кайтып, дастанны төгәлләү эшенә кереште. Әмма уе буталып, кулыннан каләме төште.

Иртәгәсе көн барча ил-йорт халкы бер хатынның ачыргаланып кычкыруыннан шаша калды. Күкрәгенә хәнҗәр кадалган хәлдә Танибәк урын өстендә канга батып ята иде. Тәненең суык булуыннан аның инде төн урталарында ук үтерелгәнлеген һәркем аңлап алды. Үтерүчеләрне куа чыгарга соң иде.

Тарих кабатланды. Хөсрәү ничек мәкерле һәлак ителсә, Танибәк тә Җанибәк ханның шымчысы тарафыннан шулай үтерелде. Котбетдин әр-Рази үзенең укучысы шаһзадәгә “Йәсин” чыкты. Күзләре яшьләнде һәм башка һичвакыт сарай тирәсендә кайнашмаска сүз бирде. Аңа хәзер бу илдә калырга ярамый иде. Гыйракка — үзенең туган иленә, төбәп юлга төште. Артыннан тансык дала җиле куа килде.

Хәзер кая бара? Кемгә килә, аны нәрсә көтә? Берсе дә билгеле түгел. «Хөсрәү вә Ширин дастаны» инде тәмам булды. Аны да бар китаплары белән бергә бахшигә тапшырды. Танибәккә үгет-нәсыйхәт, киңәш-табыш бирәчәк әсәре хәзер инде аталган кешесе колагына барып ирешмәс. Бу — остазның тарихларны айкап йөрүе аркасында соңаруы иде.

## ШАҺЗАДӘ СӨҺӘЙЛ

*Тарихи хикәя*

***Алтын Урда шагыйре Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанына 600 ел тулуга багышлана. (1394—1994)***

Ханнар өчен дә җәза кадерсезлек икән. Моны Алтын Урда хөкемдары Туктамыш хан яшьлегендә аңлап, балаларына рәхәт вә бәхетле тормыш бүләк итәргә һәрвакыт әзер булып яшәде. Ул бигрәк тә улы Сөһәйлне артыграк ярата төшә һәм аның өчен җан ата иде. Һәм менә бу сөекле шаһзадә, тәрбияче-инәкәйләре куенынннан чыгуга, ат өстенә утырды, көннәр буена сахра вә далаларга китеп югала һәм ни эшләп йөрүләре хакында хәбәрен дә бирмичә, угланнар белән елкы уйнатып, сунарчылык вә аучылык кылып, ил эчендәге кавем-кабиләләрнең гореф-гадәтләрен дә санга сукмыйча, рәнҗеш җыеп йөрүчегә әверелгәләде. Бу хакта олуг хан ишетә калса, җаны калтырап, кимсетелгән бәндәсен дәштерә, баштарак бүләк биреп, ярлыкау үтенә, соңрак зиндан яисә чыбык суктыртып җәза кыла башлады. Әмма улыңа бер генә дә яман күз карашы ташламыйча, киресенчә, аны үзенә дәштереп бүләкли һәм яратып сөя торган иде. Моның сәбәпләрен Сөһәйл аңламады, шулай кирәк дип кабул итте. Бүген газиз әткәсе аны алтын йөзекле итсә, иртәгә аңа яхшы ат, берсекөнгә күннән тегелгән ияр бирде. Болай да сараенда басып йөргән җире яхшы келәм, кигәне йомшак ефәк күлмәк-чапан булуга карамастан, ул барыбер дә үзен ул әйберләргә мохтаҗ итеп хис итте. Йөзенең күркәмлеге, буй-сынының арада бер булуы аның кадерен Сарайда гына түгел, ил эчендә дә таныткванлыктан, масаючан егетне шул сыйфатлары һавалы халәт эчендә акылсызлык кылырга этәрә, җитмәсә гади шаяртулардан башлаган эше-фигыле дә көлкедән узып китә иде. Ул гомерендә бер мәртәбә дә йөрәген мәхәббәт хисенә төрмәде, киресенчә, үзенә биһуш кыз вә хатыннарның дәрте эчендә чәчәк төсле иркәләнде, теләгәндә җимеш өзде, теләмәгәндә, сытып, читкә ыргытты.

Уналты яше тулганда Сөһәйл, арадан бер шаһзадә булып, зур гына мәҗлес кордырды, җарияләрне бакчасындагы агар сулар тирәсендә биетеп, башка төр ханзадәләр белән шагыйрь һәм җырчыларның моңлы, дәртле сүзләре вә көйләреннән рәхәт чигеп, юлбарыс тиресе җәелгән тәхет өстендә бер-бер артлы татлы шәраб савытларын бушатты. Ахырында тәмам исереп, кунакларының өстенә эчемлек сибә, алардан көлә башлады. Шул вакытта бәйрәм табынына олуг хан — әткәсе Туктамыш, үзенең вәзирләре белән килеп керде һәм улының кыланышларына хәйран калды, гарьлегенә түзә алмады, китерткән сугыш аты, аның өстенә салынган җөбә, сөңге, калкан кебек ханнар гына кия-йөртә торган кием вә коралларын бүләк итәргә дә онытып, мәгърур авазлар белән арага тавыш салды:

— Шаһзадәләр эшеме бу, Сөһәйл?!

Егет аңламады.

— Һай, әткәем килгән,— дип, Туктамышка таба шәраблы тустаганын тотып якынлашты, абыныпмы, әллә аякларын төз баса алмыйчамы, чалынып, олуг ханның чапанына эчемлеген түкте, үзе әтисенең биленә асылынып калды.

— Йа газиз ата...

Сөһәйлне бакчадан күтәреп чыгардылар. Олуг хан, тән-җаны калтырап, аны фәрманы белән озатты.

— Күземә күрсәтәсе булмагыз!

Борылды, чыгып китте, барлык сарай таифәсе аның артыннан иярде. Янбаш капкага җиткәндә Туктамыш бераз тукталып торды, ниндидер сүз әйтергәме те-

ләде. Олуг йөзендә акыл нуры пәйда булып:

— Иртәгә тәхет каршысына китерерсез, бүләкләремне калдырыгыз!— дип теләгән җиткердe, бәйрәм рәхәтенә чумган җырләреннән хан вә улы арасындагы кыен хәлгә шаһитлык иткән халыкка борылып, уң кулын алга сузды, бармакларын салындырып, йөзеклесен күтәрә төшеп кенә: — Таңгача мәҗлес өзелмәсен, әмер ирешер!— диде дә китеп барды. Авыр хәрәкәтләре вә балдак-беләзекләренең ялтыравы һәммәсенең хәтеренә сызылып, сүзләре күңелләрен кузгатып калдырды.

Иртәгә ни буласын һичкем белмәде. Сөһәйл өч көн авырды. Олуг ханга һаман да бер сүзне китерделәр:

— Улыгыз зур бәйрәмнән соң зәхмәтләнгән.

Моңа Туктамышның башта ачуы килде, әмма сарай өлкәннәре ашыкмаска киңәш иттеләр, кабаланып эш бармасын төшендерергә тырыштылар. Көннән-көн олуг ханның күңеле суына, үзе дә моны сизеп, улына кирәгенчә хөкем чыгара алмавына аптырый, ялгызы калганда:

— Һай, улым, алай ук ярамас иде дә бит,— дип хафага төшеп, күзләрен кулы белән каплый торган булды.

Зәхмәт Сөһәйлнең җанын тоткынлыкта озак богаулады, җибәрми торды. Аңа аталган дәрвиш табип Җәлалетдин, тәрбия кылып, баш калкыткан чакларында шаһзадәгә аз-азлап шәраб каптырмаса, казаланасы да иде, әмма гомере киселер сәгате җитмәгән бәндәсен Аллаһы тәгалә ташламады. Бик үк яхшыга булмаса да, егетнең бәхетенә күрә хәлләр үзгәрә бардылар.

Улы Сөһәйлне олуг хан оятлы кылган кичеңдә Мәскәү тарафына сөрмәкче дә иде, Тафтазани хәзрәтләреннән дәрес алган мулла Хәсән белән киңәш тотканнан соң, ул уеннан кайтты.

— Азгын уйнашчылар озатыла торган кяфер иленә шаһзадәне җибәрү дөрес эш кебек күренми. Аны да шул бозыклыкта гаепләүләре бар. Ил күзе күрмәсә дә, теле сөйли белә. Халык алдында Сарай өстенә бинахак кара төшүе мөмкин,— диде Туктамышка мәртәбә иясе җиз сакаллы галим.— Үзеңне үзең хөкем итү кебек эшләрнең берсе бит бу, ашыгуны шәригать өнәми!

Икенче бер утырыш-сөхбәтендә олуг хан кабат шушы мәсьәләне кузгатты, Сөһәйлне Үргәнеч шәһәренә хан итеп җибәргә, бәйрәмнән соң тагын да кунак буларак шаһзадә сараенда тоткын ителгән барча мәҗлестәшләрен үзенә ияртеп озатырга теләге барлыгын белдерде. Галим исә моның дөрес хөкем булуы белән килеште һәм:

— Харәзмдә Хәким атаның ике угылы әүлиялек юлын таптылар. Үргәнеч шул олуг шәһәрнең нигезендә корылган бөек каладыр. Шаһзадә дә анда мәртәбә табар. Әмма шикләнермен: Чыгтай иленә бик якын тора, Аксак Тимер хөкемдарның тозагына барганын ишетеп-күреп беләсез. Хәвефкә тармассызмы? — дип әйтеп, шиген дә яшерә алмады.

— Безнең мәмләкәтләр — кан-кардәш илләрдер. Халкыбыз да, телебез дә, иманыбыз да бер. Нидән Үргәнеч өстенә карендәшем йөрер икән?

— Аның өчен Үргәнеч түгел, Сарайның да кирәк булуы бар. Якын-тирә кан-кардәшләренә яу чапты, дин вә гамәлләре дә, телләре дә бер иде...

Монысын Туктамыш бер дә галиме авызыннан ишетермен дип көтмәгәндер

күрәсең, киңәшен кабул итмәде, теләген үзгәртергә уйлап та карамады.

— Үргәнеч, ни хикмәт, Сарайдан читләшә бара. Сөһәйлнең анда булуы ике якны якынлаштырыр, фикерләрне берләштерер. Аны Үргәнечкә тәрбия өчен җибәрүем белән ике куянга берьюлы атармын, ике сунарны бергә алырмын!

— Теләгегез, йа олуг хан! Сезнең фәрманыгыздан узып илегездә һичкем йөри алмый...

Туктамышның кәефе богауланды, йөзе тартылды.

Бу рәвешле авыр халәтен күреп торудан күңелгә курку гына төшә. Тафтазани шәкерте үзен гаепле сизде. Күтәреләсе, моннан чыгасы килде. Бәхете бар икән. Өйлә намазына дәшкән азан яңгырады. Манара башыннан нәзек тавышлы мәзин сузып-сузып кына еламсык аваз салды:

— Хай-йә гаа-лаа фәә-лаах... Хай-йә гаа-ләә фәә-лаах!..

— Намазга кузгалыйк, йа хәзрәт! — дип әмер йөртте Туктамыш.

Алар олуг хан вә таифәсе өчен махсус төзәтелгән Җамигь мәсҗедкә таба чыга торган ишеккә юнәлделәр. Хезмәттәге гаскәриләрдән капка вә тәртип сакчылары аяк өсте генә фарызны үтәгәннәренә игътибар да итмәстән баскычка атладылар. Эчке якта затлы халык инде сәҗдәгә киткән иде...

Сөһәйлне атнакичендә иртә белән юлга озаттылар. Аны илчелек башы ясап, Әхмәд-Бахши олуг хезмәтчесе кылынды. Үзе Үргәнеч шәһәреннән булып, Сарайда хан боерыгында торган бу шагыйрь олуг вазифа табуы белән бәхетле кылынды. Күзләреңдә энҗедәй яшьләрен пәйда итеп:

— Хезмәтем белән мәңге сөендерермен, улыгызга вә тәхетегезгә тугрылык күрсәтермен! —дигән сүзләрен кат-кат әйтте, әмма Туктамыш:

— Морадыңны хасил кылсын Хак тәгалә,— дигәннән артык сүз әйтә алмады. Болардан шул аңлашылды: арада тагын да бер ышанычлы кешесе бар һәм Сөһәйлнең бар гамәлләрен әткәсе Туктамышка хәбәр итеп торачак ул!

Шаһзадә иреккә чыкты. Ул олуг хан улы буларак һәр җирдә кабул ителәчәк. Җитмәсә газиз атасы аңа барлык уенчыларын һәм җарияләрен, сөт анасы-дайә вә тәрбиячеләрен, янәшәсендә һәрвакыт җан атып торган дусларын вә угланнарын ияртте. Алар затлы вә мәртәбәле гаскәр белән һәм дә хан кебек олы мәртәбәдә хәрәкәтләнделәр. Хәтта Туктамыш үзе дә бу рәвешле итеп сарайдан чыкмады. Егетнең горурланырлыгы бар иде. Ил-суларын кичеп, башта кыйбла ягына, аннан Көнчыгышка таба төбәп киттеләр. Бәйрәм кичәсендә атасы бүләк иткән ак айгырга затлы киемнән менеп утырган Сөһәйл олуг таифәнең әле артына, әле алдына төште, угланнарын барлады, теге-бу әмерләрен бирде һәм якыннары белән сул канатка чыккач, Әхмәд-Бахшины сәфәр башы итеп билгеләде дә егетләренә дәште:

— Сахра җилен сагындым, ау уйнап, ат йөгертик!

Егетләргә шул сүз җитә калды, һай-һайлап иярләреннән күтәрелделәр. Ул да түгел, Сөһәйл үргә таба атын куды, башкалары аңа иярде һәм юк та булдылар. Әхмәд-Бахши җитәкчелегендәге кәрван ялгызы мең бәла белән Үргәнеч юлы буйлап баруын дәвам итте, һәртөрле юлбасар төшсә, эшләре харап иде, корал тотарлык һичкем калмады.

Ханнарныкы ханнарча шул. Шаһзадә угланнары белән унбиш көннән соң гына кәрванга кайтып кушылды. Егетләре дә, үзе дә шактый гына кәефле, җит-

мәсә ияренә каплан тиресе салган иде ул. Илнең олуг затларына кунак төшеп, теләгәндә кош атып, нәфсе төшкәндә җәнлек аулап йөргәннәр.

Әхмәд-Бахши аның каршына җавап тотып килде, ат өстендә килеш кенә:

— Өч җарияне зәхмәт алды, сөт анаң да төп йортка күчте, урыннары җәннәттә булсын,— дип, исәнлек-саулык сорашканнан соң, хәлләрне бер җөмлә белән хәбәр итте.

Сөһәйлнең исе дә китмәде:

— Йа илаһи амин! — дип дога япты да шуның белән бетте.

Сарайдан чыкканда нинди диңгез вә чүлләрне кичәрлек күренгән кәрванның төсе уңган, дәрте киткән иде. Шаһзадә исә боларның барысын да, шулай кирәктер инде дигәндәй, җан җәрәхәте аша үткәрми генә кабул кылды, юлны дәвам итәргә боерды.

Үргәнечкә барып ирешкәндә көннең саны, яшәүнең мәгънәсе беткән төсле иде, ләкин халыкның гына түгел, хәтта олы-кече хан вә ханшаларның да яратып каршы алуларыннан барчасының бердәй кәефе күтәрелде. Кече ил тәхетен тоткан, Җүчи хан нәселеннән булган Йосыф ханның Сөһәйл хакында күп сүзләр ишеткәне генә түгел, Туктамыштан алынган фәрманы да бар икән. Шаһзадәгә мөмкин кадәр хөрмәтләрен күрсәтеп, ул да ике куян койрыгына тигез басарга юл эзләде. Бердән, Сарай каршында ышаныч казанса, икенчедән, унөч яшьлек гүзәл кызы Гөлчәһраны шушы асыл кошка ярәштереп, бәхетле итәргә ниятләде. Сөһәйлнең Йосыф Кингани сыйфатлы чибәрлеге, олуг зат булуы аны мең кат сөендерде һәм дә, барлык исәп-хисапларын онытып, егет аяк астында тузан халәтен табарга әзер торды. Әмма йолдызларның хәрәкәте хәвефкә тартты, шаһзадәнең килүенә атна үтте, кирәкле сый-хөрмәтне күрде дияргә дә өлгермәделәр, Аксак Тимер гаскәрләренең Үргәнечкә турылап килүләре хакында хәбәр иреште.

Сарайдан тиз генә ярдәм җитешмәячәк. Ханлык, Аллаһы тәгаләгә таянып, үз көчләре белән генә булса да каршы торырга сүз беркетте. Кораллы-коралсыз, олуг-кечек бәндәләр гаскәргә чакыртылды. Туктамышка җибәрелгән хәбәр әйләнеп кайтканда, андагы сүзләр улы Сөһәйлне кире Сарайга таләп итүе белән башланып китү сәбәпле, Йосыф ханның үте сытыла язды:

— Куркак!

Бу сүз шаһзадәне дер селкетте, ике дә уйлап тормастан:

— Мәмләкәт тәненә кылыч кадалганда мин ни өчен читтә калыйм ди әле! Угланнарым монда. Сугыш атым вә киемем монда! Мин Үргәнеч өчен көрәшергә әзер! — дип, үзенә махсус атап ясатылган тәхеттән сикереп торды һәм барчасын да Аксак Тимергә каршы аяусыз көрәшкә дәртләндерә башлады. Аның бу кыяфәтенә шаһит булган кешеләр бер-бер баһадир икәнлегенә шикләнмәс вә Гали Арысланга тиң куяр иделәр. Әмма күп хәлләрне вә затларны күреп белгән Йосыф ханның сарай таифәсе яшь җилкенчәкнең бу дәртле сүзләреннән генә эреп төшмәделәр. Аксак Тимер яулары хакында ишеткән-тойган халык өсләренә ишелеп килгән казадан җиңел генә котылып булмасына хәйран иде. Мәгәрем ки Туктамыш угылы Сөһәйл шулай каршыларында утырмаса, сугышсыз гына бирелү җаен да белдереп сүз кузгатучылар күптән табылыр иде. Әмма алар чарасыз, ике ут арасында. Бердәнбер юл — сугыш, мәрхәмәтсез-кан-

лы сугыш. Аннан кем исән чыгар да, кайсылары анда үлеп калыр? Ходай белсен...

Кояшлы, салкынча иртәнге һаваны тетрәтеп ишетелгән сугыш быргысының канлы тавышы Үргәнеч шәһәрендә яшәүче тыныч халыкны өркетеп җибәрде. Намаздан әле кузгалган мөэминнәр илереп йөгерешә башладылар. Ныгытма диварлар янына Аксак Тимер гаскәрләренең илчелеге тираннан солых хаты китергән иделәр. Йосыф хан аларны кабул итәргә әмер бирде. Җиһангир исемен тәкрарлаган тиранның ирләре үзләрен тыныч тоттылар. Аларның: «Без кем?» — дип сөйләүләреннән үк артларында олуг гаскәр барлыгын аңларга мөмкин иде. Илчелек Үргәнечнең сугышсыз бирелүен таләп итте, Туктамышның җиңеләчәген, үзләренең көчле икәнлеген белдерде. Солых бәһасе бик авыр вә шәһәр өчен алты йөз көмеш акча, кәрван-кәрван постау вә парча кебек һәртөрле затлы тукыма, сугышчы ирләр, атлар, мал-мөлкәт, иген һәм башка азык-төлектән олаулар бәрабәренә булып, сүз ахырында хан торыны Сөһәйл соратылган иде. Үргәнеч киңәш тотты. Җан башына болар шактый күп икәнлеген һәркем аңлады. Солых кабул ителмәде. Сугыш быргылары кабат канлы авазларын чыгарып, кемнәрне орышка дәртләндерде, кайсыларның болай да чыгар хәлгә җиткән җаннарын өркетте. Әмма бәрелеш булмый калды. Аксак Тимернең илчелеге Үргәнеч капкасына кабат килеп туктады, эчкә узмады. Каршы алырга чыккан гаскәр башлыгы, баһадирлыгы белән танылган олуг ир Талипҗан, кулына Җиһангирнең таләп хатын тотып, кире чигенде. Ике арада сугыш быргылары уйнаудан тукталды. Иртәгәге көнгә кадәр бәрелеш булмаячак иде.

Сараена хан барча өлкәннәрен җыеп киңәш тоткан чагында җиһангирнең таләп хатын китерделәр. Ул моны укып чыкты. Йөрәге кысканын тойды, куллары салынып төште. Күзләрендә кайгы караңгылыгы иде.

Идән уртасына төшкән хатны Сөһәйл кулына алды, укырга кереште, хәтере калды. Аксак Тимер үзенең җиңәчәгенә һичшиксез ышана, баш бирмәгән Үргәнеч җир белән тигезләнеп, өстенә арпа чәчеләчәк, диелгән. Галимнәр, картлар, яшь балалар, аналар вә кызлар кала эченнән чыгарылсын, аларның һәлакәте өчен юкса Йосыф хан намусы белән җавап бирәчәк икән. Алдагы солых хатының ахырындагы кебек үк Сөһәйлне үзенә таләп иткән. Җавапны бүген көннең ахырында китерергә әмер бирелгән.

Сөһәйл хатны укыганда Йосыф хан да зиһенен җыеп өлгерде, олуглар каршында ачу вә гайрәт белән сикереп торды һәм дә әйтә куйды:

— Аксакка Үргәнеч өстеннән әмер йөртергә иртәрәк әле! Кемнәр үзләренең бер көнлек җаннары өчен калтырап торалар, шәһәр эченнән чыксыннар! Рөхсәт бирәм. Кемнәр газиз Ватаннарын саклап калырга вә аның өчен көрәшергә әзер, мин алар белән яуны кабул итәм! Йа олуг хан Сөһәйл, язмышыңа мин хуҗа түгел. Теләсәң, безнең арада кал, кирәксә, Аксак хезмәтенә күч! Мин сугышка әзер!

Гүяки шушы сүзне генә көткән Талипҗан баһадир мәҗлесне ташлап чыкты. Гаскәрләрнең тезелүен таләп иткән быргы авазы шәһәр эчен айкап узды. Бу хәбәр Аксак Тимер яуларына кадәр барып ирешүдән соң, ныгытма-дивар капкалары ачылып, Үргәнечнең көньяк-көнчыгыш тарафына Йосыф үз көчләрен бәрелешкә дип тезә башлады. Үзенең угланнары белән баштанаяк тимер вә күннән

киенгән Сөһәйл дә каладан чыкты. Аның янындагы ирнең кулында Алтын Урда туграсы чигелгән байрак-тута, йөзләрендә битлек иде. Ак атка атланган шаһзадәнең күкрәгендәге олуг калканчага ак барс сурәте төшерелгән һәм олуг хан туграсы сугылган иде. Аны үз араларында күрүгә, гаскәриләр бер дәрт белән «ура!» авазын салдылар, йөзләрендә сугыш алдыннан сирәк була торган сөенеч балкышы күренде. Көч вә гайрәтләренә игътибар итмәү мөмкин түгел, алар җиңәргә тиеш иде.

Кич вә төн хәвеф-хәтәрсез узды. Гаскәр башлыклары сугышка әзерләнде. Түмән — йөз-башларга, йөз-башлар исә ун-башлар белән кайчан вә ничек һөҗүм итү мәсьәләләрендә, уртак фикерләргә килеп, дошманнарның мәкереннән саклык чаралары күрделәр. Станда чатырлар корып, учаклар тергезделәр. Аксак Тимердән бер хәбәр дә ишетелмәде.

Йосыф хан илнең олуглары белән кала эчендә төнен уздырды. Иртә намазы укылып, кояш чыга башлаган вакытта көньяк-көнчыгыш тарафыннан да, төньяк-көнбатыштан да сугыш быргыларының нәгърасы кызыл шәфәкъ балкышына асылынып калды. Аксак Тимер гаскәре ягыннан коточкыч иңрәү авазы килде. Бу исә сугыш филләренең үкерүе вә аларның һөҗүмгә керү билгеләре иде.

Үргәнеч манараларына менеп тамаша кылган олуглар хәйран калдылар. Аксак Тимернең шушы кадәр көчләр белән киләчәген уйларына да китермәгән иделәр. Меңнәрчә атлы вә җәяүле гаскәрләр алдына бастырылган сугыш филләре бар нәрсәне изеп-сытып бетерергә әзер булып, үзләре генә дә Үргәнечне җимереп китәчәк, моңа һичкем каршы тора алмаячак иде. Әле көрәш башланмаган, әмма кул күтәрергә иртә.

Яулар бер-берсенә күзгә-күз карашып бастылар. Сугыш быргылары оран салды. Ике як та: «Аллаһү әкбәр!» — дип кычкырышып, юлбарыслар төсле йөзгә-йөз ташландылар. Филләрен йөгертеп, Аксак Тимер явы, Үргәнеч гаскәрләрен чигендерә башлап, изә-сыта килә иделәр. Сөһәйл үз угланнарына әмер бирде, кайсы сөңге, кайсы кылыч айкап үлемгә ташланды. Күк йөзен караңгы болыт каплады, колакларда кылыч-калкан тавышы, филләр үкерүе, атлар кешнәве, гайрәтле баһадирларның аһ-уһ килеп куәтләнүләре, мөселманнарның берсенә-берсе: «Аллаһү әкбәр!»—дип ташланулары колакларда тоныкланып, борын вә авызда кан вә тузан исеннән гайре нәрсә юк иде. Бу көн мәхшәр көне, мөэминнәрнең бер-берсенә кылган мәрхәмәтсезлек көне иде. Моның өчен алар хөкем ителерләр, изге канунны бозып, үзара сугышканнары өчен җәзага тартылырлар, әмма хәзергә ул хакта уйлый алырлык хәлдә түгел алар. Йа җиһангир, шушымы синең изгелек кылуың?

Сөһәйлгә Олуг хан тутасы вә күкрәгендәге туграсы көч бирде. Ни хикмәт, каршысына килүче яуның гаскәриләре аны күрүгә читкә чыга, өстенә кылыч күтәрми, бәлки аның коралыннан кача вә чигенә иделәр. Егет моның асыл мәгънәсен төшенә алмады, әмма гайрәт күрсәтеп һаман да һөҗүм итүеннән туктамады. Тик эше кылычка-кылыч сугудан вә бушка болганудан узмады. Бу хәл шаһзадәнең ачуын тагын да кабартты. Ә үзенең хәле бетә барды.

Гөлчәһра иптәш кызлары белән манарадан сугыш манзарасын күзәтеп тора һәм аяусыз егетләрнең батырлыкларына түгел, бәлки Сөһәйлнең гаскәрләрне ерып керүенә сөенеч вә куаныч белдереп аһ ора иде. Беренче карашка Үргәнеч

ягы өстен дә чыккандай күренде. Менә-менә Аксак Тимер чигенә башлар, сугыш кырын ташлап качар төсле иде. Әмма ни хикмәт, эш киресенчә барып чыкты. Дошманнар саны арткannан-арта бирде. Үргәнеч ягы камалышта кала башлады. Ничә көннәр Гөлчәһраның бәхетле күз карашларында иркәләнгән, кызның өмете вә мәхәббәте булган Сөһәйл дә күздән гаип иде. Аһ орган җанашларның дәрте шыңшу белән алышынды. Кемнәр елый, кайсылары үкси үк башлады. Аксак Тимер гаскәрләре Үргәнеч диварларына таш вә ут ата һәм җимерү-җимертү эшенә керешкән иделәр. Шәһәр өстен сугыш кырыннан килгән караңгы тузан вә янган йортларның төтене каплады, кан исеннән мал-туар, сугыш ачысын моңа кадәр татымаган яшь-җилкенчәк шашынды, һушын югалткан кызларны вә затлыларны салкынча һавалы җир асты бүлмәләргә төшерделәр. Гөлчәһра шунда гына аңына килде. Аның беренче сүзе шул иде:

— Сөһәйл?..

Һичкем бер сүз әйтмәде.

Гайрәт белән кылыч айкап дошман уртасына узган Сөһәйлне, артыннан аркан ташлап, атыннан ектылар. Кем икәнлеге хакында хәбәрдар иделәр булса кирәк. Авыр киемдә җиргә бәрелүдән кулы вә маңгае җәрәхәтләнде, битенә юл-юл булып кан акты, тузан белән укмашып, төсе китте. Аны шушы хәлендә җиһангир каршына китерделәр. Аты, кылыч вә калкан кебек әйберләре дә монда иде. Аксак Тимер ачулы тавыш белән эндәшә куйды:

— Эттән туган көчек!..— диде.

Сөһәйлнең күзләре ялтырады. Иңгә-буйга бер чамадарак булган, озын күзле, арыслан йөрәкле ирләргә генә хас катгый йөзле бу кешенең битенә төкермәкче дә иде, курка калды.

— Тезләнн!..

Арттан тез артына суктылар. Сөһәйл алга ауды. Тиран, канәгать елмаеп:

— Көч-чек!..— дип үртәде.

Туктамышның улы икәнлеген туграсыннан танып белә иде ул...

Әсирләрне кәрван янәшәсендә ком сахрасы буйлап сөрделәр дә сөрделәр. Кая баралар, кайчан һәлакәт табалар — боларын һичкем белми, алдарак ничек тә исән калганлыкларына сөенсәләр, инде сусызлыктан вә ачлык газабыннан аларның күңелләре дөнья рәхәтенә караганда Аллаһы тәгалә күркен өстенрәк күрде. Үле гәүдәләрне читкә ташлап бардылар, сөякләрен шакаллар җыйгандыр инде...

Кала капкасына җитеп килгәндә, дивар-ныгытма өсләреннән һәм аларга җавап буларак тоткыннарны китерүче гаскәр эченнән торба-быргылар үкертеп сәламләшкәнлекләре сәбәпле, бу гадәтне тәрсә-яһүди кыланмышыннан кабул иткән Алтын Урда мөэминнәре, Аллаһы тәгаләне кат-кат исләренә төшереп, курку да калдылар. Тарихның шушы яман көне кыямәтнең мәхшәреннән ким түгелдер мөгаен, йа Ходаем!

Шәһәр халкы ганимәт малыннан өлеш чыгарылуга өмет белән төркем-төркем җыелышып, шатлык авазлары кычкырдылар. Кайсыберләре тантанада арттырып җибәрде: әсирләр өстенә тизәк ыргыттылар. Усалраклары таш белән дә алып оргалады. Бала-чага чыр-чу килде. Бары тик хатын-кызлар вә өлкәннәр генә: «Безнең дә шушы хәлләргә калуыбыз мөмкин!» — дигән төсле, сагышлы

күз карашлары белән кол итеп куыла китерелгән мескеннәрнең кайгыларын уртаклашкандай моңаешып калдылар. Тәкъдир авырлыгы кемгә төшә дә кемнәренә килми шул. Язмышлар бертөсле түгел.

Сөһәйл вә аның кебек углан, асыл зат сөякләрне тоткын сугышчылардан һәм башка әсирләрдән аерып алып, читкәрәк сөрделәр. Кемнең буе җитте, алар, яман эшкә дә санамастан, кулларын сузып, тоткыннарның яхшырак вә ялтыравык вак-төяк әйберләрен киемнәреннән тарткалап-йолыккалап калдылар. Табышка ирешкәннәре сукыр куаныч белән сикереште. Арадан берсе Сөһәйлнең күкрәгенә эленгән тугра калаена кызыгып сузылган гына иде, яннан гына килүче сакчы-гаскәри кулындагы авыр чылбыр белән тегенең беләгенә орды. Үз кешеләреннән исәпләнгән шушы яугирдән Сәмәрканд оятсызы хөкем-җавап алырмын дип көтмәгәндер күрәсең, мәтәлеп төште һәм ауган җирендә ятып калды:

— Әлең корысын!—дип әмер итте гаскәри. Аның шушылай “кулың корысын” дип, кычкыруыннан соң, ганимәт малына күз кыздырган һәркем бер-ике адым артка чигенде, артыгы белән масаеп китүчеләр дә тына төштеләр.

Хәлләр болайрак икән шул!..

Кайсы тоткынны кая куйганнардыр, таланган малны ни җиргә илткәннәр вә ничек бүлешкәннәрдер — боларын Сөһәйл һәм яраннары күзенә күрсәтмәделәр, һаман каядыр куа бирделәр үзләрен. Муеннарга вә тәнгә ябышып кына калмыйча, бугаз төбенә кадәр утыра башлаган юл тузаны кимегәннән-кимеп, арыктан аккан су челтерәүләре дә ишетелә, агачлар да күләгәле торган урынга җиткәндә генә Сөһәйл башын күтәрде. Алар бер-бер ишегалдында иделәр булса кирәк. Каршыларына таба бер төркем җарияләрме, әллә инде сарай күркәмнәренең кызларымы якынлашып килә иде.

— Гөлдерсенгә юл куең! — дип, арадан бер хатынның сүз салуы булды, гаскәриләр генә түгел, хәтта әсирләр дә ике якка аерылып, уртадан сукмак бирделәр.

Кызлар якынлашкан саен алар читкәрәк тартылдылар, юлны киңәйттеләр. Сөһәйл дә барган җиреннән туктап калды, әмма үз дәрәҗәсен белепме, әллә инде үлем сәгатен ашыктырыпмы, уңга яки сулга чыгуны кирәк тапмады, ялгызы йөзгә-йөз дошманы белән очрашты.

Гөлдерсен дигәннәре Аксак Тимернең сөекле кызы булып, өсте-башы ак белән каймаланган яшел-су җиләс күлмәк вә шундый ук бөркәнчектән иде. Сөһәйл каршысына килеп җитүгә, куй күзләре көлемсерәп, йөзе ачылып китте. Мәк чәчәге төсле күпереп торган кызыл иреннәре, ак бит очындагы тиңсез күркәм миңе үлгән җиреңнән терелтер иде. Һәм аны күрүгә Сөһәйл аңын җуярга тиеш булгандыр. Әмма егет хисләр ташкынына юл куймады, башын горур тоткан хәлендә кала бирде. Ничә көннәр ач вә сусаудан гаҗизләнгән шаһзадәнең битләре тартылган, чәч бөдрәләре тузанга укмашкан булуга да карамастан, Сөһәйл һаман да нәзек билле, калын җилкәле Идел буе каены төсле сокландыргыч вә матур иде. Аның табигый күркәм сыйфатларына сугышта алган яра эзләре һәм бүселеп төшкән киеменең ачык җилкә башлары тагын да тәэсирлерәк гүзәллек өсти. Кая барган тарафын онытыпмы, әллә инде: «Данлыклы Идел егете, Туктамышның бөркете шушы буламы?» — дигән уй беләнме Гөлдерсен, гаҗәп-

сенеп, Сөһәйлне күзләде, артыннан үтеп, алдына чыкты. Шагыйребез әйтмешли: “Кояш тирәсендә Җир ничек әйләнсә, шулай йөренде”.

Вакыйгалар үз җайлары белән мәйданга чыктылар: ваемсыз хан кызының күңеленә мәхәббәт уты йөгерде, Сөһәйлне төшләрендә күреп саташыр, көндезләрен күзләренә яшь тулып, бит очларын юадыр иде. Ә егет башка төрле уйхәсрәтләр белән янды. Зинданда ничә көн яткандыр, йөзе саргаеп, бәгыре сула башлады. Кем аның хәленә керер дә, ничекләр итеп кенә җанын юатыр? Юк андый кеше. Алтын Урда, дан-шөһрәт иясе изге Сарай шәһәре — еракта. Белми дә торганнардыр әле. Хәвеф-хәтәрсез генә гомерләрен уздыра торганнардыр! Әнә күктә бииһая балкыш белән ай тантана итә. Кулын сузсын иде ул, чыгарсын иде моннан тартып!

Сөһәйл чокыр-зинданның рәшәткәле авызына төптә яткан хәлендә өмет белән шактый озак карап торды. Анда, өстә, кемнәрдер йөренде, сөйләшкәләделәр. Каравыл алышындымы, башка бер эшме, аңлашылмый иде.

Башын озак күтәреп торганнан муены вә тәне арып, күзләренә йокы төште. Ул каядыр бара да бара. Янында кемдер бар. Кулга-кул тотышканнар. Ә-ә, күккә менеп китүләре икән.

— Әй, шаһзадә, тор җәһәтрәк!

Кемдер дәшә. Салкын бит монда, салкын!

Сөһәйл күзләрен ачты. Аңлашмыйчарак торды. Һай, йоклаган булган икән, саташкан. Бу ни тагын?

Баскыч түгелме соң? Чыгаралар бит зинданнан, югарыга чыгаралар. Нигә монда череп ятарга?

— Әй, егет, җәһәтрәк кылан! Күтәрел тизрәк!

Хатын-кыз тавышы ашыктырганга Сөһәйл, эшнең ни-нәрсә икәнлеген аңларга да өлгермичә, югарыга ыргылды. Болай тиз вә җиңел кыланганы юк иде булса кирәк, менә бит, ничек оча гына.

Зиндан авызыннан күренүгә, аңа халат бирделәр һәм башына пәрәнҗә бөркәделәр дә кулыннан җитәкләп каядыр ашыктырдылар. Гырлап йоклаган каравылчы шул килеш ятып калды, алар, бакчаның икенче ягына чыгып, тар вә тәбәнәк ишектән ниндидер бүлмәгә керделәр. Җитәкләп китерүчесе кулын ычкындырды, каршыдагы ике баскычның сул яктагысыннан күтәрелеп, ары чыкты, югалды.

Монда якты иде. Кәндилдә шәмнәрнең өчесендә генә филтә януга карамастан, караңгылык сизелми. Әллә күзләре ияләшеп җиткән, әллә башка сәбәбе бар?

— Шаһзадә Сөһәйл!

Тыныч кына әйтелгән бу ягымлы сүзләрдән егет сискәнеп китте. Бүлмәдә үзем генә икән дип уйлаган иде югыйсә.

Сөһәйл тавыш ишетелгән якка борылды, әмма баскан урыныннан кузгалмады. Эшнең нәрсәдә икәнлеген төшенми иде әлегә.

— Мин Гөлдерсен булам, Сөһәйл, курыкма!—диде ул зат.— Синең коткаручыңмын! Атама әсир төшеп, аңа кол булдың. Мин сиңа кабат ирегеңне кайтарам...

Егет акылын җыеп өлгерде, билгесезлеккә чик куелган кебек иде.

— Йә гүзәл зат, йә Гөлдерсен, мин сезнең алда бурычлымын!—дип Сөһәйл башын иде.— Әмма бер-ике соравым бар, әгәр дә «мөмкин» дисәгез, белешер идем. Гафу итәсез! Хәтерем чуалганрак вакытлар. Мөмкиндер бит, рөхсәтегез булса?

— Сүзегезне рәхмәттән башласагыз, мөмкин!

Сөһәйлгә кыенрак булып китте, шулай да ялгышын төзәтергә кирәк иде аңа. Ашыгып сүз әйткәнче, бераз фикерләп алды. Үргәнечтә Гөлчәһра белән шушындыйрак хәлдә йөзгә-йөз калып сөйләшүен исенә төшерде. Ул вакытта Сөһәйл бәхет бакчасының түрендә иде шул. Кызның хисләр бүлешүе рәхәт тә, шатлык өстенә сөенеч тә иде. Бер түгел, ничә тапкыр очраштылар. Иреннәре-иреннәрен эзләп тапкан иде. Сарайдан куылуын да, этисенең үпкә-ачуларын да оныттырды аңа Гөлчәһра. Хәтта киләчәк көннәрен дә аның белән уздырачагы хакында хыяллана иде егет. Әгәр дә сугыш бәласе чыгып, кулларына богау салынмаган булса, теләкләре тормышка ашачак иде. Менә бит язмыш аны кайларга китереп ташлады? Сөеклесеннән аерды, канатларын каерды. Кайларда икән ул Гөлчәһра?

— Әгәр дә бер-бер шаярту булмаса, рәхмәтлемен! Аллаһы Тәгалә үзегезгә бәхет вә бәрәкәтләр юлласын, Гөлдерсен! Кем икәнегезне, ни өчен болай эшләгәнегезне төшенмәсәм дә, бурычлы булуымны белдерергә телим!

— Без — танышлар. Монда куылып-сөреп китерелгән көнегездә йөзгә-йөз очраштык, хәтерегездәдер!

— Түбәнлек вә рәнҗетелүдән башкаларны хәтеремдә калдырмаганмын, гафу боерыгыз!

— Ә без бакчада очрашкан идек. Хәтеремә сеңеп калдыгыз, кызганудан төн йокыларым качты һәм сезне азат итәргә уйладым.

— Әтиегез нәрсә әйтер?

— Ул шәһәрдә юк! Илегезгә һөҗүмен дәвам итәдер. Хәбәре килде, Сарай шәһәренә ут салганнар. Олуг ханы качып киткән.

Бу сүзләрне ишеткәч, Сөһәйлнең күз аллары караңгыланып, ул тезенә егылды һәм, аңын җуеп, янга ауды. Хәзер аның хакында кем кайгыртыр? Бөтен ышанычы этисе Туктамышта иде. Коллыктан йолып алыр дип уйлый һәм Аллаһыдан ярдәм өмет итә иде. Барысы да бушка булган. Тәхетен ташлап качкан ханда балалары кайгысы бармы?

Сөһәйл күзләрен ачты. Йөзенә карап, маңгаеннан сыйпаган гүзәл кызны башта Гөлчәһра дип уйлады. Әмма исемен әйтә алмады. Теле тибрәнмәде. Бу — бәхетенә күрә булгандыр.

Күзләре йомылды. Кашларыннан, борын очларыннан назлы кулларның сыйпавы җанына вә тәненә рәхәтлек бирде. Кызның күзләреннән яшьләр тамды, егет тә тыела алмый елый иде. Гөлдерсен аның иреннәреннән үпте, ә Сөһәйл аның иңенә кулларын салды. Йөрәге кузгалды. Гөлдерсеннең итәк-тезләрендә яткан җиреннән күтәрелергә исәбендә дә юк төсле иде. Кыз һаман да аңа якынрак елышты. Мәхәббәт вә сагыш тулы күңеленә сөю-сәгадәт нурлары тулган иде.

Сөһәйл тагын күзләрен ачты. Бу юлы акылы кайткан, хәтере яңарырга өлгергән. Гөлдерсеннең йөз сызыкларын ачык күрде. Үз хәлен төшенде. Ул Үргә-

нечтә дә түгел, Гөлчәһра алдында да иркәләнми икән бит. Кем бу гүзәл зат? Пәри кызымы, адәмиме? Кеше-кара күреп алса — зинада гаепләячәкләр, аздыруда! Йомшарма, егет, йомшарма!

— Ни булды?

Кызның каушап әйтелгән сүзләре сикереп торган Сөһәйлне туктатып калдырды.

— Бер ни дә юк! Гафу итәсез, хәбәрегездән хәлем китте булса кирәк, Гөлчәһра, ә юк, Гөлдерсен!

— Гөлчәһраңның толымнарын кистереп, коллыкка саттылар. Ул хәзер ир хатыны.

— Ялгышып әйткәнмен.

— Аңыңны югалтуга ук аның исемен кабатлый башладың. Шулкадәр яраткан идеңмени? — дип, Гөлдерсен тездә калган хәлендә башын читкә борды. Ул елый иде булса кирәк.

Сөһәйлнең күңеле кузгалды. Каршына тезләнде. Кулыннан тотарга да, башыннан сыйпарга да белмәде. Хәлне аңламады. Ни тели бу гүзәл аннан? Гашыйк булган түгелме? Шулайдыр, юкса зинданнан коткарыр, төн уртасында чыгарыр идеме? Юк! Кабат шунда ташлаттыруы да бар. Кызлар уйнарга ярата, бер-бер уенчык урынына гына да күрүләре мөмкин.

— Беренче күрүдә үк...

Ничек итеп беренче күрүдән үк гашыйк булуларын, шулай Сөһәйлнең алдына-артына чыгып бөтерелүләрен, мәхәббәте аркасында төн йокыларын югалтуларын егеткә бәйнә-бәйнә сөйлисе килде Гөлдерсеннең. Әмма йөзенә оят вә итагать пәрдәсе төшеп, күзләреннән кайнар яшьләре генә ага бирде. Ни хәл бу? Язмышмы, әллә яшь йөрәкнең үҗәтләнүеме?

Аяк тавышлары якынлашып килүченең хәбәрен китерде. Гөлдерсен йөзенә пәрәнҗәсен төшерде, күтәрелде. Сөһәйл дә читкә тартылырга ашыкты, шәм яктысы үтмәгән почмакка яшеренергә теләде. Гөлдерсен:

— Безнең кеше булырга тиеш, качуның кирәге юк,— дип туктаткач, дулкынланудан урынын югалткан йөрәге дә тынычлана төште.

— Таң беленеп килә, йә ханбикә! Озатырга соңга калабыз. Атлар әзер. Капка артында көтеп торалар,— диде килеп кергән пәрәнҗәле ике хатынның берсе.

Гөлдерсен аңа кул ишарәсе ясады. Икенче хатын кәндилләрне кыскыч-җәмки белән сүндерде. Тәрәзә уемнарыннан бүлмәгә сүрән зәңгәрлек томаны үтеп керде.

— Киттек, Аллаһыга тапшырып! — диде Гөлдерсен.

Алар тар тыкрыклардан, агачлы бакчалар аша шәһәрне ташлап чыктылар. Алдан әзерләнеп куелган дүрт атка ике пар утырып, ук атар ераклыкны узганда мөфти хәзрәтләренең мәсҗеде манарасыннан беренче азан авазы яңгырады. Качып баручылар ат өстендә генә җиңелчә итеп фарыз вә сөннәтне үтәделәр дә, әле сүнеп бетмәгән Казык йолдызга төбәп чаптыра бирделәр. Алда нәрсә көтәсен белми иделәр...

...Шушы вакыйгаларны сөйләгән җиреннән Әхмәт-Бахши Үргәнчи тукталып калды. Җәмәгать каршысында исеме танылган әдип-шагыйрь Сәйф Сараи

ефәк төсле ак сакалын сыпырды, җыерчыклар чолганышында уелган күзләреннән яшь бөртеген алды, келәмгә ян белән сузылган җиреннән җыелып утырды. Мәҗлестәш сигез-тугыз мәмлүк-татарның карашлары аңа текәлгән иде. Хәзер Сәйф Сараи:

— Минем дастаным шушы турыда иде, җәмәгать! — дип сүз башлады.— Сез аны ишеттегез, менә хәбәрдән дә мәгълүмат алдыгыз. Кайчан гына даншөһрәт тоткан Кыпчак иле бүген имансыз Аксак Тимердән тапталды, харап булды. Гомеремнең ахырына кадәр Ватаныма кайтып бәхет табармын дигән идем дә, ялгышканмын икән...

Шадра йөзле Туглы-Хуҗа, боегып утырган җиреннән баш күтәреп:

— Йа Сәйф карендәшем, Әхмәт Үргәнчинең хәбәрен дә, сез мәртәбәле зат иясенең әсәрләрен дә ишеттек. Бу ике ярның язмышы ничек тәмамланганын аңламыйчарак калдым. Бөек мәхәббәт корбаннар сорый. Борынгыдан бәндәләр өчен бер-берсенә мирас итеп калдырылган сөю хисе азларны гына мәңгегә бәхетле итә. Ике олуг ата бер-берсенә ут вә таш аткан вакытта үзара гашыйк булып, бәхет эзләгән бу ике зәгыйфь-зәгыйфә барыбер максатларына ирешә алмаслар иде бит, шулаймы? — дигән соравын уртага куйды.

Сөхбәт ияләре әңгәмәдәшләренең күзләренә карашып алдылар. Сәйф Сараи нәрсә булса да сөйләргә ашыкмый иде бугай, эндәшмәде. Әхмәт Үргәнчи үз исеме телгә алынудан соң бераз дулкынланды, чапан итәген җыеп, сүз башларга уе барлыгын белдерергә теләгәндәй, фикердәшләренең йөзләренә карап-карап алды да әйтә куйды:

— Мин Сәмәркандта чагында халык арасында шундый хәбәр таралды: Сөһәйл белән Гөлдерсен сахрада ялгыз калганнар, күп җәфалардан соң Гөлдерсен вафат булган, бу хәлне егет, кичерә алмыйча, аның янында үзен-үзе хәнҗәр белән чәнчеп үтергән. Артларыннан куа килгән гаскәриләр аларның үле гәүдәләрен генә тапканнар... Моны ишеткәч, халыкның күңеле бозылды, телдән-телгә күчеп, кызлар вә хатыннар шактый күз яшьләре агыздылар. Вакыйгалар шулай булды...

Бу өстәмә хәбәрдән соң һәммәсе боегып, шигъри-дәртле күңелләр сүнеп, акыллары шаша калды. Беразга тагын тынлык урнашты. Кич иңеп килә иде. Сүзне йомгаклагандай:

— Ике татар ханы бер-берсенә дошманлык кылдылар, халыкларын җәберләделәр, Коръәнне вә шәригатьне аяк асларына салып таптадылар. Әмма балалары үзара олы мәхәббәт таптылар. Бу түгелме Аллаһы тәгаләнең кодрәте, шушы түгелме яшәеш кануны? Тарихларда кайсы дәвердән мондый хәбәр калды? Сөһәйл вә Гөлдерсен мәхәббәте безләрне вә өммәтебезне күп нәрсәләргә өйрәтер. Максатым да шушы иде. Алар хакында олуг дастаннар иҗат итәргә иде. Бу — безнең чорның гыйбрәтле ядкәре булыр иде,— диде Сәйф Сараи.

Ул сүзләрне бетереп, голамә: «Әйе, әйе!» — дигәндә, кичке намазга чакырган азан тавышы яңгырады. Барысы да күндәм рәвештә кузгалдылар һәм, тәһарәт-ханәдә сафланып, мәсҗедкә ашыктылар. Илләр иминлеге, гашыйклар бәхетенә атап догада булырлар...

Алар бүген дә шул гыйбадәтләрендә төсле, безнең иминлекне вә бәхетне

саклыйлар кебек ул изгеләр. Менә караңгы кичәдә болытлардан күк йөзе ачылып, аларның Җәмигъ мәсҗедләре күренер,— мамлүкләрнең Искәндәрия шәһәрендәге тарих белән бергә күккә ашкан гыйбадәтханәләре ул. Анда Сәйф Сараи вә аның яраннарының рухлары Коръән чыгадыр? Без, гафил бәндәләр, моны белми вә күрми калабыздыр? Мөгаен Сөһәйл вә Гөлдерсеннең рухлары да алар янәшәсендәдер? Алай гына түгел, меңнәр, миллионнардыр!

***Автордан өстәмә гыйльми бәян:***

*Әдәбият тарихчысы, профессор Хатип әфәнде Миңнегуловның «Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты» дигән хезмәте аерым китап буларак 1976 елда дөнья күргән иде. Аның 107-108 битләрендә чыганакларга таянып әйтелгән мондый сүзләр бар: «Сөһәйл вә Гөлдерсен» сюжеты (сүз Сәйф Сараиның дастаны хакында бара.—* ***Ф.Я.****) халык телендә төрле вариантларда сөйләнүче бер легендага тартым. (Легендада егет Туктамыш хан улы, ә кыз Аксак тимер кызы, диелә. Әсәрдәге кебек биредә дә егет белән кыз бергәләп качалар. Әмма легенда вариантларының соңында бераз үзгәлекләр бар. Егет белән кыз арыпталчыгып бер күл буена туктыйлар. Бераздан егет, кызны калдырып, суга китә. Ул әйләнеп кайтуга, ерткыч хайваннар кызны җәрәхәтләп үтергән булалар. Бу вариантта егетнең үзен-үзе һәлак итүе хакында бернәрсә дә әйтелми.) Легенданың икенче вариантында бу өлеш болайрак бирелә: качып баручы гашыйкларны Аксак Тимер солдатлары куып җитә; тигезсез сугышта егет һәлак була, бу хәлне күреп, кыз үз-үзенә пычак белән кадый һәм сөйгәне янына ава. Һәр ике вариантның да ахыры бер үк төрле: бу фаҗигале хәл кызның әтисенә ишетелә. Аксак Тимер, шул урынга кызын күмдереп, кабер өстенә истәлек өчен зур манара төзетә. Чиләбе өлкәсенең Варна поселогы янында 16 метрлык корылманы легенда вариантлары шушы вакыйгага нисбәт итәләр. Мавзолей тибындагы бу кирпеч корылма халыкта «Тимерлән манарасы» дип йөртелә. 1889 елда Петербург университеты профессоры Э.Ю.Петри биредә археологик тикшеренүләр алып барган. Казынулар нәтиҗәсендә манара төбеннән бер хатын-кыз скелеты һәм ир-ат баш сөяге табыла. Э.Ю.Петри фикеренчә, боларның өчесе дә монгол тибында. Хатын-кыз кабереннән ефәк тукыма кисәкләре, ике тамчылы бер пар алтын алка һәм бик нәфис эшләнгән ике алтын йөзек табыла».*

*Сәйф Сараи шушы ике гыйшыкка багышланган тиңсез дастанын 1394 елда язган, димәк аңа инде 600 ел. Истәлекле дата.*

*Һәр елда максат куям: ничек тә Сөһәйл вә Гөлдерсен каберен барып күрергә иде, дим. Әмма эшләр вә тормыш хыялны еракка, тагын да киләсе елга калдырырга мәҗбүр итәләр. Әгәр дә дөнья йөзендә мәхәббәткә багышланган һәйкәл куярга уйлыйлар икән, ул һичшиксез Сөһәйл вә Гөлдерсен кабере өстендә булырга тиеш. Аның урыны Җир йөзендә бары шул төштә генә, шулай иткәндә генә дөрес һәм урынлы була ала, дим!*

*1994.*

# ҺОМАЙ КОШЫ

*Хикәя*

Минем ул кошны күргәнем бар. Аңа таң-гаҗәеп калып, ничекләр генә сөенмәгән идем ул вакытта.

Җәй көне иде. Авылның печәнгә төшкән вакыты. Безнең дә әллә кайчаннардан аталып куелган болынлык кебек җиребез бар. Болынлык дип, бик алай ук телгә алып сөйләрлек тә түгел инде ул үзе. Ерак басулар артында, үрләрне менеп җиткәч, ике сырт арасында уймак кадәрле генә печәнлек шунда. Ни коры елларда да, ни яңгырлы җәйләрдә дә үләне яхшы була. Куе һәм үрчемле, һәр җәйдә зур ат йөге чамасы печән чыга. Әткәй әйтә, безгә җитә, ди. Кеше өлешенә кереп, тегендә-монда барып кысылуны җене сөйми, кыямәт көнендә Аллаһы тәгалә, ачуланып, газабын ирештерүе бар.

Әкрен генә күтәрелеп килүче кояшны ияртеп, без шул болынга таба юлга чыктык. Иртәнге җиләс җил, иген басуларын тулгап-болгатып, әнә ничек куян куа. Иренчәк чикерткә һәм бөҗәкләрнең кубыз тартуы ишетелә. Бу аларның инде күптән тынып калган кошлар биләмәләренә хуҗа булып өлгергәнлекләрен белдерә. Анда-санда очраган күгәрчен кадәрле кыр тавыклары тук һәм симез бөҗәкләрне чүпләп рәхәтләнәләр. Ни дисәң дә, җан сакларга юнь биргән Хак тәгаләнең мәрхәмәтле көннәреннән берсе иде бу.

Озак бардык. Әткәй соңгы елларда еш авырганлыктан хәлсез, туктап-туктап кала, чиксез күккә төбәлә. Аны көтеп мин сөтләнә башлаган бодай башагыннан бер-ике яшел бөртек алып суырам яки иген арасында үскән зәңгәр чәчәкләрне өзәм, иснәп карыйм. Кулымдагы сумкада бер литрлы банкага тутырылган сөтле чәйне күгәреп эчәсе килеп китә. Әткәйдән рөхсәт сорарга батырчылык итмим. Иреннәр кипшергән. Сабыр итәм.

Болыныбызга барып җиткәндә генә мин, бер кошка игътибар итеп, аның диңгез өстендә очкан акчарлак кебек тибрәнүенә сәерсенеп тордым. Нигә монда оча икән ул, ә? Лачын кадәр зур, хәтта казны хәтерләтә, акчарлакныкы төсле ак канатларының очларында карасы да бар. Адашып килде микәнни? Бу тирәдә санга алырлык зур сулы елга да юк, диңгез-күлләр дә ил читендә генә, барып күрерлек нәрсәләр түгел. Дөрес, адашкандыр бу кош, мескенем, адашкандыр. Башкача булмас, акчарлак башы белән югыйсә ни дип безнең басулар өстендә очып йөрер иде?

Бу фикеремне әткәйгә белдерергә уйладым.

— Әткәй, әткәй дим, бу нинди кош? Акчарлак түгелме? Нигә адашып йөри ул монда?

Хәзер уйлыйм да, бала гына булганмын икән әле ул вакытта дип, нәтиҗә чыгарам: юкса һәр сүзем сораудан гына тормас иде.

Әткәй дә озаклап, тыныч кына шул кошны күзәтте.

Оча-оча да кисәк кенә кыегаеп китә: яки чалт аяз күккә күтәрелә, яисә кабат безнең өстән әйләнеп оча. Аһ, баш түбәсеннән генә диярлек узды. Мин хәтта хәзер күтәреп китә инде дип өрки калдым. Иген өстеннән шуышып килгән күләгәсе зур, җанга шик салырлык иде. Чүгәләп тә куйдым булса кирәк.

— Һомай кошы бу,— диде бераздан әткәй.— Күптән безнең якларда кү-

ренгәне юк иде. Сәгадәт билгесе, бәхет китерә ул.

Мин берни дә аңламадым диярлек. Нәрсә ул сәгадәт? Нинди кош ул Һомай кошы? Бәхет китерә торган булгач, әйбәт икән анысы.

Инде килеп җиттек дигәндә генә шулай туктап калуыбыз вакытны бушка уздыру белән бер иде. Безгә ияреп йөргән кояш та шактый күтәрелергә өлгергән. Тау араларында адашкан җилләр уңлы-суллы йөренә. Офык артларыннан ак мамык болытлар да күренгәли. Шулай да көннәр бу араларда яхшы торачак.

Печәнлегебез елмаеп диярлек каршы алган төсле булды. Чит-читендә үләне тәбәнәк, уртасына керсәң, билдән инде ул. Таптарга гына ярамый. Анысын беләм. Әмма берәү узган инде. Күренеп тора. Ярып ук үткән. Ни калган инде аңа, монда чалышаеп йөрмәсә, урап үтә алмас иде микәнни?

Әткәй, дога кылган кебек итеп, бит очын кушучлап сыпырып куйды. Аңа ияреп мин дә кабатладым. Эшли башласак, ике-өч көндә чабып алабыз инде анысы, Алла боерса!..

Әткәй күтәреп килгән чалгысын караштырды да үз җае белән печән чабарга кереште. Әлегә миңа эш юк иде. Чалгыга буем җитсә дә, икенчесен алып килмәдек шул. Тау сыртынарак күтәрелеп, олы ташка менеп утырдым. Шаян җил, җиңсәләрдән кереп, юри кытыклаган кебек маташа, борын очларына төртептөртеп куя, ераклардан тук һәм рәхәт һава алып килә. Һәр җирдә бәхет-сәгадәт орлыклары тулышып, алда шатлыклы көннәр буласын хәбәр итә. Тыныч, күңелле. Әгәр дә сез, дөньядан туеп, имин җир эзләсәгез, кайда да түгел, менә шушында инде ул!

— Улым...

Әткәй чакыра икән. Исемне җыеп, тизрәк шунда йөгердем. Ул бер тезмәне чыккан да, хәле бетепме, чалгы сабына таянып тора. Күзләрендә әллә авыр эшнең тире, әллә яшьләр. Юк, җил генә кергәндер? Нигә әле бирешеп торсын ди. Илледән узган ир бит ул!

— Улым, менә син дә чабып кара әле...

Әйтүе булды, мин чалгыга үрелдем, һай, күптән хыялланган идем бит бу турыда. Әткәйгә чаба белгәнемне күрсәтәсем килә иде. Юккамы, болынга төшеп, кычыткан кыерлап йөрдем.

Беренче селтәнүләрем уңышсыз булып чыкты. Җиргә кадалган чалгымны тартып алам, кулны җайлыйм, ул тагын төртелә. Ачу килмәслек тә түгел шул. Нигә болай тыңлаусыз инде? Әткәй каршысында мактанырга да ирек бирми.

— Алай тотма син аны, улым. Менә болай, үз иркенәрәк куй... Кыйнап йөртмә, иркенрәк бар, җаена карабрак...

Күпме генә өйрәтмәсен, чалгы минем сыек беләкләрне санга сукмый, ир затыннан булуымны көлкегә калдыра иде. Шулай да сер бирмәскә тырыштым, батыраеп-батыраеп селтәндем. Әмма чалгым бер дә үзенә иярергә исәпләми. Мин дә һаман үҗәтләнә барам.

Тезмәне чыгып җиткәндә тәмам хәлсезләнгән идем инде. Шулай да кулның җаен таптым шикелле. Икенчесен башлаганда чалгым төртелеп газапламасына күңелемдә ышаныч туды.

Борылып карасам, чапкан җирем ат аунаган болын хәлендә, бер көлке сурәттә иде. Кайсы урыннарда печән бүселеп ята, кай җирләрдә тамыры-ние бе-

лән кубарылган, тезмәм тигезле-тигезсез, алама яка төсле килбәтсез иде.

— Барып чыгарга охшый, улым... Әле мин иртәрәкме әллә дигән идем. Өйрәнүең — үзеңә... Беренчесе шулай инде аның, аннан соң китә ул, кулыңа да килеп тора төсле.

Әткәй шулай дәртләндереп, мине тезмә башында каршы алды. Әмма сүзләрендә сөенечтән бигрәк кыенсыну кебек тынгысызлык төсмере дә ишетелде. Бүген генә түгел, соңгы вакытларда ул шулайрак сөйләшергә гадәтләнеп китте, шунлыктан игътибар итмәскә дә мөмкин иде. Аларны үземчә кабул иттем: эшкә дәртемне сүндерәсе килмидер мөгаен.

Икенче-өченче тезмә-покосларны чыгу миңа күпкә җиңелрәк булды. Чалгым да тыңлаучанрак хәзер, әткәйнең фатихасына колак салгандыр инде.

Мин шулай шактый озак чаптым. Эшнең җаена төшенә барган саен дәртем дә артты. Әмма беләкләргә кан утырды, җилкә башлары арыдылар. Тәнем шабыр тир. Маңгаема кагылып узган җил дә кайнар һәм эссе иде.

Шулай өч-дүрт тезмә чыккач, әткәй мине үз янына чакырды:

— Кил, улым, утыр... Берьюлы чабып бетерергә димәгән, хәл җыеп ал.

Аның күзләрендә килер көннәр өчен ышаныч һәм шатлык очкыннары яна иде. Мин чабылган җирләрне, болынлыгыбызны күзәттем. Шактый күп икән әле эшлисе.

— Әткәй, тиз генә бетмәс әле бу...

Ул көлеп куйды:

— Берьюлы бетмәс, азлап-азлап чапсаң, җитми дә калыр... Әле мин ышанып та бетмәгән идем, болайга китсә, кулың ятып тора, булдырырсың, иншаллаһ!..

Чалгыны читкә ташладым. Әмма алай итүемне әткәй яратмады. Урыныннан кузгалып, аңа үрелде һәм миңа эш коралы белән бәйле сабагын бирергә ашыкты, югыйсә кушып кына да кирәгенчә эшләтә ала иде бит.

— Улым, чалгыны болай ташламыйлар, сабының очы белән тезмә башына кадап куялар: югалмый да, аягыңа да ялгыш чалынмый, хәвеф-хәтәр дә күрсәтми. Ирне — халык, ир — коралны мактый. Эшеңне башкарганы өчен үзенә дә хөрмәт күрсәтергә кирәк,— дип, аны үзе уңай тапкан җиргә кадап куйды. Миңа исә: «Ә-ә-ә»,— диюдән һәм акланырлык сәбәп эзләүдән башка чара калмады.

Без утырып ял иткәндә, Һомай кошы турыбыздан тагын үтеп китте. Әллә кайдан гына килеп чыкты да, гүяки күләгәсе белән кочаклап алды. Колачлары иңгә-буйга шактый киң иде. Икенче тапкыр йөрәк түренә билгесез бер шом йөгерде. Ул да булмады, очып барган җиреннән бу кош зәңгәр күккә кереп эреде, юкка чыкты.

— Әткәй, кайда яши икән Һомай кошы?

Минем курку йөземә чыккан идеме, белмим, бәлки карашларым сәер тоелгандыр. Әткәй сынап кына туры карап алды. Елмайды. Юаткандай әйтте:

— Курыкма, улым. Бер дә яман кош түгел ул. Борынгылар әйтә торган иде: Һомай кошын күргән кеше бәхеткә ирешә, дип. Ул — Аллаһы тәгаләнең хәбәрчесе. Оясы да әллә кайларда, зәңгәр күкнең түбәсендә диләр иде. Элекләрне күренгәләгән ул. Хәзер бер дә очратканым юк иде. Бәхетле бала икәнсең...

Мин дә тынычландым. Ялга утыргач, арыганлыгымны ныграк сиздем, куз-

галасы да килмәде. Бер кызган мәлдән туктамыйча эшләсәм, яхшырак булгандыр да бәлки?

Кузгалып киткәндә аяк-кулларның авырлыгы подавай элгән төсле иде, гүя үземнекеләр түгел, чит кешенекен тагып куйганнар.

Көн уртасы авышканда эсселектән маңгайлар чатный, кигәвеннәрнең зәһәрлегеннән түзәр әмәл калмаган иде. Тагын ял итәргә тукталгач, зур ташның артында ярым күләгәлек табып, шунда сузылып яттым. Рәхәт булып киткәндәй тоелды. Кигәвен һәм чебеннәрдән качып шактый озак аунадым. Аякларның-кулларның сызлавы, көннең эсселеге тәнгә тынгылык бирми иде...

Кечкенә генә печәнлегебезне дүрт көн чаптык. Соңгы тезмә-покосны чыкканда, әүвәлгеләре кибеп өлгергән иде инде. Бөтенләй таралып бетмәсеннәр дип, күбәләштергәләп тә куйдык. Ә Һомай кошы бүтән безнең тарафларга килмәде, күренмәде. Барлыгыбызны онытты, әмма минем хәтеремә уелып калды. Зәңгәр күккә төбәлгәндә, күзләрем аны эзли башлап, кинәт килеп чыгасына ышанычым зур иде.

Чапкан печәнебезне тиз генә алып кайта алмадык. Әткәй ике көн рәттән атлы һәм машина-тракторлы кешеләрне йөреп чыкты, һәммәсе дә эштә иде.

Шулай да өченче көнне иртән-иртүк, әле кешеләр кузгалганчы ук җигүле ат белән юлга чыктык. Бу ала-кола бияне әткәй кемнән алгандыр, белмим, һәрхәлдә, безнең авылда мондый ук ялкау мал юк иде булса кирәк. Дилбегә башын үзем тотканга, ачуларымны чыгарып бетерде, артыннан төшеп этәрдәй хәлләргә җиттем.

— Кулыңда чыбыркы булмаганга шулай итә ул, улым. Бар, чыбык булса да тот,— дип, әткәй киңәш биргәч, беренче очраган сәрби куагыннан иң саллысын сындырдым. Дөрес икән, арбаларына кадәр келтерәп йөгерде. Чуар бия генә канәгатьсез рәвештә күз агы белән карап-карап куйгалады, әмма адымнарын акрынайтмады.

— Әйдә, кайтканда тау түбән...— дип, үзалдыма куанып һаман да чыбык очын һавада чожылдаткалап алгаладым. Аның саен чуар бия әмеремә яхшырак буйсына бирде.

Килеп җиттек. Еракта, авыл башында, сыерлар аваз салды. Көтү яңа чыгып килә икән. Димәк, көн кыздырырга өлгергәнче кайтып та җитәрбез, иншаллаһ...

— Аһ, харап кына иткәннәр...— Әткәйнең бу сүзләреннән йөрәк киселеп китте. Әүвәле нәрсә хакында әйткәнен төшенмәсәм дә, тиздән үзем дә шаһит булдым: чабып күбәләгән печәннәребезне туздырып-таптап, ашык-пошык төяп, урлап ук киткәннәр иде. Үлдем-беттем. Яман хәл иде шул.

— Аһ, мыскыллар гына иткәннәр...— Әткәй әрнеп-әрнеп сөйләнде, уңгасулга атлады. Нәрсә эшләргә дә белмәде.

Минем үксеп-үксеп елыйсым килде. Күзләремдәге яшь бөртекләрен чак кына тыеп тора алдым.

Килгәч-килгәч, буш кайтмас өчен дип, караклардан калганны тырмаладык та арбага төядек. Күңел тынычландырырга җитә калды анысы. Җыя торгач, ярты ат йөге булган кебек иде.

— Әллә эзләре буйлап барыйм микән?

— Йөрмә, улым, юньле адәм икән, кеше малына тимәс иде. Сүзеннән бәласе

күбрәк булыр йә!—Әткәйнең болай юаш итеп әйтүе минем үземә ошамады. Әмма сүзләренә буйсынырга мәҗбүр идем.

— Анысы шулай да, тик шушы йөк белән авылга ничек кайтып керербез, көн дә безне эшкә озаткан әнкәйгә нәрсә әйтербез?

Юлда атны ашыктырмадым, әмма җиңел йөкне түбән таба ул элдертте генә. Үпкәләүнең чиге юк иде. Карганырга ла, еларга да белмәдем. Әткәй исә бер сүз дә әйтмәде. Ничә көннәр буена куйган тырыш хезмәтебез шулай әрәм булды, угры кулына калды.

Юк, авыл да безне көлеп каршы алмады, әнкәй дә ризасызлыгын белдермәде: «Харап кына иткәннәр икән»,— дип, ачыргаланды да, болай да кәефебез киткәнлеген аңлап, бөтенләй җимереп ташларга теләмәде.

Әмма мин эш арасына керә башлаган идем инде. Җәй буе су буйларыннан һәм үзәнлекләрдән кул арбасы белән печән җыйдым. Бер сыерыбызга кышлык азык булды дип әйтергә ярамаса да, саламга кушып салырлык кына бар иде.

Ә Һомай кошы хакында мин бүтән искә төшерергә теләмәдем. Шулай да ул озак хәтеремнән чыкмады. Берничә ел рәттән авырганнан соң, әткәй вафат булды. Мин дә инде, егет дәрәҗәсенә җитешеп, калада укый идем. Җәйләрдә кайткач, шулай бервакыт әнкәйгә әткәй белән Һомай кошын күргәнлегемне сөйләдем, ничек печәнсез калуыбызны искә төшердем. Үпкәмне дә белдердем.

— Ялгышма, алай димә, улым... Һомай кошы бәхет китерә ул. Әмма бәндәләрнең усаллыгыннан саклап кала алмый. Аллаһы тәгалә бетмәс-төкәнмәс шатлыклар бирсен. Әткәгез җәннәтле булыр. Кешеләргә бер дә усаллыгы тимәде бит,— дип озак сөйләде, дога тотты. Мин исә әнкәйнең ул сүзләрендә хаклык таптым, Һомай кошын күрүем, аның күләгәсе астында калуым аркасында киләчәктә үземә бәхет ирешәчәгенә ышанычым артты.

Әмма тормыш башкачарак икән шул әле, рухы бүтәнчәрәк. Ул хәтта язмышларыбызга үз төзәтмәләрен кертә, адаштыра, бутый, безне әйләнеч юллардан йөртә. Ә шулай да минем ышанасым килә: килер төсле ул бәхет, эзләп табар кебек үземне. Бәлки ышанычымны тормышта югалттырмас өчен күренгәндер ул вакытта Һомай кошы, күләгәсе астында калдыргандыр? Менә барсы да үзгәреп китәр дә, килер кебек ул ышандырылган бәхет, килер кебек.

## АККОШ МОҢЫ

*Хикәя*

Мин ул көзне сагыш белән очраштым. Моңа кадәр ваемсыз балалык чорымда рәхәтләнеп яши, кайгы-хәсрәтне аңламый да идем бугай, һәм үзгәрдем. Боегып, сүзсезләнеп калдым. Үсә төшүем, тормышны аз гына булса да таный башлавым билгесе түгел идеме икән бу сагыш белән очрашудан алган тәэсирем?

Әйткәнемчә, көз иде. Әле яңгырлы көннәре белән зарыктырып, әле йомшак вә җылы һавасы белән күңелләрне саташтырып — октябрь ае шаярта да шаярта иде.

Басу-кырда бәрәңге вә чөгендер мәшәкатьләре бетте. Аң-белемгә тәмам сусап, дәртләнеп укуга керештек. Мәктәптә җылы һәм рәхәт. Яңа директорыбыз

Нәкыйп Әмирович килүгә, барыбыз да үзгәрдек, хәтта мәктәп бинасына да ниндидер бер мәһабәт рух өстәлде. Өлкән сыйныф укучыларында җитдилек артты. Тәнәфес вакытларында тәртип, дәресләрдә таләпчәнлек үсте. Авыл мәктәпләрендә генә була торган серле, әмма шул ук вакытта табигый самимилек «шайтан туен» алыштырды. Димәк йорт иясе кабат үзе яшәгән урынына кайтты дисәк тә ялгышу түгелдер.

Бүген ял көне. Көзге пычрак эшләрдән соң һәр авыл өендә балаларга туйганчы йокларга ирек бирәләр. Иркәләнеп, киерелеп, бер күрә башлаган төшеңне кат-кат кабатлап, йомшак-җылы түшәктә сигезләр-тугызлар тулганчы рәхәтләнеп изрисең дә изрисең инде менә. Аһ, чукынчык, күрше Нәсимне әйтәм инде. Кояш тәрәзәдән күз салырга өлгермәгән, кереп тә җиткән бит. Сабакташ диген инде аны! Йокысын симертәсе урынга, тапкан уйнар вакыт, йөри кешене борчып.

— Буага аккош төшкән! Сәлим һаман да йоклыймыни әле? Күрми кала бит!..

Аның сүзләрен мин ишетергә дә теләмәдем. Дөресрәге, аңлап та, кабул итеп тә бетермәде күңел. Күргән төшем әйбәт иде. Оныттырды инде...

— Нәсим улым, Сәлимебез йоклый бит әле. Ял көне, ял итсен,— дип, тыныч кына акыл бирә башлады әнкәй. Ә үзе мич тирәсендә кайнаша булса кирәк, таба коймагы чаж-пож килә. Аның тәмле исе, борыннарга кереп, авыз суларын китерә.

Миңа сөенеч, сер бирмәдем, борылып яттым. Нинди төш күрә идем әле? Әә, куяннар, бүреләр, аюлар җыелышып бәйрәм итә иделәр, урман аланында бугай. Әйе, әйе, нәкъ шулай! Аһ, бетте, Нәсим тынгы бирмәде.

— Фатыйма апа, буага аккош төшкән бит. Бер дә булган-күргән нәрсә түгел, очар да китәр. Сәлим күрми кала бит, дим, шуңа гына кердем.

Йокым качты. Ничек, аккош төшкән? Аһ, рәхмәтләр яугыры, менә иптәш, менә дус икән бу Нәсим, сабакташ. Йоклап ятсам, күрми калачакмын, очар да китәр. Чыннан да күз күргән нәрсәмени ул? Тере аккош! Җырларда җырлана торган аккош. Матур, бик матур диләр бит аны. Ничек күрми калырга мөмкин?

Мин сикереп тордым да, ишеккә борылган Нәсимгә эндәшергә өлгердем:

— Хәзер! Артыңнан төшеп җитәм, көтеп тор!

Сабакташ чыгып очты. Артыннан мин дә йөгердем. Өстемә бишмәтемне эләргә өлгергәнмен, әмма оекбашны кияргә онытканмын. Кире керергә туры килде.

— Нигә ул кадәр ашыгасың, улым? — диде әнкәй, мине тыеп калырга теләп.— Тамагыңа да капмыйча?

— Мин хәзер кайтам, күрәм дә,— дип әйттем дә, бу юлы тәмам кирәгенчә киенеп, авызга кайнар коймак элеп, су буена йөгердем. Анда өлкәннәр дә бар иде.

Буалган инеш буйлап ак томан булу сәбәпле, аккош үзе аермачык күренми, әмма саташып кычкыруыннан күңелләр тибрәнеп куйды. Ялгыз икән. Ничек монда төшкән ул, ә? Безнең авыл тарихында андый хәлнең булганы юктыр?

Тамаша кылучылар арасында да шундыйрак сүз чыкты. Зөфәр абый, егетләрнең кәттәсе, әйтә куйды:

— Бүген төн айлы иде. Сак кына баянда уйнап кайттым. Тынып-тынып кына инде. Сәгать төнге икеләрдә бер-бер тавыш ишетелгәндәй булды анысы, мин аны йорт казы дип уйлаган идем.

Аңа кушылып, Салихҗан абый да сүз өстәде:

— Буаны күл дип күреп төшкән инде ул. Нидәндер бик курыккан. Яр кыриена бөтенләй дә килми бит.

Аккош буа уртасында ук иде. Көзге иртәнең салкын томаны вакыйганы гүяки яман күздән яшергән төсле су өстендә эленеп тора, аккош шул ак пәрдә артында сылу кыз кебек яшеренеп утыра да утыра.

— Моның пары кайда икән? — дип, борчулы сорау ташлады Зөфәр абый.— Аккошлар парсыз булмый. Ә бу — ялгыз.

Шушы сүз әйтелүгә, мескен аккош, үзе хакында сөйләшүләрне тоепмы, катырак та ачыргаланып тавыш бирде. Шапылдатып канатларын җилпеде. Әмма очып китә алмады. Тагын ачы тавыш бирде.

Ни хикмәт, тирә-юньдә хет бер оя йорт казлары күренсен. Кошлар ханбикәсе аларның биләмәләренә килү сәбәпле, үзләренең ямьсез кыяфәтләрен күрсәтергә оялып, качкан җирләрендә ята торганнардыр инде.

— Бу очып китә алмас,— дип, үз фикерен белдерде Зөфәр абый.— Канаты каерылган моның. Берәр ерткыч авызына эләккәндер?

— Атканнардыр? — дип, зурлар арасындагы сүзгә катышты Нәсим.— Атканнардыр?.. Парын үтергәннәрдер?

Бу минутта минем өчен сабакташымнан да мәрхәмәтсез кеше юктыр кебек тоелды. Ничек теле бара шулай әйтергә, яманга юрарга?

Мин хаксыз идем.

— Дөрес такылдыйсың, кечкенә генә булсаң да! — дип әйтеп куйды Салихҗан абый. — Башкача булмас. Минзәлә ягында обком дачасы бар. Табеевка дип, махсус аккош тоталар, аттырталар икән.

Табеев кем икәнлеген мин беләидем. Сурәте дә гәҗит-журнал саен. Юк! Андый олуг кеше аккош атып йөрмәс. Яман эшкә кулы күтәрелмәс. Пионерга кергән чагымда сораганнар иде:

— Обком секретаребыз кем? — дип.

— Табеев! — дип, чатнатып җавап бирдем.

— Молодец! — диделәр.

Нигә «молодец» булмыйм ди әле? Бик афәрин мин. Аны да белмәгәч, пионерга керәм дип йөрмәс тә идем.

Салихҗан абый белән килешмәдем. Өлкәннәр дә аңа күз акайтып кына карадылар. Күпне күргән Зөфәр абый, аның колагына пышылдап:

— Мондый сүзне дөрес булса да сөйләмиләр, ахыры бар,— дип кисәткәч кенә күңелем урынына утырды, читкәрәк тә китеп бастым. Өркетте әле үзен, бик яхшы эшләде. Юкны кешегә сылтамасын. Әмма каян килгән соң бу аккош? Канаты да җәрәхәтләнгәч?

Өлкәннәр үзләрен борчыган сорауларга җавап табып бетергәннәрдер, Салихҗан абыйдан соң сүз алышмадылар. Аккошны кумаска-өркетмәскә киңәшләшеп, һәркем үз җае белән китеп барды. Су өсте һаман да томан иде. Без, малайлар, таш атмаска кисәтелгәч, кайту юлына борылдык.

— Атаммы соң,— диде Нәсим.— Нигә мин аккошка таш атыйм ди. Кулым корыр...— дип, әллә нинди ырымнар хакында сөйләп бирде. Каян барысын да беләә диген син? Әбисе сөйлидер инде.

Тыкрыктан күтәрелгәндә буа өстенә борылып карадым. Аккош, мескенем, сагышлы гына уңга-сулга йөзә, томшыгы белән су өстеннән нидер җыя-эзли иде. Минем күңелемне борчулы уйлар биләп алды: очып китә алмас микәнни? Ничек безнең буага төшкән икән ул? Очып килмичә, ничек килсен? Әйе, әйе, ул бит очып килгән, димәк...

Бу фикер төенләнешеннән күңелем үсеп китте. Нәсим белән шуны уртаклашасым, аны да сөендерәсем килде.

— Кара әле,— дидем мин, сүземне чак-чак җыярга өлгереп.— Ул бит монда очып килгән! Димәк, канаты каерылмаган! Ул шулай ук очып китә ала! Беләсеңме, очып китә ала!

Нәсим аптырап калды. Аннан соң елмаеп куйды да әйтеп салды:

— Ничек китсен ди ул. Канаты каерылган дигән сүз — парын югалткан дигән сүз була, белдеңме? — диде.— Бер дә радиодан җыр тыңламыйсыңмыни? Аккош бервакытта да ялгызы гына оча алмый. Парын эзләячәк, көтәчәк. Аны тапкач кына китәчәк!

— Кышка кадәр булса да торачакмы?

— Торачак!

— Ничек?

— Менә шулай!

Минем елыйсым, үксеп-үксеп, Нәсимне кыйный-кыйный елыйсым килде. Нигә шундый хөкем чыгара ул? Яхшыдан әйтсә ни була?

— Бәлки алар икәүдер? Син бит, аккош ялгызы очмый, дисең. Бәлки аның пары да монда гынадыр?

— И ахмак!— Тагын мине сүзләре белән сытып ташлады Нәсим.— Аларны куркытканнар. Бел. Берсен атканнар. Монысы белми калган. Куркып очкан. Су күреп, монда утырган. Куркуы узгач, ярын исенә төшергән.

— Нигә атканнар аны, нигә атканнар? — дип кычкырдым да өйгә таба йөгердем. Сарай почмагына качып, үксеп-үксеп еладым. Иртән ашамыйча чыгып чабуым искә төште. Тамагым ачканга өйгә кердем.

Әнкәйнең коймаклары суынып килә иде инде. Өстәл тирәсендә һичкем юк. Чәй — кайнар, аш — җылытылган.

Тиз генә тамак ялгадым да, бер телем икмәк кыстырып, тагын су буена йөгердем. Инде ак томан тарала башлаган, бары тик куерып үскән, көздән бераз сары йөгергән таллык тирәсендә генә челтәр кебек эленеп тора, аккош та шунда, якты сары кояштан качып, үз сагышын җыйган хәлендә боегып кына утыра иде.

Беләм мин ул әрәмәлекнең юлларын. Җәй буе шунда уйнадык. Безнең оч малайларының корып куйган чатыры да бар әле анда. «Шалаш» дип, йөртәбез. Имеш, безнең «генеральный штаб». Сугышлы уйнаганда бик кирәкле урын. “Дошманнар”ны шунда тотып китерәбез, кичләрен, җыелышып, төрле уен-көлке сөйләшәбез. Мин дә төрледән-төрле әкиятләр чыгарып шаккатырам. Табигатьнең серле һәм яшертен почмагы ул. Аккош та менә шуның өчен анда барып

сыенган.

Куендагы икмәк телеменнән борынга тәмле ис кереп тора. Яратып ашар аккош, тамагы ачкандыр. Аңа җим бирергә һичкемнең башына килмәде бит.

Куркытмас өчен читләтеп, мыштым гына шулай таллыкка якын килдем. Тапталып беткән сукмактан, агач ботакларын аралап, аккош янына киләм.

Агачлар арасыннан аккошның озын муены, кабарып торган канатлары аермачык шәйләнеп, затлы рәсемнәрдәгечә күзне иркәли. Ашарга җим эзләп суны чапырдата бугай?

Икмәк телемемне кисәкләп учыма тутырдым. Яр кырыена бик сак кына төштем. Куркыта күрмим. Аңламас изге ниятемне. Учымны алга суздым, һәм туктап калдым.

Аккош гүя кеше тавышы белән сөйли-сөйли елый иде. Нәкъ кызлар кебек. Күзләре сагышлы һәм кызыл. Башы күкрәгенә яткан.

Мин катып калдым. Әллә аккошның моңы, әллә инде күзләре тәэсир итте. Ни алга, ни артка кузгала алмадым.

— Йа Рабби Ходаем, бәндәләреңне изгелекләреңнән ташлама! Бу кадәр җәбер-җәфаларны күрсәтеп адәм мәсхәрәләренә калдырганчы, хәерле үлемнәреңне бир, йа Ходаем!

Аккош үзенә үлем тели кебек иде. Мин тетрәнеп куйдым. Учымдагы икмәк кыерчыклары җиргә сибелде, кайсылары яр читеннән суга тәгәрәде. Аккош сискәнде. Ниндидер яманлык сизенеп тавыш бирде һәм буа уртасына таба йөзде. Бу вакытта ул миңа кош түгел, бәлки әкиятләрдә сөйләнелә торган сихер золымында изалanучы хан кызы кебек тоелды. Ниндидер кара җанлы сихерче бер чибәр кызны шушындый газапларга дучар иткәндер!..

Дога яңадан кабатланды. Изге теләкләрен бәндәләргә атап, ул үзенә үлем теләде.

Мин тагын да ныграк курка калдым. Аккош инде ерак иде. Ни хикмәт, ә тавышы якында гына ишетелә.

Күзләрем белән таллыкны айкадым. Чатырыбыз да исән икән. Дога сүзләре шул яктан килә түгелме?

Куркуымнан торып йөгерердәй булдым. Әмма нидер тотып калды һәм мин, качасы урынга сихерләнеп, чатыр авызына якынлаша бирдем.

— Йа Ходаем, ялгыз аккош язмышларын биреп, мине ни өчен шулай ятим кылдың?! Күркәмлек вә чибәрлек белән хозурладың? Озын кара чәч толымнарыма егетләрнең күзен бәйләдең, әмма пар итеп, бәхетле итеп яратмагансың икән, нигә мине яшәтәсең? Нигә миннән «дивана» дип көлдертәсең? Нигә мине Казанга җибәрергә телиләр? Нигә карт әнкәмнән аералар? Мин бит дивана түгел. Нигә миннән көлмәкчеләр? — дип, анда безнең авылдан ятим Мәгъсумә әбинең ятимә кызы Галиябану апа дога кыла иде. Аны ничә көн эзлиләр. Бүксә киереп, кызыл папка белән йөрүче, башын ялтыратып кырдырган, күп ятим-ятимәләрнең үзәгенә үткән Гыйльметдин абыйга: «Мине таларга кергән иде, итәгемә үрелде!»— дип, яла яккан, акылы күченгән, имеш, дип, сөйләгәннәр иде. Хәтта әле: «Балаларга очрый күрмәсен, юләрлеге йогар, йөрәкләреннән кан суыручы убыр икән ул!» — дигән сүзләрне дә Галиябану апа хакында сабакташларым әйтмәдеме миңа? Шушы убыр тоткынлыгында калачакмын бит хә-

зер...

Безнең карашлар очрашты. Курка калдым. Кара чәчле, кара кашлы, алсу иренле ап-ак йөзендәге шардай түгәрәк ике кара күзе хәлемне алдылар. Менә хәзер ул йөрәгемне тишәр, канымны суырыр дип өркедем һәм елап җибәрдем:

— Апа, тимә инде миңа! Галиябану апа, тимә инде миңа!

Җилкәмә үрелде, алдына китерде. Еларлыгым-дәшәрлегем дә калмады. Ни тере, ни үле идем.

— Елама, энем,— дип, йомшак куллары башымны иркәләп сыйпавыннан аңыма кайттым.— Елама, энем! Син бит Фатыйма апаның кече улы,— диде ул, кабатлап.— Елама, үскәнем! Мин сиңа тимим. Мин һичкемгә тимим. Мин җүләр түгел. Дивана да түгел. Кып-кызыл Гыйльметдиннең юк-бар сүзенә ышанма. Ул мине эзәрлекләп йөри. Биш хатын алып, барысын да гүр иясе итте. Инде миңа үрелмәкче. Елама, үскәнем! Әйбәт малай бит син, Фатыйма апаныкы!

Күкрәгем ялкынсынып, үксүем яңадан куәтләнде. Әмма хәзер курыкмый идем инде. Бары тик күзләрем сәер хәлләр күрүдән вә яман уйдан соң өркүемнән күңелем генә урынына утырып җитмәгән.

— Елама, үскәнем!

Ул тагын чәчемнән сыйпады. Куенын ачты. Итәгендә иркәләнеп сулыш алдым. Күңелем утырды. Тәнем калтыранмый иде инде.

— Монда нишләп йөрисең? — дип сорады Галиябану апа, бераздан.

— Аккошка җим бирергә төшкән идем,— дип, куенымдагы икмәк телеменнән калган кисәкне чыгардым.

— И бала,— диде ул, ягымлы тавышы белән.— Күңелең изгелектә икән, күркәм бәндәләрдән булырсың!

Бераз тынып торды.

— Аккош кеше кулыннан җим ашамый ул, рәнҗесә. Ялгыз бит, парын җуйган. Кешедән яхшылык күреп өйрәнмәгән, яманлык кына күтәргән. Нинди изгелек белән килсәң дә кабул итмәс. Бир ул икмәк кисәген миңа, үскәнем? — дип әйтте.

Мин, учымны ачып, аңа таба суздым. Аннан тәмле ис килеп, борыннарны кытыклый иде.

— Әле яр буенда беразы чәчелде. Хәзер җыеп китерәм,— дип, таллар арасына коелган җирдән башка кисәкләрен дә табып бирдем.

Галиябану апа рәхмәт әйтте һәм өстәп куйды:

— Үскәнем, минем монда икәнемне кешегә сөйләмә, ярыймы!

Сүз бирдем. Әмма никләргә генә:

— Сезне моннан беркем дә таба алмас, бу урынны иптәшләремнән башка һичкем белми!—дип әйттем икән.

Ә ул ышанды. Аркамнан сөеп куйды:

— Изге бала икәнсең. Юлың гел шулай игелектә булсын!— диде.

Серемне һичкемгә сиздермәдем. Таллар арасыннан чыгып, яр кырыена килеп утырдым. Буа уртасында моңсу гына аккош йөзә. Чиста һәм ап-ак канатларын иңенә элгән, сагышлы башын аска салындырып, озын муенын бөкләгән хәлдә үзе. Яр кырыена килергә уенда да юк. Ашыйсы килмидер инде. Күңеле тулы уттыр. Сагыну, сагыш, моң-хәсрәт уты.

Мин ялгыз идем. Буа тирәсендә һичкем юк. Шушы хәлемдә күпме утырганмындыр, әнкәйнең кычкырганын ишеттем:

— Улым, кайт инде, улым!

Борылып карадым. Әнкәй тыкрык башына сыенган-качкан җиреннән мине дәшә. Кул болгап ашыктыра, әмма монда таба ни өчендер килми иде.

— Әнкәй, күр әле аккошны! Кил инде! — дип, мин дә кычкырып аны үз яныма чакырдым.

Әмма әнкәй дәшүен дәвам итте. Ничектер куркынып та, әрнеп тә чакыра төсле иде ул. Кул болгый, нидер әйтә, ишетелеп җитми.

Мин әнкәй янына йөгердем. Күзләре борчулы, гүяки артымнан Су анасы куып килгәнен күреп, шулай куркынган төсле иде.

Итәгенә килеп сарылдым:

— Әнкәй-й-й!

Йөзе агарган әнкәйнең борчулы күз карашларыннан күңелем кузгалып киткән иде. Бераздан тынычландым.

— Улым, төшмә инде бүтән анда. Киткәнеңне күрми калганмын. Ялгыз йөрмә,— дип үтенде әнкәй.

— Ярар,— дип ышандырдым.— Ярар, әнкәй!

Өйдә рәхәт иде. Әмма аккош сагышына килеп кушылган Галиябану апаның язмышы өчен әрнү күңелне борчыган, тәнне арыткан, акылны томаландырган.

Чәй эчтек. Юктан сәбәп эзләпме, күршебез Хәдичә апа кереп, ул да кайнап утырган самавыр янында урын алды. Җиләк кайнатма-вареньесын кашыклап кына каба биреп, тулы һәм кызарып киткән бит очларына бәреп чыккан эссе тир бөртекләрен яулык читенә җыя-җыя сөйли торды:

— Аккош зары хәвефле ул. Киленнәрнең буен шиңдерә, балаларның күңелен сындыра. Авылыбызга бер-бер хәтәр золым төшмәгәе дип шикләнгән Кәүсәрия абыстай. Кыз-кыркынны, бала-чагагызны аккош күрергә дигән булып җибәрә күрмәгез. Җәфасы, хәвефе зур булмагае!

Әнкәй өздереп кенә миңа карады. Болай да борчулы күңелемә караңгы шом төште.

— Ялгыз аккош күргән кешеләр бәхетсез булалар икән. Гомер буе аның сагышы күңел түреннән китми, ди!

Хәдичә апа сөйләде дә сөйләде, аның саен әнкәй борчылды. Ни әйтергә сүз таба алмады бугай, каршыдан да, җөпләп тә эндәшмәде. Тагын берәр чынаяк чәй ясады. Хәдичә апа сүздән бүленә белмәде. Җиләк кайнатмасын майлы коймакка ягып сыйлана бирде:

— Урыс Мәгъсумә кызы җүләр Галиябануны калага озатмакчылар икән. Качып йөри, ди. Гыйльметдингә кул күтәргән бит. Сәвит кешесенә. Җүләрләнгән икән, малай, диванага калган, ди. Калага, сары йортка озатмасалар, бөтен авылыбыз белән харап булырбыз. Алла сакласын, ут-күз чыгарып куюы бар. Урыстан юньле бала туамыни?..

— Нигә Мәгъсумә абыстай урыс булсын ди, татар хатымы бит ул,— дип кабатланып әйтте әнкәй. Бу вакытта аның зәңгәр күзләре куркынып зурайган иде, озын кара чәчләрен җыештырып торучы яшел яулыгы ачылып, толымнары таралып китте. Өстәл яныннан кузгалып, аралык артына керде дә төзәтенеп-бөр-

кәнеп чыкты. Вак чәчәкле озын күлмәге өстеннән япкан кызыл җирлекле алъяпкычының билен бушатыбрак бәйләде, чиста оекбаш кигән аяклары белән генә идән паласының җыерылган җирләрен төзәтеп куйды һәм:

— Мәгъсумә абыстайны яшьли беләм. Сез бит күченеп килгән кешеләр. Гыйльметдин сүзе генәдер ул... Мәгъсумә абыстай да кызы Галиябану белән күченеп килгән кеше инде, анысы. Әмма алар урыс түгел. Кызын биленә күтәреп, чәчәктәй чакларында яңгыр-кар дип тормады, яланаяк хәлендә дә колхоз дуңгызларын көтте. Ни ир, ни егет затыннан берәрсе бу эшкә алына алыр идеме? Һәркем баш тартты, ә алар бу йөкне хатын-кыз башлары белән күтәрделәр. Моның өчен генә үзләрен урыс дип атау дөресме соң?..— дип, бик борчылган хәлдә сөйли-сөйли, самавыр алдына килеп утырды, тагын берәр чынаяк чәй ясарга теләде. Ашыкмады.

Сөйләшүләре бозылып киткәндер, беразга тынып калдылар. Салкын болыт килүдән җыерылып калган тавык шикелле хәлгә кергән Хәдичә апаның йөзенә курку төсмере йөгерде, нәрсәседер исенә төшкән кебек тәрәзәгә калкына-калкына, урам якны күзәткәләп алды. Калын һәм киң гәүдәсе бер күтәрелеп, бер яңадан урынына утырды. Өстәл янында ул артык иде.

— Карале, күрше, ни, картым бакча башына гына менеп, киткән иде, күренми, кайда йөри икән?— дип сукранды да, чынаякны тәлинкәсенә әйләндереп, амин тотты.— Кузгалыйм әле, озаклап утырдым бугай, чәегез өчен рәхмәт!

Кайчан китә инде бу дип әйттерерлек итеп тагын өч-дүрт минут көттерде ул мине. Әллә ниләр сөйләп, гайбәттә авыз чайкамакчы идеме, әллә капылт кына күтәрелә алмыймы, белмим, әмма туйдырып бетерде.

Артыннан барып, әнкәй ишекләрне ябып килде. Ярты ачык калдырып чыга торган гадәте бар шул.

Минем баш тагын да миңгерәүләнгән, тәннән көчем тәмам киткән иде. Хәдичә ападан соң өйнең эче дә нурсыз калган кебек булды. Әнкәй дә һични сөйләшмәде. Чаршау артына кереп, карават башына бөгәрләндем. Күзләрем йомылды.

Галиябану апаны ялгыз аккош кебек су өстендә йөзеп йөргән, нидер әйтергә теләп газапланган итеп төшемдә күрдем һәм саташудан уянып киттем. Өйгә ут элеңгән, урамда төн.

Мин баштарак аңлый алмадым. Урын-җир өстенә чишенгән хәлдә яткырганнар, башыма юешләп яулык куйганнар, бөтен тәнем, битләрем ут кебек яна иде.

Кузгалганымны ишетеп, караватянына әнкәй килде. «Ә-ә, уяндыңмы, улым? Авырыйсың бит!» — дип, учын маңгаема куйды. Яңа гына башымнан шуып төшкән яулыкны алып:

— Компресс куярга кирәк, бала ут яна, атасы! — дигән нәтиҗәгә килде һәм әткәйне ашыктырды.

Муенны урап, калын һәм җылы компресс салдылар. Кайнар чәй каптырып, өстемә тагын да өстәмә бер кат юрган яптылар. Мин тирли башладым. Хәлсез күз кабакларым ябылды, бөтен тәнемдә авырлык иде.

Икенче көнне мәктәпкә бара алмадым. Өченчесендә дә авырдым. Дүртенче көнемдә хәлем яхшыра төшеп, аякка бастым. Баш әйләнеп, күз алларым караң-

гылангач, тагын яттым.

Кичкә хәлем яхшы иде инде. Иртәгәсе көн өчен букчама китап-дәфтәрләремне тутырдым. Апам да Нәсимнән өй эшләрен белешеп чыкты, дәресләремне хәзерләтте.

Мәктәптә чиста һәм рәхәт иде. Директорыбыз Нәкыйп Әмирович ишек төбеннән үк аяк киемен салып керүне катгый рәвештә таләп итеп куйган, һәр ялгыш басылган эзне идән юучы апалар хәтерләп-сөртеп кенә торалар. Хәтта аяк киемен дә юдыралар. Болай ук булганы юк иде әле.

Ул көнне миңа иптәшләр дә, укытучылар да әллә ни игътибар итмәделәр. Тәнәфесләрдә олы залга чыгам да, төрле уеннарны карап, шау-гөр килгән сабакташларымнан читтә, почмактан урын табып утырам. Шушы ук рәвештә соңгы дәрескә чакырган звонокны да көтеп алдым. Әдәбият иде.

Укытучыбыз — ягымлы һәм йомшак тавышлы Халидә апа Сөләймановна, һәммәбезгә дә яттан белгән, яки үзлегеңнән чыгарып, бирәр шигырь язарга кушты. Дәфтәрләребезне ачып, эшкә керештек. Мин, тәрәзәгә карап, озак кына уйланып утырдым. Иҗади эш булганлыктан, тәрәзәгә күз салу рөхсәт ителә иде. Күңелемдә көз. Сагышлы ялгыз аккош моңына Галиябану апаның язмышы хакындагы уйлар килеп буталды. Хисләр нечкәрде, бәгырем төбеннән кайнар күз яшьләре ургылып чыгардай булды. Бераздан бөтенләй башка нәрсәләрне хәтердән кичердем. Авылымны яратканым, аның матур бер урында, табигатьнең җәннәт почмагында урнашканлыгын уйлап, хыял диңгезенә чумдым, күңелгә талгын гына агылып шигъри юллар килә башлады:

Туган авылым таулар янында,  
Минзәләнең сулъяк ярында,  
Шунда үтте минем бала чагым,  
Йөгреп йөргән малай чакларым...

Беренче сүзләр икенчеләрен ияртте, икенчеләре — җөмләләрне. Шигырь техникасыннан хәбәрдарлыгым әлегә юк чамасы булганлыктан, күңелемә килгәнне тездем дә тездем. Үз якташларымны эшчән, тырыш, бәхетле итеп күз алдында тотып яздым. Барысын да хөрмәтләп, уңганлыкларына соклануымны белдердем.

Шигырем матур гына килеп чыкты. Күңелем күтәрелде, телем ачылды. «Малай чакларым үтеп китте» дигәнрәк шигъри «ялганны» акылым сизенмичәрәк калды. Ул арада дәрес бетте. Өйгә кайтканда Нәсим иярде. Эттән-көчектән курка ул. Кәефем яхшырудан, юк-бар үртәнүдән, елмаеп көлүдән көн дә яктырып киткәндәй булды. Кинәт өч тапкыр шартлау тавышы ишетелде, сискәнеп киттек.

— Мылтыктан аталар,— диде Нәсим.— Әйдә, йөгердек! Барып карыйбыз. Су буенда аталар.

Тыкрыктан болынга таба чаптык. Нәсим ялгышмаган икән. Кызыл фуражкалы, зәңгәр кительле берсе — юантык һәм икенчесе — килбәтсез милиционер, өч җәпле ыргак бәйләнгән озын бауны буа уртасына ыргыттылар да, аккошның үле гәүдәсен яр кырыена сөйрәп чыгарып, муеныннан элеп кенә машина артын-

дагы ачык ишектән кәгазь тартмага ыргыттылар. Безгә игътибар да итмәстән, көлешә-көлешә:

— Шашлыкка шәп!—дип сөйләнделәр.

Мин баштарак аларның нәрсә эшләгәнен аңышмыйча тордым, аннан соң, ачуым кабарып, көчем җитмәсә дә дөмбәслисем, кул-аякларын тешләп өзәсем килде. Әмма алар ул арада машиналарына төялешеп киттеләр дә бардылар.

Таллыкка таба йөгердем. Әмма анда Галиябану апа да юк иде. Яр кырыена килдем. Таллык элеккечә куе түгел, ике-өч көн эчендә сары яфракларын коеп та бетергән, сирәкләнеп калган кебек.

Күзләрем акайды. Буа уртасында Галиябану апаның башындагы кызыл чәчәкле кара яулыгы чайкалып торды, торды да суга батты. Үлде микәнни? Суга батты микәнни?

Өйгә таба йөгердем. Бу әллә яулык, әллә аккошның каны идеме, белмим! Капка төпләренә кайтып җитә язган Нәсимне дә узып киттем, өйгә атылып кердем дә мендәргә капландым. Әнкәй ишегалдында булган, ниндидер хәвеф сизенеп, артымнан керде:

— Нәрсә бар? Улым? Ни булды?

— Галиябану апа суга батып үлгән! — дип, такмаклап елый бирдем.

— Ничек инде? — дип, сәерсенде әнкәй.— Әле кичә көндез калага алып киткәннәр иде бит үзен, больницага,— диде.— Каян болай буага кайтып батсын ди әле ул?

Күңелемне аптырау биләп алды. Әнкәй һәммә эшне яңабаштан аңлатып биргәч кенә төшендем. Гыйльметдин дигән “бурсык” тәки үзенекенә ирешкән икән.

Көн артыннан көн үтте. Кыш башланды. Халык телендә яшертен генә сүз йөрде: «Мәгъсумә карчык Гыйльметдинне каргый икән, тәне мәңге гүр күрмәсен, этләр ашасын, кызымны ятларга сатып җибәрде, ятим итте, дип бәддога укый икән, ди». Боларын мин дә ишеттем. Әмма Галиябану апаның хәле начарлана барганын гына белми идем.

Анысы да берничә көннән мәгълүм булды. Җомга көн кич белән Галиябану апаның үле гәүдәсен Казаннан алып кайттылар, шимбәдә күмделәр. Авылның олысы-кечесе җыелган иде, диделәр. Мин дәрестән китә алмадым. Әмма ул көнне бөтен мәктәп шаулады.

Галиябану апа юләрләр йортында диваналардан күп җәбер-золым күргән. Табиплар аның сау акыллы икәнлеген белсәләр дә, Гыйльметдин абзый кебек партия кешесе әйткән сүзгә каршы килә алмаганнар, төрмәдәге кебек тотканнар. Мескен Галиябану апа, газиз әнкәсен һәм авылыбызны сагынып бик күп елаган, ахырда саташып ук китеп, дүртенче катның тәрәзәсеннән сикереп, капланып төшкән, үлгән.

Боларны ишеткәндә йөрәгем тотты, колагымда Галиябану апаның сүзләре яңгырады: «Йа Ходаем, хәерле үлемнәреңне бир, йа Ходаем!»

Әмма язмышы фаҗига белән өзелде.

Берничә айдан газиз әнкәсе Мәгъсумә абыстай да вафат булды. Каберен кызы янына, гүрен кызы ягына куйдылар. Васыяте шулай булган.

Иске, тәбәнәк салам түбәле өе һәм бәтиләре белән кәҗәсе ятим калды. Шу-

лай да тора-бара кайсы малы кемнең кулына кереп бетте. Акрынлап алар хакында бөтенләй онытып, авыл үз көенә яшәвен дәвам итте.

Әмма минем күңелем тулы сагыш иде. Тыштан авызым ерылса да, бәгырь төбендәге авыр таш һаман-һаман үзен сиздереп куя һәм тирән уйларга чумам.

Язгы ташкыннар белән буа бүселеп, суы китеп барды. Ә төбендә комга укмашкан әллә Галиябану апаның яулыгы, әллә инде аккош каны һаман да бардыр төсле. Ул юылып беткәнче авылыбыз тынычлыгын таба алмас, күзләрен авыр кайгы белән сагышланып калыр кебек. Күңелләргә моң тулыр. Бу — ялгыз аккош моңыдыр?

## АВЫЛ МӨГАЛЛИМНӘРЕ

*Хикәя*

*«Мин авыл мөгаллиме булырга хыялландым һәм,*
*ниятемне тормышка ашырып, бәхет таптым!»*
***Дустым хәбәреннән.***

### I

Без икебез дә бәхетле идек!

«Алар рәхәт яшәделәр дә инде!» — дип артыбыздан әйтеп калалар икән, бу чын сүз булыр. Әмма тормыш һаман матур гына ага димени? Көннәребез бозылып китсә, Сәлимәм матурым, чибәрем, бәгырем мине тынычландырырга ашыга: «Бөтен дөньясында бәрәкәт юк бит! Имин булыйк, сау-сәламәт! Җайланыр әле, сабыр итик, җайланыр!» — дип, ягымлы сүзләре белән күңелдән юк-бар уйларымны куа. Йомшак кулларын ике җилкәмә куя:

— Син — корабым, мин — җилкәнең бу тормыш диңгезендә...

Ә мин аңа кушылып өстим:

— Иминлек булса, йөзәрбез сәгадәт киңлегендә!

Хәсрәтемнән аерылам, Сәлимәмне кочакларыма күтәреп алам да тирбәтәм, иркәлим, үбәм һәм сөям. Бөтен тәнем буйлап, һәр күзәнәкне, мускул һәм сөякне кузгата-кузгата тыелгысыз, идарә итеп булмый торган, башбаштак һәм җилле бер хис йөгерә, мине бөтенләй диярлек үзендә эретә; акылымны, фикеремне, уемны, хәсрәтемне, җанымны һәм шуның кебек мең төрле сыйфатларымны зат-

лы һәм татлы теләккә әверелдерә. Иреннәрдә иреннәр наз таба, бәхет, иминлек. Әйләнә-тирәм чайкалып китә һәм шунда сәгать суга. Иске, борынгы сәгать. Авыл сәгате. Капкачсыз, пыяласыз. Фатир хуҗабыз Дания әбинең йорт җиһазларыннан миңа иң ошаганы; беренче күрүдә үк: «Монда иң серлесе — мин!» — дип хәбәр салган кебек булган иде әле ул, мактанчык.

— Хәтерлисеңме без бу фатирда сәгать ничәдән бирле яшибез?

— Хәтерлим, Сәлимәм, хәтерлим. Нәкъ көндезге унике иде. Ә хәзер — төнге!

— Ә бу сәгатькә карасаң, вакыт бер дә узган төсле түгел, һаман шул унике!

— Төнге... Көндезге түгел шул! Сәлимәм миннән көлә, үземне шаярта.

— Былтыргы түгел, быелгы! Мин килешәм.

— Көзгә бер ел була!

— Әйе, бер ел...

Сәлимәм китап укуын дәвам итә, мин үземнең язу эшенә чумам. Аның авыр да түгел, җиңел дә әйтелмәгән серле һәм бераз үртәлеп: «Әйе, бер ел...» — дигәне күңелемә кереп оялый. Эшемне яңартып җибәрә алмыйм. Бер-бер артлы барча вакыйгалар хәтер сандыгында кайнашып алалар.

Әйе, август ахыры... безнең монда яши башлавыбызга төгәл бер ел тулачак. Әмма мин ул узылган көннәремнең берсен генә дә әрәмгә, заяга, бушка үткән дип әйтә алмыйм. Чөнки Сәлимә белән тормышым бәхет һәм сәгадәт эчендә бит!

Без икебез дә яшь мөгаллимнәр, ягъни укытучылар. Иң кирәге, сайлаган һөнәребезне, кылган гамәлләребезне дөрес дип беләбез, эшебезне яратабыз.

Сәлимәм дә, мин дә бу тирә кешесе түгел. Ул — Стәрлебаш ягыннан, башкорт суын эчеп, иркен һавасын сулап, нигъмәтенә шөкер кылып үскән татар (ә ул үзен болгар дияргә ярата) сылуы. Ә мин исә — татар туфрагында аунап җитлеккән «милли шалкан»! Әйе-әйе, «милли шалкан»!

Студент чакларымда, Казан университетының филология факультетында укыган дәверемдә, химия-технология институтындагы сабакташ дустан телемә күчкән «шалкан» сүзен кирәксә-кирәкмәсә дә әйткәләп кыландыра идем, бара торгач, үземә тагылып калды. «Милли шалкан» кушаматын гадәтемнән арындырыр өчен Сәлимәм бирде. Ә мин бөтенләй үпкәләмим моңа. Телемнән төшереп калдырырга туры килсә дә, бик дөрес, урынлы әйтелә торган сүз дип уйлыйм. Чөнки шалкан ак була, чиста, түгәрәк, бераз әчкелтем дә, төчкелтем дә дигәндәй, нәкъ татарның үзе төсле. Кем-кем, әмма мин милләтемнең нинди балчыктан икәнлеген бик яхшы беләм дип уйлыйм. Юккамы татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, инде бер ел әдәбият укытучысы булып эшлим?

Иртәгә укучыларым минем фәннән имтихан тотачаклар. Арада шигырь язучы бер кызга гына ышанычым җитеп бетми. Хыялыйлыгы аркасында танып белүнең кадерен аңлап җиткерми, буталып бетә. Әмма әдәби әсәрләрне су кебек эчә, һәр каһарманын, һәр вакыйгасын, хәтта очраклыларын да бик яхшы хәтерли, сөйләп бирә. Тик анализы гына юк. Кереп китә дә башы ката. Аңа һәммә мөгаллим хәер-хаһлы, яраталар, сокланалар, аның белән мактаналар. Дөрес эшлиләр. Бу укучы мәктәбебезнең генә горурлыгы түгел, илкүләм шәхес булачак әле. Мантыйкый-логик фикерләвен үстерүгә дә һәрдаим игътибарын бирсә иде

ул! Ел буе өйрәттем, үзе дә аңлый:

— Абый, күңелемә канатлар үсә дә телем аның артыннан оча бугай минем. Колакларым һәр сүзен ишетә. Әмма акылым — юк! — дип аклангач:

— Сеңлем, әле алга таба да укыйсың бар. Казан университетына барам, дисең. Анда, беләсеңме, Сәгадәт абыең, Марсель абыең, Флёра апаң, Диләрә апаң кебек үтә дә таләпчән, мантыйктан башка һичнәрсәне кабул итә алмый торган олуг, акыллы, дәрәҗәле академик, профессорлар укытачак. Тәлгать абыең, Азат абыең, Хатип, Альберт абыйларың — зур галимнәр белем бирәчәк. Алар әле үзләре дә танылган язучылар; җитмәсә, мәртәбәле исемнәр алган шәхесләр. Ул язучы, профессор һәм академик абыйларың: «Тукта, бу баланың хыялы чиксез, белеме сай!» — дип нәтиҗә чыгарып куйсалар? Шуның өчен киңәшемне һичвакыт онытма: укыганда, фикерләгәндә, имтиханда мантыйк-логика, чын белем кирәк, аннан башка кешенең акыл-белем дәрәҗәсен билгеләү һич мөмкин түгел! Ә хыял, иҗади ашкыну яшь вакыттагы шигъриятеңдә юлдаш булса да, язмышыңа киртәләр куймасын!

Без шунда сөйләшүне бетерәбез. Әлфия исемле бу бала тулысынча минем белән килешә, рәхмәт әйтә. Бүтән укытучылар, хәтта Сәлимәм дә сөекле укучыма карата артык таләпчәнлектә үземне гаепләләр.

Әмма, ни хикмәт, Әлфия сүзләремне кабул итте, мантыйкка тартылды. Хәтта математика укытучысы да аның сәләтенә соклана башлады. Тик шунысы: май кояшы яшь шагыйрәне тагын адаштырып, хыялга батырды. Ә иртәгә — имтихан, чыгарылыш имтиханы...

Укучылар өчен генә түгел, миңа да тәүге хезмәт сынауларымның берсе бу. Моңа кадәр аларга кем генә дәрес биргән булса да, быел миннән сабак алдылар. Чыгарылыш сыйныф. Фикерләре, дөньяга карашлары оешып кала торган чаклары аларның!

Эшкә урнашкан вакытымда мин «яшел сакаллы» оптимист идем. Мәктәп директоры — йөзгә-биткә мөлаем гына, кара күзле, пыяла күзлекле, сабыр-таләпчән йөзле Асия Мифтаховна, ул әле математика укытучысы да:

— Сиңа татар теле һәм әдәбиятын бирү ярамас, аны кем дә укытыр. Тарихны, географияне ал,— дип караса да, мин үз сүземдә тордым:

— Юк! Ул фәннәргә кыстамавыгызны үтенәм. Мин — татар теле һәм әдәбияты мөгаллиме. Әгәр дә кирәгем юк икән, баш тартыгыз, бүтән мәктәпкә күчәрмен! Борчылмагыз! — дип кырт кистем.

Асия Мифтаховнаның, мондый үҗәт кешене күреп, күзлеге маңгаена күтәрелде. Әмма кешеләрне яхшы аера һәм таный белүе ярдәм итте булса кирәк, бераздан соң карар бирде:

— Яхшы! Ана телен укытырга шушындый чибәр, гәүдәле ир-егетнең атлыгып торуы мине сөендерә. Өлкән сыйныфларда белем бирерсез!

— Рәхмәт!

Минем башка сүзем юк иде.

Монда хатыным Сәлимәгә дә эш күп булып чыкты. Ул да минем белән бер елларда университетта укыды, урыс теле һәм әдәбияты мөгаллиме дигән диплом алып чыкты. Без үзара әүвәлге курстан бирле белешеп йөрдек-йөрдек тә, өченче уку елы башында якынаеп, бишенченең ахырында туй ясадык. Туй дип

инде, өч бүлмәгә өстәлләр куеп, кем нәрсә китерә ала, шуннан табын көйләп, мәҗлес кордык та һәр әйтелгән теләкне тормышка ашырачагыбыз хакында сүз бирдек һәм шуның белән бетте, вәссәлам. Туганнарга хәбәр бирдек, әмма чакырып азапламадык. Язгы кыр эшләре вакыты иде. Соңыннан барсын да йөреп чыктык һәм юллама буенча шушы Бөгелмә якларына килеп, почмакка-почмак диярлек сөзешеп торган меңгә якын йортлы авылны сайладык. Хәер, ронода да башка төрле фикер юк иде. Якында шушы ук җирле советка караган тагын ике кечерәк салалары бар икән, алардан балалар монда йөреп укый. Шул кече авылларның бигрәк тә берсе, тау-калкулыклар арасына сыенып утырганы миңа, артыграктыр — Сәлимәмә ошады.

— Шунда оя корыйк! — диде җанашым, барып кайту белән үк.— Җәяү йөрербез, өч чакрым ерак ара түгел. Юллары да яхшы, яшәү өчен дә тыныч, имин күренә.

— Гомер буе ерак йөреп эшләү арытыр бит?

— Машина алырбыз.

— Шулай бик телисеңмени?

— Әйе, бәгърем, бик тә!..

Башкорт һавасына кинәнеп оешкан холкы-фигыле, күңеле-омтылышлары җиңеп чыкты. Без үз оябызны быел ук корырга ниятләп тә куйдык. Әмма ул иске бер йорт нигезен яшәрлек итү өчен ел түгел, гомер кирәк булыр әле!

Бу уйларыбызны мәктәп директорыбыз белән уртаклашуны кирәк таптым. Асия Мифтаховна үзем дә җавабын таба алмаган сорауны бирде:

— Гомер буе ничек шулай күрше авылдан йөреп эшләрсез соң?

— Ачуланмагыз инде. “Җаны теләгән — елан ите ашаган” диләр бит! Шулай ниятләдек!

Минем катгый һәм юлдан борылмый торган кеше икәнлегемне яхшы белгәнгәме, артык сүз кузгатмыйча гына килеште дә куйды:

— Ярый инде алайса! Насыйбыгыз икән, бәрәкәтле булсын! Ул авылда бер дә терәк санарлык ихата калмаган иде, бәлки җан кертеп җибәрерсез?

Колхоз идарәсендә:

— Үзәккә йорт салып бирәбез! — дисәләр дә, Сәлимәмнең инде ныгытып куйган хыялларын җимерәсем килмәде. Сүземнән кайтмадым. Асия Мифтаховна да мине яклап чыкты. Утырыш аның сүзләрен бертавыштан хуплады. Ахырда колхоз рәисе, үземне котлап:

— Кадагын да эзләп йөрисең түгел, склад тулы, барысын да бирәм! — дип белдерде, ышанмыйчарак калган идем, һич ялган сүз булмады.

Март башында карар чыгардылар, апрельдә, карлар эри башлаганчы, бураны да күтәреп куйдылар. Без белми дә калдык диярлек.

Болар барсы да көтелмәгән рәхәтлек һәм бәхетләр иде.

Шуларны уйлый башласам, Мөхәммәт абый Мәһдиевнең татар романтизмына багышлаган лекцияләре исемә төшә һәм: «Әгәр дә кеше үзе сайлаган юлына тугры калса, максатына тайпылышсыз атласа, башкаларга хөрмәт күрсәтсә, ул һәрвакытта бәхетле була һәм һәр җирдә бәрәкәт таба!» — дигән сүзләре күңелемдә кабатланып, эчем-тышым нурлана.

Шулай да бу шатлыклар үземә генә түгел, хезмәттәшләрем, яңа тапкан

авылдашларым, Сәлимәм белән дә бәйле икәнен аңлыйм, бик үк ышанып та җитмим. Үземә карата таләпчәнлекне тагын да арттырам. Башкалар белән танышып-белешергә вакытым җитми. Әлегә авылдагы күп серләрне белмичә яшим. Сәлимәм дә минем янәшәмдә, фикерләр-гамәлләр уртак.

II

Инде соң икән, йокларга ятмый ярамас...

Кинәт тәрәзә өлгесен шакылдаттылар. Мин дә, Сәлимәм дә сагаеп калдык. Төн уртасы түгелме? Көткән кешебез дә юк. Берәрсенең йомышы төшкәндер бәлки?

Яткан җиреннән Сәлимәм юрганын баш очына кадәр күтәрде. Бер-бер ят күздән шикләнүе иде.

Мин пәрдәләрне ачтым. Утны сүндердем. Тәрәзә артында һичкем күренмәде. Ишеккә таба атладым. Бу авылда әлегә дошманлашкан кешем юклыктан, курку өчен сәбәп тә күренми иде. Әмма тәрәзәне кабат кактылар. Әллә ничек сәер булып китте. Өлгеләрне кузгатырлык итеп дөбердәткән төсле иде.

— Мин куркам! — диде Сәлимәм, нидәндер тагын да шикләнеп.

Аны тынычландырырга ашыктым:

— Бер дә борчылма. Тәрәзәне алып кермәсләр, мин чыгыйм әле...

— Мин дә...

— Юк, юк! Үзем генә!

— Берәр яманы булса?

— Тимәсләр әле, борчылма...

— Башыңа сукмасыннар.

— Кем?

— Алай димә, тормыш бозылды! Дөньяда усаллар күбәйде!

— Ярар, борчылма. Берәрсенең йомышы төшкәндер.

Шулай дигәем булды, тәрәзәне кабат кактылар һәм мин эшнең нәрсәдә икәнен күреп, көләргә тотындым.

— Ни булды?

— Бәрәңге элеп куйганнар! Укучыларыбыз шаярта.

Ишек ачып, хуҗабикә йоклаган бүлмә аша тыныч кына узгач, өйалдына чыктым. Бакча ягыннан сөйләшкән авазлар ишетелде. Алар кызлар иде. Берсе — Әлфия. Имтихан кайгылары юк икән үзләрендә!

Өйалды ишеге ачылган тавыш аларны өркетте, кайсы кая качтылар. Мин исә артларыннан куарга теләмәдем, кисәтеп кенә калдым:

— Иртәгә имтихан бирәсегез бар бит, Әлфия сеңлем, кайтып йоклагыз!

Бауга эленгән бәрәңгене һәм аны тартып-тартып хәрәкәтләндерү өчен бәйләнгән кәтүк җебен өзеп, күрсәтү өчен Сәлимәмә алып кердем. Ул барысын да күреп, кемнәр икәнлекләрен белеп үк калган икән.

— Иртәгә акылга утыртыйк үзләрен, тапканнар шаяртыр кешеләрне...

Үз хатирәләрем эчендә кайнашканга Сәлимәмнең фикере белән килешмәдем һәм аны тынычландырырга ашыктым:

— Кирәкмәс! Алар яшендә мин дә шулай шаярткалый торган идем. Усаллык белән түгел бит...

Әмма Сәлимәмнең ачуы кабарган иде. Ул суынырга теләмәде. Мондый халәтендә үзен беренче тапкыр диярлек күрә идем, шунлыктан ничек юатырга да белмәдем.

— Яклама шул Әлфияңне!

Аптырап киттем:

— Сәлимәм, ни сөйлисең? Ничек минем Әлфиям булсын әле ул?

— Бөтен мәктәп белә!

— Ничек?

Сәлимәм җавап бирәсе урынга елап җибәрде. Аны юатырга теләдем. Яңа килгән укытучыларның тәрәзәләренә ничек бәрәңге элеп, бер тапкыр үземнең дә шаяртканым барлыгы хакында сөйләдем.

— Ул вакытта мин бит шушы балалар төсле юри кызык ясаган идем. Укытучы апага мәхәббәтем билгесе дип һичкем кабул итмәде. Мөмкин эшме соң? Инде алар үз чордашларына гыйшык тоту яшендә. Укытучы апа-абыйларны җиденче сыйныфта гына яратасың ул. Аннан соң хөрмәт кенә кала, чын мәхәббәт соңрак килә. Минем сиңа гыйшкым шикеллесе...

Әмма Сәлимәм бу сүзләремә колак та салып тормады, күзләреннән яшьләрен һаман да сөртмәде. Бәгыремне кочагыма керттем. Чәчләреннән сыйпадым, Һай, яратам мин аның шушы хуш исле, йомшак, акылымны адаштыра торган толымнарын!

— Йә инде, җитәр! Әйдә, йоклыйк!

— Бәгырем! — Сәлимәм тынычланган төсле иде. Юк икән: — Ул кызга минем ни өчендер ачуым килә. Тыңламый, дәресләремдә ел буе шаярып утырды. Мине кәкре борынлы, ямьсез хатын итеп ясап, өстәвенә такмак та язып, башкаларны да миңа каршы котыртты.

— Кайчан?

— Бөтен мәктәп сөйләде бит!..

— Нигә мин белмим?

— Сиңа һичкем кирәк түгел, гел үзеңне генә кайгыртасың, кешенекен сукыр бер тиенгә дә санамыйсың. Шуңа белмисең!

— Ялган сүз бит бу, Сәлимәм, ялган сүз! Көлке!..

— Минме?

— Юк, бәгырем, мин көлке!

Сөйләшүнең алга таба әһәмияте юк иде. Чыннан да, мәктәпнең вак борчуларына чумуым сәбәпле, Сәлимәмне күп вакытлар бөтенләй онытkалыйм шул. Дөрес әйтә, мин үз дөньяма яшеренеп барам булса кирәк, күбәләк курчагына әверелеп киткән кебек. Эшемнән гайре һичкем һәм һичнәрсә кызыксындырмый башлады ахрысы.

Сәлимәмне иркәләп кочагыма тагын да кыстым. Аны бик тә яратам бит. Акылымнан шашардай булып, үлеп-бетеп яратам.

Тәрәзәдән ай карый, йолдызлар күз сала. Мин Сәлимәмнең иреннәрендә иреннәремә наз табам, йөрәкләрнең дәрте бергә кушыла. Калку, ак, йомшак күкрәкләрен, сылу билен кочам һәм без адашабыз. Үбешеп туя алмыйбыз. Дөнья хәсрәтләре онытыла...

— Безнең балабыз булачак!

Сәлимәмнең бу сүзләрен ишетмим, сорыйсым килә: «Ничек? Йорт салмыйча балага бармаска килешкән идек!» — дияргә телим. Әмма батырчылыгым житеп бетми.

— Безнең балабыз булачак. Мин сиңа егет алып кайтып бирәм!

— Юк, беренчесе — кыз!

Акылым урынына күңелем җавап бирә. Сәлимәмнең буена үреләм:

— Ничә айлык?

— Юләр...

— Нигә юләр?

— Ничә минутлык диген?

Аптырап калам. Сәлимәм көлә:

— Моңа кадәр сакландык, бүгеннән — бетте. Йорт салу — синең кайгы. Эшлә! Ә мин сиңа малай бүләк итәргә телим, яңа йортка керүгә — сөенче!

— Кыз!

— Минемчә булачак, бәхәсләшмә, бәгырь! Минемчә булачак!

Күзләрем йомыла. Туачак баламны җитәкләп болында йөрүем күз алдына килә. Татлы хыял безнең икебезне дә эретә.

### III

Имтиханга соңга кала язганмын. Ярый әле хуҗабикәбез, йомышы төшеп, безнең якка кергән. Сәгать тукмакларын тартуыннан уянып та киттем, аһ та иттем.

— Бүген эшкә бармыйсыз дип торам. Уятырга-уятмаска белмәдем,— дип акланды Дания әби.— Ялга чыктылар түгелме соң укытучылар?

Сәлимәмне кайнар түшәктә ялгызын калдырып, бер йотым чәйдән канәгатьлек таптым да чыгып йөгердем. Асия Мифтаховна көлеп каршы алды:

— Рөстәм Әхмәтовичның җилкәләренә канатлар үскән бүген, очып килә! Беренче имтихан алуыгыз белән тәбрик итәм! Уңышлар телим!

Рәхмәттән башка аны-моны әйтү юк инде, сынау алыначак кабинетка ашыктым. Ни хәлләр икән анда?

Әмма борчылуларым бер мизгелдә юылды да төште. Сыйныф нурланып тора, такта һәм өстәлләр ялтырый. Иң әһәмиятлесе — бөтен җирдә чәчәкләр.

— Исәнмесез, Рөстәм Әхмәтович!

Башлап эндәшүче — Әлфия. Әмма минем аңа үпкәм бар. Дөресрәге, минеке түгел, хатыным Сәлимә Назыйфовнаныкы. Шунлыктан игътибар бирү юк! Ул тагын сәлам бирә. Мин ишетмим, һәммәсенә утырырга боерам. Имтихан тәртипләрен кабат аңлатам, сәгатемә карыйм:

— Өч минуттан каршыгызга комиссия килеп утырачак. Бу сынау сезгә зур тормыш юлына ышанычлы адымнар белән керү өчен капка ачсын! Барыгызга да уңышлар телим!..

Шунда ишек ачыла һәм Асия Мифтаховна артыннан ияреп имтихан комиссиясе керә. Дөнья бер мәлгә тигезләнеп калган үлчәү тәлинкәләре хәленә килә. Директорның таләпчән кырыс карашы укучыларны утыртып куя. Сынау башлана. Мин үземне тәүге имтихан бирүче бала хәлендә сизәм. Шулай да сынатасым килми. Ышанам, бик ышанам укучыларыма. Күз белән һәрберсен тынычланды-

рырга тырышам. Әмма Әлфияне урап узам. Аңа ачуым килә. Ничек алай минем бәхетемне, минем Сәлимәмне кимсетергә батырчылык иттең син, әй, кызый!..

IV

Июль урталары җитеп, печәнгә төшәр вакытлар иде. Минем өч атнам мәктәпкә бүлеп бирелгән урманнан утын кисү белән үтте дә китте. Асия Мифтаховна:

— Рөстәм Әхмәтович, яңа урынга ихата корасыгыз да бар, үзегезгә кирәкчә агач булыр, эшкә яраклысын да, утынын да карарсыз шуннан,— дип хәер-хаһлы теләген белдергәч, баш тарта алмадым.

Көне-төне диярлек эшләргә туры килде. Куна-төнә яттык. Сигез ир затына, бергә-бергә күтәргәндә, бүрәнәләр алай ук авыр тоелмады. Беренче көннәрне һич тынгылык бирмәгән чебен-черки, кигәвен ише мәлгуньнәргә дә күнегеп беттек. Битне сакал, тәнне кер басты. Йөзләр каралып, каләм тибрәтүгә генә күнеккән куллар-бармаклар ташка әверелде. Ике атналык дигән эш егерме көнгә җитте. Шулай да күңелем шат иде. Юк-бар бәхәсләргә катнашмадым, эчүгә дә артык игътибар бирмәдем. Сәлимәмне сагынсам да, алда уздырачак шатлыклы һәм тыныч көннәремне хыялымда күзаллап, сабыр итә идем.

Укытучы булганыбыз өчен безгә ике машина утын бирделәр. Аннан тыш тагын төзелешкә яраклы ике йөк агач кайтардым. Барып чыкса, мунча һәм кечерәк терлек абзарын күтәреп кую өчен җитәр кебек иде. Утынны да иптәшләрем эшкә барырдайлардан сайлап бирделәр.

— Сәлимәңә мич ягу өчен йомычкаң күп булыр әле,— диделәр.

Урман эшенә киткәнче үк йортны нигезгә күтәреп, осталар түбәгә тотына калган иделәр. Яңа күршебез белән Сәлимәм сөйләшеп, төзүчеләргә аш әзерли, ул да көне-төне ял күрми иде.

Колхоз рәисе түбәбезне яхшы итеп эшләттергән:

— Нинди шифр ди ул? Калай юкмы әллә? — дип осталар бригадирын эт итеп сүккән. Шуннан соң бу, монда бер-бер сер бардыр дигән фикергә килеп, хатынымнан:

— Безнең рәис белән туганлыгыгыз юктыр бит? — дип белешкәләп тә маташкан.

— Үзе шулай яхшы кеше инде,— дип кенә җавап кайтара алган Сәлимәм.

Мин дә моның сәбәбен белми идем.

— Ничек шулай ярдәм итәргә уйлады икән? — дигәч, Сәлимәмә ничек тә аңлата алмадым. Шулай да:

— Кешелекле кеше... Асия Мифтаховна үтенгәндер! — дигән фикергә килдем.

Беренчедән, хуҗаларның хәер-хаһлы булулары, икенче яктан, авыл халкының безне туктаусыз игътибар күзендә тотулары һәртөрле шик-шөбһәләргә дә төшергәли иде. Әмма чит-ят җирдә оя кору өчен һәммәсенең яхшы күңелле булулары кирәк. Бу исә киләчәк тормышыбызга ышанычны арттыра барды.

Әйткәнемчә, печән өсте җитеп, утын мәшәкатьләрен яңа эшләр алыштырды. Йортыбызның түбә-кыеклары эшләнеп беткән, түшәм-сайгакларын һәм кәчәктупсаларны гына ясыйсы калган иде. Боларны төзелеш бригадасы колхоз үзә-

гендәге мастерскойда әзерләп китерәсе булганга, без дә печәнгә төшәргә уйладык.

Гадәтләре буенча авылда болынлыкларны бригадир бүлеп бирә икән. Болын дип инде, печәнлекләре — тау аралары, көтү керә алмый торган урыннар булып чыкты. Өсләренә урман авып торса да, аны караучылары үзләрен карт алпавытлар кебек хис итеп, анда кешене кертмиләр, ди. Хәтта җиләккә дә хатын-кызлар таулыкларга йөриләр, урман ягын яратып бетермиләр икән.

Мин бригадирны эзләп киттем. Габдулла абзый шәп борынлы, җыерчык йөзле, гәүдәле зат. Ихатага да ул урын күрсәтте, печәнлек хакында инде килеп сүз кузгаткач:

— Энем, ни бит әле, быел бер дә буш урын күренми. Соңардың. Нигә иртәрәк хәбәр салмадың?..— дип башын кашыды.

— Габдулла абзый, эштән аерылып булмады бит...

— Шулай инде анысы...

Каршысына бер ярты чыгарып куйдым, ул аптырабрак калды. Ни әйтергә моңа дигәндәй тагын башын кашып алды.

— Теге вакытта да сыйлап булмады үзегезне дип кенә инде, Габдулла абзый. Менә, йортны салып бетерсәк, Аллага тапшырып, мин әйтәм...— Мөмкин кадәр үзләренчә сөйләшергә тырыштым.

— Анысы инде, энем, йоласы шулай куша. Өй туе кирәк булыр. Әле бүген дә рәис сораштырып алды: «Ничегрәк, Габдулла абзый, язучының йортын бетерәләрме әле?» — ди. Аллаһы насыйп итсә, авылда бер була, дидем. Туйларга исәп дисеңме?

Ул үзенең акыллы һәм хәйләкәр кеше икәнлеген белдерергә теләп авызын ачты.

— Беләбез барысын да...— дип киная итте дә тагын колак артын кашып куйды.— Ач моны алайса, алып килгәнсең икән инде, арылып та киткән. Бибикамал әбиең дә каршы әйтмәс, эш күп булды бүген.

Түр яктан хәбәр килде:

— Тавык ите белән алма мич кашында, Габдуллаҗан, сыйла кунакны!

Торып китәргә кузгалмакчы идем, үз йортына кеше кертеп өйрәткән Габдулла абзый беләгемнән тотты, зур сер әйткән төсле пышылдады:

— Намазга җыена. Тәһарәтен бозасы килми, шуңа бу якка чыкмавы... Әйдә, берәрне!

Йомышымны хәл кыла алмаганлыктан күңелдә шатлык юк иде. Мондый вакытта аракы кабасы киләме соң?

— Мин кузгалыйм инде...

Габдулла абзыйның күзләре сәер караш ташлады.

— Үпкәләмә әле, энем. Барысын да сөйләшеп бетермәдек, сүзне башладык кына бит. Печән өчен кайгыралар димени?

Ул арада хатыны да түр яктан чыкты. Исәнләште. Өстәлгә киң табада тәмле исләр чыгарып пешкән эре бәрәңге белән аралаш тавык итен китереп куйды. Габдулла абзый чынаякларга тигезләп аракы салды:

— Тот әле йомрыңны...

Мин аның әмеренә буйсындым. Йомры дип чынаякларны атауларына инде

күнегеп җиткән идем, әмма бәрәңгене алма сүзе белән йөртүләрен кабул итеп бетерә алмадым. Печән хәсрәте дә күңелдән китмәде. Сәлимәм белән мал-туар асрый башларга, колхоздан буаз тана сорарга исәпләп тора идек. Кышлык печән хәстәрли алсак, бирми калмаслар дигән өметем дә бар иде.

— Кайгырма, егет! — Габдулла абзый йомры дигәнен көрәк куллары белән күтәрде. Бармаклары арасында ак чынаяк гүяки тавык йомыркасы кебек кенә иде, саксыз кысса, сытылып китүендә дә шик юк.— Үзе актыр, үзе сафтыр... Исәнлек өчен!

Мин аңа иярдем. Әмма савытым шактый тирән булып чыкты, каплап бетерә алмадым. Габдулла абзый тагын да кукраеп, түгәрәкләнеп китте. Аның янында минем эре сөякләрем читән казыгы рәвешендәрәк иде. Ул сүзен кабатлады:

— Кайгырма, егет!.. Әгәр дә мал асрау ниятең бар икән — изге эш. Димәк, син безнең авылга яшәр өчен килгәнсең. Бик шәп!.. Табам мин сиңа печәнлек. Бар ул. Наратбаш тау сыртының уң ягында бик матур урын күрерсең. Анда умарталык иде. Инде өч ел ул якка кеше йөрми. Сазлыгы да киңәйде. Тракторлар белән килеп, дегет эзләп, мөртәтләр бозып киткәннән соң көтү дә кергәне юк. Печәне быел матур, диләр. Барасың, күрәсең, чабасың, аласың... Бөтен болыны белән синеке. Быел чистартсаң, киләсе елга шәп печәнлек булачак. Элекләрне җиләге дә күп, яхшы иде. Быел анысы ук юктыр инде...

Габдулла абзый эре бәрәңгеләрне бөтен килеш кабып, кыздырылган тавык ите белән бергә йота бирде. Аның шулай тәмләп ашавы һәм ышандырып сөйләүләре хәмердән бераз кәефләнеп киткән аңны тагын да канатландыра, күңелне җырга тарта иде. Әмма йомышым тәмамланган булу сәбәпле кузгалу җаен карадым. Ачуланып калгандай итсәләр дә, китүем белән риза иделәр. Габдулла абзый үзе капка төпләренә кадәр озата чыкты, кергәндә искәрми калган бозау кадәрле ялкау эте өреп алды, аңа күрше ихаталарда ләңгелдәгән вак-төякләр кушылды. Иңеп килүче кич иртәгә көннең эссе буласын вәгъдә итә иде.

— Кара, энем кем, кергәләп йөр... Йомыш белән генә димени. Сөйләшкәләргә. Дус булырбыз. Бибикамал әбиең дә сезне гел мактап телгә ала. Аллаһы боерса, таякка калган авылыбызны аякка бастырырсыз, җан кертерсез төсле. Менә минем кечкенә малай да, сезнең хакта ишеткәч, авылга бөтенләйгә кайтырмын дигән кебегрәк әйткән. Әбиеңне сөендергән. Картлык көнендә терәк кирәк бит ул!

Артыгын сөйләшеп-сөйләштереп аптыратмадым. Сәлимәмне озак вакытлар күрми торудан сагынуым сүрелеп җитмәгән иде. Хушлашып, рәхмәт әйткәч, китеп бардым. Хатыным инде бер ай ялгызы яшәгән күршедәге фатирыбызда ут сүнмәгән иде әле. Хуҗабикәбез Гафифә әби дә өйдә юк, ярты гомере шәһәрдә уза икән. Әле кичә тагын китеп барган, пенсиясен алырга. Атна-ун көнсез кайтып кермәячәк, ди. Бер баргач, өч улын, дүрт кызын йөреп чыгачак.

## V

Иртәнге кояш белән диярлек уянып, җылы-рәхәт урында Сәлимәмне тагын ялгызын калдырырга кирәк таптым. Йокым туйган иде. Әллә алда яшисе көннәр өчен хәсрәтләрем шулай аякка бастырамы, әллә инде авыл тормышына өйрәнелеп җителдеме, белмим? Кулга каләм тотып язасым, китап алып укыйсым

түгел, бәлки чалгы айкап чабасым килә башлады.

Хуҗабикәнең келәтенә юнәлдем. Такта белән генә терәтелеп куелган ишеге авыр ачылды. Эчендә бер карышлап диярлек тузан утырган иде. Түрдәге хан заманы шкафның пыялаларында артымнан ияреп кергән кояш нурлары чагылды. Мин аңа-моңа кагылырга теләмәдем. Эз калдырып, йорт хуҗасын нигә юкка борчырга?

Авыл келәтендә чалгы эленә торган урын була, керүгә сул якта, югарырак, бәбкәлеккә җайланган чөйдә. Юньле төбәкнең гадәтендә шулай. Нәрсәне-нәрсәне, чалгы ишене теләсә кая ташлап йөрмиләр. Җайлы-җайсыз киселүең бар.

Әбинең карты ни җитте генә кеше булмаган икән. Бер пар олы-кече чалгылар янында озын саплы тырма, өч җәпле сәнәк һәм ярыкка кыстырылган тупас һәм йомшак янавычларына кадәр шушында иде. Боларга мөгаен биш-алты ел тимәгәннәрдер. Һәрхәлдә үз тәртипләрендә тормас иделәр.

Сөенечем ташып чыкты. Чалгыларның какшаган чөйләрен урыннарына утыртып, йомшак янавыч белән ышкып алдым. Ишегалдында үскән үләнне чабып карадым.

— Һай хуҗа абзый, гафу, исемеңне белмим, әмма дә чын кеше булгансың икән! Мәңгелек җәннәтләр насыйп әйләсен үзеңә! — дип, хак күңелдән дога укып, «Әлхәм»не кушып җибәрдем. Үземә дә рәхәт булып китте.

Өйгә кереп, электр плитәсен утка ялгадым. Чәйнек утырттым. Ул арада сыеры, сарыгы, бозавы бергә сан өчен дә тулмый кими барган көтү авылдан чыгып китте. Тыныч эндәшеп кенә Сәлимәмне уяттым. Ә аның торасы килми ятты, иркәләнде.

— Рөстәм, мин шундый матур төш күрдем, яшел болын, саф чишмәләр...

— Менә шунда барабыз да инде бүген!

— Чынмы? Ялганлыйсыңдыр әле, юри шаяртасыңдыр...

— Син җиләк җыярсың, ә мин печән чабармын...

— Ә җиләк калды микән соң әле?

— Нигә калмасын? Июль уртасы гына бит! Егерме алтылары җитсә, кибә башлыйлар. Хәтта кошлар да сайраудан туктый...

— Көз җитә аннары... Яратмыйм мин яңгырлы, салкын, күңелсез көзне, яратмыйм!..

— И-и, бәгырь! Көзгә бик тә, бик тә ерак әле, июль генә бит.

— Барыбер дә...

— Ярар, тор инде. Яшел болын, саф чишмәләрне өндә дә йөреп кайтырбыз.

Алгы бүлмәдә чәйнек ташый башлагач, Сәлимәмне көтеп тә тормастан, плитәне сүндерергә чыктым. Табын ясау хәстәренә керештем. Ул арада хатыным да торды, аңа ишегалдында юынырга су салып тордым.

— Салкын-н-н...

— Әйдә, матурым, чәйнектән кайнарын чыгарам,— дидем, куырылып китүенә борчылып.

— Кирәкми! Миңа моннан да рәхәт су юк төсле,— дип, ул рәхмәт әйтеп елмайды.

Югары очтан кемнеңдер трактор үкертеп төшүе авылны тәмам уятып, хәрәкәтне башлап җибәрде. Көннең эссе булачагына чалт аяз күк, җилсезлек, кош-

ларның инде хәзердән агач күләгәсендә мәш килүләре хәбәр вә дәлил иде. Габдулла абзый әйткән печәнлекнең кайда икәнлеген төгәл генә белмәсәм дә, калкулыктан-калкулыкка күчеп сузылган юлның очына төбәлдем. Ул урманга кереп югала иде.

— Җәяү генә барырга туры килер инде, Сәлимәм!

— Әлбәттә җәяү, Рөстәм! Мин җәяү йөрергә яратам. Табигатькә хозурланып, ашыкмыйча, җай, иплəп кенә.

— Ул вакытта, әйдә, киттек!

Иртәнге чәйне шулай тәмамлап, Сәлимәм кулына җиләк җыю өчен бидон тотты, мин исә сумкама янавыч, бер-ике утырып тамак ялгарлык ризык һәм кечерәк чиләккә тутырып бәрәңге алдым, икенче кулыма җилкә аша чалгы салдым. Безнең белән бергә утлы кояш та атлады, адымнарыбызны санап диярлек барды.

Беренче калкулыктан күтәрелгәч, артка борылып карадык. Яшеллек эчендә чумып утырган авыл үз уйлары вә теләкләре белән кыйблага таба сузылган да безгә кул болгый сыман иде. Яныннан аккан саф, зәңгәр инештә төркем-төркем ак нокталар күренде. Казлар. Су коенырга төшкәннәр.

Ә урта бер җирдә диярлек безнең яңа салган сары йорт түбә калайларында нур уйната.

— Мулла нигезе дигәннәр иде, начар урын булмас,— дип куйды Сәлимәм, авыздан сүземне өзеп алып.

— Мин дә шулай уйлыйм.

Беләгемнән иркәм кысып тотты. Күзләрендә татлы уйлардан күчкән сәгадәт яктысы, йөзендә шатлык иде.

— Без — бәхетлеләр, шулай бит!

— Аллага шөкер диген!

— Диям, диям, Рөстәмем минем, кат-кат шулай диям!

Без юлыбызны дәвам иттек.

Икенче, биегрәк күренгән калкулыкны узгач, урман янында зур гына мәйдан күренде. Мин печән җиребезне күзләдем. Бер башында чишмә, итәгендә сазлык дигән иде, нигәдер юк бит әле андый урын монда?

Әмма игътибарым гына җитмәгән. Юл чатланып киткәч, уң тарафта, урманнан шактый читтәге яулык кадәр бер болынның итәге камышлык икән. Әгәр дә кыр үрдәге аваз бирмәсә, ул тарафка борылып карыйсы түгел идем.

Яулык кадәрле болын дигәнем күз ялганы гына булып чыкты. Чынлыкта шактый киң мәйдан икән. Умарталыктан калган тартма һәм ватык рамнар урыны-урыны белән куак булып үскән таллар ягында өелеп тора, кайбер җирләрдә тракторлар батып-казып ташлаган урыннар бар, әмма печәне калын, хуш исле һәм җиләк кенә иде. Монсына бигрәк тә Сәлимәм сөенде, бар дөньясын онытты, күңелен таратып җибәрде.

— Һай эреләр, кып-кызыллары да бар,— дип сөйләнә-сөйләнә җиләк җыярга кереште.

Мин исә чишмә янына киттем. Буралап эшләнгән, улаклы, борынгыларның табигатькә мәхәббәтен дәлилләүнең үзе иде ул. Хәйран булдым. Суын эчтем, тешкә тимәде. Әмма сусавым шунда ук басылды. Тәмле иде. Кабат учыма ал-

дым, битемә бөркедем, бөтен тәнемә рәхәт җиңеллек йөгерде. Мин гүяки дөнья мәшәкатьләреннән азат кылынып, изгеләр арасына килеп кердем.

— Йа Ходам, могҗизаларыңа хәйран иттем, әлхәмдүлиллаһ!

— Исәнме, бабай!

Бу сәер сорауга күтәрелеп карасам, Сәлимәм үртәп тора икән. Учыма җәһәт кенә су алдым да аңа сиптем.

— Рөстәм, шаяртма инде, бәгырь! Минем дә авызым кипшеде.

Кулымны суздым.

— Кил, бәгырь, суы саф, татлы!

Сәлимәмне яныма китердем, аның исләре-акыллары китте. Еллар буе торып, инде тәмам суы сеңеп беткән чишмә бурасы тар һәм озын яфраклы тал куаклары арасында сыенып утыра, олы һәм тирән улагы чиста, әмма яшел суүсемнәр үсеп, зөбәрҗәткә әверелгән иде.

— Нинди бәхет, нинди сөенеч! Суы да суы, эчеп туймаслык.

Сәлимәм чишмәгә рәхмәт әйтте.

“Менә монысын дөрес эшләдең, бәгырь! Рәхмәт шушындый татлы булганың өчен! Мең рәхмәт!”

Бераздан мин дә эшкә керештем, әмма, өч-дүрт атлам чабуыма, чалгым агачка килеп төртелде. Ул умарта утырту өчен кагылган казыкларның беренчесе генә булып чыкты. Суырып алдым. Алар монда күп икән. Менә ни өчен бу болынга бер кеше дә кызыкмаган! Кайсын сындырып, кайсысын чыгарып, яки кагып мәшәкатьләнергә туры килде. Шуннан соң гына иркен сулап, беләкләрне сызганып, каерып-каерып чаба башладым. Сәлимәм ак яулыгын бөркәнде дә, усаллана барган кигәвеннәрдән качып, җиләк җыя бирде. Бер сәгатьләп пешеп эшләгәннән соң туктап учак яктым, алып килгән чиләгемә су тутырып, кайнатырга таган астым, көлгә бәрәңге тәгәрәттем. Төшкелеккә җитешәчәк болар!

Яңадан печән чабуга керештем. Җырлыйсым килеп китте. Әмма бу яктан бер дә сәләтем юклык сәбәпле тыела калдым һәм шунда, гүяки үтенгәннәрмени, Сәлимәм тыныч кына итеп шаян җырны телендә тибрәтеп җибәрде: «Дисәнә». Татарның егет-кызларны үрти торган җыры.

Чалгым чыннан да үтми башлады. Кабат янадым. Әмма җае югалды, көе китте. Бераз арыган да идем. Тукталдым. Учак янына килеп, шунда кайнаша башлаган Сәлимәмә күз ташладым. Аны кочасым, яратып сөясем килү дәрте күңелне кузгатты. Тик урыны да, вакыты да бу түгел иде.

Чәй кайнап чыккан, бәрәңгеләр пешкән. Табын әзерләргә вакыт җитте. Чишмә янына барып, битне-кулны, муен һәм күкрәкләрне юдым. Тәннең арыганлыгы шунда ук бетте диярлек. Күңел ризыкка тартылды. Яңа пешкән чикмәнле бәрәңгенең хуш исе, борыннан үтеп, тамакны кытыклый иде.

Ак ашъяулык янына Сәлимәм белән янәшә утырдык. Кара авыл икмәге, тоз, яшел суган һәм бәрәңгедән дә тәмлерәк бер генә ризык та юктыр төсле тоелды. Табигатьнең матурлыгы, дөньяның иминлеге, кылырга ният ителгән эшләрем изгелектә булу сәбәпле җан сәгадәт диңгезендә йөзә, мәхәббәтем — Сәлимәм, күңел түрендә һәм каршымда ямь өстенә ямь, сөенеч вә шатлык өсти иде.

— Рөстәм, җиләклэп эчик, бәгырь!

Хатыным эре һәм кызыл җир җиләкләре белән тулы бидонына күрсәтте.

— Иртә ич әле!

— Нәрсә иртә?

—Тиз тутыргансың дигәнем. Әле бит минем печән чабасым күп. Нәрсә эшләрсең соң?

— Тик утырырмын, синең чалгы селтәнгәнеңне карап кына...

Икебез дә көлеп җибәрдек. Сәлимәм һаман да тегеләй-болай шаяртып сөйләде. Мин ак калай кружкалардан иреннәремне пешерә-пешерә җиләкле кайнар чәй эчтем.

“Әллә шалаш ясап куяргамы?”

Фикеремне хатыным белән уртаклаштым. Ул моңа тагын да ныграк сөенде. Ашыктыра ук башлады. Ничек тә ярар дип кенә тотынган идек, шалаш эче иркен һәм яхшы булып чыкты. Элекке умарталыктан калган колга һәм киртәләр, инде ныклыкларын югалткан булсалар да, җайга килеп тордылар.

Шалашны әмәлләп бетерүгә, түренә чумдык. Монда күләгә, кигәвеннәр дә керергә атлыгып тормый иделәр. Сәлимәмне кочагыма алдым. Сөякләр йомшарып, буыннар таралып китте...

Без уянганда кояш инде шактый түбәнәеп, көн суына төшкән, учагыбыз көлгә генә калган иде. Әмма күңелемә ут йөгерде. Эшем калу сәбәпле йөзем бозылды. Йоклап ята торган чакмыни!

Тик Сәлимәм мине юату җаен тиз тапты:

— Рөстәм, ни булды? Эш өчен хафага төштеңме? Дәү әтием әйтә торган иде: «Өйләдән икендегә кадәр кылган фигыльнең бәрәкәте булмый, зәхмәте генә бар!» — дип. Менә хәзер чалгың да яхшырак үтә башлар, әүвәле тамак ялгап алыйк.

Ни диде, шул булды. Хатынымның болай олуг киңәш бирә алуын көтмәгән идем, акылына хәйран калдым. Ә ул: «Мин әле үзеңә күп нәрсәләрне өйрәтермен!» — дигәндәй елмаеп карап кына, өлешенә тигән бәрәңгесен чистартып, хөрмәт белән алдыма куйды:

— Монысын син ашыйсың. Артык зур ул, миңа шушы кечкенәләре дә җитә.

Каршы килсәм дә, ризалашырга мәҗбүр идем. Кичкә кадәр туктаусыз печән чаптым. Мул һәм бәрәкәтле тезмәләр күңелемә сөенеч өсти иде. Кояш тәмам ятагына якынлашкач, кайтыр юлга чыктык.

Калкулыкны менүгә хәйран калдым: авыл янындагы көтүлек һәм болыннарның һәр почмагында диярлек бүген эш кайнаган икән. Кайберәүләр инде печәннәрен кибәнгә куярга да өлгергәннәр. Болай көннәр матур торса, бу атнада һәркем малларына кышлык азыкны әзерләп бетерәчәк.

## VI

Печәнне чабу гына түгел, аны вакытында киптереп кибәнгә куясы, кайтарып өясе дә бар. Беренче өч көндә алны-артны карамыйча диярлек эшләдем дә эшләдем. Сәлимәм җиләк җыйды. Печәннең кипкәнен дүртенче көндә әйләндереп, тагын бераз чалгы селтәндем. Күңелем сизенә — житәрлек булды. Чабарлык урыннары бетте. Үләне дә катып һәм юкарып китте. Әлегәчә маташканым күзне туйдыру өчен генә: кирәк тә, кирәк тә түгел кебек.

Кибәнгә куеп бетергәч, мин тагын Габдулла абзыйның ишеген кактым.

— Ә-ә, әйдүк, энем, әйдүк! — дип каршы алды ул.— Печән чабып булдымы соң? Мин әйтәм, барып карауга, йөгереп кайтып, рәхмәт әйтә инде, дим. Юк, күренмәдең. Әллә юка булдымы? Яздан матур иде югыйсә!

Тыныч кына елмая бирдем. Ничек тә өенә ияреп кермичә, монда гына йомышымны белдерәсе иттем. Ул арада Бибикамал апа килеп чыкты:

— Кемгә болай Габдуллаҗан бабаң сөенә дип торам. Балалар кайтканмы әллә, мин әйтәм. Син икән әле, Рөстәм улым! Әйдә-әйдә, Габдуллаҗан, тотма кешене ишек төбендә. Булмаганны, йорттан ямь яшереп...— дия-дия кыстатмас җирдән кыстады, буйсынырга мәҗбүр итте.

Чәйләп утыралар икән.

Сизенәм, Габдулла абзыйның кыткылдаган күңеле ачы-төче су сорый. Әмма сөендерә алмыйм. Авыл җирендә бар эшнең башы-ахыры шул аракыга бәйләнеп кала бит. Йомышың төшсә, башкача хәл итеп булырын уйлау да мөмкин түгел.

Йөземә борчу йөгерә. Бибикамал апаның каймак салып ясаган чәен тиз арада бушаттым. Сүзне кузгатып җибәрмәкче итәм. Әмма, ай-ваема карамыйча, икенче кат татлы чәй салып кыстый башлыйлар. Ә Габдулла абзый: «Юкмыни анда синең, кесәңә тыгып килгәнең?» — дип сорагандай сөйләшә, җитмәсә өстәп тә куя:

— Менә, Бибикамал әбиең дә каршы килмәс ие, бүген эш тыгызрак булды, арылып та киткән...

Мин ни әйтергә белмим. Йомышым барып чыкмасын уйлап борчылам, аның саен кабаланып чәй эчәм.

— Балыннан кап, маеннан!

Бигрәк кунакчыл инде Бибикамал апа, болай ук кыстагач, тәм-томга да үреләм. Габдулла абзыйның күңеле үзенчә кытыклана. Сүзне уңлы-суллы болгап-болгатып карый. Туры әйтеп сөйләми, һаман да мин чапкан печәнлекнең нинди яхшы җир булуына басым ясый: «Аталган болыныгыз булыр!» — дип тә белдерә. Тик миннән файда югын сизенми. Үземне мокыт малай кебек тотам: аңламыйм, имеш.

Ярдәмгә Бибикамал апа килмәгән булса, мин ул көнне йомышымны белдерә дә алмый кайтып китәсе идем.

— Менә теге килгәнеңдә калдырган әйберегез бар иде, энем! Габдуллаҗан бабаң үзе генә тотмый, бүген кәефе дә көндәм күренә,— дип сөйли-сөйли, мич артындагы киштәсеннән бер башланган шешәне китереп өстәлгә куйды.

Габдулла абзыйның йөзе генә түгел, бөтен дөньясы балкып китте. Моңа кадәр киная белән мәш килгән теле тотлыкты. Беренче йомрысын әйләндереп куйгач кына бераз тынычланып калгандай булды.

Озак утырмадык. Ашыкканымны сиздердем. Безнең хуҗабикә дә кайткан иде, аңа эчкән килеш күренәсем килмәде.

— Трактор дисең инде?.. Юк нәрсә бит ул. Рәиснең кулында. Көне-төне барысы да эштә. Колхозга печәнен-башкасын ташыйлар,— дип аңлатып биргәч, минем тагын кәеф китте.

— Иртәнчәк яки кич белән булмасмы? — дип карадым. Габдулла абзый:

— Булмас,— дип кырт кисте.— Трактор — юк! Атлар да буш түгелдер. Пе-

чән өсте бит. Ә-ә... Тукта! Мин сиңа боерык язып бирәм. Атлар аранына барырсың. Хәйбулла бабаңнан бик үтенеп сорасаң, үзенекен бирер,— дип, кәгазь-каләмне түш кесәсеннән чыгарды да: «Бу кешегә җигүле ат бирерсең!» — дигән язуыннан соң тамгасын салды.

— Көне буена бер-ике юлласаң, бетә ул. Төяшергә үземне чакырырсың... Һай, юк, булмый. Мин иртәгә — басуда. Бикәң белән кайтарырсыз әле.

Саубуллашып, боерыгын кесәмә тыгып, кайтып киттем.

Мин борчылсам да, Сәлимәм сөенде. Ат белән печән ташуның нинди күңелле эш икәнлеген сөйләде. Мин дә тынычланып калдым.

Икенче көнне, көтү китүгә, абзар-араннар ягына юнәлдем. Бу тирәдә кешемазар күренми. Ат абзары дигәннәре бер җимерек сарайдан гыйбарәт булып, киртә-коймасыннан багана һәм казыклары гына тырпаеп тора иде. Унлап ат шушында гына үлән утлый, колыннары калын һәм коры тирес өстендә ауный вә уйный иделәр.

Бер әйләнеп чыктым. Алгы тәгәрмәчләре әвеш-тәвеш селкенеп торган арбадан башка һичнәрсәне күрмәдем. Шулай да сарай башында ныклап эшләнгән бер абзар булып, ишегендә бияләй кадәрле амбар йозагы эленеп тора иде. Шуңа карап тукталдым.

— Кем әле бу?

Куркып киттем диярлек. Артыма борылсам, сакал-мыеклы бер картлач кулына сәнәк тоткан хәлдә карап тора иде.

— Мин әле бу, Хәйбулла бабай!

Исемен атагач, якынрак килде. Кем икәнлегеңне танымыйм бит дигәндәй, өс-башыма күз салды. Имеш, мин аны кайдан беләм икән?

Беренче тапкыр күрүем иде.

— Кем малае буласың?

Габдулла абзый биргән боерыкны кулына тоттырдым.

— Мин бу як кешесе түгел. Укытучы.

— Һы-ы...

Хәйбулла бабай ян кесәсеннән саргайган пыяла алып, аны күз кабагына кыстырды. “Боерык”ны әйләндерә-әйләндерә карады.

— Монда “җигүле ат бирергә” дип язылган икән, энем!

— Әйе, бабай...

— Җигүле, дигән!

“Боерык”ны түш кесәсенә пөхтәләп салды. Пыяласын учына төшереп, кулъяулыгына төрде. «Бу кеше колхозда бухгалтер булып эшләгәндер»,— дип уйларга өлгердем, ә ул:

— Бар иде җигүле чаклары да атларның. Бар иде.— диде. Миңа кырын карап куйды.— Син, мөгаллим, яшь кеше әле, белмисеңдер...

Бабайның ни әйтергә теләгәнен уйлап та тормастан, ат бирмәс дип куркып:

— Беләм-беләм. Дилбегә генә тотканым бар...— дияргә ашыктым.

Ул миннән көлеп кенә куйды. Үз фикерен дәвам итеп:

— Атны җигәр өчен йөгәне-сбруе, арбасы-дилбегәсе дә кирәк. Аларын каян алыйм икән?

— Берсе дә юкмыни?

— Юк, дип, бар да инде алар...

Каешлары катып беткән дирбия-сбруйларны, теге амбар йозагын ачып, Хәйбулла бабай миңа тоттырды. Кайсын кул белән, кайсыларын улактагы суга манчып-изеп язганнан соң, юаш кына бер бияне тәртә арасына кертеп, арбага җиктек. Үзен шулай киендерүгә биябезнең кәефе килеп, елмайгандай итте. Күчәрләренә кадәр диярлек тирес һәм туфракка чумган арбаны калдык киртә колгасы белән күтәргәләп кузгатып җибәрүгә алгы тәгәрмәчләре таралып та төште. Моны ук көтмәгән Хәйбулла бабай кульяулыгы эченнән тагын теге пыяласын чыгарып күз кабагына кыстырды. Җигүле атны әйләнеп чыкты, каеш-дилбегәләрен карады һәм көтелмәгән сорау бирде:

— Әллә соң, мөгаллим, камыты киредән кидертелгәнме?

— Юк ла инде, бабай! Алгы тәгәрмәчләр таралды бит!

— Күрәм, энем, күрәм. Тәгәрмәч кенә бар ла ул.

Амбар йозагы саклаган ишекне тагын ачып, почмактагы салам өемен кузгаттык. Анда сап-сары һәм кызгылт төскә буялган тәгәрмәчләр бер түгел, биш арбага җитәрлек иде. Искеләрен алыштырдык. Җитмәсә тәрәзә төбеннән чиләге белән дегет табып, күчәрләрен дә майладык. Хәйбулла бабай көлеп куйды:

— Телсез Габбас ат караучы булып эшләгән иде. Мәрхүм... Бигрәк ярата иде инде шуларны. Ат җене кагылган... Һаман тәртиптә тотты. Синең күршең. Үзендә торасыз түгелме? Фатирлап?

Мин аның ихатасын, чалгысын-тырмасын исемә төшердем. «Исеме Габбас бабай булган икән!» — дип, рухына күңелдән рәхмәт укыдым.

— Кулы белә иде, кулы! Хәзер атның кадере бетте. Карамыйлар. Миңа тапшырган булып соң! Гомер буе бухгалтер эшендә йөрдем. Балта-пычкы, сука-сабан тотканым бар идеме соң!

Хәйбулла бабай үзе дә арбага үрмәләде.

Кузгалып киттек. Карап торуга авыр күренгән тәгәрмәчләр юлдан җиңел генә келтерәде.

— Минем йорт авыл башыннан өченчесе, урыс капка! — дип белдергәч, Хәйбулла бабайны шунда калдырып, бияне үзебезгә таба ашыктырдым.

Сәлимәм күптән әзерләнеп көтә икән инде.

— Аптырагач, эзләп бармакчы идем үзеңне,— диде, арбага утыруга.— Мин сиңа ашарга алдым. Юлда капкаларсың дип!

— Бик яхшы иткәнсең...

Бия баштарак дәртләнеп чапса да, үр менә башлагач, туктап-туктап калгалады. Түбән таба барганда тыела алмый аптыратты. Аның болай кыланулары күптән арба күрмәгәнлеген искәртсә, минем аңа ышанычны да киметә иде: ни дисәң дә, йөк белән кайтасы бар бит әле!

Озакламый бияне куалап, бер-бер артлы кигәвеннәр төште һәм, сыртына утыргалап, маен сыктылар. Әмма тиресе калын икән, малкай артык бирешмәде, койрыгын гына селтәнде. Монысы ярый икән!

Печәнлеккә килеп җиткәч, арбаны ике кибән уртасынарак куеп, атны тугардым. Аның инде кигәвеннәргә чыдамы бетеп килә. Үлән үсмәгән тузанлырак урынны чамалап, шунда пошкырып иснәде дә ауный башлады малкай. Барча җиреннән аккан тир кипшергән кебек булып китте. Арбадан бер кочак салам

төшереп, беразына ут салдым, учак ягып, өстенә яшел, кипмәгән печән һәм ат кузгалаклары ташладым. Зәһәр төтен арасына бияне кертеп, озын дилбегә башына бәйләп куйдым. Кигәвеннәр максатларына ирешә алмыйча, качу ягын карадылар. Ә мин Сәлимәм белән бергә арбага йөк төяргә керештем. Төгәл ике кибән кереп бетте.

Яңадан учакка бераз салам һәм ат кузгалагы ташлап килдем. Соры һәм авыр төтенне үз иткән бия шуның эчендә рәхәтләнеп үлән утлады.

Бастырык салырга кирәк тапмадым. Йөгем алай ук зур түгел иде. Буйга бау тартып бәйләдем. Этеп-төртеп карадым. Арба белән бергә печән дә селкенеп куйды. Болай булса — кайтып җитәчәк, таралып төшмәячәк. Шулай да ныклык өчен нәкъ уртага агач кададым. Тотынып кайтырга да яхшы булачак.

Сәлимәм арган иде. Бу эшләрем беткәч, башын җилкәмә куеп, бераз тын утырдык. Тән буйлап аккан тирем кипте диярлек. Кояш үз эшен башкара, көн балавыз эретерлек эссе иде.

— Безнең тагын дүрт кибән кала.

Сәлимәмнең болай әйтүе: «Кабат ике тапкыр киләсебез бар икән!» — дип белдерүе икәнлеген яхшы аңладым һәм:

— Монысын исән-имин кайтара алсак, алары гына калмас, иншаллаһ! — дидем.

— Бабай!..— дип мине үртәде ул.— Намаз укыйсың бар!

— Укырмын да шул!

Мин чыннан да үртәлдем. Болай үссенеп китүем мактанырлык гадәт түгел. Шунлыктан: «Сизенмәдеме?» — дип Сәлимәмә күз ташладым. Юк, ул үз уйлары белән мәшгуль иде. Бераз арып киткәнме, әллә: «Ничек кайтып җитәрбез?»— дип кайгырамы?

— Бу йөкне исән-имин генә йорт янына бушатсак, бүген икенче кат юлларга да мөмкин. Сәгать әле унберләр чамасы гына булыр,— дип, Сәлимәмә фикеремне белдердем.

— Әйдә, алай булса, кузгалыйк,— диде ул.

Мин атны җиктем. Төтен исе ялларына сеңгән бия янына кигәвеннәр артык якын килергә ашыкмадылар. Яңадан бер кат камыт бавын һәм аркалыкны карадым. Йөк белән кайту куркыта һәм бераз өркетә иде. Сазлыктан агып чыгучы, тар гына үзән ясаган сулыкны узасы бар әле. Килгәндә дә ат өркегән иде. Шунлыктан Сәлимәмә йөк өстенә утырырга киңәш итмәдем. Үрне менгәнче үзем дә атны башыннан гына тотып барырга булдым.

Шигем юкка түгел икән. Баштарак бия шул сулыкка керергә теләмәде, әмма миңа буйсынмый чарасы юк иде. Тартылып, үземне дә сөйрәп диярлек суга томырылды да, икенче якка чыгып җиткән чагында, җитешә алмавым сәбәпле, туктап калды. Йөкнең алгы тәгәрмәчләре ул арада кендеккә кадәр чумып та өлгерделәр. Нигә генә шунда ат башын кулдан җибәрмәдем дә дилбегә белән генә йөртмәдем икән үзен?

Бия кузгалып-кузгалып карады, әмма аның саен арба түбәнгәрәк бата барды. Хәзер йөкне бушатыргамы инде? Ачуым килеп, атка кычкырдым һәм: «Наа-а!» — дип, дилбегә башы белән суктым. Мескенем суырылып тартты. Мин, җәһәтрәк килеп, тәртәдән күтәрдем, ярдәм иттем. Алланың рәхмәте, йөгем куз-

галды һәм биям артыннан иярде. Атка тезләнергә ирек бирмәдем, һаман да тәртәсеннән күтәрдем һәм шулай газап белән коры җиргә чыктык.

VII

Бер җаен белеп алгач, икенче йөкне кайтару җиңелрәк булды. Атны тугарып, арбага печән салдым һәм, икмәк уып, чиләк белән су куйдым.

Иртән уянып чыксам, ни күрим, йорт тирәсендә атлар-колыннар. Араннарын ташлап килгәннәр. Сагынганнар, юксынганнар биябезне. Арба әйләнәсендә, аның кырында басып торалар. Нидер сөйләшәләрдер инде. Әллә ял итәргә дә ирек бирмәгәннәр үзенә? Шунда бер сынамыш исемә төште: яңа салынган йорт янына мал җыелса, ихатасы бәрәкәтле була, имеш.

Моңа да куандым.

Печән кайтарылып беткәч, без аны олы кибән итеп куйдык. Эш артыннан башкасын табып кына торасың инде анысы. Тормыш кору өчен болай тырышуларым авылда яшәп ятучы карт-корыны да дәртләндерде. Эшемне дә, үземне дә күрергә җай эзләп килүчеләр, исәнләшеп китүчеләр күбәйде.

Мунча һәм сарайны бурарга керештем. Әткәй балта остасы булып, бала чагымда аның кул астында эшкә өйрәнгән кеше идем. Шулай да үзем баш булып беренче тапкыр бура өям. Чокырлап алыр өчен ырмау ясадым. Бер такта кисәгенә шырпы кабы үлчәмендә ике эре кадак кактым. Юкә һәм усакларны кабыкларыннан әрчеп, кәкрерәкләрен кояшка куйдым. Кипкән саен кирәк ягын әйләндердем-тәгәрәттем: шәм кебек төзәйделәр.

Җиңелдән генә тотынган идем, мәшәкате күп булып чыкты. Ул арада яңгырлар да башланып, мине эштән аердылар.

Бу вакытта йортыбызның түшәм-сайгагын инде җәйгән иделәр. Тупса-кәчәкләрне куеп, тәрәзәләрне генә ясыйсылары калды. Яңгырлы көннәрдә баз казыдым. Комлы кызыл балчыкка төшеп җиткәндә мич чыгару кайгысы да барлыгын исәпләп, кирпеч юнәтүгә керештем.

Иске мунча тирәләрен, калдык нигез буйларын әйләндем. Өйгәләп-өйгәләп куйдым. Әмма бу тырышуым бушка булган икән. Болай маташуларымны колхоз рәисенә җиткергәннәр.

Ул да түгел, машинасы белән кирпеч һәм пар кертү өчен торбалар китереп киттеләр, сварщикны көтәргә куштылар. Мунчаны үзем генә күтәреп, бер башына кечкенә лапас кору өчен баганалар утырттым. Бәбкәлекләр юнып, инде аларны да урнаштырырмын дигән идем, осталар бригадасы килеп төште. Коймаларны коеп чыктылар. Мунча һәм лапас-сарайны да бергә-бергә эшләп бетердек. Тәрәзә яңакларын һәм тупсаларны-ишекләрне куйдылар. Ул да түгел, август урталары иде булса кирәк, сварщик килеп, пар торбаларын суздык. Бу эшне бетереп ята идек, Габдулла абзый килеп керде:

— Энем Рөстәм,— ди бу,— мич чыгаруны һичкемгә тапшырмассың! Ишетсен колагың, ул безнең «коренной номер»!

Минем өчен барыбер иде. Әмма аны көтсәң, кыш җитәр, эштән бушаганы юк бит.

Ялгышканмын. Икенче көнне Габдулла абзый кичкырын килеп тә җиткән. Кулында измә калагы, чиләк, турылагыч кебек әйберләр.

— Монда ут кермәдемени әле?

— Юк иде шул!

— Булмый икән алайса. Кичектереп торыйк. Электрикны чакыртам. Амбар-абзарларда да эше күп әле аның. Берочтан барысын да эшләп китәр.

Каршы килмәдем. Балчыкны изеп, әзерләп куярга кушты.

— Бу нәрсә бу?

— Китап, Габдулла абзый!

— «Мич чыгару һөнәре» дип язылган түгелме соң тышына?

— Әйе, Габдулла абзый!

— Чыгарып та бирәм диме?

— Юк, өйрәтәм генә, ди!

— Карап торырсың, өйрәнеп калырсың! Китаптан укып эшли торган нәрсә түгел ул. Миңа, догасын укып, әткәм төшендереп калдырды, аңа — бабам, бабама — дәү бабам... Балаларга гына серләрен күрсәтеп калмадым. Кирәк тапмадылар. «Гыйльман миче» дип ишеткәнең бармы?

— Юк...

— Ишетмәсәң, ишет! «Гыйльман миче» ул, энем, ике агачтан ут була. Тирә-юньдә бер сиксән процент «Гыйльман мичләре» — минеке. Атамныкы, хәтта бабамныкылар да бар иде әле!

Ул үзенең нәсел-нәсәбендә нинди дәрәҗәле кешеләр булуны, балаларының нинди югары уку йортларын бетереп, кайсы шәһәрләрдә яшәүләрен сөйләп китте.

— Тик менә авылны ташладылар, авылны калдырдылар,— дип зарланып та алды.

Ике көндә яңа йортыбыз мичле булды, өченче кичтә морҗасын күтәреп бетердек. Габдулла абзый чыннан да үз эшенең остасы булып чыкты. Кипкән йомычкаларны ягып җибәрүгә өч-дүрт минутлар да узмады, өй эченә җылы таралды. Пар торбаларына су тутырып, учагына ут салдык.

— Монысының җылынасына озак әле,— дип, останы сыйларга керештем.

— Үз эшем өчен җавап бирәм. Әмма бусы — сварщикныкы. Барып чыккандырмы, әйтә алмыйм! — Шулай сөйләнеп беренче йомрыны бушатуга урыныннан кузгалды Габдулла абзый. Ул арада торбаларга пар суга башлады. Мин аңлап алдым: су йөрми, авышлыклары дөрес түгел.

Кайсы урынын өскәрәк күтәреп, кайсысын аскарак төшереп, авышлыгын чама белән дөресләп чыктык. Кайнар су тавыш бирә-бирә йөгерде. Монысы да уңышлы булды. Тәрәзәсез җылы өй эченә чебен-черки тулды. Шулай да күңелдә канәгатьлек һәм рәхәтлек иде...

Августның егермеләрендә яңа йортыбызга күчтек. Сәлимәм мичкә ягып, икмәк пешерде, юып-сөртеп чыгарды. Чәй куйдык.

Кичкырын күршеләр хәл-әхвәл белешә кереп, үз оябыз булу белән котлап чыктылар.

— Мондый йортны җитештерә алгач, бәхетле кешеләр инде сез... Менә без, Бибикамал әбиең белән, атай йортында гомер кичердек,— дип сөйләде Габдулла абзый, сөенечебезне уртаклашырга кергәч.

Сәлимәм чәй яңарта башлаган иде дә:

— Юк, юк, килен, мәшәкатьләнмә, бүген арылып китте. Чәйләп-нитеп тора алмыйм. Котлап, Бибикамал әбиең белән бер вакытын белеп керербез әле, бусы күреп чыгу өчен генә,— дип туктатты.

Озаклап утырмады.

Фатир хуҗабыз иске агач өстәл, өч урындык һәм тимер карават биреп чыгарган иде. Без аңа бик рәхмәтле булдык. Беренче йорт җиһазларыбыз да шулардан гыйбарәт иде.

Тәүге кичәбез матур һәм тыныч үтте. Сәлимәм бар дөньясын онытып мине иркәләде һәм иркәләнде. Җилкәбездән зур эшләр төшкән, мунча һәм лапасыбыз да җитешеп килә иде. Быел көздә алма бакчасы утыртып калдырырга, яшелчәлекнең дә хәстәрен күрергә ниятләдем. Башкаларына көч тә, вакыт та җитмәс инде.

Төн уртасында Сәлимәм уятты, тавышы йомшак һәм серле иде:

— Рөстәм, кулыңны бир әле...

Кулымны буена куйды. Мин әле эшнең нәрсәдә икәнлеген төшенми идем. Әллә авырып киткәнме дип борчылырга да өлгердем. Бу кадәр шатлык-куанычларга күләгә төшсә, авыр буласы иде.

— Җан керде балабызга!

Җиденче кат күктә идем. Әйе, әйе, минем балага, беренче балабызга бүген җан керде.

— Исәнме, кызым!

— Ә нигә кыз? — дип сорады Сәлимәм.— Малай булсын дигән идем.

— Өч ай ярымда бары тик кызларга гына җан керә. Малайлар ялкау була дип ишеткәнем бар!

— Син беләсеңдер инде бик... Ә мин — малай, дим!

Бәхәсебез урынсыз иде. Аллаһы Тәгалә кулындагы эш.

Сәлимәмнең буен сыйпадым:

— Акыллы, сәламәт, чибәр вә күркәм бала булсын!— дип теләдем. Бу сүзләрем хатыныма да тәэсир итте һәм ул көтмәгәндә елап җибәрде.

— Ни булды, бәгырь?

— Куркам...

— Нәрсәдән?

— Мин бит сине бик тә яратам, Рөстәм! Үлеп-үлеп яратам. Сине югалтсам, алып китсә берәр хатын, нишләрмен дип уйлыйм...

Аптырап киттем. «Нигә алай сөйлисең, бәгырь?» — дигән соравым тел очында торды, әмма әйтергә базмадым. Сәлимәмне кочагыма алып, маңгаеннан, күзләреннән, иреннәреннән үптем-иркәләдем.

— Юләрем син минем! —дип, ачулангандай иттем. Шушы сүзләрем җитә калгандыр, ул тынычланган сыман булды.

Әмма шик-шөбһәләренең төбендә нинди хәсрәт вә уйлар ятканлыгын белми идем әле мин.

## VIII

Югары уку йортларына керү имтиханнарын тапшырырга киткән укучыларыбыздан соңарып булса да беренче хәбәрләр килеп иреште. Бу сынаулар алар

өчен генә түгел, мөгаллимнәргә дә иде. Мин Әлфия өчен борчылдым. Әмма моны Сәлимәмә сиздерергә тырышмадым. Бу уйларым белән Әлфияне һаман да күңел түренәрәк үткәрә барганымны чамаладым. Аның яшьлек гүзәллеге, кара күзләре, алсу түгәрәк йөзе хәтеремдә сакланып, хыялда тагын да чибәррәк һәм күркәмрәк төсләрдә төрләнә бирде.

Сәлимәмнең буе көннән-көн үзен ныграк сиздереп, кеше күзенә чалына башлады. Аны күрүгә, Габдулла абзый елмаеп сөйләшә торган булып китте. Ул, гадәтенчә, вакыт-вакыт кергәләп, хәл белешкәли иде, анысын да хәзер сирәгәйтте.

Август ае үтеп тә китте. Иртәгә — беренче сентябрь. Мәктәптә укулар башлана, сыйныф бүлмәләрен, кабинетларны тәртипкә кертәсе, дәреслекләрне һәм укучыларны барлыйсы бар.

Утны сүндереп, йокларга яттык. Әмма ни өчендер минем күзләр йомылырга ашыкмады. Урамда якты сыман иде. Ишегалдында да шәүләләр йөргән кебек булып китте. Әмма Сәлимәмне шикләндермәс өчен урынымнан кузгалмадым. Алай ук ваемсыз булырга кирәкмәгән икән.

Тәрәзәне шакыдылар. Бу тагын шул уен, бәрәңгене җепкә асып куялар да, җилдә тибрәлеп, пыялага бәрелгәләп тора булыр. Тавыштан уянып киткән Сәлимәмне тынычландырырга ашыктым:

— Авылның усал малайлары уйный торгандыр? Чыгып, өркетеп керим!

— Берәрсен гарипләндерә күрмә, берүк, Рөстәм!

— Юк ла инде, син нәрсә, бәгырь!

— Сабыр була күр!

— Бер дә борчылма!

Мин киенеп өлгергәнче бәрәңге һаман да тәрәзә өлгесен тукмак кебек төюдә булды.

Чыктым. Ни күрим: авылның усал малае дип уйлаган кешем Әлфия иде. Аптырабрак калдым. Нигә болай тагын шаяртып йөри әле ул?

— Сеңлем Әлфия, син түгелме соң?

— Әйе, Рөстәм абый, мин идем шул. Кайдан таныдыгыз?

— Нигә танымаска ди? Синнән башка һичкемнең болай аптыратканы юк!

— Ачуланмагыз инде, Рөстәм абый!

Әлфия каршыма ук килеп басты. Аның җылы һәм хуш исле тыны хисләрне кузгатып җибәрде. Әмма мин бирешмәскә тырыштым, сорау артыннан сорау яудырдым:

— Казанга китмәдеңмени әле?.. Укулар кайчан башлана?.. Туган яклар сагындырмасмы?.. Экзаменнарыңны ничек бирдең?..

Әлфия мине туктатмаса, каушауданмы, әллә сораулар күп җыелуданмы — бер-бер артлы яудырасы идем.

— Рөстәм абый, боларның бөтенесенә дә берьюлы җавап бирергәме, әллә берәмләпме?

— Берәмләп.

— Кайсыннан башларга?

— Имтиханнарны ничек бирдең?

— Барсын да «бишле»гә!

— Яхшы булган икән. Кемнәр керде?
— Ничек кемнәр?
— Казанга китүчеләрдән дигәнем.
— Барыбыз да диярлек.
— Бик яхшы булган. Кайчан китәсез?
— Казанга билетлар юк. Берсекөнгә колхоздан автобус бара.
— Анысы яхшы икән. Хәерле юллар булсын! «Биш»кә генә укы!
— Рәхмәт, абый!

Көтмәгән идем, Әлфия, үрелеп, муеныма сарылды һәм иреннәремнән үпте. Мин югалып калдым. Әмма кулларым аны кочагымда кыстылар. Ашкынулы хисләре миңа күчкәндәй булды. Айнырга тырышып, артка чигендем. Болай йомшаруыма ачуым килде. Әлфия елый идеме, әллә көләме?

— Рөстәм абый, сез минем беренче һәм җавапсыз мәхәббәтем бит!

Бу сүзләрен ишеткәч, ачуланып ташларга, куып чыгарырга тиеш идем. Ярый әле Казанга китеп бара, юкса башымны әйләндерер иде.

— Мин сезгә хатлар язармын, мин сезгә шигырьләремне атармын...

— Юк, юк! — Мин баш тартырга ашыктым.— Сез нәрсә, сеңлем! Нинди хат?.. Хат дип, инде, яз!.. Сәлимә апаң да, мин дә шат булырбыз. Ә шигырьләреңне бүтән кешегә атарсың! Үз тиңеңне яратырсың, никадәр әйбәт егетләр бар дөньяда!

— Синең кебеге — юк!

— Алай димә, сеңлем! Бар ул!..

Бу сүземнән үзем дә калтыранып киттем. Яратсалар, начармыни? Юк, юк, нинди ярату ди ул!

— Монда ничек ялгызың гына килдең? Кайта алырсыңмы соң?

— Ялгыз йөрмим мин, Рөстәм абый! Мине Рафис көтә. Матай белән. Казанга да бергә китәбез.

— Менә бит, бик яхшы. Рафисны тәртипле малай дип беләм.

Никләр генә малай дигән сүзне ычкындырдым? Әлфия көлеп үк җибәрде:

— Малай гына шул! Егет булырга мыегы чыкмаган.

Мин артык сөйләшергә базмадым. Болай да ут кебек кыз, һәр сүземне үз файдасына борып барачак!

Тагын бер кат хушлаштык. Әмма Әлфияне үземә якын китермәс өчен бер бусага югарырак менеп, ишек төбенә бастым. Күңел генә акыл белән килешеп бетмәде.

Әлфия китеп барды. Бераздан урамда мотоцикл кабынды һәм, бөтен авылны диярлек шаулатып, төнгә кереп югалды. Мин болдырга утырдым. Күзләрем күккә төбәлделәр.

Киек Каз Юлы!..

Күңелемә сагыш тулды. Моңа кадәр уйламаска тырышкан Казаным сагындырган иде. Әлфия шунда китеп барачак. Мин йөргән юллардан узачак, үзенең бәхетен һәм язмышын табачак. Казан аны зур юлга алып чыгачак. Ул авылда калыр өчен әйләнеп кайтмастыр, мөгаен. Ә минем гомер шушында үтәчәк... Тыныч һәм караңгы авылда.

Караңгы?.. Ә ни өчен караңгы?.. Ничәмә-ничә йолдызы, ае-кояшы булган

авылны караңгы дип әйтү мөмкинме соң? Юк! Авыл ул мең шәһәрләрең вә калаларыңнан да яктырак. Урман-сулары, тугай-болыннары, басу-кырлары, ә иң кирәге — яхшы халкы бар бу авылның. Димәк, бәхет өчен һәртөрле мөмкинлекләре синең каршыда. Бары тик таптап кына китмә. Хәер-хаһлы һәм яхшылыклы бул, шул чагында сине дә яратырлар, хөрмәт итәрләр!

— Нигә мине дә дәшмисең?

Артымнан Сәлимәм чыгып, яныма утырды, иңнәремә кулларын салды. Иркен һәм рәхәт итеп сулап куйды.

— Һай, нинди матур, саф һавалы төн!

— Әйе, матур шул, Сәлимәм!

— Тыныч, иркен, рәхәт!

— Мин сине яратам, Сәлимәм!

— Абау, бәгырь, ни булды сиңа?

— Берни дә түгел!

Мин аны кысып кочакладым, башын алдыма алып иркәләдем. Чәчләренә уралдым.

— Мин дә сине яратам!..

Шулай шактый озак һәм күп итеп бер-беребезгә изге мәхәббәт серләрен аңлаттык, иркәләндек, сөештек. Йолдызлы күк астында һичкайчан кабатланмас яшьлек кичәбез иде бу. Моннан соң без болай утыра алмабыз, картаербыз. Яшьлектә генә мөмкин булган мәхәббәт кичәсе безне бүтән үзенә дәшмәс. Әлфия дә тәрәзәгә бәрәңге элеп, өлгегә чирттереп шаяртмас. Гомеребез шушында, бәхетле авылда үтеп китәр...

Күк читендә ай күренде. Бераз җил чыгып алды һәм без, кереп, җылы ятагыбызга чумдык. Тыныч, иркен, рәхәт иде!

## ТИҢСЕЗЛӘР ГЫЙШКЫ

*Хикәя*

Күрше малае Харисның Фазыйлә апасы быел унынчы сыйныфны тәмамлады, Казанга укырга китәсе билгеле булды. Әмма әтисе — Тупас Гайфулла, кызының бу ниятенә каршы төшкән икән дип ишеттек. “Мин сине шәһәргә җибәрер өчен үстердеммени, әнә колхозда сыер сау, йортка файдаң тияр” дип орышкан, ди, имеш.

Булыр, әйтер, бер дә җәлләп тормас, балта күтәрсә — чаба, тешләсә — өзә торган, пырдымсызлыгы өчен “Тупас” кушаматы алган Гайфулла бит ул. Аңа йомыш төшкәндә генә Гайфулла абзый дип сөйләшәләр, ә гайбәткә кереп, телгә күтәрелсә — Тупас Гайфи, күп вакытта Тупас Гайфулла аты белән йөртәләр.

Шулай итеп, Тупас Гайфулла үз баласының хыял канатларын бер селтәнү белән өзгәләп ташлаган да, кызы, мескенем, ындыр артына качып, тиреслек башында күз яшьләрен сыккан.

Моны ишеткәч, йөрәгем кузгалып куйды, телсез калдым. Әгәр дә мин быел унынчыны бетергән егет булсам, юатыр идем генәме, яклап чыгар идем, ул Ту-

пас Гайфулланың кирәген бирер идем. Юк, булмады, мин соңрак туганмын шул. Әле дүртенче сыйныфны гына бетердем бит.

Ә шулай да Фазыйлә апаны бик яратам мин. Аның талчыбыктай зифа буе, озын кара чәче, назлы күз карашы һәм сүзләре, тагын да әллә нәрсәләре, әллә нинди гүзәллекләре мине таң-хәйран калдырып кына түгел, хәтта һушсыз итәләр. Аһ, мин өлкәнрәк булсам! Кичләрен озата барыр идем. Иртәләрдә, чишмә ярына килгәч, куен кесәсеннән дәфтәр чыгарып, йөрәк серләрен язып барган чагында Фазыйлә апа янына килеп утырыр идем, таллар арасыннан гына качып карап тормас идем, угры кебек. Эһ, юк безнең авылда аңа лаек, тиң булырлык егет! Юк, дим, шуңа күрә шәһәргә китәдер ул? Мине көтеп тормас микәнни? Үсәр идем әле. “Кайчан үсәрсең икән син, матурым” дип әйтмәс иде ул вакытта. Кара әле, Гайфулла абзый аны шәһәргә җибәрмичә дөрес эшли бит. Димәк, Фазыйлә апа монда калса, сыер сауса, мин ул арада үсеп тә җитсәм, аңа буе җитәр егет юк, һәм без, мин һәм Фазыйлә... Һе, тукта, алты ел эчендә көзен-җәен резин итекләр киеп саз ера-ера, кышларын тирес түгә-түгә тәмам таушалып, гүзәллеген югалтып бетерәчәк бит ул. Юк, шәһәргә китсен, мине шунда көтеп торсын!

Шулай дип уйладым. Күңелем нурланып китте. Хәтта сызгыргалап та куйдым. Хыялланып ук киткәнмен, шомырт ботагына җәелеп утырган җиремнән чак кына мәтәлеп төшмәдем, харап булачак идем.

— Кадалгыры!— дип кычкырган Тупас Гайфулла абзыйның тавышы колакны ярып үтте. Миңа әйттеме әллә?

Аваз килгән якка борылдым. Каян килә бу өн? Иясе күренми.

— Кадалгыры, бар, чыгып кит!.. Ычкын күз алдымнан!

Тупас Гайфулланың бакыруы икенче тапкыр бәгырьне ертып узды. Чалтырап табак-савыт ватылганы ишетелде. Фазыйлә апа йорттан атылып чыкты һәм ындыр ягына йөгерде.

Ачык ян тәрәзәләреннән атасының тагын да җикеренүләре ишетелә калды, мин, үз-үземне белештермичә, Фазыйлә апа артыннан йөгердем һәм тиреслек башына җитеп туктадым. Ерак түгел яр астында сыктап елаган Фазыйлә апаны күрүгә, янына ни рәвешле килеп басканымны сизми дә калдым.

— Елама инде, Фазыйлә апа! Син еласаң, бәгырем киселеп китә,— дип чын күңелемнән әйтүдән соң гына акылым айнып китте. Бер кулым аның иңбашыннан тоткан, икенчесе чәченнән сыйпый иде. Куркып киттем. Әмма Фазыйлә апа мине ничектер йомшак һәм җылы итеп кочты ки, мин эредем, ә ул, минә бәхет — елаудан туктады!

— И матурым минем! Нигә безнең Харис та синең кебек түгел икән? Туганым кебек яратам бит мин сине,— дип, күзләремнән үбеп алды.

“И Фазыйлә апам!”

Харис дигәне минем сыйныфташ ул. Бер дә апасына охшамаган, һаман кыйнашып-сугышып йөри, аның белән уйный башласаң, эш шуның белән тәмамлана: йә ул сине тотып тукмый, яки туйганчы елата, изеп ташлый. Апасын да тыңламый, әнисе кушканны да эшләми, һаман да урамда эт сугарып йөрүне генә ярата, әмма әтисе аның өчен иң олуг һәм мәртәбә иясе. Харис янында Тупас Гайфи дип ычкындырсаң, бетте дигән сүз, икегә бүлә үзеңне.

Фазыйлә апа мине җитәкләп инеш янына китерде. Минзәлә елгасы ташлар арасыннан челтерәп-челтерәп, йөгерә-йөгерә ага да, берәр тирәнрәк һәм йомшаграк үзәнгә җитеп, тыныч кына хәл җыя, аннан тагын бераз бара, аннан тагын ял итә. Ул ял итә торган култыклы урында балык шәп каба. Уч төбенә сырлык чабак һәм түбәнкә-ташбашлар, анда-санда кызылканатлар каптырырга яратам мин, әнә теге кызыл яр култыгына кармак ташлап.

Шулар хакында Фазыйлә апага сөйләп киттем. Ул гынамы әле, Минзәләнең бер урында алайрак, икенче җирдә болайрак чупырдап агуын да аңлатып бирдем.

— Шагыйрь син, шагыйрь икәнсең! — дип, күзләремә сөеп карап, исемемне ничектер үзенчә ягымлы итеп әйтеп елмайды дөньяның гүзәллек иясе Фазыйлә апам.

Апам? Эһ, апам шул. Мин үземнең әлегә яшь, малай гына булуымны исемә төшердем һәм башымны түбән идем.

— Ни булды, матурым? — диде Фазыйлә апа.— Әллә үзеңне шагыйрь дип атавыма үпкәләдеңме? Үпкәләмә! Шагыйрьлек— мәртәбә ул!— дигәннән соң, сүзләреннән беразга туктап торды да, яңадан канатланып, яр карлыгачы кебек уйнаклап очынгандай каядыр күккә талпынып куйды һәм:

— Бик беләсең килсә, мин дә шигырьләр язам. Инде күптән, яшь вакыттан, синең кебек чаклардан бирле. Шәһәргә укырга китү теләгем дә шуның өчен. Университетка керсәм иде дип хыялланам.

Мин тамчысы язгы бу яңгырның,
Мин кояшы аяз таңнарның,
Саба җиле булып чәчләреңне
Һәм гөлләрне сыйпап үтәрмен...

Фазыйлә апа шигырь укыды. Минем алдымда тагын бер башка үсеп китте. Инде тәмам буем җитмәслек икән. Иртән чишмә буена утырып ни яза дисәм, шигырьләр икән әле!

— Ошыймы? Матур бит, әйеме? — диде ул, минем уйларымны бүлеп.

— Әйе,— дидем, ни әйтергә белми аптырап.— Әйе!

Башка сүз кирәк түгел иде. Тукайны беләм, Мусаны, Такташны, Туфанны. Укы, дисәләр, хәзер яттан шигырьләрен сөйләп бирә алам. Ну, һәммәсен дә түгел инде, берсен-икесен. Әмма шулай да мин аларның шагыйрьлегенә соклanam. Фазыйлә апа да шундыйлардан булыр инде! Һе, хатын-кызлардан да шагыйрьләр була микәнни?

Миңа бу уем бик кызыклы булып тоелды һәм дә әйтеп куйдым:

— Хатын-кызлардан шагыйрьләр булмый инде!

— И юләрем минем! Нишләп әле булмасын ди? Бик була! Сажидә Сөләйманова, Клара Булатова — ә болар кемнәр? Шагыйрәләр, белдеңме? — дип, борын очыма йомшак бармагын төртеп куйды.— Хатын-кыз шагыйрәләр күп... Һәм араларында Сажидә апа Сөләйманова кебек, кайбер ир-ат шагыйрьләрдән өстенрәк һәм камилрәк булганнары да бар!

Минем тагын башым иелде. Шуны да белмим икән мин.

— Ярар инде, үпкәләмә,— диде Фазыйлә апа,— әле син яшь, үскәч — күп нәрсәне аңларсың, белерсең, һичшиксез... Ничек дигән әле Габдулла Тукай? «Син әле үс һәм укы күп; шунда аңларсың барын!..»

Фазыйлә апа сөйләүдән кинәт кенә туктап калды. Мин аңа күтәренеп карадым. Күзләре бездән арырак басып торган күрше авыл егете Гарифҗан абыйга төбәлгән иде.

Нишләп йөри ул монда? Ә, Фазыйлә апаның сыйныфташы бит ул. Яхшы укый дип еш мактадылар аны. Ул да Казанга укырга китәсе, диләр. Фазыйлә апаны күрергә исәбе микәнни? Берәр соравы бардыр инде, бушка йөрмәс ул.

Гарифҗан абый безгә таба килә башлады. Ул якынайган саен, Фазыйлә апамның гасабилануы артты, борчылуы йөзенә чыкты һәм ул, миңа таба иелеп:

— Бар инде, матурым, беразга арырак китеп тор, Гарифҗан белән сөйләшәсем бар иде. Әмма, берүк, кешегә әйтә күрмә! Ярыймы? — дип үтенде.

Мин эшнең җитди икәнлеген аңлап алдым һәм:

— Ярар, якында гына булам, кулын күтәрә башласа, мин аны!..— дип, йодрык төйни башлауга, Фазыйлә апа:

— Юк, юк,— дип, авызыма җылы учларын куйды.— Гарифҗан абыең андый түгел. Аннан да олуг күңелле һәм яхшы кеше юк,— диде.

Мин үпкәләдем. Сүзләре чыннан да йөрәгемне канатты. Күз яшьләремне күрсәтмәс өчен читкә йөгереп киттем. Күпме чапканмындыр, кычыткanлыкка барып кергәч кенә айныдым. Әмма соң иде, бөтен җирем чагылган, җаным гына түгел, тәнем дә әрни иде.

Бик тә, бик тә нык үпкәләдем Фазыйлә апага, чирәмгә ятып, тәгәрәп еладым, күңелемне бушаттым. Шул Гарифҗандыр аның егете, юкса нишләп очрашсыннар ди?

Аларны калдырып киткән су буена таба аякларым кабат китерде. Тал төбендә бергә утыра иделәр. Гарифҗан дигәне кулын Фазыйлә апаның биленә салган да, хәтта телсез калган булса кирәк.

Ачуым кабарды. Ниндидер этлек ясыйсым килде үзләренә. Таш алдым да суга ордым.

Фазыйлә апа аһ итте, чәрелдәп сикереп торды. Гарифҗаны минем арттан куа башлады. Мин өйгә таба элдердем. Фазыйлә апа:

— Гарифҗан, берүк тимә, кимсетә күрмә, Гарифҗан! — дип кычкырып калды.

Шактый йөгергәч, кире борылып карадым. Арттан һичкем бастырып килми икән. Ә кая соң Гарифҗаны? Һәй, мине дә куып тота алмагач, егет булып йөрмә дә инде син!

Кире су буена төшмәдем. Шүрләвем дөрес булгандыр инде. Кич буе Фазыйлә апаны капка төбендә көтеп утырдым. Бәлки егете дә түгелдер?

Һәм ялгышканмын. Төшәргә кирәк иде миңа, тотарга кирәк иде итәкләреннән!..

Икенче көнне барысы да беленде! Фазыйлә апа белән Гарифҗан Казанга китеп барганнар. Күрше авылдан килеп, Гайфулла абзыйга кызының хатын тоттырып киткәннәр икән. Үзен эзләп йөрмәскә һәм юлын кисмәскә бик тә, бик тә үтенгән, диләр. Шулай булса гына атасына Газраил килгәндә бәхиллек бирәчә-

ген язган, ә энисеннән гафу сораган икән.

Гайфулла абзый, гомергә таш бәгырьле ата, өч көн эчкән, өч төн елаган. Дүртенче көндә, кулына кечкенә чемодан тотып, шәһәр юлына таба чыгып киткәнен үзем күреп калдым. Сыксаң, таштан да су чыга шул.

Ә көтүләр китеп бер-ике сәгать үтүгә, капка төпләренә җигүле ат килеп туктады. Гарифҗанның әти-әнисе, диделәр. Төшкелеккә кадәр атлары капчык төбеннән ризык кимереп, уңга-сулга тартылгалап, арып бетте. Харис бакча артыннан гына олы юлны урап йөгереп килде. Әтисе китеп барган икән инде.

Гайфулла абзый дүрт көн үтте дигәндә генә Казаннан әйләнеп тә кайтты. Кулында чемодан түгел, бер челтәр сетка һәм җебегән кәнфит кенә булган дип сөйләделәр. Кызына киемнәрен һәм акча биреп кайткан, диделәр, Тупас Гайфине танырлык түгел, дорфалыгы шиңгән, диделәр.

Фазыйлә апа да, Гарифҗаны да, шул елда ук экзаменнарын яхшыга гына биреп, университетка укырга керделәр. Каникулларга кайткан вакытында мин аны күрмәс өчен урамга чыкмый идем. Ул безгә керә калса, карават астына качам.

— Зариф, Зариф!—дип эзләсәләр дә, таба алмаганга:

— Тагын урамга чыгып киткән,— дип, әнкәй Фазыйлә апаның хәлләрен белешүгә күчә иде...

Гомер үтте. Мин дә үстем. Тугызда укыйм.

Югары класстагыларны студентлар белән очрашу кичәсенә чакырдылар. Ул елда Фазыйлә апа кайтып җитмәгән иде әле, соңгы ел укулары, каникуллары булмый икән. Ул юклыктан сөенеп, мин дә кичәгә барырга уйладым. Бәйрәм күңелле башланды. Төрле уеннарда катнашып, кичәнең үзәгендә булдым.

Өстәл тирәли утырышып, чәй эчү, ягъни мәҗлес өлеше башланып китте. Минем урын түрдә иде. Шаяртып сөйләндем. Студентларга сокланып утырдым. Шунда Фазыйлә апа белән Гарифҗан елмаеп килеп керделәр. Директорыбыз:

— Яңа өйләнешүчеләрне, бер-берсен табышкан ярларны котлап кул чабыйк!— диде.

Алкышларга күмделәр. Сүз Фазыйлә апа белән Гарифҗан хакында бара икән. Мин дә серемне сиздермәс өчен башкаларга ияреп кул чаптым.

Биюләр башлангач, арадан Фазыйлә апа, чыгып, мине чакырды, исемемне әйтеп сөйләште. Әмма сер бирмәдем. “Мин Зариф түгел” дип ялганладым. Ул ышанмады.

— Синә да мыек чыккан икән, егетләрнең асылы, кызларның башларын әйләндерүче булачаксың,— дип сөйләнде.

Ә мин:

— Сез мине Зариф белән бутамагыз, мин — Хафиз!— дип, һаман сүзләрен кирегә бора тордым.

— Ә мин сине күрсәтүләрен директорыгыздан сорадым, Зариф, алай алдарга ярамый бит!— диде ул бию ахырында.

Мин аптырап калдым.

Яшерүдән файда юк иде. Кичәне дә ташлап чыга алмадым. Күңелле бит. Мин инде ул бала Зариф түгел, үзе дә мин сөйгән Фазыйлә апа түгел!

Аңардан шигырь укуын үтенделәр. Ул энҗедәй итеп тезеп китте:

— Мин тамчысы язгы бу яңгырның... Мин кояшы аяз таңнарның... Саба җи-

ле булып чәчләреңне... Һәм гөлләрне сыйпап үтәрмен... Маңгаеңнан күчеп күзләреңә... Иреннәрең сөеп үтәрмен!..

Күзләремә яшь килде. Үзебезнең сыйныф бүлмәсенә кереп ябылдым, йөземне кызлар кебек учларым белән каплап еламакчы идем, йөрәкнең киресенчә ташка әверелә башлаганын сиздем. Харис атылып керде.

— Зариф, әйдә, директор сине чакыра, кызык ит әле үзләрен! — дип, мине өстерәп диярлек залга чыгарды.

Миңа сүз бирделәр. Шигырь укырга!

Һәм мин дөньямны онытып укый башладым...

Кем ничек кабул иткәндер, белмим, әмма Фазыйлә апа, ут янып, нәкъ инеш буенда бергә утырган чактагы төсле карлыгачтай очынды. Укып бетерүгә, килеп мине кочты һәм:

— Яратам мин сине, Зариф!.. Гарифҗан да шундый шигырьләр язса иде,— дип, яхшы сүзгә авыр ямаулык салды.

Мин кайтарып эндәшмәдем. Башны идем дә читкә чыктым һәм өйгә кайтып киттем. Йөрәгем туң, күңелем буш калган иде.

## КОШ БАЛАСЫ

*Хикәя*

Аны чыннан да «Кош баласы» дип атарлык.

Хәбир ялгышмады. Күңелендә һичбер усаллык һәм ахмак уйлар юк иде. Электән үк танышлар үзләре, әмма танышлык дәрәҗәсе студент елларыннан калган күреп белешүдән генә гыйбарәт булганлыктан, моны дуслык дип үк атау ярамастыр. Шулай да «Кош баласы» дигәнендә хакыйкать тә юк түгел төсле. Чөнки бу ханым гүзәллеге вә күңелләрне үзенә тарту көче белән һәркемне кол итәрлек сандугач тавышлы шул.

Сандугач тавышлы, әмма сандугачның үзе түгел. Җырчы булырга да насыйп итмәгән аңа Аллаһы тәгалә. Ә Хәбир өчен аның тавышы чын мәгънәсендә сандугач инде менә. Бер сүзен ишетүдән, бер ымын күрүдән йөрәге ярылып китәрдәй була. Алларына тезләнеп, табан асларында туфрак булыр иде юкса. Өзелә бит үзәге, өзелә, мескеннең.

Аларны җәйнең матур көне очраштырды. Көтелмәгән бу вакыйгадан Хәбир каушап, онытылып йөрде. Исенә төшерә иде дә, шатлык-сөенечкә чума иде. Эссе кояшның, һәр елда арка кыздыра торган Казан-су комлыкларының рәхәтен югалтты ул. Урамнарда көннәр, хәтта кичләр буе адашып йөрүне гадәт итте. Шушылай гына үзенә тынгы тапты, җаны рәхәт бер тынычлыкка, илаһи бер канәгатьлек диңгезенә чумды. Гүяки беренче мәхәббәтен очраткан егет төсле иде ул вакытларда Хәбир.

Кешенең бәхете үзеннән генә тора дип аңлатучы ялган сафсатага ышанырга мөмкинме соң? Менә күреп тора, аны сөендергән, бәхеткә күмгән зат — Кош баласы, сөйкемле Сания икән бит!..

Юк шул, юк, кешенең бәхете үзеннән генә түгел, башкалар белән дә бәйле,

хәтта тулысы белән дип әйтерлек бүтәннәр кулында икән ләбаса.

Аларның очрашулары һәм бер-берсенә якынаюлары гел дә көтелмәгән җирдән килеп чыкты. Хәбир шәһәр үзәгендәге туңдырма кафесына кереп, ялгыз башына бер өстәл биләп, җәелеп кенә утырган иде, янына бер илаһи бәндә килеп, эндәшә куйды:

— Сезнең яныгызда урын буш булса кирәк, мөмкиндер бит?

— Әйе-әйе, рәхим итегез!— дип кабаланды Хәбир, ничектер югалып калгандай үзен хис итеп.— Утырыгыз, утыр...

Ханым рәхмәт әйтеп, җай гына урын алды. Баштарак бер сүз дә эндәшмәде, аннан соң:

— Ай-й, без танышлар да кебек бит?! — диде.

— Ничек? — дип башын күтәрде, онытылып-югалып калган җиреннән Хәбир һәм кызны танып алгандай булды. Тукта, алар бергә укыдылар түгелме? Әйе, әйе, университетта. Бер курста түгел, әмма бер чордарак. Бу кыз әле кала егете белән уңышлы гына роман да корып, аны бәхетле иткән иде бугай, хәтере ялгышмаса?

Күңелдә генә истәлекләрен яңарту егетне беразга булса да тынычландырды. Шушы «Кош баласы»ның тавышы, чәчләре, күркәм йөзе инде әллә кайчан оныта башлаган бер затны хәтерләтә иделәр. Ул — Хәбирнең мәхәббәте, үлепбетеп йөргән кызның күчермәсе кебек тоелды. Сөйләшәсе, күңеленең кузгалуыннан рәхәт мизгелләр кичерәсе килде. Кыз да сүзгә саранлык күрсәтмәде.

Җыен юк-бар хакында сөйләшкәләп утырганнан соң, Хәбир бераз фикерен җыярга өлгерде һәм үзенең әңгәмә кора белмәвенә уфтанып:

— Гафу итәсез, төрле уйлар белән башымны катырган чагым иде, онытылып киттем... Тормышларыгыз ничек бара соң? Ирегез ни хәлдә, балаларыгыз? — дип, сүзләрне кабат үз эзенә кайтарды.

— Әле мин үпкәли дә башлаган идем,— диде ханым.— Бу, мин әйтәм, юри танымаган булып маташамы?.. Алай кыска хәтерлеләрне яратмыйм мин.

— Гафу итәсез, без алай ук якын танышлардан да түгел идек бугай,— дигән сүзләре белән Хәбир бу «Кош баласы»н аз гына үпкәләтте, әмма ялгышын шунда ук төзәтеп тә куйды: — Сез бит кала егетләрен ихластан гашыйк иттереп, сала бозауларын читкә кага идегез...

Ханымга бу сүзләр бик ошады. Ул җәелеп көлде һәм шаяртып кына егетнең гүяки үт куыгына басты:

— Төлке дә әйткән, ди, йөзем җимешенә буе җитмәгәч, пешмәгән икән, имеш... Егетләр кызларны каратамыни, кызлар егетләрне карата ул! И Хәбир!..

— Сез минем исемне каян беләсез? — диде егет, аптырап.

— Студент чактан бирле беләм, Хәбир! Ә син “карамадың” дигән буласың! Карадым, бик карадым!.. Синең генә талың авыл сандугачлары өчен түгел, бәлки шәһәр чәүкәләрен үзенә җыя иде,— дип, серен ачып салды.— Әле минем исемемне дә оныткансыңдыр? Әллә белми идең дәме?

— Ничек дип әйтим?..— дип сузды егет. Ул чыннан да ханымның исемен хәтерләми генә түгел, бөтенләй белми дә бугай. Ничек итеп үзенә әйтсен? Кызык хәл.

— Сания мин, Сания,— диде ханым.— Ә сөйләшкән буласың тагын.

Хәбир бу хәлдән соң гүяки өзелеп калган телен әйләндерә алмыйча газапланды. Ык-мык итте, әмма сер бирәсе килми иде.

— Әллә берәр затлырак шәраб ачабызмы? Очрашу хөрмәтенә,— диде ул, бөтенләй башка темага кереп.

— Мөмкин,— дип ризалашты ханым.— Миң каршы түгел...

Егеткә акча янчыгын бушатырга туры килде. Әңгәмәдәше баш тартыр дип өметләнгән иде дә, барып чыкмады.

Бардан шоколад тәме килеп торган татлы эчемлек бирделәр. Беренче рюмканы ханым озаклап эчте. Әмма икенчесен салдырмады.

— Моны болай калдырып булмый бит инде,— диде Хәбир.— Эчәргә кирәк, сезнең өчен алдым!

Ханым киреләнмәде. Кыстауларны кабул итте. Тавышы тагын да ямьләнеп китте. Хәбирнең күңеле серле бер богау белән аның тоткынына әверелә барды.

Ханым чибәр иде шул, бик чибәр иде. Казан егетләре ничек әрсезләнеп йөргән иделәр аның артыннан! Кая ди ул Хәбиргә аның янына якын килү. Кызларның чибәрләреннән ояла иде бугай ул. Ахмак, килеш-килбәткә камиллеге үзенең дә җитәрлек иде юкса. Әмма Санияне каратырга уена да кермәде. Сәер түгел, диген, бу дөньяны. Кара әле ничек бер-берсенә охшаганнар алар — Хәбирнең беренче мәхәббәте, мәңгелек сөю-сәгадәте Галия белән бу Сания. Ул борыннары-күзләре, иреннәре-тавышлары, бит алмалары, буй-сыннары. Әллә ялгыша микән? Ялгышмый, буталмый. Нәкъ үзе. Чәчләрен дә аныңча кистергән. Хәтта күңел төбеннән чыккан һәр аһы да Галиянеке кебек йөрәк-бәгырьләрне айкап ташлый.

— Синең тормышлар ничек соң? — дип сорады ханым.— Кайда торасың, өйләндеңме? Балаларыгыз?

— Аһ, тавышыгыз, колакларыма сандугач моңы булып ята,— диде Хәбир, күңелендәгесен ачып салып,— сез миңа беренче мәхәббәтемне хәтерләттегез.

— Әллә ул кеше мин идемме? — диде ханым, юри шаяртып.

— Юк, ул гүяки нәкъ сез инде: тавышы да, чәчләре дә, иреннәре дә. Барча-барча якларыгыз аны хәтерләттеләр, шунлыктан акылымны җуеп, буталып утырам бугай мин?

— Кызганыч, әмма беренче мәхәббәтең мин үзем булсам кирәк дип уйларга да өлгергән идем. Ялгышканмын икән,— диде ханым, бераз үпкәләгән төс чыгарып.— Кызганыч әлбәттә!..

— Кызганыч әлбәттә...— дип кабатлады егет, ни сөйләгәнне колагы ишетмичә.— Кызганыч. Бәлки ул син булгансыңдыр, бөтен җирең аны хәтерләтә...

— Аны хәтерлисең, ә мине юк,— дип борчылды ханым.— Шулаймы?

— Мин бит сине белмәдем.

— Яратмадың дамы?

— Болай игътибар итә идем. Әмма син ялгызың түгел идең.

— Ә-ә, син Мортазин белән йөргәнемне әйтәсең инде?

— Тик аптырый идем, ничек аңа карадың син?

— Әйттем бит инде: егет сайлый кызны, кыз түгел. Ул озатты, йөреп киттек, аңа ияләштем...

— Һәм кияүгә чыктың. Балалар үстерәсез. Бер малай, бер кыз.

— Каян беләсең? Әйе, бер малай, бер кыз...

— Юк, мин болай гына әйттем. Классик вариант: бер малай, бер кыз, парлылар, димәк. Милләтнең саны артмый да, кимеми дә. Шулаймы?

— Бәлки...

Алар тагын да шактый озак сөйләшеп утырдылар. Шәраб савыты да бушады. Шунда Сания:

— Аһ, мин онытылып утырганмын икән,— дип сәгатенә карады, кабаланган төс чыгарды.— Соңга каламын!..

— Моңа мин гаепле инде!

— Юк-юк, син нәрсә!

— Барыбер соңга каласың дип кенә әйтүем.

— Шулай инде, шулай...

Кафедан чыгып, Кабан күле буена килделәр. Моннан ерак түгел генә бер агач өйнең аскы катында Хәбирнең фатиры иде. Шуның турыннан узганда егет, мактанган кыяфәттә:

— Мин менә шушы затлы сарайда яшим инде, элек мондый йортларда падишаһлар гына торган!— дип, елмайгач, Сания аңа таба елыша төште һәм:

— Йә падишаһ, күрсәт тәхетеңне, карап чыгыйк,— диде.— Каршы килмәссеңдер бит?

Баштарак Хәбир аптырап алды, аннан соң мул итеп елмайды. Шаяртадыр дип уйлады. Шулай да:

— Әйдә, керик алайса,— диде.— Әмма ятим ир кешенең фатирында тәртипсезлектән артык һичнәрсә юк икәнлеген дә беләсеңдер?..

Кабаланган төс чыгарган Сания беркая да ашыкмый булып чыкты. Хәбирнең бүлмәсе җиһазларга әллә ни бай түгел иде. Ике иске кресло, сиртмәләре тузып беткән диван, язу-сызу һәм аш-суга яраклаштырылган кечкенә парта-өстәл, аның янында артлы урындык, сүрән утлы өстәл лампасы, китаплар белән дыңгычлап тутырылган, шунда ук барлы-юклы савыт-саба да куелган шкаф-этажерка — болар барсы да болай да кысан, уңайсыз бүлмәне тагын да тынчуландырган. Стенада эленеп торган, әмма үзенең кайчан туктаганын да оныткан сәгать, тоныкланып беткән көзге һәм алар арасына кадак кагып кына эшләнгән кием элгече бүлмә дивары белән бер яшьтә кебек тойгы калдырсалар да, аларны Хәбир ике атна элек кенә ишегалдындагы чүплеккә кемнәрдер чыгарып ташланган җирдән алып кергән иде. Әмма алар, ни хикмәт, барысы да Саниянең күңеленә хуш килделәр.

— Һо, нинди романтика!— диде ул.— Нинди антиквар, нинди байлыкларга ия икәнсең!

Шулай ук микәнни? Юк, юри шаярта булса кирәк. Боларны байлык дисәң инде? Киресенчә, “нинди мескенлек” дияргә кирәк, дөреслеккә якын булыр иде.

Әмма Хәбир кире кагып бер сүз дә әйтмәде, сөйләшүне икенчегә борып:

— Нәрсә белән сыйларга үзегезне? — диде.

— «Сез» дип, сөйләшергә яратасың да инде.

— Гафу, нәрсә белән сыйларга үзеңне? Тәмле чәем бар. Грузинский. Первый сорт.

— Башка нәрсә юк икән, чәй дә ярый,— дип, Сания креслодан урын ал-

ды.— Татлы шәрабтан соң тартасым килеп китте. Мөмкинме?

— Әлбәттә,— дип, Хәбир чәй куярга кухня ягына чыкты.

Озакламый чәйнеге кайный да башлады. Әмма Сания чынаякка үрелергә ашыкмады. Кабат-кабат хәл-әхвәлләрен сораштырды. Танышлары хакында белеште, әмма алар арасында уртак дуслары бөтенләй дә юк икән. Шунлыктан бу тема да тиз төгәлләнде. Шулай да Хәбир бу вакытта Сания ханымның сүздән тукталуын теләми башлады, һаман-һаман сөйләтеп кенә, ягъни «Кош баласы»н сайратып утыртасы килү рәхәтлегендә иде. Тавышы нинди ягымлы, колакларын рәхәтләндереп тора! Тыңлаулары куаныч бирә!..

Охшаш булсалар да булырлар икән. Килеш-килбәтләренә кадәр бер үк кебек. Сания һәм... Галия!

Хәбир тәмам исәрләнде. Аның бүлмәсендә җиде ят Сания түгел, беренче мәхәббәте Галия үзе утырадыр төсле тоелды. Үбеп кочаклыйсы, шушы тыныч фатирында калырга теләсә, аның белән бергә оя корасы килде. Әмма бу ханымның ике бала анасы, ирле булуы гына бу ниятеннән тыеп тора иде.

Шәраб үз эшен эшләде. Сүзләре колакларын назлады, төс-кыяфәте күзләрен алдады. Галиянең үзе бу, үзе! Сания бөтенләй башка сурәткә ия иде түгелме? Юкса Хәбир аны студент чакларында ук озата алмас идеме?

Кайнар чәй егетнең ярсу йөрәген суыта алмады. Сания, аның күңел кылларына кагылгалап, назлы тавышы белән сайрады да сайрады. Хәбир, онытылып, ханымның каршына килеп басты, алдына иелде. Йөрәк түренә яшерелеп калдырылган изге хисләре көтмәгәндә ургылып чыктылар һәм егет, үзен-үзе белештерми:

— Ничек бер-берегезгә охшагансыз, нинди ягымлы синең тавышың...— дип кабатлана-кабатлана сөйләде дә Саниянең иреннәренә үрелде: — Бәгырем!

Соңгы әйтелгән сүзе тылсымлы иде. Туң йөрәкләр дә шушы сүздән эреп китәләр. Санияне дә тоткын итте бу «бәгырем» дигәне.

Назлы вә сусаган иреннәр кавыштылар. Юк, алай булырга тиеш түгел иде. Бу эш гөнаһ иде. Әмма ханымның чәчләреннән иңгән хушбуй исе егетнең хисләрен тагын да ялкынсындырып җибәрде һәм алар бер-берсенең кочагына тәмам чумдылар.

Урамда көн иде. Кичке якта Хәбирнең тәрәзәсенә дә җәйге кояш карый башлый. Көннең узганлыгын белдереп соңгы мул җылы нурларын яудыра, күңелләргә наз вә рәхәтлек өсти.

— Хәбир,— диде Сания.— Хәбирем...

Күкрәгенә башын куеп яткан сөекле җанның чәчләреннән сыйпады егет, башында тагын да татлырак уйлар уйнады. Ханым аның иреннәрен эзләп тапты, күзләре ярым йомылган, хисләре күкрәгеннән ташып чыгу сәбәпле исәрләнгән иде ул. Аны шулай итеп тою Хәбирнең үзен дә адаштыра, бәхет-сәгадәт диңгезенә батыра барды.

— Галиям,— диде егет,— мин сине яратам...

Әмма Сания аның бу сүзләрен ишетмәде...

— Синең белән ничек рәхәт...— диде ханым, Хәбирнең иреннәреннән иреннәре аерылган мизгелне тагын да серлерәк вә мәгънәлерәк итеп.

Алар мәхәббәт уенынннан күңелләрен чәчәккә төрерлек наз таптылар, гүяки

үзләре ир белән хатын, берәмләп түгел, парлашып яратылганнар да, мәңгегә шулай булырга тиешләр.

Бөтен дөньяның үзәгендә ялгыз икесе генә кебек иде, бүтән бер генә нәрсә дә аларга кирәк түгел; әнә Сания нинди канәгать, тыныч, бәхетле!

Әмма ханым хәмер һәм мәхәббәт тәэсиреннән айныган, хәтеренә балаларын вә үз тормышын кайтарган, күңелен тынычландырган иде инде. Бары тик чыгып китә, киенер өчен кузгала гына алмый. Чөнки монда ул уңайлы почмак, җан рәхәте тапты. Күптән бу рәвешле һәм табигый, һәм илаһи мизгелләр кичергәне юк иде.

Хәбир — балалар кебек самими, тормышны аңламаучы, һаман да романтик булып кала биргән сабый күңелле олы җан иясе. Нәрсә ди? «Мәңгегә минеке бул, мин сине генә, бары тик сине генә яратам»,— диме?

Бик калыр иде Сания...

Ханым чыгып киткәндә кич иңгән иде инде. Хәбиргә авыр булып калды. Сания аның тынычлыгын, якты җәенең җылы кояшын шулай алып китте. Моңсу, бик моңсу иде хәзер егеткә. Ул кичтә Хәбир озак итеп Кабан күле буенда утырды, таң аттырасы да иде әле, әмма җил чыгып, тәне өши башлагач кына кереп ятты.

Сания «киләм» дип, сүз ташлап киткән иде. Икенче көнне дә, өченчесендә дә, бер атна, айдан соң да күренмәде, хәбәре ишетелмәде. Ни фатирын, ни эш телефонын сорап калмаган, сагынсаң да нәрсә эшли аласың?

...Хәбирнең җәе моңсулык белән үтеп тә китте. Урамга көз керде. Әмма күңелендә һаман да мәхәббәт язы кебек иде. Менә бүген Санияне очратыр, алар тагын бәхетле булырлар. Юк икән шул, алай җиңел генә сәгадәт казану мөмкин түгел икән. Назлы иреннәре, иркә кочагы, илаһи сихри тавышы кабатланмас микәнни?

«Кош баласы» очты. Бәхетле ояны онытты. Бәлки ул монда саташып кына кергән булгандыр?

Хәбир урамнардан урамнарга күчә-күчә атлады да атлады. Үз уйлары, үз хәсрәтләре белән иде ул. Шунда берәү:

— Хәбир, исәнме? — дип эндәште.

Аһ, Сания бит бу, Сания! Бары тик анда гына менә шундый ягымлы һәм назлы тавыш!

Хәзер кочаклап алачак үзен, «Саниям, бәгырем!» диячәк!

Әмма эндәшкән ханым Сания түгел иде. Егет каушап китте. Аның каршында Галия басып тора икән, газапларга салып та, инде онытылып та бетә язган мәңгелек мәхәббәт газабы — Галиясе!

## ҮЛЕ ЕЛГА БУЕНДА АВЫЛ БАР

*Хикәя*

Адәм баласын билгесезлек җәлеп итми башласа, дөньяның кызыгы бетәдер

ул. Моны аңлаганга түгел, канybыз белән тойгангадыр, без, авыл малайлары, зурлар күзеннән качып, кайда да булса уйнау ягын карыйбыз. Урманга да барып чыгабыз, колхозның ташландык терлек абзарларына да килеп керәбез, таулар арасында да йөрибез, һич югы, ындыр артына китеп, биек арыш арасында бер-беребезгә әкият сөйләп ятабыз. Кызык вакытлар! Су буена төшкән юк, елга тулып дегет ага, казлар-үрдәкләр тәмам каралып, җир маена баштанаяк батыпчумып йөриләр, йөриләр дә — тәгәрәшеп кырылалар. Аларның ярдәм сорап кычкырулары барча терек җанны куркуга сала, йөрәкләрне сагыш били. Безнең ачу килә. Әллә, дибез, шул җир бораулап ятучы вышка-каланчаларны шартлатабызмы? Ничек кенә итеп шуны эшләргә?

Көне-төне авыл өстендә утлы факеллар уйный. Өйдә шәм дә яндырасы юк, төн уртасында да яп-якты, каләм-дәфтәр алып, дәрес хәзерләргә дә мөмкин, кызыгын гына тапмыйбыз. Җәй көне шул, мәктәп эшләренә бүтән вакытта да җитешербез әле...

Әнкәй эндәшә:

— Шомыртка чыпчык кунган, тәм кергән микәнни?

Тәрәзәгә капландым. Нинди чыпчык ди ул, Гапсаттар икән, күрше Хәкимулла абзый малае, култык дус.

— Кая йөгердең, улым? Чәй кайнап килә, тамак ялгар идең...

— Мин хәзер, тиз керәм, әнкәй!..

Озакларга бер дә теләгем юк иде. Килеп чыгуга, шомырт агачындагы Гапсаттарның аягына ябыштым:

— Төш, төш, диләр сиңа! Миңа калдырмыйсың бит...

Аңа нәрсә, авызы ерык. Инде дә буем җитмәсен белә, авызына учлап-учлап тутыра.

Бәреп үтерәм дип булмый ич инде. Нишләтергә моны?

Гапсаттар, минем гасабиланганны күреп, тагын да авызын ера, хихылдый, башын кашый. Аннары:

— Ярар алайса,— дип, минем янга теләр-теләмәс кенә сикерә.— Өлгереп җитмәгән әле бу, иртәрәк. Эче яшел. Авызны бөрештерә. Юкка борчылдың. Менә елга артына чыксак, вәт анда, малай, Гыйльмениса апалар берәр чиләк җыеп кайтканнар!..

— Өлгермәгән дип тормадың әле, авызыңа тутырдың...

— Шуңа үпкәләдеңме? Мин болай, тәмен белер өчен. Күрше хакын өлешләдем, уңышы начар булмагае дип кенә...

Болай ук ышандырып әйткәч, ризалашмыйча булмый иде. Чәкәләшергә әзер җиремнән сүрелдем.

— Әйдә елга аръягына, шомыртка!

Өстәлдә чәй дә көтеп торганга, ризалыгымны бирергә ашыкмадым.

— Ни бит... Ни... Икәү генәме? — Сәбәп үзе табылып тора тагын.— Елга артындагы ул иске авылгамы?

— Нәрсә, җеннәрдән курыктыңмы әллә? Исең киткән икән, Гарәфине дә алабыз. Аның бетие бар, әбисе язып биргән. Җеннәргә каршы. Койрыкларын да селкетә алмаслар.

— Ә койрыксыз булсалар?— Миңа ничек тә аны ышандырырлык сәбәп та-

барга кирәк, югыйсә чәйсез калам. Каймак, шуның янына — коймак, бал. Аларга өстәп әнкәй прәннек тә чыгарса, бернинди җеннәр оясы кирәкмәс, һәй, юләр, андый нигъмәтләрне калдыралар димени?

— Койрыксыз җеннәр бармы инде, ахмак сүз сөйлисең. Үзе койрыксыз да булсын, җен дә... Менә әкәмәт!..

— Убыр инде, алайса!

— Шулай диген аны, җен, имеш, койрыксыз, имеш...

Гапсаттар алдында адәм хурлыгына калдым. Ярый әле әнкәй чакырып алды. “Тиз чыгам” дип кереп шылдым. Гарәфине эзли торсын. Ул арада мин дә корсак тутырырга өлгерермен.

Уем юш килде. Бал, май, коймак янына кала прәннеге дә бар иде. Әмма чокырның төбенә төшәргә, прәннеккә үрелергә дә өлгермәдем, Гарәфинең борын тишекләрендәге авазларын да кушып сызгырган тавышы ишетелде. Озак көттерми, Гапсаттар үзе үк кереп җитәр һәм:

— Хасия апа, Ярулла чыксын әле,— дип, чәйдән бүлдерәчәк...

— Әнкәй, рәхмәт, тәмле булды,— дия-дия кузгалып, кесәмә өч прәннек тыктым да, артымнан әйтелгән үгет-нәсыйхәтләрне ишеккә кысылган хәлләрендә калдырып, култык дуслар янына элдердем. Аяклар яхшы майланган тәгәрмәчләр төсле үзләре үк йөгертә иделәр. Капкага җитәрәк, Гапсаттар белән маңгайга маңгай килдек.

— Сөзеп үтерәсең бит! — Дустым очкан җиреннән мүкәләп торды да тагын шул сүзләрен кабатлады.

Мин капкага барып сыланган идем. Гапсаттарның күңелен йомшарту өчен кесәдән тизрәк прәннек чыгарып, кулына тоттырдым. Ачуы онытылып, нәфесе хушланды. Нишлисең, койма артындагы Гарәфигә дә бирергә туры килде. Аларга ияреп, өлешемә калган өченчесен тешләштерә башладым.

Безнең юл су буена таба, басмага иде. Аннан исән-имин чыксак, иске авылның шомырт бакчасына корт булып төшәчәкбез!

— Карале, малай, бу елгадан үлек исе килә.

Ни чыкса, Гарәфинең авызыннан чыга инде ул. Телгә салынып барган җиребездә шым булдык. Елгадан чыннан да үлек исе борыныбызга кергән кебек хис ителеп, укшыта башлады. Гапсаттар үзенең борын тишекләрен каплады. Күзләре аллы-артлы йөренә иделәр.

— Моңда бер-бер үлгән нәрсә ята булыр. Дөнья шушы кадәр сасымас иде.

Әмма аның сүзләрен дәлилләүче һичнәрсә күренмәде. Елга тирәләре тәмам шәрә калган, ник бер үлән сабагы, яфраклы агач яки талчыбык күзгә чалынсын.

Басма итеп салынган, кайчандыр ак тузлы каен агачлары булып та, хәзер майланып каралган сыгылмалы ике киртә буйлап ярның икенче ягына чыгу хәтәр эш иде. Үрмәләсәң, куллар һәм тез башлары дегеткә буялачак, аяк өсте генә үтәрмен дисәң, таеп китүең, баштүбән очуың бар.

Без, уйланып, ниятләнә алмый торганда, Гапсаттар инде икенче якта иде. Һе, аңа ни кыенлыгы бар дип беләсез? Гәүдәсе җиңел, мамык кебек, җил иссә дә күтәреп кенә ала. Юка тәненә сыланып торган күлмәк-чалбарлары да элпә канат төсле.

— Әйдә, Ярулла! Нәрсәдән куркып калдың?

Чират миңа тигәч, нишлим, яңа гына шыплап тутырган шар кадәр бүксәмне уып куйдым да, баш та кашып тормастан алга атладым. Әмма минем килүемне сизенгән басма аяк йөрешемне тоюга ук сыгылгалап куйды. Елга белән чопыр-чапыр сөйләшеп алдылар. Миңа инде, хәвефтән аман дигәндәй, борылып, кайтып китәсе генә калды.

— Әйдә-әйдә, мин бу башыннан тотып торам, аяк терәп... Курыкма! — Гапсаттар әмәлен тапкандай өйрәтә бирде: — Гарәфи, син ул очын кара!

Басма уртасына килеп җиткәндә, таеп, чактан егылмый калдым. Йөрәк жу итеп, көчкә-көчкә чыгып җиткәнемне үзем генә беләм.

— Ну, малай, очсаң, негр буласы идең. Бәхетең бар икән, әле дә ярый тотып калдым...

Ай-яй, шулай ук микән?

Гарәфи генә чиратын җиңел уздырды. Ян белән ваклап-ваклап атласа да, җиңде тагын.

Гапсаттар аны да мактап куйганнан соң, юлларыбызны дәвам иттек. Комлы тар сукмак, шайтан таяклары арасыннан үтеп, шомыртлыкка таба сузылган иде. Анда безне ташландык иске авылның җимерек йортлары, салмыш мужиклар кебек кыегаешып басып торган капка баганалары каршы алачак. Аларга сәлам бирми генә узып, агач башларына үрмәләячәкбез.

Көннең эсселеге маңгайларны тирләтсә дә, телләребезнең сүзгә дәртен туктатырлык дәрәҗәдә түгел иде. Беребездән икенчебез уздыра-уздыра сафсата сатабыз. Бәхәсләшеп тә китәбез. Шулай да тарткалашуга кадәр үк барып җитмәдек әле. Ни дисәң дә, дуслар шул без!

Гапсаттарның койрыклы женнәреннән соң минем койрыксыз диюләр хакында белгән-белмәгәнемнән хикмәтләр сөйләп ташлавым гәпкә маһирлыгы чамалы Гарәфинең телен шомартты. Әмма арттырыбрак җибәрде булса кирәк.

— Минем бабай шушы авыл башында бервакыт, ни, шайтанның үзен очраткан булган. Колаклары ишәкнеке кадәр, ди... Килә икән бу, килә икән... Маңгаенда ике мөгезе бармак башы кадәр генә чыгып тора, дүрт аякта йөри, йонлач, ди, менә малай!.. Әйе, ышанмасагыз, белеп торыгыз. Башмаклары сыер тоягыныкы кебек икән. Күзләре уттай яна, кып-кызыл... Җитмәсә, койрыксыз, ди, үзе... Әйе...

Аның сүзен Гапсаттар кырт кисте.

— Андый шайтан да буламы?

— Нинди?

— Үзең әйтәсең бит, койрыксыз, дисең.

Койрыксызлар мәсьәләсендә мин «белгеч» саналганлыктан, Гарәфи, ярдәм сорагандай өметләнеп, күзләрен үземә төбәде.

— Әйе шул,— диясем генә калды һәм шулай такылдарга да өлгердем.

— Ну, малайлар, шыттырасыз да инде сез! — Гапсаттар бездән чын мәгънәсендә канәгать түгел иде.— Алдыйбыз дигәч тә, бу кадәр үк ярамый ул, Ходайны үпкәләтүегез бар.

Мондый да олы сүз култык дустыбызның авызыннан чыккач, шым калып, тыннарны кыстык. Бәхәстә аны җиңәрлек дәлилләр бездә юк иде.

Малай чакта шулай бит, кемнең сүзе өстен, ул юлбашчы була. Хәер, өлкән-

нәр арасында да хәл нисбәте үзгәчә түгел. Зурларның гамәлләрен без, балалар, кечерәйтеп уйныйбыз шул.

— Менә бу агачның шомырты пешкән күренә. Үзе эре...

Гапсаттарның бармагы төрткән җиргә күзләребез төбәлде.

Алдамый, нәкъ шулай булырга кирәк.

Аның артыннан агачка үрмәләргә үк тотындык. Бу юлы мин арткарак калдым. Коймаклы чәйдән шардай булып, сеңәргә өлгермәгән әлеге дә баягы бүксәм монда да үземне оятка калдырды. Күтәрелеп кенә китеп булмый бит, чукынчык.

Култык дуслар ул арада шомырт агачына үрмәкүчтәй менеп тә җиттеләр, мин әле һаман әйләнәм дә килеп төшәм, тәгәрим дә егылам. Болай оятка каласымны белсәм, һич югы балга-майга басым ясамаган булыр идем. Күр инде моны, йә!

Кемдер артымнан юри тартып төшерә дә, аңа кушылып, бүтәннәр көләдер төсле тоелды. Гарьлегемнән җир тишеген эзләргә тиеш идем, бу егылуымда якягыма карандым. Ни күрим, мөгезле һәм олы колаклы, кызыл күзле, хәшәрәт рәвештә маңкаланган кара йонлач тәнле, әле яңа гына, юлда Гарәфи сөйләгән шайтан миңа таба килеп маташа иде. Котым ботыма төшеп җиткәндер, куркуымнан чинап җибәрдем. Иптәшләрем ни булганын сорарга өлгергәнче мин инде алар янына менеп ябышкан идем. Аңлатырга кодрәтем җитмәде, бармак белән генә төртеп күрсәттем дә ым кактым:

— Үзе...

Теленә салына-салына шомырт чүпләгән Гапсаттар белән Гарәфи аһ итте. Безнең куркып калтырануданмы, әллә инде үзенә җан кереп өркүдәнме, шомырт агачы да дер-дер килә башлады. Болай да тәндә кот әсәребез калмаган, ә теге шайтан туп-туры безгә якынлаша бара, тояклары белән җирне актара, пошкыра, тагын әллә нәрсәләр эшли. Сөйлиләр иде аны, шайтаннан һичкая качып котылып булмый, суга чумсаң, аны корыта, тауга менсәң, ишә, агачка үрмәләсәң, тамырын каезлый, дип. Бетте башлар...

— Гарәфи,— дип пышылдады Гапсаттар,— чыгар теге бетиеңне, яндыр шул Иблисне.

Аның бу сүзләре мине дә аңга китерде. Әйе, Гарәфинең куенында Коръән теле белән язылган бети-бетек бар бит. Булды гына, шайтан беркая да китә алмый, хәзер янып юкка чыгачак.

— Янымда түгел шул...

Гарәфидән бу сүзне көтмәгән идек. Ничек инде алай? Һаман да үзе белән йөртә иде. Юк, шаярта гына торгандыр.

— Маташма, вакыты ул түгел, чыгар тизрәк. Тиз бул инде, хәзер башыбызны ашый бу!

Ләкин болай үрсәләнүем файда бирмәде. Гарәфи ышанычны акламады, хәлебез артыгы белән мөшкел иде.

Ул арада шайтан нәкъ без үрмәләгән агач төбенә килеп, нидер эзләгәндәй итте. Бәхетебезгә дип әйтимме, өскә күтәрелеп карамады. Тын алырга да куркып, өнсез калдык. Белмим, шушы хәлдә тагын күпме җансыз булыр идек, ярый әле кеше тавышлары ишетелде.

Ирләрне күрсә, Иблис кача да кача инде ул!

Кулларына кайсы тишек калай ләгән, кайсылары сәнәк-багор ише нәрсәләр тоткан хәлдә, ярсып сөйләшә-сөйләшә, ташландык йортлар артыннан өлкән кешеләр килеп чыктылар. Берсендә хәтта мылтык кебек әйбер дә бар иде. Шайтанны куа килүләредер мөгаен? Кайчан күреп-белеп өлгергәннәр?

Безгә җан керде. Гапсаттарның да атасы монда якынлашучы ирләр арасында булганлыктан, куркыр урын калмаган иде. Җитмәсә, тишек ләгән төпләрен каккалап, шаулашып та алдылар. Иблис, мескен, өркеде, моннан аяклану ягын карады.

— Авыл ягына җибәрмәгез!— дип сөрән салды ирләр.

Кемнәрдер уңга таба, кайсылары сул якка йөгереште. Без дә түбәнгә шуыштык. Вакыйгадан кызык табып, ирләрнең артларыннан иярдек. Шунда мактанган кыяфәт белән Гарәфи әйтә куйды:

— Койрыксыз шайтан булмый дип бәхәсләшәсең тагын. Күрдегезме инде?

Бу сүзләре Гапсаттарга аталган иде, әмма ул аны колагына да элмәде. Бераз барганнан соң гына:

— Кем әйтте әле сиңа аны шайтан дип? Күрмисеңмени, поши бит бу!

Поши? Чыннан да поши микәнни?

Гомеремдә беренче тапкыр тере поши күргәнлегем сәбәпле баягыдан да ныграк таң-гаҗәеп иттем.

— Әйе, Ярулла, поши бу! — дип, Гапсаттар озын нәзек буен горур кыяфәткә кертергә теләгәндәй кукраеп алды.— Әллә шайтан дип уйлаган идеңме?

— Үзең соң, агач башында!..

Әмма бу үчекләнеп әйткән сүзләрем аның белдекле кыяфәтенә зыян китермәде, этисе дә монда булганлыктан, мин аның янында чүп кенә идем. Бүтән вакытта да бик исе китеп тормый дусларына. Шундый инде ул безнең.

— Хәкимулла абзый, чыннан да бу пошимы?

Минем соравым үзенә аталганлыктан, әүвәле өстемә карап куйды, аннары, әбиләр әйтмешли, төрек солтанында гына булырга мөмкин саналган гаҗәеп шәп борынын дәү учына сыйдырып бетерергә теләгәндәй әвәләп алды. Менә шуннан соң яхшы тавышы йомшак колакларны ныгытты:

— Нәкъ үзе, поши бу, Ярулла энем!

— Шундый да хәшәрәтме?

— Юк, дегет базына төшкән ул! — Хәкимулла абзый мәгънәле төстә итеп теш арасына мин аңламаган бер урыс сүзен кыстырды.— Асылда пошилар карап туймаслык матур булалар. Ә моны харап иткәннәр. Шашынып, акылдан язып йөри. Дегеттән тәне янадыр, бичараның? Ничә көннәр шулай саташып чаба torгандыр, белгән юк... Авылга кереп, көтүгә ияреп, малларга зыян итмәгәе дип куркабыз. Ни, балалар, монда йөрмәгез...

Сүзен әйтеп бетермәде, бригадир буларак, бүтән ирләргә әмерен кычкырып, поши артыннан ашыктырды:

— Авыл ягына чаба бит, ни карыйсыз анда!

Елга аша барганда поши сазлы җиргә кереп батты. Хәле беткәнлеге сәбәпледер, аннан чыга алмады. Ирләр исә кичкә кадәр, терлекләре абзарларына кайтарылып ябылганчы, аны уратып сакладылар, һәммәсенең күзләрендә хәсрәт

иде. Пошиның кызганыч хәле, авылны төрле яклап чолгаган дегет хәвефе каршында алар да чарасыз иделәр.

Зурларның көче җитмәгәндә без, балалар, нәрсә кыра алабыз соң? Бу вакытлардан минем аңыма шул сеңеп калды: югарыдагы ниндидер иләмсез бер түрә халыкны харап итәр һәм интектерер өчен җир астыннан дегет чыгарта да, елгаларга махсус түктертә булса кирәк!

Кич иңгәндә өлкәннәр яр буенда учак тергезделәр. Пошины төне буе сакларга иде исәпләре. Безгә генә өйләргә кайтып китәргә туры килде. Шомырт ашау уе башыбыздан да чыккан.

Иртән урамда култык дусларым белән очрашкач, иң беренче сүзем шул булды:

— Әйдәгез, пошины күрергә төшәбез!

Гапсаттар миннән көлеп куйды:

— Нинди пошины?

— Кичәге!

— Аны яндырдылар шул инде...

— Ничек? — Мин Гапсаттарның якасына килеп ябыштым. Ул исә кулларымны сыпырып кына төшерде дә, әйтеп салды:

— Ишетмәдеңмени төнлә ату тавышын. Үтергәннәр дә, өстенә керәчен сибеп, ут төрткәннәр. Барыбер рәткә керәсе түгел иде инде ул.

Гапсаттарның монда гаебе юк иде. Мин дә тынычланып, якындагы капка төбенә барып утырдым. Гарәфи дә янымнан урын алды.

— Борчылмагыз, малайлар, ыһ та итмәгән. Рәхмәт кенә әйткәндер әле!

Гапсаттар шулай диде дә бит, әмма бу пошиның хәсрәте озакка җитте. Апалар-җиңгиләр ул елда урманга аяк атламас булдылар. Безне дә әрәмәлекләргә керүдән, агачлар арасында йөрүдән тыйдылар. Ни эшләсәк тә, күз-колак тота иделәр. Иске авыл янындагы шомыртлыкка да күңел тартмады. Җимешләре шул килеш коелып, әрәм булып беттеләр.

Йөрәкләргә хәвеф кереп оялады. Нишлик, хәтта урман да, без анда бармаганлыктан, моңсуланып, кечерәеп диярлек калды. Вакытыннан элек саргаеп, кара көз кергәнче үк яфракларын койды. Бу — урман иясенең адәм балалары кылган гамәлләргә үпкәсе, мескен баласы поши өчен хәсрәтләнүе иде. Аны үртәмәс өчен, авыл халкына бер-бер зыян итмәсенгә һәркем саклык күрсәтә иде анысы. Бәлки, чыннан да, урманга барудан тыелып тору, шушы рәвешле аның хуҗасыннан барчабызның ярлыкау үтенүе дөрес гамәлләрдән булгандыр?

Әмма мин тагын шуны хәтерлим, ул елда, ни хикмәт, юлларда соры бүреләрне күрү очраклары хакында бик еш сөйләделәр. Язга чыккач, көтүлеккә китерелгән маллар да шашынып, урман эченә кереп киткәннәр. Өч көн буена диярлек гаҗизләнеп, хуҗалары көчкә җыеп алды үзләрен.

Бу вакыйгалар исә безне, авыл малайларын, шактый сагайтты. Өлкәннәрдән качып уйнау гадәтебезне тәмам онытып, кеше күзе төшкән, колагы ишеткән урыннарда гына була башладык. Юк, бу безнең куркаклыгыбыздан түгел, бәлки табигать каршында адәм балаларының көчсезлеген аңлаудан килә иде.

Хәзер дә, болар хакында уйласам, кешеләр бу Җир шарыныкы түгел, читтән килгәннәр дә, шунлыктан, яулап алучылар буларак, гомерләре буена табигать

белән яки солых төзеп дустанә яшәргә, яисә көрәшергә мәҗбүрләр. Алар инде күптән, кеше һәм табигать, берсе икенчесенә бәйле югыйсә. Әмма табигать, кешеләргә теләгәннәрен эшләргә юл куйса да, аз гына ялгышулары өчен дә аларны зур газапларга тарта сыман. Шулай түгелме? Ә бәлки мин ялгышамдыр. Җир йөзендә кешедән дә көчле һәм кодрәтле бүтән җан иясе юк түгелме соң?! Шулай дигән булалар да бит...

## МӘХӘББӘТ КЫҢГЫРАВЫ, ЯКИ СӨЙЛӘНЕП БЕТМӘГӘН ХАТИРӘ

*Хикәя*

Юл йөрүнең хикмәте бар, ул һәрвакытта да диярлек гыйбрәтле була.

Казан вокзалыннан Уфа поездына утырып киткәндә үк бер кешегә игътибар иттем. Халык тегендә-монда ашыга, ә ул, һичнигә исе дә китмичә, гәҗит ачып кулына тоткан да үз җаена гына укый бирә. Килеш-килбәте дә ярыйсы гына, янында портфеле дә бар. Әмма эскәмиядә түгел, кеше йөри торган урында — баскычка җайлашып алган. Кемнәрдер аңа бәрелеп китәргә мәҗбүрләр, гафу үтенәләр, ә монын исе дә китми. Бар дөньяны янга ташлаган. Әллә салмышмы икән?

Мин утырырга тиешле составны өченче юлга кертүләрен радиодан вокзал хәбәрчесе белдерде. Шунда ашыктым. Вагонга кереп, урыныма утырдым. Җайлашырга өлгермәдем, күземә күренәме дип торам, теге кеше килеп чыкты. Бергә барачакбыз икән. Күңел киң булсын!

Тамак ялгарга гына утыргач, сүз иярә сүз чыгып, ул белдерү ясады:

— Мин сезне беләм бугай...

Каршы килмәдем. Таныштык. Камил Сабитов, инженер икән.

Кузгалып киттек. Бераздан чәй китерделәр. Җылынып алырга да өлгердек. Шуннан соң ул тагын сүз башлады:

— Мин бер хикәя укыган идем... Анда үзеннән өлкәнрәк яшьтәге кызга бер үсмернең мәхәббәте сурәтләнгән.

Аның вокзалда чагын исемә төшереп елмайдым. Нинди газета укыганлыгын сорап торасы түгел, ул — "Ватаным Татарстан", өстәлдә ята иде.

Камил Сабитов нәрсә уйлавымны аңлап алды ахрысы, теге газетаны кузгатып куйды да сөйләп китте:

— Күңелне кузгатты ул минем. Элегрәк укыган идем мин аны. Танышларым, нәкъ сине язганнар анда дип аптыраткан иделәр... Әйе, тормышта язмышлар арасында охшашлыклар бардыр инде ул. Әмма минем тарихчам башкачарак килеп чыкты. Ул хикәядәгечә үк түгел...

Болай сөйләве күңелне үртәде. Менә хәзер: "Теге, мин укыган хикәя, сезнеке иде!"— дип әйтер сыман һәм, кырыкмаса кырык гаеп табып, ачулана башлар кебек иде. Үземне бик тә уңайсыз тойдым. Шулай да, әйдә, тыңлап карыйк дигәндәй аңа дикъкатемне төбәдем. Бүлдерми генә тыңлый бирдем һәм дөньямны

оныттым. Чөнки аның хатирәсе бик матур сүзләр белән:

— Дөньяны — мин, мине дөнья сөя, сөешә идек!— дип башланып китте.

Тау асты Хисмәтулла абзыйның кызы авырып урын өстенә яткач, авыл клубы тәмам сагышланып калды. Җырласа — елата, биесә — өздерә, хикмәт инде менә, яннан үтеп китә, ут калдыра торган кыз иде шул ул.

Без, яшьрәк, боларын абыйлардан ишетә идек. Алар исә Хисмәтулла абзыйның кызы Маһинур апага һәммәсе бердәй ихластан гашыйк иделәр. Әмма кичен капка төпләренә кадәр генә булса да озата барырга берсенең дә кодрәтеннән килмәде, мөгаен, йөзем җимешенә дигәндәй, үрелеп тә буйлары җитмәгәндер инде. Ә мин әлегә яшь идем. Шулай да егетләрнең котын алып, араларына сүз салдым:

— Маһинур апаны үзем озатачакмын, белеп торыгыз!

Яшьтәшләр авызларын күтәреп көлделәр, күршем Самат, мине үчекләп, юри әйтеп куйды:

— Буең белән мактанма! Син түгел, әнә Илфат абый тилмерде аның белән. Нәрсә белән бетте? Шәһәргә чыгып качты. Маһинур үзен әллә кемгә куя ул, миңгә бер очрый торган гүзәлкәйне ияртеп кайтым да акылга утыртам дип, сүз биреп чыгып киткән, әле әйләнеп, кыз күрсәтергә җитешкәне юк әле. Атасы да, ул дивана улымнан кул селтәдем дигән, ди...

Саматның бу сүзләреннән үртәлеп куйдым:

— Дигән ди, дигән ди... Дисә соң! Ә мин менә Маһинур апаны озатачакмын һәм үземә каратачакмын!— дип егетләндем.

Әмма алай ук кыланмасам да яраган буласы иде.

Үҗәтләнүемнән яшьтәшләрем эчләрен уып көлделәр. Мыскыллый да башладылар:

— Кая ди ул сиңа!.. Маһинур апаның чибәрлеген күр дә, үзеңне бел... Буең гына бар, башка тагын нәрсәң белән мактана аласың? Гомереңдә берәр тапкыр кыз озатып караганың бармы? Син, әнә, мәктәптә чагыңда Чапай Галләменең Бибнаҗиясен дә килбәтең белән өркетә идең. Күзләреңә ничекләр тутырып карый иде. Өзелә иде шул, өзгәләнә иде... Хәзер генә, синнән булмагач, Сәфәрнең башын әйләндерә,— дип, типмичә дә бәгыремне күгәртеп, сүз артыннан сүз кузгата тордылар. Әмма аларга бирешәсем килми иде.

Без инеш ярының яшел чирәменә тезелешеп, аякларыбызны түбәнгә салындырып утырган идек. Бишебез дә монда, сабакташлар һәм җан дуслар. Быел гына урта мәктәпне күрше авылга йөреп тәмамладык, инде егет булдык. Борыннарыбызга кызлар исе кереп, акыллар буталыр чаклар бу.

Яшереп торуның файдасы юк, алар барыбер һәммә нәрсәне белеп торалар. Хәтта Сабирларның әле кичәге көндә генә сыерлары ала бозау китергәнен дә, башкасын да. Егет малайлар, әллә инде малай егетләр без?

Белсеннәр әле, үзем дә турысын әйттем.

– Клубка чыгабызмы соң?— дип, бераздан сорау ташладым аларның колагына. Дөресен генә әйткәндә, миңа барыбер иде. Чыңгыз тавы артыннан күтәрелеп килгән тулы йөзле мөләем айның серле елмаюыннан күңелем нурланып киткәндәй иде.

— Клубта ни калган?— диде күршем Самат.— Сиңа дигән Маһинур апа да юк бит анда. Шул Бибиәсма, Бибинаҗия ишеләрдән гайре күз салырлык кем бар?... Бәхетле син, Камил! Маһинур апаны озатам әле, дисең. Эһ, малай, синдәй буем булсамы?— дип сикереп тә торды, арттагы читән казыгына китереп тә типте.— Шушы нәрсә кадәр гәүдәң булмасын, үрелсәң, шүрлеккә буең җитмәсен...

— Ә син урындыкка басып мен!— диде Сабир, телгә килеп.— Мин һаман шулай итәм: буем җитмәсә, урындыкка басып үреләм.

Тәгәрәшеп көлдек. Бераз тыела калып, Маһинур апаның гүзәл күз карашлары, зифа буе, кара чәч вә кашлары, күңел кылларын чиртә торган озын керфекләре — һәммәсе-һәммәсе күз алдыма килделәр. Гүяки үзе каршымда басып торадыр кебек иде. Талпындым, чак кына яр астына барып төшмәдем, сикереп, артка ташланырга өлгердем, аякка бастым. Көтелмәгән бу хәрәкәтләремнән башкаларр өркешеп киттеләр һәм, ниндидер ят тавышлар чыгарып, эттән аякларын яшергәндәй җыерылдылар, яр читеннән бирегә ыргылдылар: йөрәкләре дөп-дөп килә иде аларның.

— Ни булды, ни булды?— дип үзара хәлләрен белешәләр, җитмәсә.

— Әнә, Сабир бит,— диде Җиһанша, болай да хәтсез борынын тартып-тартып.— Ул бит!

— Авызыңда нигә ботка пешерәсең? Ник алдыйсың?— дип, Сабирның нахак сүздән коты очты.— Ни эшләгән әле мин? Белеп сөйләш, юкса...

— Нәрсә юкса?

— Менә синең ипи шүрлегеңә буем җитә, менеп кенә төшәрмен!

Болай ук ярамый иде. Дусларның әле генә бик дустанә утырган җирдән юк кына сәбәп аркасында тарткалаша башлавы юньлегә тугел ул.

Җиһанша аптырабрак калды, аннары, Сабир әйтмешли, авыз эченндә тагын да бөтка пешерә башлады:

— Син дип инде, сине әйтәммени мин!.. Камил диясе идем...

Аның аклануы да Сабирның күңеленә хуш килмәде.

— Сабир — менә мин ул, Камил — менә ул!— дип миңа төртеп-төртеп күрсәтте.— Гомереңә барыбызны да бутадың инде!

— Исемнәрне генә лә!— диде Җиһанша, һаман да борынына тынгы бирергә теләмичә әвәләп, үзен аклый биреп:— Бүтән бутаган нәрсәләрем бар?

Ниндидер начар сүз белән зәһәр итеп әйтмәкче иде дә Сабир, сабыр канатларын төзәтеп тынычланды, тавышын йомышарта төшеп:

– Мин болай гына, ярар инде...— диде.

Бу вакытта ул, Җиһанша белән тарткалашкан җиреннән арты белән килә-килә, яр читенә җиткән иде, чак кына инешкә әйләнеп барып төшми калды, тотып алдым.

— Уф!– дип куйды ул, ике атлам диярлек кирегә сикереп.— Әле дә тотып калдың, кадаласы идем, уф! Җаным чыга язды...

Урамга таба кузгалдык.

— Клубка чыгабызмы соң?— дидем мин, бу юлысы ныклы карарга килеп, дусларымның алдына төшеп.— Тагын кайда баррасың инде, әйдәгез, йөреп кайтабыз!

Алдадым. Ә мине күңелем Тау асты Хисмәтулла абзыйлар тыкрыгына тарта. Маһинур апаны күрәсем килә. Тукта әле, нигә аларны шулай “ау асты” дип йөртәләр икән? Алар киресенчә, авылның нәкъ уртасындагы диярлек йортта яшиләр. Каян килеп анда яр асты булсын ди?

Кызыксынуым шулкадәр көчле булган ки, иптәшләремнән моның сәбәбен сораганымны сизенми дә калдым. Баш — уйлады, тел — тегермән кебек тарта торды. Көлерләр инде хәзер.

Әмма бу соравымнан дусларымның авызлары ачылып, көләргә җайлары калмаган булып чыкты. Кешенең башына да килмәгән хәлләрне белгән әлеге дә баягы Сабирыбыз тагын һәммәбезне дә хәйран калдырды:

— Тау асты дигәннәре шуннан аның, егетләр, Хисмәтулла абзый яшь чагында бер чыгарган да исемен “Тау асты чишмәсе” дип атаган. Халык аны чыннан да баштарак “Тау асты җыры” дип йөргән, әмма дә Хисмәтулла абзый солдатка алынгач, истәлеге хакына “Тау асты Хисмәтулла көе” дия башлаганнар. Шуннан килеп, җырның сүзләррен онытканнармы, үзгәртеп бетергәннәр,ә менә “Тау асты Хисмәтулла”сы абзабызга ябышып калган.

Безнең болай да ачык авызлар бөтенләй дә мич казаны кадәр булдылар. Каян beләдер бу Сабир һәммәсен дә? Юкка гына авылыбызның кола сыерлары да ала бозау китермиләрдер. Менә бит, ә?!. Әүлиядер ул...

Клубта уен-көлке дә, шау-шу да юк иде. Гөрнәдирдәй егетләр, авыз читләренә сасы папирос кабып, дөньяны төтен белән ыслый иделәр. Безгә сәлам дә юк, сүзләребезне дә ишетмиләр.

Эчкә таба уздык. Мөдирр Габдеррахман абзый, фуражкасын кыңгыр салып, бер почмакта гармун шыгырдатып утыра, ә биюгә кем дә чыкмый, теләүче дә юк. Менә шулай ул, Маһинур апаның кадеррен белегез. Сезгә кичәгезне башлап бирмәсә, үзегездән мәңге буласы түгел. Бер-берегезгә карашып тик торасыз. Бигрәкләр дә пешмәгәннәр инде безнең авылның ни кызлары, ни егетләре!

Габдеррахман абзый үз алдына боегып гармунын тарткан җиреннән айнып киткәндәй булды, уйнавыннан тукталды. Клуб эче шым калды. Безгә карап-карап алганнан соң, уйнаса да биемәсебезне аңлап, гармунын урындыкка яны белән яткырды да, үз бүлмәсенә кереп китте ул. Магнитофон чыгарып, тасма куеп карады. Биергә дәртләре җитмәдеме, һичкем уртага чыкмады. Барысы да дивар буйларынында сыенышып тора бирделәр. Ул без генә, яшь әтәчләр, зал уртасында сикерешеп, бераз язылып алдык. Биибез, имеш. Кушылучылар күренмәгәч, кыландырып маташуларыбызны ташлап, урамга таба атладык. Төн үтә дә тыныч һәм чикерткәләр сайрату, ябалаклар кычкырту белән мәшгуль иде.

Киттек.

Күктән йолдызлар ява. Шундый рәхәт һава. Әти әйтмешли, ипигә май урынына ягып ашарлык. Борын асларыбызга юка гына булып шытып килгән мыекларыбызны кытыклап салмак җиле дә үткәләп-сүткәләп куя. Күңел үрсәләнә, эһ, бер җырлыйсы һәм табаннар ярылганчы биисе килә. Туйларда сыйланып алган әткәй кебегрәк итеп, күнитекне әле уңга, сул-уңга, уң-сулга чалыштырып кына куйгалап, сабырлык белән йомшак басып кына башлап китеп, тизләнә-тизләнә барып, хәтта сүнгән җаннарны да дәртләндереп.

Әйе, карап торганым бар... И егетләр, бии, биими димени, бик бии! Шуңа күрә дә минем эти шул ул! Шәһәргә кыз эзләп чыгып качкан мокыт Илфатның, минн әйтәм, атасы Сафсата абзый түгел инде!

Сафсата. Исем диген инде. Кем тапкандыр үзенә, әллә такканмы? Һәрхәлдә сорап караганым бар, монысын Сабир да белми, мәгәре күмхуҗ булхгалтерыбыз белән кассиры гына дөресен сөйләп бирмәсәләр, юк инде. Хәер, алары да аның фамилиясен генә белә торганнардыр. Чөнки, ни, шулай бер көн инещтән кассир апа менеп килә, мдарәгә су китерүче Әннисә түтигә нидер сөйли үзе, тетә генә:

— Сафсатаны әйтер идем, кассада өч меңе җыелгандыр инде, һаман туймый, гел акчалы, өстәмә эшләрдә генә йөри. Бар икән бәхете дә...— дип.

Ә Сафсата абзыйның шундый була алуының сәбәбе бар. Монысын мин дә чамалыйм. Кемнәр кемнәр, әмма идарә тирәсендә кайнашулар исә яхшы беләләр булыр. Бригадир яки күмхуҗ рәисе, яисә берәр түрәчек белән дус икәнсең, майлы калҗа гынна кимерерсең, кулың акчадан аерылмас. Тагын нәрсә кирәк? Ә-ә, иң зур таләп — Аллаһы тәгаләнең мондый бәндәсе халык алдында җимерек баш белән һәм бугазына җиткәнче чүмергән хәлендә күренергә тиеш түгел. Серләрне дә кабер кебек сакласын, кушкан эшне дә шауламмый-нитми генә башкара торсын. Ягъни, чын мәгънәсендә куштан булсын!

Кулында һәркөн диярлек майлы калҗасы булса да, Сафсата абзыйны барыбыз да үтә йомыкый һәм күңел төбенә чумган кеше дип белә идек. Бии дә, җырлый да белми. Күршесе Хәким абзыйның малае өйләгәндә туйга чакырганнар үзен. Бераз кызып алгачмы, әллә үртәлепме яки артык мактап ташлаулары күңеленә хуш килепме, ни сәбәпледер җырлап җибәргән бу. Аның тавышы гөберле бакадан гына чыгарга мөмкин булган бакыру булып ишетелеп, өстәл тирәсендәгеләр табыннарын ташлап качарга ашыкканнар. Туйның яме, кичәнең дәрте сүнгән. Әле дә ярый ничек үзеннән арынганнар, диген? Хәким абзый ахырдан:

— Нинди үче бар иде икән минем малайда?— дип аптырап, сорашып та йөргән. Әмма Саафсата абзый гафу сорап бер бер яртыны икесенә сындыргач кына күңеле вәсвәсәдән котылган.

— Мәңгелек дошман булачак идең шул,— дигән Хәким абзый, Сафсатаның аракысының төбенә җиткәндә.

Һаман да шулай булып калса, ничек итеп улын өйләндерер, туен итәр икән?..

Ә шулай да кич матур. Күңелләррне иләсләндерерлек матур һәм бик рәхәт һавалы, бик рәхәт!

Китапларда ничек яза торганнардыр инде "бер үбешүдән егет хәлсез калды" дип? Һични белми innнде бу язучылар да. Кая ди ул бер үбешүдән, сөйгән кешең бер генә күренеп китсә дә хәлдән таясың икән, анысы. Ә инде үбешә үк калсак, бөтенләй ятып үләчәкмен кебек иде...

Әнә, Хисмәтулла абзыйларның кече якларындагы сукыр тәрәзәсендә ут бар. Маһинур апа, и җан кисәгем, җәйнең кыска төне дип тә уйламастан, кышкылыкка оекбаш бәйләп утыра торгандыр инде, яисә орчыгы зыр-зыр әйләнеп, йон эрлидер? Гөнаһ шомлыгы, дигәндәй, койма башларына менеп, шуннан багып алсам да ярар, һичкем юк хәтерләп калырга, иптәшләрем дә тыкрык башында

ук бытыр-бытыр сөйләнеп калдылар. Алар килеп җиткәнче бер теләгем куш булачак, анысы. Батырлыгым җитсә?

Уйладым, койма башларрына менеп кунакладым. Сузылып карадым, мәтәлеп тә төштем. Таактасы черек булган икән, и Тау асты Хисмәтулла, Хисмәтулла...

Чалбарым төбеннән үк умырылып ертылган. Кадакка эләккән инде бу, шушы кадәр адәм хурлыгына калмасам да яраган булыр иде!

Барысы да бетте. Бу хәлемдә кыз тотам дип йөрү мөмкин хәл түгел хәзер. Җитмәсә кемнәрдер күреп тә торганнар, караңгылык эченнән хихылдаган тавышлары ишетелә. Мәчеләр мыраулаган кебек...

Чалбарымның ертыгын кулым белән каплап, яннарына киләм. Болар һаман да көләләр, хәерсезләр! Сүгенү ярамас инде, әллә ниткән урыс төсле.

Ә-ә, Бибинаҗия белән Сәфәр тупыл төбендә утыралар икән. Беткән боларның эшләре. Бер әллә нәрсә түгелдер, юк-бар гына сөйләшәләрдер әле. Бу яшьләреннән үк алай кылана башласалар, картайгач нәрсә эшләрләр икән инде?

Мин ул вакытларда вакчыл да, тупас та идем.

— Нидән көлеп утырган буласыз?.. Кытыгыгыз килдеме әллә?— дип үчекләндем, аларны кыен хәлгә куярга теләп.

— Килде шул әле менә!— дип чәпчеп куйды Бибинаҗия.— Бик килде. Камилне алма урларга кергәнендә эт тешләдеме әллә дип торабыз, кызганып. Космонавт итәләр үзеңне болай булгач!

Бу караңгыда каян барысын да күргәннәр диген. Әмма минем ертык чалбардан икәнлегемне сизенмәделәр.

“Итә торгач булгандыр, әнә!”— дип, берәр авыр сүз табып әйтәсем килде үзләренә. Әмма аның саен үртәлә бирдем.

— Нишләп угры кебек алма урлап йөрим әле,— дип акландым.

Алар сүз таба алмасалар да, тагын да мыскыллабрак көлделәр. Билләһи, җирнең тишеге аяк астымда хасил кылынып, шунда төшеп китсен дигәннәрдер инде. Ә мин эре генә китеп бардым, телемне әрәм итеп тормадым. Итагать белмәүче албастылар кебек көлешкәндәй итеп калган булдылар, чиләгенә күрә капкачы!..

Артымнан Сәфәрнең нидер кычкыруын ишетсәм дә колакка салмадым, әмма Бибинаҗиясенеке бәгырьгә ук булып килеп кадалды:

— Төшереп югалта күрмә, төпсез ыштан!

Эһ, анысын да күргәннәр икән!

Тыкрык башында калган дусларыма сиздермәс өчен тизрәк өйгә кайтып, чалбарымны алыштырып чыгарга кирәк.

Ә алар мине һичбер шикләнмичә каршы алдылар. Юк сәбәпне бар итеп дигәндәй, өйгә ашыктым. Чалбар төбемнең җайсызлавы сәбәпле аякларым да аксый һәм бутала иделәр.

Дусларым артта калдылар. Капка төбебезгә җитеп килә идем, караңгыда кемнеңдер төкерүен ишетеп туктадым.

— Кем бар анда?

Күкрәгемә җасыз итеп берәү китереп төртте.

— Тукта, кая болай ашыгасың?..

Бу тавыш минем өчен таныш түгел иде. Җитмәсә хәмерме, аракымы исе буылдырып авызыма-борыныма тулды, тамак төбенә утырды, укшып җибәрердәй булдым. Читкәрәк тартылдым.

— Тукта диләр сиңа!

— Туктап торам бит инде, абый!— дип үтендем, куркуым чамасыз иде.— Ни кирәк сиңа? Кем син, ә?

— Нәрсә, танымыйсыңмени, корчаңгы?— диде бу сәрхүш.— Ыштан төбеңә җибәрдеңме әллә? Танытыйммы соң?

Ул якалап ук алды. Тавышы таныш кешенекенә дә охшый башлады.

Кем соң әле бу? Кемдә бар иде әле мондый иләмсез, ямьсез тавыш?

— Нәрсә, таныдыңмы?

Сәрхүш кабаттан күкрәгемә төртеп алды. Аның тупаслыгы гына да котымны алырлык иде. Мин, хәлсезләнеп, аның йодрыклап якалаган кулына капчып кебек кенә ияреп йөрдем. Урынын белеп сукмаганда да сөякләремне сындырып бетерерлек гайрәте бар иде.

— Таныдыңмы дим?!.

Кичектерми җавап бирергә тиеш идем. Әйе дисәм дә, юк дип әйтсәм дә моның ахыры нәрсә белән бетәчәген күз алдыма китерә дә алмадым, акланасы иттем:

— Белмим, абый...

— Нишләп белмисең?

— Каян белим ди? Безнең авылда исерекләр ю-ю-юк!..

— Юк?.. Хахаха! Юк дисеңме? Ә мин кем булам соң алай булгач?

— Белмим, абый!..

— Белергә кирәк! Белдеримме, энекәш?

— Белдер,— дидем, калтыранып.

Артымнан безнең очка таба килгән иптәшләремнең сөйләшкән тавышлары ишетелде, нәрсә хакындадыр бәхәсләшә иделәр. Тартылып, сәрхүш йодрыгыннан ычкынмакчы идем, ул миңа шундый итеп китереп сукты, әйләнеп барып төштем. Ни дип кычкырганымны белмим, иптәшләрем ярдәмгә килеп өлгерделәр. Дүрт ягыннан урап, йодрыкларрны кизәнә башладык. Типкәләп, изеп кенә ташлыйсы идек, нәкъ кинолардагы каһарманнарча, әмма, кая ул, сәрхүш булса да, беләккә таза бәндә булып чыкты. Безне берәм-берәм төрле якка берике генә кизәнү белән очырды да:

— Хәсисләр, кул күтәргән булалар...– дип сүгенеп, мыгырдана-мыгырдана үз юлына олакты.

Җиһанша койма башына ук очып, билдән эленеп калган. Саматның авызборыны җимерелгән. Ә минем карарлыгым да калмаган. Тик Сабирга гына һични булмаган иде. Буйга басынкы булсалар да, беләккә таза кебекләр иде. Алай гына түгел икән ул, сөякләр ныгып җитмәсә, тәнгә көч керми.

Без, аксап-туксап, урам эскәмиясенә барып утырдык. Эскәмия димәктән, инде биш еллап ятучы, сөякләнеп беткән имән агачы иде ул. Урын барыбызга да җитте. Хәтта Җиһанша, билен тотып, сузылып ук ятты һәм зарланып алды:

— Үтерде бу!

Ә бераздан тагын да сорап куйды:

— Кем булды икән, ә?

Тәннәребез әрни иде. Җиһанша, соравын колакка элмәвебездән борчылып, бу юлысы атап миннән сорады:

— Камил, кем булды икән ул?

— Белмим,— дидем мин.— Танымыйча калдым.

— Нидән бәйләнешеп киттегез соң?

— Белмим инде... Кайтып бара идем, якалап алды да бәреп екты...

— Ну, кулы каты икән!— диде Сабир.— Үгез кадәр бар гәүдәсе дә...

— Ничек инде?— диде Җиһанша.— Сиңа берни дә булмады бит!

— Булмас менә, әллә кайларга очып төшкәнемне сизми дә калганмын.

— Качып барганыңда егылгансыңдыр әле?

— Мыскыллама, Җиһанша, син үзеңнең койма башына ничек итеп эленгәннеңне исеңә ал, ичмасам!

Әле яңа гына һәркайсыбызны тугылап-болгатып узган вакыйганы кабат хәтерләребез аша кичердек. Акылга сыймаслык эш булды бу!

— Әйдәгез, артыннан киттек!— дип Самат, үртәлүдәнме, кызып җилкенде.— Куып тотарбыз, кирәген бирербез!

Тәкъдимен кабул иттек, әмма мине көтеп торуларын үтендем. Киемнәремне алыштыррып чыкмый мөмкин түгел иде. Бу юлысы чалбарым гына түгел, күлмәгем дә ертырган.

— Ерак китмәгәндер әле... Сәрхүш бит ул. Эчәренә эзләнеп йөридер, яисә ике читән арасында адашкандыр...— дип сөйләшеп, көлешкәләп тә алган булдык. Хәзер безнең йөрәкләр батырайган, куркып торасы түгел идек.

Киемнәремне алыштырып чыктым. Аннары авылны кимендә өч айкарга туры килгәндер, әмма теге бәндәне таба гына алмыйбыз шул. Хәтта капка төпләре саен караштырып, анда утыручы кызлар-егетләрдән дә сораштырып йөрдек. Тыныч парларның күңеленә хәвеф уты салганбыздыр, анысы, гафу итсеннәр. Әмма безгә кирәкле теге мөртәтнең эзенә төшеп булмады, гүяки җир тишегенә кереп киткәндәй юкка чыкты.

— Авылдашлардан берседер әле,— диде Самат, акыл бирә башлап.— Әллә кайчан өенә кереп йоклагандыр? Без генә юләр сатып йөрибез, җиде төн уртасында...

— Таныган булыр идем әле. Авылдашың булсын да, танып калма инде! Юктыр, безнекеләргә охшамаган,— дип Саматка каршы төште Җиһанша.— Берәр җирдә качып ятса гына инде...

Сабир да, мин дә эндәшмәдек. Күңелләр сүрелергә өлгергән, гайрәтебез кыйгы шиңгән иде инде. Ачуларыбыз да басылды. Исең киткән икән, берәр аю авылга төшкәндер дә, уңлы-суллы тәпәләп киткәндер, вәссәлам.

Ә, аю дигәннән, кар кешесе түгел идеме икән ул?..

Шулай уйладым. Кызыклы фикер кебек тоелды, моны әйтеп иптәшләремне дә сөендерергә кирәк таптым:

— Кар кешесе булгандыр ул!— сүземнең куәте өчен урысчалатып та әйтеп куйдым:— Снежный человек!

Юларында югалган Сабир да айныгандай булды, беләгемнән тотты, зурданн кубып сөйли башлады:

— Шулдыр, башка түгелдер! Гәҗиттән мин дә кичә генә укыдым: таулар-урманнарда яши икән үзе. Алып кадәрле. Кешене кочакласа, сыта, ди...

Теле бер кубарылса, сүзен өзми инде ул безнең Сабир, тәмам шаштыррып бетерә. Исләрең-акылларың китеп, күзләрең маңгай сөягеңнән шартлап чыкса чыга, эчеңне тотып кына тор, юкса көлдереп үтерәчәк.

Җиһанша түзмәде, тәмам онытылып китеп һәм безгә дә дөньяларны оныттырып юк-бар мажараларрны сөйләгән Сабирны бүлдерде:

— Син әллә кайларга кереп киттең, ерып кына чыга алмыйсың барыбер. Нокта куй! Кая ди ул бездә андый урман, андый карлы таулар? Кавказ дип белдеңме әллә?

Сабир һаман да үз сүзендә калды:

— Кая, нишләп булмасын ди, әнә бит!..

Барыбыз да күрсәткән якка текәлдек. Анда һични күренми һәм шәйләнми иде. Бары тик хәтер күзләребез белән исебезгә төшердек: авылыбызның ул башында зур таулар, калын-калын урманнар безнең.

Караңгылык гүяки өстебезгә басып, җаныбызны өтәләде. Кичен трактор тәгәрмәче кадәрле булып чыккан айның нуры түгел, хәтта үзенең дә кайдалыгы беленми. Йолдызлар да юк. Бөтен җиһанны мөгаен калын-калын болытлар каплап алгандыр? Җитмәсә салкын җил исеп куйды. Гөнаһ шомлыгы, куркыныч аваз ишетелеп киткәндәй булды. Нидер уладымы, әллә кемдер кычкырдымы? Бер мәлдә койма ярыкларына кысылырдай хәлдә куырылып калдык.

— Әнә бит!— дип пышылдады Сабир. Әмма сөйләгән сүзенең җеп очын югалтканы сәбәплеме, әллә үзенең шигеннән үзе өректеме, бүтән бер генә сүз әйтмәде. Ул арада теге тавыш бәгырьләрне кисеп яңадан кабатланды. Әллә өркетү, әллә курку, әллә инде ярдәмгә чакыру авазы иде ул!

Беренче булып Җиһанша сикереп торды:

— Әйдәгез, егетләр, барып карыйк: ни икән ул!— диде дә тавыш килгән якка атлый башлады. Һәммәбез дә ирексездән аңа иярдек. Ялгыз калырга куркыта иде. Гайрәтебезне каплаган шик пәрәнҗәсен балалыктан калган кызыксыну тойгысы алыштырды. Дөресен әйтим, мин инде Тау асты Хисмәтулла абзыйның җиләктәй гүзәл кызы Маһинур апа хакында бер генә дә уйлап карамадым бу минутта. Ул онытылган иде. Әйе, кыз кайгысы димени, башка борчуларым да бар әле!

Су буена төшеп җиттек. Әрәмәлек арасыннан шәм яктысы кебек учак утын шәйләп, шул урынга таба бара башладык. Матур, тыныч урын. Монда кошлар да хәтта төннәр буе сайрыйлар иде. Бүген генә ни өчендер бөтен дөньялар үлгәндәй тоела. Бер-бер хәл хикмәтедер, ул бичара кошкайлар да теге кар кешеседннән курыкканнардыр әле!

Берничә кат ишетелеп алган тавыш тагын кабатланды. Бу юлысы якында гына иде. Әле курыктык, әле бер-беребезгә сыенып, ниндидер элмәк белән тартылган кебек шунда таба атладык. Чыннан да әрәмәлек уртасындагы калку тигез аланда сукыр гына учак янып газаплана иде.

Тагын да шуннда якынлаштык. Учак тирәсендә буш шешәләр, чүпрәкләрмекиемнәрме, гәҗит-кәгазьдәр һәм ризык калдыклары аунап ята иде. Бәйрәм иткәннәр булырга кирәк!

Тавыш тагын кабатланды. Кешесе дә күренә башлады. Карагыз әле, Сәфәр бит бу!

— Сәфәр, синмени әле бу? Гүләп йөрисең...— дип әйтергә дә өлгердем.

Без туктап калдык. Ялгыштым. Бу кеше Сәфәр түгел, ә безне кыйнап качкан теге сәрхүш иде. Исе, чалымнары нәкъ шуныкы. Әйе, үзе!

Әмма ни булгандыр, бу юлысы ул артына чигенә башлады һәм, урысчалап:

— Братцы, не убивайте меня!— дип кычкыра-кычкыра, агачлар арасына ташланды.

Артыннан куа чыктык. Аякларым нindидер йомшак әйбергә абнып киттеләр һәм маңгаем белән агач кәүсәсенә бәрелдем, тәгәрәдем.

Иптәшләрем теге сәрхүш артыннан калышмадылар. Берсенең йөгерә-чаба су ярып чыкканы ишетелде. Якында гына басма бар, югыйсә. Безнекеләрдән булмас бу!

Күтәрелеп бастым. Бер кулым белән башымны тоттым. Аннарры кабат җиргә иелеп, икенче кулым белән капшап-капшап карадым, мине абндырган йомшак әйберне барларга тырыштым.

Кулым нindидер җылы нәрсәгә тиеп китте. Куркынып кинәт алдым. Шул хәлемдә беразга таш кебек катып калдым.

— Су, су?— дигән ыңгырашу тавышы ишетелде.

Кем булырга мөмкин бу? Таныш, бик таныш тавыш иде ул!

Тәнемә җан кайтты. Котым урынына утырды. Бу юлысы ике кулымны да алга таба суздым. Шәрә кеше тәненә тигәч, кабат куркынып куырылдым.

— Су, су?— дип үтенде ул гәүдә, аңына кайта башлап.

Ничек шулай килеп чыккандыр, белмим, мөгаен ул кешенең кем булуын танып алуым йөрәгемә батырлык биргәндер, учак янында аунаган буш шешәләрнең берсен алдым да инешкә йөгердем. Кабалануымнан онытылып китеп, суга барып төштем. Шешәне тутыра башладым. Ул акрын, бик акрын тулды. Су сорап ялварган тавыш колактан китмәде. Минем куркуны алыштырганн кабалану йөрәккә тынгылык бирми иде. Маһинур апа бит ул! Маһинур апа! Бәгырем киселдә. Шул ук мизгелдә йөрәгем урталай яррылды. Ничек монда болай ята ул? Әллә соң чыннан да кар кешесе идеме теге шыксыз сәрхүш? Татарча да түгел, урысча гына сөйләшә, җитмәсә!

Маһинур апага йөгереп су китердем. Сакланып кына башына, яңакларына койдым. Иреннәренә тидердем. Әмма шешәне артыграк күтәргәнмен, ахрысы, тончыкты. Кулы белән мине этәрде.

— Илфат, кирәкми, кирәкми! Тимә миңа?!.— дип туктаусыз кабатлый, елый башлады.

Тавышында өркү дә, оят та, әрнү һәм саташу да бар иде.

Мин, куырылып, артка чигенндем. Ул чыннан да мин гашыйк булган, мин озатырга тиеш булган, минем киләчәгем булган Маһинур апа иде...

Әрнеп-әрнеп ыңгырашты, кыймшанды һәм торырга тырышты.

Бу вакытта инде төн узган, сукыр таң вакытының әңгере ачылган чак иде. Әйләнә-тирәне юка гына томан сарган кебек. Ә Маһинур апа ана тума диярлек шәрә...

Урынымда тораташ хәлемдә кала бирдем. Мондый хәлне күргән мени мин?

Мондый чакта нәрсә эшләргә беләммени?

Маһинур апа киемнәрен җыйды. Өстенә тарткалады һәм әрәмәләр арасына кереп югалды. Шыңшыган тавышын салкын томан йотты...

Поездыбыз иртәнге тын һавада акрын гына шуышып бара да бара.

Мин уянып киттем. Вагон тәррәзәсе артында — куе яктылык. Иртәнге чык юындырганнмы, ялтыраган миләш һәм балан тәлгәшләре алсуланып калалар. Инде кызарырга да җитешкәннәр. Иртәрәк өлгереп киләләр, килергә дип кыш ашыга торгандыр, мөгаен.

Яткан җиремнән әйләнә-тирәмә карап алдым. Кичәге әңгәмәдәшем, үзен тимер коючы дип таныштырган, калын күзлек кигән, яше утыз җиделәр чамасы инженер иптәш Сабитов әфәнде башын өстәлгә кырын салган хәлендә йоклый иде. Исемә төшердем: аның Чаллыга кайтышы. Ялдан. Авылларыннан. Димәк, Маһинурын күреп, күңеле кузгалып килгән инде моның!

Поезд Яр Чаллы вокзалына туктады. Унбиш минутлап торыр кебек.

— Сабитов иптәш, килеп җиттегез,— дидем мин, аны уятып.— Сезгә төшәсе!

Ул тыныч кына башын күтәрде. Вагон тәрәзәсеннән урам якка карады, ашыккан һәм йөгерешкән халыкка күз йөртеп алды.

— Чаллымыни?— диде.

— Әйе, Чаллы...

— Килеп җиттек,— дип портфеленә үрелде.— Сезгә Әлмәткә кадәр, әйеме?

— Әйе, ә нигә?

Ник сораганымны үзем дә аңламый калдым.

— Ачуланма инде,— дип үзенекен сөйли бирде ул, өстәлгә күрсәтеп,— җыештырып калдыра алмадым боларны... Әллә ничек, яхшы түгел....

Өстәлдәге аракы шешәсе яртылаш кына бушаган иде.

— Үзегез белән алыгыз,— дидем, аның нәрсә хакында әйткәнен чамалап.

— Ни дип, бәлки калдырыйм?

Ул миңа сынап кына карап куйды.

— Рәхмәт,— дидем һәм шешәсен үзенә суздым,— алыгыз! Бәлки кирәге чыгар... Ә мин — эчмим, түгеп исраф итү дә килешмәс...

— Ярый, алайса,— диде ул һәм аны кәгазь бөтереп бөкеләп, портфеленә салды.— Артык сүз сөйләшкән булсак, гафу ит!

Инде чыгып китәргә тиеш булса да кузгалмыйчарак торды. Нидер әйтәсе бар иде кебек. Мин дә сүз эндәшмим. Нәрсәдер әйтергә тиеш сыман. Әмма бераздан ул, һичбер сүз кузгатмыйча, чыгу ягына атлады. Бераз баргач, ишеккә җитәрәк борылды һәм:

— Ярый, хушыгыз,— диде. Һәм баягы сүзләрен кабатлады: — Артык сүз сөйләшкән булсак, гафу ит!

Ишеккә барып җиттек.

— Бернинди дә артык сүз булмады,— дидем мин, аны тынычландырырга тырышып.— Бары тик...

— Әйе шул, бары тик...— диде ул, вагоннан чыга-чыга, үзенә үпкәләгән сыман итеп әйтеп.

Мин аны озата килә идем. Безгә каршы яңа пассажирлар күтәрелә, төртенәләр-төртеләләр, җитмәсә, зәһәр теллеләнеп:

— Кеше кергәндә комачаулап йөрмәсәләр... Сыерлар... Дуңгызлар... Нишлисең, йокы чүлмәге?— дип теләгәннәрен әйтеп бетерделәр.

Бәгырем киселде. Сүзләнер җиремнән сөйләшмәс булдым. Нигә озаткан булып йөрим инде мин, кешегә комачаулап?

Тукталып калдым. Сабитов төшеп китте. Вагонга күтәрелгән яңа пассажирлар шау-гөр килеп урын бүлешә башладылар. Тамбур бушап калды. Шунда гына чыгып бастым. Поезд кузгалырга ашыкмый иде әле. Урам якка карадым. Сабитов шунда, миңа кул селтәп калырга, озатам дип көтеп тора икән.

— Ярый, сау булыгыз,— диде ул. Әмма борылып китәргә ашыкмады. Бераздан соң әйтеп куйды: — Нидер сорамакчы идегезме?..

Поездның кузгаласын белдереп хәбәр биргән вокзал радиосы берара вакыт безне саңгырайтып тотты. Ә нигә сорамаска дип уйларга өлгердем.

— Маһинур апа белән ни булды? Авылда күрештегезме соң?

Гүяки шушы соравымны көткән, Сабитов ашыгып җавап та бирде:

— Ул минем хатыным хәзер... Әнә, килә!..— дип елмаеп, вагоннар кузгалып киткән якка төртеп күрсәтте.

Мин шунда таба үрелеп карадым. Ике баласын җитәкләгән, курчак кебек бик чибәр, кара чәчле, нечкә билле бер ханым Сабитовка йөгереп килеп, кочагына ташланды. Ул арада кечерәк малай белән кыз да әтиләренә ябыштылар.

Вокзалдан ераклашканда мин аларның һәммәсе бергә җитәкләшкән хәлләрендә китеп барганнарын гына хәтерләп калырга өлгердем. Дөньялыкка кояш тулган, мин аның нурларында иркәләнә идем.

...Бу очраклы танышымның кичен сөйләгәннәре озак вакытлар, мине дулкынландырып, хәтеремдә сакланнды. Күңелемне һаман-һаман кузгатып, хыялымны нindider ят дөньяга алып керә, ә колакта мәхәббәт кыңгыравы чыңлый кебек иде.

Алар ничекләр кавыштылар икән? Ни кызганыч, аларын ук сорап калмаганмын. Кайвакытта үземнән уйлап чыгарып, шулай булгандыр әле диясем килә, әмма ул уйдырманы күңелем кабул итми. Бәхетле, бик бәхетле син, Сабитов! Нигә бу сүзләрне аңа ул чагында әйтмәдем икән? Сөйгәнең, яраткан кешең белән кавышу — үзе зур бәхет, дөнья бәясенә торырлык хәл!

Кешеләрнең дә төрлесе бар, ә һәммәсе дә сәгадәт кояшына кул суза. Әмма сабыр итә алмаучылар ялгышалар, ялган ләззәттә адашалар. Хыянәт аша килгән рәхәтлек ахырда гомерлек җәза, бәхетсезлек бирә.

Әмма минем сүзем ул хакта түгел иде...

*1993.*

## ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ЭШЕ

*Хикәя*

Иртә таңнан торып, чык суларын эчеп, чәчәктән чәчәккә куна-куна уйнап, биеп, җырлап Күбәләк очкан-очкан да хәл алырга тукталган. Шунда тырыша-тырыша бал җыеп йөргән Кортны күргән, гаҗәпсенеп:

— И күршем, карендәшем, син көне буе иртә таңнан эштә, туктап та тора белмисең. Бераз ял итеп ал,— дигән, күңеленең һәм уеның яхшылыкта булуын яшермичә.— Синең өчен үзем бөтенесен дә башкарып куярмын!

Бал Корты эшеннән туктаган, аның белән сәламләшкән дә, Күбәләкнең килеш-килбәтенә, матурлыгына сокланып карап торган һәм нәзек, кечкенә кулларына игътибар итеп, бер дә ышанычлы түгел икәнлеген аңлап алган һәм:

— И гүзәл карендәшем, әгәр дә син минем өчен бал җыйсаң, мин синең өчен җырлап-биеп йөрсәм, ул вакытта дөньяның яме, болыннарның матурлыгы, яшәешебезнең тәме бетәр иде. Әйдә, һәркайсыбыз үзе белгән эшне җиренә җиткереп башкарсын, үз гамәле белән гомер сөрсен. Син дә, мин дә, башкалар да шуннан бәхетле булырлар,— дип җавап биргән.

Бал Кортының шушы акыллы сүзләре Күбәләкне хәйран калдырган. Берсен-берсенә карап, аңлашып елмаешканнар. Саубуллашып аерылышкач, һәркайсы үз эшләре белән очып киткәннәр.

Шулай шул, җир йөзендә һәр җан иясе үз гамәле белән яши. Әгәр дә берәүнең эшен икенче кем башкара икән, ул вакытта тормышлар да буталып бетәр иде. Ә бәлки мин ялгышамдыр?

*08.05.94.*

## ЗӘҢГӘР КҮКТӘ АК БОЛЫТ

*Хикәя*

Зәңгәр күктә ак болыт йөзә иде. Аңа утырып очкан яңгыр тамчылары әле моңланып җырладылар, әле шатланып сикерештеләр-биештеләр, әле әкиятләр сөйләштеләр. Көн матур һәм аяз иде. Әмма әллә кайдан гына авыр кара болытлар килеп чыктылар. Утлы ташларын уңга-сулга ыргыта башладылар. Ак болытка утырып йөзгән яңгыр тамчылары куркышып калдылар.

Менә бер утлы шар аларның иле булган болытына килеп тиде. Ул да түгел, кара болыт авызын дәү итеп ачты һәм ак болытны йотты. Уңнан-сулдан төртте, кимсетте, ут ташлары — яшене белән орды. Ак болытта утырган яңгыр тамчылары куркышып җиргә коелдылар, үзләренең азат булуларына сөенештеләр. Аларның һәммәсе диярлек чәчәк бакчасына туры килде. Арадан берсе — ак болытның сөекле вак тамчысы, чәчәк таҗына төшеп утырды. Ул арада кич булды. Кара болыт күк йөзендә һаман да яшен ташларын ыргытынып йөренә бирде. Вак тамчы, чәчәк таҗына кереп, шунда яшеренеп ятты һәм йоклап китте. Монда аңа тагын да рәхәтрәк иде.

Күзләрен кояш нурлары иркәләүдән уянып китсә, ни күрсен, хәвеф куркынычы үтеп киткән, күк йөзе чалт аяз! Тик анда вак тамчының иле — ак болыты гына юк икән. Нишләсен, елап җибәргән. Әмма аның елап утырганын кояш күреп алган да көлдерә башлаган. Тамчы бөртеге көлгән-көлгән дә күккә очып киткән.

Караса, аның янына үзе кебек үк яңгыр тамчылары җыелыша башлаганнар. Ул арада кайдандыр тагын ак болыт пәйда булган һәм аларның һәммәсен дә үзенә алып, очыртып алып киткән. Бу бәхетләренә сөенешеп, тамчылар кулга-кул тотынышып җырлаганнар, биегәннәр, әкиятләр сөйләшкәннәр. Аларның шатлыгын күреп, җир йөзе тагын да матуррак, ямьлерәк булып киткән.

*Май, 1994.*

## КЕЧКЕНӘ ЧЫПЧЫК МАЛАЕ

*Хикәя*

Көзләр җитте. Көннәр туңдыра башладылар. Язлыкта күчеп килгән кошлар, төркем-төркем булып, җылы якларга киттеләр. Бар табигать тынып, кояш сүнеп калгандай тоелды. Менә соңгы төркем казлар-үрдәкләр дә, үксез калган дөньяга сәламнәрен озатып, еракларга таба очып киттеләр. Аларның хушлашу авазларын ишетеп Чыпчык Малае да һавага күтәрелде, берникадәр араны араталарыннан талпынып-җилкенеп очты һәм, кайтып, әнисенә:

— Чык-чирык, чык-чирык, нигә без дә алар белән китмибез?— дип сорады.— Нигә алар үзләре генә китәләр. Нигә туган-үскән җирләрен ташлыйлар? Бер-бер яманлык көтеләме әллә?

Аның тавышы борчулы иде.

— Улым, тынычлан,— дип, аңа яратып эндәште әнкәсе.— Алар һәр елны да шулай китәләр. Ә без шушында калабыз. Туган-үскән җирләре монда булса да, алар салкын кыштан куркалар. Яхшыдан-яхшырак ватан эзләп йөриләр. Яз җитүгә, алар сагынышып кайткан булалар тагын. Мәңгегә кире китмәскә, монда калырга дип сүзләр куешканнарын, шулай сөйләшенгәннәрен ишеткәнем бар. Әмма көз җитүгә, әйткән сүзләрен оныталар. Тагын китәләр. Ватанын, туган-үскән җирен ташлаганнарның беркайчан да күңеле тынычлык таба алмый инде, анысы. Зәмһәрир салкын кышларда да ватаныбызда яшибез. Шуңа да безнең күңелләребез тыныч, бәхетебез камил! Бер дә курыкма, ак кышның матурлыгын күрүчеләр ямьле җәйнең рәхәтен яхшырак тоялар.

Әнисенең сүзләреннән соң Чыпчык Малаеның борчылуга бирелгән йөзе кабат балкып китте, ап-ак кышның тизрәк килеп җитүен теләде. Әмма иртәрәк иде әлегә. Юкка гынамы: “Ватанга мәхәббәт бала күңеленә ана сөте белән керә, ана сүзләре белән үстерелә, тойгы булып чәчәк ата, мәңгелек тынычлык һәм бәхет бирә!”— дип әйтәләр? Бу сүзләр хакыйкать булмый калмаслар!

*1994.*

## ЧЫПЧЫК МАЛАЕ ҺӘМ МАЧЫ

*Хикәя*

Капчык-капчык иген ташыдылар. Арада берсе тишек булып, ишек алдына

бодай сибелеп калды. Бөртекләрне чүпләргә дип әүвәле аларга йорт кошлары ташландылар. Әмма алар гына җыеп бетерерлек түгел иде. Тамаклары туйды. Җырлашып җибәрделәр һәм уңга-сулга таралыштылар, киерелеп яттылар. Кайсылары моннан, кайсылары тегеннән кытаклады. Кәефләре шәп иде. Миләш ботагында утырган Чыпчык Малае элек аларга игътибар итмәгән иде, гәрәбәдәй эре бодай бөртекләрен күргәч, тәмам сабыры бетте. Ботактан-ботакка сикеренде. Кайда йөри икән инде ул әнкәсе? Нигә монда гына утырып торырга кушты икән? Сүзен тыңламасаң да яхшы түгел! Әгәр дә бу бөртекләрне чүпләп алса, нәрсә була?

Чыпчык Малае тиз генә очып төште, тәкатьсездән ризык чүпләргә тотынуы булды, аны кемдер эләктереп тә алды.

— Әни-и!..— дип кычкырды Чыпчык Малае.

Тик соң иде инде. Мур кыргыры Мачы тырнагына капкан иде ул. Әйтмәгәннәр, өйрәтмәгәннәр идеме ишек алдына ялгызы төшмәскә, әнә шул кара афәткә эләгәсең, харап буласың дип? Бик әйткәннәр, кат-кат кисәткәннәр иде!

— Аһ-ваһ!.. Ха-ха-ха!... Хәзер мин сине ашыйм!— диде кара Мачы.

— Ярар, аша инде алайса,— дип килеште Чыпчык Малае,— тик белеп тор: мин — сихерле! Әүвәле яфрак идем, мине корт ашады, мин шул кортка әверелдем, әмма мине бер чыпчык малае кабып йотты. Инде мин шул Чыпчык Малаена әйләндем. Хәзер син мине ашыйсың. Мин шуннан сиңа әверeләм дә үзеңне кабып йотам!— диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, кара Мачының болай да шар кебек күзләре трактор тәгәрмәче кадәрле булдылар һәм ул, Чыпчык Малаен калдырып, ярым ачык ишектән өйгә кереп шылды.

— Менә шулай!— диде дә Чыпчык малае, рәхәтләнеп, һичбер хәвефкә бирелмичә туйганчы бодай бөртекләрен чүпләде. Мачы исә ишек алдында кабат күренмәде.

*1994.*

## МИН ҮЗЕМ БЕЛӘМ

*Хикәя*

Әгәр дә аның белән очрашмаган булсам, мин үземне әле дә бәхетле кешегә санап йөргән булыр идем, мөгаен. Ә сез алай түгел дисезме? Сөйләп бирергә кирәктер бәлки? Ышану һәркемнең үз эше, ә минем исә бу катлаулы мәсьәләне аңлатып бирүне үз өстемә алып карыйсым килә, бәлки бүтәннәр өчен әһәмияте булыр.

Кыскасы, караңгы кичәләрнең берсендә дустым килеп керде дә, сере бер кеше шикелле күзләремә карап, әмма бераз кыенсынып кына әйтә куйды:

— Синең вакытың юк идеме?

— Юк иде,— мин әйтәм.

Әмма ниндидер бер шик күңел төбен борчырга, җанны бимазаларга тотынды: кешеләр бер-берләренә юкка гына сер хакында сүз кузгатмыйлардыр бит

инде?

— Алай икән!

Аңа каршы җавабымда шулай шул дияргә кодрәтемнән килмәгәнгә, бераз вакыт аптырабрак тордым. Аның миңа текәлеп карап торуыннан бер нәрсәне аңлап алдым: Ул тиз генә китәсе түгел!

— Ярар!

Без карашып алдык та кузгалдык, авыр адымнарым мине фатирымнан түбән таба, беренче катка өстери иделәр инде. Ә минем йокламакчы идем. Бу теләгемнең әле дә беткәне юк. Үтер дә сал гына... Арылган. Кеше кайгысымыни, монда көне-төне чабып, бер ял күргән җан түгелмен, җитмәсә бу ахмак бимазалап йөри...

Күрше шул, кая барасың. Иң алдан аларга йөгерәчәкмен үзем дә... Аллаһы сакласын, кайгы килә күрмәсен!

Урамда яз вакыты иде. Күршем тәмәке кабызып җибәрде. Сасы исе бугазларга ябышты. Читтәнрәк атларга мәҗбүр булдым. Сүз башларга тиеш иде дә, нәрсәгәдер ул мәсьәләдә ашыкмый. Ә мин йолдызлар санамакчымын: бер, ике... Егермеләп була түгелме?

— Ник сөйләмисең?

— Нәрсәне?

“Эшең беткәнме әллә синең, юк белән борчымасаң?”— диеп булмый шул инде. Эһ, бимазалап йөрмәсә иде!

— Ярар, мин киттем!

— Тукта!— диде ул, китә башлаганымда әмер биреп.

— Сине монда саклап торыйммы?

Күршем караңгыда күзләремне эзләде булырга кирәк, иелеп-иелеп йөземә каранып маташты, әмма ирешә генә алмады.

— Ну-у-у!

Бу мөгрәве миңа бернәрсә дә аңлатмый иде. Шуннан? Дөньялар икегә ярылса да исе китмәс кеше шул ул. Тәмам җитлеккән. Туйганчы эчкән. Мине юләргә санап, үзенә ияртеп йөртмәкче. Һай хәйләкәр дә инде кешеләр!

Йомышының нәрсәдә икәнлеген тыңларга да теләмәстән кайтып кына китәргә уйладым. Нәрсә, мине характерсыз, пешмәгән кешегә саный әллә?

— Йә ярар, мин киттем...

— Тукта!

Ул миңа әмер бирергә кем соң әле? “Күрше хакы — Алла хакы!”— дигәч тә, ул миңа Алла түгел лә!

— Шуннан?

Бу мөгамәләдән бер генә дә файдалы фикер азыгы туймаячак иде. Нишлисең инде, ул да адәм баласы, кимсетәсе дә килми үзен.

— Эреләндең әле...

Монысы миңа биргән “югары” бәясе иде. Белә, чукынган, кайсы яктан китереп чүкергә, яньчеп кенә алды. Кемгә әйтсә дә, аны җиңел генә аягыннан егарга мөмкин булган сүзләр бу!

Нәрсә диләр икән мондый вакытта? Шайтанына олактыралармы? Җавап таба алмаган һәм бәясен кайтарып йөзенә чәпәргә көче җитмәгән гайрәтме, әллә

күрмешемнән җыйган сүз кисәкләреме акыл казанын кайнарландырып, инде дә капкачын күтәрә-күтәрә парларын ата башларга, ачуым бәреп чыгарга тиеш иде. Тыела калдым!

— Шуннан?..

Телемә килгән ошбу сүзләремнән соң, колакларыма аның җавабы ишетелергә тиеш иде дә, әмма эшләр алай ук барып чыкмады.

— Нәрсә шуннан?— дип сорады ул.

Миңа да аның болай юләр сатуы кызык булып китте. Шунлыктан:

— Белмим!— дип җавап бирдем.

— Белмәгәч, ник маташтырасың?— дип ачулана башлады ул.

Үтерде, тереләй суйды. Мин әле аны сәрхушка санаган идем, ә ул китте акыл өйрәтеп, китте... Гыйлем чишмәсе диярсең, һич тукталыры юк!

Әүвәле артка чигенеп, аннан соң борылып, ашыга-ашыга китә башлагач:

— Кая качасың?— дип җикерде.

— Йокларга!— дидем мин, коты алынган ат кебек җан фәрманга ашыгып.

— Һе... Бар-бар!.. Йоклый бир! Шундый кичәне ташлап!..

Һаваларның чыннан да чәчәклләрдән таралган хуш исләр белән тулган чагы иде. Ни дисәң дә, яз — яз инде ул! Сандугачлар да нәкъ май аеның ахырын тәбрикләп җыр сузалар. Әнә кайдадыр, кемнәрдер боза-боза гына булса да бер көйне әле башлап, әле ташлап интектерә-интектерә маташтыралар...

— Шушындый матур кичәне калдырып диген әле син! Кем йоклый ала икән? Һай егетләр...

Күршемнең колак артымнан ияреп килгән ул сүзләре җанымны кыйный иде. Ә бирешәсем юк инде, ныклык күрсәтәм:

— Мин күптән ир кисәге бит инде!

— Ха!

Ул, җавап бирергә тукталуымнан файдаланып, куып тотарга өлгергән иде инде.

Миннән зәһәрләнеп көлә үк башлады. Монысын ук көтмәгән идем. Кем дип белә ул үзен, мине кемгә саный? Юньсез!

Төкердем үзенә, дигәндәй, бу юлы, һичбер сүз әйтеп тормастан, кайтып киттем. Ул шунда сөйләнеп калды. Җылы урыныма аугач, бик озак йоклый алмыйча яттым. Аның миңа нәрсәдер әйтәсе булгандыр инде?..

Икенче көнне барысы да беленде. Юкка гына мине эзләп кермәгән икән ул. Күк капусы ачылган булган бу төндә, белми дә, күрми дә калганмын. Нишлисең, насыйп булмагандыр. Айның да, кояшның да тотылуларына шаһитлык иттем. Менә ничә еллар йокым качкан хәлемдә төннәрен урамда йөрим, күкләрне күзлим, ачылмыйлар гына шул капкалары, җәннәтләрен күреп калыр идем...

Һи, үзем беләм, имеш! Белеп бетерерсең барсын да, көтеп тор! Үзеңнең кемлегеңне генә белүе җиңел ул. Теләсәң, күршеңнән сора, әйтеп бирер.

## ТИМЕР ТӨРӘННӘР

*Повесть*

## 1. Саумы, авылым!

Ике елдан соң Фазыл туган ягына кайтты.

Көн шундый матур, шундый йомшак иде, хәтта зәңгәр күк йөзе дә ак болытларны йотып бетергән, ә кояш җирдәге яшь уҗымнар белән уйный, гүя аңа башка бер әйбер дә кирәкми, менә шулай, җил белән бергә аларны сыйпап үтә дә, тургай җыры булып күккә күтәрелә, сайрый-сайрый дөньяның матурлыгын, киңлеген, сөйгән җиренә мәдхиясен җырлый. Шулаймы, Фазыл?!

Әйе!.. Күңелендә кузгалу мизгелен көтеп яткан барлык изге хисләре уянып егетне алга әйди, алга, әнә анда, кырлар аша үткәч, сөзәк ярга төшә-менә боргаланып, авыл эченә кергән тузанлы юлга ашыктыра, әйдә, син дә җырла дигәндәй, колагына “Җидегән чишмә” көен, чылтырап аккан чуер ташлы инеш белән бергә көйли башлый... “Җидегән чишмә!..” Әйе, Фазылга таныш, бик таныш изге көй бу! Чөнки бу җыр нәкъ аның турында, менә шушы кырлары, атлам саен бәреп чыккан кечкенә чишмәләр белән тулы сөйгән иле турында. Җырла, Фазыл, җырла!

Егет кинәт туктады да су буена йөгерә-йөгерә төшеп китте. Юк, күпме генә Туган авылын күрергә ашыкмасын, менә шушы урынны, балачакта казынган комлыкны, балык тота-тота көннәренең дә үткәнен сизми калган уентыкны, беренче яшьлек хисләрен чәчәкләр белән бергә кочагында алып төшкән, сердәше булган җирне ул күрми, аның белән исәнләшми китә аламы соң? Юк! Шунсыз аңа хәтта авыл капкасы да ябык булыр иде...

Солдат инеш ярындагы “балыкчы ташлары”на басып иелде, битенә йомшак су белән сыпырып алды. Ике ел элек кенә монда сабый килеш балык чирттереп торган иде ул, ике ел элек кенә менә шушында туган яклары белән саубуллашкан иде, инде кайтты, мыегын кырган Фазыл булып кайтты...

Таныйсыңмы, инеш?!. Ике ел бит инде, таныйсыңмы?..

Инеш дулкыннары, бөгелә-сыгыла килеп, Фазыл басып торган ташларны коча иде. Танымый димени, бу — аның инеше, ул шушында, диңгез түгел, инеш суында коенып буй җиткән егет ич. Һай элеккеге чакларда... Кайчан гына иде шул әле? Әйе-әйе, бик яхшы хәтерендә. Кайчан гына? Кичә?!. Юк, бая гына!.. Юк инде, малайлыкта!

Әнә комлыкның теге башында яткан ташлар бармы? Әйе-әйе, шул ярга сыланып үсеп утырган таллар һәм мәһабәт киң кәүсәләренә мүк җыя башлаган тупыллар ягында! Ә иң читтәге, ботаклары сыдырылып төшкән агачка олы консерва савыты элеп куелган иде. Бала-чагалар, кайсысы төзлекне, кайсылары көчләрен сынау өчен шул калайга аталар идеме? Шулай ич, Фазыл?!. Син үзең аны элеп куйдың түгелме? Тик каргалар, үзеңне оя бозучы дип белеп, сиңа ташланырга әзерләнә башлагач кына төштең. Аннан соң ул калай даң да доң килеп торды. Каргалар тынычлыкларын югалтты, кара болыт булып күтәрелделәр, оча башладылар...

Фазыл шул якка таба китте. Кулына эләккән беренче ташны атты. Болай

гына, бала вакытын сагынып кына аткан иде, сискәнеп китте. Тупылдагы күгәреп беткән калай савыт һаман эленеп тора иде. Атканы нәкъ шунда барып тиде. Фазыл таш чүпли башлады. Шул калай савытка төбәп тагын да берничәне ыргытты. Аннан, шатланып, калай тавышына колак салды. Карга көтүе, ояларыннан кубып, оча-кычкыра башлады.

— Һе-һе-һей-й!..

Егет елмайды, аннан соң:

— Шулай шул, мин кайттым, саулыкмы?!.— дип әйтеп куйды.

* * *

Әйе, элек ничек рәхәт булган ул! Барысы да алдан билгеле: балалар бакчасы, аннан соң башлангыч мәктәп, аннары сигезьеллык, урта... Уйламыйча, аптырамыйча гына йөрисең. Ә менә үзеңә тормыш юлыңны сайларга калгач, айһай, авыр икән! Урта мәктәпне тәмамлагансың, аттестаты — кулыңда, тот та бер якка юл ал. Юк шул, олы юлга уйламыйча гына чыгып китеп булмый.

Гөлшат, фикерләренә чуалып, Айгөлләрдән кайтып килә иде. Аларның авыллары күрше генә булганга, шушындый матур көннәрдә өч-дүрт чакрымны велосипед белән үтү яшьләргә бер ни дә тормый. Аннары, аларда, Айгөлләрдә ничектер рәхәт, эч серләреңне бушатасың, хыялга бирелеп була, музыка да бар. Һай, менә шулай гына гомергә бергә булырга икән ул!..

Шулвакыт бер-бер артлы юл өстенә килеп төшкән ташлардан кыз сискәнеп, бераз шүрли үк калды. Нинди юньсезе шаяра тагын дип уйларга да өлгермәде, велосипедының алгы тәгәрмәченә дә таш килеп тиде. Аның артыннан ук агачлар ягыннан ниндидер калай яңгырап куйды, карга көтүе кар-кар каркылдап күтәрелде.

— Ну малай актыгы, кошлар куркытырга, оя туздырырга өйрәтәм мин сине,— дип, Гөлшат тупыллар янына ашыкты.

Әмма андагы ул кеше солдат иде...

Агачлар арасыннан килеп чыккан кызны күргәч, Фазылның таш тоткан кулы селтәнгән вакытында туктап калды. Сәерсенеп караган чибәрдән үзенең сабыйлыгы, малайлыгы өчен оялып читкә борылды да, ташын инешнең тыныч аккан җиренә томырды.

Егет, бераздан чемоданын тотып, тупыллар ягына кырын күз салды, ә кыз анда юк иде инде...

Күңелендә ташыган балачак хисләренә башка берәүнең шаһит булуы Фазылның кәефен бозды. Шуңадыр әле генә солдатның күңелендә моң булып агылган сагыну хисләре көтелмәгәндә тутыгып, хәзер күңеле гадәти хәленә кайтырга өлгергән иде. Ул эре адымнар белән авылларына китте. Бар теләге — кайтып җитәргә, туганнарны сөендерергә!..

— Саумы, авылым, саумы!

Болар нинди шатлыклы сәгадәтлек сүзләре!..

## 2. Саумы, әнкәй!

Урам тып-тын, гүя төне буе яшьләрне сукмакларында йөретеп арыган да,

хәзер кичкә кадәр йоклый. Тик ара-тирә генә капка асларыннан яисә казлар, яки канат үстерә башлаган чебиләр йөгерешеп чыгалар, йә булмаса, болынга бәйләнгән бозаулар, арканнарын өзеп, чабышып йөри. Авыл урамында ник бер кеше күренсен? Югыйсә бәйрәм алды бит! Соңгы хатта язуларына караганда, иртәгә сабан туе була түгелме соң? Мондый бәйрәм алдыннан урамнарны да тигезләштергәләп куя торганнар иде. Быел нигәдер кагылмаганнар. Урамда туздырылган чокырлы урыннар да күбәйгән...

Солдатның күзләре өр-яңа нарат өйләрне дә санап үтте...

Авыл ничектер үзгәргән кебек тоелды. Җимереклекләр бөтенләй дә калмаган (хәер, бар идеме соң алар, карчык-корчык кешеләрне санга алмаганда?), хәзер йорт-куралар матураеп, тазарып, яктырып киткән. Тәрәзәләр дә гөлләр үстерә икән.

Капкаларыннан Фазыл ишек алдына үтте. Ә анда тагын да тынычрак иде. Нәрсә бу? Солдат кайта бит, солдат! Кая киттегез сез барыгыз да?..

Егет ашыга-ашыга өйләренә керде. Ишектән күреп чыккан кеше булса, аны күтәреп алырга әзер иде ул. Тик Фазылны берәү дә каршы алмады, өйдә дә беркем юк, гүя һәммәсен җир йоткан диярсең! Әллә бөтенесе дә сабантуйдамы? Алай дисәң, бар җирләр шар ачык, өйдә дә бәйрәмчә аш-бәлеш пешеп утырмый. Менә ничек солдатны каршы алалар, ә? Кара әле, кайлардан ук күпме сагынып, йоклар йокыларын качырып, очынып кайтып төште, ә өйләрендә һичкем юк. Шулай каршы алырлар дип ашкындымыни ул бу көнгә? Аһ, ашыккансың икән шул, егет, бик нык ашыккансың!

Фазыл өй эчен әйләнеп чыкты. Бар да гади, үз урыннарында. Тик матча төшкәнме, идән күтәрелгәнме, диварлары да кысылганнар кебек — аның күңеле менә шуны сизеп алды. Ә шулай да — сагындырган!..

Солдат өйдә озак тормады, ишек алдына чыкты, үзенә якын җирләрне тизрәк күрәсе килде. Бала кебек исәнләшеп, бар нәрсәне тоткалап йөрде. Араннарга узды, сәндерәдән килгән яшь печән исе аның борынын кытыклады. Малай чагында Фазыл гел печән өстендә йокларга ярата иде. Ничектер рәхәт, җылы урын ул. Әтәч тавышларына колак сала-сала да рәхәтләнәсең, әмма кич белән генә куркыта... "Һай әнә шул малай вакытлар кабат кайтсын иде, белер идем ничек яшәргә",— дип Фазыл көлемсерәп куйды.

Туган изге нигезен карый-карый бәрәңге бакчасы ягына таба ындыр капкасыннан чыкса, исе китте. Әйе, гаҗәп иде. Ну бу авыл халкы яши белә, кара әле, менә кайда икән ул бәйрәм! Һәр бакчада ике-өч кеше (мөгаен шәһәрнекеләр дә бардыр), кайсы күлмәктән, кайсылары пляж киеменнән генә калып бәрәңге төбе өяләр. Көлешкән, сөйләшкән тавышлар да ишетелгәләп тора. Тик карчыклар гына, төпкә борыннарын терәп, әлеге дә баягы караңгы күлмәктән эшлиләр... Фазылның әнисе дә шулай акырын гына маташа, берни дә сизенмичә бәрәңге төбен өя бирде.

Шулчак гүяки берьюлы барысы да солдатны күреп алдылар. Фатыйма апаның күптәннән улын көткәнен беләләр иде, тик аның кайтканын сизенми ананың эшли бирүе бөтенесен дә гаҗәпләндерде. Шунда бер кыз, аңына килеп, чәрелдәп җибәрде:

— Фазыл абый кайткан!..

Бу иң ягымлы һәм күңелгә якын сүзләр, белмим, күпме тапкырлар кабатлангандыр, әмма солдатның әнисе һаман да эшли бирде. Нигә күрми ул, нигә ишетми?

Фазылның тәне буйлап салкын тир йөгерде. Әллә...

Фатыйма апага таба:

— Сөенче-сөенче!— дип кычкыра-кычкыра күрше кызы йөгерде...

Ә Фазыл үзе нәрсә карап тора, нигә әнисен, йөгереп барып, кочагына күтәреп алмый?

Шулвакыт Фатыйма апа да башын күтәрде. Кичләрендә дә йокламыйча көтеп арыган, җил ачкан капка янына да балам дип кат-кат йөгереп чыккан ана ул түгел идемени? Улы кайткан бит!.. Шунда сискәнүеннән күз аллары караңгыланып китте. Башы әйләнгәндәй булды. Күңеле бер нәрсәне уйлый иде, ә күзләре башканы күрде. Улы койма биеклеген дә узып киткән ич... Менә улы кайтты, менә өйгә бәрәкәт...

Фатыйма апа улы ягына таба кинәт талпынып куйды. Юк, түзмәде:

— Фазыл!— дип кычкырып җибәрде.

Бу сүзләрдән соң күз яшьләре дә бүселеп китте. Улы да кинәт айнып, ун атлыйсын бер сикереп, әнисенә таба йөгерде...

Ана белән ул, күзгә-күз карашып, тукталып калдылар. Солдат гади генә:

— Исәнме, энкәй, саумы!— дип кулын сузды. Ә әнисе, күңел төбеннән үк ярсып чыккан улым дигән сүзе белән Фазылның кочагына ташланды:

— Улым!.. Кайттыңмы?..

Фатыйма апа Фазылның кочагында җиңеләеп елап тора бирде. Һаман шушы хәлдә калыр иде дә, күршеләреннән бераз читенсенде. Тик шулай да, әйе, ни булган, бүген аның улы солдат хезмәтеннән исән-имин әйләнеп кайтты бит, ике ел буе борчылып көткән улы, газиз улы — Фазылы кайтты, ярый аңарга, бик ярый, ела әнисе, ела!.. Бәхет — еласаң тәмле...

Күршеләрдән карап торган пошык борыннар бу минутта әни дигән кешенең нинди саф, бөек һәм изге булуын аңлап житкермәсәләр дә, аналар баланың якын, кадерле бәгырь төене икәнлеген күрделәр. Алар инде эшли алмыйлар, хәзер җырларга кирәк, җырларга! Әйе, бүген өелеп бетәсе бәрәңге төпләре башка көнгә калдырылды...

Фазыл белән әнисе түр өйгә үттеләр. Егетнең тавышы катыланган иде, тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп куйды:

— Менә, энкәй, кайттым да!

... Фатыйма апа малаена карап утыра бирде. Боек күзләре, ышанмагандай, ниндидер бик кадерле әйберне күзләгәндәй, йотлыгып-йотлыгып улына төбәлгән килеш тын иделәр.

“Кара әле, әй, менә ничек бит: кайткач, аркасыннан сөя-сөя яратырмын төсле иде, ә?.. Бөтенләй дә улы үсеп беткән. Атасы кебек, нәкъ шулай, үзедәй... Сугыштан җиңеп кайткан, бәйрәм көне иде... Ничек итеп аны кочаклап үпте... Әйе, ул көннәр, ул чаклар... Менә хәзер улы да кайтты. Атасы исән булса, нәрсә дияр иде икән?.. Әй улым, улым! Син кайтканчы яшәремне күз алдыма да китермәгән идем... Исән-сау инде без, менә гомер сөреп ятабыз!”

Ананың уйлары изге иде.

Тик улының бер җирдә генә утырып торасы килмәде. Әле барып гөл яфракларын карый, әле дивардагы чигешләргә күз сала, әле тәрәзәдән багып тора. Тагын да кайтарып шул ук сүзләрен кабатлый:

— Менә, әнкәй, кайтып җиттем... Ни хәлләр соң?

Әйе, туя карап бетерерлек түгел, улы үзгәргән иде. Аңа ирләр корылыгы керә башлаган. Нәрсә дип әйтәсең инде? Әнием дип сөя дә, сөйдерә дә белми. Әтисе шаянрак иде, ә Фазылының йөргән кызы да булмады бугай? Һәрхәлдә бар икән, ишетелер иде. Кешеләр сөйләшми тормыйлар...

— Сине күргәч, этиеңнең яшь чагы исемә төшеп китте әле, нәкъ синең күк иде... Һәй, ярар инде!— Фатыйма апаның күзләрендә тагын яшьләр ялтырап китте.

— Кил әле, улым, утыр!— дип Фазылын үз янына дәште.— Менә шулай инде, яшибез...

— Әнкәй, нәрсә, әллә тормышлар авыр булдымы?

— Булды инде, ярый, кайттың... Аллаһ рәхмәтеннән ташламасын!..

Ике атна гына элгәре хәрби хезмәтен бетереп кайткан сыйныфташы Вәсим кергәндә Фазыл белән әнисе сүзсез, тыныч кына утыралар иделәр. Фатыйма апа аш та куймаган, чәен дә җылытмаган. Хәер, хәзергә кирәк идеме соң? Аларның бүгеннән бәхетле көннәре, күңелләре куанычтан туклык алган көн!

## 3. Саумысыз, туганнар!

Фатыйма апа, улы белән күрше егете Вәсимнең тел төпләре бәйләнеп китүгә куанып, аш хәстәрен күрә башлады. Фазылы кайтуын белергә өлгергән туган-тумача да килә башлаячак шул... Кереп-чыгып йөргәндә аның колагына солдат хатирәләре дә кагылгалап узды. Кайвакыт шул сүзләрен тыңлауга бирелеп, онытылып та киткәләде, кулындагы табасы мондый вакытта идәнгә төшеп, егетләрне сискәндерә иде. Ашыкканда йә табагачы аралыкка авып, яки кастрюле бии башлап, аны тагын да кабаланырга мәҗбүр итте. Кыскасы, әни кеше улы кайту куанычыннан сыйның тегесен дә, монысын да әзерләргә кереште...

Телләре җайланып ук китсен өчен егетләр “Бөгелмә малае”н да, ягъни аракы шешәсен ачып, эчемлек капкалап, сөйләшүне башлап җибәрделәр. Шулай җай гына утырганнарында күрше Гыйльфан абзый килеп керде. Култык астында йөрткән гармунын тез башына куеп, стаканы белән берне күтәрде дә:

— Эһ, зәһәр, чукынган!..— дип сөйләнә-сөйләнә, өй эчен шаулатып бераз җырлаштырып та алды.

Аның кызмачалыгы алдан ук бар иде булса кирәк. Кәефе дә яхшы, тел тегермәне дә ару әйләнә үзенең. Әмма аңа яшьләр арасында өлкән башына ялгызы озак утырырга туры килмәде. Фазылның әтисе ягыннан туган тиешле абыйсы Ахун авылның икенче башыннан ук йөгереп диярлек килеп җитте. Ул түргә узуга, ниндидер яңа төс белән куерып, бәйрәмнәре тулыланып китте.

— Ни хәл, энекәш!— дип, Фазылны кочагына алып мактаганнан соң: — Менә, хатыннан яшереп алып килгән күчтәнәч тә бар әле монда,— дия-дия, ул бер ярты ак аракыны өстәлгә китереп куйды да, сүзнең йөгәнен җиңелдән

тотып: — Энекәш, синең хөрмәткә аш астына салыйк әле,— диде, Фатыйма апа китерә башлаган ашлы тәлинкәләргә ымлады...

Ахун абзагыз бар җирдә җырсыз утырып буламыни? Аздан кәефе күтәрелеп, гел җырлап йөрүче кешене Гыйльфан да ярата. Менә киттеләр үзләренең җыр тәлинкәләрен әйләндереп, берсенә-бере куш килеп...

Гыйльфан җитез бармакларын гармун телләре буйлап йөртә тора, гаҗәеп оста итеп "Агыйдел"ен, "Урам көе"н рәттән уйнап та җибәрә, кушылмый мөмкин түгел үзенә. Әмма Ахун берсенә дә тавышын җиңәргә ирек бирми, тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып кына тора...

Тамаклары бетеп арыганда тышта төн иде инде. Фатыйма апа, бәйрәм ашына карап, күңеле тулып куанып утырды. "Һай узган гомерләр, картым гына бу көннәргә кадәр яшәмәде бит... Юк шул, юк! Латыйп сугыштан кайтканнан бирле үз рәтенә керә алмады. Һай бу сугыш. Нинди әзмәвер егетләрне суырып алды да, кайсын аксак, кайсын гарип, күпләрен чирле итеп, түшләрен бары тик орден-медальләр белән генә тутырып кайтарды. Әмма нинди горур, олы җанлы, киң рухлы иделәр алар... Менә улы Фазыл да кайтты. Бик яшь килеш, әле мыек та шытмаган хәлендә китте дә, инде чын егет булып кайтты... Һай улым, улым!"

Өстәл янындагылар дәртләнеп гәп оралар, мондый вакытта Ахун бөтен өстәлне берүзе тота. Ярты авылга ишетелерлек итеп шартлатып әйтеп салган "понимаешы" гына да ни тора... Менә кеше, менә белемле бәндә. Аңа үз фәлсәфәсе хакыйкать, үз тукыганы туксан, ә башканыкы әле аның бик олы, бөек "понимаешына" тиң килеп җитмәгән. Дөресме, дөрес түгелме, әмма кемгә-кемгә, аңарга беркем каршы тора алмый. Сабантуйда бил бирмәс батыр булуы гына җитмәгән, ачуы чыкканда читән баганаңны суырып алып, култык астына кыстырып китәрлек дәрәҗәдә ярсый да алган, чын мәгънәсендә һәм дәрәҗәсендә гади татар авылының беркатлы "мужигы" иде ул...

— Менә, син, Фазыл, авылда калам дисең... "К черту" барысы да... "Понимаешь"!.. Монда сиңа ни калган? Минем кебек борын сөртә белми торганнар болай да монда җитәрлек, "понимаешь"... Ә син — ун класс белемле, "понимаешь", җиткән-җитлеккән менә дигән егет. Шарт та шорт шәһәр урамнарының ташларын изеп, "понимаешь", йөрер идем мин, беләсең килсә... Ә син, авыз тутырып, авылда калам дисең. Ну, "брат, понимаешь", булмый болай сөйләшеп... Кая, сал әле, "понимаешь",— дип, кызулык белән тагын бер стаканны төбенә кадәр күтәреп куйды. Ачысыннан кызарып-бүртенеп, бераз тынсыз торды да сүзен дәвам итте: — Син, "брат, понимаешь", аңламыйсың әле, ә мин — беләм...

— Соң, абый, мин моны әллә кайчан уйлап арыган кеше...— Фазыл һаман да карышасы итте.

— Юк, бүлдермә син мине. Монда мин сөйлим, "понимаешь"... Тыңла!..

— Соң инде, калам тек — калам!

Ахун абыйсы, аннан бу сүзләрен ишеткәч, ничектер кинәт тынды, күңел сандыгыннан нидер эзли идеме, йөзенә уйчанлык чыкты. Энекәшенең үзсүзле булуы, үзен тыңламавы ачуын гына кабартып, эчен генә пошырды. "Эһ малай актыгы, атаң монда булса, кеше белән бәхәсләшергә өйрәтер иде,— дип уйлап, абыйсы Латыйпны исенә төшерде.— Әйе, абый, кырыс идең, әмма кешене

хөрмәт итә белә идең... Әти карт кебек кырт кына кисеп куя идең, “понимаешь”... Тик мин генә башка булдым”.

— Син, Фазыл, уйлап кара, “понимаешь”, киләчәктә колхозлар бетәчәкме? Бетәчәк! Шулай булгач, “понимаешь”, авыл да бетәчәк. Колхоз ул синең малың белән минем малны берләштергәндә генә кирәк, “понимаешь”. Ә аннары...— Ахун сүзне ерактан ук борып китереп, мәсьәләне кабыргасы белән куярга җыенды,— ә аннары, “понимаешь”, бөтенебез өчен дә бертөрле мал барлыкка килгәч, колхозның кирәге калмый... Авылны шәһәрчәләштереп җибәрәсең дә, “понимаешь”, заводка эшкә барган кебек кенә, тау артындагы малларны карап кайтасың. Җирне дә кырын ятып кына сөрәсең, “понимаешь”!

Фазыл аның шушы сүзен эләктереп тә алды:

— Соң, шулай булгач, абый, колхозда калу яхшы бит инде!— дип әйтеп тә салды.

— Нинди колхозда?.. Соң, әйтеп торам ич, “понимаешь”, “уф Алла” заманы бетте, колхоз да бетәчәк дим...— Бәхәсләшерлек көче булса да, Ахун абыйсы шактый исергән иде инде. Егет моны сизенеп алып, сүзне дәвам итми калдырды. Бу ниндидер, хәзергә юк-бар тоелган фәлсәфә аңа ошамый иде.

“Әйе, абый менә ничек үзгәргән. Бары ике ел эчендә. Уйлап кара! Ахун абый да иркенәеп, турыдан әйтеп, курыкмыйча сөйләнә башлаган...”

Ул арада кабат айныгандай калкынып, Ахун тагын җыр башлап җибәрде. Күрше Гыйльфан үкертеп гармун уйнавында булды, гүя аңа Җир йөзендә берни юк, бары үзенең әрсез колаклары һәм күңелендәге бөтен моңны әйтеп сала торган гармуны гына бар. Шул колак белән гармун бер-берсенә ярыйсы ук якын килеп, гүя үзара аңлаша иделәр. “Сарман” көе дә үзәкләрне тәмам өзгән кебек, йөрәкләргә үтеп керде. Ул чит җирләрдә яшәп, туган ягыңны җырларда гына сагынып сыкрау бер нәрсә, ә менә шушында, Сарман буйларының нәкъ уртасында утырып та шушы изге урынның моңына ничек бирелмисең ди әле! Йөгереп чыгып, менә шул илаһи туфракны үбеп-үбеп елыйсы килә. Һай Сарманым минем, Сарманым! Синдә бит изге бабамнар яткан урын, синең өчен атам каны тамган, синдә минем әнкәй дип әйткән иң беренче кадерле сүзләрем һәм ул, җир йөзендәге иң нурлы кояшның бөеклеге, миңа балам дип әйтүче анам, кырларым, тугайларым, син дә — сөйгән ярым! Юк, мин боларны мәңге санап бетерә алмам. Минем барча-барча әйберләрем, күңелемә иң кадерле булган изге урыннарым — барысы-барысы да синдә, Туган туфрагым!..

Кинәт җыр өзелеп калды...

— Исәнме, энекәш! Сау гына кайттыңмы?

Барысының да күзләре ишек ягында иде. Анда Фатыйма апаның энесе, Фазылны бик яраткан кеше басып тора иде.

— Саумы, Ризван абый!— Солдат, бераз чайкалып, ишеккә таба якынлашты.

Фазыл бу абыйсын күтәреп алып кочармын дип баштан ук уйлап-ниятләп кайткан иде. Тик болай исерек килеш кая инде ул, үзеңне дә көчкә тотып торасың... “Эһ, ньк үзгәргәнсең икән, бик кибеккәнсең икән, абый!..”

Юк, Ризванның болай коры гына кул кысышасы килмәде, энекәшен гүя бөтен күкрәгенә кертеп бетерергә теләгәндәй кочып алды ул. Ә Фазыл озын

буйлы, нык иде, әмма аның каршында чүпрәк кебек хәрәкәтсез тора бирде... “Кай арада җитештең син, энекәш, кай арада?.. Әле армиягә киткәнеңдә миңа баш түбәң күренеп тора иде, хәзер билеңнән генә кыса алам бит!”— дип Ризван абыйсы аңа карап уйланып алды.

Башкаларның тойгылы күзләре аларда иде. Хәтта Ахун да болай ук үз итеп күрешә алмавына көнләп куйды. Ул тиз генә стаканнарга калган аракыны бүлгәләп чыкты, ике кулына да аларны күтәреп, туганнары янына якынлашты:

— Әйдә әле, Ризван кода, күтәрик, энекәш хөрмәтенә!..

— Әйдә алайса!— Ризван бераз калтырана иде.— Күрше кызы кереп әйтте... Ризван абый, Фазыл абый кайтты бугай, бер солдатны юлда күрдем дип. Мин алай бик ышанып җитмәгән идем, шулай да, сөенче итеп кызга яулык биреп чыгардым... Менә, мин әйтәм, түшәмгә генә карап ятып булмас, барып килим әле, кайтмаган булса, апаны күреп, сөйләшеп утырырбыз, дим. Шулай сезгә таба якынлашкач, Ахун кода тавышын ишеттем дә, кердем әле менә!..

Шулай сөйләнә-сөйләнә күңеле нечкәреп, баласынып китүеннән көләсе килеп, әле Ахун кодасы алдында болай көлке хәлдә булуына ачуы чыгып, нәрсә генә эшләргә дә белмәде. Ул бөтен күңеле белән шатлана, калтырана бирде. “Кул биреп, ир-атларча күрешкән булсам, вәссәлам бит, югыйсә... Баласындым кода алдында, баласындым”,— дип артлы-аллы уйлаштыргалап алды. Аннан соң гына, тирән бер сулап:

— Әйдә алайса, кода... Энекәш! Синең хөрмәткә!..— диде, күтәрде.

Монысын да өстәгәч, Ахун бигрәк кәефләнеп китеп, алып килгән төргәгеннән тагын бер “баш” чыгарды. Моны күрүгә, Ризван кызарынды. “Күршеләрдән булса да алып чыгасы калган”,— дип уйлап куйды. Тик нишләсен, Ахун кебек җир җимертер сәламәтлеге юк шул. Сугыш алды, сугыш! Менә инде 35 ел сыкрана. Башта үпкәсенең яртысын кистеләр, аннан соң тешләрен суырдылар, хәзер җаны белән чутлашырга маташалармы? 35 ел инде һаман сугыша, шул каһәр суккан фашистлар белән сугыша. 57 яшенә җитте. Алып кайткан тән яраларына иптәшкә акрынлап җан яралары җыела барды... Башта эшкә дә бераз ярый иде. Үпкә дә таза кебек иде, сулыш кысылса да, болай ук сизелерлек түгел иде. Егет чакта сабан туйларда мәйдан тотты, сәнәктә ярты ат арбасы саламны уйнап кына очырта торган иде. Сугыштан соң да беләкләре таза иде, тик укасы тиз коелды. Китте инде менә шуннан... Хәзер үпкә кыса, тыны бетеп, күзләреннән яшь килә. Менә шулай инде, шулай...

Фазыл да Ризван абыйсына карап-карап ала иде. Аның тәбәнәкләнеп, җиңеләеп калганын, битендә бары очлы сөяк һәм җыерылып беткән тире генә икәнен дә күрде. “Әйе, абый, чигенгәнсең син, бик нык бирешкәнсең!” Күңеле төбеннән сытылып чыккан шушы уйларына ияреп, егетнең малай вакытыннан килгән хатирәләре дә ургып килеп чыкты. Шулай бервакыт, сигезенчене бетергәннән соң бугай, печән чабып алып кайтканында аңа урман каравылчысы очрады. Атын туктатты, әмма сүкмәде-сүгенмәде, үз кеше идеме, ачуланып сүз дә әйтмәде, тик:

— Синмени әле бу... Йөрмә болай кеше көлдереп, Ризван абыең сәнәк очына гына эләктереп ата бит моны,— диде дә китеп тә барды. Ә Фазыл күпме уйланып кайтты. Беренчедән, аңа яман усал дип даны таралган урман ка-

равылчысы бәйләнмәде, икенчедән, чынлыкта да Ризван абыйсы шундый гайрәтле микәнни?

Каравылчы хаклы иде. Инде нык какшаган булуына карамастан, Ризван абыйсы печәннең хәстәрен тиз күрде. Һәм башка вакытларда үзе белән урманга алып менә башлады, печән чабу серләренә дә өйрәтте. Ул: “Борынгыча өйрән, энекәш!”— дип әйтергә бик ярата иде.

— Эшнең рәтен белергә кирәк, рәтен! Һәр нәрсәнең үз тәртибе бар!..

Егет өчен бу сүзләр гомерлек фәлсәфә булды.

Ә хәзер абыйсы элеккеге Ризван түгел иде инде. Тик күзләре генә, тирән батып керүләренә карамастан, хәлне төгәл аңлый торган, һаман да шулай серле, төпле; мыегы да элеккечә калын, тик агарган гына. Ә башка бер җирендә дә ул юк, Ризван абыйсы юк... Фазыл үзенең аңа охшашлыгын сизә иде, шуңадыр күңеле сикереп-сикереп куйды...

Ахун тагын Гыйльфан белән җыр башлады. Күптән инде йоклап утырган Вәсим дә, айнып китеп, җырга кушылды. Ул үзен ир-атлар арасына керерлек итеп исерә алуы өчен, бүтәннәргә кушылып җырлый белгәненә күрә чын егет итеп саный иде инде. Ни дисәң дә, хәзер Вәсим чын ир, салса да гаеп түгел, җырласа да зыяны юк... Инде армиядән кайтканнан бирле сыйланып йөри, кая барып, нидән дөньясын башлап китәргә, нинди эшкә керергә ике атна буе сайлана, уйлый бирде. Фазылның да кайтасын ишеткәч, очрашуларын көтте. Менә ул да монда, эшкә икәүләп бергә башларга иде, югыйсә. Тик дусты күмхуҗ ягын каера, ә Вәсимгә удар төзелеш барган почмаклар кирәк. Күршедәге “КамАЗ”га инде бара алмый, чөнки аны хәзер алай ук мактап күкләргә чөймиләр, Себер ягы сугыла торган кадакка әйләнеп китте, менә кая китәргә иде!..

Энесе килеп кергәннән бирле Фатыйма апаның башы уйламас булды. Ул түр яктагыларны тыңлый-тыңлый, сүзләренә колак сала-сала йоклап китте...

Ул уянганда кояш, күзен ачып, инеш буендагы агачларга эленгән томан челтәрен күтәреп маташа иде. Фатыйма апа түр якка керде. Анда кичәге бәйрәм хуҗалары, кайсы башын караватка салып, кайсысы өстәлгә куеп йоклыйлар. Тик Ахун гына ара-тирә боргаланып куя, мыгырдангалап саташып ала. Әмма Ризван белән улы Фазыл болар арасында күренмәде. Алар баскычта сөйләшеп утырганнар икән, инде кояш та чыккач, бөтенләй йоклап та маташмаска булганнар.

Фатыйма апа өстәл өстен җыештыра башлаганда Гыйльфан да уянып китте. Гармунын Фазыллар утырган болдырга кочаклап алып чыкты да, озак уйлап тормыйча, “Алҗамал-Гөлҗамаллар”ны уйнап та җибәрде.

Ул арада Ахун да торып чыкты. Күзләре көләч, күңеле, аз гына йоклап алуына да карамастан, шактый шат иде. Сүзе дә болай аек чыкты:

— “Давай”, барыбер сабатуй, бәйрәм, уйна әле безнекен!— дип, “Авыл көе”н сузарга кушты. Иртәнге якта җырлауны картлар яхшыга юрамаса да, Ахун көр тавышы белән җырлап та җибәрде...

Алар шулай озак утырдылар. Башларын төзәткәннән соң, акрынлап таралыштылар.

Ишек алдында бары Ризван абыйсы белән Фазыл гына үткән ике елны берсенекен берсенә сөйләп калдылар. Аз сүзле Фатыйма апа, аларның әңгәмәсенә

колак сала-сала, келәт белән өй арасында таптанды. Исәбе бәйрәм ашы (тавык шулпасы белән бәлеш инде) әзерләү иде.

## 4. Кызлар һәм нәрсә ул мәхәббәт?

Гөлшат кич дип тә тормады, велосипедына да ягылмады, Камил абыйсының мотоциклына атланды да, артыннан йөгереп чыккан энесе Саматны тузан болыты астында калдырып, югары очка таба элдертте. Моңа ачуы килгән энекәше:

— Ну, абыйга әйтәм, ну!— дип, тез башына суга-суга, җиргә тибеп куйды. Шушы почык борынлы усал малайга да “матай җене” кагылган иде инде... Нинди генә әле — сөйкемле дәрт белән ярата ул мотоциклны. Хәтта:

— Улым, сиңа иртә бит әле!— дип әйткәләгән әтисен дә:

— Менә, утырып очасың, кая инде ул атайлар чапкан юртаклар, ә матай — “вот да”!— дия-дия, абыйсы төсле баш бармак белән мактанып үрти иде.

...Самат тыпырдап тагын тибенеп куйды да Камил абыйсы янына кереп йөгерде.

— Абый, абый, дим... Апа мотоциклны алып китте... Утыртмады... Абый, дим, абый!..

Камил өзеп-өзеп сөйләгән энесенә елмаеп карап торды да, аның унике яшьлек кечек борынына төртеп куйды. Янәсе, син бала әле... Ә сеңлесен юкка өйрәттемени ул, йөрсен, кызларның шундыйлары чибәр! Шулай да, энесе дә хаклы, ачу килерлек ич, мотоциклны сөртергә дисәң, юарга кирәксә — Самат, ә йөрергә икән — абый белән апа чаба.

Камил:

— Ярар, энекәш, кил әле,— дип, Самат белән бакчага чыкты.— Исәп ару әле минем, менә шушында, уртага дача кебек нәрсә ясап куярга иде.

Алар эңгерлек җыйган миләш агачы янына килеп утырдылар.

— Җәй буе төнлә дә саф һава. Янда транзистор, магнитофон акыра, кирәк чакта ммалайлар белән утырасың, “ак баш” (дөнья бит, белгән юк!)...

Егетең исәпләр шулайрак иде.

Саматның да күрше малайлардагы шундый шалаш-дачаны күргәне бар иде. Бигрәк тә Мөнирләрнеке ис китәрлек, сап-сары тактадан, әле быел гына ясадылар. Самат та, “шалкан” кадәр күзен алартып, алар тирәсендә йөрде, бераз көнләшкән дә иде әле. Шуны абыйсына ярып салды:

— Мөнирләрнеке кебек итеп ясыйк, яме, “вот” аларныкы — шәп, беренче сорт, беләсең килсә!..

Энесе Саматның хисләнеп сөйләгәнендә абыйсы Камил көлемсерәп кенә торды да:

— Булды алай булгач!— дип әйтеп куйды.

Гөлшат мотоциклын Айгөлләрнең капка төбендә туктатты. Бәйрәм алды киче булганга, кай җирдә салмыш мужиклар тыпырдап бии, ачык тәрәзәләрдән җыр ишелеп-ишелеп чыга, кайбер капка төпләрендә көлешә-көлешә халык сөйләшеп утыра. Гөлшат менә шул “тел бистәләре”н исәрләндереп калдырды.

Кайсы каш өстенә кулын куеп аны карап торды әбиләр: "Кем баласы булыр бу?"— дип, сораулы карашлары белән бер-берсеннән җавап эзләде. Дускаеның килгәнен күргән Айгөл, күршеләреннән очып диярлек чыкты да, яңа гына ябылган капканы шар ачып калдырган килеш, халык алдында Гөлшатны кочаклап алды:

— ...Нигә көндез үк килмәдең?.. Ай, монда, беләсеңме?.. Рәсим шәһәрдән кайткан, безнең турдан биш әйләнде бугай инде,— дип, сөенечен яшерә алмыйча мактанып куйды, дустын кулыннан җитәкләп өйләренә алып керде...

Ачык тәрәзәдән әле кызларның саф көлү тавышлары, әле музыка агылып чыкты.

Диванга утырган сердәшенең муенына Айгөл тагын килеп асылынды:

— Ай, беләсеңме, Гөлшатым, мин гашыйк булдым! Кемгә диген?

— Соң, шул Рәсимгәдер инде!

— Юк ла, ул болай гына!— Айгөл, серен әйтергә әзерләнеп, йөзенә кырыслык чыгарды да өстәлдәге китаптан фоторәсем тартып алды.— Менә ул!

Гөлшатның исе китте:

— Карале, Айгөл, каян алдың моны?..

— Ә нигә?.. Апам альбомыннан!

Кызлар бер-берсенә текәлеп авыр тын алды. Күңелләрен дулкынлану баскан иде. Бүлмәдә музыка һәм хисләр дөньясы гына яшәп калды.

Кырыс күзләрен текәгән фотодагы егетнең карашы Гөлшатны бөтенләй кашатты: "Нәрсә эшлисең син, Айгөл, нишлисең?.. Мин бит аңа үзем гашыйк булдым... Тимә, синең болай да Рәсимең кайткан!"— дип күңеленнән генә үтенә башлады...

Музыка тынды, хисләр яшәп калды...

— Бу егетнең исеме — Фазыл, кичә солдаттан кайтты. Сездән киткәч, тирәкләр янында очраттым мин аны һәм...— Гөлшат сүзләреннән тукталып калды.

Айгөлнең йөрәге нидер сизенде. Шәһәрдәге апасы исенә төште. "Эһ апам! Мин ул чакта нинди сабый булганмын әле. Син — унынчыда, мин — җиденче сыйныфта гына. Ияртә идең дә чыга идең, капка төбенә, кичен. Ә яныңа күрше авыл егете Фазыл абый килә. Моңсу гына егет үзе. Тыныч кына сөйләшеп утырабыз. Син ярата идеңме, белмим, әмма мин аны сабыйлыгым белән ни өчендер бик нык ошаттым. Йөрәккә егет идеалының чын йөзе булып керде, Фазыл — менә ул чын егет нинди була! Ә башкалар, ә башкалар — юк! Аларга үбәргә дә кочарга гына инде, бер елмаеп кына кара, шаяртуыннан дусларча гына көл, хәзер килеп җитәләр... Юк, алар әле егет үк түгел, алар әле сабыйлар!.."

Әйе, күптән хисләрен тибрәткән бу егеткә мәхәббәте аркасында Айгөл үз апасыннан да чибәррәк булып үсеп җитте. Аның кебек ахмакланып шәһәр егетен сөйсенме? Булмый! Фотоны кулына ала, һәр озата килгән егетнең сурәтен аңа янәшә куеп карый башлады, уртак чалымнарын эзләде. Бөтенесе дә башкача, барысы ят төсле иделәр. Әмма кызның курыкканы бүтән нәрсә булды — Фазыл аңа бөтенләй үк игътибар да итмичә, башка кызны озатып, яратып йөри башласа, ул чагында нишләр? "Мин яратам сине!"— дип, аның үзенә ахмакларча барып әйтеп булмый ич!

Кызның күзләре түбән иелде, җилкә турысында бераз бөдрәләнгән озын сары чәчләре аска салынды, йөрәге чыгарга урын эзләгән кебек кага иде.

Ике чибәр бер-берсен дус күреп, сердәшләр булып йөргән кызлар, очрашканда сүзсез бер генә минут та тора алмаган хыялый исәрләр бу юлы озак кына тын утырдылар. Яшерен генә туган серләре Фазылның фотосы алдында түгелеп калды...

Гөлшат, Фазылны тупыллар янында очраткач, ничектер каушап калды. Бу хәле яшь күңеленнән китми, аны дулкынландырып газаплады. Онытасы килде, ләкин яшьлекнең үз кануннары бар иде шул. Дөрес, Гөлшатның Илшаты — аны яраткан егете дә күңел түренә кереп утырган. Сигезенче сыйныфтан бирле шушы егет кисәге аның артыннан калмый, әле бакчаларына сикереп төшеп, сандугач булып сайрый, әле бүтән кызык уйлап табып, тынгы бирми. Тик хәзер, Камил абыйсы кайтканнан бирле, Гөлшатның янына Илшатның килгәне дә юк, һәй, егет диген инде аны! Ә менә Фазылны кара, тирән, тыныч, җитмәсә бик моңсу карашлы — чын ирләр төсе!

Гөлшат урыныннан кузгалды да:

— Айгөл, ярар, төн була инде, кайтам,— диде. Шушы сүзләр тын утырган иптәшен сискәндереп җибәрде. Күңеленә ялгыз калу хисе кинәттән килеп бәрелде.

— Гөлшат, ашыкма инде, сөйләшеп тә утырмадык бит әле!— Аның нидер әйтәсе, киңәшәсе килә иде бугай. Әмма озак тоткарланмадылар, икесе дә чалбардан мотоциклга утырып, Гөлшатларга киттеләр. Әмма юллары уңмады. Таудан төшкәндә алгы тәгәрмәч юлда яткан таш өстенә ялгыш килеп менде дә кызулык белән мотоциклны чайкап җибәрде... Әйләнеп киттеләр. Егылдылар.

Үкереп яткан мотоциклны, бик озак азаплангач, Гөлшат сүндерде. Тынып калган караңгы юл читеннән, тешләрен кыса-кыса, Айгөл күтәрелде. Йолдызлы кичнең җылы җиле, аның яраларына әрнетеп кагыла-кагыла, тәнен сыйпауга, ул, түзеп тора алмыйча, кычкырып җибәрде. Шул вакыт каяндыр килеп чыккан мотоциклдан юл читендә уынып җәзаланган кызларның күзләренә яктыртаяктырта көлешә башладылар. Боларның берсе Илшат иде.

— Менә бит алар кайда, бөтен авылны бетереп эзләп йөргән булам тагын, ә алар — монда!— дип, сөенә-сөенә Гөлшат янына йөгереп килде.— Авыртмыймы?..

Иптәш егете дә эшнең нәрсәдә булуын сизеп алды. Тиз генә мотоциклларын торгызды, чалшайган рульне турайтты...

Инде Илшат җиденче күктә иде. Ничек шатланмасын, юл буе егетне Гөлшаты биленнән кочаклаган килеш, башын җилкәсенә куеп кайтты бит. Шунысы гына үкенечле булды, кызның абыйсы Камил очрады да, мотоциклны алып китеп барды.

...Хәзер сабантуй күлмәген киеп тә булмас дип үкенеп алган Айгөл, дусларына килеп кергәч, яраларының әллә ни булмавын күрүгә үк тынычланды. Тик “сәфәр җитәкчесе” булган Гөлшат кына, үзен гаепле сизеп, кәефсез иде.

Ә шулай да куаныр әйберләре дә зур иде. Алар бүген төн буе бергә булачаклар. Серләрен бер-берсенә чишеп, тагын хисләр дөньясында йөриячәкләр бит! Аннан соң, Айгөл Рәсимнән качты, Гөлшат артыннан Илшат авызын ачып

карап калды. Бу хакта исләренә төшергәч, кызлар көлешә башладылар.

5. Тыңла әле, энекәш!

Авыл, бәйрәм алдыннан гөж килеп, акрын-акрын, ашыкмыйча кунаклар җыйный. Морҗалардан сыек төтен белән кушылып чыккан таба мае исен бигрәк тә шәһәрдән кайтучылар ерактан ук сизенеп сөенешә.

Төшкелеккә Фазылның апасы һәм җиңгәсе дә биш яшьлек малайлары белән кайтып төштеләр.

Бу вакытта Фазыл Ризван абыйсы янында, су буенда иде.

— Хәзер бит шәһәрдән кайтучылар да урамнан йөрми. Аннан нәрсә күрә алар? Шул ук тузан!— Ризван абыйсы акрын гына сүзләрне җыйнаштырып сөйли бирде.— Хәтереңдәдер, син белгәндәрәк алар инеш яры сукмагы буйлап кайта иде. Ямьле бәбкә үләне күмгән яшел болын аша, ә аннан тар гына комлы сукмак авылның шушы башына ук килә иде... Хәзер юк алар. Каз-үрдәк күп булса да, сукмагы юк, болыны юк! Кунаклар да юлны бакча башыннан салдылар, ни дисәң дә, авылның матур күренгән җирләреннән бердәнбер туры юл шул яктан хәзер. Ә син, монда да, урамдагы кебек, чирәмне бетергәннәр икән, дисең. Әйе шул, энекәш, бетерделәр. Юри түгел, ахмаклык аркасында. Әйе-әйе!.. Җитәкчелек эшенә менеп утырган, фикер йөртергә уйлап та бирмәүче, бары экономика, күмхуҗ байлыгын фермада, терлек башын арттыруда, басуларны һаман да киңәйтә төшүдә генә күрә торган, берьяклы, фәннән артта калган кешеләр эше бу!

Фазылга мондый фәлсәфә күптән таныш иде.

Авылда һаман да шундыйлардан котыла алмаганнар икән дип егет кайгырып та куйды.

— Гомерем минем фермада үтте. Шуңадыр томана булып калдым. Ә үзем җен ертылганчы эшли идем... Эштән кеше чир алмый икән.

Фазыл Ризван абыйсының язгы ташуда суда акканын исенә төшерде. Ничек котылгандыр?

— Батып үлсәм, яхшырак булган икән дә бит... Йә, ярар инде... Ә атаң сине гел үзенә охшаган дип сөйли иде. Сине үзе үстерәсе, үзе укытасы, зур кеше итәсе килә иде.

Фазыл аңа каршы, укыган кешеләр барысы да зур кешеләр булып бетмиләр дип, кирелеге белән әйтмәкче булган иде, исенә төште, акыл ягыннан, гыйлем ярдәмендә, белемеңә карап өстенлеккә ирешү хакында ич бу сүзләр — аңлап алды.

Ризван абыйсы һаман да сөйли иде. Ул тагын болын мәсьәләсенә әйләнеп кайтты:

— Менә бу су буен сөрдергән авыл советы рәисенә дә әйтүче булмаган. Оят, бигрәк тә безгә, авылдашларына куркак булу оят! Йөзенә шартлатып бәреп әйтүче кеше булмаган. Ә нигә авыл халкы шулай эшли алмый?.. Без бит аны үзебез сайлап куйдык! Ни өчен? Халык тормышын, эш шартларын яхшыртуны сорап биргән наказларны үтәр өчен дә түгелмени? Шуның өчен дә! Ә кайбер кешеләр, сайлауларда, миңа ничек тә ярый дип кенә катнашалар. Кирәкми безгә

болай, аңла, тыңла әле син, энекәш, әгәр дә без үз хокукларыбызны да кыссак, нәрсә була ул? Депутатны сайлыйбыз икән, димәк, безгә бурычы да бар, кирәк икән, сүгә алабыз, йә мактыйбыз.

Кем соң ялкауны эшли дип зурлый ә? Тырышны, акыллыны да булдыксыз дип хурлыйлар әле. Халык бит ул бәя бирә белә. Аңа беркем дә көчләп такмый, ул үзе белә, үзе эшли. Өстән әйткәнне генә көтеп тормаска кирәк. Уйлап кара! Менә бу су буен сөрделәр. Күп түгел, бары бер ел гына утыз сутый җиргә бәрәңге утыртыр өчен... Йә нәрсә? Бу җир елап калды, бозылып. Кара, буйдан-буйга алабута, тигәнәк, шайтан таягы баскан. Әле кайчан гына сузылып яткан кызгылт сукмак менә шушыннан үтә иде. Ә хәзер? Үзең күрәсең... Ул елны бакча башына гына күмхуҗ бәрәңге чәчте, бу кешегә җирне шуннан бүлеп бирсәләр ни була иде? Ул бит күмхуҗчы! Ә бер ел эчендә нинди болын әрәм ителде. Юк, монда уйларга тиешле кешеләрнең мәгънәсез булуларында гаеп!

Әнә, укучылар теге як болынга, таулар буена ничә еллар агач утырттылар. Күпме тырышырга мөмкин иде. Үсәләр дип уйлыйсыңмы? Юк шул! Анда “Батырлар аллеясы” яки парк ясыйк дип укучылар да чыгыш ясадылар. Күмхуҗ ярдәм итмәде. Соң, ни тора иде ул эш?.. Күмхуҗ бит үзебезнеке, эше дә үзебез өчен кирәк. Юк, һаман да шул инде... Мал йөреп, ул агачларны кимерде, изде, сындырып-таптап бетерде.

Менә, басу башына, артка, кеше аяк басмаган җирдә җиңү өчен гомерләрен биргәннәргә һәйкәл ачтылар. Нәрсә бу? Аңа бит авыл уртасында бик яхшы урыннар да бар иде. Ярамый дип, сугышта үлеп калган авылдашлар исемлеген язган тактаның өстеннән ахырда буяп куйдылар. Нәрсә, шул батырларның исемнәрен белергә ярамыйммы?..

Шулай шул, энекәш, аларны хәтердә сакларга кирәк!..

Дөрес анысы, җитешсез, кыек яклар бар инде ул, әмма болай ук мәгънәсез булырга да ярамый. Без бит җитәкчеләргә ышанабыз, аларга буйсынабыз...

Чын хуҗа була белмиләр, ә хуҗа була белергә кирәк, бик кирәк, вакыт инде.

Ризван туктап калды. Аның күзләреннән әйтәселәре күп булуын, гади кимчелекләрне дә шактый ук тирән кабул итүен, уйларының әле моның белән генә бетмәвен күрергә мөмкин иде. Кайчакта ялгышны тануы кыен, әмма Ризван инде моңа җиңел карый алмый. Шушы сыйфаты белән ул меңнәрчә кешеләргә охшаш иде.

— Син тыңла әле, энекәш! Күмхуҗда калам, дисең. Әмма укырга кирәк. Аннан соң кайтсаң да була!

— Юк, абый, мин әнкәйне калдырып китә алмыйм. Минем вөҗданым кушмый. Юк-юк, мин уртакул булмамын, анысы. Үзең дә әйтеп торасың ич, әнкәйгә карата да менә шушындый игътибарсызлык — зур ялгыш бит! Мин, абый, күп уйлап карадым. Кыскасы, күмхуҗда эшлим, читтән торып институтта укыйм. Минемчә, җиңәргә була! Тик ялгышлык кына булмасын! Эш үткәч, хатаны төзәтеп булмый ул!

Энесе белән Ризван килешә иде. Ә үзенең тормыш кылы да өзелергә тора. “Яхшы күңелле кеше син, Фазыл энем, яхшы кеше!”— дип күңеленнән генә ул сөенә иде...

Агалы-энеле акрын гына Фатыйма апалар капкасына җиткәндә өйдән гар-

мун тавышы яңгырады. Аннан кунаклар чыкты. Иң беренче булып Фазылның кочагына апасының малае Илдус атылды...

Ризван абыйсының сүзләреннән соң Фазыл бик күпне төшенде, ул аның белән килешә дә иде бугай. Әмма егетнең фәлсәфәсе бераз башкачарак иде... Мөгаен, тормыш авырлыкларына күпчелек без үзебез дә гаепледер, ул ялгышларда безнең дә өлеш күптер? Чөнки бер-беребезне вакытында туктата белмибез, күреп алып күтәрмибез. Вак-төяк ялгышлардан качу җиңел, билгеле, болар да шундыйлардан гына түгелме соң? Бәлки?..

Ә иң кирәге — безнең төп юл дөрес булсын, менә кайда ялгышмаска кирәк. Кешенең бәхетен билгеләүче тормыш юлы дөрес сайланып, киләчәгендә аны куандыра алсын. Чөнки һәркемнең шәхси бәхете халкыныкы белән үрелгәндә генә сокландыргыч була. Бар нәрсә дә үзгәрә шул. Тик Ризван абыйсы гына моны кабул итә алмый. Аның күңеле үткәнне сагына һәм, әйе, сагынырга тиеш!

## 6. Туганнар

Туганнар мәш килде...

Шушындый кызу көндә өйдә утыру бик үк рәхәт булмаса да, солдаттан кайткан егетнең бөтен эч сере, үткәннәре белән уртаклашмагач ни була ди ул? Әмма Фазыл гына кыска итеп җавап бирә. Ә ахырга таба сүзләрен бары тик “бар да әйбәт”, “барсы да яхшы” белән генә бетерә башлагач:

— Табын янында сөйләшелә ул!— дип, кияүләре сүзне йомгаклап та куйды.

Фазыл тәрәзә янына килеп басты. Балачакта хыялга бирелеп текәлеп торган нокта иде бу. Нәкъ элеккечә моннан карап торуы да ничектер рәхәт бит... Әнә, кара чәчләрен җилфердәтеп велосипедта бер кыз үтеп китте. Әйе, Фазылга таныш кыз, кайтканда очраткан сылу иде бу. Егеттә яшьлек тойгылары уянып китте, ул ачык тәрәзәгә килде, челтәрне күтәреп, урам якка башын чыгарды.

Менә авылда, менә үз өендә Фазыл, тик нидер җитми, нәрсәдер югалтылган да шуны мәңге табып булмас кебек... Ул монда ничек атлыгып ашыкты. Аһ, ничек сагынган иде туган авылын. Әмма күңеленең кайсыдыр урыны кителеп калган төсле. Ул бәлки әнә анда, ике ел бер җан, бер тән булып яшәгән солдатлар арасында калгандыр? Шул украин егетләре дә, хезмәткә килгәч кенә тәмәке тарта башлаган үзбәк дуслары да — барысы-барысы да ничектер якын иде.

— Исәнмесез!..

Фазыл каушап китте. Тәрәзә каршында шул кыз — кара чәчле, зәңгәрсу күлмәкле, мөлаем генә елмаеп торган чибәр сылу басып тора, ә күзләре егеткә төбәлгән.

— Яхшы!— дип солдат әйтте әйтүен, әмма “яхшы, чибәркәем, дигәнендә әйбәтрәк булыр иде” дип шаяртмавына үкенеп тә куйды... Ул арада кыз китеп тә барды.

... Кичкә таба Ахун печән төягән ат йөге белән килеп туктады.

— Менә, егетләр, бәйрәм алдыннан сәндерәгез буш тормасын мин әйтәм!— дия-дия, аны кыек астына җәйгәләп йөрде.— Бераз дымлырак...

Шунда ук:

— Хатыннар өйдә булганда, ир-атка менә шушында утыру яхшырак,— дип,

үзенең серен дә әйтеп куйды. Җитмәсә арба төбеннән бер кызыл аракы да чыкты.

— Менә, туган, шулай ул, син нәрсә, “давай”, моны аударабыз,— дип сикереп төште, җәһәт кенә кулына ишек алды ягында эленеп торган чүмечне алды да яңадан сәндерәгә менде.

— Менә шулай ул, туган! Бүген кайтып керсәм, Галия апаң пыран-заран китерә. Нәрсә, ди, бәйрәм дип мөгез чыгарып йөрмә, ди. Шуннан утырып аңлаттым да, кибеттән өч кызыл алып, күршемнең арбасына аттым, Хәсән абыеңны беләсең бит!.. Аңа нәрсә, шул гына кирәк. Ясалма көтүлек үз кулында. Икебезгә литрны печән арасында гына ектык та калдырдык. Күршем яхшы. Андагы — минеке, минеке – аныкы, дигәндәй, сайрашып яшибез. Ну абыйсы начар иде, ярты буразна бакчасына кереп бәрәңге утырта күрмә, буар иде. Монысы — акыллы баш. Бер буразнаны юри сукмак өчен калдыра. Без бит крәстиән, җиргә кендек бәйләнгән инде. Һич котылып булмый. Әнә шул бакчадагы егерме сутый да җәлке. Күршеңә ярты атлам да бирәсең килми. Шулай да, тату яшим дисәң, саранланма син аны, ярты капчык бәрәңгең ким чыгар, әмма күңелдә — җиңел, йөрәгең — тыныч. Менә шулай, туган!

Ул кызылны олы чүмечкә челтерәтеп салып бетерде, калдымы дигән сыман шешәгә текәлеп торганнан соң, аны тиз генә печән астына яшереп куйды. Түбә кыегы астындагы җилсез, җылы рәхәт һавага печән белән шәраб исе таралды... Ахун, беразын эчкәч:

— Мәле, туган, аударып бетер!— дип, Фазылга тоттырды. Егетнең бозыласы килми иде, шулай да абыйсына хөрмәт йөзеннән күтәрде.

— Әйе, энекәш, үстең! Ну сагындырдың бит!— дип Ахун абыйсы шунда Фазылның җилкәсенә китереп сукты. “Юк, яратып сугу гына аз, көрәшеп тә карага кирәк!” Башына килгән шушы уйдан хәрәкәтләнеп киткән гайрәтле ир хәзер егетне бакча ягына чакырды. Әйдә, янәсе, карыйк, кем булып кайткансың!..

Фатыйма апаны кияү кешенең юкка чыгуы борчый ук башлады:

— Кая олакты соң, табын да әзер, туганнар да килеп җитәр, кибеттән тагын алып кайтам дип киткән иде. Өйдә булганы җитмәгән идемени?— дип ачуланып та алды.

— Фазыл, сал, кайнеш, “давай-давай”!— дип дәрт биреп торган җизнәсенә егет күзен генә кысып куйды. Ахун аның җилкәсе аша бәрәңге сабаклары арасына барып төште. Барысы да көлешә башлады. Кияүләре кычкырган тавышка йөгереп чыккан Фатыйма апа, аларны күрмәмешкә сабышып, улына эчтән куана-куана өенә кире керде.

Ә Ахун бигрәк шат иде. Кияү кешенең үрмә җеп сумка белән күтәргән аракыларына ул арада күз ташлап, бер-икесен алды да, тиз генә сәндерәдәге печән өстенә яшерде...

Фазыл урам якка чыкты. Аның янына Вәсим килеп басты. Шул чакта мотоциклда үтеп киттеләр. Артта зәңгәр күлмәкле теге сылу кыз утырган иде. Дустыннан Фазыл шул кыз хакында сорашты. Ул сөйләгәннән соң, димәк егетең бар дип, күңеленә оялый башлаган чибәркәйдән арынырга теләде. Шунда яңадан алар күренде... Килеп туктадылар.

— Һо, Фазыл, синме бу, кайчан кайттың?— дип, инде кичә үк аның кайтканын ишеткән егет солдатның кулын кысты.

— Саумы?.. Кичә!..

Фазыл берничек тә башына китерә алмый иде. Кара әле ә, нигә соң дустын, сыйныфташын, Камилне башта ук, үтеп киткәндә үк танымый калды?!. Ярыйсы гына үзгәргән икән шул, чандырланган, үсеп тә киткән... Ул арадан берәү, көз көне армиягә алынды. Бергәләшеп, кадерләп озаттылар, ә Фазыллар шалуннары белән китте... Әйе, Камил бу!

Ике классташ бер-берсенә елмаеп карап тордылар. Бераздан алар арасына чибәр күзләр үтеп керделәр. Бу Гөлшат иде. Фазыл, сүзләрне җанландырып җибәрер өчен шаяртып:

— Карале, Камил, инде кунак кызларын да безгә калдырмагансыңдыр, ә?— дип, үз күреп Гөлшатка карады. Егеткә аның белән танышырга кирәк иде һәм бу шулай җиңел генә килеп тә чыкты.

— Юк ла, Фазыл, ул бит минем сеңлем, әллә оныттың дамы? Гөлшат!..

Камилнең егет мондый сеңлесе барын белми дә иде. Әллә оныткан да инде?

Фазылның башында сораулар кайнаганда, дусты кунак кызлары хакында сөйләп китте. Сеңлесе янында дип тә тормады, монысын озаткан идем, кирерәк, анысы болай “важный” түгел дия-дия, аларны сортларга бүлде.

Бәлки егетләр тагын да озаграк сөйләшеп торган булырлар иде, әмма хатынын култыклап, бәйрәмчә киенгән Ахун килеп җитте. Бик җәһәт кеше ул.

Башта Камил белән Гөлшатны өйгә керергә чакырып азаплады. Аннан соң хатынын мактап алды...

Табын тәмам җыелып беткән иде. Ризван да килде. Шушы, тешләре коелып, чәчләре агарган, какча-ябык абыйсы Ахун кода янында бөтенләй кечерәеп калган төсле күренсә дә, күз карашының тирәнлеге, акыл тәэсире белән көчлерәк иде. Ахун шушы күзләр белән очрашса, артык җәелеп китә алмасын белеп, берничә урын читкәрәк утырды. Туганнары аның теленә салынып, аш өстенә май булуын көтә иде.

...Бәйрәм төн уртасына кадәрле дәвам итте. Хатын-кызларның кайсы китеп, кайсылары йокларга җыена башлагач, ир-атлар печәнлеккә үрмәләделәр. Тик җырлап, биеп арыган булсалар да, күзләре ябылмады. Фазыл янына Ризван абыйсы туры килгән иде. Егетнең йокысызлыгына игътибар итте. “Энекәш киләчәктә тагын нәрсәләр планлаштыра икән, бергә чакта сүтеп калырга кирәк, тагын кайчан менә шушылай бер җыелып була бит, ныклы сүз әйтү кирәк егеткә, ялгышмасын!..” Чыннан да шулай, яңа кайткан гына чагы, яшьлеге белән хаталанмасын! Уйлары ныклы булмый торып эшне башладымы, инде планнары да барып чыкмаса, бетте диген. Кешеләр тормыш мәйданына җиңү өчен чыгарга тиеш! Әгәр андый теләк булып та дөрес юлдан китмәсәң, харап буласыңны көт тә тор. Бөтен нәрсә үзеңнең сәләтеңә, акылыңа, көчеңә карап сайланырга тиеш. Сабантуйда да шулай бит. Көрәшә белгән тимер беләклеләр генә көч алыша, ә йөгерә белгәне, беренче киләсенә шиге булмаган кеше — йөгерештә ярыша. Тормышта да кем “йөгерә белә”, кайсылар яхшы гына “көрәшә”.

Табын янында шуңа охшашлырак сүз дә булып алган иде. Тик менә хәзер аны яңартып җибәрү Ризванга уңайсыз тоелды. Арада иң карты, иң өлкәне ул

бит! Димәк, аңа сүзне башлау шарт. Җитмәсә монда менеп ятты, юкка гына түгел, сөйләшергә исәпләре барын сизенеп шулай итте. Кодасы да монда. Дөньяга икенчерәк күзлектән карый, көлкеле ягын чамалый ул. Икесе ике төрле кеше. Тормышны берничә яктан карап тикшерә алачаклар.

Шунда сүзне Ахун башлап җибәрде:

— Да егетләр, яшь чакта йокы печәнлектә тәмле була иде, нигәдер юк бит әле, йоклап булмый, йоклап!

Туганнар бераз кузгалышкалап, көлешә башладылар. Ризван шуңа ялгап та китте:

— Шулайрак шул... Фазыл, карале, анда яхшы булды дисең, ә монда эшне ничегрәк тотмак буласың соң?

— Бер-ике атна каерып печән чабып алырга исәп, Ризван абый!

— Ну-у, анысын булдырырсың син, энекәш, тик әле печән вакыты түгел... Менә бит аның башка ягы бар. Кем булырга, мин әйтәм, исәпләр?

— Соң, абый, күмхуҗда калу инде. Нигәдер сагындырды, кырда җир сөрәсе бик килә бит... Исәп менә шулайрак.

Фазыл үзсүзле иде. Кайткannан бирле шул хакта сөйләшәләр. Күпме баш катырырга була инде? Сүзгә Ахун кушылды:

— Кара әле, энекәш, һаман шул фикерең икән! Башта уку ягын чамала. Нигә ул безнең кебек белемсезлек? Кем без? Гади кешеләр! Юк, энекәш, дөрес уйламыйсың әле син... — дип, ул кызып китте, холкы шулай, тиз кызучан, тетә дә сала.— Син, энекәш, уйлап кара. Менә ичмасам эш! Мал врачы! Күмхуҗда да яхшы, интекмисең, кешеләрдән дә хәмер өзелми, шәһәргә китсәң дә югалмыйсың. Белдеңме, туган? Һәй, шаккатма син, газета саен — тракторист фәлән кадәр җир сөреп, беренчелекне алды, шуның кадәр ашлык җыеп, орден алды дигәнгә. Кая инде ул безгә, уйлап кара! Кемгә-кемгә, ә менә безнең күмхуҗда, тау сыртлары белән нефть торбалары үткән җирдә артыгын һич майтарып булмый... Кая инде ул безгә!.. Сабаныңны батырырга да өлгермисең, инде җирнең кырые күренә башлый. Булсын иде ул теге оч Шәрәфиеннән Казан Шәрәфиенә кадәр ара, вәт алыр идең орденын да, медален дә. Шулай, энекәш! Син бәлки, тырышып эшләрмен, тегеләй-болай дип, изге хыялларга чумгансыңдыр. Булмый. Сиңа кадәр Ахун абыең эшләп караган җир ул. Дөрес, газетага да алай басмадылар түгел, чыктым, әмма башкалар белән, миннән яхшыраклар белән чагыштырганда, гел бөтенләй юк нәрсәләр ул!

Фазылның ачуы килде... Ничек инде алай?..

Ахун сүзен дәвам итте:

— Фазыл, энекәш, күңелеңә авыр алма, башкага башың җитмәдеме?— дип, егетне котыртып та алды.

— Тукта әле, абый, башың юка димәкче буласың, мал врачы бул, дисең. Миңа нигә кирәк ул, ә? Юк, баш юка булса, күңелем сайлаган эшне башкармас идем... Уйладым инде, үзең дә яхшы беләсең, күптәннән уйладым, синең тракторыңа утырып йөргәнемдә үк уйладым: мин моннан беркая да китмим. Башкага күңел тартмый!

Сөйләшү барып чыкмады. Ризван инде сүзгә катышырга да теләмәде. Фазыл — үзсүзле, аны берничек тә җиңеп булмаячак. Шулай да университет бе-

терсә, яхшы булыр иде. Башлы егет бит. Фикеренең төгәллеге белән Ризван абыйсын хәйранга калдыра иде. Шулай ук артык үзсүзле булганмыни соң аның сөекле энесе? Ярар инде!

— Ну, яхшы, инде нәрсәләр кырмакчысыңдыр? Үзеңне шул тимер-томыр арасында калдырырга уйлыйсыңдыр инде!— дип, Ахун да үпкәләп тынычланды.

— Юк, абый, минем исәп башкачарак. Яшьләр бригадасы кирәк. Ну, менә, эшләрне дә, башканы да бергә башкара торган бригада кирәк. Ул вакытта нидер майтарып булыр сыман. Безнең агроном нәрсә ул?.. Кайда нинди җир, кайда уңыш ничек булыр — шуларны да белми... Менә, егетләр белән тотынсак, яшьләр бригадасы күпне эшләячәк...

Сүзләре бүленеп калды. Таң яктылыгы инде, җылына барган һава күзләрен акрынлап йомдырды.

## 7. Сабантуй

Фазыл уянып китте. Башкалар инде ишек алдында бәхәсләшә иделәр. Бигрәк тә Ахун абыйсының көр тавышы, җор теле аерылып тора, мөгаен баш төзәтергә җитешкәндер. Егет шуны гына уйларга да өлгермәде, баскычтан Ахун күтәрелде дә, шаяртып-көлеп:

— Һай туган, йоклап калдың бит, сабантуй да бетте, тор инде,— дип, Фазылны ышандырып та ташлады.

Егет ишек алдына чыгуга, Камил килеп керде. Сүзен озынга сузмыйча:

— Фазыл, сабантуйга солдат формасыннан барабыз, кызларны мин үзем табам, шаккатма, монда сиңа шобага сала башлаганнар инде,— дип, кичә төнлә сеңлесе белән Айгөлнең сөйләшүләрен ишетүенә нигезләнеп, егетнең күңеленә май ягып куйды да чыгып китте.

...Фазыллар сабантуй болынына килеп җиткәндә, халык инде җыела башлаган, ә уртада салмыш Гыйльфан абзый тальян гармунын сыздыра, вакыт-вакыт тойгылы көйләрне дә сайлап уйнаштыргалый иде. Һәр авылның үз юләрләре булган кебек, үз моңын, халык моңын үзәккә үткәрүче җырчысы да була. Менә алар юк икән, ул вакытта авыл инде чын авыл түгел, бәйрәмнәренең дә бер почмагы кителә.

Кояш күтәрелгән саен сабантуй кыза барды. Малай-шалайлар көрәшеннән соң сөлгеләрне билләренә егетләр салышты. Шулчак каяндыр бер уч болыт кисәге килеп чыкты да эре тамчылары белән җыенны сыйлап үтте. Һәрхәлдә сабантуй яңгырын картлар яхшыга юрый, елны бәрәкәтле килер, диләр. Шуңа күрә мәйдан тагын да көләчләнеп, җыелып китте. Юеш үләндә көянтәчиләкләрен тәгәрәтеп көлешә-көлешә, ялан тәпиләп апалар ярышты, ак ыштаннан картлар йөгереште. Ул да түгел, бәйләнгән җиреннән ычкынган батыр тәкәсе мәйдан буйлап ду килә-килә чабып йөрде. Бигрәк тә авыл малайлары көлмичә түзә алмады, чөнки шәһәрдән кайткан яшьтәшләре, куркышып, әниләренең итәк артына кереп поскан иделәр. Тагын мәйдан җәелеп китте. Бу вакытта чын сабантуй башланган иде. Уртада тимер беләкле ирләр көч алыша, көрәшнең бөтен шартын китереп, җиңү теләге белән сулый иде.

Фазыл авылдашлары белән күрешеп йөри-йөри арып бетте. Кайсын таныды, кайберен якынча гына белде. Аннан соң Камилгә ияреп кызлар янына китмәкче иде, Ахун абыйсы килеп чыкты да:

– Фазыл, кая йөрисең син? Әйдә, анда сине көтәләр, әйдә!— дип, аны мәйданга керергә әзерләнеп маташкан көрәшчеләр янына алып килде.

— “Давай”, туган, күрсәт үзеңне, шушындый көчне күрсәтми йөриләрмени?— дип, Фазылны көрәшкә рухландыра башлады.

Фазылның да үз көчен сынап карыйсы килә иде. Тик шулай да, әзмәвердәй ирләрне күргәч, бераз каушап китте, инде анысы да үткән иде, Хәнифне мәйдан уртасында абайлап, ачуы кабарды. Ул егет:

— Фазыл, нәрсә, бүген көрәшәбезме?.. Шүрлисеңме?.. Кызлар алдында кызык буласың килмиме?— дип, малайлар көрәшен карап торганда әллә шаяртып, әллә чынлап аңа бәйләнеп алган иде. Янәсе, сиңа бит бүләккә чүпрәк кисәге дә тәтемәячәк!

Фазыл ачуын да тыйган кебек булды. Юк, мәйданга керсә, бары җиңү өчен генә керәчәк! Сөлге-чүпрәк өчен генә көрәшмәячәк. Үзен белеп, урынын белеп, үкенмәсен белеп көрәшәчәк.

Абыйсы артык кычкырып кыстый башлады. Егет инде әзер иде. Әгәр дә хәзер җиңсә, алга таба тагын да куәтлерәкләр белән бил алышачак, менә монысы көчне-тәвәккәллекне, хәтта төгәллекне сорый...

Шунда алар янына Ризван абыйсы да килде, киңәшләрне акрын гына тезеп китте.

Фазыл мәйданга таба адым ясады...

Берничә көрәштә җиңүче булганнан соң, Фазыл ял итү нияте белән читкәрәк чыгып утырды. Аны яшьләр уратып алды, бергә агачлар арасындагы табын янына киттеләр. Монда инде аз гына да “күтәрми” кую мөмкин түгел иде... Алар исерештеләр. Фазыл исә, җизнәсе өйләренә алып кайтып юындыргач, бераздан гына хәл алды. Ул арада Ахун абыйсы килеп керде дә аны бөтенләй бетереп ташлады:

— Мәйдан сине эзләде, ә син, тапкансың эчәр вакыт!.. Хәнифне җиңдеңме, булды, имеш. Ә ул өченче батыр булып калды. Икенчене сиңа бирделәр. Эһ, син бит тәкә алачак идең! Эһ, сынаттың!..— дип, Фазылга атап бирелгән юрганны карават өстенә атты. Бүлмә буйлап эре-эре атлап йөри-йөри сүгенүен һаман дәвам итте. Бары тик Фазылның әнисе:

— Дөрес эшләдең, балам, тәкәне алам дип ватылмадың әле,— дигәч кенә, Ахун да беразга тынды...

Ул арада, мотоциклларга төялеп, яшьләр капка төбенә килеп туктады. Фазыл Камил белән бергә китте. Авыл башында машина тулы башкаларны очраттылар, юллары урманга, кичке һавада бәйрәмне дәвам иттерүгә таба иде. Анда барып җиткәч, учак тергезделәр. Барысы да шаярып көлә, уйный, җырлый башладылар. Парлар читкәрәк тартылды. Камил дә, мотоциклына ярын утыртып, каядыр юкка чыкты, башкалар, күмәкләшеп, чәчәкле болыннардан букет җыярга дип атладылар. Фазыл, хыялга бирелеп, ялгызы калган хәлендә каеннар арасына таба юнәлде. Аның ачуы килә иде. Нишлисең, хәзер монда бар әйбергә, хәтта башкаларның сүзләренә дә Хәниф хуҗа икән. Яшьләр арасында ул бәйрәм

итә, барысы да аның янында. Теге кара чәчле Гөлшат та, дус кызы Айгөл дә шуның белән киттеләр...

“Ахмак син, егет, ни калган монда, кемгә кирәгең бар синең?..”

Бу уй аның кәефен бөтенләй бетерде. Ул яңадан учак янына килде, җырлагандай итте. Тавышы көчле һәм моңлы төсле тоелды. Яшьлек мәхәббәтен исенә төшерде, аннары — Айгөлне...

Кияүдә дисең инде, ә?.. Ярар, алай булуы хәерлерәктер дә аның, әмма ярата иде бит, ярата иде...

Айгөле тагын, күзләрен тутырып карап торган булды. Ничек инде ул аны ярата алсын?.. Беренче мәхәббәтенең сеңлесен... Ахмаклык!..

Фазылның күңеле Гөлшатка төште. Исәбе аның белән йөри башлау иде югыйсә. Каян Илшат килеп чыкты диген, Гөлшатны алды да китте.

Фазыл үзенә монда урын таба алмады, читкә китте, юлы ачык тау битенә килеп чыкты. Кояш кызарып баеп бара иде. Җил исеп куйгандай булды. Егет борылды. Янына Айгөл килеп чыкты. Фазыл сүз башларга теләмәде. Әмма кыз, түзеп тормастан:

— Фазыл абый,— сүзенең башы болай килеп чыкканга бераз кызарып читкә карады. — Анда күптән табын әзер... Әйдәгез, барабызмы? Сезне чакырырга җибәрделәр,— дип, яңадан егеткә күзләрен текәде. Ә Фазыл:

— Ярар, мин барырмын, хәзер киләсемне әйт,— диде дә, тагын үз уена бирелде.

Тауның икенче ягыннан Хәниф килеп чыкты, инде китә башлаган Айгөлгә чәчәк бәйләме китереп тоттырды. Күптән ошата иде ул аны. Уңайлы вакыттан файдаланып, кызны кочагына җиңелчә генә алмачы булды, әмма Айгөл, кинәт борылды да, чәчәкләрен аның үзенә кире тапшырып, ашыга-ашыга Фазылны култыклады.

Хәниф артта калды. Алар учак янына киттеләр. Каеннар турысына килеп җитүгә, Айгөл мәхәббәт хакында сүз башлады. Аннан соң:

— Фазыл абый, мин сине яратам... Теге чактан бирле яратам,— дип, егетнең күзләренә туры карарга тырышып, ашыга-ашыга кабатлады.

Фазыл тын иде. Моны ул гүяки башына һич китерә алмаган иде. Җитмәсә — апасы, аннан соң — Гөлшат исемле чибәркәй, көндәше Хәниф бар бит әле...

Учак янында егетне ике кыз күзләде. Бу күзләрдән балкыган сөю нурын сизенми-күрми һич мөмкин түгел иде.

Кайтырга чыктылар. Аларны алып китәргә тиешле шоферны гына уята алмадылар. Рульгә Фазыл үзе утырды. Янына Айгөл белән Гөлшат урнаштылар. Алар ни көлми, ни җырламый иделәр...

Клуб әле бикләнмәгән икән. Туры шунда киттеләр. Анда җыр, бию, танса-лар иде. Айгөл белән Гөлшат каядыр юк булдылар. Фазыл да аларның артларыннан кузгалды, әмма борылып кире керде. Кирәкмәс, имеш, минем өчен яратылган чибәрләр түгел...

Клуб җырлый-җырлый урамнарга таралды. Фазылны Илшат чакырып алгач, исәбе ни икән дип уйлаган иде дә, Айгөлләр дәшкәнен ишетүгә, алар артыннан ияреләргә булды...

Төн кыскару җаен карады. Яктыра башлаган иде инде. Фазыл белән Айгөл

очраштылар. Икесе дә телсез-сүзсез дигәндәй, бары тик күзгә-күз карашып тордылар. Кызарып аткан таң гына аларны аерды.

## 8. Нишләргә?

Гөлшат нәрсә эшләргә дә белмәде. Ни күңеле тартмады, ни акылы җитмәде. Ул ярата иде... Илшатны булса — бер хәл, юк шул, аны түгел, Фазылны сөя, күңеле шуны көткән төсле... “Айгөл булмаса, мин сине үземнеке итәр идем, егет!.. Юк... Ярата белергә кирәк!” Гөлшат шундый хисләр эчендә янды.

Илшатны да ни өчендер кызгана иде. Ул, очрашкан саен:

— Аңлап булмый сине, Гөлшат, нәрсә булды?— дип борчыла.

Ә беркөнне атка атланып чапкан Илшат, Гөлшатның кер чайкавын күргәч, елгага төшеп тә җиткән. Су чәчрәтеп, аты белән күпме чаптырып узды. Әле мактанган була, күкрәген киергән, әйтерсең утлы казак егете. Әмма кинәт аты сөрлегеп-өркеп китте, инеш уртасына егетне чалкан егып та салды. Ничек алай була диген? Шунда каяндыр Фазыл килеп чыкты. Көлемсерәп торды да, тузынган атка сикереп менеп атлангач, җиңел генә чаптырып китте. Илшат исә, бик җайлы утырган егет артыннан ачуы килеп, бары тик мескен кыяфәттә карап калды. Ә Фазылны утырткан ат, үч иткәндәй, киерелеп чаба иде.

Гөлшат та аңа сокланып карап торды.

Илшатның ачуы килде. “Ну күрер әле ул, ну кирәгеңне бирермен әле... Әнә, Айгөлең алдында мактан, нигә минекенә тиясең?”

Фазылның Гөлшат алдында үзен күрсәтәсе, Илшатны кимсетәсе килми иде. Ул бары малай чагын гына исенә төшерде бит.

Атын Фазыл кире кайтаргач, Илшат, аңа бар ачуы белән суга-суга, урамга таба юыртып менеп китте. Тик ат инде алай рәхәтләнеп чапмады, җайдагы да әле бер якка, әле икенче якка капчык кебек янтая-чүмәлә иде.

Гөлшат югалып калды. Каршында Фазыл үзе басып тора шул. Яңа гына Ризван абыйсы үтеп китте. Ә башка кеше якын-тирәдә күренми иде. Тагын нәрсә кирәк, яратам диген дә кочагына атыл. Ә егет берни аңламый, елмаеп карап тик тора... Фазыл, син матур елмаясың икән бит!..

Шул чак:

— Фазыл абый, мине дә көтегез!— Кулындагы сумкасын болгый-болгый, егет янына каяндыр Илдус килеп чыкты.

Фазылның апасы малаен Гөлшат таный иде, хисләренең ялкынына су сипкәндәй булды, йөзе алсуланып китте.

Әмма кыз каршында егет югалып калмады:

— Исәнме, Гөлшат!— диде дә, килеп җиткән энесенең җилкәсенә кулын салып, Ризван абыйсы артыннан китте...

Хисләр утында калган Гөлшатның, талпынып, алар атлаган якка кош булып очасы килде...

Илдус, яшь колын кебек сукмак буйлап алга йөгерде дә, тукталып, таш ыргытып уйный башлады, аннары, исе киткәндәй, йомран ояларын актарды, кулын каш өстенә куеп, борыннарын җыера-җыера, һавада уйнаклап сайраган тургайларны күзәтте. Менә шулай ничә генә тапкыр кыланмасын, барыбер туй-

маячак, барыбер шаярудан туктамаячак бәхетле сабый иде ул. Ә артыннан барган абыйлары, никадәр генә тырышмасыннар — аннан көнләшәчәкләр, ничек кенә әле, бергә чабып китәрләр иде.

Менә бит ул гомер дигәнең, кайчан гына бала буласың да, кайчан гына үсеп, картаерга өлгерәсең!..

Энесенә Фазыл карап-карап соклана иде, аны чөеп-чөеп яратасы килде. Айгөле, Гөлшаты исенә төште...

Егет армиягә кадәр дә кызлар белән дустанә булды. Әмма хет берсе аңа уңай сүз әйтсен иде, ә хәзер, ә хәзер үзенең аларга исе дә китми. Дөнья күргәч, шулайрак буласың икән ул. Кешене кешедән аерырга өйрәнәсең. Борын чөючеләргә дә бик алай аптырамыйсың. Кая инде алар, юк-бар шунда. Ә Айгөлнең апасы? Ул нинди?.. Айгөле нинди?.. Юк, элекке ярату аңа бары тик яра гына ясап китте. Ә Айгөлне ул беркемгә дә бирмәячәк. Юкка кичләрен шунда чабамы? Тик башкалар гына юньсезләнеп арага кермәсеннәр дә, юк-бар белән башларын әйләндермәсеннәр!

Әмма Фазылга Гөлшат ныграк ошый иде...

Алар салкынча урман юлына килеп керделәр. Энесе дә бик тузынмый башлады. Аланнары да инде якын иде.

Кояш күрә башлаган егетнең күкрәге алсу төскә кергән, кәгазь эшләпә астыннан күзләре елмаеп тора. Ул кошлар оркестрына колак салды, аннары тын гына аларга кушылып җырлап җибәрде:

— Карадагынай урман, һай, караңгы төн, яхшы да гынай атлар кирәк үтәргә...

Фазыл уйларыннан арынып алды. Кояш ярыйсы ук күтәрелгән, ә алан чабыла гына башлаган, күтәрелми эшләргә дә эшләргә генә әле. Алда бит яшисе бар!..

## 9. Тимер төрәннәр...

Ахунның бу көннәрдә күңеле бигрәк тә күтәренде булды, каядыр ашыкты, ашкынды. Тракторы да гадәттәгедән яхшырак эшләгән кебек тоелды. Кыскасы, бу әле Ризван үлеменнән соң беренче шат көннәре иде. Әллә Галиясе бик иркәләгән, әллә бүтән сәбәп, әле уйларга бирелә, әле җырлый, белмәсең. Көне дисәң, көне юньсез, болытлар салынып тора... Ахунның ярдәмче малае мондый чакта шөлли иде, абыйсы ни әйтсә, шуны эшләргә әзер генә тора. Чөнки Ахун, шаяртып көлү белән бергә сүгеп тә атарга күп сорамый.

Шунда ул малай ниндидер бәлагә тап булгандай кычкырып җибәрде:

— Ахун абый, кара әле, анда нәрсәдер яна бугай?!.

Тракторист сөреп барган төрәннәрдән күзен алмыйча елмаеп кына куйды. Камылларны яндыра торганнардыр. Ул үзе үк аларга ут салган иде бит. Шул гына янадыр әле...

Тик ярдәмчесе ялгышмый иде. Ахун сискәнеп китте: әле эскерткә куелырга өлгерелмәгән салам өемнәренең бер башы күккә күтәрелгән ут эченә кереп бара. Нишләргә? Аның башыннан уй сызып үтте:

— Әгәр ут, мин яндырган камыллар буенча күченеп, эскерткә килеп капкан

булса?..

Озак уйларга вакыт юк иде. Ахунның йөзе кырысланып, аннан ачуы бәреп чыкты. Сабанын күтәртеп, тракторын шул якка куалады. Утның эчкәрәк үрмәли баруы күз белән карауга ук сизелеп тора иде. Трактор аның белән чагыштырганда бик акрын кыймылдый кебек иде. Янгын, җитмәсә, юлның икенче ягындагы бодай басуына күчте. Ахун үзенең генә аны җиңә алмаячагын төшенеп, ярдәмче малайны авылга йөгертте дә, төрәннәрен батырып, тук башакларны ярып кереп китте. Бодай басуын саклап калырга кирәк иде... Ахунның күзенә шунда өч малай чалынып китте, алар учагыннан капкан янгын иде бу. Ахун дөрес аңлады: аларның шушы дәһшәтле утны сүндерер өчен бар нәрсәне эшләргә әзер торуларын да, күшеккәннән соң учак ягып җылынырга маташкан булуларын да һәм иген басуы белән салам өемнәрен генә түгел, алайларны да бәладән коткарып калу кирәклекне — барысын-барысын да... Балалар аннан, зурлардан ярдәм көтәләр ич!..

Өлгергән иген кырын төрәннәр берничә кат бүлеп алдылар. Ут инде җәеләкүчә алмаячак иде. Ахунның күзенә ни эшләргә белми газапланган-аптыраган малайлар тагын чалынып уздылар. Ул, аты-юлы белән сүгенеп:

— Әгәр эскертне саклап кала алмасам, күрә торып яндыргансың икән дип күзне дә ачырмаячаклар... Ил алдында оят!— дип, тракторын салам өемнәре ягына борды, бүселгән-таралып яткан саламнарны урталай ярып өзмәкче булды...

Ыжгырып барган трактор, салам өемнәрен ерып-аерып, эчкә таба кереп китте. Әмма тизлеге акрынайды, тәрәзә алдына салам өелде, ул да яна иде. Трактор көчсезләнеп сүнде. Хәзер ул бернигә яраксыз: ни артка чыгып булмый, ни кабынмый, бары үзе дә бу янгын эчендә калып яначак иде... Ахун, тәрәзәне ватып, тышка ыргылды, шуны гына көткән ялкын аны да чолгап алды...

Фазыл килеп җитте, караватта кәфенләнгән Ахун абыйсының үле гәүдәсе иде. Инде сырхауханәдән алып кайтканнар... Ишек артында бер апаның еламсырап сөйләгән сүзләре ишетелеп алды:

— “Галиям, балаларым, авылдашлар ачуланмасын!” дип хушлашкан...

Фазылның бугазына төер тыгылды. Күңеле ярсып елый башлады. Ә чаршау артында Галия апасы үзен кулга алмыйча үкси иде. Егетнең күзләре Ахун абыйсына текәлеп торды.

“Җырла әле, Ахун абый... Ахун абый... Җырла әле!..”

Ахунны кодасы Ризван янына җирләделәр. “...Менә абыйлар, сез икегез дә мине ташлап киттегез... Сездән башка миңа бик авыр булачак, бик авыр булачак... Менә шуны уйладыгызмы сез?.. Ризван абый, син нәрсә дидең әле?.. Без барында куркып торма, эшлә генә, ди идеңме?.. Инде барысы да яхшы дигәндә, ә?.. Ризван абый, Ахун абый?..”

Ризван абыйсының да тетрәндергеч үлеме Фазылның исенә төште...

Печән вакыты үткән иде инде. Көне әйбәт иде, ә төнлә әллә каян яңгыр килеп, каты өермә белән агачларны аударып-сындырып китеп барды... “Фазыл, иртәгә безгә килерсең әле, сөйләшәсе сүз бар”,— дигән Ризван абыйсы, әйтелгән вакытка ишегеннән энесе узганда, инде үлеп ята иде. Фазыл әүвәле анымоны сизмәде, дәшеп карады да, болдыр төбенә чыгып утырды. Арыгандыр,

йокласын әле дип уйлап куйган иде. Шунда яңа сауган сөт күтәреп күрше апа килеп керде.

— Нишләп, Ризван абыең тормадымыни әле?.. Бик иртә аягына баса иде бит!— дип сөйләнде дә йортка узды һәм аһ итеп чыкты. Фазыл куркып китте.

Күрше хатын ялгышмады: Ризван шушы төндә йөрәген тотып үлгән иде...

Инде Фазыл икеләнә башлаган иде.

Гомер үтә икән ул. Бик тиз уза икән...

Фазыл инде уңышларга ирешә бара иде. Үзенең яшьтәшләреннән күбесе удар төзелешләргә киттеләр. Авылда калучылардан ул ялгызы гына иде. Башка механизатор егетләр унынчыны бетереп кенә эшкә тотынган, әмма уңган кешеләр булып чыктылар. Алар бүген соңгы басуда. Комбайннар белән соңгы үрне штурмларга керештеләр. Бу — Ахун абыйлары саклап калган игеннәр иде. Иң беренче булып Фазыл кузгалды, артыннан инде оешып җиткән яшьләр бригадасы тезелде. Эш шулай барса, Фазыл хыялына ирешәчәк иде. Күмхуҗда алар — беренчеләр, район үзәгендә һәм газеталарда да аларны мактыйлар.

Менә шулай бер-берең не дәртләндереп, әйдәп эшләү барысына да бик файдалы булды. Элек сизелеп торган күңел төшенкелеге бригада эчендә яши алмады, хәзер егетләр аерым-аерым йөрергә дә яратмыйлар, алар өчен иң кирәге — бергә, иптәшләренең сулышларын тоеп, ярдәмләшеп яши белүдә. Романтиканы әллә каян эзлисе юк, ул һәркайсыбызның туган кырларында да бар, тик таба гына белергә кирәк!..

Абыйсы янган җиргә Фазыл беренче булып килеп җитте. Тукталып калган комбайннарга өч малай карап басып тора иде. Намуслары кушуы буенчадыр, алар монда агач утырткан иделәр, хәзер көн дә килеп су сибәләр. Бәлки яңарып та китәр әле, имән бит! Үсеп, Ахун абыйлары кебек горур елмаеп, энекәшләренә карап торыр!..

Егетләр эшне тиз тоттылар. Ул арада район үзәгеннән машиналар килеп төште. Механизаторларны котлап, аларга мактаулы “Алдынгы комсомол яшьләр бригадасы” исеме белән бергә районның “Күчмә байрагы”н тапшырдылар. Иртәгә күмхуҗда алар өчен Уңыш бәйрәме булачак иде...

Комбайннар, гөрелдәшеп, кайту юлына чыктылар. Хат ташучы Гөлшат аларга кул болгап калды. Ул Фазылга Айгөлнең мәхәббәт хатын алып кайта иде...

Менә бу юлдан, берничә көннән соң, тимер тәрәннәрен иртәнге кояшта ялтыратып, шушы яшьләр бригадасы тракторлары белән үтеп китәчәк. Ризваннар, Ахуннар һәм башка меңнәрчә төптән җигелеп эшне тартучы, ташлыкларга, таулыкларга да карамастан һаман да батырып сөрүче тимер тәрәннәр төсле яшь буынның бу — авыл басуларына, болыннарына, кырларына буыннан-буынга тапшырылучы сәламе булыр!

*Казан-Сарман, 1980 нче ел.*

## ГАДИ ЗАМАНА

*Повесть*

1

Ул фәнгә бик соң килде. Аның буыны дип аталган эшкуарлар төркеме инде әллә кайчан кешеләр арасында танылган һәм хөрмәткә ия иделәр. Әмма Гатауллин тормышта, бигрәк тә шәһәрдәге ялагайлар төркеме арасында күптән тамыр җәеп өлгергән ялган табигыйлекне тулысынча аңлап һәм төшенеп җитә алмый гаҗизләнде. Бәлки ул яшьлектәге юләрлеккә хас беркатлылык белән агымга каршы йөзгәндәге кебек, килешмәүчәнлек белән коралланып, шул ялган табигыйлекне кабул итәргә генә теләмидер? Моны әйтүе кыен!..

Шулай ук ул төшеп калганнардан да түгел иде, гомеренең яхшы вакытларында хөрмәтле һәм кызыклы урыннарның берсендә хезмәт итте, дөресрәге, элегрәк Гатауллин республиканың чәнечкеле, усал һәм тешләүчән сатира журналының биек урындыкларында утырды. Ләкин ул аннан китте. Юк, сәламәтлеге каушаудан да түгел, анда талант та зур иде. Әмма тотты да китте. Чөнки ул һаман да, ир-егетләргә хас булмаганча, үзен таба алмаган кебек хис итә, шуның сәбәбеннән күңеле газапланулар кичерде. Элекке эше үзенә күрә мактаулы һәм ул аның арбасын җигелеп тарта, тик үзен әдәби иҗатка бирергә яратса да, бу хезмәте аңа җан рәхәтен биреп җиткерә алмады. Дөрес, ул бәлки хөрмәтле урынын калдырып та китмәс иде, әгәр... Монда аларын да яшереп торып булмый инде: әгәр аны тагын да җаваплырак һәм авыррак эшкә күчергән булсалар, ул бәлки фән эшенә китеп бармас иде. Ләкин нишләтәсең, өстәгеләр, урындагы кешеләр, аның нинди эшләр башкарырга сәләтле икәнлеген һәм нинди югарылыкка күтәрелә алачагын белергә теләмәделәр, нәрсәләргә тиң булуын күрмәделәр, яшермичә әйткәндә — сизенеп тә, белеп тә, мөгаен, күрмәгәнгә сабыштылар. Хәер, кайвакытта аңсызлык та халык өчен файдага була имеш: алар фәнгә шундый да зур галимне бирделәр. Бәлки... бәлки халык өчен аның башка, югарырак урында эшләве тагын да яхшырак булыр? Катлаулы тормыш дулкыннары эчендәге берничә корабчы җитәкче дә илнең кая барышында, кешеләрнең кем һәм нинди урындыклар биләвендә төп рольне үтиләр шул, чөнки бу галәмәтләрне алар хәл итәләр.

Менә шушындый дулкыннар белән чуарланып чайкалган, һичкем өчен дә кызыгы һәм әһәмияте булмаган көннәрнең берендә Гатауллин тормышында урын алган бер вакыйга булды. Дөрес, кайвакытта Гатауллин үзенә игътибар иткәләгәндә, исе-акылы киткәнен, югалып калган минутларын искә алмаганда, ул очраклы хәлнең бернинди эчтәлеге юклык аның өчен дә бәлки сизелми калыныр иде. Ләкин аңа соңгысы кирәгрәк һәм күңеленең тирәнлегенә тагын да файдалырак булыр сыман тоелды, шуңадыр ул бу вакыйганы исенә төшергәләп, һаман да тойгыларга бирелергә мәҗбүр һәм, үзен ачуланып, мескеннәр чиратына гына басмый, бәлки үзен иң түбән җанлылар сафыннан карый башлый, моның белән үз эшенә зур зыян да китерә иде. Менә шушы, аның тормышындагы төп вакыйганың берсе болай булды...

Гатауллин авылындагы усал малайлар рәтендә генә түгел, бәлки елаклар хисабында, үзенең өстенлеге һәм җиңүе өчен көрәшмәүчеләр санына кереп, күпләрнең хөрмәтен бары тик эш һәм хезмәт ратучанлыгы белән яулап алган тырыш бала булып үсте. Нәкъ менә шушы сыйфатлары иң кирәкле вакытта, ин-

ститутны бетереп, аспирантурага әзерлек һәм сынауларны узган чагында үзен нык сиздерде. Гатауллин үз шәхесеннән фән вәкилен ясау мөмкин түгеллеген төшенеп, моңа ачуы кабарып, бар нәрсәгә кул селтәүне кирәк тапты. Чөнки һичкем белән һәм, мөгаен, һичбер фикер белән дә килешми иде аның җаны, үзенең юк дип әйтә белүе аркасында ачуларны китергеч бер затка әйләнә баруын сизенде.

Гатауллин сынауларны яхшы үтсә дә, әмма канәгатьсезлек тоеп, үз шәхесен галим дәрәҗәсенә яраксыз дип бәяләде. Менә шушылай, объектив булмыйча, субъектив төсләргә буялган вакыйга-хәлләр аның тормышында зур роль уйнадылар. Бу аның үз шәхесенә ким итеп карый белүеннән килә иде. Мондый сыйфат суфийана бер хикмәт булганлыктан, тәрбияви көче бар исә дә, кешене бетерү, мескенгә чыгаручы тәэсир көченә дә ия иде шул.

Дөресен генә әйткәндә, кеше җиңелүләргә дучар булганда да, алда тантаналарга ирешергә мөмкин икәнлекне ул ачык аңлый һәм шуңа омтылыш белән яшәде. Андыйларның өмет бакчасында киләчәктә югары мәртәбәләргә ирешү теләге ялгыз чәчәк кебек тыныч кына балкый.

Гатауллинга да бу сыйфатлар хас иде. Ул аны җиңүләргә бертуктаусыз әйдәде һәм алып та барды. Шул ук вакытта, күңелдә җиңелүдән кимсенүләрне сизмәсә, эшеннән туктап кала һәм әллә кайларда адашып йөргән хисләренә чумып, берничә көн үзе дә югалып тора, аннан гүяки исенә килеп, күңеле тагын кыйбласын дөресли иде.

Әйе, Гатауллин шушы үзенең мескенлек чорына чыннан да күпкә бурычлы иде һәм шәхесенең галим булып җитлегүенә аның зур файдасы булганын күп тапкырлар исенә төшереп, шул самими хәленә кире кайтырга теләү очракларын соңга таба инде күңеле белән тагын да яхшырак тоя башлады.

Гатауллиның тормышындагы яңа, ягъни фән юлы гадәти рәвештә башланып китте. Әмма галимнәр коллективы аны колач җәеп каршы алмады.

— Исәнмесез!— диде ул беренче көне, ләкин аның сәламен кабул итүче булмаганны күреп бәгыре суырылды. Акылы кешеләрнең шулкадәр миһербансызлыгы аны бик нык рәнҗетте. Гатауллин көне буе горур булырга тырышса да, сабырлыгы терәлгән иде. Аның почмакка сыенып елыйсы, хәтта бар эшли башлаган эшен ташлап бу тирәдән китәсе, моннан качасы килде.

Андый чакларда адәм күңеленә балалык чоры килеп, үзен юата алырдай җылы кулны хәтере эзли башлый. Ләкин ни хикмәт, Гатауллин андый кулны тапмады. Үзен сүгә-битәрли бирде: имеш, шул кирәк сиңа, йөрмәссең!

Әмма эшләр моның белән генә бетмәделәр. Ул фән коллективыннан тәмам ятсыну тойгысына чумды, үзен юктан гына рәнҗетелүчеләр хисабына кертте. Шул ук вакытта бик кирәкле, ниндидер инсани көчне югалтуын сиземләп, күңеле белән билгесезлекнең офыкларын айкады, тик ул зарури куәтне таба һәм аның нәрсә, ничек икәнлеген төшенә генә алмады. Мондый билгесезлек икенче тапкыр кабатланганда гына Гатауллин аның асылын аңлап калды...

Алар бер яшь аспирантның фәнни эшен тикшерделәр. Гатауллин әлегә яшь галим исәпләнелеп, андый җаваплы эшләрдән баш тартырга, үзенең фикерләрен белдерүдән тыелып торырга кирәклеген яхшы төшенсә дә, өлкәннәрнең артык вакланып китүләрен күреп:

— Минемчә менә шушындый үтә катлаулы мәсьәләләр арасыннан иң төп, үзәк проблемаларны алып, берничә асыл юнәлеш белән генә чикләнү кирәктер,— дип чыгыш ясады. Дәлилләр китерде.

Шунда Гатауллин үзенә карап утырган өлкәннәрнең йөзләрендә бераз сәер елмаюның барлыгын тойды. Әйтелгән сүзләрен хуплыйлардыр диярәк фикер йөртте, уйларын бүлми генә дәвам итә бирде:

— Төрле ваклыклар арасында адашып йөрүгә караганда, иң кирәкле мәсьәләне тотып алып, аны дөрес итеп чишә белү, минемчә, дөрес юл!..

Ул, артык мавыгып китеп, кырыслана барган йөзләргә әллә ни игътибар да итеп тормыйча, үзенә кадәр сөйләгәннәрнең сүзләрен юкка чыгара барды, ләкин фикер дөреслегеннән бигрәк, үз-үзеңне тота белүнең, өлкәннәрнең һәр әйткәннәрне алтын бәясенә кабул ителергә тиешлекнең бу коллективта зур роль уйнаганлыгын Гатауллин сизеп ала белми калды. Әйе, ул сүзен бетергәндә, аңа күпләр үпкәләп өлгергән иделәр инде. Аның сүзләрен хуплагандай иттеләр итүен дә, әмма һәрберсе үзенең хаклыгына инанган төркем Гатауллины беркатлылыкта гаепләп, юкка тантана итеп йөри башлады. Алар коллектив эченә яңа килеп кергән галимне, үзләренчә үртәп “яшьлек” дип атадылар.

Ә Гатауллин җибәрелгән ялгышларын тиз төшенде, хәтта бервакыт әтисенең, ачуланып: “Хакыйкый сүзне әйтер алдыннан дөрес итеп сөйләшә белергә өйрәнергә кирәк әле сиңа”,— дип әйткәнен дә исенә алды.

Алар ул вакытта урман ягында печән чаба иделәр. Урман каравылчысы килеп чыгып, алардан монда чабу өчен рөхсәт бирә торган билет таләп итте. Гатауллин,— ул чакларда аның кушаматы Паша иде,— югалып калмыйча:

— Үзегезнең билетыгыз бармы соң? Урмандагы бар печәне үзегезгә ташып бетердегез, җитмәсә, агач сатып эчәсез!— дип әйтте дә салды. Әйе, ул хаклы иде. Ә каравылчы агай, үзәк бәгырьләрен кисеп үткән бу сүзләрдән соң холыкта-хистә бик каты кызып, малайны сүгеп кенә калмады, аның әтисен, хөкүмәтне талый дип, берничә айга төрмәгә яптырып та куйды, әле, ул гына да түгел, болын тирәләреннән җәй буена җыйнаштырып туплаган печәннәрен дә лапас астына яхшылап өеп куйган җирдән алып чыгып киттеләр. Паша үзен акларга тырышып ниләр генә эшләмәде ул вакытта, ләкин аның дөреслеге ике тиен бер акча да тормый, сүзләренә инде колак та салмый иделәр, хәтта ки шул батыр малайның хакыйкатьне сөйләвен барысы да белеп торсалар да!

Әйе, Гатауллинга бу сабак гомер буена җитәрлек иде дә, тик нишлисең, тормыш китабының кагыйдәләрен әле кат-кат кабатлау да файда китермәскә мөмкин шул!

Кешелек тә нәкъ менә шундый хаталар аркасында яши түгелме? Ялгышлар, аларны төзәтеп мәшәкатьләнүләр, аннан тагын да зуррак ялгышлар ясау һәм, киресенчә, боларга абынып китүләр... Кем белгән, бәлки ялгыша алган кешеләр тагын да бәхетлерәктер, гомумән, бәлки бу тормышта ялгышу хокукына ия дә була белергә кирәктер?

Бу турыда Гатауллин бер генә дә уйлап карамады. Ул башкачарак фикер йөртә иде: күбрәк үзен кимсетеп, сүгеп, шулар белән холкын тәртипкә кертергә тырыша иде. Аныңча ул һич тә ялгышмаска тиеш. Ә ялгыша икән, димәк ул — ахмак!

Гатауллин шушы ахмак дигән сүздән ярыйсы гына курыкса да, соңгы вакытларда мондый бәяне үзенә тагарга да өйрәнеп килә иде. Билгеле, баштарак мондый булуы өчен үз-үзенә үпкәләп тә йөргән булса, андый сыйфатына соңга таба өйрәнеп җитте, күнегә үк башлады, хәтта, аңа, ахмак дисәләр, ирен очларын селкеткәләп, кем әйтсә дә елмаерга да күнегеп китте...

Урамда көз башланды. Тупыл яфракларын әле монда, әле анда сипкәләп котырып йөрделәр аның җилләре. Гатауллин өчен бу көз шатлык алып килде, чөнки ул буйдак булып яшәвенә чик куйды, өйләнде. Туен элекке дуслары белән генә уздырды. Билгеле, шауларны яратмаган Гатауллин пөхтә һәм җитди табын әзерләүне кирәк тапты. Хатыны буласы Алсу туташ та аның белән бер сүздә иде. Туй мәҗлесләре артык шапырынусыз, матур һәм күңеле узды. Элеккеге чәчелеп-таралып үткәрелә торган зур туйларның модасы чыгып беткән һәм җитди мәҗлесләр, пөхтә һәм итагатьлелек белән кунак итешү чоры булгангадыр, бу бәйрәмнәре хакында озак вакытлар, чын күңелдән телләрендә мактап, күпләр исләренә төшергәләп торды. Гатауллин гаилә коруның ни икәнлеген яхшы ук төшенеп җитмәсә дә, Алсу белән бергә матур гына яши башлады. Калганын тормыш үзе өйрәтәчәк иде.

Беренче еллары зур мәсьәләләрдән һәм аңлашылмаучылыклардан башка гына үтте. Әмма Алсу ханым хәрәкәтчән һәм яшьлектән калган ниндидер самими усаллыкка хас үзенчәлеккә ия кешеләрнең берсе булганга, Гатауллинның кабинет караңгылыгына өйрәнгән тормышын вакыт-вакыт селкеткәләп-кузгаткалап ала торды. Әле ул гына да түгел, берничә ел үз якларына кайтырга һәм туганнарын сөендерергә вакыт таба алмаган Гатауллинны малайлык чорлары узган авылына алып кайтып килде. Имеш, кайда үскән икән ул шулай булып — күреп килсен әле!

Һәм менә үзенә нидер җитмәгәнлекне туган авылында бик яхшы төшенде Гатауллин. Ул моңа кадәр, инде күптәннән, җылы һәм кайгыртучан куллардан мәхрүм яшәгән икән! Ә хәзер ул аларны тапты. Алар — Алсуның куллары. Гатауллин көннәр дәвамында инеш буеннан, урман аланнарыннан кайтып кермәде. Ул һәр урында үзенең малай чагы белән очрашты, әнисенең үтә кайгыртучан йомшак куллары сагы астында узган шул чорларны сагынган булуын аңлап алды. Ул елларда аңа һәрбер әйбер җитенкерәгән һәм аның кайгысы булмаган, бары әнисе куенында яшәгән икән бит. Ә аннары... аннары шәһәр тормышындагы салкын китап киштәләре барысын да оныттырганнар, хәтта ана җылысыннан да читләштергәннәр. Гатауллин озак вакытлар эзләгән күңел юанычын бары тик үз якларында гына таба алуын элек күз алдына да китерә алмавын, хәзер инде бу яклар белән аның бәйләнешен беркем дә өзмәячәген аңлады. Шунда гына ул үз-үзен таба алды төсле.

Гатауллинга, ир һәм акыл кешесенә, мондый хис-кичерешләр ничектер чит һәм шул ук вакытта үз булып тоелдылар. Тормышына тагын бер мәгънә өстәлде: кеше хистән, туган яктан аерылмаска тиеш, хәтта аннан читтә, еракта булса да!

Ул көннәрдә иренең үзгәрүен, гүя балкып яши башлавын Алсу күреп яшәде. Ирен бәхетле итеп тою аның үзенә дә зур шатлыклар китерде.

Алар авылда артык озак булмадылар. Гатауллин сала халкы кебек җиргә

нык басып, эш белән кайнап йөрде. Печән чапты, какшаган каралты-кураларны төзәткәләде. Моңа олыгайган әнисе бик риза булып, сөенеп туймады. Аңа килене дә ошады. Кала кешесе булуына да карамастан, эш сөючән һәм авылча да сөйләшә белгән Алсуны күршеләренә мактап:

— И минем килен, минем килен, гел әнием генә дип тора, гел уңган, булган кеше инде... Аллага шөкер, Гарифҗанымның бәхетләре бар икән. Сабыр иткән — морадына җиткән шул менә! Ашыгып та өйләнмәде, бәхетле киләчәк насыйп итсен үзләренә!— дип, кич утырган вакытларында сораштыручы-фәлән булса яки, сүзне үзе башлап, сүз иярә сүз чыгарып әйтеп, чын күңеленнән үзенең картын да юксынуын искәртеп сөйләп алуны гадәт итте.— Менә, шушы бәхетле көннәрне Гафурҗаным гына күрә алмады шул, Гарифҗанымның пар канатлы булуын ничек көткән иде...

— Кайвакыт аңа башкалар да кушылып китеп:

— Каланыкы — калача инде, сөбхан Аллаһ, ул суга төшүләрен, көянтәчиләк күтәреп җем-җем генә басып баруларын күзем алмый карап калам, бигрәкләр булган инде. Чишмәнең ярты юлына җиткәч арый torгандыр шул, чиләкләрен чирәмгә куеп, ял итеп алгандай итә... Арый торгандыр шул, арый торгандыр...— дип сөйләшә иделәр.

Гатауллинның әнисе Сара әби бу сүзләрне кай якка, ничек аңларга да белми баш ватып тормыйча, болар начарга сөйли булырга кирәк диярәк үпкәләп:

— И-и, сөйләмә инде, Гасыймә, кеше баласыннан көнләшеп гомерең үтте инде. Үзең мәктәптә укыттың, үзең шуларны яратмадың,— дип тә әйтми тормый, сүзләрен җавапсыз уздырмый калмас булды.

Ә Гасыймә түти, үз чиратында, Сара әбинең дөрес аңламавына офтангандай итә иде. Ә кайвакыт сөйләшүләрдә мондый вак-төяк низаглар булмый да кала. Чөнки Сара әбинең бәйрәм көннәренә улы кайту, килене килү шатлыгын бозарга теләмәгән ахирәт кызлары бал-май төсле татлы сүзләрне сайрашуны мәгъкуль күрә торган була бардылар. Шуңадыр да Сара әбигә бу көннәр үтә якын, кадерле һәм бигрәк куанычлы, бәхетле булып тоелды. Ярым җимерек хуҗалыгын шушы ябык карт куллары белән этеп-төртеп алып бару авырлыгы, тормыш кайгылары аның күңеленнән мондый көннәрендә чыгып тора иделәр.

Инде улары киткәч тә Сара әби күз яшьләрен сөртә-сөртә еламсырап йөргәндә, ул бәхетле чакларындагы шаукым белән саташып ала торган була башлады.

Ахирәт кызлары аның хәлен аңлыйлар һәм инде улы белән килене хакында сүз катмыйлар. Сара әбинең аларны сагынганын барысы да беләләр, хәтта ул берничә тапкыр уйланып китеп, алардан читләшеп алгач, ахирәт дуслары нигә үзен шулай бетерә икән дип сүккәләп тә куя торган булдылар.

Ләкин бу гадәтсезлекләре озакка бармады, кунаклары китүгә атна-ун көн ярым вакыт үттеме-юкмы, алар тагын үз дигәннәренчә яши башладылар. Сулъяк күршедән Хәдичә һәм Кәримә әбиләр бөтенләй исләреннән чыгарган каз-үрдәкләрне карау белән мәшгуль булдылар, дөресен генә искәрткәндә, көндәлек хәсрәтләре Сара әбинең кайгысын ахирәтләре күңеленнән чыгарып бетерде.

Җәй икенче якка авышып, тугай-болыннардагы чәчәкләрдән нииндидер

самими, баш әйләндергеч ят ис түгел, бал аңкый, арыш басулары сарылана, ажаган уйный башлады. Мондый көннәрне авыл әбиләре, бер яктан, илгә игелек теләсә, икенче яктан: “Лә Иләһү Илләлаһ!” дип такмаклап, “Газап-авырлыкларыңнан Үзең сакла, изге хәсрәтләр генә бир, Ходаем!” дип, дога-үтенечләреннән үзләрен дә ташлап бетерми иделәр.

Ә Сара әби ничектер боларның икесен дә оныткан төсле булды. Ул берничә тапкырлар басу юлыннан кала якларына чыгып китеп карады, әмма һәр барыр юлының яртысын да үтмичә, чит-ят илләрдә үлеп калуым бар бит әле диярәк, нидер сизенгәндәй өенә кире әйләнеп кайтты. Ахирәтләре аның бу кыланышларын күреп, Сара әбине чын күңелдән кызгана иделәр. Җитмәсә, Гасыймә түти, олыдан купмый гына, Гарифҗанга тагын ял алып, кайтып китәргә үгетләп хат та язып карады, тик сүзләренә колак салмадымы, ул күренмәде.

Ә Сара әби тагын юлга чыкты. Гүяки саубуллашкандай басу-кырларны, урман-болыннарны әйләнеп-әйләнеп йөрде дә, чыккан юлына тагын барып җитә алмыйча кире кайтты. Эһ, калага Сара әби уйлаганча җәяүләп барып булмый иде шул. Ике арада ким дигәндә ике йөз ярымнан артыграк чакрым иде.

Сара әби, кайтышлый зиратка кереп, Гафурҗанын “күреп” чыкты; кабер ташы тирәсенә үскән әремне йолыккалап, үзе ятар урынны күреп сөенде. Ул әле, Гасыймәгә:

— Минем урыным чиста, Гасыймәкәй, тау сыртында, уң ягымда хәтта сәрби куагы да үсеп утыра,— дип мактанырга да исәп тота иде.

Сара әбигә, инешне аркылы чыкканында, болында үз иркеләрендә йөргән, көтүдән әллә кайчан качып калган кәҗәсе дә очрап, артыннан иярде.

Алар капкага кадәр бергә бардылар. Шунда гына Сара әби тукталып, койма буенда элек-электән яткан һәм шомарып беткән, адәм күтәрмәслек ташка утырып, калага күчтәнәчкә пешергән сала икмәген төенчегеннән чыгарып, чеметеп-чеметеп кенә кәҗәсенә ашатты, аны шулай тәмам иткәннән соң, ишек аларына узып, казык өстендәге чиста чүлмәкне алды, малкайның тулган имчәкләреннән сөтен савып, салкын суга илтеп утырткач, аны кабат болынга чыгарып җибәрде дә, өйгә кереп, түрдәге агач караватка ястык-түшәкләрен көйләштереп, “бисмиллаһ” белән ятып, йокыга да китте...

Инде кичке кояш офыкка эленергә маташа иде. Капка төбендә кычкырган кәҗә тавышыннан дикъкате китеп, укып утырган китабыннан аерылган Гасыймә әби исә тәрәзәдән урам якка күз салды. Аннары:

— И мескенем, җәбер итәләрмени?— дип, Сара әбинең кәҗәсен танып, аны мөгаен малай-шалай куып китерүенә иманы камил хәлдә капка төбенә чыкты. Тик урамда кеше-кара юк иде, ә кәҗә Гасыймәләрнең ишек алдына чабып керде дә җан өзгеч итеп тагын да бәэлди бирде. Булмаган хәл!

Гасыймә әби аны куып караса да, кәҗә чыгарга теләмәгәч, ахирәте Сара әбинең үзен алып керим әле, ияреп чыгар бу мур кыргыры нәмәрсә дип күршеләренә ашыкты.

Анда ишек-капкалар шар ачык булганга, Гасыймә мәшәкатьсез генә өйгә узды, эндәшеп-дәшеп карады, әмма җавап бирүче юк иде. Ихата тирәсеннән дә

эзләп-дәшеп керде ул, анда да күршесе күренмәде, шуннан соң, йомышы белән йөридер әле диярәк фикер итеп алды, шулай да күңеле тагын да шикләнеп, түр өйгә таба узды. Һәм шунда гына тынычланып, агач караватта яткан Сара ахирәтен абайлап алды. Аның Аллаһы каршына китеп барганлыгын аңлады да, аны-моны әйтмичә, күршеләрен җыярга тыныч кына чыгып китте...

Авылда кунак булып киткәннән соң Гатауллин, хатынының үгете буенча, бергәләп Кара диңгез буена юл тоттылар.

— Бала-чагаларыбыз юк, алар тугач, йөри дә алмабыз, үз кадеребезне үзебез белергә вакыт җиткән,— дип, үпкәләгән тавыш белән сөйләнгәләп, хатынына Гариф теләр-теләмәс кенә буйсынды. Өстәленә тулып яткан эшләрен дә тизрәк җиренә җиткерәсе бар иде, югыйсә. Хәзер тотынса, авылдан ияреп килгән күңел көрлеге һәм рухи дәрт белән аларны башкарып та чыгар кебек иде. Моңа каршы да Алсуы сүзләр тапты:

— Җәй ул эш вакыты түгел, ял итәр чак. Нинди акыллы баш синеке кебек эшне җәй көнендә башкара инде, әйт? Шушы кабинетыңда утырыр өчен әллә ниләр бирер идең,— дип ireннәрен турсайтты.

Кара диңгез буена барырга теләмәүнең башка сәбәбен Алсу сорап тормады һәм бардыр дип башына да китермәде. Ә Гатауллинда ул юк түгел иде: анда китәргә асылда аны күңеле тартмады. Ә шулай да хатыны белән килеште. Беренчедән, хатыныннан аерылып, ялгызы торып каласы килмәде, икенчедән, авылда рухына кабат йоккан балалык хисләре әле таралып өлгермәгән иде: анда йөгерү, адашыплар йөрү, уйнау-көлү, шукланып яшәү теләге көчен җуймады...

Ял вакытларының икенче яртысын Кара диңгездә калдырып кайтуларына, аларны көтеп алган аяныч хәбәр җаннарын кыйды һәм акылларын хәйран итте.

— Мин... Мин...— дип, акланырга сүз таба алмыйча изаланды Гатауллин.— Мин... Мин түш киереп, арка кыздырып ятканда, әнием үлем белән көрәшкән, гүр иясе булган... Ә мин... Мин — бәйрәм итеп йөрдем, бәйрәм!..

Гариф, күзләре яшьләнгәнне тоеп, әле үксергә җитеп, әле пышылдап: “Әнием минем, әнием, күз нурым, бәгырем минем!”— дип күңеленнән кабатлый иде. Алсу аның бу шашынуларын күрми калды. Аны бүтән сораулар борчый иде. Ул: “Хәзер нишлибез инде?.. Ничек авылга кайтабыз да кеше күзенә оялмый күренәбез?”— дип уйлый-уйлана бирде. Бу хәлләргә үзен гаепле итеп тойганга:

— Җитмәсә күршеләргә дә әйтеп калдыра белмәдек бит, почтаны алып, хәбәр итеп торган булырлар иде!— дип борчылды.

Аның үз-үзен бөтенләй дә юкка битәрләвен күреп, Гарифы юата бирде һәм күңелендәге теләген белдерергә кирәк тапты:

— Алсу, җаным, нигә үзеңне болай бетерәсең?.. Әйдә, кайтып килик, каберенә булса да сәлам биреп, агач утыртып...

— Ә халык алдында?.. Халык алдында оят бит!.. Тагын кайтып җиткәннәр, күмәргә эзләре дә булмады, йорт-җирне сатарга кайтканнар диячәкләр...— Алсу үксеп елый иде.

“Тынычлангач, бәлки башкача уйлар әле?”— дип, Гарифы аны һаман да юата торды.

Алсу бер яктан хаклы иде, халык алдында оят иде аларга. Ләкин Гатауллин үзенең кайтып килми кала алмаячагын әйткәч, хатыны да риза булды: мең рәхәтнең бер михнәте дә була торгандыр инде аның...

Гатауллиннар авылга якынлашып килгәндә кич эңгерлеге төшеп җиткән иде. Аларның машинасын таныпмы, әллә гадәт буенча гынамы, урамда очраган һәрбер зат аларга баш кагып сәлам бирде. Алар килеп җиткәндә Сара әбинең ян тәрәзәсеннән төшкән сүрән ут яктысына икесе дә игътибар иттеләр. Эшнең нидә булуын аңлашмыйча тордылар.

Аларга капканы өч өй аша торучы Әминә түти ачты. Ул:

— И балакайларым, кайтып җиттегезме, йа Рабби Ходаем, йа Рабби Ходаем!— диде дә, исәнлек-саулыкларын сораштыргач:— Өегезгә керегез, балакайларым, менә без, җыелышып, мәрхүмәбез әниегезнең җидесен үткәргән идек кенә, и балакайларым, балакайларым...— диярәк бер-бер артлы акланган тавыш белән тезеп китте.— Бездә бит шулай инде: андый йолаларны өйдә уздыру, мәрхүмәнең үз өендә үткәрү зарур санала... Әйе, балакайлар...

Алар да йортка уздылар. Эчтә, сүрән ут яктысында җиде карчык, Коръән укып, мәрхүмәнең туфрагы җиңел булуны теләп, гүяки тагын да кемнәрнеңдер килеп керүен көтеп утыра иделәр. Өй эче шыр ялангач, бернинди асылынган-эленгән чүпрәк-пәрдә дә күренми, бары тик түрдәге олы көзгегә генә ниндидер кара япма каплап куйган иделәр. Чиста итеп юылган өй диварларында да тыныч кына утырган әбиләрнең караңгы һәм артыгы белән олы күренгән шәүләләреннән гайре элеккеге чигешләрнең әсәре дә юк иде.

Әмма ишектән узучыларга игътибар итүчеләр булмады. Гатауллиннар моны үзләренчә аңлап, юктан гына борчылып алсалар да, тынычлыкны бозмыйча, почмактагы сандык өстендә урын алдылар... Коръән уку озак дәвам итте... Гатауллинның күңеленә: “Ни өчен караңгы төшкәч укыйлар икән?”— дигән сорау килде. Йомшак һәм биниһая тавыш белән укучы Әсма абыстай, тәмам итүен сиздереп булса кирәк, үз артыннан кабатлап баручы әбиләргә берничә тапкыр тыныч кына тамак кыргалап алды. Шуннан соң мөселманча битләрен сыпыргалап берничә авыз сүзне кат-кат кабатлады да Коръән китабын читкәрәк куйды.

Ахирәтләре, Сара әбинең дөньялыкта кылган яхшылыкларын исләренә алып, хатирәләрен уртаклашкандай иттеләр дә, инде вакыт соңлыгын берберсенә сиздереп, йортка атап дога укыгач, таралыша башладылар. Абыстай кеше усалраклар затыннан иде булырга кирәк, чыгып барышлый, Гарифка текәлеп:

— И Сара, авыр туфрагың җиңел булсын инде, йа Рабби, илләргә бәлаказалар килмәсен, и Алла,— дип, авыз эченнән укынгалап узды. Алсу, аның сүзләрен абайламыйча:

— Әллә каргый инде бу кортка, җаным?— дип иренә пышылдады.

Шуны ишетепме абыстай кире килде дә:

— Йа Раббым, үз колларыңа акыл-белем иңдер, и Хадаем!— диярәк, ирен читләрен яулыгы белән каплап кына сөйләнде, аннары борылып чыгып китте.

Абыстай артыннан тагын да берничә карчык иярделәр. Алар да китеп беткәч, өй эче ничектер бушап, яктыргандай булды. Монда калган әбиләр дә тавышларын бераз күтәребрәк сөйләшә башладылар. Гасыймә әби, яшьләр

янынарак килеп утырып, хәл-әхвәлләрен сорашкач, ипләп кенә:

— Әниегезнең кәҗәсе безгә кергән иде, аны сатып алып, акчасын җеназага тоттык, улым... Аннары, йорт эчендәге берничә ярарлык әйберләрне шулай ук җеназа хакына керттек... Зиратта, атаң мәрхүм — Гафурҗаны янында ул, сәрби куагы төшендә... Ул бит сәрби куагының чәчәкләнгәнен ярата иде...— дип, сөйләгән җирендә бераз туктап торганнан соң:— Авыр туфрагы җиңел булсын... Сезне кайтырлар дип көткән идек, җирләми көткән идек, улым Гарифҗан,— диде дә, яулык читләре белән күзләрен сыпыргалап, сүзсез калды.

Гүяки йортта урнашкан авыр тойгылардан котылырга теләп Гариф ишек алдына юнәлде. Сөрсеме коелып, аз гына сыктап алганнан соң, күңеле уйлар диңгезенә чумды...

Нәкъ шундый ук көзгәчәрәк кич иде ул вакытта да.

Күктә йолдызлар күзләрен йомгандай җемелдиләр, басу-кырлардан арыш исе, иген-икмәк исе килә иде. Әнисе белән Гариф югалган бозауларын эзләп йөри-йөри арыганнар, йокылары килүдән гаҗизләнә башлаган иделәр инде. Тау башына килеп чыгып, шунда озак кына хәл алып утырдылар. Әнисе:

— Йолдыз атылганда теләк теләп өлгерсәң, ул теләгең тормышка аша икән,— дигәч, Гариф тиз генә:

— Ә мин теләп өлгердем, әнкәй... Йокым килмәсен дип теләп өлгердем,— дип әйткән иде. Әмма әнисе аны, елмая-елмая:

— Алай теләмиләр бит аны, юләрем... Кешегә әйтмичә телиләр,— дип кочагына кысты.

— Беркайчан да, беркайчан дамы?— диде Гариф, бераз аптырап.

— Әйе, теләгән теләкне һичкемгә дә, бер кайчан да әйтмиләр... Аннары соң, синең кебек, дөрес булмаган теләкне дә теләмиләр шул... Безгә сөйли торганнар иде: бер ярлы-ябагай малай, таушалган, тишек-тошык киемле ятим бала шулай, йолдыз атылганда: “Барлык тишек-тошыкларым каплансын иде”,— дигән икән дә, теләге тормышка ашып, авыз-борыннары капланган ди, аннан соң ул үлгән икән...

Гариф, әнисеннән бу сүзләрне ишеткәч:

— Ярый, әнкәй, мин дөрес итеп теләрмен, яме!.. Менә, әйе, менә... Бозавыбыз табылсын дип, шулай бит, әни?— диде, дәртләнгәндәй, аннары бозаулары табылачакка чын күңеленнән ышана башлады.

Гариф сүзендә торды, йолдыз атылган саен, юл буенча шул теләген телители барды. Өйләрендә инде кайгыга баткан, ярым аякта, ярым түшәктә авырып гомерен үткәрүче этиләре карават почмагында аларның яхшы хәбәр белән кайтуларын көтеп утыра иде. Әмма озак эзләүләренең нәтиҗәсе булмаганлыктан, соңгы вакытларда Гафур абзыйның инде эче пошмый башлаган кебек күренә иде. Иренең шушындый булуына ризалыгын югалткан әнисе Сара, килеп керүгә, кинәт ачуы кабарып китеп:

— Ичмасам кешеләрдән дә белешмисең бит, Гафурҗан... Дүрт аяклы мал бит... Күренмичә йөрмәс бит инде, бозау кадәрле бозау!— дип, нишләргә белмәгәненнән елап җибәрде.

Шунда Гарифның этисе ярым шомлы һәм ярым караңгы итеп сөйләп бирде:

— Эзләмәгез инде, Сарытүш, кирәкмәс... Ул мал аякларында йөрми инде,

йөрми... Беркөн, сез өйдә юкта, Галиулла кереп чыккан иде... Тире китергән, бозау тиресе... Балык сөзгәннәрендә, күршесе Вәсил белән инде, су төбеннән тапканнар... Башы да, аяклары да шунда иде... Таш бәйләп салган булганнар... Кем суеп итен ашагандыр, белмим, Вәзыйх дисәм, гүр алдыннан гөнаһлы булырмын дип куркам, аннары, дошманнарым да бер ул гына булмады бит... Сарытүш, белә торып эзләткәнгә ачуланма, яме... Мин бит аңа ышанырга теләмәгән идем, бәлки безнеке исәндер дип исәп тота идем... Галимуллаларга да кычкырып йөрмәскә куштым... Ә малның тиресен лапас артына, утынлыкка кертеп ташладым... Ачуланма инде, ярыймы...

Гариф өчен дөнья гүяки урталайга ярылып китте, бу кадәр гаделсезлекне адәм затыннан булучылар гына кылырга мөмкин иделәр... Юк-юк, этләр эше булгандыр ул, эт җаннар эше...

Әтисе Гафурны әнисе Сара ачуланмады. Уллары Гариф кебек Сара да кешеләрнең миһербансызлыгына, җирәнгеч булуларына хәйран итеп, телсез калган иде. Аның таштай агарган битләреннән кайнар яшьләр актылар да актылар. Ә күзләре шундый моңсу, шундый кызганыч, төнге күктә балкучы гөнаһсыз йолдызлар кебек иде...

Гатауллинга бу күзләр инде караңгы йолдызлы күктән карап торалар сыман иделәр.

Ә бәлки чыннан да, кайдадыр еракта, менә шулай әнисе елап утыра торгандыр, ә?

Юк, ана кеше үләме соң, ана кеше бала күңелендә мәңге исән, мәңге исән ул! Ана... Дөнья йөзендә иң кадерле һәм изге кеше чыннан да ана кеше! Кадерле аналарны нәрсә һәм кемнәр белән тиңләп була соң?

Ишек алды ягында әби-чәбиләрнең сөйләшкәннәре ишетелде. Алар Алсуга ниләрдер аңлатып, үзләренә таралыша башладылар. Йорт тирәсе тынгач, ире хакында урамнан узучылардан күрмәгәннәрме дип хатыны Алсуның сораганы ишетелде. Теге кеше белмәвен, очратмавын әйтте. Алсу, шуннан соң ишек алдына кереп:

— Гарифҗан, син кайда?— дип, берничә тапкыр дәшкәч, Гатауллин бакчадан хатыны янына чыкты.

— Кайда йөрисең син? Котымны алып бетерәсең инде... Әйдә, керик, соң инде... Керик...— Ирен Алсу култыклап алды, өйгә таба атладылар.

Алар юлда арыган булганнар, тыныч кына, саташусыз йокладылар.

Берничә көннән Гатауллиннар, җиренә җиткереп, ике кабергә дә, әтиәниләренекенә чардуган куйдырып, Гасыймә түтигә мәрхүмәне йола кушуы буенча искә алу була-нитә калуга кирәк булыр дип акча калдырып, калага китеп тә бардылар. Аларның зәңгәр “Жигули” машинасы моннан соң авылга тиз генә кайтмаячак иде.

Ә Сара әбинең каберенә Гасыймә ахирәте күршеләренең малаеннан сәрби куагы утырттырды, гел дә үзен хәтерләтеп торсын, диде.

2

Гатауллин вак һәм олы кайгыларны авыр кичерүчән, шул ук вакытта ничектер югалып китә торган, кызыклы һәм кызганыч кеше булуы белән беррәттән,

усал җанлы бәндәләр сыйфатында да йөргән гаять аңлашылусыз зат кебек күренсә дә, аның бу үзенчәлекләрен белеп бетергән хатыны Алсу иренең мондый икәнлегенә, бер яктан, ачуы килүдән аны эт итеп орышуны кирәк тапса да, икенче яктан, тормыш иптәшенә карата ихтирамы зурлык аркасындамы, мескенен иркәлисе, юатасы килгән минутларын тормышында күп татыды, ә Гарифы, үз чиратында, Алсуның менә шушындый ике төрле кылануларына игътибар итеп, башын кирәкмәгән вак-төяк уйлар белән болгаткалап бетергәләде.

Ләкин вакыт дигән нәрсә барын да үзенә кирәкчә хәл итә белә иде. Шулай читтән бәлки ала-кола булыбрак күренгән гаилә, инде тора-бара үз матурлыгын табып, ничектер бертөслеләнеп, гадиләнеп калды. Озакламый Гариф белән Алсу бер-берсеннән туя һәм читләшә үк башладылар. Мондый чакларда кешеләрнең ничек үзгәрүләрен барыбыз да бик яхшы белгәнгә күрә, хатын кешенең үз эшләренә, ир затының үз шөгыльләренә кире кайтуларын һәм шуның белән бер-берсеннән ял итеп торуларын искәртү дә җитәдер, мөгаен.

Кешеләр өйләнешкәнче нинди холыкта һәм сыйфатта булсалар, төп хезмәтләрен кайда һәм нәрсәдә күрсәләр, гаилә тормышыннан инде суынырга да өлгерми, шул элеккеге үзенчәлекләренә, ташыган елга кабат ярларына төшкән-җыелган кебек, тагын да кайталар. Мондый чор җәмгыять үсешендә дә, иҗтимагый формалар оешу һәм төзелеш чорында да бар... Бу “кайту” мөгаен форманың яңа эчтәлек эзләве белән бәйледер! Әмма кеше өчен дә ул чор бик зур әһәмияткә ия булып тора, бигрәк тә алдагы яхшы тормышы өчен. Чөнки “кайту” вакытында һәркем үзенең төп үзенчәлекләрен билгеләп кала ала. Менә шул чорга игътибар итмәгән кеше шәхси сыйфатларын белүдән мәхрүм үк булырга да мөмкин.

Гатауллин үз шәхесенә карата җиңел кулдан караучылардан түгел иде. Кабинетына бикләнеп көн-төн укыса-язса да, урам буйлап йөресә дә, эшеннән соңарып кайтса да ул хакта күп уйлана иде. Ләкин ул фикерләре аңа бернинди файда итми, хәтта кайвакыт ачуын да китерә башлый иде...

Үз юлы белән Гатауллин ашыкмыйча гына атлый бирде. Гүяки дөньядан тәмам туйган һәм бу тормышка бернинди катнашы булмаган суфи диярсең, һичкемне күрми һәм ишетми иде ул бу мизгелләрендә. Танышлары очраганда исәнләшеп газаплануны элек тә кирәк тапмаган кеше бүген андыйларга бигрәк тә салкын иде. Ә танышлары аңа һаман очрый тордылар һәм сәламнәрен алмавына үпкәләп кала бардылар. Гатауллин хәтта трамвайда үз янына килеп утырган Алсуга да игътибар итмәде. Хатыны аңа елмаеп:

— Әллә йоклыйсыңмы, Гариф?— дигәч кенә, сискәнеп китте һәм елмаеп куйды.

Китте шуннан сүз, китте... Күңелдә үзеннән-үзе туган үпкә каядыр югалды да бетте. Тик соңыннан гына Гатауллин нигә, кемгә ачуланып йөргән идем әле дип исенә төшерергә тырышып карады, барып чыкмады. Вакыт агышы үзенең агымында юк-бар хәсрәтләрен алып киткән иде.

Көн кичкә авышты. Гатауллин йорт тәрәзәсеннән урамда кар тәгәрәтеп уйнаган малайларга карап елмаеп утыра бирде. Башлаган эше, акыл казанында кайнарга тиешле фикерләре шушында онытылып, аларны җиңелрәк булган

башкалары алыштырдылар...

Менә шулай кар өстендә янып-пешеп, катып-өшеп, кич җитүгә күкне йолдызлар каплаганга кадәр алар, авыл малайлары, бар дөньяны бер итеп уйный иделәр. Абзар-кура өсләренә менү дисеңме, карга чокыр ясап кереп качумы — берсе дә калмый иде һәм бик рәхәт, бик тә күңелле була торган иде...

— Гариф, Маратны дәш әле, кичке ашка утырасыбыз бар!

Гатауллин хатынына ярар дип җавап бирсә дә, изге хатирәләреннән кире кайтырга теләмәде булса кирәк, урыныннан кубып, малаен алып керергә ашыкмады.

Иренең кузгалырга да исәбе булмауны күргән Алсу ханым түзмәде, Гатауллинның эш кабинетына ук узып:

— Нишләвең бу, Гариф, нәрсә булды?— дип сорап куйды.

Ә ире тыныч кына утыра бирде. Бу вакытта ул ничектер ачулы һәм бик тонык кыяфәттә иде.

Гатауллин урыныннан кузгалып, тәрәзә борысына барып сөялде. Куллары күкрәге алдында чатланып тора иде.

Алсу һаман үз сүзендә булды:

— Теләмәсәң, әйтергә кирәк аны, үзем дәшер идем. Балаңны чакырып керергә дә ярамыйсыңмы хәзер?

Гатауллин Алсуның тупасланып алуына игътибар итмәде. Салмак кына:

— Мин әллә нишләдем... Юк, мин элек тә шундый идем бит... Менә хәзер дә...— Ул гел кирәкмәстән кемгәдер (бүлмәдә Алсуыннан гайре кеше дә юк иде) ым кагып куйды.— Мин гомерем буе алга омтылдым, ашыктым. Яшь чагымда бик тә акыллы, малай вакытымда бик тә тәртипле буласы килә иде. Ләкин дөнья минем белән күпме кирәк шулай шаярды. Теләмәсәм дә тәрәзә ватыла, соңыннан аны мин ватканы беленә һәм исем китә иде. Мин бит алай эшләргә теләмәдем, мин бит үземне тәртипле тоттым дип акланасым килә, әмма сүзләрем беркем өчен дә кирәкмиләр, алар миндә бүтән бер малайны күрәләр, усалны, тәртипсезне... Малайлык чорым менә шундый кирле-мырлы буларак, мәгънәсезгә үтеп китте. Укуда җиңел бара идем. Укымыйм, ә минем хакта: “Ул укый, тырыша”,— диләр. Тел һәм әдәбият фәннәре, тарих — болар минем өчен иң авыр һәм аңлаешсыз дәресләр иде. Математика, физика, химия, геометрия — менә шундыйлар минем өчен иң җиңел, хәтта бәйрәм кебек рәхәт дәресләр. Сигезенчегә кадәр шулай булдым. Юньле-башлы китап укымадым, дәрес карамадым. Һәм килде, килде ул акыл минем башыма да. Мин аны үзем чакырып китердем. Әмма анысы да рәтле-юньле булмады. Математикалардан качып, тел һәм әдәбият фәннәрен укый башладым... Һәм китте шуннан... Китте... Үземә иң кадерле һәм күңелемә бик якын басу-болыннарны ташлап шәһәргә юл алдым. Әнкәй үземә каршы килде. Мине туган ягымның басу-кырларында күрәсе килде аның... Ләкин теләге кабул булмады... Мин үземнең балачагымда ук зур хата ясаганлыгымны бары соңрак кына аңладым. Әмма аны төзәтеп булмый иде инде, соң иде...

Гатауллин кинәт башлаган бу сөйләвеннән шулай ук көтелмәгәндә һәм сүзен төенләп куймыйча тукталып калды.

Бүлмәдә сәгать текелди иде.

Бераздан Алсу, авыр сулап:

— Гариф, син эшеңне ташларга уйлыйсыңмы әллә? Үкенечең бармы?— дип, аптырап сорады, ире янына килде, күзләренә карады.

Гатауллин карашын читкә алды.

— Белмим... Мин ул сорауларны үземә бик күп бирдем, ләкин аларга җавап кына таба алганым юк... Соң инде... Беренче тапкырымда, үземнән туйгач ук, мин инде соңарганымны төшендем.

Бүлмәдәге тынлыкны бозып, гүяки фатирларын дер селкеткәндәй ишек кыңгыравы зеңгелдәде.

Ишек төбендә киемнәренә бозланып кар ябышкан, калач кебек кызарып пешкән, әлегә бакча яшендәге уллары Марат басып тора иде.

3

Гатауллин кафедрадан соңарып кайтты. Юл буена аны бары тик бер генә уй тинтерәтә иде: “Ничекләр генә итеп үз дигәненә ирешергә?”

Мондый сорау, билгеле, искечә яшәргә теләмәүче кешеләрнең һәммәсен дә борчый. Адәмнәр шуның белән алга омтылалар, көрәшкә күтәреләләр. Бу — җиңү өчен кирәк. Һәм андыйлар меңләгән. Барысының да башында меңләгән тонна фикерләр җыелып, төрле юллар белән максатның дөрес юнәлешен табуны таләп итәләр. Шул меңнәрне бер кечкенә генә Җир шары күтәреп алга, көнтөн тукталмый киләчәккә алып бара, ашыга. Ел артыннан елларны тәгәрәтә. Сүтә. Еллар белән бергә проблемаларны, мәсьәләләр белән бергә кешеләрне... Бүгенге яшь кебек тоелган мәсьәлә иртәгәге көнгә картая, бүгенге зур булып тоелган фикер — кичерәя, ә тормыш туктаусыз алга омтыла, ә кешеләр артка чигенәләр... Ләкин Гатауллин өчен бу төп мәсьәлә булып тормый. Аның исәпләре дә, уйлары да башка һәм бүтән юнәлештә иделәр...

Төсле музыка, көйләрнең төсе!.. Гүяки бергә һич кушыла алмас кебек тоелган ике сәнгатьне бергә, бербөтен итеп кушуы — аның төп ышанычы, үзен-үзе ачыклауның үзәк өлешенә әверелеп китте.

Фәлсәфәче буларак аңа бу мәсьәлә җиңел һәм аңлаешлы кебек тоела иде. Төс бервакытта да үзе генә йөрми, төс кешенең хисләре һәм тойгылары белән бәйлелектә яши, ә хисләрне һәм тойгыларны музыка аша ачыклау һәм билгеләү — мәсьәләнең чишелеше. Кеше хисе!.. Хис... Гатауллин кешенең яшәешен шуның аша күз алдына китерә иде...

Гарифның бар уйларын яктырткандай трамвай линиясеннән көлтә-көлтә булып ут сибелде. Йөртүче:

— Линия өзелде, төзек түгел,— дип, карлыккан һәм өзек-өзек, аңлаешсыз тавыш белән пассажирларына дәште. Кемнәрдер хафаланып бәргәләнә башладылар, кайсылары, тыныч кына:

— Менә инде, идарәләрендә нишләп утыра икән түрәләре, эшкуарлар,— дип сөйләнеп алдылар. Яңа гына шыплап тутырылган трамвай шул мәлдә теләми генә бушанып, халык белән чыгып киткән җылыдан соң суынып калды. Ашыгырга теләгәннәр һәм юллары озын булган кешеләр генә могҗиза өметендә утырып калдылар.

— Бу тавышлар барсы да Җирдән читтә, йолдызларга кереп адашамы икән?

— Һичшиксез шулай, тормыш ыгы-зыгысы тар урамнардан тагын да таррак галәм чикләренә күтәрелә...

Гатауллин үз алдына сөйләнергә ярата торган кешеләрдән иде. Бу фикере аның өчен генә аңлаешлы һәм гадәти булды. Чөнки ул кешеләрнең һәрвакыт исән йөрүләрен һәм яшәүләрен тели. Инде бу мөмкин хәл түгел икән, тавышлары булса да галәм хәтерендә калуын өмет итә. Кешеләрне шул галәм эчендә очратасы, күпме кирәк, шулкадәр сөйләштерәсе килә. Ә нигә, начармыни?

Әйтик, бала белән әнисе очрашсалар?..

Гатауллин шәһәр өстендә сүлпән генә йөзгән йолдызларны эзләде. Алар юк иделәр. Балкыган кала утлары караңгы болытларга нурларын аштырып торалар, гүя күк йөзе аскарак иңеп төшкән диярсең. Үзенә бер мәгърур һәм үзенчәлекле дөнья.

Гатауллин куырылып куйды. Болытлар арасыннан әнисе аңа карап торадыр төсле иде. Ана күзләре! Гариф Гафурович ул күзләрне бик ачык күрә, күк йөзе аска иңгәннән иңә, җиргә якынайганнан якыная, баш түбәсенә килеп бәрелер, йортларны җимерер, кешеләрне изәр төсле... Бу кайчанга кадәр шулай дәвам итәргә мөмкин? Гатауллин моңа игътибар итмәгән кешеләрнең ваемсызлыгына исе китте. Ничек инде?..

Акрын гына кар ява башлады. Гариф Гафуровичның исе-акылы китте. Ул шатлыгыннан елмаеп куйды. Гомерендә беренче тапкыр шәһәр өстенә төнге кар яуганын күрде. Ишелеп яуганны. Һе-е, күкләр өскә ишеләләрмени? Юкка гына бу дөньяны кызыклы һәм гаҗәеп дип әйтмиләр шул!

Ул арада трамвай кузгалып китте. Гатауллин башын тагын кыңгыр салып, үз дөньясына, фәлсәфәсенә чумды...

Соң гына кафедра мөдире Исхаков шалтыратты. Озак итеп тормышларның барышы, дөньялыкның килеше хакында сораштырганнан соң:

— Иртәгә миңа кереп чыгарсыз әле?— дип, сүзен бетерде. Гатауллин хәзер үк барысын да белешерә теләп, ни йомыш барлыгын әйтергә мөмкинлек булуын сиздереп караган иде дә, Исхаков:

— Ашыкмагыз ул кадәрле... Дөнья качмый ул!— дип кенә шаяртып куйды.

Икенче көнне дә Исхаков Гатауллин белән бик үз итеп сөйләште һәм:

— Гариф Гафурович, бүген, үз вакытыгыз белән, иртәрәк керүегез яхшы булыр, Кәримовның үзенә кагылып чыксагыз иде, ул сезне чакырткан иде,— дип әйтте.

Башта Гатауллин ул сүзләргә артык игътибар итмәде, чөнки фән буенча ректор урынбасары Кәримов янына еш кергәләргә туры килгәләде аңа. Ләкин, шулай да ул керүләре Гатауллинның үз йомышлары белән турыдан-туры бәйләнгән иделәр. Аннан ары, икенчедән, ул урынбасарны Гатауллин яратып та бетерми иде. Тар һәм текә маңгайлы, ачык, шул ук вакытта, тинтерәтеп бетердегез инде дигән кыяфәте йөзенә чыккан Кәримовның күзләрен йомышы төшкән кешенең дә бик алай атлыгып күрәсе килеп тора икән дип әйтергә мөмкин түгел.

Үз лекцияләреннән соң Гатауллин төп корпуска юнәлде. Әмма Кәримов тиз генә бушамады. Гариф Гафуровичны кабул иткән вакытында бу ректор урынбасары ничектер боегып, авыраеп киткән төсле күренә иде.

— Утырыгыз,— диярәк, Кәримов үзенә якынрак урынны тәкъдим итте.

Гатауллин озын өстәлнең бу башынарак утырды һәм тыңлыйм дигән кебек, башын күтәрә төшеп, үзен тынычландырырга тырышты. Ләкин күңеле нидер сизенгәндәй талпына, кыюсызлыгын гына аттыра иде. Кәримов сөйләргә ашыкмыйча, нидер язгалап-сызгалап маташа иде. Гатауллин аны ачулангандай:

— Ничек бу кешене шушы өстәл артында утырталар икән?— дип уйлап куйды. Бу фикереннән соң күңеле дә тынычлана төште.

— Гариф Гафурович, сез нинди мәсьәләне чишү буенча эшлисез әле?.. — Әмма шунда ук үзе моңа җавап биреп:— Ә, әйе бит әле, музыка, төс проблемасы,— дип, өстәле артыннан чыга-чыга, кабаланмый гына сүзен башлады Кәримов. Һәм тукталып калды.

— Сәнгатьтә комплекс проблемасы,— диде Гатауллин, төзәтмә кертергә ашыгып, тик Кәримов аңа игътибар итмәгәндәй, бүлмә буйлап нидер эзләнгәндәй йөренә башлады.

— Бу мәсьәлә күптән инде бик кызыклы булып, меңнәрчә кешеләрне үзенә берләштергән иде, шулай бит?.. Ялгышмасам, безнең калада бу мәсьәлә тирәсендә кызыксынучыларның беренчеләреннән тәүгесе сез идегез... Иптәш Гатауллин, дөресен генә әйткәндә, проблема артыгы белән катлаулы...— Кәримов тәрәзә янына килеп җитте, аннан урам якка карап сүзсез торды.

— Исхаков белән дә ул хакта сөйләшү булды. Ләкин, ни, турыдан-туры әйтергә кирәк, ләкин... Сез сайлаган юл, проблеманы тулы килеш чишү өчен, яшермик, туры һәм бик үк дөрес диярлек түгел.

Кәримов бу сүзләренең Гатауллинга тәэсир итү-итмәвенә игътибарын юнәлтү өчен Гариф Гафуровичка авыр күзләре белән туры карап, тагын да сүзсез торды.

— Хәзер безнең төп бурыч, сез сайлаган юлның, иң беренче, дөресме-юкмы икәнен ачыклау... Кабатланып әйтәм инде, бу турыда әле безнең алда тулы фикер юк... Икенчедән, бу өлкәнең бары тик коры фантазия булып китүен, аның киләчәген тикшерү кирәк булачак... Гомумән, без бу юлдан бару кирәк яки кирәк булмауны белергә, ачыкларга тиешбез...

Гатауллин аңа каршы бер сүз дә әйтмәде. Кафедрада башланган борчулы сөйләшүләрнең темасын монда да яңартасы, дәлиллисе килми иде аның.

— Фән, фән, фән!..— дип күңеле үчекләнде. Кәримовка каршы чыгып, юк, мин дөрес юлда дип кенә берни эшли алмый иде шул ул. Музыка һәм төс — кирәкме алар бүгенге кеше зәвыгы өчен? Кирәк! Әмма бербөтен, икесе бербөтен буларакмы, әллә инде аерым-аерым гынамы? Бу хакта бәхәс корып торуның бөтенләй дә кирәкмәс булуы ачык иде. Тик менә нинди юллар? Метод? Ничек? Кеше дөреслекне танып белүгә таба бара икән, хакыйкатьне ачыклый икән, нинди юлдан атласа да барыбер түгелмени? Юк икән шул, син үзеңчә түгел, аларча, башкалар теләгәнчә эш итәргә тиешле!

Кайнап чыккан ачуын Гатауллин күрсәтмәскә тырышты. Хәер, түрәне ул мәсьәлә кызыксындырмый иде булырга кирәк. Кәримовның гаделсез сүзләренә исе китүен дә Гатауллин сиздерми кала алмады.

— Фәндә баганалы юллар юк шул, маяклары юл уңаен күрсәтеп тормыйлар!

Гатауллин бүтән эндәшмәде. Нидер аңлата башласа да, аны Кәримов тыңлап тормаячагын төшенергә өлгергән иде инде ул.

— Сез, Гариф Гафурович, Гыйльми советка үзегезнең тикшеренүләрегезнең нәтиҗәләрен яктырткан отчет белән килсәгез иде? Иртәгә, кичке сәгать бишкә... Көн тәртибенә бу мәсьәлә кертелде!

Гатауллин, инде үзенең монда кирәксезлеген тоеп, ишеккә таба юнәлде. Аны Кәримов туктатты:

— Әйе, кыска һәм дәлилле отчет кирәк! Озынга сузмагыз... Төп максатыгыз һәм аңа ирешү юллары... Эшегезнең практик яктан файдасы — монысы иң мөһим як, онытмагыз!

— Хушыгыз!

Гатауллинга бераз җиңел булып китте. Гыйльми советка отчет белә йөрү институтта күптән кабул телгән гадәти күренеш иде. Аннан соң, әгәр анда ул, Гатауллин, җиңеп чыкса, димәк, кафедрада да өстен булачак. Аңа ышанычсыз күз белән читләтеп караулар бетәчәк.

— Исәнме, Гариф!

Гатауллин үзенә эндәшкән кешегә теләр-теләмәс кенә баш какты. Уйларына чумган килеш юлын дәвам иттерергә тартылды. Әмма эндәшүче инде аның белән тигезләшергә өлгергән иде.

— Әллә онытып та бетергәнсең, Гариф?

Гатауллин икенче күтәрелүендә игътибарын җыеп өлгергән иде, әмма уйларыннан арына алмыйча:

— Юк, гафу итегез, онытканмын,— дип кенә әйтеп куйды. Аннары, исенә төшергәндәй:

— Ә, әйе бит әле, син!— Гариф айнып киткәндәй булды.— Гафу ит, уйларым да, зиһенем дә бераз буталып алган чак иде шул, ачуланма!— дип үтенде.

Алар бик тиз уртак тел таптылар. Көлемсәр генә, утыз яшьләр тирәсе булган ул матур ханым сүзнеерактан уратып эзләп аптыратучылардан булмады, тел тегермәне сүзләр онын агызып кына тора. Җитмәсә, ир-ат халкын үз тирәсенә җыя алырлык ниндидер сөйкемле сөяге дә бар үзендә, беренче күргән кешене үк күзләренә каратып тота ала. Әмма өстендәге җитди киемнәре Айсылу ханымның тыйнак хатыннардан булуын да күрсәтеп тора иде.

— Гариф, Гариф!.. Кара инде бу каланы, көрткә чумып, карга-саесканнар тавышына эреп, йокыга киткән.

— Юк, Айсылу, монда гына шулай ул... Фән почмагы тынычлыкны ярата. Аннары, бу тирәдән машиналар йөри торган юлларны да ябып бетерделәр...

— И Гариф, Гариф... Ни булды сиңа? Элекләрне, исеңдәме, беренче тапкыр син мине озата кайтканда, нәкъ шушы урында, кала көрткә чумып, карга-саесканнар көтүен җыеп ята дигән идең, исеңдәме? Ә минем — истә, ул вакытта бу сүзләрең үземә бик тә кызык тоелган иделәр.

— Син мине ул вакытта шагыйрь дип атаган идең, Айсылу!..

— Исемдә... Син юл буе шигырьләр сөйләп кайттың. Ә мин көлдем генә, көлә идем... Ә син — сөйлисең... Мин көлгән саен тагын да күбрәк сөйлисең, ялгышмыйча, кычкырып-кычкырып...

— Эһ, шул вакытта туйдырып бетермәгән булсам иде... Шигырьләр үзләре

күңелгә килеп торганда, аларны бикләп яткыра алмыйм бит инде...

— Әй тел бистәсе!..

Гатауллинның кинәт борылып каравын сизеп алган Айсылу бу сүзе өчен үзен ачулана ук башлаган иде дә, Гарифны бөтенләй бүтән мәсьәлә борчуын аңлап алды. Тик үзе сорарга кыймады, Гатауллин да һични әйтмәде. Шулай да Гарифның, нидер уйланып, Айсылуының сүзләренә игътибар итмәвеннән, сораганнарына да җавап бирми калдыруыннан бу галимнең башында меңтөрле уйлар йөрүне аңларга була иде. Әмма Гатауллин ничектер тагын җиргә төште:

— Ни дидең әле?.. Ә, әйе шул, тел бистәсе! Ярата идем мин, Айсылу, ул кушаматны... Мин гомерем буе кешеләр белән сөйләшә белмәдем, ә шулай да, әйе, тел бистәсе буласым килә иде.

Айсылу ихтыярсыздан көлеп куйды.

— Ни сөйлисең, Гариф?.. Синең шигъри телеңә күпләрнең исе китә иде бит...

— Һе, Айсылу, алай булып чыкмады шул...

— Ярар, элек кузгатмасам, хәзер әйтәм инде... Бик ярата башлаган идем мин сине, хәтта гашыйк та булмадым микән әле үзеңә?..

— Айсылу, кара әле, нигә шулай рәнҗеттең икән син мине?

Икесе дә уйга калдылар, Айсылуның бөтенләй дә кәефе китте. Ул вакытларда Гарифны ул чыннан да рәнҗеткән иде шул...

Алар, әйе, матур гына йөрешеп киткән иделәр. Ләкин татулык никадәр ныклы булса да, аны шулай ук бик тиз генә җимереп тә ташларга мөмкин икәнне һич тә башларга сыйдырырга мөмкин түгел. Айсылу, көннәрдән-беркөнне, тотты да Гарифка үпкәләде. Сөйләшмәс һәм озаттырмас булды. Ни өчен?.. Бары тик кунакка, Айсылу чакырган җиргә бармаганы өчен. Шул гына. Әллә нәрсә дә түгел... Уйламаган, Гарифның кунакка йөрерлек мөмкинлеге юклыгын башына да кертеп карамаган. Ә Айсылу ул вакытта моны үзенчә аңлады, җитмәсә, кунакка барган җирендә аңа егетләр солтаны Зариф игътибар итте. Айсылуның беренче уе: “Миңа, Гариф, синнән дә яхшырак егетләр карый әле!”— булды. Кыш шушы ялганына тәмам ышанып узды, шуның аркасында хисләрендә адашып та калды. Ә егет солтаны ертык җан булып чыкты.

Инде менә хәзер, тагын да акыллырак булгач, бәлки ул вакытларны искә алып тору да кирәкмәгәндер? Әмма нишлисең инде, хәтерне юып ташлау кулдан килми икән шул инде!

Ә Гариф чыннан да рәнҗеде. “Син кирәк түгел миңа, без икебез ике төрле кеше, вакытыбызны бушка үткәреп йөрмә!”— дигән иде аңа ул вакытта Айсылу. Бер карасаң, һичнинди усаллыгы булмаган бу сүзләргә һич үпкәләргә дә кирәк түгел иде дә бит, хисләр дөньясына пычрак browkач,— җитмәсә кем әле, сөйгән кызың үзе, — күңел рәнҗи икән ул...

— Гариф, шулай да бер дөнья юләре булганмын икән шул!

Гатауллин эндәшмәде. Юк, үпкәләми дә, рәнҗеше дә беткән инде аның. Хәзер ул үзе аннан башка да бәхетле, гүзәле, Алсуы бар. Ә Айсылу... Ә Айсылу яшьлекнең чираттагы бер мавыгуы гына булган. “Юк, Айсылу, син үзеңне алай битәрләмә, нигә юри үз-үзеңне үртәргә маташасың?”— димәкче булган иде дә Гариф, бу сүзләренең урынсыз икәнлекләрен тоеп, бөтенләй дә башка нәрсәләр

хакында сөйли башлады.

— Айсылу, иске танышларыбызны күргәнегез юкмы соң?

— Бар... Дамирны күрдем. Ул хәзер бөтенләй үзгәргән, кырысланган. Өйләнгән булган, аерылышканнар, төрмәдә дә булып кайткан...

— Әйе... Нинди яхшы кеше иде... Ни өчен булган соң ул анда?

— Анык кына белмим... Сугышканмы, кеше акчасына кызыкканмы?

— Һич уйламассың... Ә башкалар... Гөлсинә... Үрнәк, Хафиз?..

— Юк, башкаларны очратмадым. Аннары соң, аларны исемнән үк чыгарып бетердем бугай инде, хәтта йөзләре дә хәтеремдә түгелләрдер кебек.

— Шулай инде, тормыш... Үзгәрәбез...

— Ә менә сине бик күрәсем килгән иде, Гариф. Бу тирәдән беренче тапкыр гына уздым түгел... Син ничек соң, Гариф?.. Өйләнгәнсең, балаң бар икән...

— Әйе, Алсу ул, исегездәдер?

— Истә!

Алар чатта тукталып калдылар. Хәзер юллары ике якка китәргә тиеш иде.

— Гариф, бәлки иркенрәк бер чак сөйләшеп утырырбыз? Безгә кил!.. Мин үзем дә... Үзем дә кызым... Кил, яме, менә адресым, тукта язып ук бирәм,— дип, Айсылу ничектер каушаудан кабалана башлады, сумкасыннан каләм алырдай итте.— Хәзер, менә хәзер... Язып бирәм... Килерсеңме?

Аның каушавы Гатауллинга тәэсир итте. Айсылуның кулыннан тотты. Бу хәрәкәтеннән үзе үк кыенсынып куйды, әмма аның кулын җибәрмәде. Саубуллашып:

— Юк, Айсылу, кирәкми... Тагын шулай туры килеп очрашырбыз әле. Язма! Кирәкми! Ярый... Ачуланма, Айсылу, хуш!— диде Гариф, аннан үз юлына таба атлады.

Гатауллинның чыннан да үткәнгә кире кайтасы килми иде. Ә Айсылуга ул узылган вакытлар ничектер кадерле кебек тоела иделәр.

Айсылу юл чатында ялгызы басып калды. Аның күзләре нигәдер тулдылар. Тик ул еламады. Бары тик хатын-кызларда гына була торган зур бер мыскыллану белән үпкәләде. Баштарак бу хисен ачык кына аңлап җиткермәсә дә, соңрак төшенде һәм үпкәсенең Гарифка түгел, ә яшьлегенә, кыз вакыттагы Айсылуга булуын үзе өчен ачыклады. Аннары, сөйләшеп утырырга дип чакыруы да юкка түгел иде аның. Үз итеп, элекке танышлары буларак тагын дуслашып китүгә ул һичбер каршы түгел иде.

— Әй Гариф-Гариф, нигә аңламадың син мине?..

Айсылуның елыйсы килә башлады. Аяклары баскычтан тиз-тиз югарыга таба ашыктылар. Ишекне ачты, өстәлдә рәсем китабы карап утырган кызына сыктавын сиздермичә генә урын өстенә ауды. Тиле яшьлегенә үпкәләп, үз тормышыннан, ялгызлыктан арып елады да елады Айсылу...

Уянып китсә, төн уртасы икән. Янында кызы йоклап ята. Галиясе. Әнисенә ияреп елаган-елаган да, үзе дә эреп оегандыр инде. Икәүләшеп күз яшьләренә күмелеп йоклаганнар.

Кызының битендә сызылып калган тозлы күз яшенең эзләрен Айсылу сак кына сөрткәләде дә, урынын җәеп, шунда илтеп салды. Аннары:

— И балам, балакаем!— дип сөеп алды.— Без бәхетле синең белән, бик

бәхетле — шулай бит!

Йокыдагы Айсылу тетрәнеп куйды, борылып ятты.

— И мескенем, елама, балакаем, елама!

Иртән бүлмәдә беренче булып Галия торды. Айсылуның, уянуга, исе-акылы китте. Сәгать инде сигез тулырга өлгергән иде.

— И балам, әйдә тизрәк, бакчага соңга калабыз бит,— дип, әле йокылы-уяулы күлмәкләрен алдын арка киеп маташкан кызын ашыктыра башлады.— Эшемә соңарам бит, әйдә инде!..

Әнисенең ашыгуы гына җитмәгән, аның кабалануыннан Галиясе дә каушап калган иде. Кулларыннан әле әйберләре коелды, әле яңадан йокысы килеп, аяклары аны диванга таба сөйрәделәр.

Алар ашыга-ашыга чыгып йөгерделәр. Айсылуның әле эшенә дә барып җитәсе, анда соңарганын ни дип акларга белми баш ватып аңлатма да язасы бар иде.

Ә тышта аларга исе дә китмәгән ак мамык кар акрын гына коелды да коелды, җиргә тыныч кына ята бирде.

4

— Бүген Гыйльми совет утырышы була, Сәлим Камилович. Гатауллинның фәнни эшен, гомумән дә фәнни позициясенә тикшерү үткәрәбез,— дип Исхаков шалтыраткач:

— Ярый торган эш, хуплыйм!— диде җавабында профессор.

— Сез дә кирәк булачаксыз...

— Ә-ә... Төп юнәлеш, минемчә, Гатауллинны яклау, аны күтәрү рәвешендә барыр, шулай бит?— дип сорап куйды Сәлимов, ничектер ышаныр-ышанмас килеш.

Исхаков эндәшмәде. Ул Сәлимов белән Гатауллин арасындагы каршылыкны белә һәм күрә килде. Аннары, Гатауллинны мактыйсы булсалар, Сәлимов аларга нигә? Моның өчен башкалар бар — Гатауллинны ут-күздән саклаучы Мәхмүтов, мәсәлән... Тагын... Исхаков башка галимнәрнең Гатауллин белән этле-мәчеле булуына сөенгәндәй елмаеп куйды. Мәхмүтовтан гайре кафедрада Гатауллин яклылар юк иде кебек. Хәтта ни либерал Исхаков та Гатауллинга тыныч күңел белән карый алмый. Чөнки белеп тора иде ул, мөдирлектән төшерелүенең беренче көнендә үк Гатауллин аны фәнсезлектә, ваклыкта тәнкыйтьләп чыгачак. Җитмәсә, ялгышларын бармак белән төртеп-төртеп күрсәтәчәк.

Телефоннан соравына җавап ишетмәгәч:

— Әллә, әллә “малайны” сикеренүдән туктатмакчы буласызмы?— дип тагын да сорап куйды Сәлимов. Әмма җавап ишетелмәде, бәлки:

— Сез килә аласызмы?— диде, кабатланып Исхаков, һәм, аңлатып тормастан, шушы соравы белән генә чикләнде.

Сәлимов килеште. Гыйльми советта булмаса да, кафедра әгъзасын тикшергән утырышларга шул коллективтан абруйлы берничә галимне чакыру институт өчен гадәти хәл иде. Дөресен генә искәрткәндә, узган гасырлардан ук калган бу чал институтта үзенә күрә генә гадәти саналган кануннар күп иделәр. Мөгаен шушындый үзенчәлекле яклары белән ул укытучыларын гына түгел,

каланы да серле һәм кызыклы итә. Шуның өчен бу уку йортын элек-электән бөек галимнәр ярата, язмышларын аның белән бәйли килгәннәр...

Исхаков креслосына ауды. Йөзенә тантана төсе кермәсә дә, җиңүгә ышануы билгесе булырга кирәк — тәкәбберлеге бермә-бер арткан иде. Аның төп бурычы — коллективны таркатусыз саклау. Моның өчен аның һәр кешесе бер уй вә охшаш фикерләр эчендә булырга тиешләр. Моны Исхаков ике икең дүрт кебек үк белә. Әмма аның акылы сизенгән тагын бер әһәмиятле әйбер бар. Аннан башка коллектив сүлпәнләнә, сүнә. Бу — арада бер яки ике керебеткән кеше булу!

Исхаковның фикеренчә, мондый кеше бары тик Гатауллин. Йомшак һәм тыныч күренгән, акрын һәм үз дөньясына чумган Гатауллин! Җыелышларда, утырышларда язгы боз төсле, тынычлыкны бозып, һәркемгә җан бирә торган Гатауллин!

Исхаков аны үзе генә, эченнән “Тиле Көч” дип атап йөртә. Тиле Көч! Һичкемдә булмаган ахмаклык сыман тоелырлык кирелекне һәм аек акылны җыйган көч. Тик ул көчне җигәргә, билгеле бер юнәлешкә кертеп җибәрергә генә кирәк. Исхаков үзен нәкъ менә бу яктан кирәкле зат дип уйлый, ул Гатауллинның тиле көченә йөгән салырга тиеш.

Кафедра мөдире ул бурычын да яхшы төшенә, ләкин, шул ук вакытта үзенең көчсезлеген дә бик яхшы белә иде.

— Хәерле көн!

Ишек катында Сәлимов күренде.

— Хәерле кич инде, Сәлим Камилович, хәерле кич...— дип суфийана гына сөйләнеп куйды мөдир. Ә уйларын бутап: “Иртәләгән әле бу, иртәләгән... Ит янына җыелалар... Яхшыга түгел бу, һич яхшыга түгел!”— дигән фикер узды, күзләре ачулы караш белән агач аякларын сөйрәп, тыйтаклый-тыйтаклый килгән Сәлимовны күзәтте.

— Ярый, мин дә килеп җиттем,— дип, Сәлим Кәримович мөдиргә кулын бирде.

— Утырыйк.

Бу сүзеннән соң Сәлимов түрдәге креслога барып урын алды. Аннары кулындагы вакытлы матбугатны актара башлады. Бераз киерелгәләп тә алгач, мөдиргә күз ташлады. Мөгаен аның йомышы булып та, үзе сүз башласын әле дип эреләнеп маташуыдыр? Тагын укыгандай итте. Гәҗит сәхифәләре бер-бер артлы кыштырдый бирделәр.

Әмма ул арада Сәлимовның түземлеге бетә барды. Ул:

— Гәҗит укырга да вакыт тими. Эш, эш, эш! Иртәннән эш, кичен эш!— дип, сүз башлагандай итте.

— Әйе-е, — дип сузды мөдир.— Эш!

— Аның шулай булуы яхшы, эш ул кешене яшәтә дә, яшәртә дә...

— Әйе,— дип тагын уена чумды мөдир. Бәлки ул шушы вакытта “нигә ике төрле сөйләнә икән бу кеше” диярәк әйтергә теләгәндер, шулай да Сәлимовны тагын бер кат сөзеп кенә баштанаяк карап чыкты.

Әмма Сәлимов сүзсез торучы кешеләрдән түгел иде. Ул яңа гына трамвайда булып алган көлкеле хәлне сөйләде, аннары яшь вакытларын исенә төшерде —

барыбер мөдирне үзе белән сүз алышырга мәҗбүр итте.

Инде алар Исхаков белән тормыш ваклыкларын бәйнә-бәйнә барлап, көлешеп утыра иделәр.

Гыйльми совет утырышка вакытында, төгәл җыелып бетте. Йөзләрендә шаянлык уты сүнеп җитмәгән чал профессорлар белән янәшәдә артык җитди яшь галимнәр дә җитәрлек иде. Кемгә бәхет кайчан елмая шул! Тик шунысы кызыклы, барысы да ничектер бертөслерәк, йомшаграк һәм салкынрак холыклы кешеләр икән. Дөрес, йомшак характер эчендә салкынлык булу мөмкин түгел дип, бәлки тормышны белеп җиткермәгән кешеләрдән кайсысыдыр әйтергә дә маташыр, әмма аның белән килешмәгез — нинди өлкәне адәм баласы белмәсә, ул шул яктан надан, ягъни аптыраулы була, шул мәсьәләргә килеп төртелгәнендә җаны боз сыйфатына керә...

Галимнәр арасында Сәлимов белән Исхаков ничектер югалып, сүрелеп калган кебек күренделәр. Сәлимовның белгән һәм таныган кешеләр белән зурлап кулын бирү, күрешү мизгелләре, билгеле, көлке белән бергә, күңелләрдә ул карт профессорны кызгану тойгысын да уята иде. Ләкин берни дә эшләп булмый, кешеләр үзләренә үзләре хуҗалар!

Арада иң тынычы Исхаков иде. Утырышта үзен ничек тоту һәм Совет алдында авторитетын кайсы яктан күтәрү кирәклеге хакында уйлавыннан бигрәк, коллектив язмышын кайгырту бәлки аның күңеленә зуррак мәшәкать булып яткандыр. Чөнки, бүген булмаса, иртәгә: “Сез үзегез нәрсә карадыгыз, сез үзегез?”— дип әйтәчәкләр. Ничек кенә әле! Өстәл сугып! Гатауллинның эшен яраксызга чыгарсалар, аның хезмәтен кирәксез санасалар — менә кайчан җавапны Исхаковның үзеннән дә алачаклар. Аның исендә, кафедрага мөдирлеккә сайланганында, үзенә үк: “Сез һәр буйсынган кешегезнең дәрәҗәсен сакларга, гыйльми юнәлешен һәм эш планнарын белеп торырга тиеш идегез!”— дигәннәр иде. Исхаков та белмәде түгел, белде. Булдыра алган кадәрле тырышты, хәтта булдыралмасын да ерып чыккандай итте. Ә менә хәзер — хәзер аның үзен дә җавапка тартырга мөмкиннәр. Шушы уйланулары сәбәбеннән мөдир һичкем белән гәпләшмәде, бәрелмәде һәм дау ормады, тыныч калырга тырышты. Аның үз коллективы хакында хәсрәте, бер яктан яхшыга, икенчедән, Исхаков үз шәхесе кайгысында, үз тиресен саклап калу белән мәшгуль иде. Чөнки урындагы һәр кешенең үзе хакында кайгыртуы коллективы турында уйлавыннан читтә түгел һәм — киресенчә, коллективын уйлавы да үзен барлавына бәйле. Һичбер вакыт да, мөдирен мактаганда, коллективын хурлап булмый, коллективының язмышын хәл итү ул — мөдиренә карата бәяләмә бирү. Башкача мөмкин түгел!

Исхаков уйларыннан айнып, инде эшенең нинди юнәлеш алырга мөмкин булуын да хисаплап, утырышка зиһенен тәмам хәзерлекле дип хис итте. Аның инде үзенә күрә программасы да юк түгел иде. Әгәр дә галимнәр Гатауллинны яклый башласалар, ул бары тик сөенәчәк кенә, тик монда һичбер шатланыр урын булмаслыгын да исенә алгач, Исхаков тагын уйга калды. Чөнки ул әлегә чарасыз иде. Сумалага төшкән кош төслерәк: канатын алса — коерыгы ябыша, коерыгын тартса — канаты. Әйе, дусты Шәүкәт бу хакта бик белеп язган икән. Ә Гатауллинны хурласалар, ул вакытта, билгеле инде, аны Исхаковның үзенә үк яклап чыгу кирәк булачак. Монда да берни эшләп булмый. Гатауллинның

методларын тәнкыйтьләгән, аның планнарын кире каккан, хәтта аны фантазер дип атаган кешеләрнең берсе шул әле ул!

Исхаков бу борчылуларының башына чыккандай булды, әле адашты, тагын бүтән планнар корды. Тик уена килгән соңгы фикере аның өчен иң кадерле иде. Эндәшмәскә! Сүз бирелгәнчегә кадәр актан да, карадан да эндәшмәскә. Уңга да, сулга да чәчелмәскә!

Уртаклыкта булу күп кешеләрне бәладән коткарып калган, андыйларны, ялгышып, акыллылар хисабына да кертә башлыйбыз. Бәлки дөрестән дә андыйлар акыллы буладыр? Әмма кеше көрәшми икән, ул инде акылы белән дан тота алмый. Фәндә гомумән дә шулай. Галим кешенең позициясе ачык һәм холкында үзсүзлелек булырга тиешле. Галим ул чын көрәшче, кайсы гына өлкәдә булса да — зур көрәшче! Идея өчен һәм дөреслек хакына көрәшче!

5

Гатауллин өйләренә бик кәефсез кайтып керде, туры үз бүлмәсенә юнәлде. Уйларының бер дә рәте-чираты юк иде.

...Алсу! Алсу һичбер вакытта да усал хатыннар хисабында йөрмәде. Кешегә ул начарлык тели торганнардан түгел иде.

— Гариф, кичке ашка... Гариф!

Алсуның кәефе яхшы иде булырга кирәк, ире янына елмаеп-шукланып килде дә, аны уйларыннан аерып, өстәл янына чакырды. Тик Гатауллин гына ашыкмады, һаман да үз хәсрәтеннән аерылып җитә алмый иде ул.

“Айсылу ни өчен аны эзләде икән соң? Гарифның аңа ни кирәге бар иде соң?”— Гатауллин үз-үзенә биргән шушы сорауларга җавап таба алмый аптырады.

Хатыны Алсу аны тагын бер кат чакырды, ашының суына баруын хәбәр итте.

— Нәрсә булды, Гариф?

— Белмим, үзем дә белмим шул. Кеше күңеле шулай инде ул, уйларының чытырманлыгына керә дә адаша, чума.

— Юк, Гариф, синең белән нидер булган? Нишләдең, Гарифҗан, ни булды?

Алсу иренә Гарифҗан дип гадәттә сирәк әйтә, шулай бик моңлы иркәлек белән дәшеп, аны уйлар баткаклыгыннан чыгара белә иде. Гатауллин моңа игътибар итәргә өлгерсә дә, борчулы йөзе тагын да сагышланып калды. Уйлангандай газапланды. Иркәләнергә маташуы кебек булып, бу тырышулары йөзенә чыгарга өлгергән иде инде.

— Юк, берни дә булмады!

Кешегә күңелен төшенкелеккә салырга күп кирәкми. Ир кеше хатынын юкбар белән борчый икән, ул адәм нинди ир була ди инде? Әмма Гатауллин бу хакта уйламагандыр, уйласа да, Алсуын билгесезлек белән борчуы аңа нигә кирәк? Белмим. Әмма ул бу юлы эндәшми калды. Ә Алсуы борчылуын сиздермәде, әллә ул аңа бөтенләй үк үпкәләгән иде, анысы да ачык сизелмәде. Алар кичке ашны да сүзсез генә ашадылар. Аннары һәркайсы үз бүлмәләренә кереп бикләнде. Мөгаен үпкәләшкән кешеләрнең бер-берсеннән гайрәте дә чигә торгандыр, шуңа алар үзара ерак булуны яхшыга саныйлардыр?

Гатауллин эш өстәле янында утырганында фикерләрен бик озак бер төенгә тупларга тырышса да, аларны чишә алмый газаплана бирде. Ул бер ноктага текәлгән халәтендә кала бирде. Мондый вакытта бәлки аны фикер очын югалткандыр дип уйларга да мөмкин, тик монда эшнең асылы бу түгел иде булырга кирәк.

Гатауллин өстәл яныннан, бернәрсә дә майтара алмый, ачып-ачып караган китапларын бер почмакка өеп, диванына барып ятты һәм йоклап та китте.

Иртән, әле йортта һичкем тормаган вакытта, Гатауллин үзенең гыйльми эшләренең отчетын язып бетергән иде. Бәлки шунда гына күңеле ачылып киткәндер, бәлки тагын да яшәү рәхәтен татыгандыр, ул соңгы ун елга якын гомерендә беренче тапкыр үз теләге белән кухняга таба юнәлде һәм аш әзерли башлады...

Менә хәзер ул үзенә чыгарылган хөкемне көтеп утыра. Ни диярләр? Ике сүзнең берсе бөтен эшләрне хәл итә: яки “ярый”, йә “юк”! Ләкин утырыш барышында ике төрле фикерләр күбрәк кабатландылар. Соңгы сүз итеп Кәримов:

— Билгеле, Гариф Гафуровичның эшләре кызыклы, ләкин дә төп нигезе дөрес түгел дип әйтер идем. Аннары, мондый юнәлештәге тикшеренүләргә иртәрәк тә бит әле, иртәрәк...

Шунда аның сүзләрен Исхаков бүлдереп:

— Гомумән бу эшләрендә бернинди материалистик нигезләр юк,— дип үзенең туксанын тукырга кереште.— Бу — тулысынча идеализмга корылган ниндидер бер фантазия. Тавыш дулкыны белән яктылык нурының материал чыганаклары да бөтенләй үк бер-берләреннән аерылып торалар... Моңа игътибар итәргә кирәк иде... Моны бит мәктәп баласы да белә һәм аңлый...

Сүзен бүлдергәне өчен аңа Кәримов ачулы йөз белән карап куйды, тегесе, гафу үтенгән төсле, “бетте-бетте” дигәндәй ике кулын да күтәреп, нотыгыннан тукталды.

— Шулай итеп без, Гатауллинның бу юнәлештә тикшеренүләр алып баруын кирәксез саныйбыз һәм... һәм аның студентларны укыта алырлык булуына...— Кәримов бу җөмләсен тәмамлауны кирәк тапмады булырга кирәк, шунда ук икенчегә борып җибәрде:— Гатауллин үзендә безнең уку йортында эшләрлек көч сизәме икән?— диде.

Шушы соравы белән утырышның бу өлешен тәмамлап, Гатауллинның язмышын ачык калдырган хәлдә икенче мәсьәләгә күчтеләр. Гариф Гафурович инде азат иде. Хәзер аңа кая китсә дә була. Аны хәзер институтта да тотып тормыйлар. Әнә бит, ачыктан-ачык әйттеләр: синең кирәгең юк!.. “Туктагыз, нишлисез? Минем фантазиям белән лекцияләрем арасында нинди бәйләнеш бар? Йә әйтегез? Нинди бәйләнеш бар?”— Аның акылы шашына иде.

Гатауллин өчен менә шушыннан соң иң авыр тормыш башланды. Аңа ышанмадылар. Юк, ышанмау гына түгел, аны юк итеп, таптап-изеп ташладылар. Эт урынына шул, эт урынына. Кешеләр, нинди мәрхәмәтсез җаннар сез? Нигә дип бер-берегезне егасыз, берегезгә-берегез аяк чаласыз? Бәлки сез шулай һәркайсыгызны көрәшкә лаеклы түгелме дип тикшерәсез генәдер? Бәлки сез моны бары тик тормыш кызыклырак булсын өченгә шулай эшлисездер? Ке-

шеләр! Сез тормышны бары тик үзегез генә катлауландырасыз. Нигә кирәк ул алай итү, нигә?

Менә хәзер Гатауллин: “Хатыным, мине эшемнән кудылар, юк, очырдылар, изгәләп-чәйнәп ташладылар”,— дип ничек, нинди йөзе белән кайтып әйтсен ди? Юк, нинди йөз белән шулай кайтып әйтергә мөмкин? Мине эштән кудылар? Моны әйтергә нинди батырлык кирәк! Ә бит ялганнарга да ярамый. Гомумән, ялганлау ул үзе бер авырлык, җан борчуы гына тудырачак. Ялган элек-электән бәхетсезлек чыганагы булган. Нигә кирәк бәхетсезлекне арттыру, нигә?

Әмма Гатауллин өйләренә кайтмады. Ул Айсылуларга барып керде. Ачулы һәм борчулы йөзе белән, әллә кайгысын сөйләргәме, әллә “миннән көлдегез, мин дә башкалардан көлә белермен” дипме, әмма барды да керде (барыбер түгелмени?).

Айсылу әүвәле аптырабрак калды. Аннары ничектер җанланып, акылы айнып киткәндәй булды

— Абау, ничек болай килергә булдыгыз?— дип әйткәнен үзе дә сизми калган иде булса кирәк, шушы гади һәм беркатлы сүзләреннән көлеп үк куйды.— Чынлап әйткәндә, мин сине көтмәгән идем... Юк, көткән идем, нәкъ менә бүген үк килерсең дип көткән идем.

— Ничек, Айсылу? Көткән идеңме, көтмәгән идеңме? Кайсы дөрес?

— Дөрес дип, тегесе дә, бусы да,— дип тагын шаярткандай итте Айсылу.— Ә шулай да мин сине көткән идем, килеп чыгып дөрес иткәнсез!

— Айсылу, әйдә яки син, йә сез дип кенә сөйләшәбез. Әле бусын, әле тегесен әйтеп түгел!

— Юк, тегесен дә, бусын да... Гариф, нигә болай усалландың?

Айсылу, йөзенә борчылу чыгарып, Гатауллинның күзләренә дикъкать белән карап торды.

— Әллә чәчләрең дә агаралар инде? Ә син нинди идең, исеңдәме? Шаян, үзсүзле һәм яшь идең.

— Айсылу, син дә, ачуланма, әбиләрдән түгел идең!

Ханым мондый ук тупаслыкны көтмәгән иде булырга кирәк, креслосында шым булып уйга чумды. Аның йөзенә карап, ачулы яки шат булуын төшенү кыен иде. Шулай да кешене уйга калдыра торган сүз сөенеч кәлимәсе була алмый шул... Икенче креслодагы Гатауллин да борылгалап алды.

— Бәлки шахмат уйнарбыз?

Бу сүзе көлке һәм мәгънәсез иде. Гариф Гафурович өстәлдәге шахмат тактасына күрсәтте:

— Ягъни... Мин әйтәм, әллә шахмат уйныйсызмы? Мин дә бик яратам ул уенны. Балабыз теңкәмә тиеп бетте инде, уйныйк та уйныйк, ди, ә минем вакыт юк. Ял көнне Хафиз килгән иде, хәтерлисеңме, шагыйрь, бездән бер ел укуын иртәрәк бетерде. Менә шул килгән иде. Шундый үзгәргән, хәзер танылган шагыйрь икән. Шулай дип белдерде. Ике-өч шигырь җыентыгын чыгарырга өлгергән. Берсен миңа калдырып китте. Менә, аның белән сөйләшеп утырганда, син романнар язасың бугай, мин әйтәм. Юк, ди. Мин бит шагыйрь кисәге, ди. Белмим, башыма ул каян прозаик булып кереп калган дип баш катырдым. Ә моның җавабы бик гади икән: “Җил роман” дигән исем астында кайчандыр ши-

гырьләр чыгарган булган. Менә ул ничек! Үзе дә үпкәләмәде ичмасам, миннән кычкырып кына көлде.

Гатауллинның үзенчә дусты шагыйрь Хафизның акыл сайлыгына ишарә итеп алуы иде бугай, моңа үзе дә сагаеп калды һәм, тынып, Алсуга текәлде.

— И-и, һаман да шул ук Гариф икәнсең син... Һаман шул ук... Юк, мин сиңа үпкәләмәдем... Усал син, Гариф... Юк, син түгел бу, Гариф... Нигә безгә килгәндә генә үзеңне урамда калдырып керәсең син, Гариф, ә?.. Нигә син минем белән шулай үчләнәсең? Минем ни начарлыгым тиде?

Алар уртак сүзгә килә алмадылар. Икесенең дә кәефләре юк иде. Аны таба да алмадылар. Гариф юл буена үзен мескенгә, үле җаннар хисабына санап кайтты. Икенче көнне дә аның бу хәләте чигенмәде. Өченче көнендә дә... Гатауллин тәртәләрен җыеп, моңаеп һәм сагаеп калды. Аңа авыр, бик тә авыр иде булса кирәк.

6

Айсылу шушы Гатауллинның күптәнге танышы иде, ничә еллар инде аны оныта алмыйча газапланды. Белмим, ничек шулай булгандыр, араларындагы яшь аермасына да карамастан, бер-берсенә үлеп-бетеп гашыйк чаклары да бар иде аларның.

Җәй көне, айлы кичтә, авыл урамында таныштылар. Җиләсрәк вакыт һәм яшьлектәге ниндидер бер самимилек белән тулган чаклар иде бу. Гатауллин Айсылуны капка төпләренә үк озата кайтты ул кичне...

— Тормыш-тормыш!.. Белмисең син үзеңнең гүзәллегеңне, сизмисең! Айсылу, телисеңме, мин сиңа күктәге йолдызларны үрелеп кенә алып бирәм, телисеңме?.. Ә юк, телисеңме, мин сине айга мендереп куям?.. Син бит ай кызы — Айсылу!

— Телим, Гариф, хәзер үк телим!

Алар менә шулай әүвәле уртак хыялга килделәр, аннары... Ә аннары уртак гыйшык утына чумдылар. Берсенә унсигез яшь, икенчесенә — егерме ике! Алар берсен-берсе яратканны, көннәр буе бер күрешергә юксынып йөреп, кичләрен үбешеп туймый торган ярларга әверелеп китүләрен сизенми дә, аңламый да калдылар. Хәтта икесенә дә:

— Элекләрне сез бер-берегезне белми дә идегез,— дисәләр, бу сүзләргә һич ышанмас та иделәр.

Гариф көн дә кич җитүен зарыгып көтеп ала һәм, инде эңгер-меңгер төшә башламас борын, күңелендәге барлык борчуларын ташлап, мәгъшукасы, дөньяның иң-иң гүзәл җан ияләреннән булган сылуы янына ашыга иде. Кыз да аны көтә, ялындырып кына, Гариф инде үчекләнеп башын иеп моңлана, зарыгудан көйгән күмергә әверелә башлагач кына, әкият дөньясыннан чыккан төсле пәйда була иде. Һәм алар ничектер, әүвәле тартынып кына исәнләшә иделәр:

— Исәнме, Айсылу! Менә, мин килдем әле!

— Исәнме, Гариф! Мин дә чыктым әле!

Алар җитәкләшеп алалар, иреннәренә иреннәрен тидерәләр һәм икесе дә, бу дөньядан югалып, башка тарафка — хисләр иленә кереп адашалар. Кичләр буена шулай йөриләр. Бар булган сөешүләре иркәләшү-үбешүдән узмый: алар

Җирнең иң бәхетле балалары иделәр.

Җәй сөю-сәгадәт эчендә сиздермичә генә таң аткан шикелле узды да китте. Үзе белән бергә хисләр дөньясын да алды. Бөтен авыл өчен сөйләшер бер сүз булды:

— Гариф белән Айсылу...

— Яратышалар икән...

— Чү, аларның берсе әле яңа гына калада укый башлады, икенчесе, бетереп, эшенә китеп барышы... Булмаганны!

Әйе, булмады түгел, булды. Алар чын сөю белән сөештеләр. Ә кыз яшькә өлкәнрәге иде! Ләкин иң аянычы бу түгел әле. Мәхәббәт гомумән аянычлы була аламыни ул? Сөю — сәгадәт, ә сәгадәт ул — бәхет!.. Иң аянычы соңрак булды.

Айсылу нигәдер Гарифның мәхәббәте чын булуга тулысынча ышана алмады. Чөнки ул аннан, искәрткәнебезчә, олырак яшьтә, өлкәнрәк кыз иде. Аңа егерме ике яшь шул! Айсылу үзенең Гарифтан дүрт яшькә олы булуын бары тик эшкә киткәч, эшли башлагач, боегып, Гарифны сагынып утырганнарында гына исенә төшерде. Хәтеренә китерде дә калтырап ук куйды: унсигез яшьтә адәм баласында сабыйлар мәхәббәте генә була шул әле ул!

— Сабый!

Гариф мондый кушамат алуга лаеклы кеше түгел иде дә бит, ләкин Айсылу өчен ул бары тик сабый, сабый гына икән!

Җәйнең кояшы сүрелеп, агачлар яфрак койдылар, җирне беренче ак кар, тәүге бураннар каплады. Алар гүяки кызның күңелендәге хисләр аланын да күмделәр. Айсылу барын да аңлатып Гарифка хат язды. Дөресен генә әйткәндә, хаты да, искәрергә кирәксә, ике сүздән генә гыйбарәт диярлек мәктүпләрдән иде:

“*Гариф, без бер-беребездән ерак кешеләр. Без бергә була алмыйбыз!*”

Эһ кызлар, кайвакытта нинди мәрхәмәтсезләр сез! Әгәр дә ирләр аз гына булса усалраклар икән, димәк, алар рәхмәтегез илә шулай, ягъни алар каты бәгырьле булулары белән сезгә бурычлылыналар! Һәрхәлдә мин моны шулай дип беләм.

Ни генә дисәк тә, егет халкы бераз кирерәк һәм үзенә карата таләпчәнрәк була ала ул. Ә мәхәббәте аңа башын суларга салдыра, йөрәге сөйгәне янына чакыра, ашкындыра. Менә шулар икесе, ягъни мәхәббәт белән усаллык, мөгаен тәвәккәллек шулардан киләдер, аның нисбендә бергә кушылалар, көчлерәге, билгеле — мәхәббәт инде, җиңә, ләкин вакытлыча гына. Чөнки гыйшык яман утка әйләнгәч, кеше бу ялкыннарны җиңәрлек чара эзли башлый, аны күңел каберлегенә күмәргә тырыша.

Гариф та шулай итте. Үзен җиңәргә, мәхәббәтеннән өстен чыгарга тырышты. Әмма кайвакыт шушы изге көрәшеннән күңеле айнып китә иде дә, ул тагын да тирәнрәк чоңгылларга, ярсу упкыннарга барып төшә иде. Эһ-һ авыр ла шул, бик авыр сөйгән ярыңны онытырга теләүләр, сөюдән качулар бигрәкләр дә читен шул...

— Исәнме, Айсылу!

— Ә-ә, синмени әле бу? Нишләп йөрисең монда?

— Айсылу, нигә шушы кадәр мәрхәмәтсезлек?

— Юри генә!

— Сынар өченме?

— Белмим, мин синең бу хисләреңә һәм барысына-барысына да ышанып җитмим.

Аяк асларында кар шыгырдый, гүяки басмагыз миңа, измәгез мине дигәндәй үксеп-үксеп елый.

— Айсылу, тилесеңме, мин үзгәрәм? Гел яхшы якка гына. Моңарчы мин һәркемне үз итә идем, бар кешеләр дә миңа якыннар сыман иде, кызлар да үз иделәр...

Гариф сөйләнә, гүя барысына үзе ул гаепле, аның кешелеккә карата булган изге тойгылары аның күңелендә каршылыклар тудыра.

— Юк... Ышанып бетмим мин сиңа!

Алар берничә тапкыр шулай сөйләштеләр һәм бүтән, менә шушы соңгы көннәргә кадәр бер генә тапкыр да очрашмадылар. Гариф аны кайвакытта исенә төшергәли, әмма хәзер инде элеккеге гүзәл җәй кызы сурәтенә, яшьлектәге ай сылуы буларак кына күңелендә утырып калган, үтелгән истәлекләренә җан өрә. Әмма ул тойгылары никадәр тирән булсалар, алар шулкадәр ерактарак һәм яшьлектә үк калдылар. Гомер үтә бирде, Гариф җитәрлек дәрәҗәдә үзен-үзе тотарга, мәхәббәткә алай ялгышып ышанмаска, гомумән дә сөюнең дошманы булуга кадәр барып җитә язды. Һәм менә аңа Алсуы очрады: гүзәлләрнең гүзәле иде ул кыз! Алар кавыштылар. Тормыштан сәгадәт җимешләрен бергә җыя башладылар. Тик бәхет-шатлыкларның очкыннары җаннарын озак җылыта алмады, яшәүнең дәвамы булган кайгы-хәсрәт төтене аларның күңелләренә үзенең корымын да койгалады. Һәм озакламый күңелләре тәмам буталып, бәхеткә дә, кайгыга да исләре китми башлады. Чөнки аларның күңел казаннары юшкын белән капланып, инде хисләре тупаслана бара иде. Мөгаен Гарифның күңеленә ком иртәрәк утыргандыр, ни генә булмасын, Алсу кебек итеп ул матур һәм самими җиңеллек белән ярата белмәде. Аның сөюе бары тик изге гаиләгә тугрылык хисе аша бәйләнгән бирелгәнлек, үзеңнең кемнеке булуыңны адым саен тою, соңга таба инде гүзәл истәлекләр эчендә яшәүче дөньялык мәхәббәте иде. Мондый хис һәм тойгылар бүтән төрле гашыйк утларыннан изгерәк һәм данлырак булулары белән аерылып тора. И мәхәббәт, күп кешеләрне үзгәртеп, аларда яшәү рухы кабызасың, ә кайберәүләрне бөтенләй дә таптап китеп барасың. Син изге булсаң да, мәрхәмәтсез — йөрәкләрне утта яндырасың!

...Ә Айсылу Гарифка ышанмады. Дөньяга ул үз сәер күзлеге аша карады. Чөнки ул шул җәйне, институттан соң, авылда, әбиләрендә ял итте, шаярып, романтиканың соңгы талпынуы буларак юри генә Гариф исемле яшь егетнең башын әйләндерде. Уеннан уймак чыкты. Егетне аптырата торгач үзе дә яккан учагына чолганып калды. Гарифны хәтта каладагы Искәндәреннән дә ныграк ярата иде бугай. Гариф белән күңелле һәм рәхәт иде аңарга, каланы да, һәрвакыт нидер таләп иткән Искәндәрен дә оныткан иде Айсылу. Ләкин бу шуклыкларының тамыры тирәнгә китте — Гариф аның колына әверелде! Айсылуга бу егет ничектер ятим төсле, кызганычрак иде. Шулай да бу хисләрен җиңде, ул

миңа лаеклы түгел дип, акрынлап-акрынлап күңеленә акылы аша аңлата торгач җиңде. Менә шул вакытларда Айсылу үзен көчле рухлы, дөньяда бәхет белән яшәргә сәләтле итеп тойды. Мондый исәпләре аңа яңа дәрт биреп тора иде. Искәндәре дә аны ташламады. Үз таләпләрен арттырганнан-арттырды. Алар өйләнештеләр. Гариф онытылды.

Эһ, белсәгез иде ике ярның бергә булу шатлыкларын. Тик аларның яшьлек чәчәгенә, сәгадәт гөленә көзге кыраулар бик иртә төште. Елдан артык яшәделәрме-юкмы, инде бер-берсенә үпкәләшүләре, бер-береннән җәбер-золымнар күрүләре ешайганнан ешайды. Искәндәре дә эчкечелекне хуш күрә башлады. Мондый көннәрдә Айсылу аны җан ачысы белән каргый һәм үзендә яшәүгә ышаныч артсын өчен ниндидер бер өмет йолдызын эзли иде. Тик андый йолдыз калыкмады, йөрәк яраларын савыктырыр, аһ-зарларын тыңлар кешесе бик озак еллар табылмады. Шулай да үзенә тәэсир итеп торган кемнеңдер күңел җылысы барлыгын һәм аның якында гына икәнлеген сизенә иде ул. Әйе, ул кеше — алданган Гарифы, мескен Гарифы, көлке Гарифы иде. Айсылу Гарифның аяк астына барып егылса гына үзенең ямьсез һәм шыксыз тоелган гаилә бәхетсезлегеннән котыла алыр төсле иде. Әмма көннәр элеккечә ваемсыз уза бирделәр. Кызы Галияне алып кайткан көннәрендә ул тагын да Искәндәре өчен яши башлаган сыман иде, ялгышты. Ире ниндидер серле вакыйгалар белән чуарланган кара йомгакка уралып һәлак булды. Күршеләре:

— И эчә иде дә инде!— дип сөйләнделәр.

Тик соңыннан гына йомгак чишелеп, сере ачылып китте: Искәндәрне сөяркәсе үтерткәне мәгълүм булды. Әмма бу яңалык Айсылуның гына бәгырен өзде. Бу бәхетсезлекләрне ул Гарифны рәнҗетүе өчен башына төшкән бәла дип фараз кылды. Һәм бөтен булган теләге — Гарифтан гафу үтенү, аннан рәхим-шәфкать сорау иде. Әмма Галиясен тәрбияләү белән янып йөргән ана, озак та үтми, Гарифны да онытты. Мәрхүм иренә булган ачуы һәм үпкәсе дә сүрелеп беткән иде. Алар — кыз белән ана, һәрвакыт ике дус, бер-берсенә таяныч булдылар. Ә соңгы вакытта, каладагы берничә шәфкатьле гаилә белән танышып алгач, ир бәхетенә чумган ханымнарны күргәч, аның да табигый хисләре тернәкләнеп, йөрәген хисләр өермәсе яндыра башлады. Мондый дәрт-дәрманнан ялны ул бары тик Гариф турындагы истәлекләрендә генә таба иде.

— Гариф! Гарифҗан! Гатауллин!

Хатын кыз йөрәгенә утны яңарту өчен күпме генә май тамызу кирәк: “Мин сиңа, телисеңме, йолдызлар бүләк итәм?..”

— Телим!

Айсылу хатирәләрендә сакланып калган һәм хыялында кабат яши башлаган Гарифка ышана, аның сөюенә бирелә башлады. “Кая икән ул сабый?”

Алар очраштылар. Монысын Айсылу үзе теләде!

Аннан тагын очраштылар. Бу юлы аның янына Гатауллин үзе килде. Борчу өстенә борчулар алып. Әмма аларны бу очрашулар кавыштырмады...

Гариф киткәч, Айсылу озак кына сүзсез утырды, ә аннары үзе дә чыгып йөгерде. Кышкы салкын караңгы урамны урталай ярып:

— Гарифҗан!— дип аваз салды.

Гатауллин, үзен чакыралар дип бугай, җиргә терәлердәй булып салынып

төшкән башын күтәргәннән соң, адымнарын акрынайта төшеп, як-ягына каранып куйды. Әллә Айсылуны ишетте, әллә юк: барыр юлын дәвам иттерде.

Шушы төн уртасында урам буйлап атлаган какча күләгә Айсылу өчен бик якын һәм кызганыч иде. Ул, сизенмәстән, үз хәсрәте янына Гатауллин кайгысын да кабул итте...

7

Адәм балалары өчен иң күңелле булган нәрсәнең ни икәнлеген сизенмичә, кайгыларына да игътибар итеп тормастан тормыш үз җае белән бара, үзгәрә, үзенчә хәрәкәт итә торды...

Быелгы кышның бер куандыра торган ягы шул иде — ул салкын тоелмады. Мондый җылы декабрьнең сәбәпләрен гәҗит-журнал укып баручы акыллы башлар Мексикада күп вакытлардан бирле гөрләп утырган вулканның тәэсир галәмәтеннән күрделәр. Имеш, бу утлы кыя үз эченнән меңнәрчә тонна лава һәм һава корымы чыгарып ташлаган. Ул тузан, ком һәм корым Җир шарын спираль рәвешендә әйләндереп алган, стратосфера аша җиргә таба җылы һәм суыкны кертми тора икән. Икенчеләр, шалтыравык сүзләрнең коллары, бу галәмәтләр космоска очулар аркасында, бөтен күк йөзен тишекләндереп бетерүләре сәбәпле дип раслау ягында торалар иде. Ләкин кемнең ничек әйтүенә дә карамастан, кыш чыннан да җылы килде. Һәм бу аның безгә биргән бердәнбер сөенече дә иде. Чөнки кар-бураннарны яраткан Рәсәй халкы янында яшәгән татарларда җылы һава сөяк сындырмый иде. Шулай да кичкә таба кинәт кенә суытып та куйды. Тайгак сукмаклардан шугалап бала-чага йөгерешеп узды, карт-корылар аякны саграк басу ягын карадылар. Ә боларның барына да гүя читтән, кабинет пәрдәсе аша гына вакыт-вакыт Мөхәррәмов карап торгалый иде.

Мөхәррәмов димәктән, ул буйга әллә ни озыннардан булмаса да, үзенең ак бәсләр кунган чәче һәм киң маңгае аркасында кешеләрдә үзе хакында бик яхшы уйлар калдыра иде. Йөзенә кышның салкын бураннары, көзнең бозлы яңгырлары тимәгәнгәдер, ул чиста һәм җыерчыксыз иде. Ә шулай да кайбер көннәрендә сәгатьләр буена кабинетыннан чыкмый. Эшләп утырган чакларында күз төпләре салынып, гәүдәсенә еллар авырлыгы иңә иде дә, Мөхәррәмов нәкъ картлар кыяфәтенә кереп кала. Әмма бу вакытларында да аның йөзеннән сирпелеп торган акыл көче китми, чалымнары шул килеш үзгәрмичә кала иде.

Мөхәррәмов авыл малае буларак үсте. Үзенең министр дәрәҗәсенә менеп ирешүеннән соң да әле һаман, вакыт-вакыт, ташу суында салам саллар яндырып йөрүләрен — барысын-барысын да оныта алмый иде. Шуңа күрәдер дә аңа кай вакытларда шушы кысан кабинеттан чыгып, киң басу-кырларны аркылыга-буйга иңләп йөрисе килә торган булуы гаҗәпләнерлек түгелдер. Һәм ул мондый хисләрен һичкемнән дә яшерергә уйламый иде, җитмәсә. Кала кешесе булган хатыны Миләүшә ханымга кичләрен, ә кайвакытта озаклап ук шул малай чаклары хакында бәйнә-бәйнә сөйли торган иде. Хатыны иренең бу гадәтен күптән белгәнгәдер инде, аның хатирәләрен ахырына кадәр тыңлап бетереп, һичбер вакыт бүлдерми торган иде. Һаман бер үк сүзләрнең һәм вакыйгаларның кабатланулары бәлки Миләүшә ханымны туйдырмый да торгандыр, бәлки яра-

ту, иренә карата булган ихтирамы аңа итагатьлек бирәдер, монысы хакында Мөхәррәмовның уйлап та караганы юк иде.

Алар сүзне күпчелек өстәл янында, аш артында гына сөйләшеп бетергәнлекләре сәбәпле, калган вакытын Мөхәррәмов гәҗит-журнал караштыруга, китап укуга тота иде. Ә эше хакында бер вакытта да киңәшмәгәнлегенә күрә, тора-бара аның бу сыйфаты Миләүшә ханымның да гадәтенә әверелде — аларның сөйләшер сүзләре бары тик яшьлек һәм балачак хатирәләре генә булып калды. Тора-бара бу сүзләр арасына балаларының сабый һәм яшүсмер чакларын искә алулар да килеп кушылды. Шулай итеп бу гаилә бары тик истәлекләр белән генә яши иде.

— Керегез, кер!

— Көттердем, ахрысы?

— Юк, зарарсыз... Көттермәдегез, киресенчә, миңа азрак җәелеп эшләргә мөмкинлек кенә бирдегез.

Мөхәррәмовның кабинеты ишегеннән узган Кәримов һаман да ишек катыннан түргә таба үтмәде. Кулындагы портфелен куярга урын эзли иде булса кирәк, ә анысын сәркәтип кыз янында ук калдырып керергә мөмкин иде.

— Куегыз шунда, үтегез!

— Рәхмәт, Назыйм Харисович, рәхмәт сезгә!

— Әйе-әйе!

Кәримов үзенең портфеленә ниһаять урын тапты: өстәл янындагы урындыкларның берсенә куйды.

— Назыйм Харисович, хәлләрегез ничек соң? Миләүшә ханым бер дә күренми, шул килешме соң, яхшы гынамы?

Алар күптәнге танышлар иделәр, тик якын дуслардан гына була алмадылар. Чөнки Кәримов яшьлегендә Миләүшәне ошатты, Назыймга кияүгә чыккач та, Миләүшәгә берничә тапкырлар үзенең кулын һәм йөрәген тәкъдим итеп, тормышның гөлле бакчаларында гына яшәтәчәгенә антлар итә иде. Тик ханым андый буш һәм купшы сүзләрне кабул итмәде, әллә Кәримов бөтенләй дә аңа ошамый идеме, адашмады-ялгышмады. Билгеле, моны Мөхәррәмов үз вакытында белми калды, әгәрем ки сизенгән-ниткән булса, йөрәгендә кайнаган егетлеге белән, галим-голамә кисәге булган шушы Кәримовны ни эшләткән булыр иде, билгесез. Чөнки Миләүшә ханым бу хакта бервакыт көлке хәл итеп сөйләгәч, инде өлкәннәр яшенә җитүенә карамастан, акылына буйсынган ир кеше, ашаган җиреннән торып, тәмам кәефсез калган иде һәм, кайвакытта, Кәримов исенә төшкәндә, ничектер күзләре дә шашынып алгандай итә иде. Моның нилектән алай икәнлеге соңыннанрак беленде: Кәримов кеше хатыннары белән шаярыша, бигрәк тә дуслары-танышларының тормышларын бозгалый, аларга шулай күп зыяннар да китерергә өлгер булып чыкты. Тик аның мондый начар гадәте барлыгын күпләр, бик күпләр күрми һәм белми калганда, моны бары Мөхәррәмов та очраклы рәвештә генә ишеткәләгән иде. Әүвәле аңа боларны исерек баштан, бер бәйрәмдә Кәримов үзе сөйләп ташлады, дәрәҗәдә үсми калуын шуның белән аңлатты, ә аннары, озак та үтми Кәримовның ул Миләүшә тирәсендә бөтерелгән чагына туры килде. Кәримов үзенең Мөхәррәмовка кайчан нәрсәләр сөйләгәнлеген исеннән бөтенләй дә чыгарган

иде булса кирәк, юкса Миләүшә килеп сарылырга маташмас иде.

Озак та үтми Кәримовның үзе белән дә нидер булды, ул боегып калды, аннары, берара бик тә эшлеклеләнеп китте. Тик ни хикмәттер, һаман аның ишеге тактасындагы язуда “зав.” түгел, “зам.” гына иде. Ә шулай да ул да көннәрнең берендә үсә алды. “Зам.” гына килеш калса да, барыбер күтәрелде, дәрәҗәсе дә артты. Шулай да чир китә, әмма гадәт кала диләр, ул һаман үзеннән югарыларга үтемлерәк булу өчен хатыннары аша тәэсир итүне мәгъкульрәк күрде. Менә Мөхәррәмовка килер алдыннан әүвәле Миләүшә ханым белән ике көн элек кенә Кәримовның сөйләшеп куюын Назыйм Харисович яхшы хәтерли иде.

Кәримов бу юлы да иркенләп утырырга ниятле иде булса кирәк, бик озаклап, кирәкмәгән эш-хәлләр хакында гәп корырга маташты. Аннары, Мөхәррәмовның канәгатьсез йөзен күрепме, төп йомышына күчте:

— Назыйм Харисович, бездә бер бик кызыклы утырыш булып алды әле. Хәтерлисездер, әйе, Гатауллин... Шул. Аннан күп кенә иптәшләр риза түгелләр. Сүз хәтта аны эштән азат итү хакында да барырга мөмкин.

Кәримов, сүзләреннән туктап, Мөхәррәмовның нидер әйтүен көтте. Ләкин Назыйм Харисовичның аңа текәлеп карап утыруын күреп, сагаеп кына дәвам итте:

— Билгеле, без аны җиренә җиткереп үтәрбез дип ышанам... Бу минем генә фикер түгел... Дөресен генә әйтсәк, монда минем һичбер катнашым юк!

— Нигез?

Кәримов, бу сорауны ишетүгә, сүзеннән кинәт бүленеп, тотлыгып алды:

— Нэ-нэ-ни-ничек? Нэ-нэ-нинди нигез?..

— Юк, сүз ул хакта түгел, эштән ни өчен аласыз дим?

Кәримов өстәлдәге графиннан су капты, тотлыгуыннан тукталып, елмаеп ук куйды.

— Сез ул хакта икән... Нигезе шул — Гатауллин безнең фәннең төп нигез ташларын какшата, юк проблемалар белән, файдасыз тикшеренүләр белән мәшгуль...

— Ә нинди мәсьәлә соң ул, нинди өлкәдә эшли?

— Төсле музыка... Теориясенең нигезе — тавыш дулкынын яктылык нурына үзгәртү... Үз теле белән әйтсәк, күзсезләрне колаклары аша күзле итү, колаксызларны күзләре ярдәмендә колаклы итү... Ягъни, тавыш дулкынының яктылык нурына тәэсире мәсьәләсе... Менә шундыйрак, ике яклы, буталчык, нигезсез проблемалар эчендә кайнаша ул.

Мөхәррәмов, бераз уйланып утыргач, беренче тапкыр Кәримовка үтә ягымлы караш ташлап:

— Ә шулай да, минемчә, коллективны бозмыйк... Ашыкмыйк, бераз сабыр итик. Аннары күз күрер. Мондый адымны ясау, Гатауллинны фәннән читләштерү — аның гыйльми өлкәсен кире кагу дигән сүз дә бит әле! Шуның өчен, минем үтенечем, дөрес аңлагыз, үтенүчем — хәзергә Гатауллинны болай борчу кирәкмәс. Аннары шунысы да бар, аның, ул тикшерүләр уздырган өлкәнең сәясәткә, идеологиягә зыяны да тия торган түгел,— диде.

Кәримов башта һичбер сүз әйтмәде, бераздан соң гына:

— Шулай да, Назыйм Харисович, бу хакта тагын бер кат уйлап карауны

яхшыга саныйм. Һичшиксез безнең фикерләр туры килерләр...

— Әйе-әйе, уйларсыз, хатагызны төзәтерсез дип беләм!

Борчылган кыяфәт белән чыгып киткән Кәримовның артыннан Мөхәррәмов кәефсез генә карап калды. Аннары, бераз уйланып алганнан соң, тагын үз эшенә чумды.

Табигать, сезнең тормышыгызда минем һичбер эшем юк дигән төсле, мамык-мамык булып яуган кар эчендә, җылынып кына кышкы йокыда, һичбер хәрәкәтсез ята бирде. Тик песнәк кенә, кайвакыт тәрәзәгә килеп, теке-теке суккалап киткәли иде.

8

Мөхәррәмов шул утыруы белән, җене кузгалган төсле, күп, әле тотынырга исәбе дә булмаган һәм азагы табылмый яткан эшләрне бер җиң сызгануда очлап куйды. Инде хәзер аңа премьерага, академия театрына барасы калган иде. Юл уңаеннан ресторанга кереп, аз гына коньяктан авыз итү исәбе дә юк түгел аның: тамагын ялгаган арада Миләүшә ханым да килеп җитәчәк.

Миләүшә ханым бүген үз “тәлинкәсендә”, кәефле иде. Юл буе иренә инде үсеп, буйга җиткән уллары Искәндәрнең үзенә-үзе отчет бирмәвен, кызлары Зөһрәнең вак-төяк чигеш-бәйләм белән артык мавыгуын озаклап сөйләп килде. Назыйм Харисович аны юри генә шаяртып та бүлдермәде, бары тик эшендәгечә салкынлык белән башын селкеп тыңлап барды. Ниһаять Миләүшә ханым, иренең кое төбендәге төсле салкын һәм тирән күзләренә текәлеп, ак йөзенә карап алгач, түзмәде:

— Сиңа бу дөнья әллә бар, әллә юк! Ул балаларны бер мин генә тәрбия итәргә тиешменме инде? Искәндәреңә азрак бер-ике җылы сүз әйтсәң иде, тәртибенә керер иде... Юк инде, юк!...— дип зарланырга тотынды.

Миләүшә ханымның пөхтә итеп матурлаган күз керфекләренең төсен алып, гүзәл йөзенә эз салып, ике яшь бөртеге бит очыннан тәгәрәп узды. Шоферның ишетмәвенә ишарә итеп, Мөхәррәмов:

— Кирәкми, Миләүшәм, кирәкми... Сөйләшермен үзе белән, сөйләшермен... Йә, җитәр!..— дип, хатынын тынычландырырга тырышты.

Миләүшә сак кына, ефәк кулъяулыгы ярдәмендә, үзенә күз яшьләреннән соң бозылып калгандай тоелган битен төзәткәләп куйды. Җитмәсә көзгесен чыгарды. Анда һаман да яшь, мөлаем хәлендә сакланган йөзен күреп, шатлыгыннан елмаеп куйды. Ә бераздан Миләүшә ханым тагын үзгәрде, эч серләренең әле бетмәгәнлеген раслагандай әүвәле авыр итеп офтанды, аннары:

— Кәримов килгән иде...— диде дә иренә карап алды. Әмма һаман да бертөсле халәттәге Назыйм Харисовичның хәрәкәтсез йөзеннән аның бу сүзләргә әллә ни исе китмәве сизелеп тора иде.— Синең янда булган икән. Гади эш буенча гына, ди, Назыйм... Аңа тагын ни кирәк инде? Искәндәрне үземә аспирантурага бирегез, ди...

Миләүшә ханым тагын иренә күз салды. Ә Назыйм нигәдер елмайган, әмма тыңламаган кыяфәтендә уйлана бирә иде. Калган юлны алар инде үз-үзләре белән генә сөйләшеп уздырдылар. Бер-берсенең уйларын бүлдерергә батырчылык итмәделәр ахрысы.

Театр бинасына ян ишектән генә үтеп, турыдан-туры партерга керделәр. Күпләр үзләре башлап Назыйм Харисович һәм Миләүшә ханымның сәламнәрен алдылар. Бигрәк тә Кәримов тырышлыгын күрсәтте: янындагы урынны да тәкъдим итте. Дөрестән дә аларның урыннары янәшә булып чыкты.

Театрда халык күп иде. Аларның шактые шәһәрнең галим-голамәсеннән һәм зыялы студентларыннан гыйбарәт иде. Ни дисәң дә, Туфан Миңнуллинның әсәрен уйныйлар шул. Герой шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган яңа пьесаның куелачагы хакында гәҗитләр күптән шауладылар, вакыйга һәркемне кызыксындырган, урыннарыннан кузгаткан, эшләрен калдырып торырга мәҗбүр иткән ахрысы.

Сәхнәнең ачылуын изаланып көткән, шашкын һәм дә арган кыяфәтле, куе кара чәчле, мәһабәт һәм кире холыклы Туфан Миңнуллин утырган урынында мең кат әйләнгәләп алды, сикереп торды, шуны гына көткәндәй пәрдә күтәрелде. Пьеса кирәкмәгән, тапталган, ясалма мәсьәлә белән башланып китте. Сәхнә ничектер төссез һәм әһәмиятсез кебек иде. Әмма шагыйранә агышлы куәт илә акрынлап үзенә җәлеп итә барган төп проблема төсләләнеп һәм тулыланып китте. Сәхнә үзенең төп көченә ия була барды.

Тәнәфестә үк авторны күпләр котлый башладылар. Туфан Миңнуллин үзе дә бик риза иде булса кирәк, күзендәге шашынган сөенү нурлары аның йөзен балкытып торды. Аннан читтәрәк утырган Гатауллин ни елмаерга, ни җитдиләнергә белми көлемсерәп, Миңнуллинга карап торды. Аннары аның күзләре Мөхәррәмовнныкылар белән очрашты. Алар бер-берсен белә иделәр. Әмма Гатауллин Мөхәррәмовны бары тик министр буларак, Мөхәррәмов исә Гатауллинны элеккеге журналист һәм хәзерге галим сыйфатында гына. Шул ук вакытта Мөхәррәмов Гатауллинны убылып китәргә торган текә яр читендәге кеше буларак та күз алдына китерде. Аларның күзләре бу очрашудан соң бүтән берберсенә карамадылар.

Кеше күңеле һәрвакыт юашлыкка омтыла. Аны никадәр тирәнрәк, хәтта җидешәр йозак астына яшерсәң дә, шулкадәр ул гүзәлрәк һәм сөйкемлерәк була бара.

Әмма менә шул ябык ишекләр артында яткан күңелнең ачкычлары кулыңда булып та, үзеңнең ихтыярың илә аны чит кешеләргә бирәсең һәм мәңге шулар колы буласың (мәхәббәттә дә күп вакыт менә шулай инде ул); мең ятлар да берберләренең серләренә шул “уртак тел табу” илә кулларына төшергән ачкычлар ярдәмендә кемлегеңә төшенә, җаныңа үтеп керә ала: һай кешеләр, никадәр рәхимсез сез! Нигә сезләргә башкаларның эч серләре? Нигә сез башкаларның дөньяларына катышмый вә бәгырьләренә игәү илә ышкымый яши алмыйсыз? Рәхимсез сез, кешеләр, рәхимсез!

Спектакльнең икенче өлеше дә афәрин алкышлары белән үтте. Соңыннан, автор үзенең бәхетле минутлары эчендә йөзүендә калып, дәрәҗәле барлык кешеләрне, артистларны, галим-голамә һәм журналистларны аз гына булса да бу пьеса хакында фикер алышу өчен банкет залына чакырды. Бу үтенечен кире кагу һичбер тәртип-кыйблага сыймый иде, шуңадыр бик күпләр риза булдылар. Мәҗлестә кабат-кабат автор исеменә зур рәхмәтләр әйтелде. Мондый кул чабулардан Мөхәррәмов һич тә читтә кала алмады.

— Мин,— диде ул,— шәхесләрнең йолдыз булып балкып януларын күз алдыма китерә алам, әмма аларның да менә шушындый ук, барыбыз кебек үк самими булуын, гадәти булуын әлегә уйлап җиткерә алмый идем. Бәлки, кирәксә, безнең күбебез шәхес була да аладыр...— Мөхәррәмов болай ук чөелеп китәргә уйламаган иде, әмма күңелләргә үтеп кергән уенның тәэсире сәбәбеннәндер, ул да үзенең репертуарын башкаруга кереште.— Безнең халыкның бөеклеге менә шушындый, дөньякүләм шәхесләребез булудадыр да! Мин автор өчен бик шатмын!..

Бу сүзләре күпләрнең күңеленә май булып ятты. Мөхәррәмовның җылы елмаюы артист һәм зыялылар халкын үзенә таба елышырга мәҗбүр итте. Үзләренең аңа карата булган ихтирам һәм игътибарларын бердәм күрсәтергә ашыктылар. Миләүшә ханымны да кемнәрдер үз яннарына чакырдылар. Тик шушындый җитди, шул ук вакытта оештырылган төстә уйналучы икенче, тормыштагы театрны бары бер генә кеше күзәтеп, бу хикмәтләргә тамашачы булып утыра иде. Ул кеше күп вакытларда ничектер оялгандай күзләрен читкә алып, дивардагы вак-төяк сызыкларга карый, аннары үзенә ямь тапкандай тагын нидер ният итеп, башкаларга күз ташлый. Бу кеше куе чәчле, ак битле, усал карашлы һәм озын буйлы иде. Аның тагын бер игътибарны үзенә тарта торган сыйфаты бар: өстәл янында утырганда шушындый озын һәм дәү аякларын чатлап-ботлап, бөтен тирә-якны биләп утыра. Ул кешене күпләр мәҗлесләрдә һаман да шул ук урынында күрде, әмма һичкайсы да мөрәҗәгать итмәде, аның кемгәдер кирәклеге бардыр дип уйларга мөмкин түгел иде.

Мөхәррәмовлар монда артык озак булмадылар, алар белән Исхаков та чыкты. Үтә якын танышлар булсалар да, алар бу кичәдә ике сүз дә алышмаган иделәр. Мөхәррәмов үзе белән кайту өчен Исхаковка тәкъдим ясады, ул бик теләп бу сүзләрне кабул итте. Алар юлда артыгын сөйләшмәделәр: Мөхәррәмов, һаман да элеккечә, ашыкмаска, мәсьәләне кызулык белән чишеп ташламаска киңәш итте. Бу сүзләре Гатауллин хакында иде.

— Ул үз урынында калырга тиеш, соңрак күз күрер,— диде.

Исхаков аның теләгенә хилафлык итмәячәген белдерде, тагын да:

— Сезнең өчен барын да эшләрбез!— дип, үзен зурга куярга җай тапты.

Билгеле, Мөхәррәмов сүзне беткәнгә исәпләп, Исхаковның шушы соңгы сүзләренә игътибар да итеп тормады. Үз шәхесенә бик канәгать кыяфәт белән шәһәр турында, төрле вак-төяк яңалыклар хакында сөйләнгәләп бара бирде. Исхаков исә тагын бер кат очрашып сөйләшүнең файдага гына икәнлеген кабатлады һәм Чехов урамында, фатиры төбендә министр машинасыннан төшеп калды. Менә шулай, элеккечә, бәйрәм-театрларга ул һаман да ялгызы йөри иде.

Машина бүтән урамга таба борылгач, Миләүшә ханым:

— Нинди эшләр куертып йөргән була ул, нигә инде бу тормышны юкка катлауландырырга?— дип, иренә гадәти сораулары белән мөрәҗәгать итте.

Мөхәррәмов:

— Әйе, бу мәсьәләне чишелгәнгә санаган идем шул... Юк... Монда нидер бар, нәрсәнедер әйтеп җиткермиләр,— диде һәм сүзен бетерде.— Әйе, әйе!

Шушындый гади тормыш, гади замана ничектер куерып, әллә ничә катлы һәм каударлы булып тоела башлады.

9

Тышта кар яуды да яуды. Кышның күкселләнә башлаган йөзен агартты, кешеләргә ябышып йөрде, очты, уйнады, дөньяны аклагандай итте. Аңа күпләр басып үттеләр, әмма ул барыбер горур иде, усал һәм җитди иде. Яуды да яуды, агачларны май аендагы ак чәчәкле шомыртлар рәвешенә кертеп, үзенең бар табигатьне хозурландыруына бер дә шикләнмичә, икеләнмичә яуды да яуды. Ә аларны очыртачак, теләсә кая куып йөртәчәк килбәтсез җил еракларда, бик еракларда адашып-саташып йоклый бирде.

Яратам бугай мин кышны. Чөнки кышта туганмын...

Гатауллин юлда яңа танышы белән бергә кайтты. Шул озын буйлы, яшьлек бөркелеп торган, үзенең котсыз тоелган аяк-кулларына урын таба алмаган егет аңа самимилеге һәм шул ук вакытта ашыга-ашыга нәтиҗә ясавы, шунлыктан күпне күрергә, күпне аңларга омтылучы холкы илә генә түгел, киң күңеллеге белән дә бик тиз ошап өлгерде. Танышулары да кызыклы гына булды: алар икесе бергә киемнәрен алырга гардеробка килделәр, Гатауллин ялгышлык белән номерын төшереп җибәрде, ә егет тиз генә иелеп алып бирде. Аннары сүз артыннан сүз китте.

— Минем сезне кайдадыр күргәнем бар кебек... Юк, бүген генә түгел, моннан алдарак, әмма ачулана күрмәгез, исемнән чыккан инде... Ә, туктагыз әле, сез музейларда еш буласызмы?— Гатауллин егеткә сораулы караш ташлады.

— Юк, Гариф Гафурович!

— Концертта?

— Юк, мин җырчы түгел... Артистлар арасына да болай гына килеп эләктем. Минем дустым актриса. Ул чакырды. Күр, диде... Күрдем: үземне ташлап китте... Ә аннары, мин гади укучы, студент кына...

— Димәк, сез минем лекцияләремне тыңлаган кеше инде!.. Ә дустыгыз кем соң? Ә андый итагатьсез кешене мин белмим кебек...

— Гариф Гафурович, ул кем — кыз кеше...

— Ә-ә, аңлыйм-аңлыйм!

Алар театр бинасыннан чыккач та бергә киттеләр. Шәһәрдә кышкы төн кар коя иде. Гатауллин, учын өскәрәк күтәреп, кар бөртекләрен җыя барды да, елмаеп:

— Бала чактан калган гадәтем... Малай вакытымда күктә очкан кар бөртекләре артыннан сәгатьләр буе куып йөри идем... Күңелле була иде,— дип, уйчанланып барган юлдашына карап алды.— Мин бит сезнең исемегезне исемә төшерә алмадым, беренче фараз итүләрем дә уңышсызлыкка очрагач, инде ул ялгышларымны кабатларга кирәкмәс дип саныйм.

Гатауллинның шушындый кичәдән һәм күпме вакытлар сүзсез, үз уйларына чумып йөрегәннәреннән соң никтер сөйләшәсе, кем белән булса да гәпләшәсе килә иде бугай. Чөнки ул уйларыннан гарык туйган иде.

— Мин, мин — Әхмәт!— дип сузды егет.

— Ә, Әхмәт дисең инде алайса. Әхмәт! — Гатауллин тагын да кар бөртекләрен учына җыя барды.

Гариф Гафурович кебек өлкән кешенең менә шушылай сабыйлануы Әхмәт

өчен кызык иде. Әмма сабыйларның олы кешеләр кебек кыланырга омтылуы һәм өлкәннәрнең бала-чагалыктан китеп бетмәвендә бернинди начарлык та юк сыман.

— Әхмәт, син авыл малае инде, авылдан, дигәнем, шулай бит?

— Юк, тулысы белән үк түгел... Мин — шәһәрнеке, әмма ләкин... Авыл тормышын да беләм дип әйтә алам.

— Ничек уйлыйсың: авыл матурмы, шәһәрме?

— Ә нидә соң аларның каршылыгы?

— Билгеле инде, берсе — әлегә икътисади яктан арттарак, икенчесе — мәдәниятлерәк...

— Әхмәт, әйдә болай сөйләшәбез: чагыштырулар бер өлкәдә, бер җептә булсыннар. Алдык икътисади якны — монысы аңлашыла, ачык күренеп тора... Ә мәдәният ягын карыйк... Сез кая таба кайтасыз? Мондамы?— Гатауллин үзе барган юлга күрсәтте.

— Мин сезнең белән барыйм әле...

— Ярый, юлдашым булырсыз!

Алар бераз юлны сөйләшмичә генә килделәр. Сүзне тагын Гатауллин дәвам итте:

— Шәһәр белән авылның аермасын мәдәнияттә күрергә була.— Ул Әхмәткә карады.

— Шәһәр җитәрлек үсешкә ия: кинотеатрлар, музейлар, цирк, опера — күп инде...

— Ә авыл?

— ...

— Ә авыл?

— Авылның да үзенчә үз мәдәнияте бар. Бездә аны халык культурасы дип тә әйтергә була. Фольклор дөньясы. Дөресен генә әйткәндә, авылда да мәдәният, шәһәрдә дә... Берсе халыкның үзендә үскәне, икенчесе — калада, таш кысалар эчендә... Кайсысы яхшырак? Әйтүе кыен, әмма ләкин белеп була: кемгә кайсы якынрак, шунысы ул кеше өчен яхшырак, бары шул гына!

— Әйе, Әхмәт!— Гатауллин якынрак килеп, егетнең җилкәсенә кулын сузды.— Дөрес, мин сезнең өчен бик шатмын... Ничәнчедә инде сез?

— Бишенчедә үк инде, Гариф Гафурович!— Әхмәт сүзен өзми генә дәвам итте, ул дәртләнеп аңлатырга-сөйләргә кереште.— Менә авылда шәһәр кешеләреннән көләләр инде, безне булдыксызларга, дөнья күрмәгәннәргә, чиле-пешлеләргә, ипине агачта үсә икән дип белүчеләргә тиңлиләр. Без дә инде, үзебезнең яктан, шул кыр батырларыннан, эшчән куллардан көләбез. Имеш, алар мәдәниятсез һәм фәлән-төгән генә. Менә тагын бер мисал, хәзер язучылар тырыша-тырыша, авыл агае шәһәр кешесе була алмый, шәһәр кешесе авыл агае була алмый дип гауга куптаралар. Имеш, авыл кешесе шәһәргә күчеп килсә дә төшендә баганалары белән шыгырдаган ихата капкасын күреп сагына, чөнки аны күңеле авылына тарта, диләр. Дөрес, кешедә сагыну тойгысы булмыйча мөмкин түгел. Әмма бит алар, язучылар, ялгышалар: шәһәр кешесе дә, авылныкы да бер-берсеннән һичбер аермалы түгел. Шәһәрдә дә кеше шул ук — сөйләшүе, кичерешләре һәм башкалары, авылда да шул ук. Әйтәләр, имеш та-

бигатьне авыл кешеләре генә аңлый алалар. Юк, алай түгел. Кешеләр барысы да бер, барысы да тоя, аңлый, сиземли. Тик, шул ук вакытта, таш бәгырьлеләр бар, алары инде шулай ук анда да, монда да... Гомумән, минемчә, мәдәният ул авылда — авылча, элеккечә, халыкча булырга тиешле, шулай үсәргә хаклы. Анда опера сәнгатен көчләп үстерергә кирәк түгелдер дип саныйм. Ә шулай да профессиональ сәнгать белән халык сәнгате якыная, бер-берсе белән аралаша... Алар бер сукмактан баручы ике кеше кебекләр. Алар бер-берсенең яхшы гадәтләрен бер-берсеннән алалар, үзара охшарга да тырышалар, бары шул гына!

Сүзен бетергәндәй Әхмәт фикерләрен такылдаудан тукталып калды. Ул әле генә сөйләгәннәренең кызулыгыннан айнымаган һәм һаман уйларының очын эзләп башын катыра иде.

Аларны юлларында азрак чайкалып басып торучы егет туктатып, тартырга бирергә таләп итә башлады. Әхмәт алай итте, болай итте, әмма аңа бәйләнчек егет сагыз кебекябышырга өлгергән иде инде:

— Әйдә, җыелыйк бергә... Нәрсә, теләмисезме?.. Хан корсаклар, начальниклар, имеш!— дип сөйләнә-сөйләнә артларыннан иярде.

Гатауллин, бүртенеп:

— Нишлисез сез, ни сөйлисез? Оят түгелме?— дия башлаган иде, исерек тагын да җәелебрәк китте:

— Оят, имеш... Кешеләр, карагыз, оят, имеш!.. Мине эшемнән куалар, ни өчен соң, ни өчен?.. Мине теләсә-кайсы заводка эшкә алалар, минем разрядым бар... Мәгез, мә! Начальниклар!..

Гатауллиннан арткарак калып, Әхмәт шул исерекне якалап алды да, тез астына төртте. Тегесе, чайкалып, артка мәтәлде. Аны Әхмәт тагын торгызды да:

— Йөрмә, бар, кайтып ял ит!— дип, Гатауллин артыннан килеп җитте. Исерек нәрсәгәдер төшенгәндәй, ә аннары янарга теләгәндәй кулын күтәрде, яңадан төшерде. Үткән-сүткәннең күзенә чалынмаска теләп, кар өемнәре артындагы агачлыкка таба мыгырдана-мыгырдана атлады.

Әхмәт аңа әйләнеп тә карамады, Гатауллин белән сөйләшүен дәвам иттерде һәм:

— Менә безнең мәдәниятебез!— дип көлеп куйды.

— Юк, кемгә нинди кайгы килми дә, кемнәр бераз бушанып алмыйлар,— дип, аны Гатауллин төзәтергә ашыкты,— аның хәзер шундый чагыдыр... Кемдер аны бер дә юкка кимсеткән һәм ул шул кешедән аласы үчен башкалардан кайтарып йөри. Кеше бит ул ничек тә җиңүче булырга тырыша, хәтта җиңелгәндә дә!

Гатауллин үз сүзләре эчендә югалды. Ул хәзер балаларча кар бөртекләрен дә кумый, матур үткән кичәдән алган күңел алкышларын да таратмый иде. Тормышның катлаулылыгын беразга булса да онытып тору, ял итү өчен кешеләр ни генә уйлап чыгармаганнар, ләкин аларның берсе дә күңел кылларына мәңге тәэсир итеп тора алмыйлар, алар тормыш хакыйкатеннән көчсезрәк, чөнки тормыш сәяхәт тә, күңел ача торган урын да түгел, бәлки көрәш кыры, мәңгелек көрәш мәйданы. Анда һәр кеше үзенең бәхеткә никадәр хакы барлыгын белмичә генә, үзен таныту, күрсәтү өчен генә тырыша. Шунысы кызык-

лы, монда кешеләр нидер кычкыралар, алдыйлар, көләләр, юха теллеләнәләр, кәпрәяләр һәм бүтән төрлегә әвереләләр, әмма, ни генә эшләмәсеннәр, ничек кенә җиңүче булырга тырышмасыннар, барыбер, иртәме-соңмы дөреслек җиңә! Элек-электән ул шулай килә. Моны барыбыз да беләбез! Ә нигә икән дөреслек белән генә яшәмибез?

— Ә бит күп нәрсә, бөтен әйбер икътисадтан тора. Гади итеп әйтсәк — акчадан. Акча барлык кешеләрне дә үз тирәсенә җыя. Акча һәммәне үзенә буйсындыра. Акча! Тора-бара акча тагын кешелекнең иң куркыныч һәм көчле дошманына әвереләчәк!

Әхмәт сүзләрендә тукталып калды. Аның болай сөйләнеп алуыннан әллә тамагына нидер төртелдеме, әллә башкамы — туктаусыз йөткереп куйды, сөйләгәнен дәвам итмәкче иде, Гариф Гафурович сүз алды:

— Акча? Акча әле һаман үз көчендә. Ләкин, Әхмәт дустым, тулысынча түгел! Мәсәлән, миңа акча магазинга кергәч кенә кирәк була. Аңынчы мин аны бөтенләй дә исемдә тотмыйм. Бу — күпләрнең шулай! Минем өчен акча ул — бер кәгазь кисәге, ягъни отчет кәгазе... Менә ни!.. Трамвайда талон тәртибе бар бит. Мин үземнең бушка утырып йөрмәвемне белдерү өчен талон тишәм. Бу да шулай... Мин үземнең бушка, бер файдасызга ашап ятмавымны белдерү өчен, хайван түгеллегемне раслау максатында магазинга талон, ягъни акча бирәм, акчаның эше бары шул гына!

Гатауллин бу фикереннән соң балаларча куангандай булды, адымнары да җиңеләйде.

— Димәк, акча зур көч түгел.— Әхмәт өчен әллә әңгәмәдәшен үртәү, әллә хакыйкатьнең ачылуы кызыграк иде, анысы аңлашылмады. Ул юк-бар сораулар бирүен дәвам иттерде.— Ә нигә һаман акча-акча дибез? Нигә акча дигән нәмәрсә бар соң?

Гатауллин шунда үзе дә көтелмәгән сорауны бирде:

— Әхмәт, сез өйләнмәгәнме?

— Юк, ә нигә?

— Сез хатыныгызны акча өченме, яратканыгызга күрәме алыр идегез?

— Билгеле, ятатканга күрә!

— Шулай булгач, менә тагын бер дәлил. Кеше үз тормышының нигезен төзи. Акча белән түгел, дөреслек белән!

Әхмәт көлеп куйды, ул сабыйланганнан-сабыйлана бара иде.

— Ә бит акчасыз өйләнеп тә булмый... Туй итү кирәк, дуслар...

— Ә монысы инде башка эш. Сездән туй көтелә икән, димәк, сезнең бу җәмгыятькә никадәр файда китерәчәгегез тикшерелә. Бары шул гына. Димәк, сез эшлисез, файда китерәсез дә, аңа бәрабәр — туйлык акча! Туегыздагы сыегызга карап сезгә бәя бирәләр!

Гатауллин җитәрлек аңлаешлы итеп сөйли иде, әмма Әхмәткә алар юк-бар, мәгънәсез, ялган кебек тоелдылар. Егет өчен үз туксаны хакыйкать иде. Шуның сәбәпле үз ахмаклыгын төшенеп тә җитмәде.

— Менә спекулянтлар — акчалы кешеләр бит! Бернинди файда китермиләр...

— Ничек?.. Файдалары бар. Алардан син юк әйберне аласың. Алар сиңа

әллә кайлардан юкны бар итәләр. Билгеле, өч-дүрт хакка кыйммәтлерәк итеп. Шуның өчен без юк чалбарны бар итеп киябез. Әйтәм бит, кешеләр үзләрен өстен итү өченгә тырышалар. Ләкин дөреслек барча нәрсәләрдән дә өстен, көчлерәк. Сезнең яхшы киемегезне киеп, башкалардан шуның белән өстенлегегезне күрсәтәсегез килә ди, әйтик, ә бит күбебез моңа ышанырга да өлгерә!

Әхмәт мондый ук ачулы сүзләрне көтмәгән иде бугай, ул аклана ук башлаган иде, Гатауллин, аны бүлдереп:

— Тормышта зур көч бар — дөреслек! Ул һәркайда яши. Аңа һәркем буйсына... Бары шуны онытмагыз, дустым!— диде һәм хушлашып кулын сузды.

Алар икесе ике якка, үз урамнарына таба киттеләр. Ә кар һаман да ява иде. Әллә инде табигатьне сафлар өчен, көзен шәрәләнеп калган каен кызларына ак тунын кидерергә дип, әллә адәм балаларының күңелләрен агарту теләге белән, сөендерү максатында? Шулай итеп үз сәбәбе белән кар ява да ява бирде.

10

Сиздермичә кыш моңлана иде. Ялгышалар шагыйрьләр. Яз гына моңланмый, кышның да үз көе бар. Ул әле итек олтанына ябышып нидер мыгырдана, әле морҗа тишекләренә кереп, исерек мужик кебек быдырдый, әле салмак кар белән бергә бишек көен көйли. Кем белә, бәлки кыш үзе үк язны җырга-моңга өйрәтеп калдыргандыр? Ә нигә? Көннәр җылынып, басулар буйлап кар сулары челтерәсә, каен бөреләренә кунган кар бөртегенең күзләре яшьләнсә, нинди моң туа бит! Ул кышкы озын кичләрдә кояшны сагынып моңланган күңелнең җыры түгелмени? Шул үзе!

Әмма дөньялык йөзендә әле һаман да кар иде. Кыш үзенең хозурлыгын саклап, эре кыяфәте белән урманнарда йөрде, ак сакалын межаларда тарыйтарый, басуларда йөрде, битләрне өшетте, әле борыннарга чиртте... Кышны юкка усал диләр. Кыш шаян булганга гына усал кебек ул. Кышта күпме бәхет, бәрәкәт бар.

Гатауллин тынып калган дөньялыкның моңына хәйран итте. Каян килә бу? Уңына һәм сулына карады, аннары гына күккә текәлде. Гаҗәп, бик тә гаҗәеп хакыйкать ачылды аңа. Әле генә тукталып торган кар, яңадан куерып яварга ниятендә күктән ишелеп төшеп килә, шәһәрнең яктылыгы анда мең төрле нурлар белән уйный һәм ул моң булып ишетелә иде. Бу соклану мизгеле Гатауллинга һаман да җавабын таба алмаган хакыйкатьне ачты, әмма аңа нидер булды, йөрәген тотты һәм юл читендәге кар өеменә капланды. Моң аның җанын үзе белән еракка, бик еракка, бу дөньялыктан читкә алып очты...

*Казан, 1983.*

## БЕЗ ДӘ МОНДА БАР ИДЕК
*Роман*

1

Салкын кыштан соң кинәт яктырып киткән көләч кояш нурларына агачлар һәм гөлләр генә түгел, адәм балалары да тартылган чор, гүзәл мәл иде. Әмма ул озакка сузылмады. Чыпырдашып яз ерганакларында уйнаган шаян балалар да каз бәбкәләре артыннан болынга сибелделәр, гөлләр чуарланып, агачлар купшыланып, кайчан гына салкын хөкем сөргән дөньяны онытып, җәйгә таба ашыктылар. Җәй!.. Мондый матур көннәрдә тыныч кына бәхеттә гизеп яшәп ятасы да бит, юк шул, дуамалны юкка гына юньсез димиләр. Бөтен авылны таңнан ук ду китереп Сәлим абый үте. Тузынып өенә кайтты...

Шушындый ямьле көннәрнең берендә авылга яңалык булырдай хәбәр килеп керде дә, колактан-колакка, өйдән-өйгә йөреп, тиз арада күпләрнең исен җибәрде.

— Дегет тапканнар икән, җир маен!..

Бу куаныч бик озак вакытлар телдән төшмәде. Шулай да хәбәр артыннан килгән яңасы дөньяны чуарлый торды, нефть хакындагы сүзләрне искәртте, ахырда озаккадыр оныттырды...

Шулай беркөн, инде искәрткәнебезчә, Сәлим абзый өенә таңнан ук ду килеп кайтты. Атын капка баганасына гына бәйләп калдырды да, чыбыркысын сарай ягына таба ыргытты. Ул мул булып көлеп торган чиста табаклар, чиләкләр өстенә барып төште дә, барчасын шалтыратып җиргә чәчте, поскан урыныннан тавыклар йөгерешеп чыкты. Боларга бер дә игътибар итми, Сәлим абзый бусагасы белән диярлек каерып ачкан ишегеннән өйгә узды һәм куркыныч тавыш белән:

— Суйдылар, көпә-көндез таладылар, җирәнгечләр!— дигән сүзләрне бутый-бутый, ачылган авызыннан берьюлы һәммә әйтерен чыгарып бетерде дә, хәйран калып, урындыкка сыгылып төште.

Ул арада хатыны Хәлимә җиңги көтү артыннан аз гына черем итү нияте белән борын төрткән мендәрен күпертеп рәтләде дә, алгы якка чыкты. Бик бетеренмичә, самими тавыш белән:

— Кояш күтәрелгәндә нигә болай вакытсыз шашасың, атасы, рәтлерәк кыланып буладыр бит!— дип, көйле һәм сузымлы тавышы белән иренә эндәште. Сәлимнең канына сүзләре капчыклап тоз гына салу булачагын җиңги белеп бетермәде, ахры.

— Булмый шул, булмый, рәтләп-рәтләп...— дип үртәнде Сәлим.

— Ярар-ярар,— дигән булды Хәлимә җиңги, ваемсыз гына: — Җимерелмәс!

— Җимерелә!— дип сикереп торды да Сәлим абзый, өстәлгә төртеп:— Самавырны җылыт, хәзер кайтып җитәм,— дип, аршынлап атлый-атлый ишеккә юнәлде.

Авыл тәмам уянып килә иде.

Хәлимә җиңги, самавыры тавыш алгач, иренең ямьсезләнүеннән айный алмыйча, авыз эченнән генә сөйләнеп, тәрәзә кысаларына кунырга өлгергән тузаны ашыга-ашыга сөрткәли башлады.

“Йә инде,— диде ул үзенә үзе,— бу Сәлимгә ни җитми?”

Самавыр җырлап җибәргәндә Хәлимә җиңги инде ире кузгаткан ачуын чы-

гарып бетергән иде. “Бетмәс әле, корымагандыр,— диде ул үз алдына,— буласы булгандыр. Гомерем буе чәчләремне агартты, хәзер инде бер дә исем китми”,— дип юанып куйды.

Хәлимә җиңгинең олы улы армия хезмәтен үтеп, быел яз, ташулар тынган бер ямьле көне елмаеп кайтып керде. Йортның терәге булып килә. Сәлим абзый да башын бутап, күмхуҗ җенен йоктырмаса, йа Рабби, гүзәл вә акыллы бәндәләрнең берсе буласы бу, олысы, Миргалиме.

Уртанчы улы Гатаулла да егетләнеп килә әнә, күрше Казалы урта мәктәбендә интернатта торып укый, бик мактыйлар үзен. Кечесе — Галимулла, иншаллаһ, гел дә Хәлимә җиңги инде. Һай шунда кыз бала булып дөньяга килгән булса, әнисе аны чәчәктән-чуктан гына киендереп йөретер иде, ата-бабадан килгән гүзәл тәрбиясен биреп, күгәрчен итәр иде. Булмады шул, нишлисең, Алла колы шул ул адәм дигәннәре, язмышы ни боерса, шуңа буйсынмый булмый. Йа Ходаем, болай да балалары бик гүзәлләр әле!

Хәлимә җиңги ян тәрәзә ягындагы саргаеп уңа башлаган көзгегә килеп: “Үзем дә Ходайга шөкер икән әле, матурданмын!”— дип, ирен читләрен чәнчә бармагы белән сыпыргалап алды. “Әйе, Ходайга шөкер!” Ошбу кояшлы бәйрәм көннәре бар җаннарны сөендереп кызгылт читектән генә йөрисе иде дә, Сәлиме ирек бирми диярәк үзалдына тагын ирен сүкте. Ни пычагыма дип шул тирес корты белән тормыш корды икән? Карасаң — йөзе, сөйләшсәң — юньле сүзе юк!

Әмма Сәлим абзыйның элекләрне батыр егет булуы исендә иде Хәлимә җиңгинең. Тик ничек инде, ир хатыны булып, ирне мактап булсын? Хатын-кыз булмый кала бит аннары!

Ул арада ишек алдында көлешкән авазлар ишетелде. Хәлимә җиңги, ак келәттә йоклаган малайларының тавышына куанып:

— Бусы — Миргалим көлә, бусы — кечесе,— дип куйды.

Малайлар бер-бер артлы өйгә кереп, өстәл янына уздылар. Миргалим:

— Әти кайда, әни?— дип сораган иде, башта Хәлимә җиңги, ишетмәгәндәй, эндәшмәде, улы кайтарып тагын сорагач:

— Йөри шунда, иртә таңнан дулап,— диде дә, моңсу гына: — Йа Рабби Ходаем балаларымның бәхет-куанычларын бирсен!— дип тезеп китте. Моңа каршы Миргалим:

— Бирер, әни, бирер, бирмәсә, өлешебезне тартып алырбыз,— дип көлә башлаган иде, Хәлимә җиңги:

— Чү улым, алай сөйләшмә, атаң булмый калырсың,— дип, Сәлим абзыйның пырдымсыз кылануларын исенә алып, улын үзенчә ачулангандай ите. Тик малайлары җавапка тагын көлешеп кенә куйдылар.

Кара әле кечесен, Галимулланы, пошмый гына йөргән була иде, ни кылана, әнисеннән, Хәлимә җиңгинең үзеннән көлә түгелме соң?

Әмма малайлары сөйләшү кыйбласын үзгәртеп, башка әйберләр хакында сүзката башлагач, җиңги дә сүрелеп, үз җылысына кайтты. Иртә таңнан, гомергә булмаганы, теләсә нәрсәгә үпкәли иде ул. Әллә бу иртәдә йортка картлык килеп керде, әллә ни булды?

Шуның галәмәтедер дип исәп йөртергә уйлады Хәлимә җиңги. Ире Сәлим

абзый, идарәдән әйләнеп кайткач та, авыр сүз белән бәрелмичә, аңа өлкәннәрчә кылан диярәк акыл биргәләде. Хәлимә җиңгинең акыл өйрәтүләрен Сәлим абзый башта дәшми-тынмый гына тыңлап торды да, бер янга кыйшая төшеп, чәшке-чынаякларын үзеннән читкәрәк этә-этә:

— Харап иттеләр бит, барлык көч-куәтемне биргән югары як басуны бит әле җитмәсә,— дип, салмак кына сөйләнеп алды.

— Атасы,— дигән булды Хәлимә җиңги,— иртә таңнан, көн тишелмәс борын дулыйсың, аңлатмыйсың,— дип, үзенчә иренең дуамаллыгына бәя бирде: “Шулдыр әле, югары оч Фатыйма, тагын эшен ташлап гурудка, йомырка сатарга йөгергәндер, бер дә башка булмас!”

Болай уйлау җиңгигә Сәлим абзый алдында акыллырак, белемлерәк булып кылануга ирек бирә иде.

Әмма хатынына Сәлим абзый борын чөяргә мөмкинлек бирмәде:

— Хәлимә, безнең югары басу төбендә дегет тапканнар. Каланча утыртасылары икән. Әлмәт ягындагы сарутлар безгә дә күчәр инде,— дип сөйләнә башлады.— Мин бит ул җилләр безгә тимәс, бездән дегет тапмаслар дип куана идем. Булмады... Болайга китсә, басуларым бозылып, игеннәр әрәм генә булачак икән,— дип башын игәләп торды да, эһ итеп, кызып китеп, өстәлгә орды. Башка эше калмаган. Чөнки нефть диңгезе алдында Сәлим абзый гына түгел, күмхуҗ идарәсе дә көчсез иде.

Ике атна арасы узды дигәндә, үч иткәндәй нәкъ Сәлим абзыйларның бакча башына, ихаталары артына шундый ук каланча-вышка утыртып, җирне бораулый, үзәкләрне каезлый башладылар.

Моңа Сәлим абзый түзеп тора алмады. Туры район үзәгенә, Кәрим Хафизович янына, бригадасындагы ике җигүле айгырның берсен алды да китте. Юлда усал яңгырга эләгеп, пычракка батып бетүләренә дә карамастан, кожанын да салмыйча, тугарылып секретарь янына үтеп керде. Кәрим Хафизович, тормышның барлык каршылыкларын кичергән кеше, Сәлим абзыйның өс-башына игътибар итми, бик җылы каршы алды. Утырырга урындык тәкъдим итте. Бригадирның хәлен сорашкач, күмхуҗ мәсьәләләренә тукталды:

– Язгы чәчүне уңышлы уздырдыгыз... Тик менә печән әзерләүнең начар баруына, Сәлим Латыйпович, бригадир буларак, коммунист буларак ни дисез?

Сорау гади иде. Әмма юлда аты тугарылудан өстәлеп күпергән бар усаллыгын секретарьга җиткерергә талпынып торган Сәлим абзый, кинәт тотлыгып, каушый калды. Кәрим Хафизович ашыга белми иде. Бригадирның суынып килүен сиземләп, акрын гына тагын сорап куйды.

— Иртәрәк бит әле,— дип сузды сүзен Сәлим абзый,— печәнгә иртәрәк. Рәисебезне дә үзем күндердем. Ашыкмаска кирәк. Чын үлән әле яңа үсеп килә, Кәрим Хафизович!

— Да-а, “Алга”ны кузгатуы авыррак шул,— дип, ярым көлемсерәп, секретарь соңга калу мөмкинлеген, яңгырга китсә, авыр булачакны кат-кат тәкрарлады. Юк, ул усалланмады. Ике карт коммунист бер сүзгә килә ала иде. Күмхуҗ рәисе хакында да фикерләшеп алдылар.

— Онытып торам, карагыз әле, Сәлим Латыйпович, нишләп сез, ә рәисегез килмәде?— дип сорап куйды.

Сәлим абзый сүзнең шуннан башлануын көткән иде. Әмма ялгышуына үзе гаепле булуын да аңлады: Кәрим Хафизовичны ул аз белә икән!

“Кәрим Хафизович?!.”

Коммунист. Атасы Хафиз абзый Донбасс шахталарында эшләгән кеше — эсэрлар партиясе әгъзасы булган. Күп буталган, әмма эшче аңы җиңгән кешеләрнең берсе иде. Әтисенең Кәрим нидән ялгышканын үсеп җиткәч кенә тулысы белән аңлап җиткерде. Ул үсмер малай булып килгәндә, атасы вафат иде, малай әнисе белән генә торып калды. ФЗУда укыганда армиягә алынды. Ул арада — сугыш. Сугышта ул намусына тугрылыклы булды. Мәскәү астында коммунистка керде, аннары аны “партработник” иттеләр. Хәзер — районда.

Боларын Сәлим абзый да яттан белә иде. Әмма кешене таныр өчен кимендә утны яки суны бергә кичәргә кирәк...

Тукта әле, Сәлим, син монда нәрсә эшләп йөрисең, ярдәм сорап килдеңме? Юк инде, булмас, һич булмас! Әллә кайчан “Алга”ның җирен бүлеп куйганнар: ничә гектары нефть булачак, күпмесенә әрем үсәчәк!

Сәлим абзый секретарьдан сөйләшмәс булып кайтты. Шушы тынычлануы озакка сузылды. Җыелышларда да эндәшмәде, ачуланышмады. Хатынына да авыр кагылмады. Атын да атлатып кына йөртте. Барысы да аның үзгәрүен күреп, Сәлим дә картайды дип нәтиҗә чыгардылар. Тик алар ашыга иде: уракка төшәбез дип торган көннәрне ул тагын дулап китте.

2

Бригадир чыгып киткәч тә Кәрим Хафизович озак уйланып утырды. Башта, гадәте буенча, иртәгә нинди эшләр күз алдында тотылуын барлап чыкты, аннары, ярты җирдә өзелеп калган, Сәлим абзыйга карата булган фикерләрен исенә төшерде. Секретарь үз кормасы кешеләрне ярата иде. Ә Сәлим абзый — шундыйлардан. Картның йөзен Кәрим Хафизович беренче күрүдә үк үз итте. Агара башлаган куе сары чәч һәм кырыс йөзгә хас булмаган янып торган күзләр. Сәлим абзыйның үзсүзле булуы хакында да күп хәбәрдар иде ул. Әмма бүген булган сөйләшү аңа карата күңелендә йөртелгән юк-бар уйларны берьюлы җимереп аты.

Кәрим Хафизович төн уртасында гына өенә кайтты. Урамда күн итекчән, бала вакытындагы төсле, яңгыр суларында пычтырдый-пычтырдый ләззәткә күмелеп йөрде ул. Аны кайбер яшьләр таный да икән әле: көлешеп, исәнлек сорап узалар. Секретарь алардан көнләп тә куйды. Бәхетлеләр алар, бик бәхетлеләр. Менә бит дөньялар ничек үзгәреп бара. Район җирләрендә нефть таптылар. Озакламый һәр авылга үзәкле электр уты керәчәк, бу — бер; икенчедән, нефтьчеләр район аша бик яхшы асфальт юл салырга исәп йөртәләр. Димәк, күп дигәндә ике елдан ул да пычрак урамнан түгел, ә асфальт юлдан җиңел аяк киеме белән, юк, өй башмагы белән генә уза алачак. Боларга сөенми мөмкинме соң?

Авыллар шәһәрчәгә күчә башлады, син аны телисеңме-юкмы, тормыш бер дә сорап тормый.

Якын-тирә авыллардан гына түгел, ерактан, бик ерактан яшьләр һәм хәтта өлкәннәр дә Әлмәткә җыела. Әлмәткә, нефтьчеләр шәһәренә. Төрле авылда,

йомык шәхес булып яшәгән кешеләр үзләренә монда урын табалар, кинәт балкып, янып китәләр, үзләренең көчләрен сизәләр, шунда тәрбияләнеп, чыныгу алалар. Менә сәнәгать нишләтә — меңнәрне үзенә туплый, барысын чүки, эшкә яраклы хәлгә китерә. Төрле төбәктәге үзенә хас культура монда бер учка җыелып, бөтенәеп, охшашланып китә, тормышта яңа дәрт уята. Анда җанга якын “Сарман” гына түгел, “Уфа көе” дә, “Сөн буе” да, “Агыйдел” һәм меңнәрчә башка җырлар, шул җырларның рухы булган кешеләр бергә оешып, яңа моң, нефть җыры тудыра ала. Алар барча кешеләрдән мең өлеш бәхетлеләр. Менә шулар белән булу үзе дә зур бәхет!.. Ә күмхуҗда ни? Һәр авылның үз кыйбласы, үз җыры. Әле алар бер рухта булсалар да ярар иде. Юк шул! Һәр авыл үз кирелеге белән, усаллыгы белән аерылып тора. Аңлап бетер аларның теләген. Алар — мең, син — бер!..

Кәрим Хафизовичны өендә хатыны Гөлгенә көтә иде.

Хатын ирен яратмый дигән сүзнең мәгънәсен төшенми иде ул. Ничек инде хатыны ирен яратмаска тиеш? Яратмаса, шулай сагыныр идемени ул аны? Кәрим кайтмыйча йоклый да, тынычланып утыра да алмый түгелме соң?

Гөлгенә ханым тышта яуган җәйге җылы яңгырга рәхмәт укып, ян тәрәзәне ачып җибәрде. Бакчадан саф, иркен һава агылып бүлмәгә үте. Шунда ишек ачылды. Аннан күренгән Кәрим Хафизович энәдән-җепкә кадәрле су иде. Гөлгенә, аны күргәч, шатлыгын яшерми көлә-көлә сөйләнеп иренә якынлашты да:

— Минем көзге чебиемне кайсы күлләргә салганнар,— диде,— кара, и-и-и, бигрәк көзге чеби инде, дәү балам!

Яшьлектән гадәтенә кергәнчә бер-берсен яратышып, бит очларыннан гына сөешеп алдылар.

Бу минутта алар мөгаен үзләре дә сизенмәстән самимиләнеп алганнардыр? Адәм баласына күпме җитә: бер елмаеп карау һәм шуннан аңлашып китү кешене бөтен гомере буе бәхетле итә, уйланып арыган башка, тынгысыз җанга ял бирә. Һәрхәлдә адәм баласы сөю-сәгадәттән башка көн итә алмый. Ансыз ул дөньяның ямен сизми, шатлыгын күрми.

Кәрим Хафизович үзен бәхетле бәндәләрдән саный иде. Эштән бигрәк, гаилә тормышының матур корылуы аның күңел тынычлыгын саклавына мөмкинлек бирә, вакытын кирәкле файдалануына ярдәм итә иде.

Кәрим Хафизович үз хатынына бер вакытта да орылып бәрелмәде. Яшьлектә булгандыр, анысы, әмма ул вакытта да үзенең ни кыланганын тиз сизеп, туктап кала белде. Гөлгенә ханым көмән күтәргәч, төн йокысын югалтты. Анда да, бала кайгысыннан бигрәк, тормыш иптәшенең исән-сау булуы аны ныграк борчый иде. Шул көннәрдә аны ак әби йомыш белән күрше авылга җибәрде. Кәрим Хафизовичның ул вакытта нидер буласын йөрәге сизгән иде. Юл буе: “Гөлгенәмне исән калдырсаң иде. Уч төбемдә генә йөртер идем, өрмәгән урындыкка да утыртмас идем!”— дип Ходайдан ялварды. Бик ярата иде ул Гөлгенә ханымны, бик ярата иде.

Кәрим Хафизович буйга-сынга таза булса да, гаҗәеп гүзәл җаннарны сөйдерә һәм көйдерә алган булса да, арадан, күркенә түгел, холкына кызыгып, Гөлгенәне сайлап алды. Еш авыргаласа да, Гөлгенә ханым тәкәббер һәм горур иде. Кәрим Хафизович хатынының җаен таба алмыйча озак җәфа чикте. Бәлки

яшьлек хаталары өчен үч ала торгандыр дип тә исәп йөртеп карады. Ялгышты. Исереп кайтып, гаиләсен харап итә язды. Гөлгенә ул көне еламады да, ялвармады да, ирен чиста урын-җирдә йоклатты. Үзе төне буе аяк өстендә йөреп чыкты. Кәримнең дуамаллыклары бала тугач кына юып алгандай юкка чыкты, ул тормышның җаен дилбегәсеннән тотып алды.

Гөлгенә ханым ире Кәрим ак әбинең йомышын эшләп кайтканда малай тапкан иде. Ул ирен күрүгә елмайды. Әмма аягына тора алмады. Атналап ак әби карамагында булды.

Җомга кичкә генә баладан соң кичергән авырулары үте. Гөлгенә ханым елмаеп, балкып аягына басты, йөри башлады. Тагын гаиләсенең күңелле-бәхетле көннәре башланды. Алар яхшы яшәделәр. Улларына Шәриф исеме куштылар.

Кәрим Хафизовичларның башка балалары булмады.

Шәриф кече яшендә Гөлгенә ханымга охшаган булса да, үсә төшкәч нәкъ атасы төсен алды. Хәзер ул Мәскәүдә политехник институтта укый иде. Әтиәнисенә югары курсларда аз-азлап берничә хат язды да бөтенләй диярлек хәбәрсез калды. Гөлгенә ханымның моңа бик эче поша иде. Тик ире Кәрим Хафизович кына:

— Ул бит олы кеше, үз башына яши башларга күптән вакыт,— дип, улы Шәрифне артык иркә-наздан мәхрүм итәргә кирәклекне кат-кат кабатлагач кына, Гөлгенә ханым хафаланмаска тырышты. Тик ана күңеле — ана күңеле шул: улын гел дә исеннән чыгармый, һаман, хат язуын түгел, үзен көтә иде.

Әмма улы кайтмады. Кечкенә генә открыткалар белән канәгатьләнә белән канәгатьләнә торды. Шундыйларның берсендә үзенең студентлар отряды белән эшкә китүен хәбәр иткән иде.

Ә моңа Кәрим Хафизовичның ачуы килде:

— Эшкә, имеш! Коры сүз! Аз гына хәбәр-хәтер итсә ни булган? Кайтып китсә! Атаны — ата, ананы — ана дип белми,— дип сукранды.

Шәрифне әтисе бик көткән иде. Гөлгенә ханымны үзе баштарак юатып йөрсә, хатыны хәзер Кәримне тынычланырга үгетләде.

— Кирәкми, әтисе! Ул бит инде бала-чага түгел, тормыш күрсен, кешеләрне. Гомер буе безнең куенда гына яшәмәс бит инде!

Кәрим Хафизович: “Беләм мин аларны!”— дип орылып бәрелгәндәй итсә дә тынычланды. Улы белән дә, Гөлгенә ханым белән дә килеште: “Күрсен, йөрсен!”— диде.

### 3

Сәлим абзый өенә кайтканда аны гадәттән тыш хәбәр көтә иде. Кәрим Хафизовичка бригадир ничектер үпкәләвен, ачуы килүен юл буе сүндерергә тырышты, булмады, газаплանулары бушка иде. Арбасына утырган һәм җырлапшыңшып кайткан юлаучы егетне дә эт итеп сүгәсе, гомумән дөньясына төкерәсе килде аның. Секретарь була торып та Сәлимне аңламады бит. Юк, аңларга теләмәде. Нишлисең, печән сүзе чыккач, авызы томаланды да куйды бригадирның. Әйтер сүзен әйтә алмый калды. Серен дә чишә алмады, ни өчен килүен дә ачыклап бетермәде. Киңәш тә итешмәде бит шунда. Нидәндер курыкты!

Җәйге юл инде җепшетеп, томырылып яуган яңгыр җиргә сеңгән, тик ара-тирә генә су җыелып, гүләвек булып тора иде. Сәлим абый эше юк кеше кебек юл буена шуларны санап кайтты. Бу гүләвекләр гүя Җир-ананың күз яшьләре кебек тоелдылар аңа. Сәлим абый үзе дә елый иде. Күңеле үкси иде аның. Өенә кайтып кергәнендә ул, үпкәләгән мескен карт кеше төсле, балтасын суга төшергән абзыйдай кызганыч хәлдә иде... Менә күпме вакытлар узды. Тик секретарьга булган үпкәсен Сәлим абзый һаман да оныта алмады. Шул очрашуларын вакыт-вакыт исенә төшереп, тынычлыгын җуя торган булып китте. Инде күпме сулар акты. Шушы соңы төннәрдә озак ятып та йоклый алмыйча газаплана. Бу юлы борынына дегет, җир мае исе кереп җәфа чикте, түзмәде, алласын да, каргасын да сүгә-сүгә үрле-кырлы йөренде. Тик шунда гына май исенең кайдан чыкканын абайлады.

Элгечтә дегетле пинжәк эленеп тора иде. Сәлим абзый аны көрәктәй куллары белән умырып алды һәм тышка ыргытты. Хатыны Хәлимә җиңги, йокы аралаш:

— Картым, ни кыланасың инде... Сәлим, йокла!— дигән авазлар сузды. Ачуы теленнән ычкынган ире:

— Борын төбенә үк шул дегетне сөртмәсәгез, урын беткәндер. Нигә дип шул буровой тирәсенә баралардыр? Кем киеме ул?— дип, хатынын йокысыннан тәмам уятып җиткерде.

— Ә, ул, Миргалимнең киеме иде бугай. Буровойга кергән... Бик дөрес эшләгән. Бу күмхуҗда чиләнгәнче, акчалы эш, ичмасам...— диярәк, Хәлимә җиңги аңлы-миңле тезеп китте.

Хатын-кызда була торган тәмләп сөйләү гадәте Хәлимә җиңгидә кирәгеннән артык дәү булып үскән иде. Үз ишләре арасында, кич утырган вакытларында аның кадәр дә авызына каратып сөйләүченең авылда башка булмавын бөтен халык белә. Бу бик яхшы, үзенә күрә үзенчәлекле талант билгесе иде. Ләкин, кызганычка каршы, тел ягыннан оста кешеләрнең дә бер кимчелеге бар — аларның авызлары тишек була. Ә менә Хәлимә җиңгидә ул сыйфат йөзе белән. Улы Миргалим әнисенә күпме ялварган иде бит, әтигә әйтмә дә әйтмә инде дип.

Ни булыр хәзер дигәндәй, моны исенә төшергән Хәлимә җиңги учы белән авыз-борынын каплап, куркынган күзләрен лампага ут элергә өлгергән иренә текәде.

— Абау!..

Сәлим абзый тузгымады, чәчелмәде. Урын өстенә барып яты да йоклап китте. Хәлимә җиңги, торып, лампа утын сүндерде, ятты, бәргәләнеп каккан йөрәген тыңлаштырып, тагын күзләрен йомганын сизми дә калды.

Төн, куркак малай төсле, тәрәзә артында дерелдәде.

Сәлим абзый нәрсәне-нәрсәне, әмма Миргалим улыннан мондый ук ахмаклыкны көтмәгән иде. Барыбер, акыллы эшләгән булса да, олы улыннан мондый рәнҗетелүне уена китерәсе түгел иде шул.

Ата кеше мондый вакытта нишли, нәрсә кыла ала? Билгеле инде, әтисе сүзен тыңламаган баланы орыша, малай кеше үпкәли һәм өйдән чыгып китә. Сәлим абзый исә моны эшләргә теләмәде. Дөресе, аңа авылдашлары алдында яман сүзләр белән тавышлануы ничектер оят кебек тоелды. Шулай да ул үз

үпкәсен, җан ачысын белдерми кала алмый иде: олы улына күтәрелеп тә карамады, аның белән очрашмаска тырышты.

Әмма, бер өйдә торып, һаман болай эшләү мөмкин нәрсә түгел иде шул. Сәлим абзый уйлаганның нәкъ киресен башында улы Миргалим йөртте: атасы белән киңәш-табыш кылу кирәк иде аңа.

Әмма этисе бик кире кешеләрдән булып чыкты. Миргалиме сүз башлап караса да, сөйләштерергә маташса да Сәлим абзый сер бирми йөрде. Моннан аның бик каты үпкәләгән булуын, ул гына да түгел, ачулы икәнлеген сизәргә мөмкин иде. Әмма ачу дигән яман нәрсә кабарганнан-кабара гына икән шул ул; элекләрне Миргалим, эштән кайткач, дегетле курткасын ишек артына салып керә торган иде, бу юлы нигәдер өй эчендә чишенде. Җитмәсә аз гына "яшел елан агуы"н да кулланган иде.

— Нәрсә син, малай актыгы, үрәчәгә ышкылып майланып йөрисеңме әллә, бөтен өйне сасытып?!.— дип китте тезеп, китте тезеп Сәлим абзый, үзе дә сизмәстән. Бар булган ачуы, үпкәсе бергә, җыелып торган яңгыр суы ерып юл алган төсле китте ташып, китте агып, тавышка йорт эчендә булган һәммә җан иясе диярлек җыелды, хәйран итте.

— Мин сине... Үстерәсең-үстерәсең, киендерәсең, акыл бирәсең... Әйе, ә ул тота да лачтырдатып йөзеңә төкерә, ул гынамы, бәгыреңне таптап китә...

Сәлим абзый озак сөйләде. Ата-бабалардан алып, әллә кайсы җитмеш тарихларны актарып чыгарып, уфтана-уфтана, дәртләнеп-сикереп сөйләде ул.

— Син, өметсез шайтан, мине хөрмәт итмәсәң, әниеңне санла ичмасам...— дип, сүзләрен җикереп-чатнатып әйтте дә, кинәт, көтелмәгәндә килеп чыккан һәм дөньяны пыран-заран китереп узган зилзилә кебек арып туктап калды.

Өйдәгеләрнең аңа карап торуларын сиземләп булса кирәк, бераздан үзенә урын таба алмыйча газапланды: әле өстәл артына барып утырды, әле караваткa,— болар да ярдәм итмәгәч, ишек алдына таба юнәлде.

Олыгаеп килгән этисен Миргалим җәлләп-кызганып куйды. Хәтер ярлары киңәеп, исенә аның элеккеге яшь, гайрәтле чагы килде...

...Сабан туе алдыннан авыл тугайларга-болыннарга җәелеп бәйрәм итә иде. Аларны — Миргалимне һәм ике энесен — тарантаска утыртып, Сәлим абзый шунда алып төште. Ат ялларын чайкап-болгап җибәрә, аннары алга ыргылып, киң һаваны ерткандай кешнәп ала. Каяндыр яшь тайлар уйнаклап сикергәлисикергәли килеп җитәләр. Тарантасны әйләнгәләп йөри башлыйлар. Ә болын киңәйгәннән-киңәя бара. Менә туктыйлар. Ак чәчәкләр җыя башлагач, Миргалимнең исе-акылы китә, бакчы, болында чәчәкләр күп һәм төрле-төрле була икән! Сөенеченнән Миргалим берсеннән-берсе кечкенә ике энесенә дә чәчәкләр өләшә. Шунда күк йөзе алланып, кояш батышка юнәлә... Сәлим абзый һаман елмая...

Миргалимгә этисе һәрвакыт шулай елмайган төсле булып тоела. Ул аны шуңа да бик сагына иде. Хәрби хезмәттән дә хатта "этием" дип язды. Менә хәзер дә, шушындый орышудан-үпкәләшүдән соң да ул аны яратып күкрәгенә кысарга риза, әмма нишлисең, атага да бервакыт балалары ятка әверелә, чит була башлый икән шул.

4

Миргалим икенче көнне әтисеннән иртәрәк торып, ашыга-ашыга киенде дә, ашауны да исенә алмыйча юлга ашыкты. Аны Хафизов болай ук иртәләп килер дип көтмәгән иде дә. Кичә Миргалимне бераз үртәп алуына бүген бераз борчылган мастер, шушы борын асты кибеп җитмәгән, инде нефть эшенә алынырга җөрьәт итүче сала малаеннан моны ук көтмәгән иде. Бүген, үпкәләп, күзгә дә күренмәс, эштән дә китеп барыр әле дигән иде. Ә егет — килгән. Барыннан да алда килгән.

Мастер кырын күз белән генә аңа сөзеп карап куйды:

— Килдеңме?

— Килдем!

Алар эндәшмичә озак утырдылар. Мастерниләрнедер санау-барлау белән мәшгуль иде. Ниһаять эшенең очына чыкты ахрысы, елмаеп:

— Инде таң да аткан икән,— дип куйды.

Миргалим аңа бу ахмакмы әллә дигән төсле караш ташлады. Әмма мастерның исе дә китмәде.

— Җеп очы табылды бит... Табылды...

Мастер тагын да сөйләнгәләп куйгач, сүз ияртә сүз чыгарып, сораштырырга тотынды:

— Атаң бригадир икән синең?

— Әйе!

Аның бригадир булуында минем ни эшем бар, йөрсен шунда дигән үпкәле караш егетнең күз карашыннан сиземләнә иде.

— Нәрсә, тавыш булдымы әллә?

— Ә-ә, була инде ул!

— Не вешать нос!..— дип чатнатып әйтеп куйды мастер.— Нинди эш бу?

Аннары ул ярым шаяру тонына күчте:

— Минем дә шулай булган иде ул. Менә хәзер, уч төбенә гөресе белән акча кайтарып тоттыргач, шык та итми. Алар шулай инде, җир дә җир — телләрендә... Җиремне кемгә калдырасың, йортның нигезе тарала, имеш... Йорт нәрсә ул, агач, бүген — бар, иртәгә – Алла сакласын! Йорттамыни эш? Акча булса, шулаймы?— Мастерның авыр кулы Миргалимнең җилкәсен беркавым сулга кыйшайтты. Егет авып китүдән көч хәл белән генә котылып калды. Ә Хафизовка нәрсә, елмайды-көлде генә.

— Миңа акча кирәк түгел,— дип сузды Миргалим.

Мастер каршы килмәде:

— Ярар, бушка эшләрсең, акчаңны мин алып барырмын...

Миргалим авыз чите белән мыгырданып куйды:

— Бирермен, әйе, тот!

Мастер тагын елмайды:

— Шулай диген аны, а ту, киләсез дә, миңа акча кирәкми, имеш, мин дегет эчендә туган, дегет эчендә йөзәсем килә... Йөзегез, сезгә кем мишәйт итә?..

Миргалим ык-мык килеп, тегеләй-болай сүз башлау ягын карады. Укмашкан теле оешмаган сүзләрен авызлыклап тора иде.

Буровойдан смена кузгалды. Алар будкага таба якынайган саен тирә-юнь

тынычланганнан-тынычлана, Миргалим каушаганнан-каушый бара иде. Ничек ияләнеп китәсе шуларга?

— О, Мирго!— дип сузды кулын керә-керешкә украин егете.— Мастер, бир син бу малайны үземә, егет итәм мин аны... Нишләтим, үлеп гашыйк мин аның үзенә, чынлап менә!.. Бир үземә, мастер?..

— Җәлке...— дип җавабын озынга сузып әйтте Хафизов.— Дәшмә дә, сөйләмә дә... Бирмим... Синдә, имеш... Минеке, имеш... Безнеке, диген!

— Мирго, сизенәсеңме? Безнең мастер — интернационалист... Халыклар дусты! Үлеп урысларны ярата, ә хатыны — татар!

Шушы җитә калды. Егетләр аның сүзләрен эләктереп тә алдылар, көлешә-көлешә анекдотлар сөйләшүгә дә күчтеләр.

Яңа смена килгәч кенә, бүген ял да итәсе барлыклары, төне буе эштә алҗыганлыклары исләренә төште, тиз арада җыелышып алдылар да, бөркәвечле машинага утырышып, кайтып та киттеләр.

Яңа смена алар кебек хәрәкәтчән һәм сүзчән түгел иде. Бригадирлары Галиулла Вәлишин эшкә оешуны да тиз тотты. Миргалимне өскә мендереп җибәрде. Аның бар эше җир эченә әле төшерелгән, аннан әле күтәртелгән торбаларны ычкындырып-эләктереп тору иде...

Каланчада җил сызгырды. Гүя ул: “Курыкма, курыкма!”— дип эндәшә иде. Җил белән бергә җылы җәйге иртәнге һава борын төпләрен кытыклап үте. Рәхәт иде.

Ә рәхәт озак буламыни? Кояш кичкә авышканда Миргалим инде хәлсезләнгәнен, куңелен дә курку баса башлаганын тойды. Биектә, каланча өстендә болытлар йөзә, ә аста бригада егетләре кайнаша. Буровой улый, үкерә. Бертуктаусыз “вера”, “майне” тавышлары белән чуен торбалар чыңлавы кабатланып тора. Нинди мәхшәр, нинди чуар мәгънәсезлек. Ә менә шул мәгънәсезлекнең асылында зур бәхет, батырлык ята. Үз мескенлегеңне җиңүне, кеше булуыңны таләп итә торган батырлык ята. Алай гына да түгел, бу батырлык ныклы һәм куәтле хисләр эченә чумган хезмәт матурлыгы күгендәге бер кояш төсле балкып, барлык чит-ят йөрәкләрне, моңарчы бер-берсен күрмәгән, барлыклары хакында уйлап та карамаган эшчеләрне бер санга, бер дәрт куенына җыя. Эһ, яшисе иде шулар белән бер сүздә, бер агышта һәм бер куәттә булып! Тик алар беләләр — кем аларныкы, кем алар өчен яна!

Җил һаман басу-кырлар буйлап йөгерде дә йөгерде. Кемнәрнең борынына, кемнәрнең йөрәгенә үк керде.

Смена азагында егетләр үзләренең батырлыкларын аңлаган төсле көлешә-көлешә мастер будкасына таба юнәлделәр. Шаян йөзләрендә май аеның кичке кояш яктысы иде.

— Ну егетләр,— дип елмайды Рәсим.— Кирәк булса, менә шушы Хафизовны да мәтәлдереп җибәрер идем... Булды бит, ә?

— Шыпырт,— дип эндәште аңа бригадир.— Чебешләрне көз көне саныйлар.

Рәсимнең килешәсе килмәде. Ул һаман мактанып:

— Ничек көз көне? Юк инде, иптәш Вәлишин, көнлекләп санар вакыт җиткән!

Барысы бердәм көлешеп куйдылар.

— Санарсың, пычагым...

Бригадир бу сүзләрен дә ачулы гына әйтте.

— Сезнең белән бары ташбака өстендә генә йөрергә була!

— Ничек диде, егетләр, ничек-ничек?

Рәсим аның белән килешми иде, ачуы таудай кабарды:

— Безнең беләнме?

— Сезнең белән!

Рәсим ачулы сүзләрен тутырып-борычлап җавапламакчы булган иде дә бригадир аңа ябыштырып та куйды:

— Күперенмә, күркә булырсың! Инде ничәнче коены казуың? Скважинаны ничәнчесен куясың дим?

Рәсим тынды. Эшне җаена әле яңа төшенеп килә торган егет үзе дә сизмәстән инде һавалы хисләренә атланып очканлыгын төшенде булса кирәк. Әмма бригадир башкаларның күңел ялкыннарын сүндерә алмады. Егетләр берберсеннән узышып көлештеләр, сабантуйларда булган-күргәннәрне сөйләшкәләделәр.

Аларның көлешү тавышларын басу буйлап җил таратып йөрде. Шул җил белән бергә буровой яныннан гөрселдәгән тимер шаңы ишетелде. Бригада халкы тавыш килгән якка ялт борылдылар. Гүяки каланча-вышка ава төсле иде. Аның торбалар өя торган кузласы өстендә Миргалим утыра, ә ул ыргыткан авыр чүкеч ике-өч метр гына арырак аунап ята. Кечкенә чүкеч тә колак итен ертырлык тавыш чыгарыр икән.

— Ни булды?— дип кычкырды Миргалимгә бригадир.

Егет эндәшмәде.

— Ни булды дим?

Инде үз аңын җыйган егет:

— Чүкеч төште, каяндыр өстән төште...— дип әйтергә үзендә көч тапты.

— Нәрсә-ә-ә?— дип, аңламастан гаҗәпләнде бригадир.

— Чүкечне өстә оныткanмын,— диде, тора торышка Миргалим.

Һичнәрсә аңлаша алмаган бригадирлары соңыннан барысын да төшенеп, озак вакытлар бу вакыйгадан үзара көлешеп йөрделәр. Ә ул хәл болайрак булган иде: Миргалим “высотка”да чүкечен онытып калдырган, юк-юк, дөресрәге — “высотник” кәрҗине-оясы читендә. Алҗуы-арыганлыгы аркасында идәнгә алып куюны исенә дә төшермәгән. Һәм менә егетебез чыгып килгәндә, ул авыр чүкеч, урыныннан кузгалып, аска очкан. Әгәр дә Миргалим ике генә адым кызурак атласа, харап буласы икән.

Егетләр, алар буровое янына яңа автобус килгәне күргәч, бөтенесе берьюлы дәррәү куптылар. Автобус аларга “сменчик”ларны китергән иде. Алдан мастер Хафизов чыкты. Күңеле күтәренке, кыяфәте зур тантанага килгәндәге төсле бик килешле иде.

— Ну, егетләр, менә, беренче автобус, яңасы, үзебезгә!— дип мактанып куйды ул. Һәркайсының кәефләрен сораштырды. Эш хакында ләм-мим һичбер аваз салмады. Егетләргә бу ошап җитмәде ахрысы, алар алабуга балыгы кебек кылчыкларын кабарттылар. Вәлишин да түзмәде, үлчәп-нитеп тә тормастан, ту-

рыга ярып сорап та куйды:

— Купшыланып кая барыш?

Мастер аңа елмаеп кына җавап кайтарды. Кәефе үтә яхшы иде. Ул барлык эшчеләрен энә күзеннән үткәргәндәй сынап карап үте. Аннан соң нәкъ Миргалимгә төбәп:

— Ничек соң, авырмы?— дип сорап куйды.

Миргалим үз кирелеге белән “матурмы” дип аңлады бугай:

— Матур!— дип җавап бирде.

Егетләр һәммәсе кинәт бердәй үзгәреп, шаркылдаша-шаркылдаша көлешә башладылар. Аларга хәзер Хафизовның ыспайлыгы түгел, Миргалимнең беркатлылыгы ныграк якын иде.

— Ә нигә?— дип сорап куйды Миргалим.— Ә нигә?

Барысы да тагын-тагын да көлешә бирделәр. Хәтта Миргалимгә, шаяртып, җилкәләре-куллары белән төрткәләделәр.

Автобус китәргә ашыгуын белдереп аваз салды. Егетләр Миргалимне дә, өстерәп үк алып диярлек, үзләре янына утырттылар.

Һай төшеп каласы килмәде Миргалимнең автобустан. Күңеле бригадасы белән иде. Ә монда? Монда ни буласын белгән юк! Кунарга әтисе кертсә ярар иде дә бит... Бар киемнәреннән дегет исе килә. Өйләренең бәрәкәтен качыра дип тагын җанын ашармы улының? Эһ, шул җирем дип, күмхуҗым дип үлә инде. Мәңге шулай гына һәм искечә генә торыр-торгызыр иде...

Әмма Миргалим ул әйтте дип барыбер кире борылачак түгел. Монда аңа ямьлерәк һәм күңеллерәк иде. Ул көн саен басу буйлап җәяү генә эшенә ашыкты, “смена”сыннан соң көн дә аны автобус белән кайтарып куя тордылар. Миргалимгә шулай йөрүе рәхәт һәм кызык иде. Күңелеңдәге барлык хисләрне кырларга җырларың белән таратып барасың. Сиңа күңелле, бик күңелле. Яшисе, мең яшисе килә!

Миргалим һәммә алган хезмәт хакын-акчасын әтисенә кайтарып бирсә дә, малаена карата Сәлим абзыйның күңеле һич йомшармады. Ул төкерде генә, әмма хуҗалыгы эшләрендә терәк барлыкка килүне, аның тагын да ныгып китүен, кул арасына яңа көч кергәнлеген күршеләре тоймый калмадылар.

Ә Миргалим озак та үтми башын да калкыта төште. Беренчедән, авылда күз төбендәге егетләрдән булса, икенчедән, типсә тимер өзәрлек гайрәт иясе ул, буе дисеңме, озын аяклары белән атлап килүләре дисеңме — болары аның юлына аркылы төшәргә уйлаган һәркемнең котын алырлык иде. Әмма Миргалимнең күңеле кешелекле һәм уйлары бик тә ипле иде. Яшьлек һәр егеттән үз җырын җырлата, диләр. Миргалим белән дә шулай булды. Ул йомшаклыгы белән яшьлеген бергә кушты. Һәм менә скважина коесын казып бетерүне “яхшылап” билгеләп үттеләр. Миргалим монда да үзен дәрәҗәле тотты. Әмма ләкин, егетләрнең хатын-кыз заты хакында сөйләшүләрен тыңлап торганнан соң, үзенә-үзе бәя дә куярга өлгерде. Имеш, ул — җебегән икән! Гомерендә бары тик Фирүзәне, җан кисәген сөеп иркәләгәненнән гайре башка кешене һичбер күрмәгән дә түгелме? Менә шул уе Миргалимне биләп алды. Ибенә-биген китерде. Аның батыр буласы, һәркемнән өстен чыгасы килеп китте. Бу — балалык иде. Әмма егет хис-тойгыларының асылын сизмәде-төшенмәде. Менә шунда ул

җебек авызларга хатын-кызлар хакында берәр кыйсса сөйләп җибәрсә, тиз арада үзләренең кемлекләрен белерләр иде, имеш...

Миргалим исерде. Нык исерде. Гомерендә булмаганча исерде.

Авылына кайтып җиткәч, кем капкасын кагасын исенә төшерде. Аны Мәһинур өнәп каршы алды. Әмма Миргалим аларга кереп оялагач, егетнең күсәктәй кулларыннан чирканган ханым почмакка сеңде. Төн караңгысы җиделе лампаның сүрән яктысын басып тора иде. Миргалим өстәл башына аракы чыгарып куйды. Бәйрәмнән калган яртының бер өлеше кесә төбенә түгелеп лыҗырдаткан иде.

— Эчик,– диде Миргалим,— минем эчәсем килә!

— Син эчмә инде, энем, бар, кайт, исерек бит инде син!— диде аңа Мәһинур.

— Эчик,— диде Миргалим, үртәлеп. Тик туташ ашыкмады, икенче яктан сүз катып карады.

— Әниең белсә ни әйтер? Нишләп болай йөрисең син? Бер дә мондый дип белми идем үзеңне!.. Нишләвең бу?..

Миргалимне, кәҗәлеге чыкса, үгетләү авыр иде. Татар булмый кала бит! Мәһинурның сүзләренә исе дә китмәде, үзенекен тәкрарлады:

— Эчик!..

... Эчтеләр.

Гүяки гомумән таныш булмаган ике кеше үзара уртак тел тапкандай иделәр. Озакламый Мәһинур үзе үк Миргалимгә якыная башлады.

— Миргалим, күтәр әле кулыңны?..

Туташ егетнең кочагына кереп оялады. Аңа Миргалимнең күзләре мәченеке кебек яна, дагалана башлаган кебек тоелды. Тик туташ ашыкмады.

— Ярамый... Ярамый... Кирәкми... Ашыкма, Миргалим, ашыкма!.. Минем күптән иркә-наз күргәнем юк инде, ашыкма!.. Син иркәлә мине, яратып иркәлә!..

Төн караңгылыгын ертып машина яктыртып үтте. Җәйге тузанны басып җиләс яңгыр сибәли башлады. Ара-тирә йөгергән яшен чаткылары ике шәрә тәнне йоклаткан караватның да тимер бөгәрҗәләрен яктыртып-ялтыратып уза иде.

## 5

Сәлим абзый бу төне дә иркенләп йоклый алмады. Җиле дә, яңгыры да аның ачуын гына кабартты. Ничә көннәр шушылай көндезен — аяз, кичен — яңгыр. Ни печәнгә төшеп булмый, ни башка эшләренә кулы бармый. Печән! Печәнсез калса, күмхуҗ — күмхуҗ түгел инде ул. Печән! Малны шул тота. Печән!.. Былтыр бу вакытта икенче эскертне куеп бетереп килә иделәр инде. Быел әле беренең яртысы да юк. Бозылды замана. Җирнең куәтен шулар гына бетерде инде — дегетчеләр! Маеңны-каныңны ала башласыннар әле, чыдарсыңмы? Әһе-һе-һе!..

Аның монысы да кая йөри икән? Юк, мәсхәрәнең бусына түзеп тору юк! Үз җанымны ашаучы малай үстерермен дип кем уйлаган? Юньсез!.. Ул да үзен кешегә санап йөри бит!

Сәлим абзый йокы кермәгән күңеленә урын таба алмый идән буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Йокы аралаш Хәлимә җиңги:

– Нишләвең бу? Әллә намазга күчтеңме? Ни укынасың?— дип мыгырданды.

Сәлим абзый гомер иткән хатынын эттән алып эткә ташлый-ташлый сүкте. Яңгыр тукталгач кына тынычланып, карават читенә яткан килеш йоклап китте.

Уянып киткәнендә бер ягы ямьшәйгән, муен тамырлары сызлап авырта иде. Сәлим абзый башын алга-артка җибәреп, урык-сурык китереп карады. Әмма муен тамырлары һаман авырта иделәр. Моңа кушылып, җитмәсә, күз аллары да тоныклангандай булып киткән төсле, башы да тубал кебек иде. Сәлим абзый бу минем башмы икән, урындамы соң бу дигән төсле, кулы белән аны тоткалап карады. Тик каны оеган урыннар йомшарырга ашыкмыйлар иде, аңа салкын су белән юыну да ярдәм итмәде. Иртәнге чәй алдында да ул сыпыргаланып кына утырды, ашаган ашы да күңеленә ятмады. Чәй янында сөйләнгәләргә яратучан Хәлимә җиңгигә дә өреп кенә алды:

— Нәрсә мыгырданасың инде, убырлы?!. Өшкеренеп-төкеренеп мине сихер кылуыңдыр әле,— дип, аллы-артлы сөйләнде Сәлим абзый.

Усаллыгы тел очына зәһәр агу булып җыелып килә иде инде.

– Әйе, малай кайтмады бүген...— дип сузды сүзләрен Хәлимә җиңги.— Ачуыңа тыгылырсың...

Сәлим абзый тагын да бозылып, кабатлана-кабатлана бар ачуын чыгара башлады:

— Ну, понимаешь, инде икенде күләгәсе буена җиткән малаеңны да тикшер, күмхуҗ эшенә дә чап... Нәрсә карадың? Артыннан тагылып йөре! Бүген кайтмый, иртәгә кайтмый башласа, көт тә тор: салалар да куялар безне таш капчыкка. Әйтәм бит: ул дегет эше юньлелеккә илтәме дип! Тамак чылатырга өйрәнде, менә аннан, көт тә тор!..— Сәлим абзый сүз таба алмыйча, күзләре белән бар өй эчен айкап, һәр нәрсәне барлап чыкты.— Бездән сорарлар, әйе, кемне үстердегез, диярләр. Ярый ул, прокурор алдына басарга була, ул сине белми, син — аны. Ә монда бит халык бар. Гавам-халкы бар! Ничек күренерсең? Әнә эттән яман Сәлим малае, үзе эт, малае эт, диярләр...— Ул, сүзләреннән тукталып, карчыгына бераз вакыт карап торды. Аннары кинәт: — Нәрсә утырасың? Тап!— дип җикереп җибәрде.— Мине малайсыз калдырасыңмыни?

Хәлимә җиңги түзмәде, сүтелеп китте. Карт йөзе җыерчыкланып, минут эчендә күз яше белән коенды. Ул, өстәл яныннан китеп, яулык чите белән генә чеметеп-чеметеп битләрен сөртте. Озак кына күзеннән яше китмәде.

— Кая барыйм инде...— дип сукранды ул.— Беренче малаең булса да, соңгысы түгел бит, өй тулы ир-ат... Малай дип үзәгемә төшкән идең, ярдәмчегә бер кыз да булмады шунда, һаман малай да малай... Туясың юк инде!— диде, үзенә усаллыгын җыеп һәм елаудан кинәт туктап калды.

Сәлим абзый да бу юлы ачуланмады:

— Һәй, эшендә йөридер әле... Эшләре бетмәгәндер!— дип сөйләнеп куйды. Аннары хатынына сиздерми генә басу ягына чыгып, буровойга таба колак куеп торды. Буровой каланчасының гадәттәге дөбер-шатыр эшләп утыруы ишетелми

иде. Анда җан әсәре барлыгы да сизелмәде. Тик ишек алды ягыннан сак кына капка ябылган тавыш ишетелде.

Сәлим абзый өйгә керде. Түрдә улы Миргалим, ярым айнык, ярым исерек хәлдә, чишенергә теләп булса кирәк, костюмнарын эләргә элгечтән буш урын эзли иде. Сәлим абзый аны күрмәмешкә сабышты, тик кайнап торган ачуы аның бөтен тырышлыгын югалттырды.

— Кайда йөрисең син, эттән туган нәмәрсә? Халыкта булмаганы син кыланасың инде! Ничәнче көнең китте бит! Ата йорты дип белмисең, лыгырык булып эчеп кайтасың. Кеше баласы булса, оялыр иде...

Миргалим аның сүзләренә игътибар итмәгәндәй, күкрәк кесәсеннән бер йомарлама акча чыгарып, атасына сузды. Сәлим абзый моңа каршы туздай кабынып кына китте:

— Төкерәм мин синең акчаңа!— Ул малаеның акча тоткан кулына сугып җибәрде. Акчалар бик ишле булсалар иде кирәк, идәне тутырып чәчелделәр. Сәлим абзый бу тамашага телсез калып, улына күтәрелеп карарга кыймыйча, ничектер уңайсыз хәлдә тезләренә сыгылып төште. Җыя башлады.

Охшады аңа акчалар. Аз түгел бит. Бер уч!

Миргалим текә генә, атасына сөзеп карап алды. Күрдеңме безнекеләрне дигән кыяфәт аны батырайтты. Ул, салмак кына, үз җаен белгәндәй чишенде дә, карават буена сузылып яты. Яткан җирендә йокыга да китте. Кайвакыт саташынып, сүз аралаш аңлашылырлык итеп: “Маһинур, Маһинур!”— дип, җимерек тавыш белән йотылып һәм, ара-тирә, назлы гына: “Фирүзәкәй!”— дигән сүзләрне кат-кат кабатлап йоклады ул. Аның караватны иңләгән гәүдәсе, киң күкрәкләре бер үк вакытта дәһшәтле һәм, шулай ук баһадир икәнлеген сиздерә, кот очырып кымшангалап куюлары куркытырлык иде.

Сәлим абзый акчаларны сак кына җыйды. Бөгәрләнгән урыннарын сыйпаштырды, кат-кат санап узды. Әмма санына һич төшенә алмады. Тагын санады. Буталды, тирләде. Тәне буйлап йөрәге урык-сурык чабып йөрде.

Акча иде шул бу! Гомере буе каерып эшләгән, көрәп бәрәңге боламыгын ашаган крестьяның беренче тапкыр акча күрүе иде. Моның ише акчаның күмхуҗ кассасында да булганы юктыр.

— Акча!

Сәлим абзый шомланып куйды: “Бәлки?.. Алла сакласын!..— Бераздан үзен тынычландырды, кулга алды.— Юктыр!.. Дегет эшен акчалы диләр аны!..”

Бу акчаларны һичкемгә бирәсе килмәде. Ул аларны яу белән килеп алсаң да куеныннан чыгармас дәрәҗәдә үзенең гайрәтенә ышанды.

Ишек төбендә чиләк шалтырады. Хәлимә җиңги кола сыерын савып бетергән иде булса кирәк.

Сәлим абзый яшь чагында ясап куйган шкафының йозаклы тартмасын ачты. Акчаларны әүвәле саннарга teләде. Әмма тагын буталгач, тартмага салып, биген яхшылап бикләде дә, хатынының каршысына чыкты, авыз эчендә ботка пешергәндәй:

— Кайтты бу малай...— дип, мыгырданып куйды.

Таң матур, алсу иде. Гөлләрнең таҗларын, сабый баласын әнкәсе башыннан сыйпап иркәләгән төсле, кояш нурлары назлап сөеп үттеләр. Агач яфракларын-

нан тамгалаган төнге яңгырның төймә-төймә тамчыларына ияртем таң җиле исеп куйды. Ерак урманнан күке тавышы ишетелде. Рәхәт иде яшәве, рәхәт иде.

Хатыны янынннан Сәлим абзый эре генә узып китте, мыгырданып җырлаштыргандай итте:

— “Ал-су-лана, моңла-н-на...”

Һе, әйтеп карасыннар хәзер малаеңнан эш чыкмады дип! Күрсәтерләр әле сәлимнекеләр, күрсәтерләр!

— “Җир безнеке булыр, ачулансак...”

Сәлим абзый куәт белән читән казыгына барып ябышты. Казык, шуны гына көткәндәй, ярым ямьшәеп төште.

— Кайчан черергә җитешкән диген?

Сәлим абзый үз-үзе белән сөйләшеп, абзар-кураларны, йорт тирәләрен әйләнеп узды.

— Күрсәтерләр әле, күрсәтерләр... Ну малай!.. Мин аны юкка йөри дип торам. Ә ул! Мә эти дип бит ә!.. Ал, ди!.. Сиңа алып кайтым, ди!..

Сәлим абзый бу ялганына үзе дә сизми ышанып куйды.

Көтүләрне бер кат озаткач, тагын чәй яңартырга кушып, түшәккә башын төрткән килеш тавык йокысы белән черем иткән Хәлимә җиңгәчәйне дә торгызды. Үзе, тәрәзә янына килеп:

— Әллә инде бүген тагын да яварга итә... Кояш болытка югалды. “Зәмзәм суы”ннан да авыз яңартсаң ярар иде бит,— дип, җиңгәчәйне күзләп алды. Тегесенең бар эше чәй хәстәрендә иде. Ул иренең ни сөйләгәненә һич колак салмады. Сәлим абзыйның кирле-мырлы әйткәләгән сүзләрен тыңламаска иткән иде бугай.

Чәй өлгергәч, Сәлим абзый, байлар кыяфәте илә киерелеп алып:

— Хәлимәкәй, утыр әле, сүз бар иде,— дип куйды.

Җиңгинең моңа тагын исе китмәде, шулай да бу сүзләренә колак салмый калмады, хәтта җавап та кайтарды:

— Эшеңә соңга калма, персидәтел килгәнне көтеп торма,— дип, күңеленнән сабыр гына бер кәлимә сүз чыкты.

— Калмам,— диде Сәлим абзый.— Без эшлисене бүтәннәр башкармас, безгә дә калыр. Тәпигә тора башлаганнан эшлибез, Аллага шөкер!— дип сөйләнеп куйды.

Хәлимә җиңги каршы һичбер сүз әйтмәде.

Әмма Сәлим абзыйның аны котыртасы килә иде, тик уе барып чыкмасын гына сизеп булса кирәк, турыдан-туры, мәче-тычкан уенын уйнап тормыйча, һөҗүмгә күчте:

— Баедык бит әле, Хәлимәкәй!— Ул сынап кына хатынына карап куйды...

— Малай кайтты да... Әйе, син сыерны сава идең, тотты да, менә, эти, сиңа үземнән акча, аз булса да булышу булыр, ди...

Ул шкаф тартмасын барып ачты. Миргалим шулвакыт ыңгырашып куйды. Сәлим абзый җәһәт кенә шул якка күз салып алды. Юкка борчылды, Миргалим әйләнеп кенә яткан икән. Бик яхшы, саташып мыгырданганы да бетте.

Сәлим абзый тартмадан кызыл, шәмәхә акчалар чыгарды:

— Менә, хатын, күр!.. Мондый акча безнең күмхуҗ кассаларында да юк...

Өр-яңалар! Миргалим бирде. Яхшы эшләгән өчен хезмәт хакы, ди... Мә, эти, ди бит, ә!.. Ал, ди, сиңа алып кайтым, ди... Теләсәң нәрсә эшләт, ди...

Сәлим абзый хисләнгән саен ялгышты, ялгышкан саен үз хыялларында үзе адашты. Чәе шикәрсез дә татлы, ипие майсыз да бик тәмле тоелды. Чәй арасында хатынына сөйләнә-сөйләнә, әллә ниләр эшләтү, гүяки дөньяның үзен сатып алуда фикерләнеп планнар корды. Аның бар уйларын идарәгә чакырып килгән хатын гына бүлде. Хыялланып утыра торгач, Сәлим абзый иртәнге эш бүлешүгә соңга калган иде.

6

Идарәдә аны көтеп алганнар икән. Ишек буенда тезелешкәннәр:

— Хәлимә җиңги бүген кочагында йоклаткан ахрысы,— дип, үзара шаяртышып, сүзләре белән төрттереп калдылар. Әмма Сәлим абзый аларга бик алай игътибар итеп тормады... Сөйләшеп маташыр чакмыни?..

Күмхуҗ башы рәис Хөсни малае Рифкать мыштыр-мыштыр гына вак-төяк кәгазь, сводка кисәкләрен актарып утыра иде. Сәлим абзый белән дә баш кына кагып исәнләште. Күренеп тора, нидер булган, йөзе караңгы иде.

Моннан берничә ел элек институтта читән торып укыганнан соң бераз агроном булып йөргән Рифкатьне көтмәгәндә күмхуҗ башына утыртып куйган иделәр. Дөресен әйткәндә, ул белеме зур булу аркасында бу эшкә кулай кеше булып чыкты. Янәшә торган ике авылдагы ике күмхуҗны кушкач, мондый зур хуҗалыкта дәүләт киңлекләреннән торып эш итә торган кеше кирәк дип озак уйланылганнан соң сайланган рәис иде ул. Халык аны авторитеты өчен түгел, бәлки якын итүе аркасында, үз кеше булганга куйды эш башына. Әйе, Рифкать үз кеше иде. Ятим үсте, эш рәтенә өйрәтергә этисе булмаса да, үзенең үҗәтлеге, һәркемгә булышырга омтылуы, үзсүзлелеге белән бу китек ягын тутыра белде. Әнисе Хөсникамал түти, аз гына шәйле толлардан булса да, баласын тәрбияләүгә бар көчен-җанын куйган иде. Әмма малае ничектер, әллә үсеп җитүе аркасында, әллә әнисенең акылы шәйле булудан шикләнеп, берара чит-ят җирләргә чыгып, югалып та торды. Анасы нинди генә изага төшмәде, күзләрендә яше кибеп, сукыраю галәмәте якынайгач, улы кайтып керде. Һәм шуннан бирле ике аягының берен дә чит якларга атламады. Хөсникамал түтине яхшы тәрбия кылу уе белән ул бер яшь җиңгәчәйне йортка алып кайткан иде, әмма тегесе, карт анаңны нишләп саклап ятыйм дип киткән дә барган, диделәр. Ә Рифкать бирешмәде. Үзен-үзе җиңә белде. Әнисе дә, үз җаен алып, улын хафаларга салмаска тырышты. Карчыкның гүя акылы кире кайткандай, күзләре дә сихәтләнгәндәй булды.

Тик төннәрен-иртәләрен, улым өйдәме икән дип түрдәге караватта йоклаган сөеклесен кат-кат караштырып, үз алдына сөенгәләп Коръән сүрәләрен, белгән йола-бәет-җыруларын такмаклап утыра-утыра йоклавын онытып ук бетерә иде. Әмма малае, мыштым гына маташса да, эш белән йөргән икән, тракторны ремонтка җибәрәләр дигән булып, әнисенең рөхсәте белән атна-ун көнгә калага барган да институтка кереп кайткан. Моны Хөсникамал түти белми дә калды. Улы төннәр буе әллә нинди калын китапларны укыган чакларында, кәгазь-каләм эшенә күнегеп киткәндә: “Йа Рабби-Аллам, бу баланың зиһеннәре тара-

лып, кеше көлкеләренә генә калмаса ярар иде инде!”— дия-дия, пәйгамбәрләр-фәрештәләр белән сөйләште. Төн йокламас улына да:

— Алай итмә инде, йөрәк парәм, шулкадәр күп укымасаң, тракторың йөрмәс дип беләсеңме?— дип ялвара-үтенә, Рифкатен берара гел укымас иткән иде, тагын, әллә каян шунда, элекке гадәтен яңартып җибәрде улы. Хөсникамал түти:

— Хөсни малае югарыда укый икән, өйдән торып укып, зур кеше булмакчы,— дип сөйләнүче кешеләрдән ишеткәч кенә, Рифкатенең эшенә комачау итү гадәтеннән туктады.

Рифкать җиңде. Институтны бетереп, диплом алып кайтты да, менә сиңа мә, зур кеше булып китте. Тик төннәр буе исәпләп, укып утырулары гына гадәте булып калды. Ә Хөсникамал түтинең яңа борчулары туа торды.

Аның барлык исәбе — уңган киленле булу иде. Кайчандыр йортка кереп чыккан хатынның исә монда исе дә калмаган, йа Рабби, әллә шул, бу өйләнгәнме дип, кызлар үзенә карамыйлармы икән? Хөсникамал түти ни итсә-итте, күрше-күлән карчыкларын көйләп-яраштырып, алардан кыз димләттерде. Югары оч Гайса кызы Миңлесорур, яше дә бар, тазалыгы да, диделәр. Ә чибәрлекне туйда гына карыйлар!

Булмады, юкка күрше-күләне белән Миңлесорурны җилкетте, юкка мең үлчәргә, хафаланырга, кияү кочагын уйларга хисләрен кузгатып җибәрде. Кыз никадәр көтсә дә, Рифкать ашыкмады. Ул килмәде.

— Улым риза булмаса, үзем алып кайтам, берниенә дә карамыйм, бик уңган, булган бала ул,— дип сөйләнеп йөргән Хөсникамал түти дә телсез калды. Улы, кистереп:

— Кирәкми, иртәрәк әле,— диде, — Минем үземнең йөргән кешем бар, киленле булырсың!

Шул елны Рифкать өйләнде. Хатыны бу якларда күренгән кеше түгел иде. Аны күпләр:

— Хахул икән ул,— диделәр.

Кемнәрдер:

— Марҗа!— дип бәхәс корды.

Ә чынлыкта аның хатыны Дон буеннан, нинди юллар беләндер бу якларга сугыш чорында килеп, башта балалар йортында эшләгән, аннары күрше район сырхауханәсендә шәфкать туташы булган Маша түтәйнең кызы Надя иде. Авыл халкы Надяга беренче көне үк Наилә дип исем такты. Тик бала-чага гына: “Нәдә түтәй, Нәдә түтәй!”— дип сөйләнә бирде.

Ә Наиләнең хахул кызымы, марҗамы булуына корылган бәхәскә Рифкать рәис булып алуга ук чик куелды. Ул марҗа да түгел икән, хахул кызы да булмаган ләбаса: татар, имеш! Тик Миңлесорур өчен Наилә һаман киндер ыштанлы марҗа булып калды. Ул аның таза-тулы гәүдәсен дә, озын буен да, татар кызларыныкы төсле кара чәчләрен дә яратмады.

Көндәшләр дүрт ай вакыт узгач чишмә юлында очраштылар. Тау астыннан менә торган тар такыр сукмактан мөлдерәмә тулы чиләрен көянтәсендә күтәреп Наилә күтәрелеп килә иде. Уйнап торган күкрәкләре, гүяки кысан күлмәге эченә сыешырга теләмәгәндәй, җанны үртәгәндәй сулык-сулык килеп тибрән-

деләр. Миңлесорурның үзенә көндәш тиешлеген белмәсә дә, Наилә нидер аңлагандай булды. Үтеп китәргә теләде. Миңлесорур тар сукмакта ян белән торып, көянтә-чиләкләрен җилкәсеннән төшермичә, Наиләнең юлына аркылы килде. Аска таба көндәшен этеп җибәрүдән аз гына сакланып калды. Наилә сукмактан арткарак чигенде, каршысындагы кешенең кем икәнлеген һәм ни сөйләгәнен аңлашып өлгермәде.

— Безнең егетләрне аздырып йөрмәсәң...— дип, берничә оятсыз сүзне ул арада Миңлесорур ябыштырып өлгерергә дә җитеште.

Наилә ул сүзләрен ишетте, тик мәгънәләренә төшенмәде. Куркынып читкә чигенә бирде. Калай әтәч шикелле, Миңлесорур аның артыннан атлады. Читәнгә килеп терәлгәч кенә Наилә Миңлесорурга күзләрен күтәреп карады.

Миңлесорур чигенеп куйды. Зәп-зәңгәр күзләр, кап-кара чәч, ап-ак маңгай, ярымай кара сызык кашлар, озын керфекләр астыннан текәлгән зәңгәр күзләр аны өшетеп үте. Ул куркынып куйды. Менә хәзер ул күзләр аны нидер эшләтерләр кебек иде.

Наилә, уңайлы мизгелне файдаланып, көндәшеннән ычкына алды. Чиләкләрен түгеп бетерә язып диярлек, ярым йөгерә, ярым атлый кайтып җитте дә, сарай артына чыгып, туйганчы елады. Аның беренче тапкыр күз яшьләрен сөртүче кешесе дә, иркәләп юатучы сердәше дә булмады. Әнисе аннан еракта, ә ул үзе — килен иде.

Наилә менә шушы елавыннан соң, күктә очып йөргәненнән җиргә төште, күбәләк кенә түгеллеген аңлады, йөрәк астында акыртын гына нидер селкенеп куйды. Һәм ул үзенең озакламый ана буласын, балага узган икәнлеген сизенде. Күз яшьләре белән бергә усал татар хатыннары хакындагы уйлары да күңел түрләреннән сыгылып агып чыккан кебек иде.

Бала — кайгыларны оныттыра белгән җан иясе... Бала — аналарга көч бирүче! Бала!..

Наилә моннан соң суга күрше хатыннары белән бергә төшәргә, ялгызы гына йөрмәскә өйрәнеп китте.

Ә Миңлесорур аның зәңгәр күзләреннән курка башлады. Алар аңа ниндидер яманлык эшләде һәм эшләр, һич югында ут булып йөзенә чәчрәр кебек иделәр...

Рифкать сүз башларга ашыкмады. Башта кешеләрнең җыелып беткәнен көтте булса кирәк. Аннары уйга чумды, тын утырды. Шуннан соң гына сүзен турыдан башлап:

— Бүген печәнгә төшәбез!— диде.

— Ә?.. Ни?.. Һе!..

Рәис бу ык-мыкларга игътибар итмәде. Сораштырырга тотынды:

— Беренче бригадада ничә чалгы җыелыр?

Сәлим абзый, урыныннан кубып:

— Кирәк кадәр булыр, анысы...— дип сузды.— Ир-ат халкы бик эшчән, әйе... Бер дистә чамасы булыр кебек, әйе...

Рифкать аңа карап куйды. Бу сан аз иде. Иртәнге утырышларда һичкемгә сүз әйтергә ирек бирмәүче, һәртөрле эшне сытып башкаручы Сәлим абзыйның тавышын да, үзен дә танымады ул. “Әйе, кебек, менә сиңа мә, менә сиңа...”— Моңа кадәр болар аның сүзләреннән түгел иделәр бит!

— Шул гынамы?

— Рәис иптәш, сездә инде сүз, кирәк икән, тагын да бишәүләп булыр, әйе...

— Ярар...

— Икенче бригада ничек?..

Сөйләшү озакка бармады. Әмма берәү дә яңгырдан соң печән чабуга тотыну мөмкинлеге хакында кайтарып сүз сорамады. Улы биргән акчаларның кай тарафка китәчәген исәпләп башын катырган Сәлим абзый гына, рәис:

— Атларга!— дип әйткәч, айнып киткәндәй:

— Ә нигә бүген төшәбез?— дип сорап куйды. Чыгып барган җирләреннән бригадирлар да тукталып аңа таба борылдылар.

— Әйе, ә нигә бүген төшәбез? Җир кипмәгән бит әле!

Сәлим абзыйга башкалар да кушылдылар:

— Ә нигә бүген?

Рифкать тагын кыска сүзле булды:

— Өстән шулай кушалар... Ярар, әйдәгез!

Акча кайгысыннан Сәлим абзый бары тик бригадасын җыеп бетергәндә генә котыла алды. Шкаф тартмасында яткан байлыклар мәгънәсез, әмма ышанычлы көч булып, йөрәгенә куәт биреп торырга тиеш иделәр.

Нәкъ баш очында гына карга каркылдап куйды. Аның тавышы шомлы иде. Халык нигәдер карга белән кайгының бәйләнеше бардыр дип уйлый. Ул гүяки кайгы гына алып килергә тиеш, кайгы хәбәреннән генә кычкыра. Ә югыйсә карга шатлыктан да аваз салырга тиеш бит!

Әмма карга тавышы бу юлы да кайгы булып ишетелде. Бригаданың алты кешесе дегет эшенә чыгып киткән иде. Кемнәр диген? Типсә тимер өзәрлек ирләр китә бит! Тагын хатын-кызга калырмы инде бу күмхуҗ? Алты кеше бит: Салих — югары оч Кәрим абзый малае. Әтисе күмхуҗга җанын биреп, барсын оештырып йөргән кеше иде. Сугыш чорында йөкле арбаны кендеккә утырткан-да эчен төшереп үзен харап итте. Ярый инде, Салих китсен дә ди, тормышлары авыр, сукыр әбисе, балалары, хатыны инде — ташка үлчим... Ә Камали нигә киткән? Үзе яшь чагыннан бирле арба-буразна эчендә үсте. Әлләниләр кыландырып, яңа төр бодай табып бирәм үзегезгә дип хыялланып йөргән Камали. Аңа дегет эшендә нәрсә калган? Ни һавасы, ни суы тозлы диләр бит ул дегетнең... Тагын кемнәр?.. Вәли Сәгыйте, Самат Шакиры... Барысы алты кеше бит! Типсә тимер өзәрлек ирләр, егетләр. Зарифка анда ни калган инде? Карт башы белән... Нәрсә дигән әле? Яшь чагым булса дигәнме? Яшьләрне котыртмаса, башка эше калмагандыр! Ә менә Салихтан моны көтәргә була иде. Атасы да гомере буе кала юлын таптады, бабасы да шул якларга китеп, әйләнеп кайтмады. Болар җиргә берекмәгән, болар...

Сәлим абзый шулай сөйләнә-уйлана, йомычкаларны-кайрыларны бер җиргәрәк өеп маташкан балта остасы Латыйп абзый янына килеп тукталды. Алар карашып куйдылар. Сәлим абзый агач-бүрәнәләр өстенә барып утырды. Латыйп абзый эндәшмәде, агачка чабылган балтасын алып, йөзен карады. Үткен иде. Чамалап сөйләш! Утын астына кыстырып куйган кайрагын алды. Кирәкмәсә дә тагын нидер эзләп маташты. Сәлим абзый останың болай үзен шикле тотуына, сөйләшми аптыратуына, башлап сәлам бирмәвенә ачуы килеп,

бер-бер усал сүз әйтергә атлыгып авызын ачкан иде, тыелып калды.

Алар чордашлар иде. Бересе — маһир балта остасы, икенчесе — данлыклы бригадир. Халык эчендәге кешеләр. Әмма оста, дөресен әйткәндә, бригадирдан өстенрәк иде: теле белеп түгел, кулы белеп эшли — бар кешегә дә бирелмәгән! Әмма Сәлим абзый барыбер башлап сәлам бирмәскә итте. Шулай да йомышын башкарырга тиеш иде ул.

— Син, Латыйп, ял ит... Тартып алыйк,— диде, әмма сүзен ары дәвам итә алмады.

Латыйп, ниһаять, җиргә төшкән кыска гына карандашын алды да, очын җентекләп карагач, колак артына кыстырды, Сәлим абзый янына килеп:

— Кордаш, синмени әле бу?— дип кенә әйтеп куйды.

Шулай да кул бирешеп күрештеләр, икесе дә авызларына папирос капты. Латыйп абзый кулына тагын балтасын алды, аны кайрау нияте белән тезенә җайлап куйды, әмма эшенә тотына алмый калды, Сәлим абзый сүз алды:

— Син нигә дип шушы йомычкага уралып ятасың? Шул балтаңны күтәреп йөри-йөри гомереӊ үтеп китә бит инде. Ни рәхәте бар, йә инде?..

Латыйп абзый күзләреннән елмаю нуры сипте. Теш арасыннан гына: “Һе!”— дип куйды.

— Иртән ничәдә торасың?— дип, үз сүзендә калды Сәлим абзый.— Биштә!.. Бәлки иртәрәк тә дер әле... Кич ничәдә эшеӊ бетә? Агачны күзләреӊ шәйләми башлагач! Ну, нәрсәгә инде? Күмхуҗда эшләсәӊ, келәтеӊ ашлыкка тулы торыр иде... Ә монда ни?.. Көнлекче булып, “озын берлек” артыннан йөреп гомереӊ үтеме?

Латыйп абзый тагын да: “Һе!”— дип куйды.

Күзләрендә сагыш бар иде. Әллә йорт тутырып йөргән ишле балаларын, әллә үзен җәлләп куйды.

— Эш беләнмени, эшеңнең яме булсын!

Латыйп абзый кыска сүзле иде, боларын да күңел түреннән бик саранланып кына чыгарды.

— Бүген печәнгә төшәбез, югары болынга... Әйдә! Хәзер үк!— Дип, Сәлим абзый кинәт кабынып, останың сүзен, инкарь буларак, кырт кисте. Бу сүзләр бөтенләй мәгънәсез һәм кинәт килеп чыктылар ки, Латыйп абзый усал карашын күтәреп, төбәп карап алды.

— Төшәсеңме?

— Кичә яңгыр яуды бит, төне буе... Җир дә кибеп җитмәгән.

— Җәйге көн, иртән яуса — кичкә кибә, кич яуса — иртәнгә!

— Ярар, төшәрмен!

... Сәлим абзый тыкрыктан урамга таба күтәрелгәндә әле һаман оста Латыйпның балта чапкан тавышы ишетелеп тора иде. Килерме, юкмы? Белмәссең... Балта чапканы саен бер тиен акча аның кесәсенә керә, диләр. Ә күмхуҗда аңа нәрсә: бушка эшләп тә рәхмәте юк!

Урам инде кипшегән, көн җылынган иде. Тагын шул каһәрле карга читән башыннан кычкырып калды:

— Кар-р-р... Кар-р-р...

7

Югары очтан акырын гына җил исеп куйды. Күңелендәге барлык кадерле өметләрне, тормышка, хәтта җиргә-күккә булган ышанычларны җимереп исте җил. Явар... Тагын явар, тагын, тагын!..

Сәлим абзый урам буйлап акырын гына җилгә каршы атлады. Ачуланды. Үзен-үзе битәрләп, бар самими күңел кылларын тетрәндереп орышты. Менә хәзер кире борылыр да, кайтып акчаларны яндырыр хәлгә җитеп битәрләде дөньялыкны. Акчаны тудырган, бар нәрсәгә акча аша карарга өйрәткән тормышны яндырасы иде...

— Ә ул — хаклы!

Кем, нәрсәдә? Ә шулай да хаклы! Бәлки оста Латыйп аңа караганда мең өлеш хаклыдыр? “Һе...” Тапкан бит! Үзен тапкан. Көн дә балта чаба-чаба беләкләре бары сеңергә генә калган, ә ул — эшли.

Дөнья!.. Эшли Латыйп, үзен-үзе белеп, дәрәҗәсен аңлап. Кулында бернинди хокук юк, ә ул — эшли. Хөкеме юк, ә дәрәҗәсе — бар! Ә син чабасың-чабасың, тырышасың, үз дөньяң җимерек, кеше дөньясы өчен йөрисең, ә алар... Эһ! Ә алар дегеткә кача... Юк, алар нефть эшенә түгел, акчага табына!

— Ә ул — хаклы!

Сәлим абзый барыр җиреннән борылды да өйләренә таба атлады. Килеп керешкә:

— Кая Миргалим?— дип тавыш салды, әмма аны тыңлап торучы булмады. Өйдә кеше юк иде. Тавык кетәклегеннән кичәге йомыркаларны җыеп керүче улы Галимулла күренгәч, ачык тәрәзә аша әтисе аңа эндәште:

— Миргалим абыең кая?

Улы тукталды. Әтисенә сәер генә карап куйды. Аннары җавабы тыныч кына ишетелде:

— Эштә!

Сәлим абзый чиста һәм пөхтә итеп җыештырылган караватка барып утырды. Аннары аннан торып, нидер исенә төшкәндәй, ишеккә таба китте:

— Эштә, имеш, эштә!

Аның өчен бары авылда гына эш була ала, калган һәммә җирдә, күмхуҗдан гайре урыннарда, хәтта завод һәм фабрикаларда да эт сугарып кына йөриләр иде.

Улы Галимулла белән ул ишектә кабат очрашты. Малае артка чигенде, йомыркаларны чак төшереп җибәрмәде. Сәлим абзый да, аларның тәгәри китүеннән куркып, шунда чүгәләп куйды.

— Әниең кайда?

— Әни эшкә китте. Әтиең кайтса, чәй ясап эчерт, диде... Эчәсеңме, әти?— Малай самавырның капкачын күтәрә үк башлады. Әмма Сәлим абзый ашыкканын белдереп кул гына селтәде.

— Кайчан китте әниең?

— Күптән инде... Югары болынга. Мин дә барам...

— Йөрмә! Бүген анда сиңа эш юк... Печән җыя башлагач барырсың!

Улы, куркып кына:

— Ярар!— дип әйтеп куйды.

Болынлыкка Сәлим абзый барып җиткәндә халык инде шактый җыелган, үзара сүз корып тора иделәр. Бригадирга артык игътибар итеп тормадылар, ара-тирә:

— Башлыйбызмы?.. Җире юеш шул әле... Иртәрәк... Печәнне сөрсетеп бетерәбез... Рәтле эш буламы соң шуларның?— дип, салпы ягына кыстырылган саламны йолыккалаучылар да булгалады.

Эшне җиңел кулдан булсынга Хаҗи бабай артыннан башлап җибәрделәр. Ул бераз ара чалгы белән чабып үтте дә, тукталып, маңгай өстенә кулын куйды, озак итеп карап торды, җир башын чамалады: көчне тигез бүлергә кирәк иде.

Болын гүяки кырт урталайга өзелде. Ә аннары халык кузгалды. Болын өстендә ара-тирә куркып-куркып кубыз тарткан чикерткә авазларын ярып чалгы янаган, үлән чапкан тавышлар кабатланып-кабатланып торды. Казанчылар белән Латыйп абзыйның да учак тергезергә маташканы күренде.

Төш якынлашканда күмхуҗга МТСтан калган дүрт тракторның икесе көчкә сөйрәлеп килеп җиттеләр. Тик алары да, болын башында тукталып, эшне башларга уйлап та карамадылар, уңлы-суллы казына, нәрсәләрендер боргалый башладылар. Аларны каршы алырга, эшне каян башларга күрсәтәм дип килеп тукталган Сәлим абзый, хәлләрен белешкәч, боларның яннарыннан өметсез халәттә кулын селтәп китеп барды.

Хәлимә җиңги чалгычыларны дәшеп кулын болгады. Казан янына халык җыелганчы аш тәмам куерып җиткән иде инде. Болытлар тугызларга таралып бетеп, төшкелеккә дөньялык эссе табага әйләнде. Һава бөркүләнде. Яңгырларның әсәре дә калмады.

## 8

Табакларына чумырып аш салынган кешеләрнең һәрберсе диярлек Хаҗи бабай тирәсенәрәк кунакладылар. Табында Хәлимә җиңгинең: “Ашагыз, аша, наныйларым!”— дип, һәммәсен ризыкка дәртләндергән, рухларын куәтләндергән ягымлы тавышыннан битәр һичбер башка төрле сүз булмады. Халык бары тик кашык белән генә җәһәт-җәһәт эшләде. Куаклыкта берөзлексез сайраган сандугачның әрсез тавышын бүлеп, авыл янындагы әлегә җылынырга өлгермәгән булырга тиешле буада су коенучы шау-шуга битәр малайларның, усал кыз балаларның кайчак чәрелдәшкән-үртәшкән тавышлары да ишетелгәләп, мөкиббән китә-китә тамак туйдыручыларның колакларын сакта тота иде. Печәнчеләр арасыннан иң беренче Хаҗи бабай кырын ятып, табагын читкәрәк этәреп куйды. Хәлимә җиңги ни үтенеп, тагын бер генә өлеш өстим дип, күңелләренә төшеп сыйларга тырышса да, аны күндерә алмады, бары үпкәләтмәс өчен генә әйтелгән сүзләрен ишетте:

— Син, Хәлимә килен, бер дә юкка бу боламыгыңны миңа бүлергә ашыгасың... Әнә, Зәки малаена сал, синең боткаң белән теле дә кереп киткән бугай... Хаҗи бабай, хәлең ничек, сөякләрең ниләр кыландыра дип тә сорарлыгы калмаган,— диярәк, балтачы Латыйп абзыйның үзеннән хәл-әхвәл сорамавына да, сүзсезлегенә дә төрттереп, җиңел ташлы тел тегермәнен көйләп җибәргән иде дә, барып чыкмады. Хәлимә җиңги аны аңламады булырга кирәк, гел дә кирегә сугып торды:

— Ашасын... Нигә кешенең җанын изәсең икән?.. Аша-аша, күңелем парәсе!— дип, һәммәсен шикләндереп, Латыйп абзыйны мактап, Хаҗи бабайны яманлагандай итте. Ә картлач, аның гадәтен яхшы белеп булырга кирәк, үртәде дә үртәде:

— Кара әле, Хәлимә килен, бу, тал чыпчыгы дип әйтимме, сандугачмы?— Әйләнәсендәгеләр аңа сәерсенеп карауга каршы күз читен сикертеп куйды.— Өздереп-өздереп сайрый, чукынчык, гел сине мактый. Баядан бирле тыңлап торам, әллә шул күрше авыл керәшене Ануфри инде, ә, килен?

Хәлимә җиңги казан тирәсен тырт-тырт әйләнеп узды, кулына чүмечен алып, ни кылырга теләгәнен үзе дә төшенми, тукталып калды. Бу вакытта Хаҗи бабай үзенең җор теле белән башкаларга да бәйләнә башлаган, адресатын үзгәртергә өлгергән иде. Ләкин алар бер-бер артлы бик тиз бирешә һәм үртәлә барганга күрә, үчекләнепме, ни ватылмас балтачы Латыйп абзыйның сүз күәсен тикшереп карарга итте. Монда да тагын барып чыкмагач, әйтәсен урап, үтелгән дәверләргә күчереп, үзенчәләтеп сөйләп китте. Кәефе көнең үзе төсле яхшы иде. Һаман да Латыйп абзыйга бәйләнүе иде:

— Энем, син, Латыйпҗан туган, ул вакытта менә мондый гына кендерик малай идең. Шулай да хәтеремдә, тавык чебиләре төсле аяк астына кереп буталып йөрергә өлгергән идең инде. Ә синең абзаң Шара Гарифҗан бик булган һәм күндәм кеше иде, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, үзен бер дә юкка гына әрәм итте шул... Менә бит ул тормыш нинди!

Хаҗи бабай сүзеннән тукталып, авыл якларын, болын-әрәмәлек, тау башларын күз белән берәмләп, гүяки капшап узды. Аз гына, сары тары бөртеге кадәр генә томанлы яшь аның керфек очларында асылынып калды.

— Шул Шара Гарифҗанны әйләнә-тирәдә гаҗәеп тә мут һәм вөҗданлы кеше дип сөйли торган иделәр. Ә без аннан курка идек. Мин инде, ир кеше булсам да, Шара Гарифҗанның узып киткәнен күрсәм, җиргә беркавым чүгәләп кала торган идем. Ә ул, берни сизмәгәндәй, шулай кирәк дип аңлый идеме, белмим... Бер, шулай, моны Вәлинекеләр, сәүдәгәр иделәр, Минзәлә базарына олау белән, ягъни бер-бер артлы кәрван итеп, арбаларга төятелгән өч йөкне бер үзенә биреп җибәргәннәр. Намуслы кеше булганына ышандылармы икән үзенә, әллә башын Себер җибәрү нияте белән алдан корылган хәйлә идеме, анысын белүче булмады, Шара Гарифҗан да ул хакта уйлап, фикер-ниятен кузгатырга бер дә вакыт-фәлән тапмаган булгандыр... Ә чоры — яман иде. Ай яман иде. Хәзер юк инде алар, Түбән Шөңгедән Югары Шөңгегә кадәрге арадагы йөзләп диләнкеле булыр, шул җирдә шаулап утырган кара урман юлыннан узасы бар. Күрше-тирә авыл байлары гел дә таланып кайта, базарга, әйләнеп, ерак юлдан гына йөрү мәслихәт иде... Чөнки сугыштан качып яткан ил егетләре, угрыкүсәге, барысы да шул Шөңге урманында оя корып, елан аулап, яхшы-яман байларны талап алып калган малга кинәнеп яшиләр дип сөйләшә иделәр. Имеш, дөреслеге никадәр камил дәрәҗәдә булгандыр, атлы казаклар килеп, урманны иңләп-буйлап йөргәннәр икән дә, эш чыкмагач, урманчы Хаҗины кат-кат күндереп, хәбәр салу, сигнал җаен сөйләшеп-килешенеп, үзләре китеп барганнар икән. Менә шулай Шара Гарифҗан, бу сүзләрне юк-бар санап, урман аша гына Минзәлә базарына барып та җиткән. Моның туры юлдан исән-имин килүен ка-

бакта, сыра артында сөйләгәнендә тыңлап утырган кешеләр аннан көлгәннәр генә. Ә Вәлинекеләр аның сүзен куәтләгәннәр. Кире юлда олауларга шикәр, көрәк ише нәрсәләр төяп, тагын үзен генә җибәргәннәр моның. Ә иң арттагы атның арбасына бер мичкә керосин утыртып куйганнар. Эңгер-меңгер чак икән. Гарифҗан белән бергә килгән олаучылар Югары Шөңгедә кич кунарга калганнар, бик озак аның артыннан: “Менә ахмак егет!”— дип карап торганнар. Олавы урман башына җиткәч, уң кул яктан ике тапкыр, арырак өч мәртәбә бик ачы итеп зәһәр генә сызгырганнарын да ишеткәннәр, ярдәмгә бармаганнар бит... Ә Гарифҗан аңа-моңа бер дә игътибар юнәлтеп тормаган, юлын дәва иттергән. Ә тегеләр, качаклар булыр, артыннан сагалап килеп, иң әүвәле керосин мичкәсен чишкәннәр... Төнгегә фатир кереп, аның артыннан карап калган олаучы егетләр түзмәгән, артыннан чыкканнар. Чаптырып килеп җиткәннәр, Кәримхафиз, күрше авылның бәк усал мур кыргыры адәме иде, биле сынсын, авызы җимерелеп ята икән. Ә башка һичкем юк, олау да, Шара Гарифҗан да, качаклар да... Югалганнар. Олаучылар Шара Гарифҗанны инде уйларында гүргә озатып, Кәримхафизны алып кайтканнар. Албасты кыяфәте кергән бу егет өч көннән соң гына волость төрмәсендә аңына килгән.

— Ә Гарифҗан абый? Гарифҗан абый исән идеме соң?— Соңгы вакытларда алдынгы күмхуҗчылар исемлегенә керә башлаган яшь хатын, Латыйп абзыйларга килен тиешле Наилә ашыгып соравын үзе дә сизеп, кызарып куйды.

Хаҗи абый аңа таба салмак кына борылды. Җеп очын югалттырдың, сеңлем, дигәндәй карап алып, бик озаклап тамак төбен кыргалады. Суынып килгән чәен эчеп куйды. Нигәдер кабат тамак кыргалап, ахырын чыгара алмаган хикәясен аннан соң гына дәвам иттерде:

— Ә Шара Гарифҗанмы? Шара Гарифҗан исән булган... Бик кыйный башлагач, Кәримхафиз барысын да сөйләп биргән. Аннары, аның күрсәтүләре дөрес булганча, ул төне урман эчендә вакыйгалар болайрак булган...

Шара Гарифҗан йокы аралаш мыгырданып көй көйләштереп, арба кыйшайган якның киресенә таба аз гына бөгелеп-сыгылып, авыр сәгать теле төсле, зур гәүдәсе белән олау өстендә чайкалгалап бара икән. Алгы арбада икән бу. Качаклар аның арыш капчыгы кебек бөгелә төшкән гәүдәсе астында гүяки кечерәеп калган тартмалы олау арбасының да гүяки уенчык кебек кенә булуын шәйләп, бераз шөлләп, курка ук калганнар. Кемнең дә яшисе килә бит. Ә болар — качаклар, сугыштан куркып, үлемнән качып-посып ятучылар... Шулай да мал кызыктырган күзләрен... Сөйләдемме әле?.. Башта иң арттагы керосин тәпәнен чишеп төшергәннәр. Бу һоп-һуп итеп тәгәрәп китүгә уянмасынмы Шара Гарифҗан...

— Тыр-р-р!— дигән бу, арбадан төшә-төшешкә.

Качаклар куаклар арасына чумган. Артыннан ташланырга да, алдыннан килергә дә һич йөрәкләре җитми ди үзләренең. Ә Гарифҗан төшеп калган тәпән янына акырын гына килгән дә:

— Һай, йомшаграк бәйләгәннәрмени? Юк инде, юк... Төштең дәмени?.. Ярый телең бар, әйтеп өлгердең, калдырып китә идем,— дип сөйләнә-сөйләнә, җиде потлы мичкәне озын кочагына алып кына арбага китереп тә куйган. Ка-

чаклар аһ иткәннәр...— Хаҗи бабай шушы урында тукталуны кирәк табып, әйләнә-тирәсендә авызына керердәй булып утырган халыкка күз йөртеп чыкты. Барысы да тыңлыйлардыр төсле иде. Хәтта Хәлимә җиңги дә, казанын юарга онытып, Хаҗи бабай катына кунаклаган иде. Тик балтачы Латыйп абзый гына бик ерактан, күзләрен кысарак төшеп, онытылган кыяфәттә нәрсәгәдер карап тора иде. Хаҗи бабай да шул якка күз салды. Озаклап эзләде. Күзенең дә җегәрлеге бетеп килә иде булырга кирәк. Һәм еракта-еракта, бик биектә нокта кадәр генә күренеп очкан лачыны күзләре шәйләп алгач, рухи бер җиңеллек белән елмаеп куйды. Барысы да шул ук якка төбәлгәч кенә Хаҗи бабай сөйли башлаган вакыйгасын дәвам иттерде. Хикәясе, вакыйгаларының серлелегеннәнме, тагын да кызыклырак кебек тоела башлаган иде.

— Шуннан шул, Шара Гарифҗан юлын тагын да дәвам иткән. Качаклар төн уртасынача озата барырга карар кылып, монда ук итүне хәерсезгә санап планнар корсалар да, үзара уртак фикергә килә алмаганнар, икегә бүленгәннәр. Байлык күзне кыздыра, үзенә тарта ул. Мескенкәйләрнең арасында шул Кәримхафиз дигәннәре дә булган бит, юлларын үзе башлап йөргән. Алар, озак уйлап тормастан, юлның ике ягыннан чыгып, тәртә буйлап Шара Гарифҗанга якынлашканнар. Олау инде аларга күчәр дигәндә генә Шара Гарифҗан, уң кулын сузып, Кәримхафизны бугазлап алган баш очында чыбыркы болгап алган кебек кенә әйләндереп, сул ягыннан килүченең өстенә гөрселдәтеп үк диярлек орган, ә калганнар, каргадан качкан чебиләр төсле, кайсы-кая орылыпбәрелеп посканнар да беткәннәр. Шара Гарифҗан олауда узып киткәч тә, качкан урыннарында озак кына шүрләп ятканнарыннан соң, күтәрелеп чыгарга гына исәп тотканнарында җилле-гайрәтле егетләр дә ат чаптырып, кисәүләр изәп килеп җиткәннәр. Җирдә аунаган өч җаннан артыгын тапмаганнар. Аларның да икесе мәет хәлендә, тик Кәримхафиз гына исән булган. Анысын Шөңге старостасына илтеп биргәннәр. Шул төннән соң базар юлында ник бер карак очрасын!..

Хаҗи бабай сүзен шуның белән очлагандай тынып калды.

— Нигә кирәк булган инде ул, Шара Гарифҗанга дигәнем, төнгә каршы урман авызына керергә?— Наиләнең соравы бу юлы урынлы иде.

— Бәхәс, ягъни спор инде бу!..— дип, тиз генә элеп алдылар ирләрнең булганраклары, әмма рәис хатыны, Латыйп абзыйларга килен тиеш Наиләгә ялагайлык итүне уйлап та карамыйча.

— И шуннан? Ә Гарифҗан?— диделәр, Хаҗи бабайга карап, тизрәк сөйлә инде, эшлисе дә бар әле дигәндәй һәммәсе.

— Аңа ни булсын, кайткан... Ләм-мим, кемгә дә бер сүз әйтсен...

Хаҗи бабай тагын тынып калды. Инде сүзен дәва итәр дип кешеләрнең колагы аның авызына куелган иде. Бу тынлык мизгелләре узгач, ара-тирә Кәримхафизны да кызганып сүз әйткәләшүләр башланып китте, кайсы-бере Гарифҗаны ачуландылар. Ә Латыйп абзый барчасыннан да тынычрак иде, ул, казаннар ягына карап, бер генә җөмлә өстәп куйды:

— Хәлимә җиңги, казаның көя!

Чыннан да казан төбендәге аш куерып, боткага әйләнү генә түгел, көя үк башлаган иде. Хәлимә җиңги, ах-ух килеп йөгерә-кабалана, уйлап-нитеп торма-

стан казан эченә бер чиләк салкын су тондырырга өлгерде. Болын өстеннән ачы көек исе бөтерелеп узды. Хаҗи бабайның кеткелдәп көлүе генә бу хәлгә яңача юнәлеш биреп җибәрде. Шулай инде ул, тормыштагы вакыйгага көлке күзеннән карасаң, кызыклы төсле, елак күзеннән карасаң — сыкраулы!

Арада борыннарын тотып кыландыручылар да булды. Бу мыскыллы борын тотуларны һәм көлүне аралап Латыйп абзый тагын әйтеп куйды:

— Кем килә?..

Шушындый сораулы сүзләр нинди генә авыл кешесен югалып калырга мәҗбүр итми? Барчасы да яңа гына болын буйлап узган сары төтене онытып, башларын кисәк кенә авыл ягына бордылар, күзләрен шул яктан сузылган юлга текәделәр. Чыннан да аннан җәһәт-җәһәт кемдер атлап-йөгереп бу якка таба килә иде. Бу кадәр ашыгу белән нишләп йөрер икән? Бер-бер хәвеф-хәтәр юктыр бит?

Өлкәннәрнең бәгырь кисәкләре җиде якка кисәкләнеп өзгәләнә үк башлады. Хаҗи бабай, алгарак чыгып, каш өстенә кулларын куеп озак карап торды, тынычсызланды. Үз күзләренә ышану кирәклеген оныта башлаганын сиздереп, башкаларның ярдәмен таләп итми булдыра алмады:

— Оланнар, кая, кайсыгыз анда, күз салыгызчәли, ни хәбәр?..

Кемдер:

— Фатыйма түти бу!— дип аваз салуга, башкалар да юлдагы кешене танып алдылар. Тик Фатыйма түти бу якка түгел, шәһәр юлына чыга торган сукмакка борылып, үргәрәк менә башлаган иде инде. Ул арада күзләргә ачык булып, артыннан үрдәк бәбкәләре кебек бер туктаусыз кабалана-кабалана узышып чабулаучы балалары да күренде. Үзләре үк өчәү иделәр.

Хаҗи бабай да Фатыйма түтине танып алырга өлгергән, бу тамашаны бик кызык дип табучы кайбер яшь-җилкенчәкләрнең җәберләрлек сүз атып көлүләрен ошатмыйча үртәлеп үк куйган иде. Алар һаман көлә. Кыйшайтып туры төрттерүләренә түзеп тору әмәленең табылмавы сәбәплеме, әллә көлүләр артык озакка сузылудан сүзләре мыскыллау булып яңгыравын белепме, бабай хафалы кыяфәткә керде дә:

— Оланнар, җитәрегез... Тормыш итү — калҗа кимерү түгел ул!— дип әйтеп куйды. Әмма дә хөрмәтле икән әле Хаҗи бабаларының сүзе. Базга үтеп кергән кояш яктысыннан бәрәңгенең үргән аксыл үсентеләре ничек шәлперәеп төшсә, алар шулай үзләренең хаталарын аңлап, ахырыл-әмер, сыгылгалап, телсез калдылар. Ул арада казаны бөтән йөз кызармаячагына инанган Хәлимә җиңги дә үзенчәләтеп берничә сүз катарга өлгерде:

— И-и, бигрәкләр дә нәзберекләр икән әле үзләре, кара әле ничек ашыккан булалар, мескенкәйләрем, бу челләдә әниләренә иярмәсәләр дә яраган булыр иде, юк шул, аны беләмени алар, әниләрен үчекләп... Әле дә тормышы чәчми алып бара инде... И Алла, тормыш — калҗа түгел шул, Хаҗи бабагыз дөрес әйтә... Кемгә дә күрергә язмасын...

Әгәр Хәлимә җиңгинең сүзләренә колак салып узган кеше булса, исе китәр иде: мактый да, яманлый да, сөя дә, көйдерә дә! Кемгә дә күрергә язмасын... Нәрсәне, тормышнымы? Үз сүзләренә үзе колак салса, акылы-исе китәр иде. Тик аңа вакыты бармыни? Юньләп утырып хәл алырга да мөмкинлеге калмый.

Эш тә эш...

Инде кояшның икендегә авышуын аңлап, һәммәсе дә эш коралларын аралый, кузгата башладылар. Аргырак баштагы бригада кешеләре казаннары яныннан кубып, эшкә тотынганын күреп алгач, аерым бер көнчелек белән Сәлимнекеләр тагын да җәһәтрәк хәрәкәтләнергә тотындылар. Тегеләрнең чалгы янауларының тавышы туктала, сүнә, бетә бару боларының йөрәкләренә хуш килсә дә, күңел түрләрендә җай тапмый. Эшнең күләме хезмәт көне белән исәпләнүне белүләренә карамастан, һәркемнең башкалардан бер генә адым булса да алгарак чыгасы килә иде.

9

Бу юлы Шәрифләрнең разведка буровое бөтенләй бүтән авыл янына урнашты. Әгәр дә монда эшкә кермәгән булса, ул бәлки дөньяда Кыек дигән авылның барлыгын белмәс һәм урыс салаларынча чәчелмә көнкүрештә гомер сөрүләренә исе дә китмәс иде. Урман артында гына икән. Кыеклар аның үз авылыннан сигез чакрымлап кына ераклыкта Түгелме? Әгәр дә Кыек белән Алга күмхуҗлары басуларын агач межасы бүлеп торса, ике калкулык, бер уйсулык араларында ятмаса, икесе ике районга карамасалар, бәлки алар бер-берсен яхшырак та белерләр иде. Бәлки менә шушы аралашу мөмкинлеге юклык кына ике авылның үзара дуслыгын җимергән дип әйтер идең, ул гына түгел икән. Элекләрне болар арасында тагын да бер урыс саласы булып, аларны якын мөгаммәләдән аерып торган. Дөрес, бу урыс авылының соңгы ихатасы сугыш алдыннан гына җимерелеп бетеп, халкы Кыекка кушылып, татарлашып ук беткән, хәтта үзара кызлар алышып, халык телендә генә урыс атала, асылында бөек интернационализм җимешен ашап яшиләр, имеш. Моңа егерме беренче елгы корылык вакытында ут чыгып, авылларындагы алты ихатадан гайреләре көлгә калып янып бетүләреннән соң, Кыек татарлары мәңге этешеп-төртешеп, сугышып-дуслашып яшәгән шул урыс саласын үз ярдәмнәреннән ташламыйча куеннарына алулары, тора-тора үзләрендә үк яшәтеп калдырулары сәбәпче булып чыккан, диләр. Бәлки менә шул тарихлар аркасында бу авылны Кыек дип атый башлаганнардыр? Әмма Ходай тәгалә каршысында бер гөнаһлары барлыгы да халыкта билгеле: Кыеклар кайчандыр Исламда булып, керәшенгә күчерелгән, тагын да мөселманлыкка кайткан, дин алмашып көн күргән икән. Баштарак бу авылның исеме Тарлау булган, имеш.

Ике авылны кушкач, әүвәле татар абзыйларының үткен хыялында гына яшәгән мәсьәлә чишелгән — урыс чиркәвен сүткәннәр. Мескен, бик мәгърур булса да, агачтан гына салынган икән. Ә аннан соң мәсҗидкә дә чират җиткән. Сөйләүләре әгәр дә хак булса, искелектән, чиркәү белән мәсҗидтән, диннән бу якларда иң беренче Кыек авылы котылган. Тик нигәдер мәсҗид урыны белән чиркәү нигезе һаман да саклана, картларының уйга бирелә торган җиренә әйләнеп киткәннәр. Шулай да чиркәү текә калкулыкта ук булып, зират кылу өчен кулайрак булып чыккан. Һәм менә Шәрифләрнең буровое нәкъ шушы чиркәүнең нигез ташларын кубарып атты, чиркәү булган урынга урнашты.

Буровойны халык бик тиз шәйләп алды. Ул яктан авылга ишетелеп торган корыч торбаларның бер-берләренә бәрелеп шаңгырдавы-доңгырдавы барысына

да элекке чиркәүнең зур чаңнарын хәтерләтеп, җаннарын әсәрләндереп җибәрде. Ә геологлар халыкның моңсу кыяфәттә калуларын бары бер әйбер белән генә аңлата ала иделәр: яратмыйлар, җирләрен бозганга ачуланалар. Авыл халкы үзләренең тормыш-көнкүрешләрен пыран-заран китергән нефтьчеләрне, инде берничә тапкыр ишетелеп борчуга салган җир маен сыгачак буровойларны һәркайда ничектер ятсынып каршы ала, алар хәтта бу якларның инде берничә елдан чәчәк атачагын һич башларына да китерә алмый иде. Һәм менә болар барысы да ниндидер билгесезлек эченә чумган буш хыял булып халыкның күңелен өшетеп һәм чиркандырып тора. Шәриф Кәримовичлар булган һәр җирдә вакыйгалар менә шулай кабатландылар. Әмма геологлар һич тә күз алдына китерергә мөмкин булмаган, хәтта башларына да сыйдырмаган икенче бер мәсьәлә дә бар иде халыкның моңсулануында. Ул — хәтер катламнарының актарылып атылулары, булган вакыйгаларның гүяки кабатланып, яңадан да җан аша узуы иде. Элекке чиркәү торган урынга буровой каланчасының китерелеп утыртылуы төрле ырымнар-сынамышлар тудырырга сәбәпче булса да, күңелләрне сагайтса да, үзара һич тәңгәл куелырга мөмкин булмаган параллельләр генә иделәр. Әмма халыкның күңеле, никадәр сак итсә дә, аларны абайлап бетерә ала димени соң? Ул моңсу күңелләрне асраучы корсакларның ярылганчы ашаганы да юк иде әлегә. Шулай булгач, каян инде барын да белеп бетерәсең? Мондый чакта тарих тирәнлеге генә күп сорауларга дөрес җавап табарга ярдәм итә ала.

Телләрдә матур бер мәкаль йөри: “Халык әйтсә — хак әйтә”, имеш. Хак — ул дөреснең дә иң тирәне, төгәле, аның бәясен билгеләүче, аңлы фикер аша туганы. Әмма ул да дөреслекне билгеләп бетерә алмаска мөмкин, кайчагында берьяклы, хәтта мәгънәсез үк булып китә. Бу очракта да шулай килеп чыкты. Кайчандыр кардон арты урыслары казып азапланган, эзләнгән байлык чит-ят илләрне баетачак түгел иде инде. Халык менә шуны төшенә алмый озак газапланды. Сала абзыеның бердән-бер байлыгы җир иде, аның игене иде. Ә хәзер нишлиләр? Шул изге җирне изеп-таптап китү генә түгел, маен да сыгып алачаклар икән!

Ярый, элек бер-берсеннән көлеп, сугышып яшәгәннәр үзара уртак тел таптылар, ул гына да түгел, йорт-нигезләрен бүлештеләр, күзләренә куркышып карамый башладылар. Мөселман карчыклары да Коръәнгә үзләренчә аңлатмалар биреп, намазларын болайрак болгаткалап бетерә иделәр:

— И Раббым, үзеңә кол ит, дустыңа өммәт ит, Хәүзе-Кәүсәр шәрабларында сугарылып, Туби агачы күләгәләренә күләгәләнеп, Мәрьям ана туйларын күреп, Рахман сүрәләрен ишетергә насыйп ит Рәсүлемезнең!..

Нәселе урыска барып тоташканнар үзләрен бөтенләй башкачарак тоттылар. Алар әллә нинди оҗмахлар, фәрештәләр белән саташмыйча, дин хәбәрләренә ышанмаган килеш, ярым-йорты христиан бәйрәмнәрен дә мөселманнарныкы белән буташтырып бетерделәр. Аракы янында гына үз вөҗданнарын төзәткәли иделәр. Ә яшьләр үзләренчә көн күреп, берсесенең урыс, икенчесенең татар булганлыгын һич тә исләренә төшереп, акылларын милли мәсьәләгә борырга уйлап та бирмәделәр, бары тик тел очларында барлыкка килгән уртак сүзләр аша һәм күпчелек очракларда татарча аңлашу аларда үзеннән-үзе табигый хәлгә

әйләнгән иде. Бары араларында таралган урыс исемнәренә, татар фамилияләренә, һәм, киресенчә, урыс фамилияле татар исемнәренә игътибар итеп, бу авылның тарихын белеп тормастан, кара әле, мин керәшен татарларына килеп кергәнмен бит дип адашырга, ул хакта үз фикерләрен башкаларга җиткереп, көлке хәлдә калырга да бик мөмкин иделәр. Дөрестән дә Кыекларның килүче-китүчеләрдән андыйларны еш очратканы бар иде. Аларны баштарак "төзәтteләр", аннары моңа игътибар итүдән тәмам читләштеләр. Әмма сүзләре күпкә китеп, керәшен димәкне телгә алу аркасында, холык сүтелеп китеп, бер мыскыллы елмаеп, озак вакытлар телдән-телгә күчереп, кешенең дәрәҗәсен түбәнсетүче сүзләрне авыздан төшерми йөртә иделәр.

Шәриф Кәшәповичлар отряды шушы авыл янына разведкага туктау белән халык акылы кинәт икегә бүленеп, дин мәсьәләсе картлар арасында калкып китте. Татар абзыйлары ризасыз булып:

— Нигә урыс чиркәвеннән дегет чыга да, татар мәсҗиденән чыкмаска тиеш?— дип, акыллары аңламаган сорауларына үзләренчә үк җавап сала иделәр, имеш:

— Татар мәсҗиде изге урында икән дә...

Һәм китә инде сүзләр!

Әмма бу юраулар буш булып чыктылар. Озак та үтмәде, нефть хафасы авыл халкын бөтенләй икенче төрле кыл урталайга бүлде: бер якта таушалып беткән авыр холыклы, җиргә кендеге ябышкан кешеләр калса, икенчесенә яшь һәм шат, горур һәм тәкәббер романтик, илаһи шаукымлы затлар күтәрелде. Бу бүленеш инде дин аерымлыгын да, нәсел күзәнәкләрен дә таптап үтеп, кешеләрне холыкта гына түгел, хәтта вәсвәсәдә дә үзара каршы куйды.

Көрәш кырында җиңелгәннәр өчен бу тормыш — мәгънәсез. Әмма тормыш һаман да мәгънәсез генә була алмый, әгәр дә кешеләр, шушы тормышта яшәүчеләр үзләре үк мәгънәсез булмасалар. Без, кешеләр, яңалыкны һәрвакыт мәгънәсез дип каршы алабыз, һөҗүм ачабыз. Ә яңалык үзенең җиңелмәслеген белдергәч, аны аңларга тырыша башлыйбыз. Нишлисең, һәр яңалык үзенчә мәгънәсезлеккә каршылыктан туа. Искелек, узылганнар үзләре дә мәгънәсезлеккә әйләнә бара, әгәр дә аны бүгенгең белән бәйләмәсәң. Әмма ул мәгънәсезлекнең яңалыкны тудыручы мәгънәсезлек белән аермалы ягы бары шунда — ул череп баручы искелекнең таркалу чоры гына. Шулай да искелек белән яңалык һәрвакыт бергә яшиләр, искелекне яңалык җиңеп бетереп кенә килгәндә дә яңа яңалык туа бара. Кешелек һаман яңара, хисләр-моңнар яңара, өйләр-урамнар яңара. Әмма яңалыкның иң зурысы тамырдан үзгәрү чоры тормышны бөтенләй башкача үзгәртеп куя, ул хәтта кире әйләнеп кайта-кайта, җимерек хәрабәләр төзәтә-төзәтә, яңадан-яңа җиңүләргә таба бара. Шушы тамырдан үзгәреш тудырган шартлау баштарак киеренкелек китереп чыгарып, һәрбер төшенчәгә яңача мәгънә биреп үзгәртү барлыкка китерә. Тормыш шулай дәвам итә.

Һәм менә шушы якларда нефть фонтаны атып чыгу хәбәре дә гадәттән тыш иркенрәк киңлекләргә җәелеп, киеренкелек тудырды, ул тормыш нигезләрен тамырдан үзгәртеп, үзенчә итеп кордырды. Бу яңалык гадәттән тыш усал һәм тәвәккәл үзгәрү иде инде. Аның җиңеп килүен бернинди искелек һәм үзсүзлелек тоткарлап кала алмады. Ул хәзергә җиңә иде, үзенә чигенергә мөмкинлек

калдырмыйча, күперләрен яндырып, табигатьне, көнкүрешне ватып-җимереп һаман да алга бара, усалланганнан-усаллана гына иде. Аннан хәзергә бер нәрсә таләп ителде — җиңү. Бу җиңүнең бәя-хакы да, артык миһербансызлыгы да бары арткы планга куелып, кешеләр җирдәге урынын аңларга да өлгерә алмый калачак иделәр. Бөтен җанына крестьян рухы береккән буыннар чылбыры кинәт шартлап өзелде дә мәйданга яңача тормыш, яңача көнкүреш, яңача фикерләү, яңа таләпләр һәркемнең хисси һәм табигый борчуларын җимереп, шахмат тактасындагы фигураларны буташтырып ташлаган кебек үзгәртеп куйды: нефть белән бергә мәйданга чыкканнар дөньяның төп штурвалын үзләренең кулларында әйләндергәләп, гавамны үзләренә буйсындырырга, үзләре белән исәпләшергә, замана адымнарын тонналар белән үлчәргә мәҗбүр иттеләр. Чөнки һәр яңа буровой, һәр яңа кое, скважина-чыгыр — болар кирәкле һәм артык тонна иде. Хәзер инде яңа шыткан уҗымнар, бал саркып торган чәчәк болыннары әсәрләми, ә сыланып аңкыган дегет парына бәндәләр борын төртә иделәр, әмма алай да артык юанырга үзләренә ирек куя алмыйча, башта геологларның табаны астында калсалар, аның артыннан ашкынып килгән дегетчеләр итеге ул болын һәм басуларга баса, бу гына да түгел, әле бер баштан икенчесенә җирне ярып торба үткәргечләр сузылсалар, икенче очтан киң башмаклы тракторлар җимертеп юл ярып үтәләр, чынлап торып шагыйрьләрчә: һәр яңа көн үзенчә яңа!

Яңа! Юллар яңа, көчләр яңа, уйлар яңа. Бар, исәпләшеп кара. Хәзер инде кешене берсе чиркәү астында, икенчесе мәсҗид карамагында дип бүлеп кара. Хәзер дегетче дөньяга хуҗа. Башкасы — юк. Мәсҗиде дә, чиркәве дә. Алар бары мескен карт-корылар өчен генә юаныч. Хәзер динсезләр дөньясы. Табынганнары җирдән нефть һәм икмәк алу. Юк, картлар көткән чиркәү тавышы да, азан моңы да инде кире кайтмаячак кебек иде хәзер. Кешеләр дин аерымлыгын җиңеп, берләшергә өлгерсәләр дә, дус һәм тату яшәү тәмен татысалар да, инде тагын яңача бүленүгә тап булмый кала алмадылар. Дөньясы шуңа үзгәрде дә. Карт, авыр тормыш, тыныч ярларыннан кайнап чыгып, үзен-үзе белештерми шашкын дулкыннар белән агып китте.

Киеренкелек үзен сагындырган иде. Моны һәркем сизде, тик аңлый гына алмады, буталды, шуңа күрә халык акырын кыймылдый бирде: шунлыктан нефть үзенә кешеләрне төрле яклардан җыйды. Элек киткәннәр әйләнеп кайттылар, күпләр үзләре теләп, намус кушуына тугрылыклы булып, әзербайҗаны-грузины да, урысы һәм украины да бу якларга тиз көндә баеп калыр өчен килделәр. Аларның бу бөек башлангычын җирле халык күтәреп алырга тиеш иде. Әмма...

Әмма хәзергә алар кетәклек араларына посып, буровойны, андагы эшләрне күзәттеләр, кызыксынганнары да сер бирмәделәр. Сүзләр уртак булса да, һәркем үзенчә фикер йөртте — салача... Авылның бу кыланышларына геологлар да игътибар итми калмады. Әмма дегет һәм аның белән кесәләрен тутырасы акча кайгысы алар өчен изгерәк һәм кадерлерәк иде. Озакламый алар бөтенләй Кыек халкына ияләнеп, бары үзләренең куанычлары белән һәрдаим очрашып кына яши бирделәр. Тик Шәриф Кәримович кына халык кайгысыннан ераклаша алмый иде. Аның әле әтисе — җиргә береккән кеше белән очрашасы

бар. Дөрес, ул партия әгъзасы, әмма малаен аңлармы соң? Әгәр улының әллә кайда түгел, күршедә генә казынып йөрүен белсә, бирәчәк кирәген. Имеш: “Хәл белеп китәргә дә ярамадымы сиңа, дегетче!” Дөрес, Шәриф тырышып, күп тапкырлар аңлаткалап карады, әтисе аның сүзләрен кабул итте дә төсле, килеште дә, җитмәсә; ул җаны-тәне белән бу якларның чәчәк атуына өмет итә, әмма җиргә береккән, һәр агачның, һәр яфрак-үләнең селкенүенә карап кәефе үзгәрә, иген-иген, кешеләр-кешеләр дип өзелеп тора. Ә нефть күп вакыт миһербансыз һәм усал. Ул туфрак-җирнең тәмен белүгә караганда, үзәгенә карарга мәҗбүр итә. Ул аска тарта. Нефть эшендә бер генә фәлсәфә: җир өстендә ни булмас, әмма нефть, кирәк кенә түгел, ул — мөһим, ул — киләчәк. Менә шуны беләләрме алар? Юк! Җир астына төшә беләмени алар? Хәтта шахтер улы, коммунист, партиянең районда беренче секретаре Кәрим Хафизович та асылы белән крестьянга әверелеп бетте түгелме? Кешене иген кайгысы табигать баласы итми калмый шул!

Шәриф күңеленнән әле атасы белән бәхәсләшә, әле, шул ук вакытта, халыкны ук сүгү дәрәҗәсенә барып җитә иде. Хәтта әтисенең кандидатурасы киләсе сайлауларда да җиңәсен, аның район башында калуы мөмкинлеген күз алдына китереп эче дә поша иде. Аныңча хәзер районга яңа кешеләр кирәк. Яңа! Бер олау җитешсез яклары булса да, яңача уйлый торган, нефть эшен аңлый торганнар кирәк. Хәзер сала халкына паспорт иреге бирергә иде, бу алардан дегетчеләр тизрәк җитлегү өчен иң мөһим чара. Хәзер һәр нәрсәне гавам үзе хәл итәргә тиеш. Көн үзәгендә нефть торырга тиеш.

Бу уйлары Шәрифнең күңелен мең кат айкап, тетрәтеп үтә торды. Аларның очы-кырые күренмәде, шуңа да егетнең үз алдына үтә ачуы килә һәм ул фикерләрен кая да куярга җай таба алмый. Хәтта никадәр җитди, уйчан геологлар да моныңише фикергә урын газета битләрендә генә дип саный, ә аларның эше — нефть табу, акча! Сүзләрнең буяуларын ахырдан куертырга була, ә хәзергә мәгънәсе юк. Алар бары тик мәгънәсез сүзләр тезмәсе генә түгелме? Ярым ялган һәм ярым дөреслек. Чын сүзләр бары җиңүдән соң гына сөйләнелә — бетте китте! Бүгенге хаклык — нефть һәм баста!

Әмма кеше зиһененә уйлары никадәр ешрак кайтсалар, шулкадәр үк аларга иге-чиге булмаган дәвамлы проблемалар коерыгы ияреп килә. Уйлар... Аларның кайберләренең чиге кыска вакыт аралыгына сыя, икенчеләренә гасырлар да җитенкерәми. Уйның чиге — аның чиксез булуында. Кояш төсле уй да бер балкый, бер сүрелә. Ә чыннан да кояшның чиге бармы икән?

Шәриф кояшка текәлеп карап тора башлады. Таң кояшын гаҗәеп матур була диләр, дөрес икән. Күзләре дә чагылмадылар. Тәмам ачылып җитмәгән шул әле. Кара, ничек иркенәеп чыга. Бар табигатьне хозур нурларга күмеп, дөньялыкка такыя үрә-үрә балкып чыга. Эһ, нигә һәркем дә шагыйрь түгел икән? Юк! Һәркем шагыйрь, чөнки һәркемнең күңеле үзенчә балкый, кояш кебек, тик берәүләр сүзләрен матурлап әйтеп бирә ала, берәүләр тиле уйлары арасында адашып кала. Һәр тарафтан агачлар, күлләр, тауларга бәйләнгән төсле сузылып, тартылып тора кояш нурлары. Гүя бик зур пәрәвез җир өсте белән кояш арасына оя корган. Кылларга аз гына кагылып үткән саба җиле җыр көйли, сандугач түгел, шушы таң нурлары тибрәнеп, күңелне өзә-өзә шыңшый сыман. Бу моңны

саклап каласы иде, кояш кебек нур чәчәсе, кешеләр өчен балкып торасы, кирәкле буласы иде; элеккечә, дуслар белән иңгә-иң торып, бер-береңне аңлап, һәммәсен күз алмасында булып һәм һәркемне күз уңында тотып, ярым серле, ярым гыйльми, ярым романтик, хисси дөньяда гына яшәсәң иде ул. Һәй, студентлардан да бәхетлерәк кешеләр бармы икән бу дөньяда? Кесә — такыр, тамакта — каты-коты, күңелдә — җыр! Менә ул чын һәм бәхетле студент. Ә кесәдә акчасы тулы, тәмледән яхшыны гына ашаган студентта мондый изге хисләр, саф күңел бөртекләреннән генә торган җырлы сагыш, уен-көлке никтер аблкый, нигәдер ул аларны читтән әйләнеп үтә, нигә?

Һәр яңа хис яңа уйларны кузгата, көтелмәгән тойгылар хәтер ярларына үтеп керә һәм башлана, артыннан куып тотарга өлгерә дә алмый кала торган истәлекләр агышы башлана; алар күңелнең әллә кай җирләреннән актарылып чыгалар да олы сагышка укмаша-укмаша, бәгырьне сыгып-сыгып сызландыралар: тәнгә һәм җанга бик авыр булып китә.

Искә дә алмаслык түгел шул. Менә, мең сынаулар, йокысыз төннәр аша үтеп, студент булып җитлектем дигәндә генә дөнья сине бөтергәләп үз ызаннарына кертеп адаштыра. Яши башлыйсың. Беренче курста әле син студент түгел. Чөнки башыңда бер әйбер — уку. Ул шулай кирәк тә. Әгәр шушы тиешлек сакланмаса, көт тә тор, син яки быел, яисә ике елдан инде теләсәң-теләмәсәң дә студент тормышыннан китәсең. Нәрсә соң ул студент тормышы? Моңа җавап һаман да элеккечә: ярым-йорты тормыш ул, ягъни ярым гыйльми, ярым романтик, ярым шәхси, ярым күмәк һәм ярым, ярым, ярым... Анда, әгәр дә өлгерсәң, укудан гайре бар әйбер дә яртылаш кына башкарыла. Башкача мөмкин түгел. Юкса берни дә күрми һәм аңламый калачаксың. Монда һәркемнең холкы һәм фигыле үзгәрә. Һаман да шул ярым-йортыга әверелә. Син ярым горур, ярым шаян, ярым тәкәббер, барысы да җитенкерәми, һәммәсенә өлгереп тә булмый. Менә шул ул студент һәм аның тормышы. Ни өчен шундый соң ул? Бәлки ярым ач, ярым тук тормышта яшәгәнгәдер?

Шәрифнең курсташлары белә: шулай, өченче курсны бетергәч, аларны практикага җибәрделәр. Кайда әле? Татарстанга, нефть диңгезендә йөзгән якка. Киттеләр болар урыс малае Саша белән. Казанда йөриләр. Мәктәптә Шәрифнең бергә укыган шәриктәшләре Сафа белән Марат очрадылар. Ут егетләр. Сафа педагогия институтында укый икән, ә Марат университетка ук үрмәләгән. Беренчесе бик яхшы баянчы, калын бас тавышлы, кара тут йөзле, уртача буйлы, чандыр гына бер егет үзе, ә уйнап-җырлап җибәрсә, әйтәләр, торактагы барлык кыз, хатын затыннан булганнар аның ишеге төбенә җыелалар, ә мескен егетләр оятларыннан тараканнар урынына кайсы-кая посып бетә, имеш. Монысын ук арттыралар ахыры дип, бертуктаусыз такылдаган Мараттан көлеп кенә барганнар иде, кая ул, торактагы бүлмәләренә барып керү белән Сафа җырлап җибәрмәсенме, биш-ун минут үтмәгәндер, хатын-кызлар аның ишеге артында күч кебек тыз-быз килә башладылар, әллә керәләр инде дип торганда, яхшыдан санамадылар, ахрысы, куркышып юкка да чыктылар. Марат бу хәлгә аңлатма ясады:

— Әй егетләр, азрак Мәскәү тузаннарыгызны кагыштырып килсәгез ни була иде? Козгын кебек кәпрәеп, безнең гөлдергүләребезне таратып ук бетерде-

гез... Шулай ярыймы инде?..

Әмма кызлар тыңлап ук торганнар икән. Көлешеп җибәрделәр. Мәскәү студентлары да үртәлеп куйды, Сашаның:

— Без нәрсә, без болай гына, яхшы түгел бит, җәелеп китеп булмый,— дип әйтүе булды, Марат тагын да аңа өстәде:

— Җәелмә син, брат, үзебезчә генә бул! Бездә шундый әйтем бар: “Кунак икәнсең, сыена карап түгел, хуҗасына карап хөрмәтле бул”, диләр.

Сый сүзе чыккач, егетләр җыйналышып алдылар. Әллә кайдан гына ашыгыч рәвештә юнәтеп бер “урыс малае”н таптылар. Озаклап бәхәс корып тормадылар, ач күздә чама юк, диләр, төбенә үк төштеләр. Хәзер инде бар да бер-берсенә туган һәм дус иде. Саша да, баштарак сәер тоелган татарчалатып русчаны сукалаган сүзләргә күнегеп китте. Дөресрәге, татарларны ул башкачарак итеп күз алдына китерә иде. Нигәдер алар чәчсез һәм түгәрәк кечек күзле кебек тоела иделәр. Моның, билгеле, шулай күзаллануына сәбәп тә бар иде: беренчесе — тарих укытучысы аларга, дәртләнәрәк төшеп ахрысы, татарларны шул рәвештәрәк сурәтләп сөйләде, икенчесе — үзләренең күршесендәге бер малайны, Боряны (ул бәлки Барый булгандыр инде), “Татарин” дип, йә “Кенәз” кушаматы белән үртәп ачуын китерә иделәр. Ә болар нәрсә? Кара бу Маратны: буйга — гүяки идәнгә баскан килеш түшәмне күтәреп тора, ул җилкәләр — ике диварларны тоташтыра, күзе дә кечкенә түгел, чәче дә коңгырт, әкияттәге урыс баһадирларыннан кай җире ким? Тик менә “че” авазын гына никтер бәрәңгене сытып ашаган кебек итеп сөйләшә, хәтәр болар, әй...

— Саша, ишетәсеңме, шигырь сөйли!— Шәрифнең җилкә белән төртәтөртә әйткән сүзләрен уйларына чумган Саша аңлаша алмый калды, аннары, төшенгәч:

— Шур, Тукай, да?— дип сораган иде, Шәриф аңа ачуланып күз салды. Саша тагын да айнып китте, Шәрифнең үз исемен бозып, “Шура” дигән кушамат белән эндәшүләрен яратмавы исенә төште, тик татар исемен әйтү урыс кешесенә авыр икәнен дустының аңламавына да үкенеп куйды. Әмма Шәриф үпкәсен тиз онытты. Яңадан Сашаның соравына кире кайтты:

— Юк, Тукайны түгел, үзенекен сөйли. Саша, кара, ә, шагыйрь белән бер сыйныфта укыганмын бит! Ничек әйтеп бирә! Менә ичмасам шагыйрь!

Саша Тукай дигән шагыйрь барлыгын Шәрифтән элек үк ишетеп белде. Чөнки, бәхәскә кереп, әдәбият хакында сүз чыга калса, Шәриф:

— Сез ни беләсез, сез Тукайны да белмисез бит,— дип алардан көлә торган иде.

Шәриф Сашага тагын төртте:

— Монысы инде – Җәлил шигыре, “Маобит дәфтәрләре”ннән, ишет, татарча ничек яңгырый!

Саша күңел биләмәләреннән мең кат сорау белән үтте:

— Җәлил? Җәлил? Җәлил?— Тырыша торгач, исенә дә төште: герой шагыйрь, легендар шәхес! Монысын уйлап бетерде дә Шәрифнең колагына кабатлады. Әмма пышылдап әйткәне шигырьнең сөйләнеп беткән чагында, барысының да тыныч калган вакытына туры килде. Сашаның:

— Герой шагыйрь, легендар шәхес, әйе бит?— дигәненә һәммәсе дә мыс-

кыллы көлештеләр. Көлүеннән әүвәле Марат туктады һәм Сашадан гафу үтенде һәм, бәйнә-бәйнә Муса Җәлил хакында бар белгәннәрен, күз алдына китергәненчә сугыш вакыйгаларын, фашист төрмәләрен сөйләп бирде. Саша бу вакытта Маратка рәхмәтле күзләре белән текәлеп, соклану хисләрен яшерми тыңлап утырды. Ул шат иде. Кинәт аңа бер хакыйкать йөзен ачты: кеше никадәр физик яктан көчле һәм гайрәтле булса, шулкадәр үк башкаларны аңлаучан, шагыйрь күңелле була икән!

Ул арада Марат Муса Җәлилгә багышланган шигырен укырга тотынды. Бу юлы Шәриф шәрехли-аңлата, Марат артыннан Саша өчен сүзләрне урысчага тәрҗемә итә торды. Әмма аларга комачаулаучылар да табылды. Кай арада югалган Сафа бертөркем кызларны җыеп алып кергән, җитмәсә бер кәстрүл аш һәм бер таба бәрәңге дә тотканнар. Туташлар да монысында оялышып тормадылар, Маратның шигырен ярты юлда өзеп, Мәскәү егетләре белән таныштыруын үтенделәр. Алар әрсезләнде. Марат, каушап, һаман шул сөйләнеп бетмәгән шигыренең юлларын кабатлады:

— Төрмәләрнең алларында, чәчкәләрдә тибрәнәләр җырлар, тибрәнәләр...

Әмма азагына җитә алмаячагын аңлап, әүвәле тынычланырга тырышты, аннары, хисләрен сүндерергә теләпме, ишек артына чыкты.

Урамда кич иде. Йолдызлар ниндидер ят соры нур белән кабарынып-бүртенеп, без монда гына дип гүяки кычкырырга да оялмыйча, җемелдәшеп-җемелдәшеп яна иделәр.

Мондый күккә игътибар иткән кешенең күңелендә бары тик бер генә төрле уй туа ала — күк йөзен урталай аерып-ертып атарга! Маратта да туды ул уйлар. Әмма алар тиз үттеләр. Чөнки аның колагына тәрәзәләрне калтыратып ишетелгән җыр керде, фикерләрен бүлде, хисләренә бүтән юнәлеш бирде. Җырны һаман шул Сафа сиптерә иде. Ә ул җырлаганда колагыңа мамык тутырып та һич котыла алмыйсың. Сафа кешене юлдан яздыручы сәмруг кошлар төсле генә түгел, җанга үтеп керә-керә, бәгырьләрне изә-изә җырлый белә иде шул. Менә бу юлы бөтенләй башка шаян җыр башкара, әмма колакка авыр вакыйга, сагыш-кайгы булып килеп ирешә. Тагын үзенә, ягъни Сафага гашыйк Фәйрүзәдән көлә инде бу! Әллә каян тапканнар шул уңган, чибәр кызга Карчык кушаматын? Имеш, карт-корылар кебек иртә таңнан тора икән, йокысыз, диләр. Белмим, кеше ни генә кыланмый һәм кыландырмый, тапканнар көнләшерлек сыйфат. Карчык, имеш... Сафа да шул кушаматтан гына курка, егет түгел ул. Үзүзен генә үрти, елата инде чибәркәйне. Шулай да ярыйсы гына җыру икән бу:

Карчыкларны яратмыйлар
Теше сирәккә күрә,
Түлке аны асырыйлар
Нәнкә кирәккә генә.

Киленнәр эштән кайталар
Берлины алган кебек,
Кайнаналар посып ята
Пленга калган кебек...

Маратның күңеле ничектер яктырып китте. Үзенең нигә иптәшләрен калдырып чыгуын аңламый, бер дә юктан аларга үпкәләвенә үкенә үк башлады. Тик ничек кире кермәк кирәк, ничек? Җае чыкты тагын: Марат, эзләнеп, бер “урыс малаен” күршеләреннән юнәткәч, бүлмәгә, дуслары янына узды. Аны шау-гөр килеп каршы алдылар. Маратның “табышы” түргә кереп кунаклаган туташларга да ошады. Әмма кунак егетләре Саша белән Шәриф үзләренең тиздән китәчәкләрен, төнге бердәге Казан-Уфа поездына билетлары барлыгын хуҗаларга әйттеләр. Шулай да, ялына торгач, шешәне бушатмый кузгалмадылар.

Казан урамнарында дымлы җиләс җил адашып йөри иде. Алар җырлый-җырлый, бер-берен шаян сүзләр белән көлдереп, вокзалга кадәр җәяүләп кенә төштеләр. Әгәр дә тагын азрак урамнарны урап йөрегән булсалар, бөтенләй үк соңарып каласы булганнар икән, инде кузгалырга әзерләнгән поездга алар йөгерә-чаба барып утырдылар, хәтта кешеләрчә саубуллаша да алмадылар.

Поезд акырын кузгалса да, тизлекне алырга өлгерде. Үзенең пассажирларына бишек җырын көйләгән төсле рельсларга бәргәләп-чирткәләп алга таба атлыкты ул. Ә Саша белән Шәрифкә яхшы урын да табылды: алар, ике дә уйлап тормастан, плацкарт вагонның һәр бүлекчәсендә була торган чемоданнар, юл биштәрләре өчен махсус көйләнгән киштәгә менеп яттылар. Шәриф уянып киткәндә әле төн иде, икенче тапкыр күзләрен ачканда таң аткан һәм яктырган кебек күренде, моңа игътибар итмәстән, ул тагын йокыга чумды, тагын бераздан башын калкытса, инде төн җиткән кебек күренде. Чыннан да әллә төне-көне йокланылган инде? Поезд унсигез сәгать эчендә Бөгелмәдә булачак дигән иделәр түгелме? Эһ, вагончыга уятырга да кушмаганнар шунда!

Шәриф хафага калды. Ул арада Казанда ач карынга койган аракы үзен сизderергә өлгерде, башы чәрдәкләнеп чатный башлады. Уйланып алуы кайнар майга бер тамчы су таму кебек тәэсир итте, кул тормозын өзеп, ул тиз генә поездны туктатасы, моннан сикереп төшеп каласы килде егетнең. Шулай да, тырышсаң, махмырлы башны да җыярга була икән! Шәриф үзен кулга алырга тырышып, соңарган юлчылар кебек ярым йокылы, сабыр күренгән бабай янына төртелә-этенә килеп утырды. Тик аңа каршы бабай бер сүз әйтмәде. Ягына борылып та карамады. Йөзе чат мишәрнеке иде.

— Абзый,— дип аңа тагын төртеп алды Шәриф,— Бөгелмәгә еракмы? Кайчан уздык?— диде кабатлап һәм сабырсызланып.

— Кичке якта, энем, кичке якта,— диде бабай, авазларны үзенчә авызыннан сыгып чыгарып,— күптән үттек үзен... Бөгелмә дисеңме әле, әйе, кем?..

Шәриф, бар ачуыннан кабарып (гүя бабай аны уятмаган да, аңа ярдәм итмәгән):

— Әйе-әйе, Бөгелмә, абзый,— диде.

— Ә-ә?— диде бабай, тагын да сабырланып. Шулай да елмаймыйча булдыра алмады:— Бөгелмәгә идегезме, гуй... Һе-е...

Шәриф инде ачуыннан шартлый язып, аңа эндәшә дә алмый иде. Ә бабай тезеп кенә китте:

— Үттек инде, энем, үттек, күптән үттек үзен... Әллә Бөгелмәгә идеме?.. Моннан автобус йөри булыр, энем...

Бабай елмайган хәлендә утырып калды, Шәриф белән Саша ашыга-ашыга, кечкенә бер станцада поездан төшеп калдылар. Ялгыз тәрәзәле бинадан күренгән сары ут яктылыгы төнге караңгылыкны кыл урталай өзеп, дөньялыктан аларны койма белән аерган кебек иде: гүяки шушы сары ут яктырткан җирдән соң шунда ук бик тирән диңгез башлана.

Мондый сәер уйлар егетләрне дә шөлләтми узмады. Алар ут һәм төн чигендә тукталып калдылар. Тик төнге караңгылыкка таба авыр адымнарын җай гына сөйрәштереп, җилкәсе аша салынган көянтәсенә катык сатканнан бушаган бидоннарын һәм шәһәр икмәкләрен аскан хәлендә авыл хатыны кереп югалгач кына, аның артыннан егетләр дә тәвәккәлләделәр. Төн караңгылыгына керүгә, ерак булмаган авылның тәрәзәләреннән сирәк-сирәк кенә төшкән сукыр яктылык, күз алмаларында чагылгалап, аларны алга таба, үзенә дәште. Шунда киттеләр, соңга калып пешерелгән икмәк исе һәм ярым куркак эт тавышлары аларның күңелләрен ялкынсыткалый башлады.

— Безнең авыл да моннан булырга тиеш түгел, әбиләрнең авылы!.. Минем бу авылны күргәнем бар кебек... Бу аларның күрше авыллары булса кирәк,— дип, Шәриф Сашага уендагын ярып салды.— Көнчыгыштарак булырга тиеш!..

Сүзенең дөреслеген белер өчен сораштырырга дип, урамга кергәч, кеше эзләп карадылар. Тик берәү дә күренмәде. Соңга калган утлар да сүнешеп, хәрәкәттә этләр генә калдылар. Егетләргә авылның икенче башында гына ут эленгән йорт очрады. Капкасы төбенә килсәләр, кеше дә бар икән. Әмма сүз куертып маташучы булмады ул, үзара аңлаша, уртак тел таба алмадылар. Моның сәбәбе — егетләрнең ачуы килеп, чөйле сүзләр кыстыргалап сөйләшүләреннән иде.

— Бу йортка бүген әҗәл керде, энем, алай кыланма,— диде ул капка төбен саклаучы, сүзе белән Шәрифләрне озата барып.

Моны ишетүләренә, егетләрнең коты калтыранып куйды. Күрше авылга җитәрәк таң үзенең туарга җыенуын белдерә башлаган, шәфәкъ ягы нурга манылган иде. Авыл башында ук Шәрифләргә атлы юлаучы очрады. Туктатып хәл белештеләр. Абзый кеше боларның кая барышларын төшенгәч, бик зур рәхәтләнү диңгезенә төшкәндәй озаклап ухылдый-ухылдый көлде һәм:

— Энем, сезгә бик яман туры килгән әле бу... Сез эзләгән Бөгелмә ягына бару өчен поезда кимендә уналты сәгатьләп килергә кирәк, ә сез җәяүләргә план коргансыз,— дип, җитдиләнергә тырышып әйтүе булды, тагын тыела алмый хихылдады.

Ачыкланды: егетләрне алдаганнар, мокытлар урынына күргәннәр икән. Менә сөйләш кеше белән маңгай өстеннән генә карап, хәзер кәмит ясыйлар үзеңнән!

Ә егетләргә башка бернинди чара калмады: беренче поездга көч хәл белән генә эләгеп, Казанга кире кайтып киттеләр. Аларны дөнья шулай өйрәтте, әүвәле кикрикләре салынып төште, аннан соң ачулары кабарды һәм, соңыннан гына, уйлана башлагач, тик бар нәрсәгә дә үзләренең генә гаепле булуларын, миһербанлы һәм кешелекле кыланмауларын исләренә китереп, тагын да күңелләрен авыр яралар белән сызландырдылар. Ә шулай да барыбер ачык көнгә, кояшка туры карыйсы килә адәм баласының. Шушы әрсез һәм ут коя-

шына, алсу таңнарда балкышына сокланып туры карыйсы килә. Кояш! Син дөньяны гына түгел, күңелләрне дә изге буяуларга манасың! Кояш һәм... Кояш һәм нефть, әйе-әйе, кояш һәм нефть!..

Шәриф үзалдына онытылып, үзсүзләнеп алды. Әтисе белән бәхәсләшкән төсле, ачулы йөз белән, мыскылланып, беркем дә белми торган хакыйкатьне үзе генә төшенгән кебек итеп. Әнә әтисе, Кәрим Хафизович, партия кешесе, җаваплы хезмәткәр, райком секретаре, ә көнүзәк мәсьәләне аңлап җитми, имеш. Нефть эше авыр, безнең халык ул эшкә күнекмәгән, әүвәле кадрлар, ә аннары киң колач җәеп тотынсаң да була. Юк инде, кадерле әтием, эш һәм көндәлек батыр хезмәт үзе кадрларны җитештерәчәк. Ат тугарып җигә белгән кешегә нефть эше тансыграк, үзрәк булачак, менә күреп торырсың! Әнә, инде яшекарты диярлек нефть эшендә. Аларны акча үзенә тарта, диярсең, җаннарын җуйганнар, диярсең... Юк инде, кадерле әтием, хезмәт көненә алынган өч-дүрт бөртек ашлык белән торуга караганда, кесә тулы акча белән яшәве җиңелрәк. Ә нигә җиңел булмасын? Чөнки акчага без һаман да табынабыз. Бар куәтлелек — акчада! Кайсы кешеләр бай яшиләр, алар мәдәниятле булалар. Уйлап кара — гади арифметика: кемнең кесәсендә акчасы күбрәк һәм кемнең кесәсенә ул агып кереп бара, шул исәптән чыгып та тора. Ә өч бөртек ашлык белән генә мәдәният булмаячак, ул кесәгә түгел, корсакка да җитми. Ә син киләчәк, дисең, табигать тәрбияли, имеш! Тәрбияли, әгәр дә тәрбияләр табигатең булса. Әүвәле аңлый белергә, өйрәнергә кирәк ул табигатьне, моның өчен дә мәдәниятле булу сорала. Ә алай дип уйлап торамы авыл агасы: “Һай төз каен, бигрәкләр дә сылу, кызлар төсле икән”,— дип? Юк, һич юк!.. Ә мәдәниятле кеше өчен ул каен табигатьнең гүзәл сыны, шагыйрь булса, аңа атап шигырь язар иде... Ә мәдәниятле кеше бу каен хакында кимендә өч-дүрт шагыйрьнең шигырен яттан укыячак!..

Шәрифне әтисе мондый вакытларда бүлдерә иде:

— Синең мәдәниятле кешең никадәр интеллектуаль булырга өлгермәсен, барыбер ул агачның, утын түмәренә әйләнәсен күз алдына китерә алмый. Ә авыл агае өчен, иң беренче, табигать кочагындагы каен — себерке, аннары, киселгәч — утын, гади утын гына түгел, кышкы салкыннарда өй эченә җылы, тәнгә сихәт, җанга рәхәт бирә торган учак утыны; икенчедән, ул каен бүрәнәсе яки йорт диварын бөтен итеп торучы җанлы шигырь, ипле ятучы, төзелеш өчен кирәкле агач!

Андый чакларда Камил Хафизович салмак кына сөйләгән җиреннән тагын да акрынаеп, сүзләрне эзли-эзли газапланадыр иде. Бәлки үзенең фикерләре буталы булу аркасында, яки инде әйткән сүзенең төшендерелмичә өзелгәненә офтана идеме, анысын ук Шәриф аңламый, әмма ул, сүзләрен сайлаганда, никадәр акрынайса, шулкадәр уйлары да дөреслектән ерак төсле тоела иде. Һәм вакытның күбесен буш сүзләргә әрәм итеп, ата белән улы сөйләшүләрдән тәмам арыган кыяфәттә туктала иделәр. Икесе дә үзләренең әйтәселәрен аңлатып җиткерә алмаганнары хакында уйлап офтана-офтана, өлкәннәр белән яшьләрнең килешә алмаячаклары борынгыдан ук килгәнлегенә фикер игътибарын юнәлткәннән соң, бүтән бу темага сөйләшмәскә үз-үзләренә антлар эчеп, һәркайсы яраткан шөгыльләренә чума иделәр. Кәрим Хафизович журнал һәм

китап сәхифәләреннән башка районнарның һәм төбәкләрнең хәлләре һәм уңышлары-борчулары белән таныша, эзләнә, яза-сыза. Ә Шәриф, икенче бүлмәгә чыгып, малай чагында урамга багып утырган тәрәзә төбеннән кояш баешына текәлә. Уйларга чумып, кызара башлаган миләшләргә соклана, шигъри хискә бирелә. Әмма тора-бара бу кыланышлары онытылгандай булганнан соң, ул хисләре ниндидер тулы бер эчтәлек ала башлап, Шәриф буталчык һәм төрле тойгылар эчендә түгел, ә гади һәм эчке гүзәллеккә ия моң кочагында кала. Бу моң мөгаен романтик хисләрнең күңелне алга дәшүе булгандыр?..

Һәм менә хәзер, бүген шушы таң атышына карап торганында да бу хис-тойгылары аның күңелен кабат биләп алгандай тоелды. Ул әллә самими кыз елмаюы, әллә инде яшьлек ашкынуы иде, йөрәк эченә кереп нидер пышылдый, җанын билгесез дулкыннар кочагына ярсый-ярсый дәшә иде.

Бәлки ул сөю утыннан янып бетми калган кисәү булгандыр?..

10

Бию, ул дөньяда кеше тарафыннан кичерелгән хисләрнең эчтәлеген, тел һәм шигърият белән аңлатып бетерергә мөмкин булмаганын төшендереп бирә ала торган иң бөек омтылышы, хиснең иң югары ноктасыдыр бәлки? Ул, шушы нокта буларак, бөтен, тулы һәм омтылыш төсле ашкынулы түгелме соң? Ул бит рәсемнәрдән гаҗәеп дәрәҗәдә җанлы булуы белән генә аерылып тора. Бию һәм рәсем – алар икесе дә бер үк җенестән барлыкка килгәннәр, уртак форма һәм эчтәлеккә ияләр. Һәм шуңа күрә дә алар сүзсез аңлашыла торган шигърият. Боларның икесе дә үзләренә сыйдыра алган кадерле хис сәнгать төрләренең берсендә дә юк, бары бию һәм рәсемнән югарыга сөю генә күтәрелә ала. Ул тагын да зуррак эчтәлеккә һәм бөтенлекле формага ия. Сөю! Ул сүзсез, әмма дөньяда булган барлык сүзләрдән эчтәлеклерәк, ул чиксезлеккә ия. Сөю! Шуңа күрә дә аны шагыйрьләр һич кенә сөйләп, аңлатып, күңелләргә җиткереп бетерә алмыйлар. Чөнки ул аерым шагыйрьләрнең хисләренә караганда да бөегрәк, чөнки ул шигърияттән күпкә, бик күпкә өстенрәк. Менә, баштан ук ул Гөлгенәне яратты. Нинди гүзәл һәм горур иде ул... Бәлки читтән караганда гына шулай тоелгандыр?.. Ә якыннан танышкач, аның бу яклары гына түгел, башка сыйфатлары да, бигрәк тә күңеленең матурлыгы үзен сиздерә башлады: бу — самимилек иде. Камил шуңадыр бар җаны белән аңа гашыйк булды. Берсе — комсомол вожагы, эшчән егет, икенчесе – комсомолка, сабыр һәм күндәм холыклы, әмма үз дигәнен эш итә иде. Билгеле, башлангыч сыйныфлар өчен шушындый укытучылар кирәктер дә: самими дә булсын, тәвәккәл дә! Алар берберсен якыннан белешкәнгә кадәр үзара яратыша, сокланыша иделәр. Ә серләрен Яңа ел кичәсендә генә яшерми бүлештеләр. Клуб бикләнергә вакыт җиткән иде инде. Күпләр таралышып, азлар гына торып калгач, тагын бусы инде соңгысы дип башлангач, Камил, кыенсынып кына, Гөлгенәне биюгә алды һәм серен, турыдан булды бу дип тормады, әйтте дә салды:

— Мин сине яратам!..

Кыз урталай диярлек бөгелеп төште. Әмма үзен кулына тиз арада алырга өлгерде һәм аның әрсез сүзләрен кире какты:

— Камил абый, сез нәрсә, ничек инде?..

Егет бер башлаган туры сүзеннән чыкмыйча, матурлап һәм боргалап, үлчәп-уйлап сөйләнгәләп тормады, юлын элеккечә туры тотты. Имеш, беткән баш — беткән, инде хәзер сырмаланып торырлыгың калдымы соң!

— Берничек тә түгел... Чын дөресе... Бүген мин сезне озатам, ярыймы?..

Каушавын кыз моннан соң да яшерә алмады:

— Ничек инде?— дип калтыранды ул.

— Чөнки мин сине яратам!— диде Камил, тагын да әрсезләнеп һәм үзенең мондый дорфалыгын үзе үк аңлап җиткермичә.

— Ничек инде?..— диде кыз, тәмам хәлсезләнеп.

Сүзләре шунда өзелделәр, бию-уен беткән иде. Алар кайтырга чыктылар. Янәшә барсалар да, озак кына сүзсез атладылар...

Шул кичәдән соң төгәл ике атна узды һәм алар өйләнештеләр. Аннары Шәриф туды. Аннан соң сугыш башланды...

Сугыш...

Кешелекнең куркыныч саташуы буларак истә калган, никадәр миһербансызлык һәм кайгы-хәсрәт кылган, җанны да, тәнне дә, җирне дә яралар белән каплаган сугыш!.. Хәтеренә тирән уелганга күрәдер инде, Камил Хафизович сугыш хакында уйларга һәм сүз кузгатырга да яратмый, сөйләшүләр шул якка таба кереп китсә, нәфрәтеннән үзен көчкә тыеп кала, күз алдына тереләй яндырылган хатын-кыз, бала-чага, карт-корыны китереп, танклар белән тапталган авылларны, самолетлардан коелган бомбалардан җимерелгән шәһәрләрне исенә төшереп, үзен тойгы һәм хисләр чигенә җиткерә иде. Мөгаен аның йөрәк чире дә шулар хисабыннандыр? Дөрес, сугыштан кайткан кайсы солдатта гына юк икән ул андый йөрәк чире?

Камил Хафизович сугыш мәхшәреннән исән-имин чыкса да, Гөлгенәсе аның үзгәргәнен, җаны суынуын күреп, ничә төннәр буена зар калып, хисләрен яшереп елады. Күпме көткән кешесе, үз ире бит!

Кайчагында Гөлгенә ханым, иренә карап утыра-утыра иде дә, соравын бирә иде:

— Кая синең, Камил, кара бөдрә чәчләрең?

Җавап бары тик ишарә белән генә иде: “Анда!”

— Кая синең елмайган иреннәрең?.. Нурлы йөзең?.. Кая?..

— Анда!— Камил Хафизович тагын Герман ягына ишарәләп куя. Ә Гөлгенә ханым, күрше бүлмәгә чыгып, үкси-үкси елый, иренә җан, дәрт бирүнең серен таба алмавына мыскыллана:

— Нишләдең син, Камил?.. Нишләттеләр сине?..

Җаваплар һаман да бертөрлерәк була бирделәр. Шулай да Камил Хафизовичның куәте-акылы вакыт-вакыт урынына утырган төсле була башлады. Мәхәббәт ташны да эретә диләр. (Минем ул сүзләрнең хаклыгына ышанычым юк иде. Әмма тормыш үзе аңа ышанырга мәҗбүр итте. Фәрһәд хакындагы әкиятләр минем өчен дә үз тоела башладылар). Камил Хафизович яңадан тугандай булды. Гомерен МТС ягулыкларын каравыллап үткәрер бу дигән Гөлгенә ханым да ялгышын тиз аңлады. Камиле гүяки кинәт яшәреп китеп, дүрт-биш квадрат метрлы такта сарайга сыймый, ниндидер, яшьлектә генә була торган хис белән алга, болытларга ашкына башлады. Булмады... Аны тиз бәреп төшер-

деләр. Әмма ире бу юлы да тиз генә бирешмәде, нидер көткән кебек, йортының чын хуҗасы бу морҗаны болай итеп сүтәргә һәм корырга кирәк, бу капканы шулай эшләсәң яхшыдан булыр дигән кебек, Хафиз малае Камил дә нәкъ шундыйрак уйлар эчендә йөзде. Чыннан да хуҗалык эшенә, күмхуҗ эшенә аның бар уйлау-фикерләү егәре, осталыгы, хәтта гәүдә тотышы ук килеп тора иде: киң җилкәләр, туры басынкы адым, шактый уйчан, күзгә бик авыр тоелган баш һәм хисләрне җыярга этәрүче, дулаган атка да йөгән салырдай туры, буйсындыручан караш һәм йөз, әмма менә шушы булганлык комплексына бер әйбер комачау итә иде, ул да булса — чәчләр, ни сары, ни коңгырт, ни ак булган чәчләр. Камил Хафизовичның бу килешсез ягы нигәдер беренче караштa ук күзгә чалынып, аның хакында бик үк яхшы фикерләргә этәрми иде. Әмма Камил Хафизович белән сүз тегермәнендә очрашкан кеше инде чәчләр, тышкы кыяфәт белән буталмый, бәлки нәкъ уңай якларын сизенеп ала, өстән генә карап сөйләшүе дә инде югарыга карап әңгәмәләшүгә күчә бара иде. Кәрим Хафизовичның йөзендәге мәгънә билгеләре өстен чыкты һәм башкалар хакында кайгыртучы булуы авыл халкы арасында күмхуҗ җыелышыннан соң купты.

Җыелыш үзе болай башланды:

Бозлы-яңгырлы яз көне идарә составы җыелышып уйга калды. Сорау — бер, мәсьәлә — ике иде. Сорау: ни өчен рәис Солтан Сәрсибашев күмхуҗны алга сөйри алмый? Мәсьәләләрдән беренчесе, алга таба Сәрсибашевтан ниләр өмет итеп була? (Бу мәсьәлә авылларда гына була торган беркатлылык һәм турылык белән халыкка белдерелгән иде); икенчесе, кемне рәислеккә сайларга? (Монысының бәхәскә куелуы беренчесенең зарурлыгын юкка чыгара иде).

Район вәкиле үзе идарә утырышында катнашып, сүзне әле Сәрсебашевны яклап, әле аңа каршы барын сөйләп карады. Билгеле, ул юри идарәне сынавын белдермәде, әмма өлкәннәргә бу карт төлке Сәхил Гыйлемзарович ошамады. Чөнки ул аларны тәмам бутап бетергәч, үзе бүтән йомышлары белән чыгып киткәләп йөрде. Бары икенче мәсьәлә куелу белән барысы да җиңел суладылар. Беренчедән, язгы пычрактагы ярты көн әрәм узу исләренә төште, икенчедән, сәгатьләр буена барган бәхәскә чик куелды. Сәрсебашевны сыгып газапландыру бетте, ә икенче мәсьәлә бик тиз чишелде, Гыйлемзарович юклыктан файдаланып, бу сорауны күмхуҗның гомуми җыелышына куярга булдылар. Сорауга шунда җавабы табылачак иде. Ничек кенә итеп әле, район җитәкчесе үзе үк килеп, җитмәсә бер яңа рәис тә тапканы, үз кешесен үз теләгенчә халыктан мәҗбүранә куйдырачагы да билгеле булды.

Кешеләр һәммәсе дә диярлек уңлы-суллы сөйләшенгәндә, булачак рәисне читләтеп кенә күзләделәр, хатын-кызларга ул ошады ахрысы, йөзен-кыяфәтен мактап туймадылар. Тик ирләр генә актан да, карадан да эндәшмәделәр.

Сүзне озакка сузмыйча, мәсьәләне уртага куйдылар: кемне сайларга? Гыйлемзарович канәгатьлек белән куанып елмая иде, имеш, сез белмисез дә белмисез инде, ә миңа бик яхшы билгеле!

Әмма аның елмайганына үртәлептер, урыннан кычкыручылар да табылды:

— Алып килгәнсез бит инде, этле-мәчеле уйнаган булып...

— Куегыз шуны, безгә нәрсә!..

— Эш рәтлерәк барса шунда, ярамаган тагын...

— Кем икән соң үзе?..

Бу реплика һәм сорауларга күңеле булып ахрысы, райком секретаре Бибиев Сәхил Гыйлемзарович урынынннан кузгалды. Сүзләрне ерактан, тын агып утырган чишмә ярларында утырган район үзәгеннән алып, Казан якларыннан уратып кайтып, матур итеп тәфсилли-тәфсилли сөйләп китте, инде тәмам арыткач кына, булачак рәиснең кемлеген шәрехләп алды:

— Сезнең алдыгызда, хөрмәтле һәм мөхтәрәм күмхузчылар, Рәис Вилданович. Эш стажы унбиш елга тула, күпне күргән...— Бибиев шып туктады, өстәлдән нидер эзләде, кайдандыр табылган күркәм стаканда су китерделәр. Бу вакытта Рәис Вилданович ни эшләргә белми басып тора бирде. Әмма күп сөйләп арыган, башкаларны талчыктырып бетергән телен болай гына җайлап булмасы секретарьның сүз таба алмавыннан ук күренә иде. Һәм менә ул тагын зиһенен җыеп өлгерде, таныштыруын дәвам итте: — Шахтада күмер чапкан, сугышта батырларча көрәшеп, күп яралар алган, орден-медальләре дә байтак, МТСта завхоз иде, аннары...

Вилданович мактала торды, хатын-кызларның “И-и-и...” диеп исләре китә барды, ирләрнең башлары буйсыначакларын белдереп аска иелгәннән-иелде.

Сүзләрдән шул беленде:

— Бу булса, җиңәчәк инде. Җитмеш кат тирене салдырыр...

Бары тик МТСтан күмхуҗга күчкән кешеләр генә авыз читләрен боргалап һәм яшереп елмаештылар.

Һәм ниһаять сүз күмхуҗчыларның үзләренә бирелде. Ара-тирә тавыш та купкалады:

— Сайлыйк әйдә!

— Безгә нәрсә, сайлыйк!

— Булсын шунда!

— Ярар,— диде Бибиев,— сайлыйбызмы?.. Тавышка куям...

Ул, кыйммәтле мизгелләрен югалтып, тәрәзә ягына күз салды. Һәркем шул якка карады, зиһеннәрен югалтырга өлгерер өчен бу җиткән иде. Анда Сәрсебашев, исерек гәүдәсен сөйрәп, киртәләр буйлап кайтырга чамалый, әмма булдыра алмый, урык-сурык килеп газаплана иде.

— Шуннан,— дип сузды тагын Бибиев, тик күпләрнең күзе, анықына ияреп тәрәзәгә баккан, киртә буендагы Сәрсебашевта иде. Күмхуҗчыларның дикъкатен җыелышка кире кайтарырга кирәк булды. Бу очракта берәр нәрсә сөйләп куюның яхшы икәнлеге Бибиевкә яхшы билгеле иде. Әмма үзенең дә күзләренә гел шул Сәрсебашев сурәте китмәде, ике егет җилкәсенә асылынган хәлендә ул яктан югалгач та тиз генә зиһенен кабат бер ноктага җыя алмады. Шунда Бибиевнең әйтергә теләгән сүзен өзделәр. Торып баскан кеше аңа таныш кебек иде. “Нишләмәк кирәк, җыелышны бәлки бу кеше туры юлга кертер, аннары соң, шулай кирәк, үзләре дә сөйләштерсеннәр!”— дип пышылдады Бибиев өстәл янындагыларга, сүзләрен адрессыз гына юнәлтеп.

Бибиев утырды. Каты утырды. Торып баскан кеше боргалап тормады. Турыдан ярып:

— Иптәшләр, күмхуҗчылар! Сайлагыз мине, бер елдан күмхуҗны миллионерга чыгарам,— дип әйтеп салды.

Ышанмадылар.

Тик мужикларның гына башы өскә калыкты. Җыелыш өзелде. Икенче көнгә кадәр чигерелеп, ә анда, аңа ышануларын белдереп, һәммәсе бер тавыштан шул кеше файдасына тавышларын бирделәр. Ул кеше чыннан да рәис булырга лаеклы иде — Кәрим Хафизович!

Бибиевкә дә нидер булды, соклануын яшермичә:

— Тәвәккәл таш яра, ышанабыз!.. Ярый, Кәрим Хафизович, сезне сайлыйм,— диде һәм, үз сүзенә үзе үк ышанмыйча, җәйгә кадәр күмхуҗ эшенә тыгылмыйча, дәшми-тынмый район үзәгендә нәтиҗәләрне көтеп ятты.

Ә күмхуҗларының эшләре бик авырга, тәмам күтәрәмгә калган вакытлар иде бу.

Беренче эш — малларга азык кирәк иде. Кара язда аны каян аласың да, ничек ул башмак-таналарны, тояк-санакларны беренче үләнгә кадәр генә булса да алып чыгасың? Шушы эш ышандырырлыкмы? Юк! Аңа кем ышансын... Әмма татар барда — хәтәр бар, дигәннәр. Эш чыннан да көтелгәннән дә хәтәррәк булып чыкты. Кәрим Хафизович малларны гына түгел, күмхуҗны да аякка бастыра алды.

Эш болайрак оешты: әүвәле Кәрим Хафизович мал-туар утарларын йөреп чыкты, бар булган ашлык һәм азыкны җитди, төгәл хисапка кертте. Хәлләр мөшкел иделәр. Хәтта чәчүлек орлыкның да күбесен дәүләттән сатып алырга туры киләчәк иде. Беренче көннәре менә шулар белән үтте.

Аннары бөтенләй дә көтелмәгән вакыйгалар башланып киттеләр. Һәркем, кем аякта йөри ала, көрәк, сәнәк, балта, пычкы тота белә, эшкә чыгарылдылар. Авыллары артындагы сазлыктан тал ботакларын чаптыртты, камыш җыйдырды, ылыслы агачларның түбәнге ботакларыннан себеркеләр ясаттырды һәм боларны абзар-кураларга ташыттырып, мал-туарның астына һәм алдына куйдырттырды. Ачка беткән хайванкайларга бәйрәм булды бу.

Икенче атнаның өченче көне рәис күмхуҗ территориясен ташлап ук китте. Моны беркем белмәде. Күмхузчылар өчен ул кайсыдыр күрше тирәклектә тал бөресе җыядыр кебек иде. Шулай тагын бер атна вакыт үтте.

Өченче атнада рәиснең юклыгы беленде. Шапалай Саттар, юри шаяртып:

— Талдан малларга чир керә, имеш... Егетләр, әнә Хафиз малае, мин күмхуҗны күтәрәм дип тал җыйдырганы өчен, районнан китерелгән җантимер кулына кергән, башы Себер киткән икән,— диярәк сөйләнгәләп, куш янына иш тә өстәп куйгалап, җитмәсә: — Үзен дә бетерде ул малай актыгы, тиздән авылыбыз белән үк Себер ягына озатачак икәннәр,— дигәч, күмхуҗда эш башлап йөрүче коммунист Закир абзый Лотфи үзе үк район үзәгенә ат чаптырган, яхшылата аңлата икән үзләренә:

— Егет — безнеке, тиясе булмагыз! Чал чәчем белән ант итеп әйтәм, күмхуҗны торгызыр, аякка бастырыр ул,— дигән, җитмәсә: — Сүзем хак, башымны кисмәгә бирәм!— дигәне дә җитә каласы икән.

Бу вакыйга чыннан да булган, әмма шаян сүз осталары аңа күпне кушып сөйләмәсәләр дә ярар иде. Шунысы бер хикмәт, авылның ике башыннан, бер ягыннан Закир абзый районда әйткәннәрен халыкка сөйли-сөйли килә икән, икенче ягыннан дәү чананы тракторга тактырып, алагаем йөк итеп төяткән фу-

раж белән Кәрим Хафизович кайтып төшкән.

Тагын ышанмадылар. Юк, булмас аннан, диделәр. Тик Закир абзый ышангач, күмхуҗда да, районда да кем каршы сүз әйтер? Ышандылар. Әмма күмхуҗлары ике-өч ел эчендә миллионерга чыккач, тагын ышанмадылар, хата эзләделәр. Һәр җирдә хәйлә күрделәр. Ләкин ахырда ышанырга туры килде аларга. Менә шуннан инде Камил Хафизович абруй алды. Бишенче елында аны районга ук күтәреп, беренче секретарь урынына куйдылар. Бу вакыт эчендә шулай үсеп китәргә лаеклы иде ул. Әмма бу тарихларны күпләр белми һәм искәрми иде. Менә инде хәзер бөтен бер район өчен җаваплы кешеләрнең беренчесе ул!

Ә тормышлар һаман да үзгәрә тора икән. Баштарак эш белән бөтенләй дә игътибар итәргә туры килмәгән аңарга, ваклыклар инде зурая башлаганнар, алар сизелерлек булып, үзләренең һәр җирдә комачау иткәнлекләрен күрсәтеп тора иделәр. Ә тормышның кинәттән үзгәрүе, бу якларның тиз арада нефть фонтаны астында калуы ул ваклыкларны тулысы белән алга чыгарды. Һәм алар гади ваклыклар гына булуларын югалтып, төп шартка һәм сәбәпләргә әйләнеп киттеләр. Шуларның берсе һәм беренчесе — күмхуҗларның киләчәге иде. Берничә ел элек кенә алдагы көне зур булып күренгән күмәк хуҗалык бүген инде иске бер кыйшайган тәгәрмәч төсле, алга барган, тизлекне зурайткан саен, төп кормага ешрак суга һәм үзен дә җимерә бара иде.

Исендә Камил Хафизовичның, бик исендә. Ул вакытта әле күмхуҗ рәисе генә булып эшләсә дә, күп башлангычларның өлгесе иде ул. Шулай берзаман район бюросыда аның җитәкләгән күмхуҗындагы эшләрнең барышы белән кызыксындылар. Мондый гамәлләр Бибиев тарафыннан эндәшелми генә алып барылганга күрә, гаҗәпләнерлек урын юк кебек күренде. Әмма каныгучан Бибиевкә нидер кирәген төшенү дә җиңел иде. Чөнки район артка калганнан кала, моның сәбәбе дә бер генә — күмхуҗлар тәмам бүселә бара, район идарәсе күрәләтә шуңа игътибар итми, рәисләрне башбаштаклыкка этәрә иде. Ә алда барган күмхуҗлар Бибиев планнарына буйсынырга теләми. Ни дигәндә дә, аларда көч, аларда эш дәрте сүнмәгән, хуҗалыклар яхшыра, ныгый гына бара. Тик кемнәр-кемнәр, ә район үзәгендәгеләр яхшы белә: алга киткән һәр күмхуҗның карынында арта калган күмхуҗларның өлеше ята. Бу яктан Камил Хафизович та ялтыраганнардан түгел. Аның район алдында ике бурычы бар: беренчесе — кара язда, рәис булып эшли башлаганының тәүге атналарында ук башка күмхуҗларга тиешле фуражны ул үзләренә юллап алып кайтты, ә икенче бурычы — коммунист сүзе, намус эше — биргән сүзне үтәп, ышанычны аклау иде. Ә Бибиев беренче бурычын искәртеп түгел, икенчесе белән аның минминлегенә суктырырга яраткан талантлы җитәкче, үзсүзле һәм булдыклы ир иде. Ул, кирәк булса, шушы коммунист намусы дигәнен шулкадәр кабарта ала иде, хәтта бернинди файдасызга үзеңне корбан итәргә мәҗбүр буласың. Әүвәлге очрашуларында Камил Хафизович аның бу сыйфатына сокланса, азакка таба ул сүзләрнең таш атып тәрәзә вату белән тәңгәллеген сизенде, ә инде җитәкчелек эшен төшенеп алгач, район үзәгендә еш була башлаганыннан соң аңлады: Бибиевнең тәлинкәсе бер генә яклы һәм гаҗәеп туйдыручан, җанга тиючән икән. Әмма Бибиев хәйләкәр төлке иде. Үзенә буйсынмаганнарны шома гына

буразнасына яраштыра ала. Һәм бюрода да Камил Хафизовичның отчетын хуплап, аңа җиңел генә йөгән кидертә алды. Бибиевнең ул йөгәнне нык тотачагын яшь рәис аңлап җиткермәде һәм ару капты — алга да, артка да, уңга да, сулга да борылмый барырга туры килде үзенә. Сораганынча Камил Хафизовичка МТСның тракторларын Бибиев бүлеп бирде, ягъни, аңа туктаусыз булышты. Рәис дә моны чын күңелдән, эш кирәге өчен ярдәм итүе дип кабул итте. Әмма бу булышлыкның төп мәгънәсенә бер елдан соң гына төшенде. Ул тракторлар ярты ел эчендә ватылып, эшкә яраклыларыннан чиреге генә калды. Сәбәбе – яхшы җиһазлы машина-трактор мастерское гына түгел, запас частьләр дә юк иде. Әмма районда Бибиев аның белән башкача сөйләште:

— Камил Хафизович иптәш, үзенең коммунистик намусын онытып, ашлык “задание”се үтәлмәүдә техника җитмәгәнлекне дәлил итеп куя... Уйлап карыйк... Искә төшерик, иптәшләр, кемдә техника юк та, кемдә көч аз...

Камил Хафизович үзен горур тотарга тырышса да, ачуыннан кызарып-бүртенеп чыгуын сизенми калды. Маңгай читләреннән салкын тир бөркелеп, ул эсселе-суыклы булды, әмма каршы сүз әйтә алмады, йөгәне аны нык тоткан иде. Шулай да җавапсыз калса, үзен таптап китәселәрен сизенде ул.

— Минем кара уемча, гаеп техникада гына түгел...— дип сүзен башлаган рәискә Бибиев ямау салырга да өлгерде:

— Дөрес, бик дөрес, бөтен гаеп кешеләрдә, шәхесләр булмауда! Оештыра белүче авторитетның җитлекмәвендә!..

Бу күрәләтә сыртка суккалау иде. Әмма Бибиев үзе кыйнаган урыннарны сыйпап та куярга ярата һәм шулай эшләде дә. Тик бу юлы ул гадәте бик елдыр, шома, сизелерлек булып чыкмады:

— Ә сезнең күмхуҗга ни җитми?— Бу соравыннан соң Бибиевнең борылыш ясавын яхшы аңлаган Камил Хафизович киреләнергә булды. Акыллы баш буларак, бездә дә гаеп юк түгел инде дисә, әллә кайчан алтын балык тотар иде... Юк, ул сүзләрнең кирәклеген яхшы тойса да, үзенең ир сүзе сөйләвенә ныклы ышанып, җаны теләгәне әйтте:

— МТСларны таратмаска иде!

Бөтенесе шым калдылар. Үзәк партия карарына каршы килгән “егетләр” белән элегрәк башкача сүз ката иделәр, бу юлы инде әйтелгәннең сәбәпләрен дәлилләү таләп ителә иде. Рәис үзе дә кыстатып тормады:

— Минемчә,— диде ул,— бар гаеп бары тик үзебезнең күмхуҗда, тракторларны көйләү-җайлау һәм шуның кебек эшләрне башкару өчен үзебездә үк мастерской булдырмауда!

Бу сүзләреннән соң Бибиев балкып тантана итте. Сүз — атылган ук төсле, никадәр оста ычкынса, шулкадәр төз барып тия. Камил Хафизовичның да сүзләре файдага булды. Озак сөйләнеп утырмыйча, барлык әйтәсен ул шуның белән йомгаклап та куйды:

— Соңгы ел күмхуҗларга зур яңалыклар алып килде, көтелмәгән үзгәрешләр күбебезне бөтенләй эшкә яраксыз итеп ташлады дип әйтмим, әмма ел эчендә алынган тәҗрибәләрне җыйнаштырырга, уртак фикергә килергә вакыт түгелме? Күмхуҗ рәисләре, алдынгы күмхуҗчылар җыелышып, шул хакта киңәш-табыш оештыру яхшыга гына булыр иде!

Бибиевкә монысы да ошады. Ул үзенең килешүен белдереп баш какты. Мондый киңәшмәләрне кыш башында ук, яңа кар утыргач җыелышып уздыру яхшырак булыр дигән карарга килделәр.

Карар хакында юл буе Камил Хафизович уйланып кайтты. Аның башында әүвәле бер уй купты, әллә барысын да шул җыелышта бәйнә-бәйнә сөйләп бирергәме? Аннары икенчесе, өченчесе... Ул бары тик күмхуҗы кырларына җиткәч кенә сүрелә төшеп, үзенең бюрода булуын кабат күз алдына китерде. Тагын да ясала киленә торган ялгышларны, бераздан алардан арынып, кылган уңышларын һәм җиңүләрен исенә төшерде, җанына сеңдерде. Бибиевнең тоткан йөгәнен соңгы вакытларында азрак бушатырга өлгерүен төшенеп алгач, Камил Хафизович елмая ук башлады. Аңа рәхәт, бик тә рәхәт булып китте. Ни дисәң дә ул Бибиев кадәр Бибиевне җиңеп кайтып килә иде шул... Ә янда, Көнчыгыш якта сары ярым ай, калкулыклар өстендә генә, үрелеп алырлык кына биеклектә тәмле сыр кебек, туклыклы сурәттә ялтырый, рәхәтлек биреп елмая иде...

Ә берничә көннән Камил Хафизовичны бюрога кабат чакырттылар һәм үзен секретарь итеп, аны сайлауда күрсәтергә исәпләре барлыкны белдерделәр...

11

Тормышлар яхшырган саен әнкәйне хәтеремә алам. Ул миннән еракта, авылда. Үзем шәһәрдә, Казан каласында яшим. Кызым үсә. Ә без үскәндә алты бала идек. Берсеннән-берсе кечкенә, ә ашау ягына килгәндә — берсеннән-берсе усалрак алты тамак идек. Әнкәй кыска кышкы көннәрдә бер караңгыдан икенчесенә кадәр бәрәннәр карый, анда-санда безне, ике малаен, яки олырак кыз балаларын ияртеп, төнге каравылга бара. Иң күңеллесе — ул каравыл дигәннәре атнага берничә тапкыр кабатланып тора иде, ә өйдә күпереп торган икмәкләрне мич тутырып пешерә. Җылылар... Күрше малайлары ак күмәч белән тәгамь итә иде, ә безнекеләр — күпереп торган чын икмәк, бодай ипие, кара ипи. Шуңадыр күрше малайларыннан тазарак һәм үткенрәк идек. Кышлар безнең өйдә шулай үтеп китә тордылар. Җәйгә чыкканчы ук гаиләбезнең сигез тамагы — әткәй-әнкәй һәм без, балалар, тулып торган сай икмәк ларының төбенә төшеп җитә идек. Әнкәй безне, балаларын ияртеп, чүгендер утарга алып чыгып китә. Ярыша-ярыша эшлибез. Анан, тәмам арыгач, утырып, яңа гына тишелеп чыккан яшел кыяклы суган белән тозлап ипи ашыйбыз, чишмә суы эчәбез...

Илнең бу чоры нык үскән социализм юлыннан зур атлап барган чаклары иде. Без бәлки ил кайгыларыннан ерак булсак та, шул ук илебез белән бергә бара идек. Әмма җәй башына ук әйләндереп, тузаны кагылган лар безнең өметләрне башка якка юнәлтергә мәҗбүр итә. Әнкәй, нинди уңган кеше ул безнең, булыр-булмас сигез-тугыз тавыгының йомырка салганын көтеп ала да, дистәгә тулуга, шәһәргә илтеп, аларны икмәккә алыштырып кайта. Дөрестән дә безнең тавыклар тырышлардан иделәр, аларның шуңа күрә йомыркалары да эре була иде. Ә эре йомыркаларны шәһәр халкы ярата, кулдан өзеп ала. Әнкәйгә ияреп барган без дә, сөенешеп, аларны саткан акчаны икмәккә алыштырабыз да, табадай кызган шәһәр урамнарыннан җәяүләп узып, авылыбыз ягына илтүче юлга чыгып басабыз.

Бу йөрүләр еш кабатлана иделәр. Шуңадыр мин яшьли шәһәрнең ни-нәрсә икәнлеген белеп үстем. Әнкәйгә рәхмәт, шулар аркасында шәһәрнең дә, авылның да ниндилеген яхшы аерам кебек.

Тормышлар матурланган саен мин шулай әнкәйне искә алам һәм җаным елый башлый.

*Казан, 1984.*

# ӘНИЕМ, КОРЪӘН ЧЫГАРСЫҢ

*Повесть*

## I

Зимагур Хәләфнең кайтып төшүе авылда күп сүзләрне кузгатты. Язгы ташулар бетеп, халыкның басу-кырга чыккан вакытлары иде. Югары очтагы Галимулла хәзрәтнең мәдрәсәсендә кыш буена гыйлем эстәгән шәкертләре таралышканнан соң, бу беренче зур вакыйга булды. Аталар кызларына йорт капкасыннан үтеп чыгарга ярамаслык рәвештә кисәттеләр, аналар, күз-колак тотып кына, аларның һәр адымнарын барларга тиеш иделәр, хәтта урынлы-урынсызга:

— Пәрдәне ник күтәрдең әле, чоланга чыгып, токмач кис, эшең беткәнме әллә? — дип ачулануны да гадәт иттеләр.

Шулай да чибәрлектә дөнья бәһасе кызларның соңгы көннәрдә итәкләре кыскара төште. Сәбәбе зимагур Хәләфнең кемлеге белән бәйле икәнлеген авыл кызлары үзләре генә белделәр.

Тик бер Шәрифәгә генә кеше-кара кагынып сүз әйтмәде. Ни дисәң дә, бай кызы шул. Кемнеке диген әле? Корытай Хафизныкы, тирә-юньдә генә түгел, кала сәүдәгәрләре белән дә ярышкан, Казан байгуралары белән дә курыкмыйча эш йөрткән, серләренә кереп, сәясәт өлкәсендә дә ат уйнаклаткан, илдә үк булмаса да, татарда танылган шәхеснең кызы бит ул. Әле ничә еллар элек кенә Нижгурд каласына барып, олы сәүдә арасында, пароход яллатып, җыелыш корганнарында, Ука елгасының тирәнлеген бер калай этәч Казан шәкертенә үлчәткән иде. Аркылы төшеп карагыз сез аның юлына. Карурманнан чыгып, фаэтон тәртәсенә ябышкан чуашларның да маңгаена алтатар терәгән кеше бит ул. Нигә дип зимагур Хәләфтән йортындагы наз иясе гөлчәчәктәй кызы Шәрифә куркып торсын ди әле?

— Килеп, урамда күренә калса, телеңне күрсәт үзенә! — диде бит әтисе.— Йөзенә чуан чыксын! Атакай әйтә торган иде, дошманыңа тел күрсәт, йөзе бозылыр дип. Син дә шулай ит. Битен чуан бассын, мур кыргыры!..

Шәрифә — укымышлы кыз. Әтисе инде ничәләр ел рәттән, бер дә өзмичә, Казаннан мөгаллимә китертте. Җәгърафия, химия, әлҗабра фәннәре белән бергә хөсне хат, гарәп теле, лисане төрек, франса дәреслекләреннән күнекмәләр өйрәттерде. Зур сәүдәдән кайтып керер иде дә:

— Йә әле кызым, имтихан — фарыз кифаядер, нәрсәләргә өйрәндең? —

дип, дәштерер, мөгаллимәсе каршында барысын да сорар, белгәнен дә, белмәгәнен дә төпченер иде. Әгәр дә Шәрифә йөгерек тел белән сөйләсә, укып-язып та күрсәтте исә, и мактар, кала бүләген кулына тоттырыр иде. Ә киресенчә булса, Мөхәммәд галәйһис-сәламнеке төсле калын кара кашларын кылыч борыны өстенә җыерып китерер иде дә:

— Болай уңмасаң, сине Әнглатернга алып бармам, Лонданның манарасына алып менмәм,— дип орышыр иде.

Ул гына да түгел, соңыннан мөгаллимәсенә дә усал сүзләр әйтеп, күрше бүлмәдә тавыш чыгарыр, иртәгесен, гафу сорагандай, һәммәсенә дә, «колак ялы өчен» дигәндәй, берәр бүләк бирер иде. Укый-өйрәнә торгач, этисенең теленнән төшкән ул Әнглатерн, Лондан, манара хакында Шәрифә белеп, үз алдына көлеп тә йөрде: шулкадәр байлыгы була торып, җәгъърафия фәненнән хәбәрдар түгел икән бит атасы! Ул олуг манара, дөньяның сигезенче могҗизасы, бер дә Лонданда төзелмәгән, франсаларның Париж шәһәрендә шул!

Бу белемнәре Шәрифәне этисеннән өстен чыгарды, мөгаллимәсенең тәрбия сәгатьләре аңа рухи ирекнең нәрсә икәнлеген татырга мөмкинчелек бирде. Байлар арасында Хафиз дөрестән җәдитчә саналса да, күп мәсьәләләрдә, бигрәк тә хәл гыйлемендә, кадимчеләрдән һич тә калышмады. Моны да акрынлап төшенә башлады кызы. Аның өчен кызык иде. Әгәр дә берәр катлаулы мәсьәлә килеп чыкса, этисе:

— Казандагы Галәветдин бай бу хакта ничек уйлый икән, Аллаһы тәгалә боерса, бу барганымда төгәл белеп кайтам әле! — дип, зәңгәр каләм белән сызгалап, куен дәфтәренә язып та куя иде.

Ә Шәрифә бик яхшы белә. Әтисенең бу дәфтәрен кулына тотып караганы бар: анда нәрсә язылса, ул инде хәл ителә. Әле элгәре, моннан ике кыш элек: «Голландский әтәч ике тавык күкәе салды»,—дип язып куйганнан соң, шул ялгышына ничә тапкыр төртелеп, адәм хуры булган иде. Голландский әтәчләр күкәй дә сала икән дип сөйләп йөргән бит. Ә чынлыкта голланд әтәче белән яшәгән тавыкларының өлгерлеген һәм күкәй ташу тәртибен генә исәпкә алып барган җиреннән ялгыш язган булган. Кем белә, голланд әтәче дә татарныкыннан артык түгеллеген төшенгәч, мактану нияте белән юри шулай сөйләнеп йөргәндер? Телгә осталыкта аның белән ярышырлык кеше юк диләр бит!

Шулай итеп, затлы кыз Шәрифәнең генә, зимагур Хәләф кайтты дип, итәге кыскармады. Егетләр хакында уйларга аңа әле иртәрәк иде, аннан соң, төрек лисанында язылган руманнардагы егетләр булса икән ул, исең китәр иде.

## II

Ә Шәрифә, чынлыкта, зимагур Хәләфнең кем икәнлеген дә, төс-кыяфәтен дә белми иде. Шуның белән бәхетле булды. Үзенә гайбәт итеп кенә ишеттергәләделәр: ул, бәдбәхет, калада ихтилалчылар белән бик әшнә икән дә, ут чыгармакчылар, падишаһ галиҗәнапларына тел-теш тидермәкчеләр, ди. Авызына тәмәке капкач, ут чыгармый калмас инде, булыр-булыр...

Шәрифәнең иркен вакытлары, мөгаллимә апасы да, берничә көнгә ял сорап, калага китте. Яшь кызлар укый торган руманнар да китерермен, диде. Шәрифә бигрәк тә Гаяз Исхакыйны соратырга үтенде, соңгы араларда, менә өченче елы

диярлек, яңа чыккан китапларын алдыра алмый. Падишаһ аны бер дә яратмый, ди шул. Андый олуг әдипне дә үз итмәскә мөмкин микәнни соң? Бер дә укый белмиме әллә? Юк, араларын юри бутый торгандыр!

Шәрифә, тәрәзә янына килеп, чәчәкле-чуклы калын пәрдә артындагы томан кебек сыек ак челтәрләрне күтәрде, яшеллеккә төренгән тау сыртларында йөргән мал-туарны нокта-нокта булып сибелгән җирләреннән шәйләде. Якындарак балалар йөгерешеп уйный иде. Әмма мәш килүләренең чыр-чуы аңа ишетелмәде, аларга бик тә күңелсездер кебек тоелды үзенә.

Авыл балалары төсле гомергә дә шулай уйнап йөгергәне булмады Шәрифәнең. Кечкенә чагында бер катышып караган иде, кызык тапмыйча, кайтып китте. Шушы икенче каттагы бүлмәсенә күтәрелеп, кулына курчагын алды да, үсеп җиткәнче аның белән генә уйнады. Яшьтәшләре булган авыл кызлары һәм малайлары бик тә усаллар һәм дорфалар төсле тоелды. Соңыннан, инде китаплар укый башлагач, ул моның шулай икәнлегенә тулысынча инанды. Ә курчагын инде күптән түрдәге пыяла ишекле киштәгә утыртып куйды. Әле хәзер дә, кайвакыт, күңеле баласынып киткәндә, шул курчагын кулына ала да сөйләштерә башлый:

— Хәлең ни хәл? Җанкисәгем минем!

— Утырып ардым дисеңме?

— Апаңның эшләре күп, укыйсы, белем эстисе бар!

— Уйныйсым килә дисеңме?

— Әйдә, ярар, уйнап алыйк, алай булгач...

Әмма азга гына дип башлаган уены сәгатьләргә сузыла да, әнисе йә апасы күреп алып, орышалар үзен.

— Син инде курчак уены яшеннән чыккан! Әтиең белсә,— диләр,— безне орышыр, китабыңа утыр!

— Каладан кайтты дамыни?

Шәрифәнең тутырып караган кара матур күзләреннән оялып, алар чарасыздан башларын түбән ияләр. Ничек инде болай? Үзләре гел дөрес сөйләргә кушалар, ә үзләре ялганлыйлар?

— Дөресен әйтәбез! Әтиең ул шундый кеше, көтмәгәндә кайтып керә. Синнән имтихан тота башлый. Белмәсәң, көнеңне курчак кына уйнап уздыргансың, ди, карамыйсыз баланы дип, безне дә ачулана.

Шәрифә аларны аңлый, әмма авызын турсайтып, иреннәрен салындыра. Үпкәләгәндәй итә. Менә йөгерешә башлыйлар. Берсе кызыл прәннек китерә, икенчесе, китаплардагы рәсемнәрне күрсәтеп, берәр хикәя сөйли. Ә Шәрифә, астыртын гына көлеп, һаман да элеккечә үзалдына башын салындырып утыра бирә.

Кызык та чаклары булган икән. Инде хәзер үсте шул. Алай кылану бер дә килешми. Китаптагы кызлар шикелле нәзакәт иясе, пөхтә гүзәл бану дәрәҗәсенә омтыла ул. Ә андыйларга авыз турсайту һич тә килешми. Алар горур башларын бер дә салындырмыйлар. Үпкәләгәндә дә, читкә йөгереп, кешедән качып кына күзләреннән тамган энҗе яшьләрен кулъяулык читенә җыялар. Шәрифә дә хәзер шулай итә башлады. Беркөнне, мөгаллимә апасының дәресен төшенә алмыйча гаҗизләнгәч, үпкәләп, чаршау артына посты да еламакчы булып маташты. Тик нигәдер ул гүзәл бикәләрнеке төсле итеп күзләреннән яшьләре елгадай

акмады, бер тамчы гына килгән кебек булды да туктады. Ни гарьлек инде бу? Шулар кебек итеп елый да алмагач, ничек инде аларга тиңләшә алсын? Юк, үзләре шикелле һичшиксез булдыра белергә өйрәнергә кирәк! Калышалар димени? Бәлки сәбәбе бардыр? Нигә моңынчы башына да китереп карамаган? Ул руман кызларының сөйгән ярлары бар бит, шуларны яратулары сәбәпле, хисләреннән ташып елыйлар!

Шәрифәнең гомере гел ачышлардан гына тора, һаман да китаплар өйрәнүдән. Тукта, мәхәббәт, диде бит әле. Әйе, әйе, сөю сәгадәтенә тартыла аның күңеле.

Кинәт йөзләре балкып китүдән Шәрифә үзе дә оялып, челтәрне төшерде дә кулына китабын алды.

— Мәхәббәт!.. Әй мәхәббәт, мин бит синең нинди икәнлегеңне беләм! И Ходаем, миңа да Таһир-Зөһрәләрнең мәхәббәтен насыйп әйләсәң иде...

Шәрифә ялгышты. Болай ук ярамый иде. Аһ, ялгышты. Белми идемени ул Таһир-Зөһрәләрнең бәхетсез мәхәббәтен, укыганнары юк идемени Сәйфелмөлек-Бәдыйгыльҗамал, Йосыф-Зөләйха, тагын да күпмеләрнең гыйшык газапларын кичерүләре хакында? Бар иде, күп мәртәбәләр укыганы бар иде.

— Чын мәхәббәт булса, барча сынауларына да түзәр идем...

Андый олы мәхәббәтне кем әле гел шулай бәхетсез, газаплы гына дип әйткән? «Сөю — сәгадәт» дигәннәрен кая куясың?

Ә Шәрифә яратса — бары тик бәхете өчен генә яр сөячәк. Аның ул егете, бәгырен өзгәләрлек җанашы кала шәкерте кебек булыр, башына кәләпүшен кыңгыр салып йөрер, чәче бераз озын, җәдитчә кистерелгән, мыегы — кара, ыспай... Әй лә, шушы кадәр үк мөмкин димени? Ярар инде, борыны чак кына кәкрерәк булса да рөхсәт, тик төрекләрнеке кебек ямьсез, тукмактай рәвештәгесе генә туры килмәсен. Әнә «Мулла Насретдин» мәҗәлләсендә нинди хәшәрәт итеп ясыйлар үзләрен. Юк, андыйлары кирәкмәс. «Аң» журналында бик матур берәүне урнаштырганнар иде, менә шундыйрагы яхшы булыр!

Шәрифә кабат тәрәзә янына килде, келәләрен күтәреп, ачып ук җибәрде. Дөнья гөрләп тора иде. Тирә-якта дәртле кошлар сайрашалар, балалар чыр-чу килә. Ә һавасы да һавасы, өрфия кебек, битне сыпырып кына ала, ничек рәхәт! Әллә урамга чыгасымы икән, шәкертләр дә очрап борчырлык түгел.

III

Юраган юш килә ди бит. Югары очтан берәү бире таба атлый иде. Буйга озынчарак, какча йөзле, кара мыеклы бу кеше ни сәбәпледер тукталып калды һәм күтәрелеп карады. Шәрифәгә яшеренергә инде соң иде. Күзләре очрашты. Тәвәккәл һәм олы күзләре белән егет аны кочып кына алды. Кызның тәкате китте. Бер мәлгә йөрәге тибүдән тукталды, кайсыдыр җиреннән, күңеленең иң аргы почмагыннан нидер кубарылдымы, башы чайкалып китте. Моңа кадәр татымаган оят һәм курку хисе катыш дәрте кузгалып, бәгыре киселде. Тойгылары йөзенә бәреп, бит алмаларын кызартып чыгарды. Әгәр дә тәрәзә яңагына тотынып калмаган булса, Шәрифә артка китеп авасы иде. Егет тә тартылып куйды, гүяки шушы хәрәкәте белән аны бәладән коткарып калды. Алар йөзгә-йөз, ирengә-ирен очрашкан кебек булдылар.

Юк, юк, бу кадәрле ярамый, болай ук мөмкин түгел!

Шәрифә артка чигенде. Туры килеп, йомшак урын-җиргә утырды. Кулындагы китабын күкрәгенә кысты. Хисләрен яшерергә теләде. Ул арада янына кергән әнисе:

— Көпә-көндез урын-җир өстендә югалып утырасың! Нинди булмаган эш ди әле бу? Нинди әдәпсезлек,— дип сөйләнгәләп бүлмәдә йөренде.— Күзле энәне күрмәдеңме?.. Җиләнемне яңартырга тегүче Бибиәсма абыстай килгән. Кая куясыздыр шуны? — дигән җиреннән, эзләгән әйберсен табып, куана-куана чыгып китте. Шушы минутта бу йорт эчендә ничә җан иясе булса, һәркайсының үз хәсрәте белән яшәгән вакыты иде.

Әнисенең кирәкмәсне сизенүеннән курыккан Шәрифә хисләр тойгысыннан арынырга өлгерде. Төсе кайтты. Кызыллыгы качты. Әмма тәне буйлап кайнар тир йөгерде.

Инде тәрәзә пәрдәсе артына качып кына күзәтте Шәрифә. Егет чыннан да чибәр, бер кашык су белән йотарлык иде. Әйе, Казан шәкерте булырга кирәк. Өстендә карасу-зәңгәр батисттан тегелгән җәдитләр җиләне, башындагы кара кәләпүше бераз авышып тора. Ярабби, чәчләре дә заманча, румандагы каһарманнарныкы төсле итеп кистерелгән ләбаса! Мыегы да бар икән, килешле генә күренә. Ул бала белән нәрсә сөйләшә соң ул? Кесәсеннән чыгарып, әллә тагын кәнфит тә бирдеме? Шулайдыр, шулайдыр, Шәрифәне сораштыра torгандыр. Бу як кешесе түгелдер. Казаннандыр! Болай ук оста кыланмас иде. Ә-ә... Белде! Китап сатучы булырга кирәк, үтеп барышлый тукталгандыр. Мәдрәсәдән дә шәкертләрне чыккан, таралышкан дигәннәр иде. Шунда фатир төшкәндер. Юкса югары очтан бире таба килмәс иде. Нәкъ үзе! Ул пөхтәлек, хәрәкәтләрендәге тәртип, елмаюларындагы затлылык! Ай, бәгырем, һәй-һәй генә... Мондый егет солтанына унбиш кыз гыйшык тотадыр әле. Әтисе дә берәр кадим сәүдәгәрдер. Үзе йөреп мал җыйсын дип, улын шушы ерак сәфәренә куып чыгаргандыр. И бәгырь, тамаклары да ачыккандыр инде, бичаракай...

Мәхәббәтнең беренче очкыны чәчрәп китүдән Шәрифәнең теле акылын алмаштырды, ни сөйләсә, шуны дөрес дип белде, нәрсә уйласа, аны пышылдап кабатлады. И бала, болай ук бер күрүдән егет таба алгач һәм аңа гыйшык та тота башлагач, бәхетләрең булыр да булыр инде үзеңнең!

## IV

Кичкә Шәрифәнең кулына бер хат килеп иреште. Аны китергән кыз — күрше Сәгыйдә җиңгинең зәңгәр күзле сөеклесе иде. Ул кайвакыт шулай кергәләп йөри, Шәрифә апасыннан китаплар укытып, хикәяләр тыңлый, хәтта өлкәннәрдән яшереп кенә икесе бергә курчак та уйный иделәр. Хуҗалар моны белсәләр дә, күрмәмешкә салынып, аларны бүлдерми иделәр. Бигрәк тә әнисе инде, кызы Шәрифәнең буй җитеп килгәне белән килешергә теләми, баласытып карый иде. Чынлыкта кызы үзе дә, балигълык яшенә ирешеп, хәзер зур булып килгәнен сизмәде. Моңа кадәр шулай иде.

— И бала, алай ук ярый димени? Тәмам куркытып бетергәнбез икән, әтиең дә артыгын сораштырып аптыратмасын, әйтеп куярмын. Чәй эчеп алырсың, ял итмичә ярамас...

Асрауны чакырып, тиз генә өстәл ясап, чәй хәстәрен күрергә, бүлмәләрнең һавасын алыштырырга боерды. Шәрифә, бер әйткән сүзеннән кире кайтып, аның өчен аталган бу хезмәтләреннән баш тарта алмый иде инде.

V

Корытай Хафиз кайтып керүгә, бөтен дөнья берьюлы хәрәкәткә килә. Моңа кадәр итәк иләп йөргән хезмәтчеләр, тиз ара үзләренә шөгыль табып, җан-фәрманга эшкә тотыналар, һәммәсе дә үзләренең өлгерлек һәм тырышлыкларын күрсәтергә ашыгалар. Мәхшәр купкан диярсең. Бары тик олы кикрикле голланд әтәче генә, нәселдән килгән горурлыкны саклап, ишегалды уртасына чыгып баса да, кукраеп тавыш сала. Әллә шушы рәвешле хуҗасын сәламли, әллә инде аның белән ярышырга теләп уртага чакыра, һәрвакыт шулай кылана.

Аяк астына очраган һәммә кош-корт Хафиздан биш-алты адым читкә очарга мөмкин, әмма дә әтәчкә тидем юк. Мактанычы һәм куанычына әверелгән бу асыл кош гүяки аның үзе иде төсле, һәрхәлдә шул: йорт арасында эшләүчеләр аны бары тик хуҗа белән генә тиңлиләр, җае чыкканда, кеше-кара күзеннән яшереп кенә үзеннән байның үчен алырга да күп уйлап тормыйлар, әмма да әтәчнең тавышка шәплеге, кимсенүгә бер дә ризалык бирмәве аларны куркыта. Хәтта болай дип әйтәләр: имеш, бай абзый бу әтәченең койрыгында ничә канат-каурый барлыгын да төгәл белә икән, телен дә аңлый! Әмма алай ук түгелдер инде! Булмаганны. Сөләйман пәйгамбәрмени ул, кош-корт телен белештерергә?

Бу юлы Корытай Хафиз һәм дә канәгатьсезлек, һәм дә усаллык белән җенләнеп кайтты. Сәбәбен бары тик Шәрифәнең әнкәсе Фагыйлә абыстай гына сорап белергә мөмкин иде дә, иренең коры авыздан чыккан ике сүзеннән аның да соравы тамагына утырып калды.

— Абау, атасы, нәрсә кылануың бу? — дип әйтергә тиеш иде дә, тәкатен табарга өлгерде. Үз җаена яшәп яткан тыныч көннәренең көтмәгәндә тузаны күтәреләсе иде юкса.

Ашап-эчкәч кенә Корытай Хафиз бераз тынычлана төште. Әүвәле пәрәмәч белән кайнар шулпадан тәм тапты, аннары өстәлгә токмачлы аш белән тавык китерделәр, анысыннан да канәгатьлек иткәч, бәлеш башлап, яртысына якын өлешен ашады, вак бәлеш һәм таба коймагы белән чәй эчте, каймак, май һәм балны чамадан тыш куллanудан эче катып киткәндәй булды, киерелеп куйды, тәмам бүселеп, кәнәфигә килеп утырды һәм тагын да сорады:

— Кая, хатын, сөзмә китерсеннәр әле, әйт аларга!— дип кикерде.

— Син нәрсә инде, атасы, тәртипсезләнәсең,— дигән сүзенә ияртеп, Фагыйлә абыстай тиз арада хәбәр салды: — Абзагызга сөзмә китерегез!..

— Алай димә әле син, Фагыйлә, кикерү — Аллаһы тәгаләгә шөкер-хәмде дигәннәр борынгылар. Калада да, Садри Максудовлар янында чак тыелып калам, анда — яхшы түгел, ә монда — килешеп тора. Әткәм мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, бер кикергәндә җитмеш дию пәриенең тамагына сөяк тыгыла дия торган иде, бездән генә калмасын. Сөзмәне әллә күрше авылдан әйләндереп китерәләр инде? Әйт әле үзләренә...

Бу сүзе җитә калды, асрау, битен ак яулыгы белән өрпәгән хәлдә йөгертеп кенә килеп тә җитте, нәзек һәм йомшак кулында утырган чокырны бай абзасы-

на сузды. Аның бу рәвештә күренүенә үк Казан ханәләрендә хатыннар белән шаяргаларга бер дә каршылыгы булмаган Хафизның дәрте кузгалды. «Кол кызлары илә уйнауны пәйгамбәрләр дә ят итмәгәннәр әле...» — диярәк ниятләнеп, җай чамаларга кирәклеген фикеренә киртләп куйды. Әмма бу уйлары: «Алла сакласын, җен баласыдыр бу, котыртып йөри»,— дип, «Әгузе бисмиллаһ...» белән тәмамланды.

Сөзмәдән Хафиз байның ашказаны тегермән ташыдай эшли башлады, әмма юлда шактый араларны йоклап кайтуы сәбәпле, күзләре эленергә уйламый иделәр булса кирәк. Ятып аласы итмәде. Кәнәфидә аяк бөкләп утырган хәлдә:

— Анасы, кызыбыз кая соң? Бар, чакыр әле бире! — дип әмер бирде.

Әмма Фагыйлә абыстай:

— Атасы, калдырып тор баланы, синең канәгатьлегең өчен артыгын тырышып укыган булырга кирәк, арыбрак киткән,— дигәч:

— Ярар, ярар, анасы... Бала торып торсын,— дип, күтелмәгән җирдән килешеп тә куйды. Авыл хәлләрен сораштырырга керешә һәм: — Теге зимагур нигә әле безнең капка төбендә чуала? Ут-күздән Аллаһ сакласын! Әйткәннәр иде аны, калада бик тә кызылланып йөри, дип. Чыбыркылап кудырдым әле үзен!— диде.

— Аңа ни калган икән инде монда?

— Әйтәм бит, яманлык белән йөри ул, яманлык, белән. Кеше алдында оят. Аның хакында сүз чыккач та, безнең авылдан дип әйтергә телем бармады. Урысча киенеп, башына картуз сылап йөри ди. Ни галәмәт чәчен үстергән. Зимагур да зимагур, Хәләф тә зимагур инде менә... Аллаһ сакласын, андыйлар белән бер очрашсаң, икенче тапкыр күрәсең килмәс!

— Чыбыркы белән кудыртып дөрес эшләмәгәнсең, атасы, котыртып дип әйтүем...

— Син әле, Фагыйлә,— Хафиз бай йомшарган җиреннән кинәт кызып китте,— өйрәтеп утырган булма чүпрәк башың белән. Монда, үз авылым уртасында шул мескен зимагурдан куркып торырга кем дип белдең әле мине... Базар көнне Земской управага кереп, мин аны кулга алдыртырга да күп сорамамын.

Җилкәсенә уңлы-суллы болгап диярлек чапанын элгән Хафиз бай ишектән чыгып ук китте. Казан хәлләрен сораштырырга сүз җае килгәненә өметтә булган Фагыйлә абыстайның да, үпкә-бавыры урыныннан кузгалып, иренең бу рәвешле пырдымсызлануына кәефе кырылырга өлгерде. «Иркәләп бер сүз дә әйтмәде бит, юньсез!» — дип уйларга кодрәтеннән килмәде, әмма дә:

— Ризыгыгыз тәмсез пешкән, исраф итүдән артыгын белмисез, бай абзагыз ачуланды,— дип, тик-томалга барысын да орышырга тотынды. Бушап калган өстәлнең йорт хезмәтчеләренә бүтәнчә сөйләгәнен башына кертеп тә карарга теләмәде.

Бу көнне дә Шәрифә кичкә кадәр үз эшләре һәм хисләре белән мәш килде, аны борчырга җөрьәт итәрлек һичкем табылмады. Ирен сагынудан тәкате киткән әнкәсе исә бары тик үз буй-сыны, киеме-чибәрлеге өчен җан атты.

## VI

Икенче көндә булган вакыйгаларның бернинди дә әһәмияте юк иде. Гүяки

Шәрифәнең бәхете тәмам сүнеп, күгендә әрсез кара кургашын болытлар гына калды. Уң вә сулы буталды. Мондый чакта киңәшергә мөгаллимә апасы да янында түгел ичмасам. Бу кадәр дә чибәрлек һәм инсаф иясе кызга күкләр үзләренең мәрхәмәтен юлламаса, дөньялыкның дөреслеге бетеп, хакыйкать тәлинкәсе ватылырга гына тиеш бит!

Әмма Аллаһы тәгаләнең хөкеме бар нәрсәләрдән дә алда йөрде. Икенче кәррә язылган асыл эчтәлектәге хат Шәрифәнең күңеле күгендә кояшны балкытты. Анда ошбу юллардан гайре һичнәрсә булмаса да, зиһене камил вә тәрбия иясенә җитәрлек иде:

*«Гыйззәт сахибе Шәрифә туташ!*

*Барча гүзәллекне Сезнең йөзеңездә күргән без фәкыйрегез өмет вә интизар белән күп хәсрәттәмез ки, әгәрем дә бу кичәдә Сезне капуыңыз төбендә очратмасак, Аллаһы тәгалә рәхим-шәфкатен кылсын иде генә диеп теләремездә каламыз! Сәгадәт дулкынларында йөреткән нәфсемез корабы Сез ки гүзәллек иясе кемсәнәнең янына килеп җитәрлек хәлендә түгелдер. Әгәрем атаңыз кебек олуг зат безнең барлыгымызны инкарьлек белән чит-ят кыла күрмәсә иде, алдыңызга кереп, аяк бөкләп, кулыңызга бер кагылып үтүне мәртәбә санар идек...»*

Хатның ахыры укый алмаслык хәрефләр белән чуарланган иде. Шул да җитә калды, Шәрифәнең күңелендә әллә нинди билгесез хисләр өермәсен кузгатып җибәрде. Асылда алар һичбер хәбәр бирерлек язмалар булмыйча, бары тик сурәткә һәм рәсем ишегә охшаш нииндидер хәрәкәтләр белән генә бизәлгән иделәр.

Әмма Шәрифә җанашның күңеле алардан билгесез гыйлем вә серләрне эзләде, чөнки хатта кирәгеннән артык тәэсирле сүзләр табылырга тиешлеген көтте. Җитешмәгәнен хыялы тутырды һәм башына әллә нинди уйлар килеп, бәхетен арттырды.

Бу вакытта хат сахибе егет кемсәнә, мәдрәсәдә әлегә торып калган шәкертләр янына кич утырырга барып, арада сүз кузгаткан, хәтта кесәсеннән уен картасы чыгарып өләшкән һәм дөньясын онытырга өлгергән иде. Отыш хәсрәте белән мавыгып, әзмәвер шәкертләр, моңа кадәр бер-бер авылдан сабанчы агай киләр дә үзләрен муллалыкка дәгъва кылыр дип, тәрәзә төбеннән китмәгән җирләреннән кузгалып, мәдрәсә почмагында өелгән кат-кат мендәр өстен җай вә рәхәтлек өчен кулайрак күрделәр. Алардан боларны күпсенергә мөмкин булган хәлфәләре исә Корытай Хафизның йортында аш һәм сыйдан хөрмәт табуы сәбәпле, болар яшьтән укылган һәртөрле китап хикмәтләрендәге кебек үзләрен сәгадәт чүлмәгендә төсле хис иттеләр. Кичне уздырып, төнгә кадәр даулаштылар, карта уены арасында үзләренең чыннан да сыртларын каезлаган ишан-мулла ыругының нәсел-нәсәбен эт иттеләр. Бәхетләре дә шуның белән арткандай тоелды. Әмма күз шәрифләре ачык булудан тыш, күңел һәм зиһеннәре дә камиллеккә ирешергә җитешмәүлек сәбәпле, алар һаман да сурә белән аять арасында буталган ахмак кыяфәтләреннән чыга алмадылар. Дөрес, бары тик Сираҗи мәхдүм генә уенга катнашы юк кеше шикелле «Гыйльме хәят вә кәүсәре

хас» исеме илә кулъязма хәлендә таралыш тапкан бер дәфтәрдән әллә нинди сәер хәлләр табып куанды. Атасы мәрхүм булып та, муллалыкны кулына алырга өлгерми калды, авыллары өчен ул артык дип табылды. Анда кире кайту өчен юлы бикләнгән иде. Сәбәбе бары тик атасында дип уйласа да, ялгышты ул, бик ялгышты. Авылларының умыртка баганасы булган Кәрим байның чокырга аударылуыннан соң, барчаларны үзләренә буйсындырырга өлгергән ат карагы чуашлар,— бәлки, алар чынлыкта чуашлар булмыйча, мишәр таифәсеннән азган кавемнәрдер, монысы ук вакыйгаларны сөйләүчедән ачык беленмәде,— җайларына кимчелек китермәслек зат — Сәрдәлек Янгир-Хафисә исеме белән дан алган берәүне хөтбәче иттеләр. Падишаһ хәзрәтләре бу Сираҗи мәхдүмнең авылы башына кара хачи агачы, ягъни кара багана утырттырганнан бирле аннан хәбәр болайга таба чыкмый, аларга таба хат-мәктүп ирешми иде. Инде ике ел дәвамында бер-бер өмет белән гомерен мәдрәсә эчендә мөгаллимлеккә өйрәнүче пишкадәм рәвешендә уздырып та, җае килмәгәнлектән һәртөрле әсәрләр аша гыйлем хәсрәтендә калган акыл иясенең үпкә авыруыннан һәм күңеле бозылудан тешләре коела башлап, борын астына җебек төшәргә өлгерде. Хәзрәтләре белде, Сираҗига зәхмәт кагылган, имештер. Бозау тизәге белән йөзен уып, күкрәгенә арыш боламыгы сыламаганда, барыбер файда тимәс, сырхавы куәтләнә генә барыр, диде.

Әмма мәхдүмнең күңеле яшәү һәм тәрәккыять тели иде. Бохарада барча галимнәрне «бер тишеккә тыккан» Курсави хәзрәтләренең китапларына таянып эш йөртергә уйлаган замана баласы ниятләрен һәрвакыт шулай зурдан кора шул. Тәһарәте бозылуына игътибар итмәстән намазын ташламаган мәхдүмне иптәшләре дә чит-ят кыла башласа, эшләре яхшылык белән бетмәячәк иде. Шулай да Сираҗи мәхдүм үз җаен үзе белеп, быелгысы җәйдә кыргый башкорт һәм кыргыз далаларына юнәлергә сәрмая туплауга керешкәч, аннан аерылуны бәла кебек авыр бер газап күргән өлкән яшьтәге әзмәвер шәкертләр моны мөмкин кадәр хәер-садакадан баш тартырга өнди башладылар. Тик шуны гына берсе дә белмәде: иртәгә, таң әтәчләре кычкырып, мәсҗедтә намаз укылу белән юлга чыгачак сәүдә кәрваны Сираҗины бу мәдрәсәдән читкә алып китәчәк иде. Менә шунлыктан ул әлегә халыкка фаш ителмәгән могҗизалы китапларга соңгы вакытларда игътибар күзен салды, күңелен баглады. Кыргый башкорт вә кыргыз даирәсендә мондый хәбәрләр гаять тә кирәк булачак әле аңа.

## VII

Корытай Хафизлар йортында мәҗлес таңгача сузылды. Шәрифә бу арада биш ятып, алты торды. Атасының да, муллаларның да телендә зимагур Хәләф иде. Өч мәхәлләне бер итеп йөргән Хафиз байның маен кайнатса, бары тик шушы мәлгунь Хәләф кенә кайнатадыр, мөгаен? Юкса барысы бердәй аны эттән алып эткә ташламас, авызларын пычратып газап чикмәс иде.

Зимагур Хәләфнең бәхете шушы сүзләрдән, мәгәрем ки, арта калса, аннан да бай һәм горур зат дөнья йөзендә яшәмәс вә яшәргә дә мөмкин түгел иде. Аййай да ямьсез кеше икән үзе. Әле кичә генә югары очта исерек баштан теләсә нәрсәләр әйткәләп йөргән, имеш тә, сукыр Гайшәгә бәйләнгән, ди.

— Авылдан кудыртырга кирәк аны!

Корытай Хафиз сүзне шушы рәвешле коры тотканлыктан, берара әңгәмәгә катышмый утырган Кәримулла мәзин дә фикерен белдереп кенә авызын ачты:

— Ярамастыр, җәмәгать...

Мәҗлестәшләрнең күңеленә хуш килергә мөмкин булмаган бу кәлимәнең урынсыз икәнлеген акылындагы һәркем төшенергә өлгергәнче, Шәрифәнең әткәсе:

— Әллә, кем, ни түгелме... Атаң баласы...— дип, уңлы-суллы әйтеп куюга, һәммәсе бер авыздан диярлек хахылдадылар. Бу көлүләренең асылы, әлбәттә, бар иде. Ярлы-ябагайдан адәм рәтенә керә башлаган мәзиннең буын туганы булган зимагур Хәләф аңа якын иде. Чукынсын дөньясы дип, ни очраса, шуны чукындырып йөргән урыс динчеләре белән, йөзгә-йөз килеп, орышларда катнашкан, каладагы театр һәм кәмит төсле заманча эшләрдән яхшы хәбәрдарлыгы булган Корытай Хафиз, мәсьәләне тиз ара сәясәткә борып җибәреп, үзенә кирәкчә сүз туглату җаен бу очракта да тиз тапты:

— Син, кара әле, Кәримулла, ни дип әйтим, мәхдүм сүзе сиңа килешмәс инде.— Аның бу сөйләгәненнән мыскыллаудан бигрәк, мулла нәселеннән килгән имамнарны зурлау, үз ягына тагын ныграк аудару теләге дә барлыгы сизенгән кешегә бер дә яшерен түгел иде. Аллаһ сакласын, бу Кәримулланы акылга куәтле, холыкка сабыр дип әйтәләр, кеше алдында да сөекле, юкса бөтен теләк-моратларны бозып ташлавы бар.— Алай ук, якының дигәч тә, дөрес булмас. Хатын ягыннан кардәшлекне пәйгамбәребез дә югары куймаган. Ташла. Зимагур кем дә, син кем! Аллаһыга шөкер, быелгы зәкяткә үзегезгә бер тай бирербез. Шулайрак уйлап тора идек,— дип өстәмәсенме.

Бетте Кәримулла мәзин, арт аяклары белән чалынды, сүзеннән кире кайту ягын карады. Ирләрдә сер торса, хатыннар гайбәтчегә чыкмас иде.

Мәҗлеснең ахырында майда гына пешкән бәлеш төбе тамакларын кикертә башлап, күрше яктагы абыстайлары да кайту вакыты җиткәнлеген төшенергә өлгерделәр.

Икенче көнне таралып, монда сөйләнгән сүзләрдән сер буларак килеп ирешкән хәбәр шул иде: кичен кайтканда Кәримулла мәзиннең абыстае, иренә таяк башы белән төрткәләп, аның умыртка сөяген зәгыйфьләндергән, ди, мескен, иртәнге намазда, сәҗдәгә киткән җиреннән артык аваз чыгарып, тәһарәтен сындырган икән. Имеш, тагын да шул, Кәримулланы мәзинлектән төшереп, мәдрәсәдә җәй уздыручы адашкан башкорт малае Алатайны,— Аллаһы тае дигән исемдер инде,— аның урынына күтәрмәкчеләр бугай дигәннәр иде, дәрес ирешелгән сүз булмады, ахрысы. Шулай да Кәримулла мәзиннең көтелмәгәндә хасталануы халыкны борчуга салган. Өшкерү-төкерү галәмәтләренең хикмәте бар икәнлегенә чын күңелдән ышанган ярлы-ябагайның күңеленә хуш килгән, балаларына үрнәк саналган кешенең болай адәм рәтеннән чыгуы авылдагы көнкүрешнең тәртибен бозарга мөмкинлеген сизенгән байлар, ике көн рәттән, үзен һәм абыстаен ашка чакырып, шактый сыйлагач кына сихәтен тапты Аллаһ бәндәсе. Әмма күз карашында мәкер һәм ышанычсызлык галәмәтләре калганлыгын Корытай Хафиз өченче күзе белән сизенә иде булса кирәк, зимагур Хәләфне бөтенләй дә хисаптан калдыргандай кыланды, мәҗлесләрдә телгә алмаска булды. Шулай итеп, әүвәле һич сәбәпсез яманаты таралган егетне һәммәсе дә күңеллә-

реннән җиңел генә чыгарып ташлагандай иттеләр. Әмма бу хәл вакытлы гына иде. Ул һаман да шулай инде, әгәр дә олуг давыл ише нәмәрсә булырга җыена икән, дөньялар тәмам тынычланып калгандай тоела, шом җиргә сеңеп тора.

VIII

Зимагур Хәләфнең шәкертләр белән карта уены ясауларын авыл белмәмешкә салынды. Нинди хәл ди ул, булмаганны! Аны сөйләргә, кешегә әйтергә ярый димени? Гайбәттән Аллаһ сакласын. Кыш буе Коръән ятлаган, шәригатьне гарәпнең үзеннән дә яхшы белгән әзмәвер шәкертләр, читек кунычыннан чыгарып, карта уйнасын, имеш, авылдан бәрәкәт качар. Юк, юк! Алар болай гына, «санлы» кебек нәмәрсә белән мәшгульләрдер...

Аңламассың бу «авыл» дигәннәрен. Кайсы яклары белән йокларга яталар икән? Калада мондый хәл ишетелсә, ул шәкертләрне управага чакыртып, зиндан чокырының тирәнлеген үлчәтерләр иде дә бит, болар алай түгел, булганны да күрмәмешкә салынып, юкны бар кебек сөйләргә генә осталар. Авылның барча бәласе һич тә күзе сукырлыкта түгел, фикере томаналыкта. Әгәр дә халыкны артка калдырыйм дисәң, авылларга ку инде аларны, шәһәрнең капкасыннан да кертмә. Әле дә ярый зимагур Хәләфнең карта уены коткысы озакка бармады, бер хәйлә генә булып чыкты. Үзара шактый дуслашып алгач, бу очрашулар бөтенләй бүтән юнәлеш алып киттеләр. Казанда Учительская школада ике еллап укыган җиреннән алдырылган, «Әл-Ислах» кәмитите белән якыннан белешлек иткән зимагур сасый ук башлаган шәкертләрнең күңелләренә беренче орлыкны сипте:

— Һай, егетләр, безне «Ачлык падишаһ» газапларга сала бит!

Бу сүзне ишеткән башкорт шәкерте:

— Ә-ә, нугай ата, бәнем бәрәңге кабартмам калган ие, бирәемме-е...— дип аваз салгач, Хәләфнең йөзенә горурлык йөгерде. Шәкертләрнең сәкесендә сузылып, кулларын шәригатькә хилаф рәвештә баш артына кыстырып яткан хәлендә:

— Да-а, егетләр, сезнең эшләр хөрти икән!— дип, бик тә хикмәтле гыйбарә әйтеп ташлады.

Мескеннәргә җитә калды. Елына йөздән артык шәкертне асраган авыл аларның күз алдында тиз арада аклы-каралыга әверелде дә куйды. Хәләф киткәч тә «Диваны хикмәт»тән, «Бакырган китабы», «Хәмде-би-хәд» кебек әсәрләрдән күңелләрендә калган бәетләрне телләренә алып, зимагурның сүзләренә күп дәлилләр таптылар. Башкорт шәкерте Алатайның: «Бу нугай әкәнең әйткәннәре падишаһ хәзрәтләренә инкарь итү булырга кирәк!» — дигәннәре дә юкка чыгарылды. Чөнки «Ачлык падишаһ» гыйбарәсеннән патша галиҗәнапләре дә үзләре кебек үк ачыга икән кебек аңлашылды. Бу исә шәкертләрнең акыллары зәгыйфь хәлдән түгел, киресенчә, фәндә-гыйлемдә, мантыйк һәм шигырьдә маһирлыкларыннан килә иде. Шулай да җитлегергә өлгермәгән балаларга белем орлыкларын артыгы белән сибәргә ярамый шул, бигрәк диваналанып китәләр, яшьләре егермедән узганда да үзләрен сабыйлыкта кебек хис итәләр! Юк, юк, әфәнделәр, балага үзенең үскәнен, зурайганын һәрдаим белдереп-әйтеп тормасаң, ул аны, җитлегүен, ачык төшенеп бетерә алмый икән!

Хәләфнең авыл халкы каршында хөрмәте юк түгел иде. Инде дә килеп, шәкертләр белән якыннан аралашуы аның затына карата кадерне үстерә төште. Төс-биткә күркәмлеге, буй-сынының затлылыгы һәм, боларга өстәп, тагын да, калада укулары, Ямаш Хөсәененә кардәш тиешле булулары — болар барысы да егетнең абруе өчен хезмәт иттеләр. Әгәр дә моңа кадәр Корытай Хафиз белән телгә килмәгән, Казанда аның каршына чыгып, үзенә ияргән яшьләргә: «Безнең авылның сорыкортын күрәсезме?» — дип көләргә вә, мыскыллап, бәрәнге чүбе ыргытырга өндәмәгән булса, зимагур исемен дә алмас иде. Әмма нәрсә эшлисең, үткән хәлләрне кире кайтарып төзәтү мөмкин түгел шул.

Шәкертләр ягына килеп йөргәләве һәр ике як өчен дә бары тик файдалы гына булганлыктан, әле таралышырга җыенмаган бу китап кортларының боткалары пешә, борчаклары яхшы бүртә бирде. Хәләф зимагурның калада Тукаев, Камал, Әмирханнар белән күрешеп сөйләшкәнлекләре дә ачылгач, җәдит мәктәбенең тәрәккыять хезмәтендә китергән җимешләре саналган, шулай да мөгаллимлектән муллалыкны өстенрәк күргән бу дин хадимнәренең күзләрендә соклану очкыннары чәчрәми калмады. «Тәрҗеман»нан узган, «Вакыт» һәм «Шура»ларны актарган, үзләре дә бер-ике шигырь һәм бәет, мәкалә бастырырга өлгергәннәре өчен Хәләфнең кадере бер-ике хикәягә җитәрлек иде. Идел аръягына адашып чыккан башкорт шәкерте:

— Ай нугай әкә, ул Тукаев дигәннәре бигрәк тә моңлы бәндә инде, кул сузсаң, буй җитми торган адәмдер ул, ә? — дип тел шартлатуы шәригать гыйлемен күргән шәкертләрне сагайта калды. Моңа кадәр үзеннән: «Ул башкорт дигәннәре нинди халык соң?» — дип сораганда, шыпырт кына җырлап, әллә нинди яшел дала һәм бозлы кыр-урманнар хакында сөйләүләре җитмәгән, инде дә тел шартлатсын имеш, зобани...

Әмма зимагур Хәләф өчен бу башкорт баласының тел шартлатуы шәригатькә хилаф кебек тоелмады, бәлки соклану билгесе рәвешендә аңлашылды. Биргән хәбәреннән шәкертләр бик тә канәгатьсез калдылар. Кайберләре хәтта:

— Ишеткән бар иде аны, Җәләлетдин мәхдүмгә тартымлыгын, хак икән,— дип куйдылар. Ташмөхәммәднең шул ук Фатих Әмирхан булуы, мескеннең ике аягы да богауланып зәхмәтләнүе, Камал әфәнденең, мөфти дәрәҗәсе алырлык җиреннән, дин китаплары язып та, инде хәзер сурәт төшерү гамәле илә мәшгульлеге һәм тагын әллә нинди хәбәрләр авыл мәдрәсәсенең иңә төшкән түшәмен гүяки каерып ташлап, диварларын аударгандай иттеләр. Тик бу тоем һәм кичерешләр артыкка бармыйча, Хәләфнең тормыш хакындагы дәресләре башланып китүгә, дивар вә түшәмнәр яңадан урыннарына утырып, шәкертләрне һәрьяклап кысарга җыенгандай иде.

Берничә кичәдән соң болар барысы бергә яки Урал шахталарына, яисә Баку тарафына чыгып китәргә, яңача тормыш корырга дәртләндерелгәннәр иде. Хәләф аларга юл күрсәтеп баручы җитәкче ителергә тиеш исә дә, әле тәкъдиреннән ни киләсен башына да китерми иде.

Менә, сабан-сука бетсен, инде дә сабантуйлар узсын, печәнне дә бетерик дип суза-суза, ярты җәйнең узганын да сизми калдылар. Шәкертләр һәммәсе диярлек үз авылларына таралышкан, әмма мәдрәсәдә торып калган дүрт ятим татар баласы һәм башкорт асылы Алатай алар белән һәрдаим диярлек хат-хәбәр

алышуны туктатмый иделәр. Болар, хәтта, юллык акча юнәтү нияте белән, Хәләфнең өйрәтүенчә, Корытай Хафизның кибетеннән көтәчәккә вак-төяк товар алып, ерак авылларга да баргалап килделәр. Бары тик керемнәре генә ихтыяҗ һәм бурычларын капларга китә бирде. Юлга чыгарлык җай табылмады. Нугай әкә каршында абруй казанырга җыенган Алатай бигрәк тә зур тырышлыклар куеп маташты, әмма аның хәлләре дә әллә ни мактанырлык түгел иде. Ниятләнгән эш, вакытында башланмыйча, озакка сузылуы һәм соңгырак вакытларга калдырылуы сәбәпле, көн кадагыннан төшә биреп, киләсе елга аталырга да бик мөмкин иде. Гүяки моның шулай буласын белдереп, Хәләфнең күңеленә бүтән бер корт төште. Җанның серләрен һәм мәхәббәтнең нәрсә икәнлеген аңлаган кешеләр моның мәгънәсенә төшенер, әлбәттә.

IX

Йөрәкләр кайнар булса, көннәрнең суыклыгы, елларның авырлыгы сизелми диләр бит. Хәләф белән дә шулайрак килеп чыкты. Күңел түрендәге изге хисләре көннән-көн тернәкләнә барып, тиздән җимеш бакчасы кебек өлгереп җитәчәк тә иде. Әмма берничә көн рәттән язган хатлары җавапсыз калгач, арада хәбәрче ролен үтәгән гүзәл кыз балага өч бакыр акчасы сарыф ителгәч, инде бүтәнчә җае калмаганлыгын аңлаган хәлдә Хәләф үзенең хисләреннән баш тартырга тиеш иде. Сизенмичә калды, аның белән язмыш уйнады. Дөресрәге, изге хисләренә чиртеп, кыз шаяртты. Үз башына буласын белмичә һәм аңлап җиткермичә шулай эшләде ул. Шаяртты, шаяртты да, килеп капты: егеттән аңа ай буена бер генә мәктүп тә килеп ирешмәде. Адәм көлкесе. Онытты, ахрысы, Шәрифәнең барлыгын, башканы тапты...

Һәм ул шулай буласы да иде, әгәр бу кичәдә кыз, уйланмаган җирдән күтәрелеп, иңнәренә зәңгәр чиләк-көянтәсен асып, Шәех чишмәсенә суга дип төшмәсә. Егет тә, күңеле боекканнан җанына ямь таба алмыйча, Аллаһы тәгалә кушып, урам әйләнеп узган җиреннән аны күреп алды, үз-үзен онытып, тал агачы төбенә килеп сөялде, елмаеп кына сүз катты. Ил күзенә бу кадәр үк күренмәсә дә ярар иде. Күрәчәгедер инде, күрәчәге. Кайда егыласыңны белсәң, салам җәяр идең, диләрме? Хак сүз икән! Ә шулай да юкка борчылырга кирәкмәс. Егет белән кыз очраган җирдә сандугач та җырсыз кала алмый шул. Шәрифәнең әллә көянтәсенә үк кунып сайрадымы? Алай ук түгел дип әйтергә кыймыйм, әмма ике пар йөрәкнең мизгел эчендә тигез һәм бертөрле итеп тибрәнеп куюы дөньяларның астын-өскә китерде. Күк капусының бикле җиреннән келәләре бушадымы, әллә бәндәләргә дә вакыт-вакыт бәхетле мизгелләр бүләк кылынадырмы, күктән кояш төшеп, агар сулар һавага чөелде, чишмәләр кире улакларына агып менде, шиңгән чәчәк, тергезелеп, сөенечкә төренде. Шушы минутның сәгадәтен күреп калу һәм тояр өчен кайберәүләр гомерләре буе тырышлык куймыйлармыни? Мондый мизгелләр һәркем тормышында булса да, күпләр аны урап узалар, сизенмичә калалар, гүяки яшәмәгән дә кебек булып, дөнья йөзеннән китеп баралар. Эһ, тормышлар диген, башкасы хакында сүз юк инде, анысы.

Егет белән кызның бу очрашулары моңа кадәр пыскып кына маташкан мәхәббәт учакларын тергезеп үк җибәрде. Тәкъдирдән килгән бәхет булуы сәбәпледер, күзләренең үзара якынаюыннан хисләр чакмасы чәчрәп китте. Шәрифә-

нең калтыраулы тавышы һәм әллә ни ачык ишетелмәгән сүзләре йөрәк шаукымыннан хәбәр иде. Моны егет тә аңлады.

— Абый, дим, юлымны кисмә инде, берүк?..

— Мин угры түгелдермен, җанаш. Алар гына юл кисәләр.

Хәләфнең сүзләре Шәрифәгә көлү кебек аңлашылган идеме, әллә кыз каушаудан шулай сөйләндеме, бер дә теләгәненчә килеп чыкмады. Ул укыган руманнарда болай түгел иде бит!

— Абый, көлмәгез инде миннән...

Көләме соң, нинди көлү ди ул? Киресенчә, аның аяк асларына ак җәймә булып җәелергә риза егетебез.

Битен капларга кирәклеген Шәрифә әле яңа гына искәреп, җилкәсендәге сулы чиләк-көянтәсен дә онытып, уң кулы белән тартылды. Монысы ук кирәк түгел иде. Әгәр дә Хәләф тотып калмаган булса, чиләкләре ычкынып, төпсез калачак яки һич югында түгелеп яньчеләчәк иделәр.

Шәрифә уң-сулына карап куйды: әле дә ярый кеше күрерлек, адәм көлкесенә калырлык түгел икән.

Бу мизгелдән соң аның күңеленә Хәләф тагын да якынрак һәм үзрәк булып китте. Алар аерылыштылар. Шәрифә ничек кайтып җиткәнен, аягы кайсы сукмаклардан йөргәнен сизмичә дә калды, йөрәге сикерде, бөтен гәүдәсен аркылыга-иңгә калтырану басты. Әмма бу тән дерелдәве түгел, бәлки җанның очынуы иде.

Кыз үзенең хисләрен һичкемгә сиздерәсе итмәде. Ашыгып кайткан җиреннән, чиләкләрен бушатмыйча, болдырда калдырды да, җанын кая куярга белмичә, бакча ягына чыкты. Алмагачлар арасына эшләнелгән, әмма соңгы вакытларда кадере югалу, ике-өч ел рәттән буяу күрмәве сәбәпле «картаеп» киткән күшәк-беседкага узып, кулларын тез өстендә кушырган хәлдә уйга талып утырды. Аңа рәхәт иде. Дөньялыкта кайгысы калмаган абыстай шикелле болай югалып утыруына игътибар күзе ташлаучы булмады. Әмма әтисе, кайтып, болдырдагы сулы чиләкләрне күрүгә үк тавыш чыгаргач кына, Шәрифә, усал-усал сүзләр колагын ярып үтүдән рәнҗеп, сихри халәтеннән айныды.

— Адәм тәганәләре, болдырда су калдырып... Бәдбәхетләр... Өммәттә юк эшне сездән көтегез инде. Ризык исрафлары,— дип, хуҗа кемнәрнедер орышты. Бары тик Фагыйлә абыстай чыккач кына барсы да хәл ителеп, бераз тынычлап тордылар. Әмма ул да түгел, Корытай Хафиз икенче яклап тагын тавыш куптарды:

— Асраулар кая, әрәмтамаклар! Шәрифә кызымны суга җибәрмәсәгез, беткән ди бүтән кеше... Авыл алдында оялыгыз ичмасам, миннән курыкмасагыз, Алладан куркыгыз!..

— Үзе барам диде бит, атасы, нигә алай дисең?..

Шәрифәнең әнисе бу рәвешле аклангач, әтисе тагын да кистереп куйды:

— Әгәр инде асрауларны тыңлата алмасаң, үзең барырга иде, җиләк кебек кызыңны суга җибәр инде, тавык баш!..

Шәрифәгә оят булып китте. Әгәр дә сулы чиләкләрен болдырда калдырмыйча, чоланга керткән булса, бу тавыш чыкмас та иде. Инде соң. Ә нигә? Чыгып, араларына керсә, әтисе аңлар, әнисен ачуланудан туктар!

Кызы күренүгә, Корытай Хафиз тиз җаена кайтты, елмаеп ук сөйләшә башлады:

— Әй, бөртегем, Шәрифәм, кил әле бире. Менә әниең белән сөйләшә идек. Ни, дип. Ни... Әнисе, чәйне яңарт, ярармы!

Монсын ук көтмәгәнгә, Шәрифә дә сагаеп калды. Фагыйлә абыстай исә игътибар да итеп тормады булса кирәк, иренең әмерен асрауларга җиткерергә дип кереп китте.

— Ни булды, кызым, кәефең юылмасын, әйе... Кайвакытта тамак карлыга да кычкырыбрак сөйләргә туры килгәли, әйе...

Әтисе болай дисә дә, сәбәпнең бүтәндә икәнлеген кызның күңеле сизенә, әмма акылы аңлап җиткерә алмый иде. Корытай Хафиз юктан гына болай, кызын күрүгә үк сары май кебек эреп китмәс иде, максатына ирешү өчен вакыт уңаен җайлыйдыр?

— Менә каладагы бай йортка килен булып төшсәң, күз алдына китер, кызым, ике катлы таш пулат, мәгърур сарай... Болай су ташытып бимазаламаслар...

Шәрифәнең җавапка сүзе юк иде. Ата кеше нәрсә әйтмәс тә, нинди хыяллар белән яшәмәс!

## X

Килер көннәренең бәхете Шәрифәнең үзендә иде. Бөтен шатлык-куанычы укый торган китапларында һәм дә мәхәббәт хатларында булганлыктан, ул бу тормыштан ераклаша барды. Моңа кадәр дә яшәешнең хәйләсен һәм мәгънәсен руманнардан гына белгәнлектән, киләчәген дә шуларда язылганча итеп күз алдына китерә, алардан чыгып, ата-анасы үзен аңламаячагын сизенә, бүтәнчә һич тә мөмкин түгел дип белә иде. Төрек һәм татар руманнары ата-бала каршылыгын тәфсилләп сурәтләгәнгә, Шәрифә бәхетен ничек корачагын төшенгән дә сыман. Юк, ул аларның сүзенә колак салмас, мәхәббәтеннән баш тартмас, шул кала шәкерте белән бергә булырдыр мөгаен!

Җаны теләгән елан итен ашаган, дигәндәй, егет белән җайлап очрашып, йөрәк серләрен ишетәсе килә башлады. Теге көнне чишмәдән кайтканында ни өчен каушаганына аңлатма таба алмады, шулай да икенче юлы үзен алай өстен тотарга кирәкмәс санады. Әмма кулына көянтә-чиләк ала башласа, ирек куймадылар. Әнисе:

— Нинди хәл ди ул, кызым, атаң белсә, тагын орышыр,— дип юлын бүлде, капканы ачып чыгарга мөмкинлек калмады, һава сулыйсы килгәндә дә алма бакчасында гомерен уздырды. Ургылып чыгарга җиткән хисләр ташкыны акрынлап утырды, кире җыела башлады. Күңелен тынычлык хөкеме көннән-көн ныграк били барды. Алар шушы рәвешле онытылырга да мөмкин иделәр.

Әмма егет тәвәккәл булып чыкты. Җомга көнне, ахшам алдыннан Шәрифәләрнең бакчасына төште һәм кызны агачлар арасына дәшеп китерде. Кыз әүвәле аңлашмыйчарак калды, аны күрүдән йөрәге кузгалган, сиземе бетеп, зиһене буталган иде. Кеше алларында оятлы булудан курыкты. Шулай да, алма караган кыяфәт чыгарып, егет янынарак килде.

— Сез монда нишләп йөрисез, әти кайтса?..

— Борчылма, матурым,— диде егет,— эткәгез хәзрәткә чакырулы, ул шунда икәнлеген яхшы беләм, хафаланыр урын юк, сүзләре тиз генә бетмәс әле...

— Шулай да анысы... Әмма көпә-көндез, ил-күз аек чакта дигәнем...

Егеткә җитә калды. Шәрифәнең болай сөйләве күңеленә хуш килде. Карале, ул аны кумый икән бит, киресенчә саклыкка гына чакыра, кызлар күңелендә җитмеш дию пәрие бар диләр иде, хак сүз икән!

— Мин сезнең белән, гыйззәт иясе сөекле туташ, бер-бер очрашу өметендә яшәмәктә идем.— Егетнең акылы түгел, ташып чыгарга торган хисләре шушы рәвешле итеп телен тибрәндерде.— Әмма үзегезне читтән генә булса да күреп калу мең газап вә авырлыкларга бәрабәр. Кич болынга да төшмисез...

Кичке уеннар хакында Шәрифәнең ишеткәне бар иде. Имеш, анда кызлар-егетләр, җырлап-биеп, адәм көлкеләре ясыйлар икән. Хәзрәт әйтә, моңа чик куярга кирәк, замана яшьләре тәмам бозылып беткәнче дип. Бу да шулар янына йөри микәнни? Үзе шәкерт... Кызның, моңа кадәр күрелмәгән көнчелек хисе кабынып, бит очларын ялкын алды, әмма теленә усаллыгы чыкмады, сорап кына куйды:

— Сез дә ул бозыклар янына йөрисезмени?

Егет оятка калырга тиеш булса да елмайды гына.

— Йөрим шул, Шәрифә, җанаш! Әмма анда һичбер бозыклык галәмәтләрен күргәнем юк. Сезне очратмаммы дип кенә төшкәлим.

— Авыл кызлары янынамы?

— Юк инде, матурым, Шәрифә, сезне сагынудан гына шул.

— Ә минем исемемне кайдан беләсез?

— Бәрәкаллаһ, ничек кайдан? Хафиз бай кызы гүзәл Шәрифәнең исемен белмәскә!

— Ә үзегез кем соң?

— Ничек инде кем?

— Исемегез, дим...

Алар шул рәвешле шактый озак сөйләшергә мөмкин иделәр, ләкин бакча капкасыннан кереп килгән Хафиз бай Шәрифәне чакырып аваз салды:

— Син кайда, Шәрифә кызым?..

Хәләф тиз арада карлыган куагы артына посты, Шәрифә, ике кулына да коелган алмалар алып, тавыш килгән якка таба атлады:

— Мин монда... Ни бар иде, әтием?..

— Кызым, нишләп дөньяңны оныттың инде, бүген кич каладан кунаклар көтәбез бит. Алдан әйтеп куймасам иде, зиннәтләреңне так, матур күлмәкләреңне киеп ал... Бу алмалар әле кызарырга да өлгермәгәннәр, ямь-яшелләр түгелме соң? Калдыр аларны, ташла, ташла. Җәһәтрәк атлыйк. Мин дә онытып җибәргәнмен. Менә-менә килеп төшәрләр.

— Кемнәр соң алар, әтием?

Бик олы, мәртәбә иясе кешеләр. Тимершаһ хәзрәт үзенең улы Дәүләтшаһ әфәнде белән. Ай-һай мөхтәрәм затлар да инде, кызым. Аларның күңеленә кереп калырга тырыш. Акчуриннар бит, кенәзләр!

Дәүләтшаһ әфәнденең дә килүе, Тимершаһ хәзрәтнең дә кунак төшүе аңлы кеше өчен күп нәрсәләр хакында сөйли иде. Акчурин кадәр Акчуриннар юк эш

белән генә монда йөрмәсләр, җитди сәбәбе күренмәсә, алар шушындый да ерак сәяхәтне кирәк дип табар иделәрмени!?. Юк, әлбәттә. Әткәсе менә нәрсә өчен хәзрәткә кергән булган икән! Аш җыя торганнардыр?..

Шәрифәнең бакча әйләнеп йөрергә мөмкинлеге калмады, һай, егет, сабыр итеп көтсәң, кыз монда тагын чыгар әле, берүк, китмә генә!

XI

Тимер күчәр һәм сиртмәләргә эшләнгән зур тарантасны авылда моңарчы күргәннәре юк иде. Хәтта Корытай Хафиз да мондый рәхәтлекләрдән мәхрүм. Кара син аның гәрәбәләр тагып эшләнелгән затлы бизәкләрен, мең чакрымнар үтеп тә армас атларын, яңгыр хәвефе булганда күтәрелеп куела торган түбәләрен, анысын-монысын. Хәтта арбага менү-төшү өчен аерым баскычы да бар икән. Шушы кадәрле юл узса, авыл абзасының сыртына бармак калынлыгы туфрак утырыр иде, боларның ак кәчтүм һәм эшләпәләрендә ник бер генә бөртек тузан әсәре күренсен?

Бүтән вакыт булса, урамда тырай тибүче авыл малайлары арба артыннан дәррәү чабар иделәр, ә моннан курка калдылар. Аллаһ сакласын, йә әллә кемнәрдер әле! Урыс булып куймасыннар, бигрәкләр дә адәмчә кием киенмәгәннәр болар.

Дәүләтшаһ әфәнде Акчурин бик тә ипле кеше икән, йөзенә ник бер усаллык билгесе чыксын. Яшь, мыегы да кара, сирәклеген сизмисең, килешеп тора. Ә менә этисе булырга тиешлесе, өлкәнрәге, Тимершаһ хәзрәтнең күз карашларында исә әллә ниткән усаллык һәм канәгатьсезлек сизелә. Кузлада утырган, ат башларын тотучы абзыйга кулындагы тимер таягы белән нигәдер ике тапкыр төртеп куйды. Болай минут саен сыртыңны каезлый башласалар, билсез калуың да бар!

Кунакларның килгәнен Хафиз бай тәрәзәдән күреп өлгерде һәм, капка төпләренә җиткән вакытларына туры китереп, хатыны Фагыйлә белән каршы алырга чыкты. Монысы ук, ягъни хатын ияртеп, ир кешеләрне йортка узарга чакыру әһеле мөэмин өчен килешмәсә дә, соңгы ике елда Казанда гадәткә кергән Аурупа йолаларыннан берсе иде. Акчуриннар бу хәлгә үзләре ягыннан тиешенчә бәя бирделәр һәм, тәрәккыятьнең шушындый да караңгы салага үтеп керүенә сөенеп, милләтнең киләчәге зурдан икәнлеге хакында горурланып сүз салыштылар:

— Ай, ба-а-а, афәрин, җәмәгать, ай, ба-а-а, ни күркәм хәлдер бу!..

Тимершаһның телгә осталыгы мәгълүм булганлыктан, алдан ук моны көткән Хафиз бай да сынатасы итмәде. Өс-башын калача кәчтүм һәм ботинкаларга алыштырган, алтын сәгатен таккан, кулына тимер таяк алган сыйфатта, иярләнгән сыер хәлендәрәк булуыннан котылырга теләп, ике генә кәлимә әйтте:

— Мәрхабә, туганкайлар!..

Иренең бу рәвешле дә гаҗәеп дәрәҗәдә яңача үз-үзен тотуын беренче тапкыр күргән Фагыйлә ханым егылыплар китә язды. Күпме сорады Аллаһы тәгаләдән, ирен ипләндерсен иде, диде. Менә күрдеңме нишли: сандугач булып кына сайрамый инде. Үпкәләмәслек тә түгел бит, һай җаным, «Кунакларны түргә әйдәремез» диме? Телен кара үзенең, әллә нинди тез-мезләргә күчеп бетте. Ми-

шәрләр дә болай ук сөйләшмәс, валлаһи. Тел бөкләндереп сүз куерту да Аурупа галәмәте микәнни?

Шушылар хакында уйланып, Фагыйлә ханым кунакларының ни сәбәпле килүен уена да кертеп карамады. Бераз сыйланып, өстәл янынннан кузгалгач, Хафиз бай Шәрифәне дәштереп алгач кына йөрәк астында нидер кузгалып, акылы айныды. Карасана, зур эш белән йөриләр икән ләбаса!

Кызны күрүгә, улы Дәүләтшаһ әфәндедән бигрәк, әтисе Тимершаһ хәзрәтләре Акчурин аны бер кашык су белән йотарлык хәлгә керде, күзләре берьюлы ике яктан уйнап, түгәрәк гәүдәсе туп кебек сикергәләп алгандай итте. Әмма карт ишаннар төсле «Бәракаллаһ!» дип, Шәрифәгә кул сузып, акылыннан язарлык хәлгә җитмәде, карашын тиз генә Хафиз бай белән Фагыйлә ханымга күчерде: кайсысына охшаш икән, янәсе!

Шәрифә алар янында булганда һәм аннан соң да йөрәк серләреннән бер генә сүз дә сөйләшенмәде, бары тик:

— Улым, барыгыз әле, әгәр дә Хафиз әфәнде рөхсәт итсә, кызы белән бакча һавасын сулап керегез,— дип, Тимершаһ хәзрәтләре Акчурин, җаен китереп кенә, Дәүләтшаһын урынынннан кубарды. Асыл кошның затлылыгын күрергә һәм бәяләргә өлгергән егет, үз-үзенә бик канәгать рәвештә кузгалып, шушы туташны тиздән кочагында эретергә мөмкинлеген уйларга теләмәсә дә, тыела алмады. Куллары гына түгел, хәтта җаны-йөрәге дә Шәрифәгә тартылды, бу мизгелдә җәннәткә керү хәбәрен алгандай изге тойгылар кичерде. Әмма Дәүләтшаһ әфәнде, ике-өч адым атлауга, эчке әгъзаларында уңайсызлык тоеп, җаны тибрәнеп алудан бөтенләй дә кәефсезләнү галәмәтен хис итте. Әле дә ярый хәзрәтнең кереп килүен белдереп хәбәр бирделәр дә, аның каршына егет белән кызны чыгаруны әдәпсезлеккә санап, яшьләрне кире бордылар. Шәрифә кабат үз бүлмәсенә керде, Дәүләтшаһ исә өстәл янына утырды. Ул булмады, ишекне иңгә-буйга тутырып диярлек, абыстае белән хәзрәт үзе дә күренде.

Хафиз бай йортында бу мәҗлес иртәнгәчә дәвам итте. Сәхәрдә мәсҗедкә барып намаз кылганнан соң, йокысыз төн уздырган кунаклар кайтыр юлга кузгалдылар. Болай ашыгуларының сәбәбе ике атнадан соң зурлап киләселәре белән генә аклана иде. Шәрифәнең язмышы һичбер ай-вайсыз хәл ителгән санала башлады, шулай итеп, ул ике атнадан кияү куенына керергә тиеш күрелде. Хәбәр бик тиз авыл эчендә һәм тирә-юньгә таралды. Акчуриннар тарантасы артыннан күтәрелгән тузан басылырга да өлгермәстән һәммә йорт әһеле бу хакта гәп корды. Хәер, гореф-гадәтне белгән кешеләр моны алдан ук фараз кылырга җитешкән иделәр: Хафиз байның эшләре тагын да яхшырак тәгәрәячәк.

## XII

Хәләфнең күңел төбен нинди кортлар төшеп кимергәнен кемнәр белсен дә, никләр генә хәл-әхвәлен белешсеннәр? Болар барсы да Шәрифә өчен билгесез калды. Әмма үзенең язмышы атасы тарафыннан хәл кылынганын аңларлык башы бар иде кызның. Дәүләтшаһ әфәнденең күңелләренә хуш килгәнлеген сиздереп, әнисе:

— Бу Акчуриннарның кечесе бигрәкләр дә тәрбияле икән. Ул сүзгә катнашмауларына кадәр әллә нинди бер олуглык өстәп тора үзенә. Кызыбыз бәхетле

булыр, Аллаһы боерса...— дип, Шәрифәнең хисләрен кайнарландырырга тырышулары да булачак никахны хуп күрүе хакында сөйли иде. Корытай Хафизның аңа ияртеп әйтелгән һәр сүзендә байлык һәм мәртәбә өмете бар иде:

— Аллаһы тәгаләнең амин дигән сәгатендә, тәкъдир кушып башлаган эштер, анасы! Казан каласында сәүдәбез генә түгел, сүзебез дә үтемле булып китәр. Әле, мин әйтәм, моңа кадәр бер дә бирешмәдек. Инде һәммәсеннән алга чыгарбыз. Кызым кадәр кызым бит ул, Акчуриннарны да буйсындырды диген, ә!.. Менә бит ул ничек!

Барысын да искә алгач, Шәрифәне яман күздән саклау ниятенә керешеп, янына утырмачы әбине дәштерделәр. Кем белә, авылда күз атып йөргән берәр ярлы-ябагай кызыгып куеп, эшне бозуы да бар. Дошманнар да юк түгел.

Читлеккә төшкән асыл кош төсле, Шәрифә хәтта ялгызы бакчага чыгудан да мәхрүм иде. Шушы рәвешле дүрт-биш көн төгәлләнеп, утырмачы әби дә кызның холык-фигылен өйрәнеп өлгерде, аңа ышаныч баглады. Мөмкинлек күренсә, башын салып, йоклап алуны гадәт итте. Ничә көннәр өй һавасын гына сулаудан Шәрифәнең төс-кыяфәте һәм сәламәтлегенә зыян килер дип әнисе сагаймаса, йөрәк түренә керергә өлгергән егетен кыз кабат күрмәс тә иде.

Ул көнне бакча аеруча хозур һәм һавасы саф булып, иртәнге якның салкынча җиләс җиле тәннәргә иркенлек алып килде. Хезмәтен гадәтенчә җиренә җиткереп башкарам дип уйлаган утырмачы әби алмагач төбендәге урынында йокыга талуга, ялгызы моңаеп калган Шәрифәнең аяк астына алма тәгәрәп килде. Гүяки җәннәт бакчасыннан өзелеп төшкән дә, кызны үртәргә маташа имеш. .

Алмагач артында, чак кына иелеп, үз янына чакыручы егет качып тора иде. Аны-моны уйламастан, Шәрифә Хәләф янына атылды. Ничек шулай булгандыр, әмма алар кочакка-кочак диярлек туры килделәр. Шәрифә зарлана ук башлады:

— Атамнар башымны ашарга маташалар. Надан бай малаена бирергә итәләр...

«Надан» дигәннән, бу кадәресе артык, җитмәсә дөрес бәя түгел иде. Хәләф шунда ук төзәтү җаен карады:

— Алай димә, матурым... Хак булса, ул егетне Аурупа телендә дә сөйләшә диләр.

Һай ахмак, анысын бит Шәрифә үзе дә белеште, әмма Дәүләтшаһ әфәндегә күңеле ятмады. Ә син, шуны да аңламыйча, көндәшеңне яклап торасың бит, пешмәгән. Белсә ни! Дәүләтшаһта синең кебек төс-бит, кыяфәт бармы? Юк! Буй-сын, дисеңме, руманнарда гына язылганча килеш-килбәт һәм үз-үзеңне тотышың дисеңме, кайсын табасың боларның ул байгурада? Нигә бу егетләр шушылай пешмәгән булалар икән, нәкъ китаптагыча!

Шәрифәнең фикер кайнарлыгы йөзенә бәреп чыкты. Хәләф хакында уйлаган көннәре мизгел эчендә хәтерендә актарылып ташланды да акылын йөрәк хисләре күмеп китте: «Заяга калмасын, бер күтәрелеп үпсен иде ичмасам!»

Каушап китүдәнме, әллә башка сәбәп аркасындамы, пешмәгән егет телсез тора бирде. Никләр генә аңламый икән? Шәрифә үзе беренче адымны ясасынмыни?

— Без мәңге кавыша алмабыз инде...

Бу сүзләрен әйткәндә егет, Шәрифәдән генә түгел, хәтта үзеннән дә оялды. Әмма кызның бәгыре урталай теленеп китте. Бу пешмәгәнне артыгы белән кызганды һәм язмышының аныкыннан да яманрак икәнлеге хакында уйлап борчылырга өлгерде. Аның фикере белән килешмичә:

— Алай димәгез, әле никах мәҗлесе җыелмаган, вакыт бар. Тәкъдиребез Аллаһы кулында. Миңа ул байгура ошамый. Бирмә, ташлама шул козгынның тырнагына,— дип пышылдауга, Шәрифәнең сүзләренә ияреп чыккан күз яшьләре алсу бите буйлап йөгерде, кызыл якут ирененнән узып, ияк очына төште. Акылы һәм йөрәге шашынган егет, үз-үзен белештерми, кызны кочагына алды. Бу гамәленә Шәрифә каршы килмәде. Тәне буйлап сихри калтырану йөгерүгә карамастан, наз иркендә кала бирде. Әмма егет, артыгына батырчылыгы җитмичә, тукталып калды.

— Миңа сезне бирмәсләр инде?

— Кемнәр?..

Кызның бу соравы Хәләфне бетереп ташлады. Ни әйтергә белмичә, башы аска иелде.

— Кемнәр дип инде, әтиегез-әниегез дигәнем...

— Ә алар мине бүтәнгә бирделәр бит инде, никахлашасы гына калды...

— Ничек инде бирделәр?

— Бирергә булдылар дигәнем...

— Шулай шул. Миңа сорарга калмады.

— Ә син сорап торма!

— Ничек инде?.. Ә сез ризамы соң?

— Нәрсәгә?

— Урлап качсам, дим...

— Батырчылыгың җитәрме?

— Җитмәгән кая ди ул!

Үзгәрсә үзгәрә икән кеше, егетнең күкрәгендә лачын очынды диярсең.

— Хәзер үкме?

— Әйе, хәзер үк!

Шәрифә акылында түгел иде булса кирәк. Утырмачы әби йокысында калды. Ә алар, арткы капкадан узып, таллыкка төштеләр һәм, инешнең аргы ягына чыгып, авыл урамына кереп тә тормастан, Түбән очка таба ашыктылар. Дөресрәге, егет туктап хәл дә җыярга теләмәде. Су аркылы чыкканда күтәреп алган Шәрифәсен кулыннан төшермәде.

Ул көннең һәм бу гамәлләренең нәрсә белән бетәсен бер Аллаһы тәгалә үзе генә белә иде.

## XIII

Шәрифәнең кайдалыгы икенче көнне үк авылда мәгълүм булды. «Эш узган, Корытай Хафизны яшьләр акылга утырткannaр!»— дип, бер дә яшермичә сөйләделәр. Чөнки бай үзе дә туй эшләре белән калага киткән җиреннән әйләнеп кайтмаган, утырмачы әби келәткә бикләнгән, хөкем көтеп ята, Фагыйлә абыстай кара кайгыдан урын өстенә егылган иде. «Һай бала, шул зимагур өчен үстердеммени мин сине? Атаң нәрсәләр әйтер!» — дип аһ оруларын ишеткән ке-

шенең йөрәк мае кайнамыйча калмастыр? Дөрестән дә Шәрифәнең бу гамәле юньсезлек иде. Моны кыз үзе генә аңламады. Муллаларның берсе дә никах укырга теләмәделәр. Йоланы мәдрәсәдәге башкорт шәкерте җиренә җиткереп башкарган икән дип сөйләделәр. Тик шул кичәдән соң авылдан аның бөтенләй чыгып китүенә генә аптырадылар.

Хәләфнең агасы авылда староста булганлыктан, яшьләрнең бу гамәленә сарулары кайнаган кешеләр һичбер эшкә алынырга кыймадылар. Барысы да Хафиз байның каладан кайтып төшүен ут йотып диярлек көттеләр.

Кешенең бәхете үзеннән дә зур була алмый, бары тик артыннан яки алдыннан гына йөри. Вакыйгалар бер-бер артлы шушыны дәлиллиләр төсле иде.

Корытай Хафиз, кайтып кергән уңаена, бу хәлләрдән хәбәрдар булып, келәткә бикләнелгән җиреннән утырмачыны сөйрәп чыгарды һәм эт итеп кыйнап ташлады. Дөньялыкның яме байларның мәрхәмәтеннән дип күнеккән әби, йөзетәне изелеп беткәч, исән калуына шөкрана кылып, аяк өстенә басарга тырышып карады. Хафиз бай кереп киткәнче хезмәтчеләре дә поскан урыннарыннан чыгарга һәм әбигә, һич югы, кул бирергә кыймый торганнар иде, хәзер күтәреп үк алдылар.

Хатыны башына сөлге ураган хәлдә урын өстендә ятканлыктан, аны да адәм мәсхәрәсе ясап ташларга морадын хасил кылып кайткан байгура гайрәтен сүндерде. Тезләренә егылып, Фагыйлә абыстайга ауды һәм бер аһ орды да елап җибәрде. Кешегә сөйләсәң, һичкем ышанырлык хәл түгел иде бу. Яшьли атасыз калган авыр вакытларында да болай рәнҗетелгәне булмагандыр? Җирне умырып-тешләп тырмашмадымыни ул? Бу байлыкларын нәрсә өчен җыйды? Аллаһы тәгалә аңа дөнья каршысында бердәнбер, гүзәл бала бүләк итте, мирза кызлары да эсти алмаган белемне һәм тәрбияне бирделәр. Кая, кайсыгызда бар андый бала? Күрсәтегез! Юк икән шул, юк икән! Кеше баласы, ичмасам, ата-ананың кадерен белә, сүзен тыңлый, әдәп саклый. Аһ, Шәрифә, Шәрифә!

Хафиз бай да, Фагыйлә абыстай да үзара сүз алып-салып сөйләшерлек хәлдә түгел иделәр. Рәнҗешләре бертөрле, хәсрәтләрендә дә һичнинди аерма юк, нәрсә дисеннәр инде, болай да аңлашылып тора шул.

Болай ятып эш чыкмаячак иде, әмма Корытай Хафиз булып, Корытай Хафиз байның да тавы ишелде, дөнья йөзенә күтәрелеп карыйсы килмәде. Ә нинди бүләкләр алып кайткан иде югыйсә! Бөтен базарларны йөреп, дус-иптәшләренә хәбәрләр салып, туйга чакырып. Оятын кая куярсың да, ничекләр генә аңлатырсың? Урлаткан булса, бер хәл иде. Ябышып ук киткән диләр бит. Кайдан барысын да белеп торалар? Әллә юри генә сөйлиләрме, котыртыр, коткы салыр өчен дим, ә?

— Әнисе...— Хафиз бай тынычлангандай иде.

Бу сүзен ишетүгә, Фагыйлә абыстайның йөрәк мае эреп китә торган иде элекләрне. Һай, булган икән вакытлар, бәхеткә туйган чаклар!

— Әнисе, әллә, мин әйтәм, урлаганнар гынамы? Ул зимагурны беләсең бит. Никләр генә кудыртмадым үзен!

— Һай атасы, атасы, куеныбызда елан үстергәнбез икән! — Фагыйлә абыстай бу хакта ничә тапкыр уйлаганлыктан, тонык кына итеп сөйли бирде:— Кеше җибәртеп тә, болай да белештем. Үзе дә хәбәр салды. Борчылмагыз, имеш,

үз тиңемә чыктым, имеш. Нинди тиңе ди ул анын? Әтрәк-әләм. Гыйбрәт. Бабасыннан калган өйләре җиргә сеңеп бетте. Зимагурлыкта гомерен уздырды. Нәселе яхшы дигән булалар. Алпавытлар, имештер. Тапканнар мактар нәрсә, ул алпавытлыкларының комы Әби падишаһ вакытында ук коелып беткәндер, ачуым бер килмәгәе.

Татарның борынгыдан килгән шушы бердәнбер сүгенү сүзен, ягъни «ачуым бер килмәгәе»не Фагыйлә абыстайның гомеренә дә теленә алганы юк иде, менә әйтте бит, җиңеләеп киткәндәй булды. Әмма дару кебек азга гына файдасы тигән сүз артыннан хәсрәт караңгылыгы тагын да авыраеп килде. Бүген дә ул урыныннан тора алмады. Йорт эчендәге асраулар күзгә күренергә батырчылык итмәделәр. Хәтта бохар песие дә хуҗабикәсенең хәле яманлыкны тойды, бөтен гаепне әһеле сычканнан күрде. Алар гына боза тынычлыкны!

XIV

Шәрифәсенең үгетләрлек җире юк икәнлекне Корытай Хафиз үзе дә барып белде. Бәрепләр генә үтерергә әзер иде, Аллаһы тәгаләдән курыкты.

— Анаң каргый, авыл аптырый... Ташла, кайт, ул зимагурга дип үстергән кызым юк минем, бәгыремне телгәләмә,— дипләр дә карады. Нәрсә ди бит ә?

— Әтием,— дигән була,— мин ялгышмадым. Иремнең гаебе юк, теләп бардым,— дип әйтә шул, җир тишекләре дә ачылмый андый вакытта, төшепләр китәр идең. Хан сараенда яши иде кызы, хәзер ярты җимерек сәке башында хәсрәт чигеп утыра бит!

Ничек керсә, шулай сәлам бирмичә чыкты алардан Хафиз. Нәрсә уйларга белмәде. Кызының Хәләфкә мәхәббәтенә хәйран итеп кайтты. Ул хәлләрдән бай абзый бүген-иртәгә генә айный алмаячак иде.

Бу кичне кемнәрдер урамнан җырлап уздылар:

Быелгы ел бигрәк иртә
Арыш башак ташлады,
Хафиз байның чибәр кызын
Хәләф мөртәт ашады.

Болай ук кирәкми иде, җәмәгать, ярамый бит инде! Колагына түгел, йөрәгенә уелды бу сүзләр Хафиз байның, бәгырен соңгы кисәгенә кадәр телгәләде. Ул мөртәтне ничек кияүләсен ди инде ул, кеше алларында нинди йөз белән күренсен икән инде?

Хәләфнең татлы мәхәббәте күп дигәндә бары тик өч көнгә җитте. Артын-алдын уйламаган җиреннән хәсрәткә төште. Әнисе дә киленне өнәп бетермәде, кая ди ул эш кушарга, Шәрифә алдында сүз әйтергә дә ояла иде.

Авыл яшьләренең алар урамыннан да урап узулары, мыскыллы җырлары саруын кайнатты. Артларыннан чыгып, ачуланырга атлыккан иде дә, булмады. Капка тавышын ишетүгә, каядыр эреп югалдылар. Хәләф урам уртасында озак басып торды һәм шунда нинди ялгыш ясаганлыгын аңлап алды. Әмма төзәтергә инде соң иде.

Әллә Шәрифәне ата-анасына илтеп кенә тапшырсынмы? Булмаганны?!

Нинди йөз белән? Алданрак уйларга кирәк иде, төн кунганчыга, гүзәл кызның кочагында эрегәнчегә кадәр!

Хыялда гына йөртергә мөмкин булган фәрештәдәй затның ничек үзенә насыйп ителгәнен аңларлык хәле юк иде. Чыннан да, әгәр кешегә сөйләсә, һичкем ышаначак түгел шул. Уен гына кебек иде. Ничек болай килеп чыкты, диген? Ике күрешеп, аңлашырга да өлгермәгән җирдән бит! Һай, тәкъдиреңдә булса, бирә икән ул Ходай. Ният кенә кыл, белештерми дә каласың.

Бары тик Шәрифә генә юк-барны уйлап борчылмады. Ул бәхетле иде. Укылган руманнарыннан ук барысын да белеп, ике күрешүне егерме иткән, шулардагыча эшнең башын-ахырын сәгадәт мәйданы ясап күз алдына китерә иде. Әмма тормышының бүтән якка борылачагын белмәде. Әлегә ул сөенде, теге бай малаеннан котылып, Хәләфнеке, бер күрүдә гашыйк иттергән егетенеке булуына шатланды.

XV

Никахларын «Митрәкә кенәгәсе»нә муллалар теркәргә теләмәделәр. Хәер, шәригать кануннарын белгән кешеләр өчен мондый язуның кирәге дә юк иде. Әгәр дә аларга хөтбә укылган икән, падишаһ хәзрәтләренең дәфтәрендә исәпкә алынмауның гына хилафы бармы соң? Әмма дә ләкин, авылда төрле хәбәрләр таралып, һәрбер бәла-казага Хәләф белән Шәрифәне гаепләргә теләүчеләр көннән-көн ишәергә дә мөмкин иде. Эшләр болайга ук китсә, яшьләрне харап итеп ташларга да күп сорап тормаслар. Яхшы чакта чит-ят җирләргә китеп барырга да мөмкин. Шулай да моңа аяклары тартмыйчарак торды. Шәрифә исә әтисеннән һәм газиз әнкәсеннән миһербан өметендә яшәде, гафу итәрләр, ятратканына барды бит, аңларлар кебек иде.

Атасы дәррәү кубып, дөньяларны җимертеп, сынга таза егетләр белән килеп кергәч нәрсә дигән иде аларга Шәрифә? «Йөрмә, әтием, мин үзем теләп бардым, сөеп-яратып чыктым. Иремнең һичбер гаебе юк. Аллаһы тәгаләнең хакы өчен дип әйтәм, өзмә бәхетемнән! Әгәр дә мине моннан алып кайтырга килгәнсез икән, җеназамны да илтүче сез булырсыз! Таһир-Зөһрәләрнең рухын исегезгә төшерегез. Тәкъдиремә каршы килгәнегез өчен Аллаһы тәгалә кыямәт көнендә гафу итәрме, шуны уйлагыз!»

Бу сүзләрен ишетүгә, коелып кына төштеләр. Кабарынган кикрикләре шиңде. Әмма Корытай Хафиз түзмәде: «Иблис икәнсең!» — дип бәгырен айкап бер аһ орды. Аның: «Баламны үз башыма гына укытканмын икән!» — дип уйларлык җире дә бар иде. Моңа кадәр Казан байларына ияреп, хатын-кызларга гыйлем алу килешә, милләтебез укымышлы булсын, дәрәҗәсе күтәрелсен дип, өряңа җәдитләр кебек сөйләнүләре өчен эче пошты. Бабайлар заманын исенә төшерерлек тә иде шул. Мондый хәл күренә калса, кызларын алар чәчләреннән генә сөйрәп кайтарганнар. Юк, кая ди ул үз теләкләре белән кияүгә бару, хәтта дөнья йөзен бер күрергә зарыгып яшәгәннәр. Инкыйлаб, имеш, тәрәккыять — чәнчелеп кенә китсеннәр! Кода булырга тиешлеләрдән Йосыф хан Акчура хәзрәтләре, боларны ишетеп, акылга утырыр әле! Дөнья шулай ул, бер буталдыңмы, бөтенләй тугылап ташлый, бәхетеңне кайда һәм кайчан югалтканыңны да онытасың!

Хафиз байның шушы кадәр дә оятка калганы һәм урынга авып авырганы гомерендә дә булмады. Йөрәге шашынудан һәм бәгыре кайнаудан тәне-йөзе шешеп чыкты. Кешене ачудан кабара, диләр, дөрес икән. Әгәр дә болайга китсә, Шәрифәсенең хәсрәте аны кабер якасына китерәчәк иде. Галимулла хәзрәтнең чынаяк язып өшкерүләре, земской шифаханәдән китерелгән яһүд духтыры, кара канын ишаннан суыртулары — берсе дә ярдәм итмәде. Сәүдә хәсрәте дә оныттылды. Әти-әнисенең урын өстендә ятканлыгын ишеткән Шәрифә ишек төбеннән эчкә уздырылмады, ул аларга инде ят иде. Җитмәсә, корсагы кышлыкта ук борынына җитте. Балалары туасы иде...

Язлыкта исә, апрель ахыры, дүшәмбе көн Хафиз бай дөнья куйды. Бар җиһанны бер итеп йөргән, гәүдәсе белән генә түгел, сүз әйтүеннән дә бүтәннәрне сытып китәрлек мондый мәһабәт затның шушы рәвешле рихләт кылачагын һичкем башына китермәгән иде. Халык авыз күтәреп еларга әзерләнде. Ни дисәң дә, тирә-юньгә чыксаң, Хафиз бай мактаныч та, авылның терәге дә иде. Мәсҗеден салдырды, мәдрәсәсен тотты. Мулласын-тегесен асрады. Әгәр дә анда ул кадәр байлыклар булмаса, халыкка бу эшләр авырга киләчәк, хәтта мөмкин дә түгел иде. Җеназага җыелган халык матәм тотканда, йөкле Шәрифә, араларына кереп, әтисе белән хушлашты. Ирләр артка чигенделәр, абыстайлар сүз кузгатырга кыймадылар. Дөньялар бер мәлгә тынып торды. Шәрифәнең тын тартуына ук һәммәсенең күзеннән кайнар яшьләр коелды. Фагыйлә абыстайның каршына:

— Әни-ем...— дип килеп баш оргач, мескен ана түзмәде, кызын тезенә күтәрде.

Шәригатькә хилаф итмәс өчен үкереп еламаска тырыштылар, әмма өзгәләнеп чыккан аһлары җирдән күкләргә ашты. Мөмкин түгел чакта да ана кеше үзсүзле баласын гафу итәргә әзер шул. Бәхетлеләр генә кешеләрне оныталар, сагышлылар исә пар киләләр.

Хафиз байның җеназасына кырык көн булды дигәндә Шәрифәнең кызы туды. Әтисен җирләгәннән соң, әнисе белән бер йортта яшәп калганлыктан, ирен бөтенләй диярлек оныткан иде. Исенә иң беренче булып ул төште, һайлар да сөенер инде, бичаракай!

Бу хәбәрне ишеткәч, Хәләф кая басканын да белмәде. Сөенче китергән яланаяклы малай: «...Шәрифә апа чакыртты»,— дип сүзен бетерүгә, сөяк саплы пәкесен тоттырды. Басудагы бөтен эшен ташлап, ат башын малайга калдырып, авылга йөгерде. Чишмә буена җиткәч, бит-кулларын юды, урамнан салмак адымнар белән барырга тырышты. Әмма аны хәтерләп торырлык һичкем күренмәде. Шулай да сер бирәсе итмәде.

Ә Хәләфне Фагыйлә абыстайның ялчылары ишектән дә уздырмадылар, сабыйны да күрсәтмәделәр. Монысы инде адәм хурлыгы иде. Дулап кына нәрсә майтарырга мөмкин? Талпынма, “ир бәхете — хатыннан” диләр түгелме соң? Һәм шулай булып та чыкты.

## XVI

Татар авылында, капка баганасының да күзе бар, диләр, һәркем диярлек Хәләфнең нинди оятка калганлыгын сәгате-минуты белән белеп алган иде. Моңа

кадәр һаман да Фагыйлә абыстай ягында торып, аның усаллыгын акларга теләүчеләр дә, шушы вакыйгадан соң, кияве Хәләфне яклый башладылар.

— Нигә инде яшьләрне аералар,— дип җыру һәм бәетләр дә сөйләштереп, белгән-белмәгән хәбәрләрне дә искә алып, күңелләрен тутырган сагыш шәрабын чайкаудан түгелеп китүчеләр дә булды. Бигрәк тә абыстайның асраулары үзгәчә кыланды. Шәрифәне сагынулары да, аңа карата хөрмәтләре дә, бүтәне дә бергә килеп кушылган, бәгырьләрен тибрәткән иде. Ишек артына чыккалаган вакытларында һәртөрле сүзләр телгә алынып, һаман да ирен соратып тинтерәгән Шәрифәгә хәл вакыйгасын чишеп салдылар. Фагыйлә абыстайга үз дигәненчә эшләргә насыйп булмады. Кызы ата йортын икенче мәртәбә ташлап чыкты.

Ишегалдында юкәдән бау ишеп маташкан Хәләф урыныннан куба алмыйча торды. Күзенә күренгән кешенең хатыны Шәрифә икәнлегенә исе китте. Йөгереп барасы да, кулындагы ак биләүдәге баланы күтәреп аласы иде дә бит югыйсә. Ни хәл итәсең, артык көттергән аны хатыны, артыгын изалаган. Инде Шәрифәсез, җан кисәккәесез дә калырга тиешлеге белән килешеп, бөтенләй дә өметен өзгән иде шул.

— Хәләф, без кайттык!..

Ир үзенең салмак адымнарын санады. Шәрифә исә, киресенчә, аңа ташланды. Бала Хәләфнең кулларына күчте. Әти-әнисенең күзләреннән яшь акканда, ул елмая иде.

— Таныды, Хәләфем, сине таныды... Атам өендә елаудан арынмаган иде...

— И кызым, Зарифам минем!

— «Зарифә» диярбезме икән инде? Ә без «Фатыйма» кушмакчы идек.— Боларны сөйләгәндә Шәрифәнең йөзе кабат балкып китте, һәрьяклап бары тик мәхәббәт өчен генә яратылган хатынга ире кочагына сыену һәм бала назын татудан артык тагын нәрсә кирәк соң?

Ике гашыйкның бер ояда тормышларын яңартып җибәрәселәрен көткән кешеләргә бу хәбәрләр ирешеп, аларның күңелләренә шатлык һәм сөенеч тулганда, Фагыйлә абыстай әрнеп карганды:

— Шул зимагурың белән рәхәт күрмәсәң иде, ил алдындагы кадеремне бетердең, арада яхшы булсын дип ничек тәрбияләткән идек, атаң да бәхиллеген бирмәде үзеңә...

Чәчләрен йолкыр дәрәҗәгә җитеп саташулары чиктән ашты, көне төнгә буталды, акылы адашты. Бу хәлендә үз-үзен онытып, никадәр олуг гөнаһлар кылганлыгын төшенерлек чарасы калмады.

Әмма, аңа карамастан, Шәрифәнең бәхет чәчәге балкудан туктамады. Яраткан ире кочагында яшәүнең тәмен һәм ләззәтен югалтырга һич тә теләмәде. Әгәр моңа кадәр гомере атасының ике катлы иркен йортында узган булса да, үзе теләп, рөхсәтсез, ябышып ук Хәләфкә барганлыгы сәбәпле, тормышын ярлы өйдә уздыруга күңеле бер дә каршы килмәде. Аныңча алга таба барсы да яхшырыр, көйләнеп китәр төсле тоелды.

“Яшьлек — җүләрлек” диләр шул. Шәрифәне чыннан да «юләргә» санарга мөмкин иде. Тормышның татлысыннан кем инде, аңы була торып, ачысына үз теләге белән төшсен? Юк, әнисе дә, әтисе дә ялгыштылар, китап укытып күңе-

лен боздылар. Белем кешене агарта, диләр. Алай ук түгел икән шул, диванага да сабыштыра ул.

Авыл буйлап шушындый сүзләр йөрде. Кызларын мәктәпкә илтергә уйлаган ата-аналар ниятләреннән кайттылар. Хәтта ир балаларын да быел мәдрәсәгә салмаска дип сүзләр беркетүләр башланды. Шул рәвешле дөньялар җайланган җирләреннән аркылыга-буйга бутала башлады.

XVII

Хәләф бу көздә әнисен җирләде. Ишеткәне бар иде аның, олы бәла ялгызы гына йөрми, дип. Нәкъ шулай булып чыкты. Матурлыкта беренчелек мәртәбәсен һичкемгә бирмәячәк кызлары авырып китте. Мәет артыннан өйне юып чыгарганда, бераз һава керсен дип, ишекне ачыбрак тоткан иделәр, бишектәге балага ярамаган ахрысы. Тәне буе кызышып елады, үрсәләнде сабый. Хәтта күкрәк сөтен дә капмас булды.

Әнисен җирләгәндә дә күңеле болай ук бәргәләнмәгән иде, әле яңа гына авызын япкан кабер янына икенчесен казып, кызын шунда куйгач, Хәләфнең ике күзеннән дә тоташ кайнар яшьләр коелды. Ялгызы озак басып торды, иман кәлимәсен туктаусыз кычкырып укыды. Шактый вакытыннан соң айныгач, Шәрифәсен исенә төшереп, аның янына ашыгырга кирәк тапты. Ике ел эчендә тагын да гүзәлләнгән хатыны бетмәс-төкәнмәс шатлыгы вә куанычы шул, аны югалтса, ул вакытта нишләр?

— Борчылма, матурым, Аллаһы тәгалә насыйп әйләсә, Зарифә урынына Гарифәне алып кайтырбыз! Хак тәгаләнең бирмешеннән узарга язмасын да, Ходай сәламәтлегеңне бирсен...

Әйтте әйтүен, әмма бәгыре киселде Хәләфнең. Хатынын кочып, икәүләшеп еладылар. Хәсрәт икесен бергә сыкты. Алдагы язмышларының мәрхәмәтенә өмет багладылар. Тормыш сынаулары каршысында бөгелеп төшү, һәлакәткә юл кую адәм баласына килешә торган гамәл түгел бит ул.

Алар кабат тернәкләнеп киттеләр. Бер-берсенә карата хөрмәт һәм мәхәббәтләре ярдәмгә килде. Ярату кебек бөек хиснең тормышта нәрсәгә кирәклеге, сөйгәнең белән бер куышта яшәүнең тәме ни икәнлекне Шәрифә инде китаплардан укып кына түгел, үзе татып күрде. Әгәр дә насыйбы Хәләф урынына бүтән берәү, яратмаган кешесе булса, Зарифәнең үлеменнән соң, ул яки акылдан шашар, яисә үз-үзенә кул салыр иде.

И, бала хәсрәте... Син ни өчен газиз аналарның бәгырьләрен кисәсең дә, канлы яшьләр түктерәсең? Шулай булмасаң, дөньяның дөрес түгеллеген белми калырбыз дисеңме әллә?

Тормышлары яңадан үз эзенә кереп барганда, инде бөтен авырлыклар артта калып, күңелләре ипләнә төшкәндә, староста авыл буйлап хәбәр салды:

— Падишаһ хәзрәтләренә каршы явыз Герман сугыш башлаган. Егерме биш яшькәчә ир-егетләр солдатка алынырга, кәмисий үтәргә әзерләнсеннәр. Курыкмасыннар, мөхарабә озакка бармаска кирәк. Падишаһыбыз бик көчле!

Бу сүзләренең беренче өлеше хак булса да, ахырдан үзе өстәгәне ир-егетләрнең чыгып качмавы, илдә тәртипнең югалмавы өчен юри генә юатып әйтелгән иде. Әмма күпләр аның нәкъ менә шунысын дөрескә санадылар. Үзләре ба-

рып җиткәнче сугышның бетәчәгенә, «батыр» исеме белән кайтачакларына ышандылар. Япон сугышында яраланган авыл старостасының ни рәвешле тормышы җайланганлыгын күпләр яхшы белә иде. Солдатка чакыртылган һәркем диярлек шуны уйлады.

Авылдан сугышка китәргә тиешлеләрдән иң беренче кеше Хәләф иде. Заманында урысча да укыганлыгы сәбәпле, аны падишаһ хәзрәтләренә бик кирәкле дип таптылар.

Август аенда ук башланган сугыш җиле, шулай итеп, кара көз ахырында татар авыллары өстенә дә кайгы-хәсрәт канатын җәйде. Бай балаларының да солдатка алынуы, Казан мәдрәсәсендә белем эстәп яткан шәкертләрнең, мөгаллимнәрнең, хәтта яшь муллаларның да иңнәренә мылтык асуы, кан эченә җибәрелүләре бер-бер артлы ишетелеп торганлыктан, халык үзен чарасыз калган кебек хис итте. Шул көннәрдә тагын бер сүз таралды, имеш, падишаһ хәзрәтләре татардан сөекле керәшеннәрен солдатка алмый икән. Сугышка бармас өчен иманыннан язарга әзер бәдбәхетләр дә табылып, авыллары белән чукынырга җыенучылар да бар, имеш. Әмма кайда икән ул юләрләр? Әллә юк-бар сүз генә микән?

Бер ел элек кенә бөтен татар иле диярлек Романовларның тәхеткә утыру хөрмәтенә уздырылган олуг юбилей уңаеннан бик көчле рухи күтәрелеш кичергән иделәр, «Ак падишаһымызга Ходай тәгалә озын гомерләр бирсен!» — дип, догага кушып, «амин» тота башлауга гына бусы нинди чукындыру тагын? Урыс үзенекен яклар инде, татарны түгел.

Бу сүзләргә һәм гайбәтләргә бер генә катнашы булмаган кеше сыйфатында тотты үзен Хәләф. Бүтәннәр ни-нәрсә сөйләшкәнне ишетмәде, бәхәсләргә катнашмады. Бөтен хәсрәте Шәрифәсе хакында иде. Япа-ялгызын ничек калдырып китә алсын? Кемнәр кулына? Бу бәхетсез башы әллә әйләнеп кайта, әллә юк, кем белә? Ялгызы ничек яшәр?

Хәләфнең бәгыре болай ук кискәләнеп өзелгәне юк иде. Менә бит, эшләр кая таба бара, бу тормышның бер дә терәге булмый икән. Китапларда дөрес язганнар, дөньялыкка таянырга ярамый, фани ул, фани! Әмма ташлап та китү, газиз җаннан баш тарту, Аллаһының тәкъдиреннән борын чөерү дә дөрес түгел. Падишаһлар гына, адәмнәрнең гомерләрен кисү өчен, үзләрен Хак тәгалә дәрәҗәсенә куярга теләп, сугыш уенын китереп чыгаралар.

Чарасызлыктан туган авыр уйлары Хәләфне изә иде.

Шундый көннәренең берсендә Сираҗи мәхдүм килеп керде. Көтелмәгән җирдән пәйда булуы, авызларын ерып сөйләшүе, сүз саен «Аллаһ хакы»н калдырмавы Хәләфнең салынып төшкән болытлы күңел күген яктыртып җибәрде. Теге вакытларда алар, мәдрәсәдә муллалык көтеп яткан шәкертләр, кышка калдырылмыйча, авылдан ук чыгарылган иделәр. Хәләфнең Шәрифәгә өйләнүендә үзләрен каты гаепләп, Хафиз бай кудырган иде. Алар исә Донбасс шахталарына барып җиткәннәр, Иделдә-Донда балык тотканнар, дөньяның барча әчесен-төчесен диярлек татыганнар икән. Сөйләп киткәч, сүз күп булды. Инде дә солдатка алыну өчен кайтарылганлыгы да, билгеле, йөрәкләрендә әрнү уятты.

— Аллаһы тәгаләнең бирмешеннән узмыш юк,— дип киңәштеләр дә ни килсә, шуңа буйсынырга булдылар. Әмма Хәләфнең күңелендә Шәрифә кайгы-

сы иде. Бу мәсьәләне кем белән дә арага куеп тикшермәгәнлектән, мәхдүм Сиражиның бик вакытлы килүеннән файдаланып, хәсрәтен аңа чиште.

— Син, Хәләф абый,— диде Сиражи, гәүдәсен терсәгенә таяндырып,— әнисенә кайтар аны. Ышанычлы җирдә булуы яхшы. Монда ялгызын калдырудан бер дә юнь күрмим. "Илдә ир бетсә — әтрәк азына" диләрме? Шәрифә абыстай күркәм зат. Ялгызын калдырма! Шту син!

Моңа кадәр теленә гарәп-фарсыны мул кыстырып сөйләшә торган Сиражи мәхдүмнең урыс сүзләре белән дә милли теленең йомшак басуын чүпләтүе сәер иде. Хәләф шуңа игътибар итеп, бермәлгә үз хәсрәтен онытып, көтелмәгән урында елмаеп куйды.

— Син көлмә әле, мин ялгыш сөйләмим,— дип, Сиражи кырыслана төште.— Үзе ризалык бирсә инде... Уйлама, аерылып кайткан дип әйтүче булмас. Дөнья күрмәгән кеше икәнмен, мондый дөрес киңәш бирә алмас идем.

Мәсьәләнең асылына төшеп тикшергәннән соң, Хәләф тә Сиражиның сүзләре белән тулысынча килеште. Чаршау артында үз эше белән мәшгуль Шәрифә исә, ире ни дисә, шуңа күнәргә мәҗбүр икәнлеген белеп, үз уйларына чумды. Ир дип, мәхәббәт дип, шушы кадәр адәм оятларына калганнан һәм анасыннан, газиз атасыннан каргышлар алгач, ничекләр итеп, ничә ташлап чыккан туган йорт бусагасыннан башын югары тотып атлап керсен икән ул? Бу тормышын үзе теләде бит, һичкем аңа такмады. Кайчан зарланып сүз әйткәне булды? Ике катлы, күркәм җиһазлы, бай йортны калдыруы җиңел идеме соң аңа? «Җәннәттән тәмугка төштең!» — дип, абыстайлар ачуланганда да сер бирмәде ул. Һай, ниләр генә күрер икән бу газиз яшь башкайлары...

## XVIII

— Сүземнән чыкмассың инде,—дип сүз башлады Хәләф, Сиражи мәхдүм китеп берара вакыт үтүгә, Шәрифәне үз янына алгач. ,

— Атны да, сыерны да алырсың... Әллә кайтырмын, әллә — юк...

Бу сүзләреннән соң Хәләфнең күзләре дымланып, бәгыре өзгәләнгәндәй булды. Шәрифәнең аңгы-миңге калган чагы, тәне изрәгән, хәлсез төсле иде. Ике кешенең әңгәмәсенә колак салып торган өченче заттай, тагын бер җан иясе үзен белдереп, хәбәр китерде. Әйтәм соңгы вакытларда Шәрифәнең хәле китә иде.

— Хәләф, безнең балабыз булачак!..

Ире моны көтмәгән идеме, үз хәсрәтеннән айнып китте.

— Ничек?

— Җан керде үзенә! Иншалла, сугыштан исән-имин кайтырсың. Изге фал бу, беләсеңме!

Ничә көннәр күкрәгенә башын салып йөргән Хәләф аяк өстенә басты.

— Шәрифәм, мин янында булмамын, сакла берүк бу балабызны! Бердәнбер әманәтем — шул!

Болай ук үтенү артык иде...

Ике көннән никрутлар олавы авылдан чыгып китте. Кичтән старостаның бик каты кыйналган булуы сәбәпле, басу капкасын, озата килгән халыктан аерылып чыгып, Камалетдин мәзин япты. Барсы да үр башына йөгерделәр. Әмма аралар ераклашкан саен, көзнең вак яңгыры күз күремен каплады. Китеп бару-

чылар гүяки гаип булдылар.

«Әйләнеп кайта гына күрсеннәр, йа Рабби Ходаем!» — һәммәсенең телендә шул иде.

XIX

Аты-сыеры үз туган йортына китерелгәнлек сәбәпле, Шәрифә дә, алдан сөйләшеп куелганча, ирен озаткан көнне әнкәләренә кайтып керде. Соңгы вакытларда бик бетерешкән Фагыйлә абыйстай бу минутларны санап диярлек көтә иде. Кызы, бусагадан узып, төенчеген тоткан хәлендә басып калгач:

— Менә теләгем кабул булдымы? Зимагурың олактымы? — дип аягына басты.— Баланың анадан узганы юк әле! Ни әйттем, шул килде. Атаң башына җиткән ул зимагурың әйләнеп кайтмасын, дөмексен! Сугыш ише бәла җир йөзендә әнә шундый кешеләр күбәйгәннән килә ул...

— Әни!..

Әмма Шәрифәнең йөрәген өзеп әйткән сүзеннән генә Фагыйлә абыстай айнырга теләмәде, эченә җыелган ачуын һаман да чайкый бирде.

— Әни! Алай диярлек булсаң, мин кире китәм!

Фагыйлә абыстай акыл кабасында әйтер фикерен эрләп-нитеп тормады, җавап буларак, кызының йөзенә сүзләрен ямап та куйды:

— Китәр җирең бик ерак инде! Кая барырсың? Йә, сөйлә! Башыңны имансыз зимагур кулына салып ни күрдең?..

Шәрифә бер сүз дә әйтә алмады. Ана тәрбиясендә торып калды. Шушы көннән соң бераз сырхауланып алган Фагыйлә абыстай дә махсус рәвештә бәхәс башларга теләмәде. Тынычланып калды. Үзе дигәнчә дөньяның бара икәнлегенә кинәнеп, шушы елдан кабат гайрәте кайтты. Хафиз байдан соң бөлгенлеккә кадәр китереп җиткерелгән кибетенә тәртип салды, эш кәгазьләренә тотынып, әле җан бирергә өлгермәгән сәүдәләрен яңартып җибәрде. Фагыйлә абыстайның бу һөнәрләргә осталыгы барлыгына шикләнүче кибетчеләре бик авыр хәлдә калдылар. Үз кесәләренә тутырган акчаларын кире кайтарырга мәҗбүр ителделәр.

Әмма Фагыйлә абыстайның тормышы болай тиз генә җайлана торган түгел иде әле. Кызы Шәрифәнең йөкле икәнлеген белүгә, кабат хафага төште. Юк инде, китеп олаккан һәм мәңге кайтмаячак зимагурның баласын тәрбиялисе түгел! Имче карчык дәштереп, котылдырырга кирәк бу бәладән.

Шулай уйлады һәм эш тә итте. Атна кичендә, чана юллары ныгыгач, авылдан унбиш чакрым ераклыктагы пристаньгә ат чаптырды. Җиңел чанада толыпка төренеп утырган хәлендә дөньяның рәхәтлекләрен исенә төшереп барды. Пристаньле авылдагы им-томга оста хатынны тиз табып, йомышын аңлатты. Бик кыйммәт бәягә даруын алып, чәйләп тә тормастан, кире үз юлына ашыкты.

— Көнгә ике кашыктан артык кушмыйча чәйгә салып кына бирерсең! Өчкә китсә, көч булыр. Әгәрем ки, файда итәрлек түгел икән, тагын килерсең. Атна-атна ярымда хәл кылыныр,— дип имче өйрәтеп әйтә калды, Фагыйлә абыстай:

— Йа Рабби, бирсен Ходай!—дип, ут капкандай кабаланып ашыкты. Әмма кулыннан даруны ычкындырмады. Эшнең башын-ахырын уйламады. Ул карчыкны бик тә гыйлем, диләр, үз кызына Шәрифәсенә һични булмас әле!

## XX

Хәләфтән хат-хәбәр ирешмәде. Шәрифәнең исә йөге үзен шактый белдерә башлады. Әмма соңгы көннәрдә күзләре томаланып, башы авырта, кызыша һәм укшый, үзен әллә нинди зәхмәткә юлыккан төсле хис итә иде. Моның барысын да буендагы баладан күреп, кеше-карага, бигрәк тә әнисенә белдерәсе килмәде. Бер атна дигәндә телдән язды. Төннәр буе саташа, куркулыгы кузгала торган булып китте.

Серне белгән кеше бердәнбер иде, әнкәсе Фагыйлә генә. Эшнең ахыры яхшы бетәсенә сөенеп, кызына даруны бирә торды. Әмма кичтән урын өстенә яткан Шәрифә иртән аякка баса алмады. Төшкелек якынлашканда, авызыннан сары сасы сулар килеп, тәне зәңгәрләнә башлады. Бу көнне даруны тыеп торырга уйлаган ана эшнең ахырын мыштым гына көтеп йөренә иде, кызы аңа үтенеп сүз катты:

— Әнкәй?..

Инде ничә көннәр телсез калган Шәрифәнең моны әйтүенә, Фагыйлә абыстай дәртләнеп китте. «Әһе, котылдык бәладән!» — дип, тиз генә килеп тә җитте:

— Барысы да җиңел генә уздымы! Менә шулай, Аллаһы ташламасын, бәла китүчән ул!

— Әни...

— Йә-йә, кызым, әйт. Нәрсә диярсең?

— Мин үләрмен инде!

— Курыкма, балаң гына төшә торгандыр, бик авырдың бит. Менә, түз, бераздан барысы да бетәр, тазарып, ныгып китәрсең!

— Баламның инде иртәннән бирле җаны юк. Төш күргән идем. Имеш, түр өйдә, өстәл өстендә олы кара табут тора. Эче тулы кызыл кан иде, ут кабып, янып бетте...

— Саташу төше генә ул. Юк-барны уйлама, барысы да үтәр!

Әмма Фагыйлә абыстай бик нык ялгышты. Моңа кадәр укынган каргышлары кабул булу сәгате тупсадан кереп килә иде инде.

Урамда буран. Ак кар тәрәзәләргә килеп сарылды. Гүяки җир йөзен генә түгел, кешеләрнең күңелләрен дә пакьләндерергә тели сыман. Әмма кодрәте генә җитми. Бәлки шуңадыр тәнебезгә салкын йөгертә дә, буыннарыбызны туңдырадыр? Юк, кар аклыгы бәндәләрнең җан сафлыгы белән һичничек тә ярәшә алмый. Ул бары тик тереклекне генә юк итә, бетерә. Пакьлек һәрвакытта да яхшы дияргә ярамый. Җан әсәре бар урында каралык та булмый калмас. Гөнаһлардан тәмам азат кешеләр дә юк. Шуңа күрә дә борынгы әүлияләр аклыкка гөнаһ аша, аны үтү аша килгәннәр һәм шушы рәвешле гамәл йөрткәндә генә изгелеккә ирешү мөмкин дип уйлаганнар. Гөнаһның никадәр начар икәнлеген аңлаганнан соң гына сафлыкның бөеклегенә төшенергә мөмкин. Ә кыш, кар нәрсә ул? Кәфенлекне хәтерләтә түгелме?

## XXI

Шәрифәнең хәле яхшырмады һәм әйбәтләнәчәк тә түгел иде. Шулай да Фагыйлә абыстай эшне башкача чишелер дип көтте. Үзе дә мондый гына хәлләрне

кичергәнлектән һәм имче карчыктан теге даруны алдыртып, ире Корытай Хафизга белдермичә, кирәк чагында файдаланганлыгы сәбәпле, вакыйгаларның ахырында бәлаләр артта калачагын һич икеләнүсез белә кебек иде ул. Әмма, үз баласы булса да, кешене кеше кабатлый алмый, һәрьяктан охшаш түгел шул.

Кечке якта Шәрифә айнып киткән кебек тоелды. Тавышы да ачык һәм ягымлы иде. Фагыйлә абыстай аның янында калды. Агын һәм карасын уйлады, кызы көмәннән нигә котылмады икән дип башын катырды.

Төн уртасы җиткәндә Шәрифәне тулгак тота башлап, инде үле баласыннан котылырмы дигән өметтәге Фагыйлә абыстай кара коелып төште. Юк, бу тулгак кына түгел, үлем хәбәре иде. Йөзе агарып калган Шәрифәнең өстенә егылып, ана кычкырып җибәрде:

— Кызым, үлмә, кызым!

Шунда акылы да китәр иде, әмма Шәрифә күзләрен ачты һәм әйтә бирде:

— Әнием, ачуланма, мин үләрмен инде,— диде.

— Юк, юк, кызым, нинди үлү ди ул?

Өй эчендә тынлык урнашты. Бу төндә йокламаган йорт һәм ишегалды хезмәтчеләренең күңелләре дә нидер сизенә, гомергә усаллык белән дан тоткан карт эт тә оясына сеңгән иде. Хуҗаларының йокламавын сизенгән сыерлар да тавыш биреп, сур мөгезен кычкырткан кебек мөгердәштеләр. Болар барсы да әллә нинди генә шомлык тудыра, куркыта иде.

Шәрифә тагын күзләрен ачты. Гүяки дөньяны үзе белән алырга теләп йотылып карады. Фагыйлә абыстайның исә тәне буйлап калтырану йөгерде. Теләмәгән җирдән иман кәлимәсен кабатлады.

— Әни!..

— Әү, кызым, мин монда, янында басып торам! Миңа таба кара!

Әмма Шәрифә аны күрми, карашы күкнең әллә кай төшләренә таба төбәлгән идеме, әллә күзләренә түшәмнән ары һични чыгалмадымы, билгесез. Шулай да сүзләре ачык ишетелде:

— Әнием, минем каберем өстендә Коръән чыгарсың! Хәләфемне бик тә сагындым. Мәңге күрә алмам микәнни? Әманәтен дә үти алмадым... Әни... Коръән чыгарсың...

Йорт эчендә кабер тынлыгы урнашты. Шәрифә мәңгелеккә китеп барды. Аның йөзендә рәнҗү, каргыш, бәхетсезлек билгеләре иде.

— Кызым, Шәрифә!.. Балам минем...

...Кәфенлеккә төрелгән Шәрифә җылы гүренә озатылырга әзер иде. Яшь икән, бик аз яшәгән икән ул, санап карасаң. Бу дөньяның иң гүзәл һәм иң зур байлыгы булса да, унтугыз яшенә дә килеп җитәргә өлгермәгән.

Сугыш китергән кайгы-хәсрәткә тиң күрделәр Шәрифәнең вафаты хәбәрен. Аның хакында күп тапкырлар гайбәт сөйләп, телләрен чайкаган тишек авызлар да, гомерләрендә Шәрифә турында бары тик бер генә ишеткән бала-чагалар да җеназасына җыелган иделәр. Моннан биш ел элек кенә, Корытай Хафизның җир җимертеп йөргән чакларында нәселе менә шушы рәвештә өзелер дип һичкем уйламаган иде. Әмма Аллаһы тәгаләнең бирмеш көненнән узмыш юк икән ул. Фагыйлә абыстай, кызыңның васыятен онытма!

...1918 нче елның язындамы, кыш ахырындамы, сугышчы солдатлардан де-

путат буларак Казанга кайткан Хәләф үз авылына да сугылып чыгарга уйлады. Шәрифәнең вафатыннан соң акылы күченгән Фагыйлә абыстайның кышкы суыкта, станца юлында өшеп вафат булганлыгыннан хәбәрдар иде ул.

Корытай Хафизның йорт-җирен хезмәтчеләренә биреп, мал-туардан мәзингә өлеш чыгарып, хатыны Шәрифәнең кабере нурлансынга Коръән чыгуны авыл абыстаена йөкләп, озакка тукталмастан китеп тә барды. Шуннан бирле зимагур Хәләфнең кайдалыгын беркем дә белмәде. Әмма кайтып килмәгәе дип уйлаучылар шактый иде.

## ТӘКЪДИР ХӨКЕМЕ
*Повесть*

«Вәлиулланы бәхет күмде!» — дип сөйләнде авылдашлары. Хактан да шулай булса иде!..

Бәхет дигәнең сугыштан соң чатан калып кайткан, метр да кырык сигез буйлы һәм чытык йөзле бәндәне генә күмә алырлык булырга тиеш иде тиешен. Пленда, фашист тоткынлыгында ат караучы булып эшләгән дигәч тә, җиңү китергән шатлык-сөенеч, окопларны үтеп, яралы хәлдә әсир төшкән сугышчыны да урап узмаска, бере белән бирәсен бише белән кайтарырга бурычлы түгелме соң ул?

Бурычлы-бурычлы. Һай заманалар. Мужик кадеренең дә арткан, ә хатынкызның тиенгә генә калган чаклары да була икән!

Вәлиулла үзе, фашисттан чыккач, Сталин урманнарын аударганда, агач астына эләгеп, аяк сындырудан соң ирек алды, язның иң матур чагында, май уртасында илгә кайтып төште. Ил дигәне — туган авылы иде. Бихисап иксез-чиксез Рәсәй җирләре, тегеләре-болары да барсы бергә каләм тибрәтүчеләр телендә ил исемен йөртсә дә, халык «ил» дигән чагында үз төбәген генә күз алдында тота, калганы — ватанмы, чёртыммы шунда.

Ил һавасы тәнгә сихәтлек, җанга рәхәтлек алып килә!

Вәлиулла, титаклап-чатанлап йөрүенә карамастан, очып-канатланып ук кайтты. Аны олы һәм зур куаныч-бәхет көтеп торадыр шикелле иде. Үрдән туган авылы күренүгә, күңеле ярсып кузгалды, сөенече эченә сыймады, җырлап та җибәрде. Тавышы-моңы булмаса да, үзенә ярый шунда, күршегә керәсе түгел. Немец атларын караганда Вәлиулла җырлап җибәрсә, абзарның теге башындагы аранда ярым йоклап торган карт айгыр (нәсел өчен генә тотканнар үзен), яшәреп киткәндәй, башын югары калкыта да, чыдамын югалтып, кешникешни диварга тибә торган иде. Яратуы идеме аның җырчыны, әллә башкамы? Әмма Вәлиулла ул тирәгә килергә көне буе куркып йөри иде, белмәссең, хайванның башында нинди уйлар бардыр бит?..

Көн кичкә авышып, сәгать дүртләр-бишләр чамасыдыр. Бөгелмә комендатурасында озак тотмаган булсалар, ике көн алданрак та кайтып җитешер иде дә,

ярар, аларны ачуланып булмый. Документларын тәртипкә керткәч тә бик җиткән, үз эшләрен башкардылар бит, Хода бәндәләре шул. Зонадагы әфисәрләр төсле усал кыланырлармы дип көткән иде дә, юк, тыныч сөйләштеләр: «Предписание килеп җитсен, хәл итәрбез!» — генә диделәр дә бетте, сабыр итәргә туры килде. Шундый язуны айлар буе көтүчеләр дә бар икән. Вәлиулла ике көндә алгач, озын буйлы, кылыч борынлы бер мишәр татары:

— Катыгың каты икән, пәхетең куерган,— дип көйләп, хикмәтле сүз дә катып куйды.— Без, пряме, ай сузабыз, сезгә көндә китерә. Танышларыңдыр, ниуштo?!

Нинди танышлык ди инде ул, каян килсен. Шулай килеп чыкты Вәлиулланың, әмма дә мишәргә сер биреп тормады. Дәшми-тынмый китеп барды. Ике көн булды дигәндә Бөгелмәдән Дүсемгә, Минзәлә елгасының башланган җиреннән җиде-сигез чакрым түбәнгә урнашкан авылына кайтып иреште менә!

Үрдән төшкән саен, салам түбәле йорт-кураларның киртәләре вә агартылган диварлары, дөньяга текәлеп утырган тәрәзәләре ачыграк күренә башлады.

Урам тын иде. Тәрәзә төпләрендәге берән-сәрән яран гөлләр кояшны күзли. Нигәдер эт-мәче ише җан ияләре күренми. Сугыш зәхмәте аларны да кырган булса кирәк. Тирә-юньдә бүре ише корткычлар күбәйгән, диделәр бит. Аларның эше бу.

Әмма эт һәм мәчеләрнең дә юкка чыгуларына сәбәпче — ачлык-түбәнлек, авыр тормыш мәшәкатьләре икәнлеген уйларлык түгел иде Вәлиулла. Чөнки сугышка алынган көннән бирле туган авылын сагынып офтанды, монда рәхәт, бәхет-сәгадәт төсле тоела иде аңа.

Башта ындыр артлап, бакча башыннан гына кайткан иде ул. Аннан соң тыкрык юлын таптады, урамга кереп, сулга борылды. Инде хәзер атасы йортына да килеп җитә. Ни бер-бер этле җан очрасын, әллә бар да качып беткәннәр? Бакчакырда да адәм-фәлән күренмәде. Ни булыр бу?

Туып үскән нигезләре каршына килеп туктагач, Вәлиулла ирексездән елап җибәрде. Ни алга, ни артка бара алмады. Хикмәтле бер көч аны урам уртасына кадаклап куйгандай иде.

— Сагынып-очынып кайткан туган туфрагым, йортым-җирем!..— дип пышылдады ул. Хәле сәер иде.

Тәрәзә каршында болай кыланып торганчы, авыл башында ук кара туфракны кочып еласа ни булган иде? Юк шул, анда очынып кайтты, ул хакта уйламады. Менә хәзер туфрак тотты, сагышын чыгарта күңеленнән.

Ихаталар әлегә нык икән. Әмма барсы да ничектер җиргә сеңеп беткән шикелле күренәләр. Кая ди ул немецлардагы төсле киң амбарлар вә абзарлар, биек йорт-җир һәм текә кыеклар? И мескен, гарип, җимерек, кечкенә татар авылы, и шыксыз, тишек-тошык абзар-кура, өй-ни. И сөекле, кадерле, йөрәк түрендәге җылы учак — туган ил, туган авыл!

Вәлиуллаларның җилкапкасыннан чандыр, гәүдәгә калкулырак һәм җилкәлерәк, хәтта йөз-биткә дә шактый күркәм бер ир егет чыгып басты. Өстендә солдат киеме, аягында чабата иде.

— Абый, синме бу? — дип эндәште ул.

Таныды, энекәше Җаббар бит. Таныды, танымый димени? Кара, ничек үз-

гәргән, өйләнгәндер дә инде.

— Сәлам дип әйтимме, энекәш? Мин идем әле бу,— дип, каушаган тавышы белән сөйләнде Вәлиулла. Инде күзеннән яшь кипкән, күңеле утыра башлаган иде, тагын зиһене таралып төште. Кочаклашып күрештеләр.

— Абый... Абый... Исәнмени син, абый?!— дип сөенде энесе Җаббар.— Абый!..

— Исәнмени дип, исән шул, нишләп исән булмыйм, ди. Яшибез әле,— дип үртәлде Вәлиулла, кинәт тупаслана башлап. Шушы рәвешле үртәлеп-киреләнеп куюы файда бирде, күңеле урынына утырды.

— Нигә, күмәргә булган идеңме? — диде ул, ачуланып, җилкапканы үзе ача-ача.

— Юк ла инде, хәбәрсез югалуыңнан соң бит...— дип аклана калды урам ягында Җаббар.

— Без югалмыйбыз, белеп тор!— диде әкәмәт тавышы белән Вәлиулла.— Без югалмыйбыз!

Чатанлап ихатага узды, өй ишегенә кул сузды. Ишелеп китәрдәй торган өйалдының, ни хикмәт, тупса астындагы җыештырылган саламнар өстендә утырган кыртлый тавык усалланып чәрелдәде, нигез өсләрендә иске чыпта, урын-җир, кием-салым киптерергә җәеп салынган иде. Шушыдыр инде татарның бар булган кырык ямаулы олуг мал-мөлкәте, и бәрәкәтсез Чыңгыз токымы, и йоклаган ханнар нәселе, чабаталы морзалар...

Чинап кына ишек ачылды. Аннан Вәлиулланың әнисе Миңҗамал түти күренде. Бу тәбәнәк карчык кайчандыр кыздырылган шома борчак шикелле тере вә каты иде, хәзер куырылып-бөрешеп калган, күзләре һәм аяклары да бетерешкән күренә, кулында — таяк, күптәннән хезмәттәдер, шомарып-сөякләнеп беткән.

— Әни!— диде тыныч кына Вәлиулла.

Артыннан кереп килгән Җаббар куанычын белдерергә кодрәт таба алмыйча калды.

— Әни!..

Вәлиулла белән әнисенең күзләре очраштылар. Икесе дә калтырый башлады, Җаббар бер-бер артлы аларны күзәтте.

— Әни!

Әни кеше алга тартылды, аяк астына салынган такта башына чалынып китте һәм Вәлиулланың кочагына ауды:

— Улы-ы-ым! Улы-ым!—диде ул, берөзлексез кабатлап.

Сулышы утырды, хәле кайтты. Әмма һаман да шул сүзен кабатлады:

— Улым!

Җаббарын да болай ук дастаннарда җыру итәрлек рәвештә каршы алмаган иде. Вәлиулласы сөеклерәк иде микәнни? Биш ел хәбәр-хәтерсез, югалганнар хисабында йөргән һәм инде үлеләр исемлегендә атала торган улы бит бу. Ничек болай? Каян?

— Улым? Кайттыңмы? Улым, кайттыңмы?— диде ана, кабат хәлсезләнеп.— Улым?

— Кайттым, әни, кайттым! — диде Вәлиулла.— Тынычлан. Исән-сау мин!

Миңҗамалның йомышы булып тышка чыгуы иде, барысы да онытылды.

Ике ягыннан ике улы тотып өйгә алып керде. Сулышы кабат кайтты. Самавыр куйдылар.

Чәй янына Вәлиулла эре кисәк шикәр, кала икмәге һәм кәнфит боламыгы бирде.

— Болары — кучтәнәч,— диде ул, биштәреннән өч төргәк чыгарып.— Бөгелмә базарыннан авыз тәменә алдым.

Эндәшми-тынмый гына чәй эчтеләр. Араларыннан кара мәче йөгереп үтмәгән иде, юкса нигә болай телсез калдылар соң? Әллә Вәлиулланың сорауларга төксе генә җавап кайтаруларыннан куркыбрак калдылармы икән?

“Югары оч Вафа улы Германнан алтын сәгать, әнисенә шәльяулык, тагын әллә никадәр байлыклар төяп кайтты, өч көн бәйрәм иттеләр. Безнекеләр каткан шикәр белән җебегән кәнфиттән башка сөендерер нәрсә таба алмаганнар” дип сукрансынмыни инде Миңҗамал карчык? Нинди ахмаклык булыр иде. Юкка үпкәләп утыра бит, юкка!

— Улым, биш ел буена бер дә хатың-хәбәрең килмәде,— дип әйтергә җөрьәт итте ул.— Бер дә исеңә кермәдекмени соң?

— Аннан монда хәбәр йөрми иде шул,— дип әйтә куйды Вәлиулла.— Плен төшеп, әсирлек ачысын татырга туры килде.

Ана эндәшмәде, моның ни-нәрсә икәнлеген аңлый иде булса кирәк ул. Улы Җаббар белән сугыштан соң очрашкан минутлардан ук аларын гына төшенгән иде, шунлыктан дәшми-тынмый гына утырды.

— Аннан соң ике ел урман кистерделәр. Менә аягым сынып, чатан калмаган булсам, әле кайчан очрашыр идек тә күрешүләр насыйп итәр иде,— диде Вәлиулла һәм артык башка сүз сөйләмәде.

Ана кеше дә барысын аңлап алды, намазсыз башына дога да укып куйды. Исән-имин күренгән икән, шөкер Ходайга, мең шөкер!

Вәлиулла юлдан ватылып кайтса да, сузылып яткач, күзенә йокы кермәде. Көрәк-сәнәк саплап-яңартып маташкан энесе янына чыгып утырды.

— Әни бик бетерешкән. Нигә бу гомергә кадәр килен алып кайтмадың? — диде ул, Җаббарның күңеленә гүяки ике җәпле күзенең сорау сәнәге белән китереп кадап.— Кызлар юкмы әллә?

— Нигә кызлар булмасын? — диде энесе, сорау катыш җавап белән.— Бөтен дөньясы тол хәзер. Җиләк кебек кыздан телисеңме, тулып торган килен-кыркыннанмы, ирсез хатыннарданмы— һәммәсе дә бар. Вафа абзый улы Галимулланы хәтерлисеңдер. Әйе-әйе, үзеңнән бер яшькәме кече, каладан гаскәргә алынды. Көн дә хатын алыштыра дип сөйлиләр. Нәрсә инде, сөйлиләр дип, үзем дә белеп торам анысы. Хатын-кыз, солдаткалар тәмам ачыкканнар ир затына, ир-ат кочагына, хәмерен дә, башкасын да әзерләп көтеп кенә торалар. Галимулла гармунын тибрәндергәли, сызып җибәрә дә, и всү...

Җаббарның эш майтарган җиреннән коралы төшеп китте, татлы кыланчык сүзе өзелде. Вәлиулла, ихластан дәртләнеп, ирлеге уянган җиреннән айныгандай, пешмәгән энесеннән, аның уңышсыз фигыленнән көлеп утыра бирде. Авылда елап калган, кульяулыклар чигеп озаткан асыл кызы булмады, мәхәббәт сәгадәтенең татлы кояшы әлегә насыйбы белән тау артыннан чыкмаган иде.

Шулай да һәркемдә дә җан дигәннәре бар бит ул.

— Нәрсә, бөтен кызлар-хатыннар да бер калыптанмыни хәзер?—дип сорау бирмичә калмады Вәлиулла, күңеленнән моның шулай икәнлегенә ризалык белдереп һәм өйләнмичә, мәхәббәт газапларын чикми генә солдатка китүенә куанып. Менә шулай ул. Анда күпме батыр башлар, асыл егетләр калды. Мәхәббәт бәхете белән тулы иде бит күңел чүлмәкләре!

— Юк,— диде Җаббар, йөзенә сәерлек билгесе чыгарып.— Алай да күп түгел. Югары очтан бер-ике, түбән очтан берничә, дигәндәй,— дип, берьюлы өч-дүрт хатын-кызны атады. Вәлиулланың хәтере яңарып утырды. Җаббар телендә Фатыйма исеме аталуга, хәтта оятсыз балкыш белән күзләре уйнап куйды. Аһ, бу текәнең дә буе сынган икән. Һо, ничек йөртә иде үзен, ничекләр саклый иде?! Дөнья бу! Бервакыт шулай, уенда чакта, артыннан килеп кочкан өчен яңагына ничек суккан иде Вәлиулланың? Исенә төшерәсе булыр, чёрт! Белсен үз кадерен хәзер. Галимулла олтырагы диген, ха-ха-ха!

Вәлиулла ниятләп тә куйды: Фатыйма бу кичтә аныкы булачак, әйе, әйе, Вәлиулланыкы. Галимулланы дуслык хисе янына кушып, бәйрәм хисабыннан, кайту хөрмәтенә бер ярты — урыс малае белән сыйларга да...

— Монда аракы бармы соң, авылда? — дип сорап куйды ул Җаббардан. Анары: «Эһ, юлда ук, каладан алып кайтасы калган»,— диде үзалдына офтанып.

— Кибеттә иң ходовое шул инде, башка һични юк. Аракы — вүле,— диде Җаббар, елмаеп.— Алып кайтыйммы?

— Кирәк булыр. Мин — юлдан төшкән кеше, артык күренеп йөрү килешмәс бүгенгә. Әллә чыннан да барып кына киләсеңме?

— Рәт бар икән, нигә бармаска?

Вәлиулла берәмтекләп кенә кызыл, сары, яшел, зәңгәр кәгазь акчаларын күкрәк кесәсеннән чыгарды. Күп булмаса да, җитәрлек иде. Икене алырга дип кызыл-сары кәгазьлеләрне сузды. Болар үз кулына күчүгә, әмер үтәп күнеккән яхшы солдат төсле “честь” биреп, Җаббар чыгып та китте. Вәлиулла үзе керешеп, энекәше этләнеп маташкан унбиш минутлык эшне өзми-куймый башкарып та ташлады. Көрәк-сәнәк сап тапты.

Юк, Вәлиулла әвеш-тәвеш йоклап йөрмәс. Болайга барса, иң шәп кызны кочагына кертер, тешләшсә тешләшер. Әмма дә ләкин үз дигәне булыр. Европаны күргән, сугыш вә әсирлек ачысын татыган, дөньяны үз зиһененә җитәрлек дәрәҗәдә таный-белә башлаган, утыз яше дә тулмаган ир-егет өчен гүзәл кыз бастионын алу бер уен гына бит ул. Аксак аяк һәм буй тәбәнәклеге комачау итсә итәр, әмма дә хатыны чибәр һәм калку булыр. Вәлиулла, сайлагач-сайлагач, метрдан түгел, метр да siксән чамаларындагыны табар, үзенә туры килмәде, балалары буй белән масаерлар. Бетте, уйланды-ниятләнде һәм шулай хәл ителергә тиеш, башка төрле юлга бармаячак.

Урам якта Җаббар белән кемнеңдер сөйләшкәннәре ишетелде. Озакламый алар ишегалдына уздылар. Ияреп кергәне очып диярлек капланырдай иде үзенә шул чакта.

— Сәлам, Вәлиулла, кайттыңмы? Исән-сау гына кайттыңмы?— дип күреште энесе артыннан атлаган көр тавышлы кеше, уң кулын бер дә галәмәт җәеп җибәреп.

Култык астына кыстырган гармуныннан һәм бераз сакланып калган чалымнарыннан бу олуг ирләр кыяфәте белән ныгыган затның шулай да Галимулла икәнлеген чамаларга мөмкин иде. Һай өс-башлары, бер дә галәмәт икән: аякларында ялтырап торган яхшы хром итекләр — трофей, буй-сынына килешеп торган гәләфи чалбар һәм күтәрмә изүле, утыртма җилкәле әфисәрләр гимнастеркасы, ут чәчеп торган дүрт түгәрәк медаль... Кызыл Йолдыз ордены. Болар өстәмәсенә, җитмәсә, калын кара мыек (бераз буяган булса кирәк), артка җибәреп таралган кара чәч (бераз кояш йөгергән), әрсез күзләр, метр да сиксән ике, әллә тагын метр да сиксән биш чамалары буй, киң күкрәк, көрәктәй таза куллар һәм, иң шәбе, шәпләрнең шәбе — хатын-кызны юешләтә торган калын вәкарьле тавыш... Да-а-а, иң шәп хатыннар моныкы инде!

Шушы рәвешле күз йөртеп һәм зиһенендә фикер йөгертеп өлгерде Вәлиулла, шунлыктан кәефе дә кырыла төште. Гомере буе һәммә кешедән өстен чыгарга өметләнгән, үзен мескен итеп таныргa теләмәгән бәндәне Галимулла ишеләрнең сурәте дә чыгырдан чыгара, саруын кайната шул. Аһ, якаларын...

— Исәнме, дим, Галимулла!— диде Вәлиулла, сүзне икенче тапкыр кабатлаган төсмер чыгарып.— Кайттым әле менә. Карап-карап торам, йорт-җир таушалып беткән. Әни дә олыгайган,— дип, көрәк-сәнәкләрне җыештыра башлады.

— Баш исән кайткач, бүтәне — дөнья эше. Һәммәбезнең дә ихата бертөсле, күтәрелер әле,— диде Галимулла, җәелеп киткән кулын кесәсенә җыеп, авызын ерган хәлдә.

— Сез күтәрерсез анысы,— дип белдерде нәфрәт нәҗесенә буылган Вәлиулла.— Бу аяклар белән нәрсә эшләп булыр икән!

«Аяк белән түгел, кул белән эшлиләр аны»,— димәкче иде дә Галимулла, акылы куәт алып өлгерде һәм ул мондый вакытта иң кулай сорауны борчылганлык белән әйтеп куйды:

— Кайсы фронтта?

— Кайсы дип, Сталин фронтында,— диде Вәлиулла, Галимулланың моны барыбер аңламаячагын тәгаен гына төшенеп. Әмма Сталин дип әйтте әйтүен, тик күңеленә курку йөгерде. Бу исемне телгә алмаска ул үзалдына ант иткән иде югыйсә. Башны бетерәчәкләр, Себер җибәрәчәкләр!..

— Ә-ә, Сталинград...— дип сузды кунак.

Вәлиулла канәгать елмайды, үзен шулай дип танытуына күңеле булды, үпкә-турсаюлары коелып төште. Галимулланы шушы сүзеннән якын итә башлап, аның белән сыйланасы килде. Ни дисәң дә, чордашлар вә бер урам малайлары иделәр бит.

— Җаббар, кая, бәрәңге-ипи ише нәрсәләр юкмыни? Алып кайткансыңдыр бит? — дип, сорау-әмер тавышы белән әйтә куйды.

— Хәзер, абый,— дип, тегесе үз эшендә булды.

Ул арада әниләре Миңҗамал түти болдыр башына чыгып тотынды. Әллә нинди әкәмәт ялагай тавыш белән:

— И-и, Галимулла улым, керденмени? Менә сөенеч! Вәлиулла улым кайтты бит. Югалган җиреннән. Әле догадан гына кузгалдым. Хәл белешеп керүеңә рәхмәт яусын. Бергә уйнап үстегез бит. Алты яшәр юлдан кайтыр, алтмыш

яшәр хәл белешә керер. Йә, чәебез дә кайнап утыра. Нигә өйгә узмыйсыз? Чакыр, улым, кунакны,— дип сөйләнде дә сөйләнде.

Бергә уйнау, дигәннән, алай ук түгел иде инде ул түгелен. Галимулла малай чактан таза һәм нык бәдәнле булды, Вәлиулланы кыйнап кына үстерде. Бер дә тынгы бирми иде. Аныңча түгел икән, бетте, касык төбенә берне генә тортә, бөгәрләнеп очасың.

Болары Галимулланың хәтерендә дә бик шәп сакланган булуга карамастан, ул, тәмам җайга алып:

— Шулай шул, шулай,— дип, җөпләгәндәй итеп куәтләндерде Миңҗамал түтинең сүзләрен.— Хәзер дә бергә йөрербез. Вәлиулла иң затлы, иң чибәр кызны алып кайтыр, түр башына утыртып куяр! Шулай бит, Вәлиулла? — диде дә көрәктәй куллары белән аның җилкәсенә суккалады.

Миңҗамал түтинең сөекле-сөексезе сер бирмәскә тырышты, сынын катырып куйды. Әмма Галимулланың кулына кем чыдасын? Изелеп китте. Әнисе моны сизмәде, Галимулла аңламады. Шулай да Вәлиулланың күңеленә татлы хисләр яккан, сары май булып агылган сүзләре ни җитте бәндәне дә биһуш итәрлек һәм авыртуны оныттырырлык иде. Миңҗамал түти дә куанды. Галимулла белән дуслык тотса, югалмас улы, югалмас.

— Бик шулай, Галимулла улым, бик шулай,— диде ана, куанычы тагын да куш килеп.— Гел юк җирдән ике малай үстердек бит, гел юк җирдән.

Җаббар өйгә чакырды. Эссерәк иде. Берәр стаканны бушатып, суык бәрәңге белән таза телем арыш ипиен бөкләп куйгач, “отставной”ларга җан керде. Галимулла, тез башына гармунын җайлап, әллә кай тарафлардан урап-урап килеп, «Кара урман» көен сыздырып ук җибәрде һәм сузып җырлый башлады. Тавышы шәп, уены яхшы иде егетнең. Бирсә бирә икән Ходай тәгалә!

Алар озак шушы рәвешләре белән утырдылар. Вәлиулла, ахырга таба исереп китеп, үзенең аһ-зарларын сөйләп ташлады. Галимулла һәм Җаббар аның сүзләрен тыңладылар да, тыңламадылар да. Күргән баш күргән инде. Әйе, егет сөйләвен сөйләде, әмма әсирлектән соң урман аударганда үзен агач басуы хакында гына ләм-мим эндәшмәде. Белми генә торсыннар әле. Авылга солдатлар күп кайткан, ә асыл ир-егетләрдән шактыйлары хәбәрсез югалган, һәлакәт тапкан, чит-ят туфракта ятып калган. Әсирләрдән илдә күренгән беренче кеше әлегә Вәлиулла гына икән. Шунлыктан арада бу хәлләрне аңларлык бәндә әллә булыр, әллә юк?..

Икенче яртыны төгәлләгәндә Җаббар ләх булган, Вәлиулла, әллә юл газабыннан арып, әллә башка сәбәптән, сәкегә үк түнеп йоклап киткән иде. Галимулла үз өлешенә тигән стаканны күтәреп аударды, Миңҗамал түтигә рәхмәт әйтеп, җай гына «шуып» чыгып китте. Югары очка таба менгәндә гармунын «Урам көе»нә сыздырып җибәрде. Ераклашканнан ераклашты. Инде авылга төн төшкән иде.

Кемнең-кемнең, әмма Галимулланың әйләнә-тирәдә абруе зур. Колхозда счетовод булып эшли, кичләрен дә йоклап ятмый, яшь килен һәм кызларның күңелләрен күреп йөри. Фатыйма «явыз» аны кунарга да калдыргалый дип әлгәрерәк сөйләштерә иделәр, хәзер андый-мондый гайбәтләр ишетелми башладылар бугай?

Галимулла бер атна буена күренмәде. Отчет белән район үзәгенә киткән диме шунда? Ә Вәлиулланың туган авылында эшләре пешмәде. Ни өчендер ят күрделәр үзен. Кәкре аяк Миңсылуга тикле, сүз катып белештерә башлауга, кырт кисте, якын да җибәрмәде:

— Пленный! — дип мыскыллады.

Моның сәбәбен Вәлиулла кайткан көнендә үк артык сөйләшеп ташлавыннан, Галимулладан күргән иде, менә юкә чыбык буйлап аларның йортларына да хәбәр иреште. Авыл советына комиссариаттан кеше килеп, Вәлиулла хакында аны-моны белешеп, фашист кулында әсир ятканлыгын сөйләп, уң-сул күзне аек тотарга кушып, халыкны колаклы итеп киткән икән.

Моны ишеткәч тә Вәлиулла хәлләрнең бик үк шәптән түгеллеген төшенеп алды. Дүсемдә кыз чыкмаячак аңа, әйе, әйтте, диярсез. Хәтта Минзәлә елгасын кирегә борып агызсын, барыбер юк.

Үз авылларында рәт тапмаган егет күршегә йөгерә инде ул.

Ә Вәлиулла арырак карады. 12-15 чакрымнар гына ераклыкта булмае, Рангазар авылына төбәп юл алды. Эш белешеп, каралты-куралар төзекләндерергә яллданачак ул. Балта эшен кулы белә төсле генәме соң, ятып та тора инде менә. Татар белән Германда гына туа ул шундый осталар, төгәллек кирәк, төгәллек, җитди караш!

Рангазар ачык күңеллелек белән таң аттыра торган авыл булып чыкты. Вәлиуллага һичбер кыңгыр караучы очрамады. Эше дә табылды тагын. Колхоз утарларын төзекләндерәсе, кайда тотка сугасы, анда киртә тотасы, монда түбә ямасы икән.

Квартирга дип бер тол хатын йортына төшерделәр. Әмма хуҗабикә буласы бу юан вә тупас зат алдан ук шарт куйды:

— Мунчасын ягармын, ашарына пешерермен, әмма йоклавын лапас сәндерәсендә йоклар, җаен табар, сузылып ятар, беләм мин аларны. Буе җитәме-юкмы, хәзер ата үрдәк төсле үрмәлиләр. Юкса мин күршеләрдә кунармын!

— Юк ла инде,— дип, канәгатьсезлек белдерде Вәлиулланы китерә килгән бригадир.— Ким-хур булмассың!

— Алай түгел, кеше бар, тел бар,— диде тол хатын.— Алай түгел ул, энем, кем!..

— Ярар,— диде Вәлиулла, күңеленә яшергән хәлдә генә уй йөртеп.— Печәнлектә урын иркен, һавасы саф дигәндәй, шунда йоклармын. Бер генә атнага чыдарлыктыр әле.

Шулай килештеләр. Вәлиулла бер караңгыдан икенчесенә кадәр эшләде, арып-тынып кайта да, печәнлектә изрәп йоклый торган иде. Тол хатынның кулы тәмле, ризыгы туклыклы икән. Көннән-көн Вәлиулланың сын-беләкләре тыгызлана барды.

Әмма шушы өченче төннең икенче яртысында шәп кенә итеп яңгыр яуды. Печәнлек дигәннәренең салам түбәсе бетешкән шул, Вәлиулланың бар җире лач су булды. Барып, хуҗабикәнең өй тәрәзәсен какты. Эшне аңлатып бирде. Колхоз эшендәге кешегә мондый вакытта ишек ачмау ярыймы соң инде? Башка чарасы калмагач, тол хатын Вәлиулланы эчкә уздырды. Әмма егет әрсез булып чыкты, хуҗабикәнең урынына менеп, җылыга кереп ятты һәм үз дигәнен эшлә-

де. Әллә шулай килеп чыкты? Баштарак киреләнсә дә, бара-бара, ир кулы тиеп китүгә, сынды хатын, сынды. Сынды һәм төпләнде. Вәлиулла шул төннән соң печәнлектән җылы кочакка, йомшак урын-җиргә чумды. Күңеле эштән кайтты, этлеге артты.

Шулай соңгы көннәренең берсендә утарлар ягыннан, киртә тотып бетергәч, иртәрәк кайтып килә иде, чишмә буена махсус юлыгып, бер матур гына кызга тап булды. Буе, уенда йөрткәнчә үк булмаса да, метр да җитмеш-сиксәннән чак кына ким иде. Һәрхәлдә, Вәлиулланың үзенә шул чама күренде.

Һай, нәкъ шушындый хатын кирәк бит аңа. Аһ, буе да буе. Ул гынамы соң әле? Ну, егетләр! Озын кара чәч толымнары, туры гәүдәсе, таза аяк вә беләкләре, калку күкрәкләре! Кем кызы икән ул? Егете бармы?

Кемнән диген әле, хуҗабикәнең үзеннән белеште Вәлиулла. Кияүдә түгел, ди. Шәрифулла кызы Сабира икән ул. Йөргән егете сугышта хәбәрсез югалган. Бик асыл зат булган. Башка очрашкан кешесе-нәрсәсе юк икән.

Бу хәбәрне ишетүгә, Вәлиулланың күңеле гөлбакча кебек чәчәккә күмелде. Күктән көткән бәхетен җирдә тапты һәм бу кичтә кабат печәнлеккә менеп ятты. Әмма күзенә йокы кермәде. Клубка чыгарга ниятләде. Түбән сикереп, егетләрчә җәһәтлек белән урам капкасын гына ачкан иде: «Кайда соң боларның клуб дигән нәрсәләре?» — дигән уй акылын чорнап алды. Ничә көннәр торып та, әллә нинди сәер хыялларда йөзеп тә, шуның кайдалыгын белешмәгән бит, ахмак. Кирәге чыкмады шул.

Вәлиулла кузгала алмыйча бераз басып торды. Хуҗабикәнең тәрәзәсенә күз салды. Әллә кем, убырлымы карап торадыр төсле булды. Күңеле шикләнеп, аркалары чымырдап куйды. Тәрәзәдән йолкып диярлек күзләрен алды да урамның икенче башына шылды. Бу өркүеннән озак айный алмый барды. Күптән, бик күптән андый курку хисен кичергәне юк иде бит. Балалык хатирәсе кебек булды ул аңа. Дерт итеп курку-шикләнүнең дә яхшылыгы бар икән.

Вәлиулла ничә озын вә авыр еллар буена изелүне тоеп яшәде. Германда да, Советта да аны шушы мескенлек ташламады, «кара сакалына» әверелде. Ә менә авылда яшәве, чибәр һәм буе метр да сиксән чамалары булган кызны яр итеп хыялланулары Вәлиуллага шул изелү тойгысыннан котылырга ярдәм итеп, кимхурлыкларны оныттырганнар иде.

Болар урынына гадәти кешеләрдә була торган хисләре уянып, алар бала чагын исенә төшерделәр, ул үзен сабый кебек хис итә башлаган иде. Хәтта ялгыз хатынның җылы кочагы һәм симез күкрәкләре дә аннан ана баласы ясаган булган икән. Әмма хәзерге өркүенең яхшы бер гамәл икәнлеген әлегә ул төшенә алмый, малай чагындагы төсле шушылай бичураданмы качып баруы иде.

Тәрәзәдә чыннан да бер зат бар иде шул. Ул — озын толымнарын туздырган хуҗабикәнең сыны-йөзе иде. Вәлиулла аны күргәч куркып китте. Хуҗабикә бу хакта башына да китермәгән, йокысыз җиреннән торып, квартирантының урамга чыкканын күрүгә, күңелендәге кызыксынудан: «Кая бара бу бәндә?» — дип карап кына калуы иде. «Әллә соң Шәрифулла кызы Сабира артыннан китүеме, аксак хәерсезнең? — дип пошаманга төшми калмады ялгыз башы.— Булыр, асыл зат кызларны да карачкылар кулына калдырды бу сугыш!»

Сыздырып уйнаган гармун тавышына таба килеп чыкты Вәлиулла. Димәк,

клублары да шушы тирәдә генә боларның. Әмма ул ялгышты. Гармун тартучылары әллә кем түгел икән; биш сәрхуш утыралар мыгырдап-җырлашып.

— Егетләргә сәлам дип әйтик... Клубыгыз кайда сезнең?— диде Вәлиулла, соравы белән аларның җан ләззәтен таратып җибәреп.

Ишетеп алдылар, җырдан тукталып тындылар.

— Ни дисең?

— Клубыгыз кая, дим!

— Кайсы авылныкы үзең?

— Моннан күренми,— диде Вәлиулла, сер бирмәскә тырышып, әмма ялгышты. Җавабы тупас булып аңлашылды.

— Алай икән... Алайса клубыбыз да күренми,— дип төртеп куйды болар.

Вәлиулла уңайсыз хәлгә калганлыгын төшенеп алды. Җавапсыз гына китәргә кала инде аңа хәзер. Нәрсә эзләдең — шуңа барып төртелдең. Яңадан башлап авылын да әйтсә, барыбер юл күрсәтмәсләр. Юк, яхшы чагында китеп котылуы дөресрәк, әллә нәрсә кыландырып ташларлар. Хәзерге кешедә иман юк бит ул.

Вәлиулла үкчәсен күтәрде. Арырак атлавы булды, тегеләрнең берсе эндәшә калды:

— Тукта әле, кем... Вәлиулла түгелме соң син?

Егет шым булды. Колаклары торды. Таныш тавыш. Карлыккан, әмма көр һәм ныклы итеп кем сөйләшә соң монда Галимулла төсле?

— Шул үзе дип әйтсәм, ни диярсең?

— Точно, шул үзе! — дип сөенде теге.— Кил әле бирегә, Вәлиулла. Бу мин бит, Галимулла! Танымыйсыңмы әллә?

Ул, чыннан да Галимулла иде. Ничекләр монда килеп чыккан, хәерсез? Хатын-кызга сап булу өчен йөридер инде!

Вәлиулла алар янына борылды. Галимулла торып баскан, кочаклап ук алырга әзер иде.

— Һо, сине монда дигәннәр иде, дөрес икән. Яхшы хатынга кергәнсең дип тә ишеттек үзеңне. Дөресме? — дип, Вәлиулланы култык астына кыстырып та куйды. Үзе һаман сөйләнде:

— Минем монда дустым яши. Таныш бул. Чех өстенә бергә барып кердек үзе белән. Габдулла туганым дип белерсең. Йә-йә...

Вәлиулланы башлаган аракы белән сыйладылар. Хәл-әхвәлләрен белештеләр, әмма хатын-кыз мәсьәләсендә ләм-мим сүз чыкмады. Галимулла дусты янына хәл белешеп кенә килгән икән. Анда-санда күрешкәләп торалар үзләре, берсен-берсе онытмыйча.

Бу авылда клуб юк, сугыш елларында балалар йорты иткәннәр дә, яңасын һаман күтәрә алмыйлар, ди. Яшьләр болында гына җырлашып бииләр, күңел ачалар икән.

Чыннан да авыл башыннан, еректан бик тонык кына аларның гармунда дәртле көй сибүләре ишетелгәләп тә киткәли. Мәгәре тагын аз гына атласа, Галимулланың гармуны бутамаган булса, Вәлиулла шул тирәләргә барып чыгасы да икән. Хәзер кузгалып китә алмый алар яныннан. Яхшы түгел, кушылды бит!

Вәлиулла алай да боларны күндерә алды. Яшьләр тирәсеннән бер әйләнеп килделәр. Эзләп барган Сабирасын гына таба алмады. Сораштыруны кирәксез

санады. Әмма Габдулланың авышып йөргән кызы очрап, егетне аерып алды һәм алар да югалып алдылар.

Инде яшьләр дә таралышты. Кызлар, үзләренә ияртеп чыккан эне яки сеңелләрен җитәкләп, кайту юлына төштеләр. Артларыннан пинжәкләрен җилкә очына элгән егетләр иярде. Кайсылары җырлаган була, башкалары сөйләшә иде. Артта Галимулланың көлеп алганы ишетелде. Дөньяга ямь кайткандай тоелып калды.

— Галимулла, әйдә, сыздырып җиффәр әле гармуныңда! Монда синең кебек уйный белүчеләр юк бугай! — дип тәкъдим итте дусты янына килеп баскан Вәлиулла, авылдашын дәртләндереп. Күрсеннәр әле кем икәнлекләрен!

Мондый чакларда Галимулла ялындырып тора димени, әллә нинди әкәмәт борылмалы-сыгылмалы итеп көйләтеп, тальянында уйнап та җибәрде. Барсы да «һай!» итеп куйдылар һәм алар янына тартылдылар. «Сарман көе» бөтен кешене үзенә җыя, бәгырен суя, күзләреннән яшь китерә ала торган сихри көчкә ия икән. Менә бит ул ничек!

Галимулла күңелле кеше шул. Чак кына тагын бер кызга ияреп тә китмәде. Вәлиулла комачаулап калдырды. Габдуллаларда кунып китәргә сөйләшенгән исә дә, аның кайтканын көтеп торырга теләмәде, иртәгә таң белән идарәгә җитешәсе бар икән, Вәлиулла янында гына төн уздырырга булды.

— Шушы сәндерәдән генә йолдыз санап ятам дисең инде алайса,— дип көлде Галимулла.— Өйгә кереп, хуҗабикә куенында рәхәтләндереп кочак җылытырлык урын юк идемени?

Мондый мыскыллауны Вәлиулла күтәрә алмады. Хәлләрне сөйләмәм дигән иде дә, әйтми булмас инде, адәм рәтеннән бөтенләй чыгарып ташлар дип фикер йөртте.

— Бүген син барга гына шушындый «хөрмәтне» сайладым. Моңа кадәр җылы куен рәхәтеннән чыкмадым!—диярәк мактанудан сүзен башлап, барысын да сөйләп ташлады. Хәтта Сабира хакында да әйтте Вәлиулла.

Авылдашы телсез калды. Нәрсә дияргә дә белмәде. Ярты карыш буе булмасын, үрелгәне сандугач ук түгелме? Юктыр, әллә нәрсә күреп кенә саташкандыр әле. Галимулла менә шулайрак фикер итте. Әмма Вәлиулла татлы хыял диңгезенә гарык булып чумган иде. Менә бит, күптән уйлап йөргәннәре тормышка ашып китәр. Бер ир-егеткә дүрт-биш хатын-кыз туры килә, арадан иң шәбен сайлап алмасмы соң ул? Үзенекен өзеп калдырмаячак. Тик менә Галимулла гына комачаулый күрмәсен. Ник әйтте инде ул аңа? Мәгәрем ки шул Сабирага күзе төшеп, Вәлиулладан тартып алу хыялына керсә, бетте диген, көн күрсәтмәячәк үзләренә.

Хәзер үк килешеп куярга кирәк.

Шул уйлар белән башын катырган Вәлиулланың күзенә йокы кермәде. Сабираны электән йөргән кызы итеп тоя, үзенеке итеп хис итә башлады. Әллә нигә генә Галимулладан көнләшеп, аның юлга аркылы килүеннән курыкты. Күңеле яман эш сизенде. Тартып ала күрмәсен, Алла сакласын!

— Сабирага өйләнә калсам, сиңа ике ярты куярмын! —диде Вәлиулла, авылдашын үз җәтмәсенә алдап кертергә теләп.

— Ярар...— дип мыгырданды Галимулла үзалдына, йокы аралаш.

— Әйткән сүзме?

— Ярар...

— Килештек!

— Ярар...

Галимулла борылып ятты. Ул арыган, ә иртәгә таң белән китәсе, идарә йорты ачылуга кайтып җитәсе дә бар.

— Йокла инде...— диде ул, үтенеп.

Әмма Вәлиулла озак боргаланып ятты, йокысыз аптырады. Төн уртасында хуҗабикә ишегалдына чыгып керде, каралты-куралары тирәсендә сөйләнеп йөренде:

— Ут-күз төшерә күрмәсеннәр, мәлгуньнәр!

Монысын Вәлиулла ачык ишетте. Янына кереп, күңелен күрергәме әллә дип тә уйлады. Әмма Сабира хакындагы татлы хыяллары тыеп калдылар аны.

Галимулла таң белән китеп барды. «Кыз сорарга кирәк булса, мине чакыр, җырлатып алып кайтырбыз!»—дип тә әйтте әле йокы аралаш саубуллашып калган авылдашына.

Вәлиулла бу иртәдә төш күрде. Имеш, болар — өчәү: берсе — үзе, икенчесе — Галимулла һәм өченчесе тагын бер күркәм генә ир Сабираның каршына килеп чыктылар. Мескен кыз уңга-сулга тартылды. Әниләре дә монда гына икән. Галимуллага тотып бирделәр үзен. Әмма Галимулла дигәннәре Вәлиулла үзе икән. Сабира теге өченче ир ягына йөгерә, ә Вәлиулла аның башына йөгән сала. Имештер, Сабира түгел, бозау икән ул. Әмма сөт бирә икән. Ничек болайдыр?

Вәлиулла уянып китте. Иртәнге сигезләр җиткән. Озак йоклаган бит. Хуҗабикә дә эшкә китеп барган. Ишек төбендә икмәк һәм сөт калдырган анысы.

Болар белән ризыкланганнан соң Вәлиулла, балтасын култыгына кыстырып, чатан-чотан атлый-атлый, колхоз амбарлары ягына таба юнәлде. Әмма бүген күңелендә эш дәрте шулай ук юк иде. Атлар араны яныннан да тыныч кына үтеп китә алмады. Бахбайларның уйнашып кешнәүләре күңелен кузгатты. Гүяки аны Эмма чакырадыр кебек иде. Немец кызы, сары чәчле, зәңгәр уйчан күзле, авылның яшь хатыны.

Вәлиулла, пленга төшкәч, баштарак “качып булмасмы” дип тә уйлаштыргалый иде. Әсирләр арасында тәвәккәлләре дә булмады түгел. Әмма аларның язмышы койма артында атылу, яки этләрдән талатылып, газ камераларында агулану белән тәмамланды. Боларны һәркем белеп тора иде? Бу хакта шактый күп сүзләрдән соң, Вәлиулла тоткынлыктан котылу хыялын күңеленнән бөтенләй чыгарып ыргытты, шуның аркасында барысын да карышусыз үтәүче колга әверелде.

Көннәрнең берендә аларны урман чистартырга китерделәр. Лагерьлары Берлин янында ук иде. Кичкә кадәр армый-талмый эшләде ул. Сакчыларда әллә ни уяулык сизелмәде. Карт солдатлар. Аннан соң, фашист оясында бул да, чыгу-качу хакында хыяллан инде, ахмак. Әмма урман һавасы күңелләрне кузгатып җибәрде. Ирек исе килә иде аннан. Вәлиулла үзен тоткынлыктан азат кеше дип хис итте. Башка әсирләр дә шушындый уйлар белән «агуланган» булганнар икән. Кич эңгере иңә башлагач, аларны куып лагерьга китерәселәр иде. Шул исләренә төшеп, күңелләрендә туган рәхәтлек хисләре чәчелеп китте. Ирекне

югалтырга теләмәүдән аның күкрәгендә тагын ургып-ургып тоткынлыктан качу уе кайнады, тынычлыгын бозды. Мондый кичерешләр һәммә әсирне алмаштырган кебек итте, иңнәренә канат бирде.

Карт сакчылар, бер урында өелешеп, нидер хакында сөйләшә иделәр. Качарга уңай. Моннан файдаланып, өч кеше өч якка ташланды. Әмма сизгер этләр тавыш куптарды һәм, башка тоткыннарның күз алдында качакларны атып үтерделәр.

Әсирләр эштән куылып кайтты. Бу вакыйгадан соң Вәлиулла үз язмышы белән уйнамаска карар кылды. Коллык дәрәҗәсен үстерде. Хәзер ул, хәтта сак астында калмаса да, качу хакында уйламаска кирәклегенә төшенде.

Тоткыннарны төрле авыл эшләренә вакыт-вакыт берничә айга алып китә торган иделәр. Буе кыска булганга, Вәлиулла кебек хезмәтче һичкемгә кирәк булмады. Әсирләр арасыннан кем дә кем шулай эшкә алынса, бу кешедән көнләшә иде ул.

Әмма бәхете бар икән. Аны да алдылар, тырыш вә күндәмлеге файда итте. Ялгызын бер хуторга китерделәр. Ат карау эшен йөкләделәр. Монда таныштышул Эмма — гади авыл хатыны белән. Ире Сталинград сугышында һәлак булган. Балалары булмаган.

Вәлиулла немец телендә аз-маз сукалый иде. Шул ярдәм итте. Вакыт-вакыт Эмма атларга укол кадарга килә иде. Мал врачы икән. Вәлиулла аңа ярдәм итә. Тотышып тора. Хатын үзенең баласы булмауны бик авыр кичерә, хәтта яшь колыннарын ияртткән бияләрдән дә көнләшә, мондый мизгелләрендә, битен баскан сары-көрән сипкелләре каралып беткәндәй тоела. Шунлыктан ул Вәлиулланы шаярткалау гадәтенә кереп китте. Егет баштарак шикләнде, юри кыландыра дип уйлады. Әмма ирлеге уянып, бер килүендә Эмманы саламга екты. Хатын карышмады. Вәлиулла беразга аптырап калды. Ярый торган эш булыр микән? Юри шулай кыланмыйммы?

Эммага ир тәне кирәк иде. Вәлиулланы изүеннән тартып алды да тәвәккәлләргә мәҗбүр итте. Алар бер-берсен ошаттылар. Вәлиулланың егетлек укасы коелды. Төз басып йөри башлады. Ул вакытларда аның һәр саны төгәл, хәле яхшы иде. Ат карау сәбәбе белән Эмма да ешрак килә торган булып китте һәм берсендә үзенең буйга узганлыгын хәбәр итте, куанычы эченә сыймый иде. Вәлиулла исә өректе, агарынды, каушады һәм бу хатын янына кабат килмәскә ант эчте. Ул-бу билгеле булса, атачакларын белә һәм аңлый иде ул. Әмма Эмма да ахмак хатын түгел икән. Йөгенең кемнән икәнлеген һичкемгә сиздермәде. Имеш, шәһәрдә бер танышы бар икән, шуның бүләге дигән хәбәр таратты. Бер яктан, Вәлиулланы шундый эше өчен яратса, икенче яктан, куркаклыгына әрни, ә өченчедән, егетнең дә хәлен аңлый иде.

Өч айдан Вәлиулланы кире лагерына кайтардылар. Ул арада татар тоткыннары Германиягә каршы фетнәдә гаепләнде һәм аларны Франциягә олактырдылар, аннан чехларга китерделәр...

Калганнарын Вәлиулла исенә төшерергә теләми иде. Барысы да артта калды бит инде. Сугыш китермәгән имгәклекне Совет бирде аңа, аягын ни мәсхәрә ясады...

Атлар кешни. Араларында Эмма йөридер кебек булып китте Вәлиуллага.

Беләсе иде, исәннәрме икән? Кеме туды икән? Кызмы, малаймы? Исеме ничек? Ни дисәң дә, Вәлиулланың да баласы бит ул. Малайдыр әле, малайдыр! Кемгә охшаган икән?

Вәлиуллага рәхәт булып китте. Герман илендә баласы үсеп ята, нәсел ядкәре. Үзе дә хәзер иректә. Метр да җитмеш-сиксән буйлы кыз алачак, тормышын көйләп җибәреп, итәгенбала белән тутырачак. Болар инде язып куелган һәм шулай булырга тиеш. Күңеле сизә, җаны тели.

Амбарда эш артык күп түгел икән. Биш сайгакны алыштырды, кыйшаеп төшкән ишек тупсаларын күчереп утыртты. Шунда кайдандыр көлешеп сөйләшкән тавыш ишетелде. Һай, монда кызлар-хатыннар амбар эчләрен акшарлау-агарту белән мәшгуль икән бит!

Юк эшен бар итеп, Вәлиулла алар тирәсен урап узды. Һәрберсе аерым амбар эчендә эшлиләр, әмма бергә җыелышып әңгәмә коралар, гайбәт саталар, шулай ял итеп тә алалар икән.

Вәлиулланы күрүгә, шикләнеп, урыннарыннан куптылар, тиз-тиз таралышып та беттеләр. Егетнең күзләре үткен булып чыкты. Сабира амбарлардан өченче бүлемдә эшли икән. Вәлиулла туп-туры шунда килеп керде. Зур эш майтарган кеше кебек тегесен-монысын карап йөри башлады. Сабира оялып кына йөзен яшергәндәй итте. Ай-һай тәүфыйклы бала икән үзе, рәхмәт яугыры!

«Ничек сүз катарга, кайсы баштан?» — дип баш ватты Вәлиулла. Тамак кырган булды һәм бер сайгакның арадан сыгылып-сыгылып киткәненә игътибарын юнәлтеп:

— Ашлыкны күтәрә алмас бу,— диде.— Кубарырга кирәк, ашыгып агарткансың.

Сабира моны орышу, эштән гаеп табу сүзе дип аңлады, башы түбән иелде. Бәрәкаллаһ!

Моны сизеп алган Вәлиулла тагын да катырак кыланды:

— Совет малын исраф итү бу. Белеп торгансыңдыр әле, юри шулай эшләгәнсеңдер!

Сабира бөтенләй бөгелеп төште.

— Абый, мин белмәдем бит,— диде ул, еларга җитешеп.

— Белмәсәң, әйтергә кирәк иде. Совет әйберсе, колхоз малы, әйе!

Кыз изелде. Өркүе йөрәгенә капты. Хәзер чыгып йөгерәчәк иде. Вәлиулла йомшарта төшәргә өлгерде:

— Ярар, кешегә әйтмәбез! Аркылыга такта гына кагарбыз. Быелга чыдар. Берни булмас,— диде.

Кызның кулыннан эш рәте китте, әмма ул чыгып йөгермәде. Олы күркәгә дә кечкенә козгын тырнагын батыра ала иде хәзер. Вәлиулла, моңа кәефе килеп, сораша бирде:

— Сабира бит әле син, әйеме?

— Әйе, абый, Сабира мин.

— Әтиеңнең исеме Шәрифулладыр бит?

— Әйе, абый, Шәрифулла. Боларның барысын да кайдан беләсез, абый?

— Мин белмәгән әйбер юк.

— Алай икән.

— Менә атна-ун көннән синең кулыңны сорап килерләр.

— Нигә?

— Нигә дип, бәхетеңә сөен. Хәзер һәр иргә биш хатын-кыз туры килә, аннан да күбрәк булмаса. Кыз баланың йортка ирешүе шарт. Әти-әниең дә сөенер.

— Нигә?

— Бәхетеңә!..

Сабира шыңшып куйды.

— Нигә елыйсың?

— Ә минем иргә барасым килми.

— Нинди юләр сүз ул. Әйтелде, бетте. Атна-ун көн дигәндә килерләр.

— Каян беләсез?

— Әйттем бит, мин барысын да белеп торам, дидем. Сүзем көфер булмас. Ярармы?

— Ярар,— диде Сабира, үзен-үзе белештермичә.

— Менә сөйләштек,— дип сөенде Вәлиулла.— Күтәрсең! ...

...Берничә көннән ул амбарга икенче максат белән килде. Эше беткән иде. Хезмәтенә хакын гына аласы калган. «Акчасы бер атнадан гына булыр,— дип сүз бирде колхоз рәисе, шунда очрашкач, эшләрен карап чыккач,— яки ашлык белән түләрбез. Бераз мөмкинлегебез бар бугай әле!»

Барысы да аңлашылды. Артыгын сөйләшү кирәк түгел иде. Бер атнадан ул монда барыбер киләчәк, тарантас җигеп, кыз алырга! Шунда тияр ашлыгын да, акчасын да алып китәр. Берьюлы ике куянның койрыгына басар. Шулай да Вәлиулла туган авылына буш кул белән кайтмас өчен колхоз рәисеннән биш дистә йомырка һәм өч кадак балга “Боерык” алды, завхозны эзләп китте. Кайда булсын инде ул, карт бүре, шушындадыр, амбарлар тирәсендә, складларын саклап утырадыр.

Хатыннар һаман эштә иделәр. Киленнәр һәм кызлар әллә ничек моңландырып кына җырлыйлар, колак салган кешегә йөрәккә ятарлык рәвештә ишетелеп тора. Элгәрерәк, колхоз чыккан дәвердә, комсомоллар гел шулай җырлап эшлиләр иде. Үзләренең күлмәк-ыштаннары кырык ямаулы, тамаклары ач, бетеренгән булырлар, ә һаман да берәр дәртле көй белән «киләчәк тормышны кору өчен» тырышалар иде. Ул вакытларда аларга әби-бабайлар, битәрләп: «Авыз күтәреп, фәрештәләрне качырып, бигрәк пырдымсыз кыланалар, бидгатьләр!» — дия тордылар югыйсә. Ни әйттеләр, ә комсомоллар колак салмады, тыела белмәде. Шайтан чире барлык авылларга да йогып, хәзер бу хәлләргә өлкәннәрнең әллә ни исе китми иде.

Татар авыллары борынгыдан җырга-моңга бай булган. Бәйрәмнәрдә һәм сабантуйларында бөтен тарафлар диярлек җыр белән гөрләгән, муллалар да, диншәригать тә андый вакытта күңел ачуны тыймаган һәм халык иҗатына балта чабучы канунны һичбер чорда һичнинди хөкемдар уйлап чыгармаган, чыгарырга да тиешле түгел. Җыр — кешене рухландыра, сүнгән күңелләрне уята, тәнгә дәрт вә көч бирә. Әби-бабайларның комсомолларга карата мондый мөнәсәбәте бер дә дин вә шәригать хөкемен өстен күрүдән түгел, бәлки бары тик аларның кызыллыкларын яратмауларыннан килеп туган сүзләр иде. Ничек үз күрсеннәр ди? Мәсҗед манараларын кисеп, гыйбадәт йортларын клуб һәм ат абзары ясап

бетергән имансызларны кем яратсын, яратмас шул. Дөньялары бөтенләй баш-аякка әйләндерелеп ташланган иде бит. Сугыш чыгып, бәндәләр һәммәсе бердәй хәлгә куелып кына барысы да яңадан урынына утырды. Ни кызыл комсомол вә коммунистлар да газиз бала һәм газиз җан төшенчәләренең бер дә юк сүз түгеллеген аңлап, Аллаһы тәгаләне исләренә төшерделәр. Бу сугышта Советлар да, халык та, башкасы да түгел, хакыйкать җиңүче булып чыккан иде. Моны күпләр аңламады һәм төшенмәделәр, әмма һәркемнең күңеле боларны сизми калмады. Акылга барып ирешмәс эшләрне дә бәндә җаны тоя һәм аңлап тора шул...

Вәлиулла шыпырт кына йөренде. Сабираның кайдалыгын карап килде. Сөйләшми-тынмый гына үз эше белән мәшгуль икән, афәрин! Шунда кызлардан-мы-киленнәрдәнме берсе: «Сабира, оныт инде, оныт! Хәтереңнән чыгарып ташла, җырга кушыл!» — дип өндәп алды. Вәлиулла моны колак арты белән генә түгел, бәгырь ите белән дә ишетеп торды, «Һай!—диде ул, күңеленнән генә.— Сабираны үпкәләткән бу җеннәр!» Әмма кызның кәефен җибәрүчеләр алар түгел икән. Сәбәп тиз ачыкланды. Икенче берсе әйтә куйды: «Немецларга әсир төшкән кешеләрне унар ел урман кистерәләр икән, илен саткан сатлыклар исәпләнәләр. Галимҗаның өчен хафа йотма, кайтыр бер. Башы исән-сау булсын!»— диде. «Сабира шул әсир куенына керсенме, гомере буе әсир Галимҗанның сөйрәлчеге дип өстererләр үзен,— диде бер усал тавышлы хатын. Бәгырьләрне ерткаларга тел бирсә дә бирер икән шайтан мәлгунь.— Елама, нигә елыйсың? Сукранма!»

Сабира елый, мыштым гына яшь агыза икән. Башка кеше әллә кайчан эшен ташлап, каядыр аулак урынга йөгерер, шунда яшереп кенә күңелен бушатыр иде. Әмма Сабира алай итмәгән. Басынкы гына бәндә түгелме үзе?

Вәлиулла җиденче күктә иде. Сабираны ничек тә үз җәтмәсенә эләктерергә һәм бәхеткә чумарга бөтен юллар күренеп тора түгелме?

Хатын-кызларның үзара сөйләшүләренә мең рәхмәт әйтте ул. Күпне төшендерделәр бит. Боларны белеп тору бик кирәк. Әсирдә ятканлыгы хакында белдермәс, гел батырга чыгарыр үзен. Әллә нинди таулар вәгъдә итмәс, башка бер-бер юлын табар, сөйләштерер, кызны үзенеке итәр. Итәр, итми калмас! Әйтәләр иде бит аңа: «Сиңа,— диләр иде,— бу үҗәтлегең белән шайтанны да кулыңда биетергә була!» Һәм Вәлиулла биетәчәк тә, күреп кенә торырсыз!

Болар хакында уйланганда буеның бер карышка үсеп киткәнлеген тойды ул. Гүяки бөтен дөньяның кендеге аңа бәйләнгән, нәрсә дисә, шул буласы!

Сабиралар, тынычланып, бу юлы дәшми-тынмый эшләрен дәвам иттерделәр. Вәлиуллага тыңлап торырлык артык сүз юк иде. Ә нигә кирәк? Тиешлесенә колак салды, теләгәнен алды, артыгы барыбер сөендерерлек булмас иде. Аллаһы тәгаләгә рәхмәт әйтсен дә сөенечен уртаклашсын гына инде!

Завхоз шушы тирәдә генә ындыр алларын себереп йөри икән. “Боерык” буенча тиешлесен үлчәп бирде һәм вәссәлам, хуш! Вәлиулла, кичкә калуына карамастан, юлга чыкты. Дүсем авылына кадәр аның адымнары белән ике сәгать ярымлап ара үтәсе бар иде. Бәхетенәдер, авыл башыннан чыгып, бераз баруга, артыннан Карамалы урысы ат бастырып җитеште. Ни дисәң дә, биш чакрым, юл калган иде бит.

— Әйдә, безгә кадәр, хорошо будет,— диде ул, ярымын татар, яртысын урысча такылдап.— Садись, солдатик!

Кызык инде бу дөнья дигәннәре. Карамалы авылында элек өяз үзәге булган имеш, Кәтеринә падишаһ хәзрәтләре дә анда тукталып үткән. Юк ла дип белдерүче тарихчылар исә монда Татищевның булу-булмавын һич тә инкарь итә алмаслар. Кем-кем, әмма дә ләкин урыс хезмәтенә күчкән бу морза ул авыл аша гына үтми калмагандыр, бөтен Себерне үз кулында «чәчәк аттырган» бит.

Карамалы — ярым татар, ярым урыс авылы буларак аерылып тора. Татар абзыйлары үзләренә күрә бер мәртәбә белән аны русчалап «Александровка» исемендә атасалар, руслар, сөенеч вә канәгатьлек хисенә буталып, татарлар арасында «Карамалин» дип мактана иделәр. Бу авыл — хикмәтле урын. Мондагы рус төгәл татарча белә, татары исә русчаны шәп сукалый. Элгәре татар байлары монда килеп сәүдә тотканнар, базар ясаганнар, шактый гына исерешеп, дөнья куптарырга яратканнар. Бу тирә халкы ишетеп беләдер, шушы сәбәпләр аркасында бер мәкаль дә чыккан: «Татарин пьет — свиньей станет, русский пьет — коровой мычит!» Әмма татарлар аны үзләренчә үзгәрткәннәр: «Дуңгыз буласың килсә, Карамалыга бар!»

Вәлиулла юл уңае өчен генә дип шушы урыс арбасында урын алды. Баштарак сөйләшүләре инде күтәрелеп килүче игеннәрнең яхшылыгы хакында барды. Ул да түгел, үзен Ваня дип таныштырган Иван әйтә куйды:

— Зачем тәпиләп идти, когда кичкә можно ат белән кайтырга. Безнең больницадан бу вакытта сезнең якка путь держут, посетители. Айда к нам!

Урыс дөресен такылдый. Чыннан да, атка гына утырып кайтса, начар булмас иде. Әмма андыйлар очрамаса? Тагын өч чакрым юл өстәлә. Юк, җәяү китсен, иң яхшысы! Карамалының үзенә кайта икән бит бу урыс!

Вәлиулла шушы уйлар белән үзен-үзе борчып барды, тик аерым карарга килә алмый гына аптырады. Карамалы ягына борылган юлга җиткәндә, каршыларына кара ат җигелгән тарантасның юыртып кына килүе шәйләнде. Урыс туктады һәм:

— Солдатик, там что-то килә, видишь? — дип сүз салды.

Озак көтәргә туры килмәде. Юл тузанының чак кына күтәрелүе, атының уйнап кына килүеннән ул кешенең бер-бер түрә икәнлеген исәп итү авыр эш түгел иде. Шулай да урында утыручылар кичкә каршы кайда булса да баралармы соң? Юктыр мөгаен! Аннан соң шунысы да бар, сугыш тәмамлану белән ул мактаулы затларның кикрикләре бераз шиңебрәк китте. Кем очраса, алмый калдырмыйлар хәзер, бигрәк тә солдат киемендәге кешене.

Вәлиулла урыс арбасыннан төшеп калырга карар итте. Ул арада тарантас та килеп җитте. Солдат киемле, биштәр аскан кеше янынннан ничек җәһәт кенә үтә алыр икән? Йөрәге җитмәс!

Әмма ат җай гына үтеп тә китте. Дилбегә тоткан үткен йөз Вәлиуллага борылып карады. Шактый җир узгач кына тукталды һәм кычкырды:

— Вәлиулла, синме соң бу? Кая барасың болай кичкырын?

Тавышына караганда, аның Галимулла икәнлеген танымый мөмкин түгел иде. Вәлиулла титак-титак тарантаска таба ашыкты. Бер-ике тапкыр сөрлегеп китеп, чак капланмады. Галимулла кара айгырны көч белән тыеп тора иде.

— Сәлам!

Вәлиулла җавап бирергә ашыкмады. Дөресрәге, тыны кысылган, ашыгудан эчәк-бавырларына эссе капкан иде.

— Сәлам-м!— дип өзек-өзек әйтеп, тарантаска сикерде ул.

Сыртына дию каплангандай тоеп, ат ыргылып тартылды һәм тирбәлеп кенә алга ашкынды.

— Мин Сарайлыга да кереп чыгарга тиеш идем әле. Үзәккә отчет белән бардым. Көнем үтеп китте. Комиссия утырышын да бүгенгә куйган булганнар,— дип сөйләнде Галимулла.— Бу айгырны военком кайтартты. “Списанный” дигәннәр иде, ялгышканнардыр алар. Шундый да яхшы мал, мин сиңа әйтим, кара, ничек бара!

— Шәп!

— Шәп кенәме соң! Аргы ягы, шәпнең шәбе!

— Шулай...

Бу вакытта Вәлиулла Галимулладан көнләшү хисендә үз йөрәген ашый башлаган иде. Нигә ул гына шулай байларча йөри дә, Вәлиулла теләнче хәлендә сөйрәлә?

— Эш вакытында җигәр өчен үземә атадылар. Колхоз рәисе әйтә, син йөреп тор, үзеңне берәр чокырга илтеп аудармаса, үземә алырмын, диде,— дип үз сүзен сөйли бирде Галимулла.

Вәлиулла юкка үчләшә иде. Әгәр дә бу ат башын Галимулла түгел, бөтенләй башка кеше тоткан булса, юлчы очратуга гына туктап торыр идеме? Юк! Кызганыч, Вәлиуллага кешене яклап фикерләү һәвәслеген тәкъдире кызганган. Аның каравы көнчелек утының шактый кайнарын биргән. «Мәңге болай кара айгыр җигеп йөри алмассың, җае чыгар, үшән ат та бирмәсләр үзеңә, янарсың әле!» — дип уйлый иде ул бу вакытта. Миһербансыз кешене юлдаш иткәнче, шайтанга таянуың артык. Адәм баласы көнчелекле булса, иблистән яманрак.

Сул аягын бөкләп, уң аягын асылындырып барган фырт Галимулланы шушы вакытта Вәлиулла саксыз гына җилкә хәрәкәте белән тәгәрмәч астына тәгәрәтә ала иде. Аннан соң эзлә син гаеплене, аты йөрсен шунда, басуларны урап.

— Ничек, күрештеңме теге күз салган кызың белән? — дип сорап куйды Галимулла, Вәлиулланы юк-бар уйларыннан аралап.

— Күрдем.

— Ни сөйләштегез?

— Ачык кына берни дә түгел.

— Нишләргә булдың соң?

— Алырга да кайтырга.

— Алдан белешеп тә тормастанмы?

— Ә ни булган? Сораштырып-нитеп йөрсәң, гомер уза да китә ул, бик тиз.

— Юк, мин әйтәм, күңеле кайдадыр бит, дим. Кыз кешедер.

— Монсына һич шикләнәсе юк. Күңел — күңел инде ул. Кем кочса, шуны сөя җан!

— Алай ук микән?

— Тагын ничек булыр дисең?

— Белмим инде.

Галимулланың шушы сүзеннән соң Вәлиулла сытылып киткәндәй булды. Үте кабарып, хәзер юл рәхәтен бозып ташлаячак иде дә, сабырлык тапты. Берәүләр тарантастан төшеп, төкереп калырга мөмкин, ә ул алай эшләргә җөрьәт итмәде. Аннан соң, болайрак бит әле: Галимулла ни җитте генә кеше түгел, сүзе һәр җирдә үтә, авыл саен дусты. Менә Сарайлыга кагылып чыгам ди бит. Әйләнеч дип тә уйламый. Болай йөрсә, төнгә үк калачаклар.

— Әллә, мин әйтәм, Сарайлыны урап йөрмибезме, төнгә каршы?-—диде Вәлиулла, сүзне икенчегә борып.— Очравың яхшы булды. Төгәл бүгенгә аталган йомышың юк икән, давай, Дүсемгә кайтыйк. Берәр ярты да табарбыз.

— Әйтмә дә инде,— дип куйды Галимулла, әллә килешеп, әллә Вәлиулланың сүзен юкка чыгарып.

Тузанлы юлдан тарантасның җиңел тәгәрмәчләре дәртләнеп кенә келтери, кара айгыр җай гына юырта, басу-кырлар, чәчәкле печән болыннары шуышып кына кала бара. Әмма көтүе белән чебен-кигәвен атның сыртын каезларга тәмам хәзерлек белән куа килә, бары тик җитешә генә алмый иде. Һәркемнең, һәрнәрсәнең үз теләге шул. Дөнья яратылыштан бирле кечек вә олуг хәшәрәтләр үз җайлары-көннәре белән бар кылынганнар.

— Ярар,— диде Галимулла.— Сарайлыга соңардык бугай. Сәрбия куаклыгыннан борылып китәрбез.

Сәрбия куаклыгының бер очы сазлыкка килеп чыга, уң канатыннан — Сарайлыга, сулыннан исә Дүсемгә юллар китеп бара. Элекләрне бу урында таган асып, чатыр корган чегәннәр ятар иде. Соңгы еллар эчендә күренгәннәре юк икән. Аларны да сөрделәр микәнни?

Авылга кайтып төшкәч, Вәлиулла үз җае белән генә өйләренә китте. Галимулла атын аранга илтте. Төнге каравылчы килеп тә җиткән, капка ачып көтә иде.

— Әллә кайлардан ишетелеп тора малкаеңның күкрәк кагышлары, бигрәк затлы нәрсәкәй икән, күз генә тия күрмәсен, тфү-тфү,— дип сөйләнде ул, кечкенә сакалын сыпырып. Көндез булса, канәгать елмайган җиреннән җыер чыклы йөзе балкыганын да шәйләргә мөмкиндер бу картның.

Кайтышлый Галимулла, сөйләшенгәнчә, Вәлиуллаларга сугылып чыгарга иткән иде дә, ни өчендер кирәкмәс эш дип уйлады. Болай да юл буе әвеш-тәвеш сүз генә алышып бардылар, тагын очрашудан артыгына ирешә алмаслар иде. Шулай итеп, ул көнне аларның сукмаклары туры килмәде, икенче көнне һәм өченчесендә дә күрешмәделәр. Галимулланың колхоз эше дә муеннан, район комиссиясенең тикшерү белән килүен көтә иделәр. Менә дүртенче көнне алары таң белән төштеләр, сәгатьләр буе кәгазьләрдә казындылар, хуҗалыкның астын-өскә әйләндереп чыктылар. Арбаларына гадәти кадәр бал, ит, йомырка, он ише нәрсәләр салып яшерелгәч кенә бераз кешечә кылана башладылар, көн эчендә тикшергәч, кичкә китеп олактылар.

Галимулла алар янында йөрергә, кисәтүләрне теркәп барырга, кичен шешә ачып сыйларга мәҗбүр иде. Ул боларны җиренә җиткереп эшләгәндәй итте, әмма бер хата ясады: аракыны бердәй тигез эчмәде, азрак күтәрде. Үз-үзен болай тотышы түрәләргә ошап бетмәде, җанын очлы без төсле каезларга гына тордылар. Алар өчен бу гаҗәп хәл кебек тоелды.

Һәм менә алар китте. Болардан котылсам, тәүлек буенча йоклармын дип уйлаган иде Галимулла, барып кына чыкмады. Аны эзләп Вәлиулла керде. Әйдәкли-әйдәкли үзләренә алып китте. Шешә ачып, иртәгә кич кыз алып кайтырга бару теләген әйтте:

— Миңа,— диде,— иртәгә уңайлы көн булса кирәк, тәгаен генә белмәсәм дә, һәрхәлдә, күңелем сизә. Сәгать кичке өчләрдә, көн сүрелгәндә юлга төшү яхшы инде. Кара айгырыңны да җиксәң, иңеңә гармуныңны да ассаң, Сабираны бирми калмаслар!—дип, үз планнарын күптән Галимулла белән килешеп куйган кеше кебек сөйләнде. Арыган һәм салмыш бәндәләр кәлҗемәгә әверелә. Мондый халәт бүген исә Галимулланың шәплеге иде. Ул, килешеп, Вәлиуллага сүз бирергә дә өлгерде:

— Мин үзем яучы булырмын, телемә каратып торырлар. Ә син, Сабираны кочагыңа алырсың. Мәһәре — ике шешә бәйрәм суыннан дип исәпләрбез!—диде, бик тә җитди сөйләнеп.

Бу сүзләрен ишеткән Вәлиулланың шушы минутта күк капусы ачылырга тиеш иде дә, әмма, көферлеккә каршы, күңеленә шик тә төшәргә өлгерде. Татлы алманы комсыз корт ничек тишкәләсә, аның да күкрәк җимеше — кызны үзенеке итү дәрте белән янган йөрәге иләккә әверелде. «Алдый бу Галимулла, бик җиңелдән килешә. Әллә нинди ниятләре бардыр әле!»— дигән уйлары башын катырды.

Алар шактый озак утырдылар. Сабираны барып алырга һәм «бәхетле» итәргә килешенеп кул сугыштылар да, Галимулла, гармунын култык астына кыстырган хәлендә, сүрән лампа утыннан чыгып, төнге караңгылыкка чумды. Вәлиулла, аның артыннан утны сүндереп, йокыга талды.

Аллаһы тәгалә бер насыйп итсә, дошманнар үч кулы белән генә нәрсә эшли алалар соң? Юк, әлбәттә! Алдан белдереп тә куя әле ул адәм баласына.

Вәлиулла төш күрде. Урман, имештер. Бер якты яланга килеп чыкты. Анда каен үсә икән. Аңа үрелде. Кочаклады. Аһ, каен түгел лә, назлы кыз икән бу. Туйганчы үпте. Әмма, ни хикмәт, каен каралып калды. Көз икән, имештер. Вәлиулла ул каенны кисәргә тели, кулы җитми. Килә дә кочаклап ала, әмма ни сөенми, ни көлми. Кайдадыр этәч кычкыра.

Уянып китте. Кояш чыккан икән инде. Энесе Җаббар өстәл янында катык ашап утыра.

— Абый, тордыңмы?

— Әйе, торырга кирәк. Таң да аткан икән.

— Әллә кайчан.

Алар артыгын сөйләшеп тормадылар. Җаббар эшкә китәргә дип кузгалып маташа иде. Вәлиулла аны туктатмады, серен дә чишеп маташмады. Күңеле тынычсыз иде.

Энесе чыгып киткәч, ишегалларын себерештереп, арып-сарып яткан әйберләрне җыештырды, койма-киртәләрне төзәтте, аннан соң, көн авышкач, идарә ягына юнәлде. Анда барып җитсә, Галимулла өч-дүрт кеше белән тәмәке көйрәтеп, ни хакындадыр гәпләшә иде.

Вәлиулланы танып алдылар. Исәнләштеләр. Хәл-әхвәл сорашып, төрле юкбар хакында телләренә салынгач, кайсы кая китеп барды.

— Ни йомыш иде соң идарәдә? — диде Галимулла.— Эш сорап йөрүме әллә, мин әйтәм?

Вәлиулланың ачуы кабарды. Әле кичә генә сөйләшеп, сүз куешкан иделәр түгелме соң?

— Бүген кыз алырга барабызмы? — диде Галимулла һаман да сорауларына җавап алалмыйча, аптырашлы карашын ачулы йөзле Вәлиуллага төбәп.— Әллә кире уйладыңмы?

Вәлиулла ялгыш фикергә килүеннән оялып куйды. Йөзе яктырды. Кояш күл өстендә ничек ялтыраса, аның да күзләреңдә шундый нурлар уйный иде. «Юк, Галимулла сүзендә тора торган кеше бит ул!»— диде, бөтен күңеле белән куанып, әмма эчтәге шатлыгын тышка чыгармыйча яшереп тә калдыра алмады, авызы шәп кенә ерылды.

— Кара айгырны җигеп, тарантас тагып барсак, күркәм буласы инде ул,— диде шунда ук.

— Белмим, ничек икән? Тарантас буш түгел бугай. Син идарә атларын караучы Җамалетдин бабай белән сөйләшеп ал әле. Кыңгырау да такмас микән? — диде Галимулла, йөзенә җитдилек чыгарып.

— Нинди кыңгырау ди инде ул? — дип каршы төште ашыгыч рәвештә Вәлиулла.— Кеше көлдереп, бөтен авылга ишеттереп...

Икесе дә сүздән калды. Бераздан соң гына тынлык бозылды. Сүз сүзне уята, уянган сүз күңелне кузгата, кузгалган күңел адәмне елата, дигәндәй, Вәлиулла тагын кәефсезләнә башлады.

— Аннан соң миңа кем кара айгыр җигеп бирсен ди, тарантаска, җитмәсә. Моны син үзең эшләсәң генә инде,— диде ул, үтенү һәм мескенлек белән йөзен сулдырып.— Ярдәм ит инде?

Галимулла аптыраулы хәлгә калган иде, сүз эзләп күршегә керми торган кеше турыдан бәрә, ул да шулай эшләде, ярды да салды:

— Мин өйләнәмме, синме?

Берәү булса, борылып кына китәр иде. Әмма әсирлек вә тоткынлык шулпасын ашап, сабырлык бишмәте имән кайрысы кадәр калынайган Вәлиулла алай итмәде. Сүздән калып бераз торды да бернинди хәвефе юк кеше төсле:

— Мин өйләнәм!— дип әйтте.

«Юньле бәндә икән, тыңларга тиеш Галимулла!» — диде ул күңеленнән генә исәп-хисап йөртеп. Әмма иптәше бөтенләй башкача уйлады: «Нахал, өйләнәсең икән, үзең тап атын да, башкасын да!»

Галимулла үз уенда фикерен төйнәде, әмма моны кычкырып әйтмәде. Болай гына, ачуы килү иде бу. Күңеле йомшара төшкәнче сүзсез калды, аннан соң, юшкыны коелгач, әйтә куйды:

— Җамалетдин абзый шушында гына, атлар карап йөри иде, кереп белешә тор әле. Яхшырагын җиксен тарантаска, мин рәистән белешеп, рөхсәт алып чыгам! Бар-бар!..

Берсе идарәгә чумды, икенчесе абзар-куралар ягына кереп китте.

Вәлиулла эшнең барып чыгасына ышана иде. Күргән төшен исенә китерде: сылу кызны кочты бит ул, фалы дөрескә чыгар, Аллаһы боерса!

Идарәнең атлар араны артта, капкадан кергәч тә киң ишегалдының сулъяк

почмагында икән. Җамалетдин абзый дигәннәре илле белән алтмыш арасындагы тәбәнәк, бер күзе сукыр, чытык йөзле, чәчне төптән кырдырган, сакалга да әллә ни ихлас куймаучы бабай иде. Ул якында гына чана тарткыларын, кошовка тәртәләрен төзәткәләп йөри булып чыкты.

Вәлиулла аның белән сөйләшеп, йомышын әйтергә өлгергәнче, Галимулла кулындагы «Боерык» кәгазе белән килеп тә җитте.

— Мәле моны, Җамалетдин абзый, китәсе бар, ашыктырсаң иде,— диде.

Туры айгырны җигеп, кибеткә һәм Галимулланың гармунына тукталып, мәшәкатьсез генә китеп тә бардылар. Үргә каршы булуына карамастан, ат юыртып кына элдерде. Гасырлар йокысына чумган калкулык вә тау сыртлары кояшта аркаларын җылытып ята калдылар. Әле төшке вакытлар гына якынаеп килә, иртәрәк түгелме?

Урман янын узгач, тигез юллар һәм киң басулар башланып китте. Кәләшенең авылына сәгать эчендә диярлек барып та ирештеләр. Рангазар авылы бүген кияү көтми иде.

Вакыйга болайрак булды. Кыз сорарга килгән кияү егетләре иң элек идарәгә тукталып, Вәлиулланың хезмәте өчен тиешле хакны алдылар. Боларны тарантас артына куеп, кәеф вә гайрәт артсынга тамак төпләрен чылаткач, Сабираларның капка төпләренә кадәр гармун тарта-тарта җырлашып килделәр. Галимулланың аякларында ялтырап торган кара хром итекләр, өстендә ак күлмәк һәм кара костюм-чалбар иде. Ә өйләнү нияте белән йөргән Вәлиулла буй-сынга, төс-биткә генә түгел, кием ягыннан да шактый калышып, өстендә сугышка кадәрге мода белән тегелгән, иске, нафталин исе сеңгән кара зәңгәр пинжәк һәм дә төсе киткәнрәк шундый ук чалбардан иде.

Әмма күлмәк яхшы аның. Өр-яңа, бүген генә фабриктан кайткан диярсең: ап-ак, каты якалы, кешелеккә генә киярлек. Германнан килгән, Бөгелмә базарында кулына төшкән, шулай да трофей саналырлык истәлек. Күпме кулларны күргәндер, әмма иясез саклanганлыгы күренеп тора, кер тимәгән, юылган нәрсә түгеллеге дә сизелә.

Вәлиулла ат башын тотып барды. Галимулла, сул аягын тарантастан салындырып, гүяки җиргә сөйрәткәндәй егетләрчә утырган хәлдә ярты тавышка гына җырлый-җырлый, гармун сыздырып килде. Халык эштән кайткан, кояш утыргамы-юкмы икәнлеген чамалаган вакытлар иде. Нәкъ сәгате!

Капка төпләрендә, тыкрык башларында берән-сәрән өлкәннәр, каш өсләренә кул җәеп, артларыннан таныргa ниятләп калдылар. Галимулла сабантуйлары алдындагыча халыкны дәртләндереп үтте. Юньле-башлы бәйрәм күрмәгән авыл уянып киткәндәй булды. Тарантас Сабиралар капкасына тукталгач, һәммәсе эшнең асылын төшенде. Вәлиулла ат башын ныклы тапкан койма баганасына бәйли калды. Галимулла, яңадан гармун тартып, ишегалдына керде.

Өйдән өлкән яшьтәге бер абзый чыкты. Шәрифулла, кызның атасы, кылыч борынлы, калын гына кашлы икән үзе. Аны күрүгә, бераз төшергәнен юри сиздереп, Галимулла кыландырып әйтә куйды:

— Саулармысыз, исәнлек-иминлек булсын! Бәхет иңдереп йөрибез әле, Шәрифулла абзый!

Дөнья кузгалды. Сер бавы тиз чишелде. Карт белән карчык, юк-бардан гына

булса да өстәл әзерләргә кирәген төшенеп, кабалану аркасында сөйләнгән сүзләрне ярты колакка гына тыңлап, күңелләренә салып үлчәргә өлгерә дә алмый калдылар диярлек. Мулласы да чакыртылгач, Галимулла гармунын беразга куеп торды. Никах хөтбәсе укылып, төенчеген култык астына кыстырган кызны тарантаска чыгарып та утырттылар. Ашыгырга кирәк, көтү кайта иде инде, әле күпме юл үтәсе бар.

Вәлиулла дилбегәне тагын үзе тотты. Тарантас оясына Сабира һәм гармун тарткан Галимулла утырдылар. Саубуллашуны озакка сузмыйча кузгалдылар. Дүсемгә кайтып җиткәндә, кояш иңгән, күк йөзендә кызыл шәфәкъ нуры да сүнеп бара иде инде.

Тау сыртлатып, авыл башына тукталдылар. Төнге тынлыкны чакыра-чакыра, җәйге җылы көн сүнгәннән-сүнә, оеганнан-ойый, йокыга җыена иде. Галимулла юл буе җырлап, гармун уйнатып, шаяртып кайткан җиреннән тынып калды. Сабирага күз салды. Кыз да күзләрен күтәрде. Ничектер ягымлы һәм күп нәрсәләр вәгъдә иткән төсле итеп карады ул Галимуллага, әллә яратып, әллә алдагы кичнең рәхәтлек пәрәнҗәсенә төренгәнлеген белдереп. Әмма егет бирешмәде, хәле хәл, уйлары уй иделәр аның.

Галимулла тарантастан төште. Тау астында тыныч кына яткан авыл кача-кача күзли төсле иде аларны.

Ат тартылып куйды. Китеп үк барса да начар булмас иде. Вәлиулла ашыга торгандыр. Әмма эндәшми.

— Ярый, мин киттем әле,— диде Галимулла, кияү белән кәләшкә мул елмаеп, эше күплек кыяфәт чыгарып.

— Кая-я? — дип, ыңгырашкан тавыш белән Сабира эндәшүгә, Вәлиулла җыерылып куйды.

Галимулла югалып калмады. Уйнаган уенын ахырына кадәр җиткерергә тиеш иде ул. Шунлыктан сер бирмәде:

— Кайта торыгыз, колхоз эше бар иде, туй көнендә дә тыныч тотмыйлар! Тиз әйләнеп киләм,— диде дә, сукмак буйлап төшеп, тыкрыкка борылды, китеп тә югалды.

Артыннан Сабира карап-карап калды. Эченә ут төшкән, ниндидер мәкерне сизенә төсле иде.

Капка төпләренә Вәлиулла атны җилдертеп кенә китереп, ян белән барып тукталды. Киленне йортка алып керде. Карчык әнисе әйдә юк иде. Җаббар үзе генә булып чыкты. Чәй куйдылар. Сәке башына төенчеген тотып утыртылган җиреннән Сабира һичбер селкенмәде. Галимулланың кайтканын биш күз, ут күңел белән көтә, шулай да тыштан бик сабыр иде.

Җаббар һәм Вәлиулла, ишегалдына чыгып, нидер сөйләштеләр дә... Өй эчендә җырлап утырган самавыр вә килен белән кияүдән башка һичкем калмады. Өчле лампаның сүрән утында утырып чәй эчтеләр. Сабира баштарак теләмәгән иде, әмма бу сыйдан баш тарту килешмәс диптер, ике тапкыр чак кына йотым ясады, чынаягы тулы көенчә калды. Тамак яшерүе иде, бичараның.

Төннең урталары җитте. Вәлиулла белән Сабира сөйләшми-тынмый гына утырдылар. Киленнең алдында төенчеге, урыны — сәке башы иде. Кияү дә үзен тыныч тотты.

Һәм шунда гармун тавышы ишетелде. Галимулла тагын да төшереп алган икән инде, «Шахта көе»нә җырлап узды. Сабираның күңелен кузгатты. «Кайта бит, кияве кайта!»

Әмма көткән кеше күренмәде, чөнки монда артык иде ул. Сабираны Вәлиулла өчен алып кайттылар бит. Метр да җитмештән калку буйлы гүзәл зат киндерә буе пәри табагачына насыйп икәнлеген белми иде әле.

Сабираның хәлен Вәлиулла аңламый. Үзенә төшкәнен белә, әмма сабырлыгын тел яшерә, ояла дип кабул итте. Урын җәйде һәм кәләшенең төенчеген алып:

— Йә, йокларбыз иңде хәзер, әзерлән-җыен,— дип, тыныч кына әйтеп, шулай да коры итеп куйды.

— Ничек инде? — диде аптыраган Сабира.— Галимулла кайтмады бит әле, аны көтәм!

— Ул әллә кайчан җиденче төшен күрә инде, йоклыйк. Ул монда килми. Үз өе бар бит аның,— диде Вәлиулла, юмалау тавышына күчеп.— Бергә йокларбыз. Ни дисәң дә, никахлы хатыным бит син минем!

Сабира һични аңламады һәм телсез калды. Озын чәч толымнары тагын да сузылыбрак киткәндәй булдылар. Акылы акрын эшләде. Шулай да, кешегә баш бирелгәч, уйлый-уйлый барсын да аңлап ала икән.

— Ничек? — дип сорады Сабира бераздан, тәмам аптырашлы хәлдә.

— Менә шулай,— диде Вәлиулла, бер дә кабаланмыйча, лампа утын өреп сүндереп.— Сине миңа сорадык һәм үземә дип алып кайттык.

— Мин китәм!

— Кит! Кая бара аласың? Кияүгә чыкканыңны бөтен авыл белеп калды. Ни уйларлар?

— Мине Галимуллага бирделәр. Ул сорап алды мине. Никахны да аның исемен атап укыдылар. Янәшәмә дә ул утырып кайтты, син түгел!

— Мин таптым, мин алып кайттым, и всү тут!— диде Вәлиулла, шыңшый башлаган кызга кул сузып.— Әйдә, күгәрченем, никахлы булдык, иртәгә авыл советыннан таныклык барып алырбыз.

— Әни-и генәм!—дип әйтте, хәтта кычкырырга теләде Сабира, ләкин тавышы бик зәгыйфь чыкты...

Вәлиулла уянып китте. Сабираның ертык күлмәк һәм киемнәрен күз алдыннан җыеп алды. Буена күз салды. Хатыны күркәм, хәтта күз карашына да татлы иде. Җиләген ашатты, хәзер беркая да китә алмый инде ул!

Вәлиулла һавага чыкты. Кояш инде күзен дә ачып килә иде. Махра төрде. Эмманы исенә төшерде. Сагына түгелме соң?

Өйдән ишек ачылды. Тупсада Сабира басып тора иде. Кулына төенчеген тоткан, чәче-башы җыелган, әмма сөмсере коелган.

Аңа Вәлиулла эре генә эндәшеп куйды:

— Хатын, кая барасың?

Сабира сискәнде. Әмма тәкъдиргә буйсынуын белдереп, акрын гына пышылдады:

— Белмим...

Вәлиулланың тавышы көрәйгән, үзен ир итеп тою билгеләре аңарда арткан

иде. Әмер бирде:

— Бар, кереп самавыр куй. Тамак кипкән. Таң да атып килә. Әни белән энекәш тә кайтырлар.

Күрше-күләндә чиләкләр шалтыраганы, сыерлар мөгердәшеп куйганы ишетелде. Сабира, тупсадан борылып, кире керде.

Хәзер ул самавыр куяр, өй эчен җыештырыр, йа тәкъдире Ходa!

## ИЛАҺИ КАНУН

*Повесть*

Мин бәхетле идем. Сәгадәт диңгезенә очраган язмышымның көмеш корабы, назлы кояш елмаюы белән хозурланып, талгын җилләр иркәләвендә тыныч һәм рәхәт кенә йөзә дә йөзә. Тормышым күге һәрвакыт шулай аяз, бәхет дулкыннары юлдаш булыр төсле иде. Дөньяга адәм баласы яратылган икән, аның бәхетсез вә күңелсез көннәр кичерергә хакы юк. Бу — илаһи канун! Моны бозган бәндәләр җавапка тартылалар һәм олуг хаким — хакыйкать тарафыннан хөкем ителәләр. Без беребез дә аннан азат түгел. Ирекле төсле кыланабыз гына, әмма чынлыкта исә барчабыз да үзара тыгыз җепләр белән бәйләнешкән, арадан кемнең күңеле сынса, башкаларга да ул тәэсир итә һәм сәгадәт диңгезенең якты кояшы йөзенә кара болыт пәрдәсе тартылып куелгандай була. Яшәеш дигәнебез менә шушы инде. Меңнәрдә — берәүнең, берәүдә меңнәрнең эше бар. Әмма мәхәббәт... Ә мәхәббәт бу канунга буйсынмый, аның үз законнары. Аны аңлатып бирү бик авыр эш. Шулай да бу җитди бурычны үз өстемә алып, инде телләрдән-телләргә күчеп йөргән серле хәбәрләрне, артык сүздән аралап, нәрсә ничек булганны сөйләмәкче идем. «Әллә кирәк түгелме?» — дип тә күңелем теләк чишмәсенә үзенең шик ташын тәгәрәтеп, аны туктаткандай итте. Төннәрем йокысын югалтты, көннәрем борчуда узды. Сүз чишмәсе — елгага, елга —диңгезгә әверелде һәм менә мәхәббәтнең илаһи канунын бәян итәргә булдым. Сүземне — дөрес, каләмемне төз тоттым, алай да серенә төшенмәүчеләрнең кулына бу язма керсә, гафу итәрсез!..

Алар электән берсен-берсе авылдашлар буларак белә иделәр. Үзара дуслыклары, йөзгә-йөз калып сөйләшкәннәре, хәтта үзара хөрмәт хисе белән исәнләшеп узганнары да юк иде. Чү, бераз ялгышам, моннан дүрт ел элек алар очраштылар. Азга гына, әмма сөйләшмәделәр. Бу күрешүләре игътибарга алырлык түгел, шуңа да бик тиз онытылды, һәм менә аларны йолдызлы кичә кавыштырды, мәхәббәт утының чаткысы йөрәкләренә йокты, иреннәрендә иреннәре наз тапты. Вакыйга авылда башланып, шәһәрдән-шәһәргә күчәчәк иде.

Кич. Авыл, маэмайларның нигез астына посып вакыт-вакыт өрүләреннән уянгалап-уянгалап, төнге ялга сузылып ятты. Яшьләр клубка, икенче төрле әйткәндә, Мәдәният йортына җырлы-биюле кичә уздырырга җыелыштылар. Шәһәрдән студентлар кайткан вакыт. Клуб тулы халык. Таштан мәһабәт итеп са-

лынган, иркен-киң заллары, төрле-төрле уңайлы эш бүлмәләре булган, зур тамаша залы һәм бай сәхнәсе белән ни җитте салаларны гына түгел, шәһәрләрне дә кызыктырырлык бу йорт чын мәгънәсендә Мәдәният сарае иде. Олы вә киң ишекләреннән үзенә чакырып, урамга тасмалардан дәртле көйләр агыла. Яшьләр җыела, яшьләр...

Кемнәрнедер бу кичә кавыштырачак, кемнәргәдер беренче мәхәббәт назы бүләк итәчәк, кемнәрнедер үпкәләтеп аерачак. Ә алар, мин сезгә сөйләргә җыенган гүзәл затлар, бүген бер-берсенә елмаеп, хәтта серле елмаеп дияр идем, караячаклар...

— Сәлам, егетләр!

Ә менә ул да килеп җитте. Дуслары-танышлары белән күрешә. Җантимер Корбыев Нурулла улы. Җилкәле, озын-нык буйлы студент, шунлыктан ябык һәм яшьләргә ятышлы чиста вә пөхтә, заманча киенгән асыл зат. Ул безнең соклангычыбыз иде. Әле яңа гына мыек чыгарган яшьтәшләрем һәммәсе аны хөрмәт итә иделәр. Җантимер абый. Егерме-егерме бер яшьләр чамасында. Кызлар белән авылда яратышып йөрмәде дә төсле. Бер укытучы апабызны кышкы ялларга кайткан вакытларында озаткалады да бугай, әмма болай, вакыт кына үткәргәләгән, диделәр. Башка гайбәтен белмим, күрше Бәрия әби генә нидер сөйләнгәләп йөрде, имеш: «Миндә арт җылытып ятучы карт бер сазаган кыз асыл егет карчыгасы Нурулланың Җантимерен читлегенә алдап кертмәкче иде дә, әнкәсе рәхмәт әйтсен, саклап калдым үзен»,— дип.

Дөрес булдымы икән? Бәлки хаклы сүзләрдер, чөнки безгә кергәч ул аларны сөйләнгәләп утырган иде, колак салып алган бар сүзләре шул булды, башкасын белмим...

— Сәлам, егетләр!

Җантимер абый шул рәвешле кул сугып күреште. Безне дә урап узмады. Казан хәлләреннән бер-ике хәбәр сөйләп алачак хәзер.

Аңа таба елыштык.

— Илдә ниләр бар? — дип сорады ул, ярым шаяртканын сиздерергә теләп.— Барыгыз да исән-саулармы соң?

— Әлегә исән идек әле, Казанда ниләр бар? — диде, утызын куып килгән «сакаллы» егет Камай абый.— Бездә шул инде, яздан — басуга, көздән — фермага. Трактор гына чыдасын.

— Гатаны кыскан икән. Ничек алай булды соң?

— Азрак төшергән көне иде. Үзе кулын тыккан, диләр.

— Юк ла инде. Хуҗалар сүзен сөйлисең. Мин шунда идем,— дип белдерде Самат.— Суырып алды. Әле дә ярый имгәнеп кенә калды, юкса...

Сүз комбайнга утырган Гата хакында бара иде. Шкивка эләгеп, кулын кыскан, әле дә ярый имгәнеп кенә калган, булышчысы сүндереп өлгергән, юкса бәласе зур буласы икән.

Казан шәһәре елдан-ел матурая бара, ди Җантимер абый. Татар иҗтимагый хәрәкәте, «Азатлык» яшьләре һәм башка берничә милли үзәкләр Татарстан җөмһүриятенең азатлыгын даулауда зур эшләр алып барганнар. Хөкүмәт тә аларның теләкләрен аңлап эш итә, ди.

Клубта бүген һинд картинасы иде. “Башлана” дип әйтүләренә кереп киттек.

Яхшы фильм булды. Мәхәббәт, сагыш, авыр язмышлар һәм хакыйкатькә ирешү хакында иде ул. Авыл кешеләре һинд киноларын үлеп сөябез дә инде!

Кинодан соң кичә башланып китте. Биюгә оста Җантимер абый кызларны-егетләрне үзенә каратып тотты. Көнче күбәләк Гыйльметдин Хәлфәсе бүген төшереп чыккан иде, тавыш-гауга кубарып маташты. Җантимер абыйга да бәйләнмәкче иде. Барып кына чыкмады, буе тиз бөгелде.

Ә бию-уеннар өзелеп тормады һәм шунда...

Һәм шунда клубка, биючеләр уртасына, күпләрнең төн йокысында татлы төше булырдай Җәмилә апа үзенең иптәш кызы Кадрия апа белән килеп керделәр. Инде сәгать төнге унберләр якынлаша иде түгелме соң? Бу вакыт җиткәч кем уенга килә ди инде? Димәк, язмышы кушкан!

Биючеләрнең биюләре бозылган кебек булды. Яшьләр төркемнәргә бүленештеләр. Бары тик Җантимер абый гына берсенә дә кушылмады, үз җае белән читкәрәк китеп басты. Күңелендә нәрсә иде икән, белмим. Минем уемча, Җантимер абый белән Җәмилә апа шундый да пар килгәннәр, икесен кавыштырасы да назлы ярлар итәсе генә югыйсә. Белмим, нигә алар үзара дус түгелләр икән? Ә, исемә төште, Җәмилә апа белән директор малае Сабирҗан абый йөри дип сөйлиләр бит. Дөрестер, инде тугызынчы сыйныфтан бирле дуслар икәннәр. Җитмәсә Сабирҗан абыйга шушы сөйкемле Җәмилә апа аркасында авыз-борыны җимерелеп, кан йотарга да туры килгән. Монысы — егетләр гайбәте...

Бервакыт Җәмилә апаның шәһәрдәге мәхәббәте кыйнаткан, диләр... Икенче көнне, тагын килмәсләр микән дип, төн буе сабирҗаннар капка төбендә биш егет, шешә бушатып, гомер уздырганнар, тегеләр генә күренмәгән. «Бәхетләре бар икән!» — диярәк сөйләгән икән Сабирҗан абый, тәмам үзен батырга чыгарып: «Канга чумдырасы идем, барчасын ишеп!»

Булдыра алгач, шунда ук, беренче очрашудан акыл сабагын укытырга кирәк иде аны!

Җәмилә апа!.. Һе, әллә ничек инде Җәмилә апа дип әйтүләре. Мин дә егет бит инде. Җәмилә туташ! Әйе, әйе, Җәмилә туташ, Җантимер әфәнде! Юк, Җантимер әфәнде дип әйтеп булмый әлегә үзенә, әфәнделеккә ирешү өчен асыл зат сыйфатлары күренсә дә, дан вә шөһрәте белән алай ук әфәнделеге сизелми. Ә менә Җәмилә апа — Җәмилә туташ, үзе чибәр, үзе сылу, үзе матур, үзе күркәм, ул аяклар, ул чәчләр — барысын да Хак тәгалә атап аңа гына биргән, аз гына бөгелсә, биле дә өзелеп кенә китәр төсле.

Быел ул Казанда бик югары һәм мактаулы институтны бетереп кайтты, әмма эшкә генә үзебезнең якларга күндермәгәннәр, Уфага ук җибәргәннәр, җиде ят, җиде еракка. Элеккечә кышын-җәен каникулларга кайтып та йөри алмас инде. Сагынырбыз!

Җантимер абыйны Кадрия апа үзенә дәшеп алды. Җәмилә туташ алар янына авышты, Сабирҗаны читкәрәк тартылды. Җантимердән ояладыр ул. Бәлки, берәр сүз әйтеп куганнардыр үзен?..

— Җантимер, син безнең белән исәнләшмисең дә,— диде Җәмилә туташ, ярым шаярткан төс чыгарып.

— И Җәмилә туташ,— диде Җантимер. Сөйләшә белә дә инде, үзгенә генә баса! — Сезнең кебек сандугачлар белән минут саен исәнләшеп торсаң да аз бу-

лыр! Ак каеннар сыман бөгелә җаным!

— Җантимер сүз эзләп күршегә керми инде,— диде Кадриясе, Җәмилә дускаен якларга теләп.— Кесәгә дә керми, әмма...

— Әмма дип, бер дә әмма түгел. Әмма дигәннән, элекке вакытларда Казанда булган бер хәл! Пишкадәм бар икән. Кушаматын «Әмди» диләр моның. Мәдрәсәдә муллалыкка урын көтеп ята ди бу. Карт мулла белән ашка аны да, ягъни мулла янына мулла күреп чакырталар икән. Менә шундый мәҗлесләрнең берсендә карт мулла сорап куя үзеннән, оятлы итү максатыннан чыгып: «Әмди, әӘмди, әйт әле, Кабан күленең суы ничә чиләк булыр?» «Чиләгеңә карап, чиләгеңә!»— дип җавап бирә Әмди, бер дә югалып калмый. «Ничек инде?» — дип сәерсенә мулла абзый. «Әгәр дә бер-бер чиләгең ярты Кабан күлен сыйдыра икән, ул вакытта ике чиләк булыр, мәгәрем ки чиреген генә чумырса, дүрт чиләк булыр»,— дия Әмди, барсын да хәйранга калдырып. Менә шулай!..

Җантимернең шушы хикәятеннән бөтенесе дә хихылдап җибәрделәр. Бигрәк тә Җәмилә туташ ихлас күңелдән назланып көлде ки, гүя пыялалар зеңләп торгандай иде. Сүзнең ни хакта икәнлеген белмәсәләр дә, бөтен клуб эче аларга ияреп җиңелчә елмаю нурында балкыды. Җантимер генә һич сер бирмичә, канәгать төстә озын буен төз тотты. Ул — хан иде, барчабызга да башлык.

— Иртәгә минем бәйрәм, Җантимер, килерсеңме? — дип сорады Җәмилә туташ, егетнең күңелен җилкендереп.— Күңелле булыр.

— Шашлык, шәраб һәм чибәр кызлар! Нинди егет мондый мәҗлестән баш тарта ала соң? Һәрхәлдә андый ахмак мин түгел... Кайда була соң ул бәйрәм? — диде Җантимер, үз алдына канәгать төстә.— Җидегән чишмә буенда, таңга кадәр! Шулаймы?

Җантимернең бу сүзләре кызларга хуш килде булса кирәк, барысы да сөенештеләр. Әмма Җәмилә туташ әйтеп куйды:

— Таңга кадәр? Кызык. Ә минем Җидегән чишмәдә таң каршылаганым юк иде әле!

— Димәк, каршы алачаксың! Нинди асыл зат шушындый бәхеттән коры калган! Болай һич ярамый.

Җантимернең кыланып сөйләшүе идеме бу, әллә инде чынлап ук шулай уйлыймы, анысы сизелмәде. Әмма Җәмилә аның шушы сүзләрен чын күңелдән кабул итте. Шаяртуга каршы шаярту, уенга уен белән җавап биреп, үзе дә егетне сүз ятьмәсендә бутап, күңелен адаштырырлык тәкъдимнәр ясады.

— Синең кебек егет асылы белән таң каршылау күп кызларның хыялы инде ул,— дигән булды.

Бу чыннан да яхшы, күңелне кузгатырлык тәкъдим иде. Мондый сүздән соң кайсы егетнең уена ниләр кермәс тә, ничек итеп үзен татлы хыялда адашудан саклап кала алыр? Азамат ир күңелендә иярле җитез акбүз ат ятар, диләр. Җантимер дә бу кичәдә үзен шулай сизде. Җәмиләне озатырга дигән теләген күңеленә салып куйды. Кыз да өтек Сабирҗанын онытты. Җантимернең уенын-чынын, өздереп-өздереп күз текәүләрен чын вә ихлас хис тойгысының чаткысы буларак кабул итте.

— Шашлыкны үзем әзерләрмен,— диде Җантимер,— җитәрлек кадәр булыр, яңа суелган сарык итеннән. Килештекме? Шәраб өчен бераз сәмән дә ки-

рәк була торгандыр инде?

Кылт итеп шунда Сабирҗанны уйлап куйды булса кирәк, арадан аны эзләп, уңына-сулына каранды да:

— Бу эшне Сабирҗанга тапшырыйкмы әллә? Кая әле үзе?— дип сорады.

— Ул китте инде,— диде Җәмилә.

Бу сүзләр күп нәрсәләрне аңлата иде. Җәмилә бу кичәдә Сабирҗанның аптыратуларыннан азат. Күз карашлары да шул хакта сөйли: «Йә, батыр егет, син дә азаттыр бит? Озата килә аласың!»

Җантимер дә шушы нияткә килгән идеме?

— Ә мин китмәдем, ә мин һәрвакыт сезнең яныгызда! — диде аларга артларыннан Сабирҗанның тавышы.— Нәрсә бар иде?

Каян килеп чыккан. Ничек? Барысын да ишетеп торган? Әйе, ишетеп торган сөйләшүләрне һәм көлешүләрне мыштым Сабирҗан. Ә Җәмилә сиздерергә теләмәгәнме, әллә юри Җантимерне үртәгәнме? Боларны егет күңеле уйларга да өлгермәде, Сабирҗанның сүзгә-сүз кушып дәвам иткән сөйләменә игътибар итәргә мәҗбүр булды.

— Мин палатка алып китерәм, поход палаткасы. Машина да миннән. Ул кадәр ерак юлга җәяү йөреп буламыни?

— Бик яхшы, чатыр да, учак та һәм шашлык белән эчемлек тә әзерләнәчәк димәк. Әмма мин...

Җантимер тотлыгып калды. Ерык авызы колакларыннан борын астына җыелып төште.

— Нәрсә мин? Әллә бара алмыйсыңмы, Җантимер? — дип сорады Кадрия, күренеп тора, егетнең бу сүзеннән аның кәефе киткән иде.— Нәрсә мин?..

— Сез барыгыз да парлылар, ә мин ялгызым гына булачакмын. Күңелсезлек хәнҗәре йөрәгемне тишкәләүдән куркам,— диде Җантимер, болай да тойгылардан куерган сүзләргә кара дегет өстәгән төсле итеп.

Шуны гына көткәннәр диярсең, кызларның йөзләре кабат балкып китте. Сөйләшү тагын үз җае белән акты.

— Ничек парың юк? — диде Кадрия.— Булмаса, табарбыз, бездә кызлар бар!

Җәмилә, күзләрен сагышландырып, түбән карады. Йөзе буйлап кайнарлык йөгерде, тәннәре калтыранып куйды, калку күкрәкләрен, нечкә билен, сылу буй-сынын тибрәндереп назлы аһ, күңеленең тирән төпкеленнән чыгып, яшерен серләрен халыкка белдереп, йөрәкләргә ук кебек килеп кадалды.

— Үземә пар булырсың!—диде ул, шаярту төсе чыгарып.— Мин ярыймдырмы?..

Җантимер мондый ук тәкъдимне көтмәгән иде, бәгыре киселде. Авыз читлегеннән тел былбылы чыгып очты диярсең, нәрсә әйтергә дә белми газапланды. Җавапсыз калдырырга да теләмәде.

— Ярый, ярый, син дә ярыйсың!— диде Җантимер, Сабирҗанга да, башкаларына да ишетелерлек итеп.— Ярарсың әле!

Бу сөйләшү күңелсез бетәргә мөмкин иде. Сабирҗан тавыш чыгарса, Җәмилә үпкәләсә, барлык ниятләре челпәрәмә килеп ватылачак иделәр. Әмма да ләкин акыллы бәндә икән үзе. Юкка гына гомерен институтта укып үткәрмәгән,

чаялыгы файда иткәндер инде. Рәхәтләнеп, күңеле булганчы көлде Җәмилә, тагын да шаяртып куйды:

— Ярагач бик яхшы, Җантимер,— диде.

Бию-җырдан торган кичә тәмамланды. Җантимер, Җәмиләләр белән бер читтә көлешә башлагач, башкалар моны үз адресларына алып, залны ташлап ук чыкканнар икән. Клубта утлар сүнде. Эчтәге яшьләр, төркем-төркем булып, караңгы һәм тыныч кына йоклап яткан авыл урамнарына вә тыкрыкларына кереп югалдылар, парлылар капка төпләренә сыенып калды.

Җәмилә белән Кадриядән Җантимер аерылырга теләмәде, алар янәшә баруларын дәвам иттерделәр. Сабирҗан да мыштым маэмай төсле аларның артыннан иярде. Югары очта «Шахта көе»нә кемдер гармун тартып җибәрде, аның шулкадәр дә оста уйнавы күңел күзләрен үзенә каратты. Әмма уенчы бераздан тынып калды. Инеш шаулавы, вакыт-вакыт кына берәр баскыч асты көчекнең ләң-ләң итеп куюы, бакаларның тамак төбе белән сайраулары һәм йоклаган җиреннән адашып алгалаган җил кисәгенең агач башларына тиеп, тупылларны лепердәтүеннән тыш башка тавыш юк иде. Күрше урамда берәү мотоцикл кабызды, чинатып китеп барды. Якын-тирәдәге берәр авылның җиде йөрәкле егете бездән кыз тапкандыр инде, шуны эзләп, күрешү өчен төшкәндер.

Сабирҗан иярә килде. Кадриянең үз егете бүген кайдадыр киткән икән, шуңа ул парсыз. Аны Җантимер озатсын микәнни?

Кызлар, колак куешып, нидер сөйләштеләр. Моның нәтиҗәсе тиздән беленде. Кадрия Сабирҗанны култыклап алды, Җантимер өчен Җәмилә әзер иде. Әйдә, аңлашыгыз, асыл егет — сылу кыз! Моңа кадәр ничек кенә булса да Җәмилә белән калу җаен уйлап баш катырган Җантимер көтелмәгән бу уңайлыктан югалып калды. Сабирҗан исә Кадрияне озатып килергә мәҗбүр иде.

— Әйдәгез, бергәләп барабыз,— диде Җантимер.— Күпер аша чыгасыгыз да бар!

Ул кирәкмәгән сүз әйтте. Моңа Җәмиләнең ачуы килде.

— Әйдәгез,— диде Сабирҗан.

— Йөрмәгез, мине Сабирҗан озата,— диде Кадрия.

Җәмилә бу вакытта җан дустына мең рәхмәтле иде.

Әмма Җантимернең килделе-киттеле сөйләве генә бәгырен кисте. Ничек дип аңласын инде ул аны хәзер?

— Без киттек, озатам-киләм,— диде Сабирҗан, Кадрияне ашыктырып.— Әллә син дә барасыңмы, Җәмилә? — Ул шикләнеп тукталды һәм бәгыре түрендә изге рәсем итеп саклаган җан кисәгеннән сорады. Әмма кыз:

— Юк-юк, әни соңга калып йөрергә кушмады. Мин кереп китәм, сау булыгыз! — дип, капка бавына барып тотынды.

Сабирҗан белән Кадрия түбән очка төшеп киттеләр, Җантимер урам уртасында торып калды. Нигә комачаулап йөрде инде ул? Аны бу хәлгә төшерү әллә кызларның хәйләсе генә идеме?

Кадрия, шактый күркәм булса да, Җантимергә ошый торган кыз түгел. Ә менә Җәмилә, төшеңә керсә, төшлегеңне кузгатырлык! Сабирҗан ничә еллар аның кулын үбү өчен генә дә ярты җанын бирергә әзер булып йөри. Ә Җәмиләне Җантимер капка төбендә үк туктата ала иде. Менә бит кызык иттеләр. Хәер,

Сабирҗан болай да төн йокысын югалткандыр инде?

Җантимер үз урамнарына таба борылды. Көлеп куйды һәм эре адымнар белән атлап китте. Төн караңгы, җылы, рәхәт, әмма йолдызсыз, җылы юрган болытлы иде.

— Җан-ти-мер! Җантимер!

Пышылдап кына кемдер дәште. Егет туктап калды, тавыш килгән яктан сүз иясенең шәүләсен шәйләргә тырышты.

— Җантимер!

— Әү? Нәрсә булды? — дип сорады егет, дәшкән кешенең Җәмилә икәнлеген төшенеп.— Нәрсә бар? Чыгып сөйләш!

Җәмилә койма артыннан чакыра икән. Нишләп чыкмый ул, бер-бер хәл булмагандыр бит?

— Мин урам якка чыкмыйм, безнең бакча башына мен, хәзер килеп җитәм,— диде Җәмилә, ярым каушаган, әмма үтенеч тулы теләк тавышы белән.— Хәзер киләм, Сабирҗан күрмәсен!

Менә сиңа мә! Аңла бу кызларны. Нәрсә кирәк инде аңа?

— Ярар,— диде дә Җантимер.

Тыкрыктан кереп, бакча башына менде. Еш-еш сулап, бераздан Җәмилә дә күренде һәм кече капкадан артка чыкты.

— Күлмәгемне пычратып бетердем бугай? Аягымны да кычыткан чакты,— дип зарланды ул. Әмма үзалдына сөенеп әйтүе аңлашылып тора иде. .

Җантимер ни дияргә дә белмәде. Кыз болай яхшы сайрый аңа ошый иде булса кирәк.

— Ой, бүгенге кичә нинди матур, нинди җылы, нинди рәхәт, бик рәхәт,— диде Җәмилә һаман да, аяк киемнәрен кулына тоткан хәлендә чыклы үләндә бии-бии бөтерелеп.— Үзе җылы, үзе рәхәт...

Җантимер һаман да сүзсез калды. Минутлары илаһи, гаҗәеп илаһи шул. Ничек итеп ихластан тыңлап тормыйсың ди?

— Җантимер, әйдә, болыннардан әйләнеп киләбез. Әнә аргы очта яшьләр йокламый, магнитофон уйнаталар!..

Җантимер һаман да сүзсез калды.

— Син мине, бу нинди сәер-исәр кыз дип уйлыйсыңдыр инде, әйеме? Юләр, дисеңме?

Җантимер тагын да эндәшмәде.

— Алай уйлама инде. Минем бәхетле көннәрем, диплом алдым, Уфага эшкә китәм. Анда ничекләр булыр икән? Күңелсез түгел микән?

Җантимер һаман да сүзсез иде. Җылы һәм якын итеп кенә кызны кулыннан тотты.

Җәмилә сөйләвеннән тукталды. Әмма:

— Җантимер?..— дип аптыраулы сорау бирергә өлгерде.

Тавышы сак иде.

— Җәмилә!..

Тавышы назлы иде.

— Әү? — дип сорады кыз, иркә тавыш белән.

— Җәмилә, әйдә...

— Кая?

— Болынга барыйк, диден!

Алар китте. Бу вакытта күк йөзе вакыйгаларны күреп калырга дип болыт пәрдәсен чак кына ача төште. Күз сирпегән йолдызлар, авызлары ачык хәлдә онытылып, сәер хәлдә түбән карадылар. Хәйран иделәр.

Айның да йөзе ачылды. Җәмилә белән Җантимер су буенда янәшә утыра иделәр. Салкынча җил исеп куйды. Таңны уятырга тели идеме? Иртәрәк бит әле... Әмма җил бераздан тагын тибрәнәчәк. Өстендәге җәйге курткасын салып, Җантимер кызның аркасына япты.

— Салкындыр?..

— Рәхмәт!..

Шуннан соң алар күп нәрсәләр хакында сөйләшеп алдылар. Әмма икесе дә бер үк сорауны бер-берсенә бирергә батырчылык итмәделәр. Югыйсә ул болай булырга тиеш иде:

— Синең яраткан кешең бармы?

Яки:

— Синең кебек гүзәл затның аккоштай пары бардыр инде?

Таң алдыннан була торган эңгер җәелде. Беренче күрешү-озатышу өчен бу кадәр соңаруның итагатьне бозу икәнлеген Җәмилә аңлый иде.

— Мин кайтам инде, өйгә керергә вакыт,— диде ул, әмма Җантимернең әтәч тиреседәй юка курткасын өстеннән салмады.

Алар, тыныч адымнар белән килә-килә, капка төбенә җиттеләр. Кыз, егеткә таба борылып, нәкъ алдына туктады да:

— Мин керәм инде,— диде, тынычлыгын югалтып.

Бу вакытта Җантимернең әрсез кулы капка бавын тартып, ачылып китсенгә әзерләп куйган иде инде.

— Ярар, керерсең,— диде ул, ачыла барган капканы тотып.— Әмма бер сүзем бар. Син сихерле бер кәлимә әйтергә тиешсең!

— Нинди кәлимә ул, Җантимер? — диде Җәмилә, аңламыйча калып.

Җавап һәрхәлдә гүзәл романнардагыча булырга тиеш иде: «Иртәгә чыгарсыңмы?.. Мин сине көтәрмен!»

Җантимер китап телен болай да яхшы белә, әмма кабатланырга теләмәде, әйтте дә куйды:

— Яратам, диген, керерсең!

Кыз каушады. Тәне буйлап рәхәтлек йөгерде.

— Яратам, диген, керерсең,— диде тагын да Җантимер, сорап алган кеше төсле шарт куеп.

— Юк! — диде Җәмилә.

— Димәк, кермисең? — Җантимер гүяки алдан ук шушы җавапны көтеп торган иде.

— Мин алай әйтмәдем,— диде кыз, бер дә юктан оялып.

Җантимернең әрсезлегенә каршы усал сүз дә ычкындырырга хакы бар иде аның. Әмма һаман оялуда булды:

— Мин алай дип әйтмәдем, Җантимер!

— Әйтмәдең? Ә нәрсә дидең? Яратам дидеңме? Йә-йә!

Бу инде чын мәгънәсендә оятсызлык иде. Әмма кызның үлчәү тәлинкәләре ватылган минут шул бу.

— Яратам,— диде ул. Әйтте һәм үз сүзеннән үзе тагын да ныграк оялды.— Керим инде?..

— Тагын әйт,— дип әрсезләнде егет.

— Мин сине яратам,— диде Җәмилә. Бу юлы каушавы узган иде инде.— Керим инде!

—Ышанмадым, тагын әйт. Аннан соң керерсең. Хакыйкать булсын өчен сүзнең өч кат кабатлануы шарт, өч дәлил кебек аңлашылыр.

— Мин сине яратам, Җантимер,— диде кыз.

Әллә уйный, әллә чынын сөйли иде. Егет тәмам коелып төште. Нәрсә өчен уйнап маташты соң ул? Әгәр дә Җәмилә дөресен әйтсә? Әгәр дә яратуы хак булса, ул вакытта нәрсә эшләрсең соң?

Җантимернең куллары җыелды, капка бавы буш калды, кызга юл ачык иде.

— Сау бул!—диде дә Җәмилә өйләренә кереп йөгерде.

— Сау бул,— дип озатып калды Җантимер,— сау бул!

Үзалдына көлеп куйды ул. Чөнки сөйләшүнең болай ук йөрәге файдасына буласын көтмәгән иде. Кем бит әле, үзе, Җәмилә, беренче озатудан ук авыз тутырып: «Мин сине яратам!» — диде, Җантимернең йөрәген кузгатты, бәгырь үзәгенә мәхәббәт гөлчәчәгенең кайнар очлы энәсен китереп кадады. Егет үз өйләренә таба юнәлде. Авыл иртәнге тынлыкка чумган, бары тик таң әтәчләре генә тавыш бирә, хәтта маэмайлар да талып йоклый иделәр.

Буш урамда Җантимернең авыр аяк тавышлары үзара сөйләшәләр кебек иде: «Сөйгәнеңне таптыңмы, егет? Сөйгәнеңне таптыңмы, егет?» Ә ул чыннан да сөйгәнен тапкан иде. Иртәгәге көн, юк инде, бүгенге көн тагын нинди яңалык алып килер? Кеше көлкесенә калдырырмы, әллә инде йолдызларга кадәр чөярме егетнең күңелен?

Ә йолдызлар сүнеп беткәннәр, бары тик арадан берсе генә, таң йолдызы Чулпан гына кызарып яна иде.

Бу көнне Җантимер вакытның ничек озын һәм озак сузылганына аптырап бетте. Шашлыкка ит тә, үз ягыннан бераз шәраб вә хәмер дә әзерләп куйды. Аннан тыш никадәр эшләрне башкарып ташлады. Арымады-талчыкмады. Әмма вакыт дигәне һаман да сөйрәлеп кенә атлый бирде.

Көн кичкә авышканда, Җантимер тәмам зарыгып беткән иде. Юк сәбәпне бар итеп, Җәмиләләр турыннан әйләнеп кенә килергә берничә тапкыр ният тә кылып карады. Хисләре аны ашкындыра иде.

Җәмилә, мескенем, урам юлдан егет-кыркын күренү белән, тәрәзәдән-тәрәзәгә йөрде, гаҗизләнде юкка. Ә егет кисәге, Җантимере, узмады гына шул, узмады. Аптырагач, аргы очның чишмә суы яхшы дигән сәбәп белән чиләкләрен яшел көянтәсенә элеп, почта буен да әйләнеп килде Җәмилә. Әмма күрергә теләгән кешесе очрамады, чиләкләрен кат-кат юып-чайкап азапланып беткәч кенә кайтыр юлга чыкты һәм су буенда утын ватып яткан кайнар Җантимерне шәйләп алды, күңеленә эссе капты, тәне ут булды, җилкәсеннән көянтәсе белән бергә чиләкләре чак кына төшеп китмәделәр.

Кич инде. Сабирҗан, йөк машинасы әрҗәсенә утыргычлар җайлап, чатыр

һәм башка кирәк-яракларны салып, билгеләнгән урынга килеп туктады. Кадрия белән Җәмилә инде шунда иделәр.

Кадриянең егете Тимергали «Иж» мотоциклы белән Сабирҗан алдыннан гына килеп җитте. Ул — күрше авыл егете. Күптән бу тирәдә чуала. Сөйләүләренә караганда, уңган егет, бик тә уңган, диләр үзен, килеш-килбәт тә яхшы. Әмма салгаларга ярата икән. Шулай да холыксыз түгел, ди. Кадриясе үлеп сөя үзен. Мәгәре бүген өйләнәм дисә, каршы да килмәячәк, тик менә егет кенә ашыктырмый. Кызның капка төпләрендә кунса куна, әмма бераз сабыр итә әлегә. Үзеннән башкага Кадрияне каратмаячак.

Сабирҗан яшьләрне кузовка утыртты, Җәмиләне үз янына алмакчы иде, тыңламады җан кисәге, өстә, башкалар янында урын тапты. Тагын да ике капка төбенә тукталып, берничә кешене алдылар. Җантимергә дә чират җитте. Ул, көтмәгән кебек, эш белән мәшгуль булып маташа иде. Әтисе дә, энесе дә шунда иделәр.

Сигнал бирделәр. Җантимер үзен эзләп килүләрен, ашыктыруларын аңлап, алдан хәстәрен күреп куйган әйберләрен кәгазь тартмада алып чыкты да кузовтагыларга тапшырды:

— Ватмагыз!

Җантимернең кием алыштырганын чак кына көтеп торырга туры килде.

Кузгалдылар. Кызлар-егетләр җырлап җибәрде. Кояш баеп маташа. Машина элдертә генә. Анда, барыр юлда Җидегән чишмә һәм серле урман көтә.

Җантимер җырга кушылмады. Ә Җәмилә исә, аңа да карамастан, сөендешатланды. Бик яхшы, шулай кирәк, бүген аның бәйрәме.

Җидегән чишмә чыннан да матур җирдә икән. Аның бер ягында — сылу каенлык, икенче башында — юкәлек, хәтта аз гына шомырт агачлары да бар.

Егетләр, караңгылык иңгәнче дип, җәһәтрәк палатка-чатырны кора башладылар. Җантимер, коры-сары утын җыйнаштырып, учак тергезде. Шашлык хәзерләү эшенә җитәкчелекне Тимергали үз кулына алды. Бар да җитешкәнче, кызлар, ашъяулык җәеп, табын җәйделәр. Тасмалардан төрле якларга дәртле вә мәхәббәт самимиятенең моңлы көйләре агыла бирде.

— Егетләр, өстәл әзер, мәҗлесне башлыйбыз,— диде Кадрия, һәммәсен дә үз янына дәшеп.

Җәмилә аның кырына тезләнде. Сабирҗан да алар тирәсеннән урын тапты, ян белән ятты. Тимергали үз җанашы Кадриянең икенче ягыннан җайланды. Җантимер өчен барыбер иде. Җәмилә буш түгел, Сабирҗан монда. Шунлыктан урынны каршы яктан сайлады. Әмма ул да башкалар белән тигез сыйланды. Бер утыргач, мәҗлес бердәм дәвам итте. Кайбер парлылар беразга гына булса да учак янын ташлап, караңгы юллардан йөреп килгәләделәр. Әмма озакка югалучыларның барлыгы-юклыгы сизелмәде. Җәмиләне Сабирҗан Җидегән чишмә тарафына дәшеп карады. Әмма кыз аңа иярмәде, мин китсәм, мәҗлес таркалыр, аңла инде, дидеме? Ә Җантимер башка нәрсәне төшенде, комачаулый иде ул аларга. Чатыр эченә кереп, почмакка сеңде. Хәзер Җәмилә дә Сабирҗаны белән йөреп килә ала дип уйлады ул үз алдына, нигә араларына керергә?

Чатырның хәйләсе бар икән. Яшь парлар монда керәләр дә тәгәрәшеп үбешәләр. Беренчеләр булып Кадрия белән Тимергали эчкә үттеләр, ишекне бәй-

ләштереп куйдылар һәм, иркәләнә-сөешә үбеш уенын башлап, бер-берсенең дәрт тулып җитлеккән ирен һәм ияк асларыннан мәхәббәтнең пешкән алмасын ашадылар. Шулай шактый гына сөю-сәгадәтнең назын вә ямен-тәмен татыган чакларында чатыр ишегенә Сабирҗан килеп, аны чишеп җибәрде. «Хәзер Җәмилә белән аның чиратыдыр инде?»— дип уйлады Җантимер, поскан җирендә мыштым гына песи кебек күзләп.

Сабирҗан ялгызы керде. Кадрия белән Тимергалигә тап булып:

— Җәмиләне дә чакырыгыз әле? — дип үтенде.— Сине эзли ул, Кадрия, кая китте икән, ди.

Егетнең тозагы идеме бу, әллә инде чыннан да шулаймы? Хәер, моның ни әһәмияте бар?

Кадрия шунда ук Җәмиләне чакыра башлады:

— Мин монда, чатыр эчендә, Җәмилә, кил!— диде ул.

Җәмилә якында гына икән. Ул да керде. Аның урыны Сабирҗан белән Җантимер арасына туры килде.

— Монда кемнәр бар соң? — дип сорады ул, борчылган тавыш белән.

— Мин, Тимергали, Сабирҗан,— диде аңа җавабында Кадрия.

— Җантимер дә монда кергән иде түгелме? — дип сорап куйды Җәмилә.— Кайда икән ул? Бер дә якын-тирәдә күренми, берәрсе беләнме әллә?

— Сәвияләр беләндер, алар белән китте бугай,— диде Сабирҗан, белгән кеше шикелле.— Әйттем бит инде! Артларыннан күреп калдым. Сиңа нәрсәгә кирәк инде ул?

— Юк, болай гына соравым иде,— диде Җәмилә, борчылган тавышы белән.— Болай гына... Сабирҗан, тик кенә утыр әле!

— Җантимер белән минем сөйләшәсем бар иде,— дигән булды Тимергали, сәбәп тапканын сиздермичә, урыныннан кузгалып.

— Нәрсә хакында? — дип сорады шунда Җантимер, барысын да хәйранга калдырып.

— Абау, монда кеше бар икән! — дип курыкты Кадрия.— Йөрәгемне кузгаттың!

Җәмилә караңгыга таба кулын сузды, бармаклары Җантимернең башына туры килде. Шунда, форсаттан файдаланып, иркәлисе итте. Сәвияләр белән китте дигән булалар тагын, менә ул, монда икән!

— Аһ астыртын,— диде Кадрия,— аһ астыртын! Тыңланып кына ятасың монда, песи кебек!

— Ярар, ятмыйм,— дип, Җантимер чатырдан чыгарга күтәрелде. Кемдер чабуыннан тыеп калмакчы иде, әмма егет аңа буйсынмады. Кадриядән тагын әллә ниләр ишетер йә?..

Җантимер, ялгызлыктан аптырап, караңгы юлдан атлады, иркен иген басуына чыкты. Офык ачылган, таң беленеп килә иде. Иртәнге эңгер-меңгер. Җәйге төн кыска, үтеп тә бара.

Сабирҗан машинасын кычкыртты. Җыелу сигналы. Җантимер килеп җиткәндә барысы да монда иделәр. Табында соңгы шәраб вә хәмерләр ачылган, савытларга бүленгән, һәркемнең алдына берәр өлеш шашлык куелган.

— Әйдә, утыр, кайда йөрисең, кузгалабыз, бушатабыз да!..— Тимергали

Җантимерне ачуланды.— Әллә кайтып киткәнсеңме, дигән идек! Үпкәләп!

Җантимер хәмерне бер-бер артлы күтәрде. Шашлык тәмле иде.

Кызлар табынны җыештыра башладылар. Буш шешәләрне, кәгазь һәм башка артык-портыкны чокыр ягына Тимергали илтеп ташлады, Сабирҗан чатырын сүтеп төрде. Кузовка аттылар. Төялештеләр. Бу юлы да Җәмилә кабинага утырмады, өскә күтәрелде. Җантимернең янына үзе килеп басты һәм бер кулы белән кузовның биек җиренә тотынды, икенчесе белән егетне култыклап алды.

— Сиңа ышанам, мине тотып кайт!— диде, серле итеп.

Бу сүз күп нәрсәләр хакында сөйли иде. Җантимер кызның биленнән кочты. Машина кузгалып китте, арттан мотоциклына атланган Тимергали иярде. Тузан күтәрелгәнлектән, аннан килә алмыйча, башка юлга кереп югалды.

— Адашмас микән? — диде моңа борчылган Җантимер.

— Адашмас,— диде Җәмилә,— юлларны яхшы белә ул.

Яшьләр җырлап җибәрделәр. Инде Җантимер дә кушылды. Шушы рәвештә таң алдыннан алар авылга кайтып төштеләр. Барысы да Җидегән чишмә буенда узган бу кичәдән канәгать иделәр.

Сабирҗан машинасын Җәмиләләр тыкрыгына китереп туктатты. Тимергали дә кайтып җитте. Мотоциклы әкәмәт әшәке тавышлар чыгарып үкерә иде. Боташкамы, агач төбенәме барып менгән дә, төтен юлын тиштергән, хәтта өздерә язган икән. Егетләр шуны караштыра башладылар.

— Моны болай гына юньгә кертеп булмый,— диде Җантимер,— алыштырырга яки яматырга кирәк.

— Кайтып җиткәнче чыдый ул,— дип, Тимергали кулын селтәде, аптырап тормастан.— Болай да рәте-юне китеп бара иде.

Яшьләр тарала башладылар. Сабирҗан да нигәдер машинасы тирәсендә кайнашты. Җәмилә белән Җантимер икесе генә бергә калган иделәр. Шунда:

— Рәхмәт әйтеп килим әле,— дип, Җәмилә Сабирҗаны янына китеп барды.

Димәк эшләр шулайрак тора!

Җантимер, үзенең артык икәнен аңлап, юл уртасыннан сукмакка таба атлады. Шул килеш кенә эз суытасы иде дә, аны Җәмилә дәште:

— Җантимер, чиләкләрне алып кереш әле!

Егет кире борылды, кыз чыннан да чиләкләр күтәргән, үзләренең капка янына да килеп җитә язган иде.

— Тагын бармы? — дип сорады Җантимер.

— Менә, кулымда, егет бул әле, күтәреш!— дип әмер итте гүзәл зат, күңел түреннән килгән назлы һәм татлы тавышы белән сихерләп.

— Җиңел ич болар,— диде Җантимер, үртәпме-үртәлепме.

— Синең өчен,— диде кыз.

Капканы ачып керделәр. Чиләкләрне болдыр төбенә китереп куйдылар. Әмма Җантимер кире чыгарга ашыкмады, басты да калды.

— Бар инде, соң бит,— диде Җәмилә.

— Соң түгел, иртә инде,— дип үртәде егет, аның хәзер шаяртып сөйләшергә кәефе килеп тора иде.

Сабирҗан машинасын кабызды, бераз гүләтеп торды да үз капка төпләренә таба кузгалып китте.

— Бар инде,— диде Җәмилә, Җантимерне куалап.— Китмәсәң, сөреп чыгарам хәзер!

— Әйдә, чыгар,— диде Җантимер, исе дә китмичә.

Егетне Җәмилә күкрәгеннән салмак кына артка этәрә бирде. Менә Җантимер капка баганасына аркасы белән килеп сөялде һәм кызны кулыннан тотып алды.

— Җибәр!— диде Җәмилә, әмма кинәт усаллыгы сүрелде.— Җибәр...

— Җибәр, әнине чакырам, диген! — Егет үртәргә теләде.

— Җибәр инде, Җантимер, өйгә керәсем бар, соң инде,— диде кыз, үтенеп.

— Бер үп, аннан соң керерсең!

— Үпмим,— диде Җәмилә, башын артка алып,— нигә мин сине үбәргә тиеш әле?

— Ярый алайса, үзем үбәрмен,— диде егет һәм кызны кочагына алды. Җәмилә карышмады.

— Үбәм,— диде егет һәм кызның иреннән суырып үпте. Татлы һәм йомшак иде алар. Түзмәде, тагын-тагын үпте.

Инде икесе дә тынычланып калдылар. Шул рәвешле берничә минутка югалып тордылар. Шунда Җәмилә:

— Җантимер, керим инде, соң бит,— дип айнып китте, әмма хәрәкәтләре салмак иде.

— Үп, аннан соң керерсең,— диде Җантимер, иске сүзен яңартып.

Җәмилә үрелеп кенә үзе үбеп алды. Татлы, тәмле, рәхәт, үлене терелтерлек иреннәр иде алар!

— Тагын,— дип пышылдады егет.

Алар шулай шактый озак үбештеләр. «Мин сине яратам!»— дип, бер-берсенә изге сүзләрне әйттеләр һәм Җәмилә, инде егет кочагыннан чыгарга теләмәгәнен хис иткән хәлендә, барыбер дә өйләренә кереп китте. Бу вакытта кояш үзенең алсу нурларын аяз күк йөзендә уйната башлаган, сыер саварга чыккан түтиләр чиләкләрен шалтырата, мал куа иделәр. Җантимер тагын үзеннән-үзе көлеп куйды. Бу серле кичәнең болай сихри тәмамлануы аның өчен сәер, бик тә сәер иде.

— Тыныч йокы, җанкисәк!

Бу сүзне ул Җәмиләгә әйткән иде, хәзер урам буйлап кабатлап бара:

— Тыныч йокы, җанкисәк!

«Җан кисмәгең капкачлы булды!» — дип, үзе хакында уйлап куйды егет. Аның йөрәк түрендә мәхәббәт уты очкынланып-очкынланып уйный иде. Ә Җәмилә ниләр кичерә торгандыр? Ә Җәмиләкәй нинди утларда яна торгандыр? Назлы, татлы, чибәр, сылу, сихри кыз Җәмилә, Җәмиләкәй!

Икенче көнне Сабирҗан Җәмиләнең янына да килмәде. Машинасында ерак юлга киткән, диделәр. Җәмилә дә капка төпләрендә озаклап утырмады.

— Мин бер атнага Чаллыга барып кайтам. Бүтән кызларны берүк озатма, ярыймы, Җантимер!— дип үтенде ул. Үзе кочты, үзе үпте. Кирәк булганга гына аерылыштылар. Юкса таң аттырасылар иде.

Бер атнага! Монда сәгате көнгә тигез, ә ул бер атна буена булмаячак. Ничек түзәргә мөмкин? Бер атна!

Атнаның беренче көнендә үк Җантимер Җәмиләләр очын ике әйләнде. Бәлки китмәгәндер, ә?

Кыз чынында өйдә юк иде. Җантимергә күңелсез хәзер. Рәхәттән күңеле михнәткә төште.

Колхоз эшенә Казаннан эшче кызларны китергәннәр икән. Алар тыкрык башы Кәҗә Гайфуллада яшиләр, ди. Тагын да бер хәбәрне Җантимергә энесе Зарифҗан алып кайтты. Ферма төзекләндерү-ремонт эшенә Казан университетыннан егетләр килеп ялланганнар, шабашкага. Авылда студентларның барын-югын сорашканнар, аралашу өчен. Зарифҗан моны сөйләп бетергәч:

— Абый, синең хакта әйткән идем, белмибез андыйны, диделәр,— дип өстәп куйды.— Университетныкылар микәнни соң алар, сине дә белмәгәч?

—Һе,— диде Җантимер,— университетта унбер мең студент кына укый, кайдан алар барысын да белеп бетерсеннәр икән? Мин дә аларны танымый торганмындыр? Очрашырга кирәк, танышырга!

Җантимернең печән чабу эше белән көне үтеп китте, һай рәхәт вакытлар. Саф һава, хуш ис. Кигәвен кебек зәһәр мәлгуньнәр булмаса, тагын да яхшырак та бит. Төрле яклап кунып талыйлар, бигрәк тә көндезге унбердән өчкә кадәр котыралар, юньсезләр!

Кичен Җантимер теге студент егетләр янына китте. Бишәү икәннәр, математиклар. Танышып-белешкәч, клубка чыктылар. Җантимергә монда күңелсез иде. Студентлар да кәеф таба алмадылар.

Зарифҗан шунда абыйсы Җантимергә ялынды:

— Анда Казан кызлары өйләрендә бикләнеп утыралар, ди. Чыкмыйлар. Әллә үзең барып, клубка чакырасыңмы соң аларны?

— Нигә? — диде, исе китеп Җантимер.

— Нигә булсын, син элекләрне дә Казан кызларын үзеңә ияртеп йөри идең. Егетләр дә шулай сөйлиләр. Абыең алып чыкса, без танышыр идек үзләре белән, диләр. Әйдә инде, абый?

Аның сүзләрен студентлар да колакларына элделәр. «Нигә монда торабыз?» — дип, Җантимерне әйдәкли башладылар. Юл уңаенда шабашник студентлардан Җабир гитара алып чыкты, шәп уйный кебек болай.

Кызлар бер дә бикләнеп утырмаганнар икән. Ишекләре шар ачык. Студентларны капка төбендә калдырып, Җантимер түргә узды.

— Сәлам кызларга, асыл кошларга! — диде ул керә-керешкә үк.— Шундый матур кичтә сагышланып утырасызмы?

— Ә нәрсә эшлик инде? — дип сүз башлады арадан бер чаясы.— Авылдаш егетләрегез тәрәзәдән карап йөрүдән башканы белмиләр бит!

— Мондый чибәрләрдән күзләрен алалмаганга шулай тәрәзә күзлиләр алар! — Җантимер шаярткан төсле әйтте.— Чыгып күренегез үзләренә, тынычланырлар... Бер нинди сере дә юк моның!

—Х-ә-ә-зер!— диде кыз, үртәлеп.— Чыктык, йөгердек.

— Бик яхшы, ул вакытта — сөйләштек, клубка алып барам үзегезне! Киенегез, ясаныгыз, унбиш минуттан әйләнеп керәм. “Бәхетебез бар икән” дип дога кылыгыз. Бәлки кайсыгыздыр назлы ярын да эзләп килгәндер? Бездә егетләр бер кашык су белән йотарлык. Үзләре — чибәр, үзләре — эшчәннәр. Минем ке-

бек... Әйе!..

Җантимернең сүзгә һаман-һаман үзен кыстырып куюлары шаярту өчен генә иде югыйсә. Әмма мактану буларак та килеп чыктылар. Каршыларында басып торган бу асыл затны күреп торган кызлар аның сүзләренә чын күңелләреннән ышандылар. Килеш-килбәтенә сокланып күзләре уйнады, сүзләрен тыңлаудан колаклары иркәләнде.

— Болай ук итеп кодалагач, чыкмыйча да булмас, кызлар, әйдәгез, авылларын аслы-өсле айкыйк әле,— диде бер чаясы.

Аның белән һәммәсе килештеләр. Җантимер, ишекне ябып, болдырга чыгып басты. Йорт хуҗалары өлкәннәр икән, инде ятарга да өлгергәннәр. Аларны тынгысызлап йөрмәсәң дә ярар иде дә, әмма Зарифҗаннар кебек чебен көтүе тәрәзә саклый икән, йокы юк инде аларга. Алай да булмый, болай да яхшы түгел. Ике яманлыкның иң авырын сайлый, диләр, адәм баласын. Бу юлы да шулай килеп чыкты.

Кызлар үзләренең шәһәрчә кадак үкчә, нәзек баулы аяк киемнәрен киеп һәм затлы итәк, кофталардан чыккан иделәр. Теге чаясы Җантимерне култыклап та алды, әйтеп тә салды:

— Кая, күрсәт — күрсәтәсе әйберләреңне!

Һәммәсе эчләре катканчы көлде.

— Күрсәтсәм, куркып качмассыңмы? — дигән булды егет.

— Кая качасың инде?— дип элеп кенә алды чая кыз.— Безне монда көзгә кадәр җибәрделәр, эшегезне эшләргә. Үзегездән — юк, менә без бетереп китик әле. Дан булсын!

— Бетерергә килдек без бу җирне!..— дип күтәреп алды шабашник Тимур, балкытырга диясе урында, мәгълүм җырны башлап.

Кыз моның сүзләренә үпкәләргә тиеш иде, әмма төшеп калганнардан түгел икән. Бу чаялыгы белән Идел кичәрлек, ни җитте ир-егетләрнең борынына чиртерлек.

— Бетерәбез аны! Бетерәбез!..— диде кыз, егетләрне дәртләндереп.— Әйдә, киттек клубыгызга.

Шабашник студент егетләр дә бу эшче кызлар өчен шушы авылныкылар буларак аңлашылдылар, чөнки алар Җантимер белән килделәр, аның белән бергә йөриләр, ул әйткәннәрне куәтләп сөйләшәләр иде.

Казан кызлары артыннан бүтәннәр дә иярделәр. Урам буйлап гөрләшеп күтәрелделәр. Студент егетләр кулдан-кулга күчереп гитара чиртте. Авылныкылар арттанрак калып килә иделәр, җай табып, кызларның алдына төштеләр, һәммәсе үзенә яр сайларга тырыша, кайсына булса да сүз катарга җай эзли иде. Клубка якынлашып җиткәнче бер-икесе Казан кызлары белән танышып та өлгерде. Барысы шат, гөрләшәләр иде.

Клубта озаклап кичә ясау мөмкин булмады, инде соң икән. Мөдир, хафага калып, уңлы-суллы бүлмәләрне бикләп йөренә башлагач, яшьләр урамга агылды. Җантимер Казан кызлары белән чыкты.

— Хәзер кая барабыз? — диде чая кыз.— Ике мәртәбә биеп алыр өчен генә безне кузгатып йөрдеңме?

Бу чая телгә генә түгел, йөзгә-биткә дә шактый күркәм икән. Буе гына әллә

ни калку түгел, терсәгеннән аз гына өскәрәк үлчәмдә. Әмма минем буем тәбәнәк дип тормады әле, Җантимергә тигәнәк кебек чытырдап ябышты. Ну капты егет, уңга да, сулга да һичбер адым ясый алмый. Бетте башы, Җәмиләнең дус-танышлары алдында оятлы итә бу!

Казан кызлары белән җырлашып, инеш буйларын әйләнделәр. Җантимер аларга төрледән-төрле кызыклар сөйләп бетерде, чая кыз һаман да аның белә-гендә йөрде, күңеле хушланудан айный алмый идеме, әллә шушындый егетне күптән эләктерәсе килгәнме? Башка егетләр, дуга рәвешендә аларны урап, арт-тан көтүләре белән ияреп килделәр.

Болай ук шаулашып, авылның йокысын качыру ярый торган эшләрдән тү-гел иде. Җантимер бу чаядан ничек тә котылу җаен карады. Мәктәп бакчасында эскәмияләргә кызларны утыртты да сиздерми генә китеп тә барды. Җиткән! Булды, таныштырды!

Бу кичне егет сөекле Җәмиләсен бик тә сагынган иде. Ярый әле Казан кыз-лары булды, алар белән йөреп, күңеленә бераз тынычлык иңде. Өченче көндә инде ул тагын да ныграк боекты. Кич җиткәч, әүвәле яңа танышлары — студент егетләр янына барды, алар урыннарында юк иделәр. Казан кызларына киткән-нәр икән. Җантимер дә, кая барып бәрелергә белмәгән кеше төсле уңга-сулга йөренде дә тарсынып кына шунда юнәлде.

Кызларны студентлар капка төпләрендә көтеп утыралар икән. Яннарында бер-ике затлы шәраб шешәләре дә бар. Җантимерне күрүгә, Тимур дигәннәре көлеп җибәрде:

— Кичә сине үземә алыштырырга туры килде, малай. «Кая ул?» дип сораш-тырып аптыратып бетерде чаясы. Яхшы кыз күренә!

— Мин бик шатмын, Тимур. Барыбер үземә озатырга насыйп булмас иде аны,— дияргә мәҗбүр иде Җантимер.

— Нигә?

— Сәбәбе бар! Җиңгәң ачуланыр.

Һәммәсе дә тагын көлеп куйды. Җиңгә дигәне йөргән кызны белдерә инде анысы. Әмма егетләрнең гозерләре дә бар икән. Шәрабны күрсәтеп:

— Әйдә, оештыр әле, син җаен беләсең!— диделәр.

— Каян белим инде? — дигән булды Җантимер.— Мин дә сезнең кебек ин-де, Аллаһ бәндәсе!

— Юк, синең яхшы килеп чыга!

— Ярар алайса,— диде Җантимер, алар белән килешеп,— китерегез шәраб-ларыгызны.

Икесен дә кулына тотып карады да, берсен кире бирде.

— Мин, кереп, өстәл оештыра торам, унбиш минуттан рәхим итәрсез,— диде дә Казан кызлары янына ашыкты.

Алар әле мунчадан гына чыгып маташалар икән. Җантимерне күрүгә, ай-һайлап кайсы-кая посты. Чая кызның гына исе китмәде. Халат кигән хәлендә, күкрәкләре ачылып китүдән дә хафаланмыйча, көзге алдында боргаланып-бор-галанып, калын чәчләрен йомшак сөлге белән сөртә бирде. Исәнләшеп түргә уз-ган егеткә ләм-мим бер сүз дә әйтмәде. «Менә, күр, мин баймы?» — дигәндәй, һаман әле уңга, әле сулга бөгелде. Калку күкрәкләре, нечкә биле, чүлмәк төсле

кояшта янган тыгыз тәне күзләрне адаштырырлык матур иделәр. Җантимер, өстәл янына килеп, теге шешәләрнең берсен уртага куйды һәм тәкъдим ясады:

— Сыйланабызмы?

Җавап ишетелмәде.

Кызлар белән болай сөйләшү ярамый иде. Әмма сүзне кайдан башларга?

— Оҗмах кошлары,— диде Җантимер, тагын да бер тапкыр талпынып, сөйләшүне башлар өчен тагын да атлыгып: — Кызлар, күчтәнәч бар иде, яхшы шәраб! Илдә-көндә юк нәрсә!

— Әрсез,— диде чая кыз,— әрсез! Кешенең киенәсе бар, ә ул күзен дә йоммый, ояла да белми!..

— Ярар инде,— диде җавабында егет.— Шундый гүзәллеккә каян килә бу кадәр усаллык.

Бетте, егетнең кирәген бирәләр хәзер, җанын ашаячак бу чая. Сөйләшә белмәсә, тик кенә торсын иде. Усалга «усал» дип әйтсәң, башыңны бетерә дә бетерә бит инде!

Әмма чая кыз бер генә сүз дә әйтмәде. Киенде-ясанды һәм:

— Кичә кая югалдың? — дип сорады.— Качтың! Ә бүген тагын килеп җиткәнсең.

Җантимер шушы сүзне күптән көткән иде. Бик яхшы булды әле бу.

— Сезгә алма өзеп китерергә киткән идем, килсәм, берегез дә юк,— дип, алдан хәстәрләп куйган җавабын бирде егет, акланган кыяфәт чыгарып.— Киткәнсез дә баргансыз...

— Алмаларың кая соң? — диде чая, ачуын яшермичә.

Җантимер үз сүзен сөйли бирде:

— Ярый әле көтеп тормагансыз, ул яшел алмалар белән ким-хур гына булачак идем. Суга агыздым.

— Әйтәм аны агып баралар иде,— дип төрттереп куйды чая.— Бүген генә су коенганда Әминә җыйды аларны. Менә! — диде дә өстәлгә бер тәлинкә яшел алмалар китереп куйды.— Шулар идеме?

— Белмим,— дияргә башы эшләде Җантимернең,— алар да кебек, алар түгел дә төсле. Охшаганнар икән...

Кызлар көлеп җибәрделәр. Кичә Зарифҗаннар җыеп биргән иде аларны.

— Синнән башка да сыйлаучылар табылды, сатлык! — дип, вакыйгага ямау салып куйды әлеге дә баягы чая.

— Ярар инде, кызлар? — дип ялынырга мәҗбүр булды Җантимер.— Гафу!

Ул арада ишектән студентлар килеп керделәр.

— Исәнмесез!

— О Тимур, Тимурчик!—дип бәргәләнде чая, халатының путасын ашыгып бәйләп.

Таза гәүдәле, кара мыеклы шабашник исә авызын мул итеп ерды да, канәгать төстә:

— Да, Саида, привет!— дип әйтеп куйды.

Башкалар да исәнләштеләр. Җабир дигәне, вәсвәсәләнеп:

— Ирочка чыккан идеме әллә? — дип сорады.

— Мин монда, Зибрик мой!— дип, чаршау артыннан киенеп-ясанган мөла-

ем кыз күренде.— Бүген клубка сходим, да?

Болар берсен-берсе табышып та өлгергәннәр икән. «Ике Тимернең берсе артык икәнлеге күренеп тора»,— дип уйлады Җантимер, үзен һәм Тимурны күздә тотып. Урыныннан кузгалды.

— Ә син куда? — дип аркылы төште чая.

— Клубка,— диде Җантимер.— Мин монда артык икән.

Аның бу сүзе кызга ошамады. Саида дигәч тә, исеме Сәйдә булса кирәк аның?

— Клуб бүгеннән ремонтта,— диде Тимур, ягъни Тимурчик дигәннәре.— Аны ачмаячаклар. Без эшлибез. Дивар-стеналарын эчтән буяп агарта башладык, анда бүген батып үләрлек. Бер айга җитәрлек эш бар.

— Ф-и-и-и,— дип сузды ирен турсайткан чая Сәйдә.— Авылга килеп тә клубта не быть, что это такое, кызлар?

— Я не люблю клубсыз авылларны, терпеть не могу,— диде аңа кушылып Ирочка дигәннәре.— Юньле авылда җәй көне кем инде клубка ремонт ясый ди? Эш вакытында әле, җитмәсә!

— Ә кайчан кирәк иде соң? — диде Тимур.

— А почему когда мы здесь?! — диде Сәйдә.— Без киткәч ясар идегез әле.

— Кыш көнеме?

— Нәрсә, без монда кышка кадәр ятарга обязаны, да? Нет уж! Безгә начальник цеха әйтте! «Не больше месяца!» диде. Унбиш-егерме көн, и без монда юк инде!

— Белмим,— дип сүз төртеп куйды Җантимер. Барысы аңа борылып карагач, аннары дәвам итте:— Сезгә кадәр килгән бүтән елгылар да башта шулай әйтә иделәр, октябрьдә, кар яугач кына китә иделәр.

— Ә син каян беләсең барысын да? Ел саен шулай Казан кызлары артыннан чаба идең дә, ташлап кача идеңме? Кар яуганчы, имеш. Ә без алай булмаячакбыз, вот, күрерсез! — диде Сәйдә, Җантимергә ачулы карашын ташлап.— Тоже миңа, җегет!

Барысы да кинәт сүзсез калды. Сәйдә чыгырыннан чыкса, чәйнәп ташлаячагын иптәшләре белә иде. Җантимернең авызы капланды, студентлар эндәшмәделәр. Сөйләшү темасы югалды. Ни әйтергә кирәген, нәрсәдән кабат сүз башларга тиешлеген дә аңламадылар. Шулай шактый гына тын торгач, арадан Җантимер сүз катып карады:

— Клуб та ачылмагач, әйдәгез монда гына сөйләшеп утырабыз,— диде ул.

Казан кызлары тәкъдимне теләми генә кабул иттеләр. Егетләр шәраб ачты. Тимур уен картасы чыгарып, аларны берәмләп таратты, башкалар да өстәл янына җыелыштылар...

Инде вакыт төнге унберләр якынлашып килә иде. Беренче булып урыныннан Җантимер кузгалды. Студентлар аңа иярде. Саубуллашып чыктылар. Ишек ачылган тавышка өркеп, әле мыек та йөртергә өлгермәгән берничә егет кисәге урамга чыгып шылды. Кемдер койма аша сикерде. Иптәшләре белән Җантимер Җәмиләләр тыкрыгына килеп керде. Төнге урамны ярып тавыш ишетелде:

— Җан... Тимур!..

Киң урамнар тараеп калгандай булды. Колагы белән генә түгел, күңеле бе-

лән дә ишетте Җантимер. Җәмилә бу, һай, Җәмиләкәй! Кайткан икән!

— Җан-тимер!..

Кыз урамның икенче ягыннан дәште, Җантимер башта ук моны шәйләп алды. Әмма:

— Тимур, сине чакыралар бугай? — дип әйтте. Үртәве идеме бу, әллә шаяртуымы?

— Юк! Җантимер Корбыев, сине чакыралар!

Бусы — Кадрия тавышы. Җантимернең аяклары баскан урынында катып калдылар. Көттереп кенә түгел, үзе үк ашыгып кайткан Җәмиләсе-Җәмиләкәе, бәгыре, назы, мәхәббәте!

— Ярый, егетләр, мине дәшәләр икән,— дип, саубуллашкач, кирегә борылды Җантимер. Кадрия белән Җәмилә икәүдән-икәү генә эскәмиядә сөйләшеп утыралар иде.

— Исәнмесез! — диде егет, аларны төнге караңгылыкка көчкә шәйләп, кайда утыруларын чамалап өлгереп.

Куанычын күкрәгенә сыйдыра алмый иде ул хәзер.

— Кайттың дамыни, Җәмилә?!

Их, сөйләшә белми дә инде, һай, егетләр! Сагынып көткән ярына кемнәр шулай ди? Бәгырем, ярым, дип әйтергә кирәк иде, өзелеп көттем, бик озак югалып тордың, нигә иртәрәк кайтмадың дияргә иде. Ә ул тагын ни сөйләнә әле?

— Бер атнага дип киткән идең, Җәмилә, ничек иртәләргә булдың?

Кыз чыннан да ашыгып-ашкынып кайтмадымыни? Өч-дүрт көне-кичәсе аңа озын бер гомер кебек тоелды шул. Аның бу рәвешле шулкадәр өзелеп кайчан һәм кемне сагынганы бар иде? Эһ, Җантимер, Җантимер! Чыннан да, җаның тимер-таш икән синең!

Җәмилә актан да, карадан да эндәшмәде. Аның күңеле елый иде. Кайтып төшүгә ишеткән беренче сүзе шул булды: Казаннан колхозга эшче кызларны китергәннәр икән, Җантимер аларны озатып йөргән! Җитмәсә Җәмиләнең йөрәк ярасына үз сеңлесе дә тоз салды: «Җантимер абый,— диде,— Казан кызларына шәраб бушатып утыра!»

Менә инде үз күзләре белән дә күрде Җәмилә: Җантимере шул кызлардан кәефләнеп кайтып килә!

— Ни булды, Җәмилә? Ник эндәшмисең?— ди Җантимер, аның да бәгыре өзгәләнә. Әмма кызның ник сөйләшмәгәнен әлегә белми иде ул.

— Җәмилә, нәрсә булды?

— Мин сиңа әйттемме? — дип, Җәмилә ачулы гына сүз ташлады.

— Нәрсәне?

— Кызлар озатма, дидемме?

— Мин озатмадым.

— Нигә алдыйсың, ничек озатмадың?

Кызның күңеле ярсыган иде. Кадрия урыныннан торды һәм саубуллашып китте дә барды, Җәмилә каршында хөкем көтеп торган Җантимер каккан казыктай катты да калды. Хәзер кирәген ала! Акланырлык сүзе дә юк. Җәмилә төннең караңгылыгын үз тирәсенә җыеп, деспот кыяфәтендә, сытып ташлардай булып, ачуын чак тыеп утыра иде. Бу — рәнҗү, мәхәббәтен аяк астына салып тап-

таган мәгъшугына үпкәләве иде. Кузгала-китә алмады кыз. Аның үз-үзен шулай тотарга хакы бар иде: ярата ул шушы Җантимерне, өзелеп ярата. Гүяки гомере буе яраткан, танышып-йөрешә башлаганнарына бер атна гына түгел, тулы бер гомер төсле!

Егетенең эндәшә алмый торуы Җәмиләне бераз тынычландырды. Дөрестән дә хәзер Җантимер өчен авызга су капкан кебек торудан да яхшысы юк, чөнки һәр әйтелгән сүзе кызның бәгырен генә изәчәк.

Җәмилә урыныннан кузгалды. Әмма өйләренә кереп китәргә теләмәде. Урам буйлап атлады, артыннан Җантимер тугры эт кебек ияреп бара иде. Ярата шул ул аны, өзелеп ярата!

Җәмилә бу юлы Сабирҗаннар турына килде. Җантимерне көлке хәленә куймакчы идеме, ягъни Сабирҗанны очратып, аның кочагына ташланып, белмим? Һәрхәлдә күңеленә ул уй кереп чыккандыр?

Әмма шунда гына Җантимернең үпкәләвеннән кинәт куркып китте. Тыкрыктан ташлы чишмә буена төште. Чирәмгә утырды. Рәхәт һәм йомшак төн, әмма күңеле генә изелгән. Челтерәп су ага. Чишмә тавышы хәсрәтне тарата, диләр, дөрес икән!

Шунда Җантимер дә Җәмилә янына килеп утырды, кочакламакчы булды. Кыз бар ачуы белән аның яңагына китереп сукты һәм, әрнеп елый-елый, егетнең күкрәген төя башлады.

— Мин сиңа әйтмәдеммени?.. Мин сиңа әйтмәдеммени?..

— Әйткән идең, яратам дип әйткән идең,— диде, кыз бераз тынычлангач, Җантимер.— Мин дә сине яратам бит. Өзелеп көттем. Сагынуымнан түзә алмас булып Казан кызлары янына бардым. Әмма берсен дә озатмадым мин аларның,— дип сөйләнде.

Җантимернең акыл чишмәсе саеккан идеме, әллә инде аклана да белмиме? “Иш янына куш” дигәндәй, һаман кирәкмәс сүзләр кыстыра. Казан кызлары янына барганлыгын кабатлап нигә исенә төшерергә кирәк иде соң? Болай да аңлашыла түгелме?

Акланган саен егет каралана башлады һәм тынып калды, сүзе бетте. Йә, нәрсә әйтә ала инде ул? Һичбер сүзе үтмәячәк. Иң яхшысы — кайтып китсен, яки тик кенә утырсын инде!

Эндәшми торырга кемнең дә башы эшли. Әгәр дә инде эшләми икән, ул вакытта кеше санына кереп тә йөрмәсен!

— Ничек инде син алай була алдың, Җантимер? — дип, авыр сулыш алды кыз.— Ничек алай була алдың?

— Мин сиңа хәзер бер кыйсса сөйлим,— диде егет, шуның белән барысын да аңлатырга теләп.— Әгәр дә тыңлар булсаң?

Җәмилә «ярар» дип тә, «юк» дип тә әйтмәде. Җантимер моны ризалык билгесе дип аңлады. Аңа хәзер барыбердер инде? Аралары болай да бозылды. Дөресен әйткәнендә дә кыз тыңларга теләми.

— Мин күп кызлар белән йөрдем инде... Хактан да — йөреп карадым,— дип, вакыйгаларны бәян итүгә күчте Җантимер.— Әмма берсен дә алдамадым, берсеннән дә көлмәдем. Йөри башлаган чагымда: «Менә ул — минем бәхетем!»— дия торган идем. Ә соңыннан, бераз вакыт дус булып йөргәч, юк, ул тү-

гел, дип күңелемә шик төшә иде дә җиңел генә ул кызны оныта торган идем. Ничек дип әйтим, алар минем өчен чын мәхәббәт булмагандыр инде...

Шушы сүзеннән соң егет сөйләүдән бераз тукталып торды. Күңеле моңлы аның, шуңа күрә сүзләре дә тәэсирле чыга. Җәмилә дә тынычланып калгандай булды кебек...

— Миңа инде егерме яшь. Азмы бу, күпме? Бу яшендә егетләр оя кора. Ә мин, чын мәгънәсендә дияргә кирәк, яши дә башламадым әле. Сине дә, беренче көнне озатуымнан соң: «Менә ул — минем бәхетем!» — дип уйладым. Яраттым мин сине, Җәмилә, яраттым! Әллә ничек кенә шулай килеп чыкты инде. Күңелем түрендә якты кояшым булдың син минем!..

— Беренче тапкыр гашыйк булуым тугызынчы сыйныфта ук булды, башыма сагыш өйде. Әмма мәхәббәтем хакында һичкемгә әйтмәдем, ә һәркем белеп алды. Бик авыр булды җавапсыз мәхәббәтнең ачысын тату. Белмим, нинди хәлләргә төшкән булыр иде бу баш. Әллә инде каяндыр укыдым, әллә үз акылым җитте: бер генә кешегә багып, аңа гына гыйшык тотарга ярамый, берьюлы өч, яки биш кыз белән йөрергә кирәк дигән канунны кабул иттем. Шуның аркасында сөю хисен югалттым. Чөйне чөй белән чыгаралар, шулай бит? Мин дә нәкъ шуны эшләдем. Бары тик чибәр вә матурларга гына күз салдым. Игътибарсыз калмадым. Мәхәббәтемнең җавапсыз икәнлеген тоеп, унынчы сыйныфта ук башка бер кунак кызын озаттым, хатлар алыша башладык. Ул арада өченче берәү белән таныштым. Болар икесе дә, әйтүләренә-язуларына караганда, төнлә төшләрендә дә мине кочаклап саташалар икән. Ә мин — юк, кая ди ул саташу, һаман теге кызны уйлыйм. Күрше сыйныфтан иде ул. Зарифә исемле. Аны башка берәү яр итеп өлгергән. Озатышып та йөрешәләр үзара. Ә минем исә Зарифә белән утырып бер сөйләшкән, аңа йөрәк серләремне аңлатканым да юк. Һәм алай эшли дә алмас идем. Күңелемдә мәхәббәт уты гына, көнчелек хисе кебек авыр тойгы вә кичерешләрем бөтенләй сизелми. Хәтта Зарифә белән теге егетнең шулай матур итеп йөрүләренә сөенеп бетә алмыйм. Әмма яратам, үлеп яратам үзен. Теге, сөйләшеп, хат алышкан ике кыз, берсеннән-берсе узышып вә уздырып, кичергән хисләре хакында сөйлиләр, язалар. Сүзләренә үземне ышандырырга тырышам, авыр. Әмма мин бу хәлгә күнегеп киттем. Кызлар белән йөрмәс булдым. Ә юлымда бер гүзәл очрады, һәммә нәрсәләр хакында оныткан идем. Мәшәкатьле чакта... Менә шундый вакытта очрады ул кыз. Чибәр, төз, сылу гәүдәле. Бер кашык су белән йотарсың!

— Ул күңелемә керде. Зарифә дә, башкасы да онытылды. Әмма мин инде ахмак түгел. Мәхәббәт мәсьәләсендә азмы-күпме тәҗрибәм бар. Эшләр авырга киткәнче, башка берәү белән дә роман корып җибәрдем. Җиңелгәрәк туры килде, хисләр адашты...

— Син мине түбән зат дип уйлыйсыңдыр инде, әйеме? Мин аның шулай икәнлеген үзем дә белеп торам. Әйе, түбән зат мин, хәтта син уйлаганнан да түбәнрәк. Ә нәрсә эшләргә кушасың? Кешене бөек иткән әйбер дә мәхәббәт, түбәнсеткәне дә!..

— Мин җиңел юлны сайладым. Башкаларның мәхәббәтендә җылындым, шулай бер дә суыкта калмадым, һәрбер дуслык үзенә ияртеп барыбер мәхәббәт алып килде. Азмы аның җылысы, күпме — әһәмияте юк. Мин ярата беләм, мин

ярата беләчәкмен. Әмма һәрвакыт җиңүче булырга, онытылганнар хисабында калырга теләмим. Җиңүче кеше үзе җиңелүче, онытылган кеше үзе онытучы. Ә мин аннан да, моннан да азат булырга телим. Мин — азат кеше! Кемне уйга кертсәм, шуны озата бара алам. Кирәкми дип әйткән кешене әлегә очратканым булмады. Ә Зарифәне үз гомеремдә бер генә тапкыр да озатмадым. Мин аның илаһи сурәтен күңелемдә хыялым белән тудырдым, тормыш аны бәреп ватты. Менә синең белән дуслашкан көннән бирле мин башка бер кызга, яки гүзәл затка дип әйтик, күңел теләгеен куеп, күз салганым юк. Казан кызлары янына баруым һичбер ният белән түгел, йөрәк әрнүдән, вакыт озынлыгын җиңәргә теләүдән генә булды...

— Мин сиңа рәхмәтлемен. Мең рәхмәтле! Син минем яшьлегемнең заяга үткәнлеген аңлата алдың. «Яратам» дигән сүзең һәм үбүең бар булганнарны сызып ташлады. Миңа хәзер һичкем кирәк түгел!— дип сүзен бетерде Җантимер һәм өстәп куйды.— Синнән башка!..

Тагын арада тынлык урнашты. Чишмә суы ташлардан ташларга сикерә-сикерә челтерәп ага да ага. Кая ашыга, кемне күрәсе бар? Әйе, аның да зур юлга керәсе, елга булып, диңгез тулып ургыйсы киләдер инде? Ә дәрья — чиксез бит ул. Шушы чишмә суы кебек мең вә миллион елгалардан җыела бит ул. Ә диңгездә бу чишмәнең суы кайларда булыр? Төптә калырмы, дулкын чәчрәп, ярга бәрелерме, парга әйләнеп күккә очармы, әллә инде аккош канатларында энҗе бөртекләре булырмы?

Кешеләр дә шулай. Әллә нинди хыяллар белән яшиләр. Гаилә коралар һәм тормыш диңгезендә үз урыннарын тапкан төсле булалар, тәүге хыялларын онытыалар. Әмма йөрәк түрләрендәге тәүге ярату, йә булмаса чын сөю утының пыскыган очкыны нурына канәгатьләнеп яши бирәләр. Эһ, Җантимер, син дә шулар кебекме инде? Эһ, Җәмилә, син дә гомереңне алар төсле уздырырсыңмы инде? Мәхәббәт бик тә юка чүлмәк төсле шул ул, төште исә — ватылды. Адәм баласының юктан гына ничек хәтере калса, сөю-сәгадәт тә чак кына саксызлык күрсәтүдән челпәрәмә киләчәк!..

Алар сөйләшмичә озак кына утырдылар. Гаепле кеше Җантимер иде. Белә иде ул аны. Шунлыктан кыздан гафу сорап карады. Җәмилә эндәшмәде.

— Ярый алайса, соңгы тапкыр бер үбим дә, сау бул, бәгырь!—дип, Җантимер кызга таба якынлашты, кочагына алды. Икенче тапкыр Җәмилә егетнең яңагына сукты. Әмма күкрәгеннән төймәде, үксеп, башын аңа куйды. Җантимер үпкәләмәде, Җәмиләнең чәчләреннән иркәләп сыйпады.

— Йә, ярар инде, җитәр, мин сине яратам, барыбер яратачакмын,— дип, кат-кат әйтте, алдамады. Башка төрле сүзләрне кузгату артык иде. Шунда кызның күңеле тынычланды һәм ул әйтеп куйды, егет моны ук көтмәгән иде:

— Мин дә сине яратам шул, Җантимер!

Җир белән күк әйләнеп киттеләр. Дөнья үзе мәгънәсез бернәрсәгә әверелеп калды. Егет кызны кысып кочаклады, кулларына күтәреп алды, берничә адым атлады. Чык төшеп, үлән юешләнгән икән. Җантимернең аяклары таеп киттеләр һәм ул егылды, кулындагы затлы бәллүрне ватмас өчен ничек сак кылансалар, егет тә шулай эшләде, кызны бәрелү-сугылудан саклап калды.

Алар кабат үбештеләр. Әмма артыгына егетнең намусы комачаулады, кыз

бәлки каршы булмас иде. Төне-сәгате шундый иде түгелме? Җантимернең холкында киртә сикерү галәмәте бөтенләй юклыктан, ул тыныч һәм хафасыз иде. Таңга кадәр йөрделәр. Үбешеп һәм сөйләшеп туймадылар. Яктыргач кына аерылыштылар. Кешедән оят!

— Хуш, Җәмиләм, тыныч йокы!

— Хуш, Җантимер! Тыныч йокы!

— Хуш, бәгырь!

Бу төннең беренче яртысында булып узган аңлашылмаучылык инде бишбылтыр элекләрне үк үткән төсле иде. Ә хәзер мәхәббәт учагы яктысында таң атып килә. Көн озын булачак...

Авыл кешесенең шул инде, гел дә эше бетеп тормый: җәй башыннан утын әзерлисең, аннары печәнгә төшәсең, тегесе-бусы, тагын йөз дә бер җәфасы. Барысы да кирәк. Җәйдән хәстәрен күрмәсәң, кыш көне нужасын кичерәчәксең! Электән шулай килгән!

Җантимерләр печәннән соң кабат утын эшенә күчтеләр. Кисү, яру-вату белән мәшгуль булдылар. Аталары Нурулла абзый авыру иде. Шифаханәдә бер атна торды да, качып, табиплардан баш тартып кайтты. «Анда нишләп ятасың, юньләп караучы да юк, үзләре дә белмиләр!» — дип юатты ул борчылган хатынын. Яше шактый иде инде. Авыл кешесе илледән соң кинәт какшап төшә шул, алтмышында тәмам бөкре картларга әверелә. Тормышы авыр бит. Яшең җитсә кырыкка, эшең китәр шырыкка, дигәндәй.

Хатыны Газизә апа белән ире Нурулла абзый тигездән алты бала үстерделәр. Дүртесе — кызлар, калган икесе малай иде. Берсе — Җантимер, тимер кебек ныклы булсын, тәүге балалары Ринат төсле бер яшен тутыруга үлеп китмәсен, диделәр, исемен сайлаганда. Малай таза булып үсте. Ул буй, ул беләк, ул гәүдә — барысы да алыплардай. Зарифҗан да абыйсын куып килә. Монысын алып кайткан вакытларында Нурулла абзый кырыкларны узган иде. Үскәнен күрерменме дип тә уйлана иде. Менә анысы да, Аллаһ рәхмәте, күтәрелеп килә, абыйсы артыннан барып, Казанда укырга керәм дип йөри.

Нурулла абзый алтмыш ике яшенә чыккан иде. Зарифҗан туып, өч ел үтүгә, өлкән кызларын кияүгә бирделәр. Бабай аталып йөртелә башлады. Хатыны Газизәдән дә бик уңды ул, кыз чагында чибәр булды, гаилә коргач, тәүфыйгы артты, эшчән вә тырыш та иде.

Зарифҗан белән Җантимер су буенда утын ватып ята иделәр, аргы яктан, кояш нурында күзләрне уйнатып, буада су коеныргa дип ике кыз килде. Егетләр аларны шәйләп алдылар, әмма сер бирмәделәр, һаман балта селтәнүдә булды эшләре.

— Абый, кара әле,— диде Зарифҗан.— Җәмилә апалар түгелме соң болар?

Җантимер ишетмәмешкә салынды, алар икәнен белмимени ул, күзләре сукыр түгел ләбаса, кая ашыга бу яшьләр?

— Абый, кара инде!

— Карыйм, карыйм,— дип, эшеннән тукталды Җантимер.— Күреп торам бит инде.

Арадан берсе чыннан да Җәмилә иде. Күлмәкләрен чишенеп ташларга да өлгергәннәр, су коену киемнәреннән генә калганнар. Гүяки: «Менә, күр мине,

чагыштырып кара! Күзең кызыгырлыкмы?» — дип сорый төсле иде Җәмилә шушы кыяфәтендә Җантимердән.

— Эһ, егетләр, энҗе болар, энҗе!— дип әйтеп салды җанашы.

Җәмилә янындагы кыз Кадрия түгел иде. «Ә, Сәлимә икән, ул да каникулга кайткан!» — дип уйлады Җантимер.

— Абый, без дә су коенабызмы соң? — диде Зарифҗан, юктан күзен уйнатып, борынына мәхәббәт төтене исе керә башлаганын сиздереп.

— Нәфсеңне тыя төш! — Җантимер әллә үзен, әллә энесен битәрләде.— Һәр ялтыраган энҗе түгел!

— Синең өчен әйтмим лә,— дип үпкәләде энесе.— Җәмилә апа өчен әйтәм. Ике көннән ул Уфага китеп барасы икән, эшкә аны шунда билгеләгәннәр. Үзеңне күреп каласы килгәндер аның!

— Син соң шулай икәнен кайлардан беләсең?

— Бөтен авыл сөйли. Җәмилә апа сиңа үпкәләп елаган, үксеп елаган. Казан кызлары янына йөргәнең өчен.

— Каян беләсең?

— Беләм инде, белмәсәм, сөйләмәс идем. Авылда сүз юкә чыбыклы телефоннан гына йөри, теге урамның башында бүген бер-бер хәл булса, иртәгә безнең очта һәммә кеше белеп тора. Ышанмыйсыңмы әллә?

— Кичә ниләр булган соң?

— Әйттем бит инде. Кичә Җәмилә апа ахмак Җантимер абый өчен кара күзләреннән кайнар яшьләрен түккән, дидем.

— Ярый, шулай да булсын ди. Тагын ниләр?

— Калганы сиңа кагылмый. Ә-ә, студентлар Казан кызларын шәраб белән сыйлаганнар, мунчаларында ятып йоклаганнар...

— Как? — дип сәерсенде Җантимер.— Каким образом?

— Русча сөйләшмә әле. Хәзер русча сөйләшү шәһәрдә дә модада түгел, ә сиңа бөтенләй килешми!

— Юк, ничек алай дип кенә сорадым мин, ничек алай?

— Менә шулай инде...

— Алар бит минем белән кайтып киткәннәр иде.

— Кайтсалар соң, аннан килгәннәрдер. Сәйдәсе сине эзләткән. Өеннән дәшеп чыгарам мин аны хәзер, дигән, бик беләсең килсә.

— Нигә дәшмәгән соң?

— Җантимер абый, әллә юри шулай юләргә салынасың, әллә бар булганың шушы? Нигә кирәк сиңа ул Сәйдә? Җәмилә апага берсе дә җитми аларның!

— Белә-әм! — дип сузды, су буендагы гүзәлләрдән күзләрен алалмыйча торган Җантимер. Шулай дөньясын онытты. Ул хәзер башка яссылыкка күчкән. Мәхәббәт диңгезендә хыял корабын йөздерә иде.

Яр буена килеп утырды ул. Кызлар, кызыктырып, су коендылар. Җантимер дә чишенеп суга чумды. Җылы да, рәхәт тә иде. Колачлап йөзеп китте. Башта кызлардан читкә таба. Курыкмасыннар. Аннан тагын чумды һәм Җәмилә ягына борылды, йөзде дә йөзде. Алдына күз салды. Нәкъ кызның каршына, сөеклесе алдына килеп чыкты.

— Исәнме, Җәмилә бәгырем!

— Исәнме, Җантимер!

Эһ, шушы сүзләре! Назлы тавышы белән сөйләтеп кенә торасы иде үзен!

— Җантимер, алай итмә, мин судан куркам,— диде кыз үтенеп, йөзгән җирдән инде генә кочакларга талпынган егетне сабырлыкка өндәп.— Шаярма, ярамый!.. Суда бит без!

— Гафу, Җәмиләм,— диде аны тынычландырып Җантимер һәм дә тагын бер кат серле итеп исемен кабатлады.— Җәмиләм!

Бераз коенгач, ярга чыгып утырдылар. Монда ком иде. Алар артыннан Зарифҗан да бер читтәрәк урын алды. Колак куеп тыңлаштыра башлады.

— Якынрак кил, нигә читтә оялып кына утырасың? — диде Җәмилә, Зарифҗанны дәшеп.— Күңелсездер бит?

Кем белә, бәлки ул әле Җәмиләнең каен энесе дә булыр? Бераз аңа да күнегә торса, начар эш түгел. Әмма Зарифҗан һаман да үз җае белән утыра бирде. Җантимер исә Җәмиләнең буй-сыныннан күзләрен алалмады. Аны үбәсе-кочасы килде. Ул арада Сәлимә дә алар янына чыгып басты. Буй-сын дигәннән, бу вакытта ул ябыграк һәм ямьсезрәк төсле иде.

—Аһ, суы да суы шушы Минзәләнең,— диде ул, килә-килешкә.— Коенып туймаслык. Үзе җылы, үзе рәхәт. Шулай бит, Җантимер?

— Шулай, Сәлимә! Исәнме, хәлләрең ничек? — дип белеште егет.— Күптән күренгәнең юк, Казанда да очрашулар булмады. Әле генә кайттыңмы соң, әллә күптәнме?

— Мин кайтып-китеп йөрим. Практикада идем. Түбән Кама ерак түгел бит. Ял саен монда мин, менә хәзер — каникул.

— Яхшы инде алайса!

— Мин дә шулай дим!

Сәлимә дә алар янына килеп утырды. Әмма Җәмилә аның үз-үзен Җантимер каршында җиңелчә тотуыннан уңайсызланып куйды. Сәлимәнең күкрәкчәләре бушрак икән, рәтләгән булып, бөтенләй ачып ук куйды да, сизмичәрәк калу рәвешен китереп бераздан соң гына каплады. Җитмәсә, су коену киемнәре гаҗәеп нәзек һәм, әйтергә кирәк, җеп кенә төсле иделәр. Җайлы-җайсыз селкенүенә үк гаурәт җирләре: «Без монда!» — дип кычкырыша башлыйлардыр сыман. Сәлимә бик яхшы белә, мондый кием нинди таш һәм тимер егетләрне дә эретә. Җантимер дә игътибар итте түгелме үзенә? Юк икән, егетнең күзләре Җәмиләне сөендерә иде. Ничек итеп аңа «оятсыз» дип әйтә аласың? Егетнең күзләрендә кабынган мәхәббәт ялкыннары гөнаһсыз һәм назлы иделәр, аларның җылысында коену Җәмиләгә рәхәт иде. Кем уйлаган араларында мәхәббәт җепләре үрелер дип?

Яр буенда болай озак ялтырап яту килешә торган эш түгел иде. Егетләргә ярый, аларны һичкем гаепләмәс, ә менә кызларга әти-әниләрдән сүзе булыр.

Яңадан суга керделәр. Бу юлы озаклап коенмадылар. Егетләр бер ярга, кызлар каршыдагысына чыкты. «Җантимер, киенгәч, безнең янга килер микән?» — дип уйлады Җәмилә, чакырырга теләп.

Егет нәкъ шулай эшләде дә. Гүяки аларның йөрәкләренә, Зарифҗан әйтмешли, чыбыксыз телефон сузылган иде.

Җантимер кызларны тыкрыкка кадәр озата килде. Җәмиләнең күркәм ирен-

нәре сөенеч белән елмая иде. Алар икесе дә: кыз да, егет тә бәхетлеләр икән, ничек итеп үзара назланып сөешәләр! Яратыша белеп яраталар алар бер-берсен. Таһир белән Зөһрә кебек. Язмышлары гына аларныкы кебек бетә күрмәсен инде, йа Рабби Ходаем!

Җантимер, Җәмиләне озатып килгәч, шактый озак үз алдына уйланып утырды. Мәхәббәтләре уен гына түгел, чын иде, бик тирәнгә киткән иде. Ике көннән аерыласылары бар. Җантимер монда калачак, Җәмилә китеп барачак. Ялгыз башы җиде ят җирләрдә нәрсәләр эшләр икән ул?..

Ике көннән Җәмилә Уфага юлга чыкты. Ә университетта укулар башланырга атна ярымнан артык вакыт бар иде әле. Җантимер ялгыз башын кайларга куярга да белмәде. Студентлар янына да, Казан кызларына да бармый инде ул хәзер. Чая кыз да үзенә табынган яры Тимур белән канәгатьтер?

Әмма егет күңелендә чаптар яхшы ат булыр, ди. Җантимер дә үзен шулайрак хис итте. Бу халәте аның күңелсезлеген, Җәмиләне юксынуын арттырды. Җырлыйсы да, елыйсы да килә иде егетнең. Тик ни хикмәт, җырласа — тавышы юк, еласа — күзеннән яше чыкмый.

Сагыш арбасына ияргән Җантимер Җәмиләләр очына барып чыкты. Урамнарыннан бер әйләнде дә, өйләренә кайтып ятарга булды. Әмма юлында Сәлимә очрады. Ул да ялгызы гына иде. Сөйләшеп хәлләр белештеләр.

— Нигә күңелсез йөрисең? — дип сорады Җантимер.

— Син дә күңелле йөргән кешегә охшамагансың,— диде Сәлимә, җавабында егетнең күңелен яулау теләгеН йомшаклык белән сиздереп.— Клубка барган идем, һаман бикле икән. Тапканнар ремонт ясарга вакыт. Яшьләр күрше авылларга йөриләр ди.

— Әллә без дә барабызмы? — дип әйтеп куйды Җантимер, тәкъдим ясау уе белән түгел, болай гына, сүз иярә сүз чыгып кына.

— Әйдә соң,— диде кыз, егетнең сүзләрен шунда ук куәтләп.

Әмма Җантимер:

— Техника кирәк, мотоциклым да юк. Җәяү ул араларны йөреп булмый бит,— дип, үз сүзен үзе үк кире какты.

— Энекәшнеке бар,—диде Сәлимә.— Йөртә беләсеңдер бит? Ишегалдында гына, әйдә, киттек. Монда аптырап йөргәнче, күрше авыл яшьләрен дә күреп кайтырбыз!

Сәлимә шаяртмаган. Энесенең мотоциклы ишегалларында, капка янында ук икән. Сәлимә этләрен тотып торды, Җантимер мотоциклны алып чыкты һәм китеп тә бардылар.

Күрше авыллар яши белә иде. Клублары тулы яшьләр, уен-көлке, җыр-бию. Сәлимә белән Җантимер дә аларга кушылып киттеләр, шул рәвешле шактый онытылып күңел ачтылар...

Инде кайтырга кирәк иде. Юлда тагын да авылдашлары очрап, бергә-бергә һәркайсы мотоциклларда чабышып-ярышып бардылар. Үзләре йөгерми бит, техника чаба.

Икенче көнне сәгате-минуты белән авылда сүз таралган иде: «Җантимер хәзер Сәлимә белән йөри башлаган икән!»

Моңа дәлил буларак аларны башка көннәрдә дә бергә күрделәр. Кадриягә,

хәтта Җәмиләнең үзенә дә ул сүз барып ирешәчәк иде. Һич югы, моны Җәмиләнең сеңлесе апасына җиткерәчәк!

Сәлимә белән Җантимер өч көн рәттән күрше авыллардагы клубларда йөрделәр. Кызның күңелендә нинди уйлар кайнагандыр, әмма егет һаман да үзенең Җәмиләсен исеннән чыгармады. Аны онытмаячак ул һәм хәтереннән алып ташларга да җыенмый, йөрәге мөмкинлек бирмәячәк. Чөнки мәхәббәте көннән-көн арта гына бара. Ул бу хакта Сәлимәгә дә әйтте. Сердәшләр, янәсе. Әмма кызның үзе һәм авылдашлары гына алай уйламаганнардыр, гайбәт сүзләре Җантимернең колагына да килеп ирешә.

Сөйләүләренә караганда, Сәлимә бераз җилбәзәклеге белән дан алырга да өлгергән кыз икән. Моны Җантимер дә ишетеп белә иде, әмма дөрескә генә санамады. Шунлыктан Сәлимә белән икесе арасында нәрсәдер булуы хакында уйлап та карамады. Ә кул салу, буй кую кебек омтылышны күңеленә дә кертмәде, аңарда намус төшенчәсенең бу мәсьәләдә артыгы белән камил булуы оятсызлык кылу өчен мөмкинлек бирми иде. Тагын да шул: ул бит Җәмиләне сөя-ярата, ничек инде башка берәүгә күз сала алсын?

Сәлимә егеткә ят кыз, аның белән бу рәвешле озак йөреп булмый иде. Җантимер, кешедән сүзләр дә ишеткәләгәч, дөрес эшләмәвен аңлады һәм кичләрен өйдән ерак китмәү ниятенә килде. Шулай эшләде дә. Җәмиләсез көннәре бербер артлы үтеп тә китте һәм ул Казанга очты. Самолетта туган туфрактан аерылу сагышыннан күңеле кузгалды. Тагын укулар башлана, анда-санда гына туган йортка кайтып киләчәк, язса, бер-ике тапкыр хат күндереп, әти-әнисенең, туганнарының хәлен белешәчәк.

Тулай торакка студентлар каникулдан җыела башлаган иде. Бер көне бүлмә алу, җыештыру, дусларының хәлен белешү белән үтеп тә китте. Кичкә күңелен, гадәте буенча, сагыш биләп алды. Җәмиләкәе исенә төшеп, бәгыре кайнады. Бер-ике атна эчендә шушы кызның ничек бик тиз күңелгә кереп оялавын аңлый алмады ул. Бүтән кызлар белән танышасы да, сөйләшәсе дә килмәде. Былтыр аның дуслашып йөргән группадашы Хәлимә бар иде. Кичен ул кыз үзе Җантимер янына хәл белешергә кереп чыккан булды. Егет:

— Арыдым,— дип, аның белән сөйләшеп тормады.

Җәмиләсенә җитәрдәй, аның белән ярышырлык кыз Җантимернең күргәнбелгәннәре арасында юк иде. Шундый да чибәр, шундый да акыллы ярны яратмаска, аңа үлеп гашыйк булмаска мөмкин идеме соң?

Ишек кактылар.

— Керегез!

— Сәлам, Җантимер! — дип исәнләште, керә-керешкә киң атлап һәм кул сузып озын буйлы, чандыр гәүдәле, кара чәчле егет. Ул бик яхшыга гына укучы Сарман егете Зарифулла иде, Җантимернең дусты.

— Сиңа хат бар,— дип, өстәлгә конверт ыргытты.— Нишләп ялгызың гына ятасың? Йөреп-күреп килмибезме?

— Бу вакыттамы?—диде Җантимер, хатны кулына алып.— Кайда барырбыз икән инде?

Хат Уфадан, Җәмиләнең үзеннән иде.

— Соң, уку елын болай җиңелчә генә башлап җибәреп булмый бит инде,—

диде Зарифулла.

— Миндә тәкъдим юк, мин арыдым бугай,— дип кырт кисте җавабында Җантимер.— Мин монда калам.

— Хат кемнән?

— Уфадан.

— Синең Уфада хат алыша торган кемең бар?

— Бар инде...

— Ярый алайса, укып чык тынычлап, мин егетләр янына менеп төшәм әле. Очрашуларны “юмасак”, ел күңелсез узар.

— Анысы шулай инде.

Зарифулла чыгып китте. Җантимер бу вакытта конвертны ачкан, хатны укый башлаган гына иде, тагын ишек шакыдылар. Рөхсәтсез-нисез Хәлимә килеп керде.

— Нәрсә, хат алдыңмы әллә? — диде ул, Җантимерне үртәп.— Килмәс борын. Кая әле, кемнәр яза?

Җитез хәрәкәт белән егет кулыннан хатны тартып алды да шаярта ук башлады:

— Хатны синең кебек җиңел генә ачмыйлар аны, менә шулай! Әйдә, биеп күрсәт!— дип үртәде.

Җантимер тик кенә басып торды да:

— Ярар, җитәр инде, Хәлимә!..— дип үтенде.

— Бер дә җитми, биеп күрсәт,— диде кыз.— Юкса ачып укыйм!

— Анысын эшләмисең, тәрбиясезлек була,— диде Җантимер, чын күңелдән аңа үпкәләп.

— Ә нигә тәрбиясезлек булсын ди әле ул, Җантимерем? Хат сиңа килгәндер бит? Димәк миңа да!— диде Хәлимә. Бу мишәр кызы хатны чыннан да хәзер укый башлаячак иде.

— Ярар, бии,— диде егет, — тик хатны әүвәле кулыма бир!

Хәлимәнең күзләре хат юлларында иде. Ул кычкырып укый да башлады:

— «Исәнме, Җантимер! Сиңа сагынып, бик сагынып хат язучы кеше, сине яратучы, үлеп-үлеп яратучы Җәмилә...»

Хәлимә шушы урында туктап калды, ачуы кабарды, шаярткан җиреннән кинәт кенә усалга әверелде һәм, хатны ертып ташлап:

— Аһ, оятсыз! Мин тагын сине...— диде дә, сүзләрен дә әйтеп бетермәстән, елап җибәреп, атыла-бәрелә чыгып китте.

Сөеклесе язган хатның кисәкләрен Җантимер җыеп алды һәм өстәлгә тезә башлады. Аңа хәзер һичнәрсә кирәкми, беләсе иде: ниләр язган икән Җәмиләкәй? Сагынган икән бит ул да!

Тагын ишек шакыдылар, кабат-кабат. Күрше бүлмәдә урын алган Куба негр-зәнкиләре бераз шәраб тәмләп маташалар икән, тоз сорап керделәр, икмәк кисәге дә үтенделәр. Әмма Җантимердә әлегә бу кирәк-ярактан берсе дә юк иде. Алар башка бүлмәләр буйлап сораша киттеләр. Гафу үтенергә туры килде Җантимергә, чит ил халкы алдында итагать сакламый булмый иде.

Хат матур башланып киткән. Җәмилә үзенең үлеп яратуын искә төшергән, сагынам, дигән. Ул юлларын укыганда егет тагын да онытылып китте, авылын

исенә төшерде, Җәмиләнең күркәмлеген, тавышын сагынды, сурәтен күз алдына китерде. Аңа рәхәт иде.

*«Исәнме, Җантимер!»*

Ертык кәгазь битләрен өстәл өстенә тезеп, сүзне сүзгә, хәрефне хәрефкә җыеп укуын дәвам итте егет:

*«Сиңа сагынып, бик сагынып хат язучы кеше, сине яратучы, үлеп-үлеп яратучы Җәмилә булам мин. Бәлки исеңә төшергәнсеңдер? Бәлки хәтереңне яңартырга теләмисеңдер? Чөнки синең йөри торган кызларың күптер? Ике-өч көнгә мин Чаллыга киткәч тә башка кызлар белән болгана башлаган идең. Хәзер инде син — Казанда, анда да дусларың, йөргән кызларың күп инде!*

*Миннән сораган идең: «Егетең бармы?»— дип. Җантимер, син аңларга тиеш, Сабирҗан белән мин бервакытта да йөрмәдем, хәтта ул үзе артымнан калмаса да. Үбешмәдем дә. Тагын аның төсле бер егет бар. Ул авыл хуҗалыгы институтында укый. Минем кулымны сорап йөри...»*

Бу юлларны укыганда Җантимернең йөрәге чымырдап куйды, кәефе кырылды. Җәмилә кебек гүзәл затның егете булмый калмый инде ул. Әйтмәгән иде, сиздермәгән иде югыйсә!

*«Ул мине бик тә ярата. Биш ел артымнан йөри инде. Әмма аны мин яратмыйм, ярата алмыйм. Үзенә сүз биргән ул: әгәр миңа булмасаң, беркемгә дә булмассың, урлап качам, барыбер үземнеке итәм, дигән.*

*Җантимер, син бу сүзләремә артык игътибар бирмә, ярыймы? Мин сине, бары тик сине генә өзелеп яратам! Ә бәлки, шулай тоела гына торгандыр?*

*Уфага килеп урнаштым. Эшем күңелле, әмма һәрвакыт сине искә төшерәм.*

*Авылда чакларда син әйткән идең, Уфага килеп чыгарга тырышырмын дип. Рәхим итеп килә аласың. Әмма алдан хат язып хәбәр ит, ярыймы!*

*Кабат сәлам белән Җәмиләң!»*

Җантимер хатны ахырына кадәр йотылып укыды, күңелендә хисләр ташкыны ургып тулып, бәгырь төбендәге хәтер ташларын кузгата, җанын әрнетә иде. Җәмиләне беренче мәхәббәте итеп танырга тиеш иде егет. Моңа кадәр булган кыз күзләүләр, яратам дип хәсрәт йотып йөрүләр, сагышка төштем дип уфтанулар барысы да бары тик чүп кенә икәннәр, ялган, хәсрәтсез, утсыз төтеннәр генә! Һәм менә аның да йөрәгенә гыйшык уты йокты, бу инде чын-хакыйкый, мәңге бакый һичкемгә насыйп булмас, һичкемдә дә кабатланмас бөек мәхәббәт дигән нәрсә — илаһи канун иде! Соңгы атналарында Җантимер гел Җәмиләсе турындагы уйлар белән генә яши. Шулай рәхәт, шулай күңелле иде аңа.

Димәк аның әле Уфага да юлга чыгасы бар икән. Сүз биргән бит. Үтәргә бурычлы! Исенә төшереп ярый әле чакырды Җәмилә.

Укулар тыныч кына башланып киттеләр. Быел колхозларга булышу өчен студентларны ни сәбәпледер кузгатмадылар. Түбән курстагыларны гына, район җитәкчелегенең тырышлыгы белән, анда-санда эшкә йөртеп аптыраттылар.

Укудан бушаган арада Җантимер, анда-монда хезмәткә ялланып, үзенә акча юнәтте, иптәшләренә бурычка керде. Ялга каршы көннәренең берендә Уфага

очасы иде ул.

Юлы уңай булды. Уфа аэропорты шәһәрдән ерак икән анысы. Ә Невская урамын белүчеләр бөтенләй очрамады. Бары тик бер кеше генә кайда икәнлеген чама белән әйтте: «Яңа микрорайонда ул!»

Җантимергә, юк акчасын бар итеп, такси ялларга туры килде. Баксаң, якында гына булып чыкты, ерак дигәннәр иде. Урыс халкы белән башкортларның мәңгелек дуслык һәйкәленнән ике-өч квартал узуга гына икән.

Җантимер барып кергәндә Җәмилә, көтеп утыргандай, үз бүлмәсендә иде. Егетнең җавап хаты килеп өлгермәгән икән әле. Шулай да гел көтеп, сагынып яшәгән җанашы.

— Абау! — дип аптырап китте кыз.— Абау, Җантимер, синме бу?

— Мин, Җәмиләм, мин! Нигә аптырадың? Киләм дип әйткән идем. Килдем!— диде Җантимер, кызны кочагына алырга теләп. Әмма Җәмилә артка чигенде. Үзе пышылдады: — Кирәкми, кеше күрүе бар!

Җәмиләне өч бүлмәле фатирның бер бүлмәсенә иптәш кызлары белән урнаштырганнар икән. Кайсы бүлмәдә — дүрт урын, кайсында — биш. Ә алар, Җәмиләләр, икесе генә бер бүлмәдә яшиләр. Аерым фатирны шушылай тулай торак итүләре уңышлы уйлап чыгарылган, һәрхәлдә кызларның үзләренә дә, Җантимергә дә мондый бүлмәләрдә яшәү уңайлы тоелды.

Егет Уфада ике кич булды, өченчесендә китеп тә барды. Шул кичәләрнең берсендә кинотеатрга дип чыктылар. Яхшы картина иде. Әмма билетлар гына булмады. Җантимер башка бер тәрәзәгә килеп, аның артында утырган матур ханымга елмайды һәм дүрт кенә билет сорады. Өстәп түләүгә сөенеп, ул ханым тиз арада кайдандыр билетлар табып бирде.

Әле сеанс башланырга бераз вакыт бар иде. Җантимер һәм тагын ике иптәше белән Җәмилә һавага чыктылар. Каршыда гына чәчәкләр сатучы әбиләрнең сәүдәсе гөрли икән. Җантимер бер букет алды һәм аны, Җәмиләне үчекләп, арадан иптәш кызларының берсенә, боегып калганына тоттырды. Бу аның күңеле сак һәм саф булудан, кеше хәлен аңлавыннан гына иде югыйсә.

Моннан соң һәрберсен туңдырма белән сыйлады.

Кинодан кызлар кәефле кайттылар, күркәм мәҗлес оештырдылар. Бәйрәмгә тагын ике егет килеп кушылды. Башкорт университеты егетләре икән. Әмма кемнәр артыннан килүләре мәгълүм булмады. Җантимердән алар буй-сынга, килеш-килбәткә шактый калышалар, шунлыктан үзләрен бераз читтәрәк тоттылар, үзләрен бай итеп күрсәтергә тырыштылар. Әмма мәҗлес үзәгендә Җантимер үзе булды, туйганчы көлкеле мәзәкләр һәм вакыйгалар сөйләде. Җырладылар-биеделәр...

Халык төн уртасында гына таралды. Җантимерне аерым бүлмәдә йоклаттылар. Аның Җәмилә белән сөйләшеп утырасы килде, әмма кыз үз намусы өчен борчыла иде. Бераз кызмача егетнең бер-бер ялгышлык эшләп ташлавыннан шикләнеп, иптәш кызлары белән йоклады аның чибәркәе.

Ә икенче көнне алар иртәдән кичкә кадәр бергә генә йөрделәр. Кыз, ике тапкыр урам телефоныннан шалтыратып, ниндидер егет белән дә сөйләште. Җантимер моңа шикләнә калды. Сораштырып карады, әмма Җәмилә серен чишмәде:

— Башмакчыга, башмакчыга... Аяк киемнәремне төзәтергә тиеш иде,— дигән булды, Җантимерне өзелеп яратуы, аннан башка яши дә алмаячагы хакында сөйләде. Егет тә үз ягыннан һаман шул мәсьәләдә такылдады.

Җәмилә бу көннәрдә генә авылдан хат алган икән. Җантимернең Сәлимә белән дуслашып йөрүләрен әллә ниләр дип күпертеп бетергәннәр. Кыз шул хакта көтмәгәндә сорап куйды. Егет моңа сәерсенеп калды, аптыраулы күз карашы Җәмиләне сагайтты.

— Син мине алдагансың, беркем белән дә йөрмәдем, сине генә яратам дигән идең, Җантимер? Ничек болай була соң ул? Үзең берне сөйлисең, әмма кыланышларың бөтенләй башкача! Кичә чәчәкләрне дә ике сәгатьлек танышыңа тоттырдың. Юк, мин сәерсенмәдем, аптыравын аптырасам да... Әмма башкалар нәрсә уйлаганнардыр бит? Үпкәләттең, Җантимер!—дип, күңелендәгесен әйтеп бирде Җәмилә, ул инде хәзер еларга әзер иде.

Җантимер чыннан да үлеп-бетеп ярата белә. Әмма башкаларда үзенә карата мондый хиснең шушы рәвешле күңел бакчаларында чәчәк атар яки балкытыр дип күз алдына китергәне, акылы-җаны белән тойганы юк иде. Менә Җәмилә белән икесе арасында гаҗәеп хәлләр килеп чыкты. Болар егетне шикләндерә һәм сәерсендерәләр. Шулай да аның күңеле тулы сөенеч, язгы гөлбакча төсле хәзер аның җаны. Кыз өчен ул гомерен дә бирергә әзер. Кабул итеп кенә алсын. Ничек бар, шулай. Бөтен тулылыгы белән!..

Җәмилә дә үзен Җантимергә багышларга әзер иде бугай? Әмма егет тәвәккәл түгел. Нидер көтә. Аңа инде ир кеше була белергә кирәк. Ә ул ашыкмый. Юкса кочакласын Җәмиләсен, үбешсеннәр. Тәннәре тәнгә сеңгәнче, иреннәре иреннәренә күченгәнче. Инде икенче көне түгелме соң? Юньле-башлы серләшеп утырганнары да юк. Әле берсе уңга китә, әле икенчесе сулга, дигәндәй. Болай ярыймы инде? Укуын ташлап, дусларын онытып монда ашкынды бит ул. Бер күрешүгә зар булып, бер сөйләшүне гомере дәрәҗәсенә күреп. Эһ, Җантимер, Җантимер!

Җәмиләнең күңелендә туган шикләнүләрен егетнең үз-үзен тотышы тагын да куәтле төсле иде. «Җантимер минем белән ялгызы гына калырга, бар дөньясын онытып сөйләшергә теләми бугай? Оныткан. Мин кирәкмимдер аңа. Юкны бар итеп кенә килгән ул монда»,— дип тә уйлый ала иде кыз, егетнең һаман уйчан йөрүенә һәрдаим игътибар юнәлтеп, болардан үзенчә нәтиҗә чыгарып була бит! «Кадрия дәрес язган, синең җанда — синеке, синнән киткәч — женнеке,— дигән.— Күңеле башкада аның, бүтән берәү хакында уйлый ул!» Болай фикерләве белән кыз ялгыша иде әлбәттә, үзен бутый гына иде.

Җәмиләнең күзгә туры карап соравыннан Җантимер югалып калды, Сәлимә белән дуслык вакыйгасы шушылай кирәкмәгән урында калкып чыгасын башына да китермәгән иде ул. Тотылды егет. Тотылды гынамы соң, капты, бик яхшы капты. Хәзер нәрсә дип акланыр инде ул?

Җантимер эндәшмәде. Моны Җәмилә үзенчә аңлады. Ачуы чиктән узды һәм ул әйтеп ташлады:

— Сез барыгыз да юләрләр. Нигә миңа гына шушындый ахмаклар туры килә икән? Сине башка төрле дип уйлаган идем, Сибгать кебек түгелдер дигән идем. Шундый ук икәнсең!

Җәмиләнең Сибгать исемле егете дә булганлыгын яки барлыгын Җантимернең ишеткәне юк иде. Кем ул? Кыз бу исемгә аеруча зур мәгънә бирде, басым ясап узды бит.

Шунлыктан Җантимер сорамыйча да булдыра алмады:

— Кем сон ул Сибгать?

Җәмилә дә егетнең белешүләреннән агарынды-борчылды. Бу халәте ачу катыш иде. Шунлыктан атылып бәрелердәй булды һәм әйтеп үк бирде:

— Хатта аның хакында язган идем инде. Авыл хуҗалыгы институтында укый дип. Шул инде — Сибгать. Мин Әлмәттә укыганда, интернат мәктәптә, беләсеңдер, шул вакытлардан бирле йөри инде ул минем артымнан.

Җантимер болар хакында хатта укыган булса да күптән оныткан, Җәмилә аны юри үчекләр өчен генә язган дип уйлаган иде дә, ялгышканын аңлады. Кызның күңелендә икән бу бәндә, югыйсә исенә дә төшереп тормас иде ул аны. Шунлыктан болар барысы да егет колагына әле хәзер генә билгеле булган яңалык кебек ишетелде. Дөрес, Җәмиләнең Әлмәт мәктәбендә кайчандыр укыганлыгын да белми иде ул. Чөнки бу кыз белән авылдашлар булсалар да, элегрәк һичвакыт кызыксынмады, аның хакында мәгълүматлар җыйнамады. Егетләр белән йөргән-йөрмәгәнен дә белми иде. Гүяки Җәмилә бары тик аның өчен генә туган, аның өчен генә үскән.

Сибгать диген, ә? Нинди бәндә икән инде ул? Җәмилә кебек Җәмилә артыннан яшьли гыйшык тотып йөргән икән, андый-мондый гына кеше булырга тиеш түгел! Ә кыз аңа үзе ничек карый соң? Яратамы? Яратмаганын белдергән төсле дә кебек. Әмма ни өчен хәтереннән чыгарып ташламый? Онытырга кирәк иде аны күптән, мәгәрем ки яратмый икән! Ничек була инде ул, үзе яратмыйм мин аны, ди, үзе һаман исенә төшерә, аның белән чагыштыра? Юк, аларның араларында нидер бар яки булган. Сәбәпсездән кыз кеше ир-егетне шул рәвештә бәяләмәс иде! Идеалы түгел идеме?

Җантимер тагын сорау бирмичә кала алмады:

— Ни өчен аның хакында чирканып кына әйтәсең, Җәмилә? Ярата торгандыр бит ул үзеңне?

— Беләм, ярата. Әмма юләр ул, бозау. Аның яратуы гына җитми шул. Хисләребез аваздаш булырга тиеш!

Үзенә гыйшкы төшкән кешене Җәмиләнең шулай бәяләве Җантимерне шикләндерде. Күңелсез күренеш иде бу. Гашыйк кешене!.. Ничек мөмкин? Ничек мөмкин күңелендәге бөек хискә үзен корбан итүчене шушылай түбәнсетү? Ләйлә өчен Мәҗнүн акылыннан язган, Таһирга була Зөһрә үз-үзен үтергән!

— Җәмилә, үзеңне яраткан кешедән алай көләргә ярамый. Бәлки, ул синең бәхетеңдер!— дип борчылды Җантимер, бу вакытта гүяки үзе хакында да, чын йөрәктән шушы кызны ярсып яратуы турында да онытып.

Әйе, онытып. Гашыйклар үзләренең мәхәббәтләрен оныта алсалар, алар мәгъшуклар хисабыннан түгел инде. Димәк син, Җантимер, мәхәббәт ялкынында чын йөрәктән көймисең әлегә, ярата белмисең! Әгәр дә ярың: «Мин ул егетне сөймим, күңелемдә син генә!» — дип әйткән икән, нигә ул вакытта аңа: «Син ул егетне дә хөрмәт ит, мине дә ярат!» — дигән таләпне куясың? Синең ул сүзләрең, хәтта чын күңелдән булсалар да, ахмак кешенекеләр! Каян килгән Мә-

хәббәт алиһәсе, каян килгән Сөю-сәгадәт сакчысы? Бу синең эшең түгел!

Әмма Җантимернең башына ул уйлар кереп тә карамадылар. Егет, киресенчә, үзен Сибгать урынында кебек хис итә башлады, шунлыктан аны яклый иде.

— Үзеңне яраткан кешене алай юкка чыгарып ташларга ярамый, Җәмилә,— диде ул, юләр сүзләрен кабатлап.

Матур әдәбият укып, китап белән җенләнеп, гуманистка әйләнеп беткән ахмак бер юләр икәнсең бит син, һай, егет!

— Аның мәхәббәте ничә еллар сыналган, ул сине ярата, димәк бәхетле итә ала...— дип, Җантимер саташкандай сөйли бирде.

Хак сүзләрнең шушылай сару кайнаткыч, мәгънәсез булуын Җәмиләнең гомерендә беренче тапкыр тоюыдыр бүген? Юк, Җантимер ялган сөйли, аның мөгаен: «Мин сине яратам, бары тик сине генә яратам, син дә мине генә сөй, ул егетне күңелеңнән генә түгел, башыңнан ук чыгарып ташла, исеңә дә төшермә! Син минеке генә булырга тиеш, башкага карарга хакың юк!» — диясе киләдер, юри, сынар өчен генә суфиланып маташадыр?

Кыз шулай уйларга тиеш тә булгандыр?.. Ярата шул ул Җантимерне! Ярата! Хәтта ахмак сүзләрен дә гафу итә алачак түгелме?

— Син мине яратасыңдыр бит, Җантимер? — дип сорады Җәмилә, егетне эзгә кертергә теләп.

— Яратам!— диде Җантимер, хисләрен яшерә алмыйча.

—Яраткач, нигә алай сөйлисең? — диде кыз, үпкәләп.

Алар бу сөйләшү вакытында Җәмиләнең бүлмәсендә иделәр. Кыз тәрәзә янында басып тора. Карашлары еракка, зәңгәр күк йөзенә текәлгән. Бу куе зәңгәрлек аның күңелен тагын да тутырып җибәрде. Җантимер һаман үз фәлсәфәсен такылдый бирде. Җәмилә аны тыңламый иде инде. Күз алдына Сибгатьне китерде. Җәмилә өчен утларга керергә әзер булган ул егетнең төнге сәгать өчләрдә исерек килеш Казанның бер почмагыннан икенчесенә кадәр ашкынып килүләрен, тулай торакны аякка бастырып, тавыш-гауга чыгарып уятуларын, икенче көнне сәгатьләр буе гафу үтенеп аптыратуларын исенә төшерде. Бозау гынамы соң, мунчала иде Сибгате.

Ә монысы кем инде тагын? Йөрешеннән, үз-үзен тотышыннан чыгып кына һичкемне дә бәяләп булмый икән шул. Җантимер, азамат егет, күпләрнең төшләренә кереп саташтырган асыл зат бу сөйләшүдә мәхәббәттән башы әйләнгән бер дивана кебек иде түгелме? Әллә соң барлык егетләр дә шуның рәвешлеләрме, ахмакლармы?

— Сибгать нииндирәк егет ул? — дип, кат-кат сорап маташкан Җантимернең сүзләреннән Җәмилә айнып китте.

— Синең кебек. Шулкадәр бер-берегезгә охшасагыз охшарсыз икән! — дип әйтте дә салды кыз, аптырап та тормастан. Аның өчен хәзер барыбер иде, үпкәләсә үпкәләсен, аның эше. Эһ, егет! Ә бәлки Җәмилә ул да синең кебек миңа диваналарча гашыйк диярргә теләгәндер?

Җантимер чыннан да ахмакланган кешене хәтерләтә иде. Аның табигый хасиятеннән килгән рухи зыялылыгы романнарда сурәтләнгән затлы каһарманнарның фәлсәфәсе белән тагын да юкартылган һәм тормыш таләпләреннән читләшкән ахрысы. Мәгәрем ки ул ат караучы, яки шофер икән, техник, яисә фи-

нансист-экономист белемле булса, гади кешеләр төсле үк дөньяны аңлар, карашлары да аларныкыннан әллә ни аермалы кебек күренмәс иде. Ә ул әдәбият белән җенләнгән, шигърият белән шашкан егет шул. Болардан беразга аерылып торганда әнә үзен ничек тотты! Үз бәхете өчен көрәшүче кебек хәтеренә кереп калган иде Җәмиләнең, ә хәзер Сибгать өчен кайгыра бу дивана! Сүзләреннән туктый белмәсә дә белмәс икән!

— Ул сине яратса, аны юкка чыгарып ташларга кирәкми, Җәмилә,— дип тора, юләр сатып...

— Җитте сиңа, булды, ишеттем!— дип, кинәт кизәнеп яңагына суккандай әйтте Җәмилә. Күзләреннән кайнар яшьләре атылып чыкты һәм ул, мендәргә капланып елый башлады: — Юләр, юләр, юләр!..

Мәхәббәттән кешеләр мәҗнүн-диванага әверелә, диләр. Шуны да белмимени Җәмилә? Егетенең юләр кебек тоелуы аңа аның яратуын мең кат ачык һәм төгәл итеп дәлилли түгелмени? Менә бит үз күзләре белән күреп, колаклары белән ишетеп, акылы белән аңлап тора Җантимернең хәлен! Нинди шик калырга мөмкин? Бу егет синең өчен туган бит, һай бәхетле туташ!

Җантимер исә нәрсә әйтергә, ярын ничек юатырга белмәде. Шулай да Җәмиләнең янына утырды, башыннан сыйпады, аркасына кулы тиеп узды, ирлеге уянды, ахмак фәлсәфәсе канат белән сыпыргандай юкка чыкты һәм кызга якынайганнан якынайды.

— Мин сине яратам, мин сине беркемгә дә бирмим, хәтта миннән артыграк яратсалар да бирмим! Син минеке генә булырга тиеш! Син — минеке! Минеке булырга тиеш!— дип, үзе дә белмәстән, Җәмиләгә кирәкле акыллы сүзләрне сөйли башлады ул.

Кыз менә шушыны көтә иде. Аны нәкъ менә шушы сүзләр, шушы наз гына юата ала. Аңа шушындый үлеп гашыйк булган әрсез Җантимер кирәк, үле фәлсәфә иясе акыллы баш Җантимер түгел.

Кыз елаудан туктады. Егетенең кочагына кереп, рәхәттә эрүдән сәгадәт тапты. Бар дөньяны, әхлагын-мәсләген онытасы килде. Җантимердән тәвәккәллек теләде, иреннәреннән иреннәре гүяки бал җыйды, акылы исәрләнде.

Күк зәңгәр, зәп-зәңгәр иде. Әбиләр чуагының салкын сары кояшы бөтен дөньяны алтынга мана, катлы-катлы шәһәр йортларын сыйпый, хәтта аларга да көз буяуларын иңдерә төсле иде. Җәмилә үз буена күз салды. Җантимернең сынын карашлары белән бәяләп узды. Егетнең киң җилкәләре, ныклы беләкләре һәм күкрәкләре тормышта ныклы терәк булачагын сөйли иделәр.

Алар ярым шәрә калдылар. Бу — Җантимернең эше. Җәмиләне кочагында һәм назлы иреннәрендә эретте, җилкәләрен-кулларын, күкрәкләрен-билләрен үпте, әмма кендектән түбән аңа юл бикле иде. Егет адашты, максатына ашыкты, әмма кыз айныды, кичектерә белде. Алай гына булмый әле ул!

— Җәмилә, мин сине яратам,— дип пышылдады егет, үбешүдән һәм кочаклашудан инде җан канәгатьлеге вә тынычлык табып.

— Мин дә сине яратам,— диде Җәмилә, сихри мәхәббәт дөньясының илаһи канунына туры китереп, җаны кушканча сөйләп.— Яратам шул, Җантимер, яратам!

— Бул минеке! — диде егет.

— Мин — синеке,— диде кыз,— әмма әлегә бөтенләй үк түгел. Үпкәләмә!

— Ярар, Җәмиләм...

Менә бу — чын гашыйклар сөйләшүе иде кыз фикеренчә. Бу чыннан да дөрес сөешү иде.

Алар бер-берсенә соклана-соклана киенделәр, тагын кочаклашып утырдылар. Шулай рәхәт иде. Кыз тагын егеткә үрелде, егет — кызга, уен кабат башланам дигәндә, Җәмиләнең иптәш кызы ишеккә килеп, аларны чәйгә чакырдылар.

Җантимер Казанга мәхәббәт хисләре белән тагын да баеп кайтты. Аны Җәмиләсе ярата, ул — Җәмиләне! Икесе дә пар килгәннәр, бәхетлеләр. Моны тою, белеп тору бик рәхәт, бик тә, бик тә рәхәт. Шушы сәгадәт эчендә яшисе дә яшисе инде хәзер.

Җантимерне дуслары югалтып торганнар икән. Беренчеләрдән булып Хәлимә очрады егеткә. Бераз үпкәләбрәк йөргән кызны алыштырганнар да куйганнар диярсең, авызын ерып, үзе килеп күреште:

— О-о, Җантимер!— диде ул, кыланып.— Авылга, әниең янына бәрәңге алышырга кайтып килдеңме әллә? Сине югалткан идек!..

Ул шулай сөйләде дә сөйләде.

Бу атнада, ял көне, җәйне озату бәйрәмен ясап алганнар икән. Биектау ягына нарат урманына барып, чатырлар корып, таганнар асып кичләгәннәр дуслары:

— Синең артыңнан да биш тапкыр әйләнгәнмендер. Кызганыч, китеп баргансың. Күршең Хафиз әйтмәгән булса, белмәс тә идем... Бик кызык, рәхәтлек. Ул һава, ул табигать, ул җыр-бию. Күңелле булды. Ә син бәрәңге алып, әтиәниеңә булышып килдең инде. Анысы да ярый!..

Хәлимә шулай сөйләнә-сөйләнә, Җантимергә сылана ук башлады. Аннан соң тагын һәм тагын да матурлап-чуклап, ваклап-ваклап күп нәрсәләр хакын да хәбәр бирүен дәвам итте. Гармунчы Камалетдингә соклануын яшермәде. Җырчы егет Гыйльми Шәрип тә алар белән барган икән.

Җантимер бик яхшы белә иде: Хәлимә аралашучан кыз, шау-шулы мәҗлесләрне ярата, гел үзәктә була. Димәк аның бәхете дә ул кичәдә чәчәк аткан һәм аңа сокланучылар да үзләренең хисләрен яшерә алмаганнар. Болай ук шат күңелле булмас иде.

— Ул Гыйльми Шәрип менә егет ичмасам! Ул җырлый, ул җырлый. Урманнар яңгырап торды. Тирә-яктан башка студентлар да җыелыштылар. Озак утырдык. Җырлап таң аттырдык. Аннан соң гына йокладык, тулай торакка кайткач. Икенче көнне генә уянганмын,— дип, тагын әллә ниләр сөйләп бетерде. Гыйльми Шәрипнең үзенә бәйләнүләрен дә, озата кайтуларын, тагын килергә вәгъдә бирүләрен дә онытмады. Аның бу сүзләре, беләдерме, Җантимерне сөендерәләр генә. Димәк шул: килер көннәрнең берендә Хәлимәнең сагыз кебек ябышуыннан котылачак икән әле ул.

— Яхшы булган,— дип куйды Җантимер, кызга ишетелерлек итеп.

— Яхшы булган?..

Алар торакка җитеп килә иделәр. Юлда берничә танышлары очрап, сәлам дә алыштылар. Бусагага якынайдылар. Хәлимә һаман да Җантимернең беләгеннән кысып кочкан хәлендә килә иде.

— Хәзер сезгә керәбез, чәй эчәбез, авыл каймагы белән, шулаймы, Жантимер? — диде ул, баш тартырга урын калдырмыйча.— Алып килергә онытмагансыңдыр бит?

Җантимер кире какмады, юк дип әйтмәде. Торакның пыяла ишегенә юнәлде. Шунда хатын-кызлар тавышы белән берәү дәште:

— Хәлимә, Хәлимәкәй-гөлкәй! Исәнмесез, мин килде-ем!..

Бу кеше кечкенә башына киң эшләпә, ә өстенә япон курткасы кигән иде.

— О-о, Гыйльми Шәрип,— дип мул елмайды Хәлимә. Аннан Җантимергә: — Тимурчик, гафу итәсез, чәйне башка вакытка калдырырбыз. Коймакны-каймакны ашап-ашатып бетермә! Ишетсен колагың! Минем яныма килгәннәр икән,— диде дә чакырган кешесенә таба китеп тә барды. Юк, барды гынамы соң, боргалана-сыргалана, гүгелди-гугелди биеп килде Гыйльми Шәрипнең янына һәм, кочагына кереп бетәм дигәндәй, бит очыннан үбеп алды да, сәерсенеп карап торган Җантимерне, әллә юри, әллә чын, олы күзләрен хәйләкәр йомгалап һәм ягымлы караш ташлап үртәде. Менә шулай, егет, белеп тор ди төсле иде аның елмаюлары шушы мәлдә.

Алар анда калдылар. Җантимер, бәхетле баладай сөенеп, торак ишегеннән эчкә чумды. Ул көлә иде: Хәлимәнең кыланышларыннан да һәм үзенең шушылай җиңел генә аңардан котылуыннан да.

Бүлмәсендә чыннан да һичкем дә юк иде. Җантимер чәй дә куеп тормады, ашарга да теләге юк иде. Студентларның классик халәте саналган позада караватка сузылып ятты һәм кулына китап алды. Китап эченнән Җәмиләнең хатыннан бер кәгазь кисәге шуып төште һәм егет татлы уй-хыяллар диңгезенә кереп чумды.

Хатның эчтәлеген хәзер яттан диярлек белә иде ул. Җәмиләнең беренче хаты һәм әлегә бердәнбер хаты булганлыктан, бу кәгазь кисәкләре аңа бик тә, бик тә кадерле иде.

Шушы рәвешендә озак уйга чумып ятканы сәбәпле егетнең күзләре йомылды. Ул үзен ак болытларда йөзгән кебек хис итте. Шунда кемнеңдер эндәшүе аны сискәндереп куйды. Җантимер күзләрен ачты. Кем әрсезләнеп йөри икән? Егетнең төшенә кергән ак болытлар зәңгәр күк йөзендә һаман да йөзә иделәр кебек. Күзләрен кабат йомды.

— Җантимер, әллә йоклыйсың инде?

— Йоклыйм,— диде җавабында Җантимер, әмма күзләрен ачарга теләмәде. Ә ак болытлар инде таралган, йокысы качкан иде. Күзләрен ачарга һәм торып утырырга мәҗбүр булды.

— Ә, Таһирҗан икән әле, сәлам,— диде ул бүлмәдәшенә.— Кайттыңмыни? Хәлләр ничек? Илдә ниләр бар?

— Сине югалттылар,— диде Таһирҗан.— Дөньяң түгәрәкләнде инде. Ну, ничек барып килдең? Яхшы каршыладылармы үзеңне?

— Начар түгел...

— Әйдә, сөйлә инде!

— Нәрсәсен?

— Соң, ниләр булганын!

— Яхшы булды,— диде җавабында Җантимер.— Яхшы булды. Тагын нәр-

сәсен сөйлим инде? Бардым, күрдем, кайттым!

Таһирҗан аптырап торды. Җантимернең нинди халәттә булуын белергә теләп, карашын аның йөзеннән алмады. «Моны бик сыйламаганнар, коймагы пешмәгән!» — дип уйлап куйды булса кирәк һәм дустының кәефен күтәрергә теләп шунда:

— Йә, ташла,— диде дә шаяртуга күчте.— Кызлар бетмәгән! Моның өчен Уфага барып йөрүнең һич кирәге юк. Ә менә авыл хуҗалыгы институтына барсак була. Анда бүген «Әбиләр чуагы» дип аталган кичә узачак. Киттек шунда! Бик яхшы берәр кыз белән танышырсың, бүтәннәре онытылыр. Исеңдә тот, безнең девиз: «Берьюлы өч кызның башын әйләндер, юкса үзеңнеке әйләнер!»

Таһирҗанның эшләре начар түгел иде. Буйга һәм килеш-килбәттә бер дә ким-хур дияргә җире юк иде. Соңгы вакытта Авыл хуҗалыгы институтыннан Сәвия исемле бакыр чәчле Ырынбур кызының башын әйләндерә иде ул. Шуңа була кичәгә барасы килә аның.

— Юк, мин бүлмәдә генә калам,— диде җавабында Җантимер.

— Ничек?

— Менә шулай.

— Ахмак булма. Мин анда үзем генә нишләп йөрим? Юлы да ерак, җәһәннәм артында ук бит ул. Әйдә инде, берәрсе белән танышырсың, Уфа җилләре дә онытылыр. Әйдә, вакытында барып җитәргә кирәк!

Уфа җилләре дигәннән, Җәмилә артыннан йөргән теге егетне шунда Җантимер кабат исенә төшерде. Сибгать бит әле ул! Шул егетнең үзен күреп, сынап та кайтырга мөмкин.

— Ярар,— диде Җантимер һәм торып басты.— Бу юлы синеңчә булсын. Киттек әйдә!

Тորактан чыкканда Җантимер ирексездән уңга борылып карады. Аңда кәнтәй Хәлимә дә, артыннан килгән теге җырчы егете дә юк, алар урынында бер зәнки-негр егете белән юан ханым гөрләшеп тора иделәр.

Авыл хуҗалыгы институтында уздырылган кичә Җантимергә ошамады. Университетта моның ише бәйрәмнәр күңеллерәк һәм ничектер уңайлырак, әйтергә мөмкин, күркәмрәк була торган иде. Ә болар — авылчарак. Дөресрәге, шәһәргә авышырга омтылган авылчарак икән. Мәгәрем ки нәкъ авылда уздырыла торган бәйрәмнәр төсле кичәләр оештырсалар, бу уңышлырак һәм экзотик аһәң белән баетылганрак булыр иде. Нигә дип әле алар да шәһәргә тартылырга омтылалар? Әнә Казан Мәдәни үзәге, кала үзәгендә төзелгән амбар кадәрле замана бинасы икәнлеген дә онытып, авылча аулак өйләр, каз өмәләре кебек йөрәкләрне гайрәтләндерерлек халык йолаларын үле хәлгә төшереп, Казанга китереп такты. Авыл белән шәһәрне якынлаштыру уенда хыялланган коммунистларның да бу рәвешле кылану мөмкин икәнлек башларына да кереп карамас иде юкса.

Әмма Җантимер шушы кичәдә Сибгать белән танышты. Монда кызларны күңеле якын күрмәде. Кичә иң кызган вакытта Таһирҗан белән аның бәхетле мәхәббәт алиһәсен калдырып залдан чыккан иде, элекке танышларын очратты. Сүз арасында алар янына Сибгать килде. Белешләр түгел иделәр. Җантимернең авылдашы, быел гына укырга кергән Дамир исемле егет аларны таныштырды.

— Җантимер абый, бу — безнең белән яшәүче Сибгать абый була! Хәзер диплом язалар. Шунлыктан кичәләргә бик йөрми,— диде Дамир, сары озын чәчләрен сулдан уңга каерып һәм ак йөзенә уелган зәңгәр күзләрен кабарта төшеп сөйләнеп.

— Ә, Сибгатьмени? Таныш булыйк,— диде Җантимер, бу егетнең чыннан да Җәмиләгә лаеклымы-түгелме икәнлеген беренче күрешүдән үк чамаларга теләгәндәй сынап карап торып.— Таныш булыйк, Дамирның авылдашы Җантимер булам!

Сибгать тә үзен кыюсызрак тотты. Чәчләре җиткән, дулкынланып иңенә төшкәннәр, бераз агара башлаган бөртекләре дә күзгә ташланып тора. Егетнең килеш-килбәте ким-хурлардан түгел икән. Буе гына уртача кебек, һәрхәлдә Дамир белән Җантимердән бер башка тәбәнәк үзе. Әмма башкалардан бераз калкулырак. Кылчыкланып сөйләшә.

— Әһә, Җәмиләнең авылдашларыннан икән алайса. Беләм, беләм. Бер мүкләк сыер белән очрашып сөйләшергә туры килгән иде элекләрне. Акыл сабагын арттарак калып укый икән, бераз ярдәм иттек үзенә. Күренгәлиме соң? Сабирҗан, дигәннәре, директор малае диме шунда?..— Сибгать баскан җирендә уңгасулга кизәнеп, уч төбенә йодрыгын суккалап, шактый җиңелдән сүз болгатып ташлады. Әмма кызыклы тәкъдиме дә бар икән үзенең:

— Әйдә, Дамир, дәш авылдашыңны, бер шешә шәраб бар, андый әйберне мондый бәйрәм көнне калдырып булмый бит инде, аударырбыз,— диде.

Җантимер сыйлануга каршы түгел иде. Башкаларның да ияргә исәпләре булуга карамастан, Сибгать аларны кире какты.

Беренчесен күтәргәннән соң, Дамир кабат кичәгә китеп барды, Сибгать белән Җантимер күзгә-күз генә калдылар. Тагын берәр стаканны бушатып куйдылар. Сибгать бертуктаусыз Җәмилә хакында сөйләнде, кырыкмаса кырык җирдә кабатланды. Сүзләреннән шул аңлашылды: егет үзенекен һичкайчан ычкындырмаячак!

— Бик беләсең килсә,— дип сөйләде Сибгать,— бик беләсең килсә, Җәмилә минеке һәм минеке генә булып калырга тиеш! Аңа һичкем өйләнмәячәк, ул һичкем яры булмаячак, миннән башканың!

Җантимер тыныч кына тыңлады да тыңлады. Кайвакыт Сибгатьне куәтләгәндәй, яки инде тыңлаганын аңлатып баш селкергә, яисә әйе сүзен телдә тибрәтергә мәҗбүр булды. Кыскасы, ул аны аңларга тырышты һәм чын күңеленнән егетне үксез мәхәббәткә төшүе өчен кызгана башлады.

— Мин бит беркем белән дә йөрмәдем, бер генә кызга да юри булса даябышмадым. Малай чагымнан бирле күз алдымда Җәмиләдән бүтән илаһи затның торганын хәтерләмим. Мин аны беренче күрүдән яраттым, шунлыктан ул минеке генә булырга тиеш. Күрдем, күрдем мин ул Сабирҗан дигәннәрен. Әле ул бозау хакында Җәмиләнең итәгенә тагылмакчы дигән сүзне дә ишеткән идем. Әгәр белсәм!.. Тагын бер кеше бар икән анда, сезнең авылда, Җәмилә белән йөри башлаганнар. Сабирҗанның коерыгы кысылган. Монда, Казанда укый, диләр ул егетен. Җәмилә артыннан барган. Әгәр дә кем икәнен белсәм!.. Дамир да төгәл генә әйтә алмады. Әгәр белсәм, аның да арт сабагын укытам, әйтте диярсең!

Сибгатьнең бу сүзләреннән Җантимер аптырабрак калды. Белеп сөйләшәме бу, әллә инде сукыр килешме? Монысы аңлашылмады. Ә нигә Җантимердән Җәмиләнең егете кем икәнлеген сорамый икән? Беләдер!

Сибгать кабатланды. Кабатланган саен тәвәккәлрәк һәм усалрак булырга тырышты. Шәраб тәме Җантимернең авызында күптән кипте, тәненә сеңде. Кабат айныды, ә Сибгать һаман исерекләрчә сөйләнә бирде...

— Мин Җәмилә өчен сугышырга әзер, хәтта атышырга! Ничек кенә булмасын, ул бары тик минеке генә! Ул бары тик минеке генә, и, всё!..

Ә кызның кемне яратуы-яратмавы аны бөтенләй кызыксындырмый иде. Җантимер үзенең Зарифәгә гыйшык тотып йөргән чакларын исенә төшерде. Ул вакытта аңа трактористлар курсында укып маташкан авылдашы Гыйльметдин бәйләнеп алган иде. Ул да шушындый ук сүзләрне янау белән әйтте түгелме соң? Шунда аннан Җантимер сораган да иде әле:

— Зарифә үзе кемне яратса, шуның белән йөриячәк инде!— дип.— Син аны ратканыңны әйтәсең дә, ул, моңа карап, сине яратыр микәнни соң? Белмим!

Моңа каршы кылчык Гыйльметдин ничек җавап бирде әле? Башта авызын тутырып көлде, аннан соң, күкрәк суга-суга:

— Миңа комачаулаучы кеше булырга тиеш түгел. Яраттыра белербез. Иң мөһиме — үзем яратам. Кызлар шулай алар, син яратсаң, синеке була, мин яратсам, минеке, белдеңме?! — дип, Җантимерне тәмам аптыраштa калдырган иде. Боларга кызның уй-кичерешләре, йөрәк хисләре бернәрсә дә тормый. Теләсәләр, яраткан кешеләренең җаннарын таптап та китәргә күп сорамаслар?..

Гыйльметдиннән шундый сүзләрне ишетү Җантимерне гарьләндерде. Ачуы кабарып, кулларын йодрыклады. Әмма алар — бишәү, ул берүзе генә иде. Җантимер кискен хәрәкәт ясауга, Гыйльметдиннең мөритләреннән олырагы, Тәкә Самат дигән кушамат белән дан алганы Җантимернең яңагына менеп тә төште:

— Селкенмә, егет, ипи шүрлегең җимерелер,— дип масайды, җитмәсә.— Монсы әлегә аванс кына, получкасы соңрак булыр, акылыңа килмәсәң!

Җантимер көчсез иде, буыннары ныгып җитмәгән. Әмма сүз белән булса да җавап кайтармыйча калмады ул бу вакытта:

— Зарифә үзе кемне сайлый, шуңа булсын! Мин аны яуларга теләмим. Ул хайван да түгел, җир дә түгел, талап алырга. Ә тере кеше!— дип кенә әйтә алды. Әмма Гыйльметдин кырт кисте:

— Кыз ич ул, минеке булыр. Булмаса, булдырырбыз!

Бу вакыйгадан соң ничәмә-ничә еллар агып кына үтеп киткәннәр. Зарифә исә барыбер Гыйльметдингә тәтемәде, Җантимернең дә күңелен башка берәү яулады.

Шушыларны исенә төшергәнлектән, Җантимер бу юлы Сибгатькә эндәшмичә калды. Файдасы булмаячак иде. Ә Сибгать һаман сөйләде дә сөйләде, бүлмәне уңнан сулга айкады, йодрыгы белән уч төбен төйде, сәер кыланышлар ясады.

— Мин,— диде ул,— Җәмилә берәүгә чыга калса, туйларына илле кеше җыеп киләм һәм киявен үтереп китәм, яки тукмап, канга батырып. Барыбер үзләренә яшәр көн күрсәтмәячәкмен! Җәмилә минеке генә булырга тиеш! Анда әйт, авылдашларыңа, һәммәсе белеп торсыннар! Минем сүз — бер: мин Җәми-

ләне яратам, ул да мине яратыр! Шунлыктан ул минеке...

Сибгать күп сөйләде. Шушы аз гына шәрабтан исердеме икән дип уйлады аның хакында Җантимер.

Инде соң иде. Кичә таралып, егетләр үз урыннарына кайттылар. Йокларга вакыт җитеп, күптән төн уртасы үткән иде. Әмма Сибгать кенә монда куна калган Җантимергә йокы бирмәде. Әле елады, әле сүгенде, әле йодрык төйнәп йөрде. Шулай да телендә һаман Җәмилә булды, кызга бары тик үзенең генә лаеклы икәнлеген дәлилләргә тырышты. Таң аткач кына арып йокыга китте. Шунда Җантимер дә черем итеп алды.

«Әллә Дамир бер-бер сүз сөйләдеме икән? — дип уйланды егет.— Юк, мөмкин түгел, ул вакытта Дамир Казанда иде... Әмма кем белән гәпләшеп утырганын белеп такылдагандыр инде бу юләр. Юкса болай ук аптыратып бетермәс иде... Ә йөзгә-сынга күркәм күренә үзе. Җәмиләгә юк-бар кешеләр гашыйк булып йөрмәгәннәр икән!»

Кичке акыл иртәнгә ярамый, диләр. Икенче көнне егетләр кайсы кая таралыштылар. Җантимер исә лекция тыңларга китеп барды. Укулары болай да күп калган иде. Таһирҗан ул көнне кич кенә кайтып күренде, кәефе яхшы, авызы ерык иде.

Җәмилә хакындагы уйларын Җантимер күңеле түренә бикләп куйды. Әмма вакыт-вакыт сөю-сәгадәт йөрәк түреннән сагыш булып ургыла-ургыла чыга да аны бөтенләй кайгылы итә, тормыштан аера иде. Болай яшәве бик авыр исә дә, яшь кеше өчен үзенә күрә бер ләззәт тә иде. Элек шушы тойгыны Зарифә хакында хатирәләре һәм изге хыяллары бүләк иткән булса, хәзер аның урынын тулысынча Җәмилә биләп алганлыктан, сөю рәхәтлеге аңа дәрт тә өсти торды. Ул үзен хәзер гомерендә беренче тапкыр чын мәгънәсендә гашыйк кешеләрдән саный башлады. Шулай да Сибгатьне кайвакыт исенә төшереп, кешелек сыйфатлары өстен чыгу аркасында: «Аның өчен Җәмилә кирәк, Җәмиләсез үзен-үзе харап итәчәк ул! Әллә мин аларның бәхетенә комачау итүче микән?» — дип тә уйлап куя һәм шушы соравына җавап эзли, хәтта тапкан төсле була иде. Моның нәтиҗәсендә: «Җәмиләне Сибгать бәхетле итәр, миннән аңа бәхет килмәс!» — дип, ахмак фикернең ялтырап куюыннан күңелен адаштыра торды. Тик җаны гына бу нәтиҗәне кабул итә алмый һәм төшләренә Җәмиләсе кереп, Җантимер юклы-барлы уйларыннан арына алгалады.

Шул рәвешле сентябрь һәм октябрь айлары үтеп китте.

Уфа белән Казан арасында ике гашыйкның мәхәббәт хатлары йөреп торды. Әмма Сибгать тә югалып калмаган икән, Җәмиләнең күңелен ул да әле хат белән, әле бүләк, әле үзе барып-килеп яуларга тырышкан. Туктаусыз булып торган һөҗүмнән әлбәттә, кыз, нинди генә ныгытма кебек күренмәсен, бирелергә дә мөмкин. Шулай да Җантимергә булган мәхәббәте аның җанын саф килеш саклап калган иде.

Көннәр үз тәртибе белән уза торды. Ноябрь ялларының берсендә Җәмилә һәм Җантимер туган авылларында күрешергә хат аша килешенделәр. Көз яңгырлы һәм авыр булса да, алар кайтканда көннәр ничектер яктырган, ара-тирә кояш та чыгып, инде йокыга талган табигатьне уятырга маташа төсле иде.

Авылда Җантимернең балачак дусларыннан Салих белән Васил дә ялда

икәннәр. Очрашуга, беренче сүзләре кайдан булса да шәраб алып, күрешүне билгеләп үтү тәкъдиме белән башланып китте. Егетләрнең кәефләре шәплек күренеп тора. Җантимер дә каршы килмәде. Кичен су буена җыелыштылар һәм утырулары озак та үтми җырга авышты. Өчесе дә шактый исерделәр. Аларның гөрләшүләренә башка егетләр дә килеп кушылды. Берсе дә буш кул белән түгел иде. Һәммәсе үз җайларыннан берәр сый чыгардылар. Җантимер тәмам исерде. Гомерендә беренче тапкыр шушы хәлгә калуы иде. Моңа кадәр кабып кына куя торган егет иде үзе. Ә бүген авызланды, салган берсен күтәрә барды. Әллә нинди кызык әкәмәтләр сөйләп бетерде, ә күңелендә һаман да Җәмиләсе булды.

Очрашачак алар. Җантимер бәхеткә күмәчәк үзен. Йөрәгендә саклап килгән барлык сүзләрен вә серләрен чишеп салачак һәм кызның кулын сораячак, беткән баш бетсен! Икесе ике шәһәрдә яшәсеннәр, юклы-барлы ел ярым эчендә берни дә булмас әле. Өйләнешсеннәр генә!

Шушы уйлары белән мәҗлесне ташлап, Җантимер клубка таба юнәлде. Әмма аякларында көчсезлек сизеп, бераз туктап торды, артыннан Салихның:

— Бүген йөрмә, анда ни калган, кем дә юк,— дип кычкырган сүзләренә дә колак салмады, яңадан үзен кулга алып китте дә барды.

Клуб юлы су аша чыгып, тауга таба алып менә иде. Җантимер басмадан чак кына егылып төшмәде. Әмма күтәрелә барган юл аның бөтен егәрен алды. Исерек башы әйләнә иде, йолдызлар буталдылар. Сәрхуш егет, читкәрәк китеп, яр кырыена утырды һәм, күзләре йомылып, йокыга чумды. Өсте-башы карарлык түгел, шакшы һәм балчык кына иде инде.

Җантимер эреп йоклады. Төнге сәгать берләрдә генә суык җилдән айнып киткәндәй булды. Үзенең кайда ятканлыгын берара аңлашмый торды. Шунда кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышын ишетеп, аңы тагын да буталды.

Болар фонарь белән Җантимернең йөзенә яктырттылар. Аннан соң, һични әйтеп тормастан, берсе аңа шактый каты итеп сукты, егет урталай бөгелеп төште. Типкәләделәр-типкәләделәр дә, үз эшләренә вәхшиләрчә куанышып китеп бардылар.

Шактый озак ятты Җантимер. Көзге салкын җил аның ертылган изүләре аша үтәли йөрде. Инде суына барган тәне үлем белән яшәү арасында тартышты. Иреннәре ярылган, маңгай һәм авыз-борыннарына кан укмашкан, авырта иделәр.

Яшьлек өстен чыкты. Үлеп яткан Җантимергә җан керде һәм ул тагын күзләрен ачты. Күкнең читендә генә матур, бик матур ярымай урак кебек кадалып тора иде. Чалт аяз төн. Киек каз юлы кыйбла тарафына дәшә. Анда Җәмилә белән Җантимер гүяки кошлар кебек очып бара иделәр.

Бу сурәт озак бозылмады. Егетнең акылы кайнады, җаны сикерде. Әмма серле сурәт барыбер югалмады. Егет белән кыз. Кулга-кул тотышканнар да еракка-еракка очалар.

— Җәмил ә-ә-ә!..

Җантимер кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. Нәрсә булды соң? Нишләп монда ята ул? Егет боларның берсен дә аңламады. Сөеклесенең исемен кычкыруга, дөнья үз төсенә кайткандай булды. Төн шыксыз һәм караңгы, суык иде. Күктә болытлар куера башлап, ай һәм йолдызларны йотарга тотындылар.

Җантимер аякларына басты. Тагын чайкалып китте. Баш чүмечен тотты. Бу урыны бик нык авырта, әмма ярасы юк иде. Белгәннәр кайда сугарга!

Егет инештә кулын-битен юды. Ул инде тәмам айныган, әмма барыбер хәлсез иде. Аны кемнәр кыйнады, ни өчен? Ул бу сорауларына җавап таба алмады. Бәлки аларга Җантимер берәр начар сүз әйткәндер, сүгенгәндер? Кем белә, бәлки? Эчмәскә кирәк иде шушы кадәр, эчмәскә кирәк иде!

Инеш җырлый-җырлый акты та акты. Төннең салкыны да, күз булуы да, Җантимернең хәле дә аңа барыбер иде. Адәм балалары сагышлансалар, кайгыга батсалар, аның янына киләләр, инде ничә йөз еллар буена тәннәрен юындыра, җаннарын сугара, кайгыларын агыза ул аларның. Моннан соң да шулай булыр. Җансыз хирург-врач төсле ул. Аңа барыбер, чүп агызамы, әллә инде сагыш-кайгынымы? Икесе дә бер үк нәрсә түгелмени?

Кулын-битен югач, Җантимер сәгатен эзләде. Тимәгәннәр икән. Акчалары да урынында. Нәрсә өчен кыйнаганнар? Кем белсен...

Җантимер, чүгәләгән җиреннән калкып, ярдан өскә карады. Аның йөзенә үткер фонарь белән тагын яктырттылар. Егет ике шәүләне генә чамалап калды.

Алар эндәшмәделәр. Җантимер үзенең беләкләрендә көч сизде. Хәзер ул аларны изеп ташлаячак.

Ике як бер-берсенә якынлаша бирде. Җантимер, кайнарланып:

— Кем кыйнады мине? — дип, дошманнарыннан санаган ике шәүләгә ташланды. Биле буйлап кайнарлык йөгергәнен тойды. Гүяки тәненә ут кадалды һәм эчәгеләрен айкап чыгарды. Аяклары кинәт хәлсезләнеп, гәүдәсе чайкалды һәм ул ярдан түбән таба, суның уртасына ук диярлек егылып төште.

Инеш кочагында тыныч һәм рәхәт иде. Җантимернең җырлыйсы килде, җырлыйсы, кычкырып бер җырлыйсы. Әмма тавышы чыкмады.

Инеш аны ташлы шарлавыкка чыгарды. «Ничек батып үлмәдем икән? — дип уйлады ул.— Ничек батып үлмәдем икән?»

Акылы җавап таба алмады. Хәер, кирәк тә түгел иде инде. Чөнки Киек Каз Юлы бит бу, инеш түгел. Әнә ул үзе дә очып бара. Киек Каз Юлыннан. Ак канатлы, энҗедәй ап-ак каз. Кая оча? Җылы якка, рәхәт, бәхетле җирләргәдер инде... Ә нигә ялгызы гына?..

Иртәнчәк кар яуды. Шарлавык эчендәге ташларны һәм яр буйларын юка гына элпә белән боз сарган иде. Бөтен дөнья ап-ак булган. Берничә көннән җиргә кар ятса, каз өмәләре башланып китәчәк, халык бәйрәм итәчәк. Авылның күңелле һәм шатлыклы көннәре бу. Кичләрен яшьләр бәлки аулак өйләр оештырырлар, биерләр-җырларлар. Апалар каз маенда гына тәбикмәк һәм коймак пешерерләр. Каймакка манып-манып абзыйлар чәй эчәрләр.

Җәмилә авылга бер генә көн өчен, Җантимерен күреп, кайнар иреннәрен үптереп, кочагында җылынып, сүзләреннән иркәләнеп китәр өчен генә кайткан иде. Әмма очраша алмауларыннан, егетнең алдавыннан күңеле киселде, күзләренә яшь тулды, төне буе йоклый алмады. Юклы-барлы бер-ике сәгатькә генә күзләре йомылды. Төш күрде. Төшендә Киек каз юлы буйлап адашып очканын күзаллаудан кычкырырдай итте. Шунда кайдандыр Сибгать килеп чыкты. Кулында ук-җәя иде. Аңа төбәп атты. Җәмиләгә тиде һәм шушы юньсезнең кочагына ул егылып төште. Сибгать авыз күтәреп көлде. Җәмилә Җантимерен ча-

кырды. Әмма бәгырь кисәге аны ишетмәде. Киек каз юлы буйлап каядыр еракка ашыга-ашыга очты, энҗеле ялгыз аккош булып очты. Әйләнеп тә карамады.

Җәмилә куркынып уянды. Әнисе аның янында басып тора иде.

— Ни булды, балам? Кемне дәшәсең? Саташасың бугай? — диде ул, юатулы тавышы белән бер-бер артлы сораулар яудырып.— Китәсем бар дигән идең. Кешеләр кузгалганчы юлга чыгыйк.

Төше онытылды. Җәмиләгә ашыгырга кирәк иде. Эшкә соңарырга ярамый. Бүген китсә, Уфага кичкә генә барып җитәчәк, аннары — эш-эш-эш.

Урамда ап-ак мамык кар яуган иде. Бөтен дөнья яктырып киткәндәй. Иртәнге эңгер-меңгер кар аклыгы белән сизелми дә.

Җәмилә биштәр-сумкаларын җыештырды да юлга чыкты. Әнисе озата килде. Кызының Җантимерләр йорты яныннан узган вакытта әйләнеп-әйләнеп карaганын күреп торды, йөрәге хәвефкә төште. “Шушы кадәр яратса да яратыр икән” дип уйлады ул үзалдына боегып.

— Җантимер дә кайткан булгандыр?—дип сорады кызыннан.

— Кайтканын әйткәннәр иде,— диде Җәмилә, сагышлы тавыш белән.

— Күрешмәдегезме?

— Юк, әни,— диде дә Җәмилә һәм елап җибәрде.

Әнкәсенең бәгыре киселде. Ничек кенә юатырга да белмәде кызын — йөрәге парәсен.

— Шулай килеп чыккандыр инде. Ышанырга ярыймы соң хәзерге егетләргә,— дип әйтеп, кызын орышкандай итте. Еламасын, имеш!

Җәмиләне олы юлга ук чыгарып, озатып ук калды. Кызы, бичаракаем, боек һәм сагышлы күз карашын әнисеннән яшереп кенә саубуллашты да китеп барды. Авылга анасы йөрәген тотып кайтты. Төнлә Җантимер белән булган хәлләрдән кызы төсле үк ул да хәбәрдар түгел иде әлегә.

Җәмилә чыннан да сагышлы рәнҗү белән китте авылдан. Бераздан күңелендә сәер тынлык кына калды, аннан соң ачуы кабарды. Юл буе Җантимерне битәрләп барды. Барысын да әйтеп хат язарга, башка минем хакта уеңа да алма дип, мөнәсәбәтләренә нокта куярга уйлады.

Җантимерне Җәмилә бала чагыннан бирле хәтерли иде. Чая һәм шаян бу малай вакыт-вакыт чишмәгә су алырга килә иде дә, дүрт чиләк сыешлы бидонын тутырып, чанага утырткач, авызын ерып кына китеп тә бара. Башка берәүләр булса, су чәчрәтеп, кызларның җелекләренә үтәләр. Ә Җантимер алай итми, бөтен кешегә илтифатлы иде. Кызлар һәм апалар үзен үртәп тә карыйлар, ул бирешми, авызын гына ера, үзенең эше белән мәшгуль. Аны күреп, усал телле хатыннар сүзеннән Җәмиләнең күңеле кителә, Җантимерне башыннан сыйпап юатасы килә. Ә ул моңа мохтаҗ булмады. Сөяккә дә эредән үсте.

Җәмиләләр берара Әлмәткә китеп яшәделәр, ике-өч ел. Кабат авылга әйләнеп кайткач күрде: Җантимер егет иде инде. Әмма сукмаклары очрашмады. Хәзер суга да йөрми башлаган икән, энесе алыштырган үзен.

Зарифә белән Җантимернең мөнәсәбәтләре хакында ишеткәч, егетнең күңелен яуларга мөмкин түгел икәнен яхшы аңлап, моның белән дә килеште ул. Ә бу җәйлектә яратышып йөри башлагач, Җәмиләне бәхет-сәгадәт күмде. Алар пар килгәннәр бит!

Һәм менә барысы да бетте. Җантимер алдап кына йөргән икән аны. Бер дә башкача түгел! Кайтты бит Җантимер, кайтты! Ни өчен клубта күренмәде? Исерек Салихларның сүзе дөрес булды микәнни? «Югары очка китте ул, Зарифә артыннан»,— диделәр. Шулайдыр. Килми калмас иде. Берьюлы өч кызны озатам дигән була иде. Капка төпләренә кайткач та күпме аны көтеп утырды, килмәде егет, килмәде!

Язачак, барысын да әйтеп язачак, ачуланып-рәнҗеп язачак хатны аңа Җәмилә. Юлда гына язып булмый. Әллә поездга утыруга каләм тибрәтә алырмынмы дигән иде дә, мөмкин түгел икән. Гел чайкый...

Эшкә вакытында килеп җитеште, өлгерде Җәмилә. Аның боек хәлен барча хезмәттәшләре башта ук сизеп алдылар, әмма борчымадылар, сораштырмадылар. Кичен кайткач кына вакыты табылып, хат яза алды ул. Туйганчы ачуланды Җантимерне, ышанычсыз, ахмак дип атады. Конверт тышына адресын теркәүгә, тагын капланып елады.

Иптәшләре кич белән киногa чакырган иделәр. Хатны да ташлап китәргә кирәк. Җәмилә аларга иярде. Картина аңа ошамады. Арыган булса да, кайткач күзенә йокы кермәде, гел елыйсы килеп торды һәм авылда күргән төшен исенә китерде. Күзен йомды, барысы да хәтерендә калган икән: Киек каз юлыннан Җантимер энҗеле аккош булып, ак канатларын җилпи-җилпи каядыр оча да оча, ә үзе Җәмиләне дәшә. Тукта, Җәмилә үзе аны чакырган иде түгелме?

Тагын төш күргән икән. Сәгать чылтыраудан уянып, иптәш кызлары эшкә ашыктылар. Бүген иртәннән Уфада да кар яуды. Ап-ак, чиста, якты кар... Бу — Җантимерне кәфенләп күмгән көн иде...

Дөньяда Илаһи канун бар, диләр. Ул — мәхәббәт!

Мин бәхетле идем. Әйе, бәхетле идем. Бәхетемнең кадерен белеп кенә яшисе дә яшисе идем. Әмма язмыш дигәне кермәгән утларга кертә, күрмәгән газапларны күрсәтә икән. Ә ул кешенең кемлегеннән генә тормый, башкаларның үзүзләрен тотышларына да бәйле.

Бар бу Җирдә Илаһи канун. Бар! Әйе, ул Чын Мәхәббәт дип атала. Аның мәгънәсен аңларга теләгән кешеләр Таһир-Зөһрәне, Ләйлә-Мәҗнүнне исләренә төшерсеннәр, Киек каз юлына күзләрен күтәреп карасыннар, ул — Гашыйклар кыйбласы. Дөньялыкта кавыша алмаган ярлар анда бер-берсен табалар. Әгәр дә сез бер-бер ялгыз кошның анда очып йөргәнен күзалласагыз, белегез, ул үзенең ярын көтә, аны дәшә! Әмма Илаһи канунны бозмый, дөньялыкка килеп төшми. Көтә, бәлки, кычкыра-кычкыра чакыра да торгандыр!

Һәм сөекле яры да, озак көттергәннән соң, канат тибрәтеп күкләргә күтәреләр. Алар очрашырлар, сөенешерләр һәм китеп барырлар. Болай булмау мөмкин түгел, бу — Илаһи канун!

## СИХЕРЧЕ КЫЗЫ

*Повесть*

Һәр җәйне шәһәрдән авылга кайтарып, мине әбиләрдә калдыра торган иделәр. Соңгы ике елда бу бәхет тәтемәде. Шулай да быел алдан ук әйтеп куйдым:

— Әбиемнәргә кайтасым килә! Мин авылны яратам! Каз бәбкәләрен, сарык бәтиләрен, маэмаебызны сагындым! — дидем.

— Нинди маэмай инде ул? Әллә кайчан бозау кадәрле эткә әверелгәндер!— дип, әткәй каршы чыгып караса да, үз сүземне кабатладым.

Әнкәй килеште:

— Ярар, улым! Кайтарырбыз... Безнең белән бергә ял итәсең килмәгәч, авылда ятарсың, сала малае булып!— дип әйткәч, башым күккә тиде.

Сала малае да булырмын әле! Бик булырмын! Ә нигә? Ярамыймыни? Авылда минем дусларым күп, җәйнең башыннан ахырына кадәр алар белән эт сугарып йөрибез. Ачуланучы-әрләүче дә юк, беркем комачауламый. Бәлки әле әткәй дә ялгышадыр! Акбаем алай ук бозау кадәрле эткә әверелмәгәндер, һаман да маэмайдыр! Юри әйтә ул, белеп торам. Авылга җибәрәсе килми. Гел дә үз янында гына тотар иде. Юк инде! Алай булмас, быел мине авыл көтә! Кызыктырмагыз әллә нинди зәңгәр күлле, бозлы-карлы тауларыгыз белән. Кирәк икән, үзегез генә шунда китегез. Ә миңа авыл һавасы, суы-чишмәсе, урманы-болыны, һәммә-һәммә җирләре якын. Яратам мин сала малае булып, аяк-кулларны тузанга батырып, су буйларында балык чирттереп, иптәш малайларым белән мәш килергә. Ни дисәгез дә, миңа бит инде унике яшь. Сабый бала түгел. Үзем өчен куркасы да, борчыласы да юк! Анда дусларымнан Гамил, Айдар, Җиһангир бар. Менә дигән шәп малайлар. Әйттем — бетте, җәем шулар белән үтәчәк!

I

Сабантуйга дип атап авылга кайткач, әткәй белән әнкәй мине калдырып, елак сеңлем Зөһрәне үзләре белән алып киттеләр. Мин кул селтәп, озаткандай иттем.

— Улым Алмаз, дәү әниеңне тыңла! Эшләрендә булыш, көне буе уйнап кына йөрмә,— дип, әнкәй үгет-нәсыйхәтен тапшырса да, аларның машинасы юл тузанына күмелүе булды, урамга чыгып та шылдым. Инде күптән тәрәзә каршыбызда кайнашкан Гамил белән Айдарның су буена таба төшеп киткәннәрен күреп калган идем, шунда гына уйный торганнардыр әле!

Ялгышмадым. Алар бер өем бүрәнәләр өстендә тирбәлеп-сөйләшеп утыра иделәр. Мине күрүгә, каршыма ук җитешеп төштеләр. Беренчеләрдән Гамил миңа кулын сузды:

— Сәлам, брат!

Аның болай кыландырып сөйләшүе абыйсыннан күчкән гадәте булганлыктан, мин дә өлкәннәрчә кул бирдем һәм шапылдатып уч төбенә суктым да:

— Шәпме хәлләр?..— дип кенә җибәрдем.

Ул арада Айдар да кулын сузды:

— Исәнме? Нигә былтыр кайтмадың?— диде ул.

Күрештек. Аның югарыга тартылып киткән буе, ерык авызы, башындагы түбәтәе тәмам үзен олыгайтып җибәргәннәр, кыяфәтенә карап кына танымаска

да мөмкин иде, әмма хәрәкәтләре һаман да элеккечә, кыеш-мыеш килеп торган җил тегермәнен хәтерләтә. Ә Гамил ныгып, тазарып киткән. Ярым шәрә тәне тулып, мускуллары тыгызланып тора.

Турникта уйнаштыргалыйлар икән! Ярышларда да катнашкалаганнар. Мактанышып алырга да өлгерделәр. Авыл малайлары шундый инде алар. Ни булса да — авызлары ерык, ни эшләсәләр дә — мактанырга гына торалар. Ә мин алай түгел. Шәһәрский!

Үзем турында кирәкмәс. Аларга дип алып кайткан күчтәнәчләрем дә бар бит әле: кармаклар, матур-җайлы, ал-кызыл калкавычлары, көмеш энәләре булган яхшы җепле кармаклар! Мин аларны, кесәмнән чыгарып, берәм-берәм Гамил белән Айдарга суздым.

— Ә Җиһангир кайда?

— Бүген күренмәде әле! Йокысыннан уянып җитмәгәндер?.. Әйткән иде, каникулларга чыксам, төшкә кадәр йокы симертәм дип. Шулайдыр.

Гамилнең бу сүзләреннән Айдар тагын да шәбрәк итеп авызын ерды. Аңа мин дә кушылдым. Дусларым, китергән бүләкләремә сөенеп, тәмам дөньяларын оныткан хәлдә кармакларын тикшерә башладылар. Балыкка төшәргә теләкләре кузгалырга өлгергәч, түземлекләре бетте. Мин дә әйдәкли башладым. Әмма Айдарның башы салынып, пышылдап кына аңлатты:

— Анда сихерче кызы әле! Ул менмичә, су буена төшә алмыйбыз!

— Нишли соң ул анда?

— Балык тота!

— Тотса ни, нәрсә булган?

Гамил минем киреләнүне тиз басты:

— Ярамый, зәхмәт китерүе бар!

Чарасыздан мин дә бүрәнәләр өстенә килеп утырдым. Җиһангир дустыма дигән кармакны карый башладым. Аның белән Айдар һәм Гамил дә кызыксынып киттеләр.

— Моныкы әйбәтрәк! — диде Гамил, көнләшкән төсле итеп.

— Алайса алыштыр, синңа булсын,— дип, Җиһангирныкын аңа суздым. Тик Гамил үзенең кармакларын учлап тоткан иде, алардан аерыласы килмәде, карап алды да:

— Минеке дә яхшы!— дип мактанып куйды.

Җиһангир һаман да күренмәде.

— Ул булса, куркып тормас идек! — диде Айдар.

Гамил аның белән килешергә ашыкты. Боларның икесенең дә йөзләренә чыккан сәер бер өркәклек шәүләсе миңа да күчте. Чөнки ул сихерче кызы һәм аның әнкәсе хакында бераз гына булса да хәбәрдар идем.

II

Аның әнисе кем икәнлеген мин ачык кына белмим дә, хәтта күргәнем дә юк. Яшәгән йортлары авылдан читтәрәк булганлыктан, ул якка хәтта маллар да бармый, малайлар да, усалланып, яшелчә бакчаларына керми, ихаталарын урап узарга тырышалар иде. Әмма ул сихерче хатын исеме белән дан тоткан апаның кызы Камилә белән мин шактый яхшы таныш булып, элек кайтканымда бергә

уйнаганым да бар иде. Тик шуннан соң бик озак авырып яттым да сихерче зәхмәтеннән дип әткәй-әнкәй авылга аягымны да бастырмаска киңәшеп куйган иделәр. Хәзер зур үскәнлегем сәбәпле ышандылар булса кирәк.

Ул сихерче хатын турында ишеткән-белгәннәремне бергә җыеп сөйли калсам, көлкеле һәм адәм ышанмаслык бер хикәя кебек нәрсә барлыкка киләчәк. Шулай да хәбәр итеп китәргә кирәктер. Үзем боларга бик ышанып җитмәсәм дә, кайвакыт күңелгә килә дә, әллә тагын хак микән дигән сорау борчый башлый күңелне. Чыннан да, Тукай әйтмешли: «Күктә ниләр булмас дисең, очсызкырыйсыз күк бит ул!..» Бу җир йөзендә дә шулайдыр инде! Башкача түгелдер?

Камиләнең әнкәсе, имештер, инде йөз елгача гомер сөргән әби, диләр. Әмма кызы гына нигәдер бик яшь әле. Миннән дә кечерәк булса кирәк? Танышкан вакытыбызда ул әле икенче сыйныфны гына бетергән иде, хәзер дүрткә күчкәндер мөгаен. Аның хакында: «Гел «бишкә» генә укый!» — дип ишеткәнем бар иде. Белмәгән нәрсәсе, танымаган үләне юк!

Сөйләргә теләгәнем әнкәсе хакында да булганлыктан, сүзне әүвәле шуннан башларга кирәктер?

Вакыйгалар менә болайрак диләр: имештер, элекке заманнарда авылның олуг байларыннан саналган бер адәме бик нык авырып киткән. Сырхавы шулкадәр дә каты булган ки, һәртөрле табиплар вә им-томчылар аңа бернинди дәва да таба алмаганнар. Инде менә-менә үләр дип көткәннәр үзен. Әмма дә ләкин әҗәле җитмәгән кешене үлем алып китә димени? Гомере бар икән. Кайчандыр кемгәдер бик зур яхшылыклар эшләп, аны ниндидер афәттән коткарган ахрысы? Әмма ни генә булмасын, бәндәләрнең яманлыгы да, яхшылыгы да җирдә калмый, бер кайтарыла шул. Монда да шул хәл кабатланган.

Инде үлә, инде күмәрбез дип аптыраган туганнарының һәм гаиләсен шаккатырып, көннәрнең берендә боларга бер им-томчы әби килеп кергән дә әйткән:

— Йа Аллаһы Тәгаләнең изге колы, син күргән җәбер-золымны язмыш безгә бирмәсен! Синең каршыңда күпме табип вә сырхау серләрен белгән бәндәләр хезмәт куйдылар, әмма һичберсенең күңеле нәтиҗә сөенече белән балкымады. Син әҗәлеңне дә, тынычлык-иминлегеңне дә тапмадың. Инде мин килдем! Яхшылык җирдә ятмыйдыр...

Аның сүзләреннән гаҗәпләнгән халык телсез калган, актан да, карадан да сүз катарга җыенучы күренмәгән. Ә бу серле зат һаман да үз эшендә булган. Авыруны баштанаяк карап чыккан, йөзеннән сыпырган, сулышын тыңлаган.

— Аллаһы тәгаләнең рәхмәт-шәфкатьләре ирешсен... Бу бәладән үзеңне коткарырмын!—дигән һәм әлеге хәлгә шаһитлык кылып торган туганнарына әйткән:

— Барыгыз, далага чыгыгыз һәм миңа шундый сөяк китерегез: ул саф һәм чиста булсын, кайчандыр суелган атның калак сөяге төсле оча сөягеннән булсын, кипкән булсын! — дип әмер биргән.

Ни кирәксә, шул инде, дигәндәй, бу сүзләргә колак салып, һәммәсе кыргадалага чәчелгәннәр. Бик күп ара җирләрне узып, һәртөрле сөякләргә юлыкканнар, әмма кирәклесен таба алмыйча гаҗизләнгәннәр.

Ә сырхау бай һәм сихерче зат тыныч һәм сабыр гына боларны көтә биргәннәр.

— Әгәр дә абзарымдагы кара айгырымны суйдырып, сөяген җилдә җилләтергә куйсам, бу вакыт эчендә шул дәрәҗәгә килер иде,— дип байның әйтүе булган, кече улы кайтып кергән:

— Йа Аллаһы тәгаләнең колы, кирәгеңне вә сораганыңны алып кайттым,— дип шатландырган.

Аның артыннан уртанчысы, койрыгына ияреп диярлек өлкәне җитешкән. Сихер вә серләр иясе бәндә бу китерелгәннәрне кырын күз белән генә карап алган да, кече улыныкын сайлап:

— Ә боларын, калганнарын, илтеп күмегез!— дигән.

Ул арада учак ягып, серләр иясе сөякне утка ташлаган, янәшәсенә тимер кендек куйган. Үзе бар дөньясын онытып җыр сузган, кулында думбраны бииткән. Кем күреп калырга, кайсы кызык эзләп килгән: халык тамаша кылуда икән.

Җырлый вә такмаклар әйтә торгач, җырчының авызы күбекләнеп калган. Ул арада уттагы тимер дә кып-кызыл булып кызган. Сихерче аны чыгарып, теленә тидереп караган. Халык аһ иткән. Тамаша кылучы хатыннар куркудан йөзләрен яшергәннәр, ирләр аңсызланып калган. Ә серләр иясенең тел очы чожлап, тимер безелдәп куйган.

Шуннан соң яндырылган сөякне чыгарып, сихерче аны төйгән, тузан хәленә китергән. Яңадан тимерне алып, авызына таба китергән. Йөзләре агарып калган халыкны тагын да хәйранга калдырып, пычак белән сихер иясе тел очын кискән дә, ут кебек кызган тимергә канын тамызган. Чыккан исне сырхауга таба өргән. Тегенең дә бу хәлләрне күреп торудан таң-гаҗәеп калып, авызлары ачылган мәле икән. Йөзенә кайнар һәм моңа кадәр һичбер тапкыр да борынына кермәгән иснең йөгерүеннән ул тагын да аһ иткән.

Бу да түгел, серләр иясе сихерче, теге сөяк тузанын үзенең билбавыннан чыгарган кечкенә шешәдәге суы белән изеп-болгатып, тагын да бераз сыеклык вә су өстәп, шул сыекчаны авызына алган һәм кайнар тимер кендек аша сырхауның йөзенә кабат йөгерткән.

Бу эшләре беткәннән соң:

— Өч көннән атагыз аягына басар, озын гомерләр кичерер, эше вә гамәле яхшылык вә хөрмәттә исә, башка һичкайчан аңа зәхмәт кагылмас!— дип белдергән.

Егетләр баштарак ышанмыйча торганнар. Шунда газиз аталары ыңгырашып әйткән:

— Мин бу серләр иясенә ышандым! Аллаһы тәгаләнең әүлия бәндәсеннәндер. Мул итеп сыйлагыз, байлыгымнан ни кирәк, шуны бирегез, акчаны кызганмагыз! — дип әмер иткән.

Уллары тиз арада әмерне үтәргә ашыкканнар. Әмма бу зат аларны туктаткан һәм:

— Дөньялар бозылырлар. Әмма дә ләкин бер теләгем бар! Вакытлар үткәннән соң авылыгызга ялгыз хатын керер, кулында биләүле бала булыр. Аны какмагыз-сукмагыз! Бу вакытта балаларыгыз денсез вә имансыз, күңелләрегез җимерек вә ертык, мәсҗедегез ауган хәлдә булса да, ул анага хөрмәт күрсәтегез! Йортсыз-җирсез калдырмагыз! Аны кадерләп тәрбияләгез. Менә шул теләгем!— дигән.

Бай шунда үзенең утарын теге киләчәк хатынга атаган һәм аны көтәчәген вә балаларына бу хакта васыятьнамә төзеп калдырачагын белдереп иман кәлимәсен кабатлаган, сүз биргән. Шуннан соң серләр иясе ничек көтмәгәндә пәйда булса, шулай китеп тә барган. Өч көннән бай абзый аякка баскан. Авыл читендәге утарының әйләнәсенә алма бакчасы утырткан, йортын кат-кат төзекләндергән. Әмма анда һичкемне яшәтмәгән.

Ул арада илдә ихтилал чыгып, тормышлар тәмам бозылып беткән. Байны йорт-җиреннән куганнар, әмма әманәт итеп куйган утарына тиюче булмаган. Колхозлар оеша башлап, каладан рәис китергәннәр. Бу бәндә сабан-суканың нәрсә икәнлеген белмәсә дә, бик тә үткер кеше булып чыккан. Байның васыять утарына кереп төпләнгән.

Баштарак бар да җай гына барса да, бу рәиснең гаиләсенә афәт юлыгып, үзе дә сырхауга калган. Табиплар моның серен белә алмаганнар. Җеназасын илткәндә халык кинәт теге серләр иясе белән булган вакыйганы исләренә төшергән. Шуннан бирле утар шул килеш калган. Алма бакчалары кыргыйланган, түбәләре яңгырдан череп, йорты иңеп беткән. Әмма серләр иясе әйткән хатын авылга килмәгән, бай да сөрелгән җиреннән кире кайта алмаган. Илдә сугышлар чыгып, төрле-төрле хикмәтләр булып беткән. Шулай итеп, сихер иясенең юраганнары һәммәсе дә диярлек юш килгән. Бары...

Имештер, халыкны таң-гаҗәпкә калдырып, көннәрнең берендә авылдан сөрелгән бай утарының бакчасы да, йорты да әүвәлге хәленә кайткан. Урам буйлап, ул да түгел, ак биләүдә бала күтәреп бер хатын үткән һәм шул өйгә кереп яши башлаган. Баштарак аны килеп күрергә курыкканнар. Әмма ир-егетләрнең күзләренә ул хатынның чибәрлеге чалынмыйча калмаган, алар читтәге бу йортка сукмак салырга уйлаганнар. Тик хыяллары гына барып чыкмаган. Килеп җитүләре була икән, каршыларына яки берәр бозау кадәрле олы кара эт, яисә карчыга-ябалак чыга, ди. Кайсыларын агачлар тотып кала, кайберәүләре егылып зәхмәт таба башлаган. Шулай да моны кемнәргәдер хәбәр итәргә курыкканнар, ә болар шушында яши биргәннәр. Камилә исә менә бу хатынның биләүдәге кызы икән.

III

Сөйләнергә тиешле сүзләр күп булуга карамастан, аларны калдырып, миңа да тормыш вакыйгаларына кайтырга туры килә...

Иптәш малайларым белән утырган арада тегене-моны сораштырып, сихер иясе хакында тузга язмаган хәлләр хакында уйларга да өлгермәдем, өстенә менеп утырган каен бүрәнәм канатлангандай күккә таба сикереп куйды. Ни күрим, каршыбызда Камилә басып тора иде. Шомырт кара күзләре, кара елан кебек чәч толымы, кояшта янган бит очлары — болар барысы да аны шоколад төсенә керткән, матурлык һәм чибәрлекләрен дә өстәсәң, акылларны алырлык бер гүзәлгә әверелдереп бара иде. Минем тел очыннан ике генә сүз чыкты:

— Исәнме, Камилә?

Ул моны көткән иде, күренеп тора, сүзләреннән үк сизелә бит.

— Ә-ә, Алмаз кайткан икән! Кала малае!

Кулындагы зур, өч литрлы банкасын җиргә куйды. Аның эчендә нәрсәләр-

дер йөзә иде. Гамил белән Айдар агачлар артына качу ягын карадылар. Әмма өелеп торган утын бүрәнәләре арасына кермәсәң, башка җирдә котылу урыны юк иде.

— Бакалары сикереп чыга күрмәсен, тотып ашыйлар үзеңне!— дип, миңа киңәш бирергә дә өлгерделәр, тик качып җитешә генә алмадым.

Безнең болай тора салып шүрләвебез Камиләнең үзенә бик тә көлке тоелгандыр инде, тәгәрәпләр китте инде менә: эчен тотып, ямьле йөзен тагын да күркәмләндереп, минем кебек ахмакларны кызык итеп...

Иптәшләрем нинди хисләр кичергәндер, бәлки оятлары күлмәкләреннән тартып, һаман да җиргә табарак сыеныргa мәҗбүр иткәндер? Әмма мин сер бирмәскә тырыштым. Ничек үземне кулга тотып өлгерергә, шушы ерык авызлы чибәр кыз алдында куркак кала малае дигән исемне алмаска? Моның өчен чын егетләр шикелле үк гайрәтле һәм батыр кыяфәт ясарга тиеш идем. Шушы фикер акылымны яндырып узуга, йөземә кызыллык йөгергәнен тойдым. Камилә һаман да эче катып көлә иде.

— Нигә хихылдыйсың? Кузгалмагансыңдыр бит акылыңнан?

Болай әйтеп ташлавымнан кыз кинәт кенә үзгәреп китте. Йөзенә бәреп моңа кадәр һичкем: «Юләрләнденңме әллә?» — дип, минем кебек мәгънәсез рәвештә әйткәне булмагандыр?

Әллә ялгыш ишетәмме дигәндәй, Камилә инде аптыраштa карап торды. Утын агачлары артына сеңгән иптәшләремнең башы калкыды. Алар: «Нәрсә булыр инде?»— дип, күзләрен тәреләндерделәр. Камиләнең усал карашыннан инде минем тәнем буйлап икенче кат куркып калтырану хисе йөгерергә өлгерде. Хәлем харап иде.

Ярдәм өметендә иптәшләремә сыеныргa теләдем. Әмма аларның үз хәлләре хәл булу сәбәпле, мине бәладән коткарып калуларына һичбер ышаныч юк иде. Табигый рәвештә артка чигенгәндәй иттем. Әмма утырган урыным каен бүрәнәсе булу сәбәпле, тигезлегемне югалтып, чалкан киттем һәм, баштүбән кадалып, бүз үләнгә барып төштем. Күзләремнән утлар күренеп, һәлакәтем шушы икән дип уйладым. Бу кадәр дә мыскыл булмасам инде!

Яман хәлем өстенә гарьләнү хисе мине бөтенләй дә бетереп ташлады. Инде елап, өйгә таба йөгерәсе генә кала! Ә анда кемгә сыенам? Әбиемәме? Шушы башым беләнме?

Чарасызлыгым иш янына куш килеп, башымнан акылны, тәннән гайрәтне чыгарды. Мин инде бүселеп киткән капчык сыйфатында идем.

— Сихерче бәрде! Күзе белән чөйде!..— дип, иптәшләрем телгә килделәр дә, ул да түгел, Гамил артыннан Айдар, шәрран ярып, өйләренә таба шылдылар.

Мин исә Камилә кулында калдым. Тилгән тырнагында көзге чебеш ничек чикылдаса, мин дә шулай тырмашырга әзер идем. Әмма ничектер җанга җылы һәм рәхәт булып китте, бөтен дөньям онытылды, йоклап киткәнемне сизми дә калдым. Моны үлем дип тойдым, җанымны язмышым кулына тапшырдым.

— Уян инде, Алмаз, берни дә булмады... Егылудан гына малай кеше имгәнми! — дип Камиләнең йомшак кына сөйләвеннән һәм башымны сыпыруыннан соң күзләрем ачылды. Җәйнең үткер һәм туры кояшына чагылган күзләремне кабат кыстым. Сакланып кына керфекләремне күтәргәндә, сихерче кызының

карашына очрап, ятсынып ук киттем. Әмма бу юлы курку урынына җан түремә рәхәтлек һәм тынычлык тулган иде.

— Зәхмәт кагылмасын!— дигән сүзеннән соң тагын да айнып киткәндәй булдым һәм сикереп тордым.

— Нәрсә соң ул?

Камилә миннән рәхәтләнеп көлде. Яңа гына кичергән тынычлыгым инде юкка чыккан, күңелемдә кабат юшкыннар кайнап, акылыма аптырау коткысы төшкән иде. Соравымны кабатладым:

— Нәрсә соң ул зәхмәт?

Бу юлы Камилә үзе дә аптырап калды. Кара күзләрен миңа тутырып карады, наданлыгыма исе-акылы китеп булса кирәк:

— Шуны да белмисеңмени? — дип куйды.

— Белмим дип, беләм бугай... Усаллыктыр иңде. Сихерченең зәхмәте тия диләр бит.

Никләр генә шушы сихерче сүзен әйттем. Моңа Камиләнең ачуы киләчәк, хәзер котымны чыгарачак инде дип көттем, әмма бу куркуым да юкка гына икән.

— Сихерчеләрдә зәхмәт була да була инде ул. Алар бит дию пәриләре белән эш итәләр, җен-пәриләрне арбаларына җигәләр...

Минем баш бетте алайса. Бу сихерче кызы чыннан да дию-җеннәр белән бергә эшнәлек кылса, харап кына итеп ташлый инде хәзер. Өлкәннәр сүзен тыңламыйча, тапканмын бәйләнер кешене!

— Синең дә җен-пәриләрең бармы?

Куркак кешенең акылы китә икән ул. Минем дә шулайрак килеп чыкты. Берсе артыннан икенчесе дигәндәй, һаман да ялгыша бирдем. Котым ботыма гына качтымы соң?

— Ә нигә булмасын ди?

Камилә рәхәтләнеп куркыта бирде.

— Аның берсенең исеме — Аксак, икенчесенеке — Сукыр, өченчесенеке — Чулак... Кайсына әмер итсәм дә, башыңа җитәләр инде!

— Юк ла, шаяртасыңдыр әле...

Көчсез генә чыккан тавышымны Камилә элеп алды, елмаеп, юаткандай әйтте. Шул сүзләреннән соң котым бераз тәнемә кайткандай иде:

— Менә, менә акылың эшли башлады, дәвам ит...

Тагын нәрсә дияргә инде моңа? Иң яхшысы — торып йөгерү инде. Ә артыннан мыскыллап-көлеп калса? Кызлар каршында, кала малае була торып, шулай оятка калырга мөмкинме соң? Юк инде! Нәрсә дисә, шул! Бирешеп торасы түгелмен!

— Диюләреңне чакыр! Сугышабыз!

Минем болай батыраеп китүемнән Камилә тагын да эче катып көлә башлады. Мин аны, малай башым белән, менә хәзер төртеп егарга, теленең мыскыллауларына чик куярга тиеш идемме? Бәлки шулай кирәк булгандыр. Әмма кыюлыгым җитмәде. Шомырт кара күзләре һәм матурлыгы каршында баш иярга, күтәрелгән кулымны төшерергә мәҗбүр идем.

— Ышанмыйм мин ул диюләреңә! — дип белдерүдән артык эшкә ярамадым

анысы.

— Ә кем сиңа, әйе, ышан әле, ди?

— Ышанмыйм шул! Тапкансың куркытыр әйбер! Дию пәрие, имеш! Биш ятып, бер төшемә кермәгәнне... Юк-бар сөйләп торасың тагын. «Барчасы юк сүз аларның, булганы юктыр гомер!»

— Беләсең икән!

— Беләм шул!

— Тукайны!

— Аны әйтәсеңмени?

— Ә диюләр, зәхмәтләр хакында һичнәрсә дә белмисең! Ахмак син!

— Үзең кем!

— Камилә...

— Беләм...

Безнең болай телләшеп китүебезнең ахыры-чиге юк иде. Шулай да Камилә ерылган авызын җыярга ашыкмады, минеке исә бәлеш кебек бүселеп китәргә генә тора. Ну, кызый, малайлар белән телләшеп тә җиңелмәсәң, башың бетте!

Уйлаганымны әйтергә өлгермәдем, күз алларыма караңгылык җәелеп, кулым белән баш капкачын тоттым. Җайлы-җайсыз егылуымның беренче нәтиҗәсе иде бу.

Камилә ярдәмгә ашыкты. Инде йөзенә борчылу һәм минем өчен ут йоту төсе чыккан.

— Юләр, ышанмаган буласың тагын. Әйттем бит, зәхмәте тия, дип. Төкер җиргә!

Мин егылган урынга ул бер-бер артлы такмаклап төкеренде дә кабатларга кушты:

— Тфү-тфү, бетсен-китсен, җиргә иңсен! Миннән үтсен, шунда бетсен! Тфү-тфү...

Бу такмак үземә дә кызык кебек тоелды. Өч кат кабатлап төкерендем, җитмәсә уң аягым белән шул җиргә тибеп-тибеп тә куйдым. Гүя саулык-сәламәтлегем шушыңа гына бәйләнгән, гүя гади генә бу такмак бәладән коткара инде! Әмма дөрес булып чыкты. Күңелем урынына утырды. Әле яңа гына авыртып алган баш капкачым сихәтлек тапты.

Мин инде бернәрсәдән дә курыкмый торган затка әверелдем сыман: сихерче кызының серен белдем бит!

## IV

Айдар белән Гамил менеп йөгергән җирләреннән кабат әйләнеп килеп, койма артына кача-поса почмактан безне күзәткәндә, мин инде Камилә белән уртак телгә килеп беткән идем. Аның әллә нинди диюләр хакында сөйләүләре, зәхмәтләрнең ак һәм карасы барлыгы турында белдерүләре кызык та, серле дә иде. Һай дөньялар, белми генә йөрибез икән!

Ышанмый торгансыздыр инде? Йә, ярар, анысы — сезнең эш. Әмма минеке — сөйләп бирү!

Кайсыннан башлыйм икән? Ә-ә, ничек бар, ни рәвешле булган, шулай!..

Камилә әйтә, зәхмәт, ди, диюләрдән килә! Имештер, бу җир йөзенең аркы-

лысы-буена, өстеннән астына кадәр һәммә урыннарда меңләгән вә йөзләгән дию гуртлары-кавеме булып, алар кешеләргә һәрдаим зыян эшләргә генә торалар. Әмма һәр диюнең дә барча кешеләргә дә көче җитми. Әйтик, минем үземә бары тик бер диюнең генә, яки аның кавеменең генә гайрәте зыян китерә, ә бүтәннәре ни генә кылмасыннар, кулларыннан килми. Шулай да дию-пәри заты бик тә үзсүзле һәм башбаштак булу сәбәпле, ничек тә адәм баласына үз көчләрен күрсәтергә атлыгып кына торалар, ди. Шулай итеп, җир йөзендә күпме кеше яшәсә, һәммәсенә каршы бер-бер төркем диюләр гурты каһәр әзерләп йөриләр, саклык кылырга кирәк икән!

Бу кадәрле дә көтелмәгән нәрсәләр хакында ишетү мине бөтенләй дә бетереп ташлады, утырып елыйсы гына калды. Бәндәләрнең мескенлеге, коралсыз вә көчсез булулары тагын да олы кайгыларга салды, үземне түгел, башкаларны кызганып еларга әзер идем. Тик сер бирәсе килми. Сихерче икән, хәтта кызы гына саналса да, асылда бер-бер хикмәтләрне белмиме дип сорау бирергә теләдем. Әмма куркуданмы телем ябышкан, авызым бикләнгән иде.

— Нәрсә дисең?

Камиләнең авырттырып кына әйтеп куюы ярады тагын, миңа да көч керде, сүз капкасын бикләгән иреннәрнең йозаклары ватылып:

— Бер дә алардан котылу җае юкмыни? — диярга ашыктым.

— Нигә булмасын ди? Бик бар... Әни әйтә...

Сөйли генә башлаган иде, сүзеннән бүлдереп, каршысына теге куркаклар килеп басты. Гамил белән Айдар өченче берәүнен киң җилкәләре артына качып кына йодрык селкиләр. Ә теге күсәк, билләренә таянган хәлдә:

— Бар, бар, әниеңә кайтып әйт...— дип үрти бирде.

Бу кеше Җиһангир иде. Моңа тулысынча ышанычым булмаса да, кыланышы һәм катылана төшкән тавышы үзен танырга ярдәм итте. Камилә белән артыгын бәхәсләшеп тормастан, ул миңа таба борылды һәм:

— Нишләтте бу сине, сихерче кызы? — дип хәлемне белешүдән исәнләшеп күрешүен башлап җибәрде.

— Белмим... Берни дә түгел...

— Алай димә! Бик яхшы аңлыйм. Курыкма син аннан. Әгәр дә зыян ясап, зәхмәтен китерә калса, үземә генә әйт. Тиз акылга утыртырмын!

Җиһангир шул рәвешле күкрәк каккан арада Камилә, банкасын тотып, безнең яннан таю ягын карады. Иптәшләрем миңа таба борылып баскан, кызның аяк суытуын сизенми иделәр. Күреп торсам да әләкләргә теләмәдем. Ничек кинәт пәйда булса, Камилә шул рәвешле юкка да чыкты, якты көндә эреде диярсең.

Бераздан без, дүрт иптәш, болытлы салкын көннән соң кояш чыгып үсемлекләрне ничек балкытып җибәрсә, шулай иркенәеп, әлеге дә баягы каен бүрәнәләр өстендә арка җылыга идек. Үзенә бүләккә дип китергән кармакларны күргәч, Җиһангир бөтенләй дә йомшарып, куанычын яшерә алмыйча, мине мактауда булды:

— Ну шәп тә дус инде үзең, Алмаз! Бер дигәне! Әллә кайчан хыялланып йөри идем. Каян белдең! Нәкъ мин яраткан төстә бит калкавычлары да...

Үземә кыенрак булып китте. Иптәшләремнән Айдарны да аның сүзләре туй-

дыра башлаган икән, сүзгә катышырга ашыкты:

— Әйдәгез балыкка төшәбез! Бүген яхшы каба торган көн инде, әйе бит!

— Кайдан белдең?

Гамил аптырабрак аңа карады, соравын кабатлады:

— Кайдан белдең, дим!

— Әнә Камилә дә тоткан бит...

Иптәшләрем сәер күз карашларын аңа төбәгәч, мин дә ярдәмгә ашыктым:

— Тоткан... Тоткан шул!

Әллә каушадым, әллә башка сәбәптән, моңарчы күрелмәгән хәл, телем тотлыгып алды. Дусларымның сәер күз карашлары инде үземне үтәли чыктылар.

— Күрдем бит, банкысында иде,— дип акланырга ашыктым.— Кызылканатлар, берсе-берсе беләк озынлыгы!

— Бакалар, диген!

Җиһангир мыскыллы гына итеп көлгәндәй итте. Әмма аның кыланышына игътибар бирмәдем, сүзләренә генә ачуым кабарды, кире какмыйча калдыра алмадым:

— Бакалар түгел, балыклар иде!

Сүзгә катышудан читләшеп өлгергән Айдар да әйткәннәремне куәтләде. Тик Җиһангир гына йөрәккә шом йөгертте:

— Кояш авышмыйча төштем юк, егетләр! Теләсәгез нишләгез! Су анасының тозагына кабасым юк! Сихерче кызы да юктан гына йөрмәгәндер! Котыртып куйгандыр үзен...

Тукайны укыганым булганлыктан, Су анасының гына нindилеген бик яхшы күз алдыма китерә идем. Шунда укытучымның дәрес аңлатканда әйткән сүзләре исемә төште дә:

— Юк сүз, ялган,— дип кырт кистем.— Әкияткә ышандыгызмы?

Әле яңа гына үзем белән булып узган вакыйганы бөтенләй үк хәтеремнән чыгарып ташларга өлгергәнмен. Авыз оясыннан сүз кошы чыгып очуга, акылым кушланып, ник әйттем икән дигән хәсрәтем йөрәгемә ябышты, аяк бармакларымнан алып колак очына кадәр кызардым булса кирәк. Иптәшләрем тагын да исләре киткән сурәттә күзләре белән иңем-буемны үлчәделәр.

— Ярар,— дип нәтиҗә чыгарды Җиһангир.— Шәһәр малае, белеп сөйләми! Күргән нәрсәсе түгелдер. Яле, Гамил, культура-агарту эшләрен башлап җибәр. Бер кыйссаңны тәвәккәллә, сабак биреп үт шәкерткә, белемсез калмасын!

V

Җиһангир ни әйтсә, шул икән: әмер итүе булды, Гамил телгә дә килде. Беренче сүзләре авыр гына чыкса да, ике-өч җөмләдән соң ул ихластан үз иркенә безне буйсындырды. Инде мең мәртәбәләр ишетеп тә, мең дә беренчесеннән хәтта Айдар белән Җиһангир да баш тартмадылар, анысын сөйлә, монысына да туктал дип көч бирделәр, үртәп тә алгаладылар. Мин үзем хәйран идем, билләһи! Ишеткән нәрсәләрмени?

— Син “юк” дисең, ә мин әйтәм: бар! Нинди генә әле, ниндие генә.— Гамил кулларына ирек биреп, каршысында хәрәкәтләр белән хәйран зур түгәрәк ясады. Әмма Айдар сүзеннән бүлдерде:

— Албастыны сөйләмә, Албасты кирәкми әлегә! Су анасын, Су анасын, дим!

«Катнашма!» дигәндәй, Җиһангир кысылып өлгергән Айдарга төртеп алды, тегенең теле киселде. Гамил, тын алырга өлгереп, сүз айгырына көч бирде:

— Су анасымы, Су анасы шундый да мәлгунь икән ул, үзе гел дә адәм кыяфәтенә керә ала ди. Аны сихерчеләр су төбеннән чакырып чыгаралар да яшь балаларны батырып үтерергә әмер бирәләр икән. Карачкы да карачкы, Су анасы да шулай карачкы инде менә. Үзенең аяклары артка таба карап тора икән, элпәле ди. Ә күкрәкләре инде тезләренә кадәр асылынган. Менә болай! — Гамил ихласланып вә илһамланып китеп, куллары белән тубыкларына кадәр төшеп күрсәтте. Минем өчен болар яңалык булса да, Айдар катышмый кала алмады:

— Үзең тезгә кадәр, дисең, әмма җиргә кадәр асылындырып күрсәтәсең, булмаганны!

— Нәрсә, күргәнең бармы әллә?

— Күрмәстән сөйләмәс идем... Күрдем шул!

— Әбиеңә кайтып сөйлә, күргәнсең ди менә, көтеп тор!

— Үзең күрмәгәч тә, кешенекенә катышма, яме! Күптән булды ул. Төштем су буена шулай иртәнчәк. Карыйм: яр кырында берсе чәчләрен тараштырып утыра, алтын тарагы да бар иде. Кояшта ялтырый инде менә сиңа. Каттым да калдым.

— Сөйләп утырма юкны! Әкият...

— Тыңларга ирек бир әле! — Җиһангир шунда Айдарның касыгына ару гына төртеп куйды.

— Нәрсә һаман мине каезлыйсың? Әнә Гамилгә төрт, ул алдалап утыра бит! — Айдар канәгать түгел иде. Әмма аның шунда тынып калуы Гамилнең телен чишеп җибәрде. Инде хикәясе ахырына кадәр сүз дилбегәсен үз кулыннан ычкындырмады. Мең дә беренче тапкыр тыңлап та ышанып җитмәгән, әллә ышанудан узган Айдарның күзләре барыбызныкыннан да яктырак ялтырый иде. Юкка батыр кебек кылана ахыры ул, курка торгандыр әле! Шуның өчен Гамилгә каршы төшәдер, сөйләтмәскә маташтыра, серен бирмәскә тырышадыр!

— Ә беләсезме, Су анасын тотып була икән! Әти сөйләде! — Җиһангир да, Айдар да Гамилдән мондый сүзне беренче ишетүләре иде булса кирәк, көтмәгәндә авызлары ачылып, иреннәре салынып төште.

— Булмас ла, кит аннан!

— Кая китим!

Җиһангирның Гамилгә сөйләр өчен куәт бирүе, берсе икенчесен аңламаган кебек кылanулары көлке дә, җайсыз да иде. Мин дә сорау ташларга кирәк таптым:

— Ничек тоталар?

— Нәрсә, берегезнең дә ишеткәне юк идемени? — Гамил һаваланып китте. Менә хәзер: «Нәрсә бирәсез, сөйлим!» — дип шарт куйса, барыбызны да ыштансыз калдыра инде.

Юк, Гамил алай эшләмәде. Үртәп торуны кирәк санамыйча, белгәнен җәеп салырга ашыкты. Ул сөйләде, аның саен Айдарның күзләре тынычлыгын югалтты, Җиһангир исә, батыраеп, беләкләрендәге мускулларын тоткалап-тот-

калап алды. Әгәр дә менә шунда Су анасы күренсә, ул аны тотып алачак һәм харап итеп ташлаячак иде. Әмма җае гына килмәде.

— Әти сөйләгәннән генә, малайлар, әти сөйләгәннән генә,— дип аклангалап алды Гамил.— Сере бар икән аның, белеп эшләсәң, борчаны да дагаларга мөмкин ди. Шулай бервакыт, элекке вакытларда инде, борынгы заманнарда бер иргә Су анасы каршы чыккан да, тегене батырырга маташа ди бу. Юк ла инде. Ул кеше көтүче булган, имештер. Әллә баймы? Ярар, кем генә дә түгел, бер ир, бик белә торган кеше икән, бисмилласын әйтеп, эләктереп алган ди Су анасын. Ә-ә, теге качарга маташа икән. Әмма күкрәкләре алга салынып төшкәч, йөгерергә комачаулаган үзенә. Әгәр дә шунда аларны аркасына ташлап өлгергән булса, ат белән дә куып тоту мөмкин түгел ди. Ә бу абзый Су анасын чәчләреннән эләктереп тә алган, кыйный да башлаган. Әгәр дә чыбыркы яки камчы белән суксаң, ул зурая-үсә генә икән. Белеп кыйнаган бу. Чалбар каешын салып алган да берне суга икән, икене, өчне. Су анасы үкереп җыларга тотынган: «Җибәр мине, әгәр дә үз иркемә куйсаң, үзеңә дә, балаларыңа да, нәселеңә дә зыян китермәм, мәңге якын килмәм!» — дип әйтә икән. Ә ир юләр түгел ди. Нигә җибәрсен әле ул аны? Бер тоткач ычкындырсаң, тагын кайчан очрый әле сиңа?

— Шулай итеп, каеш белән суккалаган да ике чәч бөртеген өзеп алган. Су анасы тагын да хәтәррәк җылый башлаган. Үтенә икән бу: «Алма, бир миңа, алар сиңа бер дә бәхет китермәс, тынычлык та бирмәс!» — ди икән. Ә теге ир тыңламаган. Белә икән: әгәр дә ике чәч бөртеген алып калмасаң, Су анасы биргән сүзен оныта да бүтәннәргә зыян эшләвен, су кергәндә батырып үтерүләрен дәвам итә ди. Шуңа күрә басмадан барганда аска карарга ярамый. Күзләреңне күрсә, Су анасы үрелә дә тартып төшерә икән. Башың әйләнсә дә түзәргә, басманың аргы башына карарга кирәк.

— Теге ир ике бөртек чәчен өенә алып кайткан. Әмма Су анасы да артыннан килгән. Ничек тә алдаларга-ялганларга уйлый үзе. Ике чәч бөртеген кире аласы бар бит. Әмма ир бирешми, үтенүләре-ялынуларына колак та салмый. Су анасы кайта бирә ияреп.

— Коръән эченә салып куярга кирәк икән ул, аның чәчләрен, дигәнем. Йортта, һәммә кешедә Коръән булу шуның өчен дә бик кирәк бит. Изге китап, тынычлык саклап, Аллаһы тәгаләнең барлыгын хәтта җен-шайтан ишеләргә дә белдереп тора. Коръән булган йортка алар керә алмый, керсәләр дә зыян ясарга көчләре җитми ди. Ул-бу кыла калсалар, суга икән ул аларга. «Әгузебилләһи!» сүзен әйтүгә, җеннәр ничек янып юкка чыксалар, Коръәнне күрүгә — шулай хәлсезләнәләр икән.

— Шуннан бу кеше теге Су анасының чәчләрен, өенә алып кайтып, Коръән эченә салып куйган, һичкемгә кагылырга кушмаган. Су анасы нишләсен, адәм сурәтенә кергән дә, боларга хезмәтче булып ялланган. Бер көн яши бу аларда, ике көн, өч, дүрт... Бер ай, аннан бер ел үтеп киткән. Бик тырыш икән үзе. Хуҗаның ышанычын яулау өчен нинди генә авыр хезмәтләрне дә башкара ди. Тирес түгәргә кушса, аны да эшли, җир сөрдерсә, сука да тартып йөри бу. Әмма ирне алдый алмый. Ике чәч бөртеген урлап кына качар иде, Коръәнгә якын килергә курка. Үрелә калса, кулы пешә, йөзе карала. Шулай да түзә, җай эзли. Ба-

лаларын карый, хатыны тирәсендә бөтерелә. Уе гына барып чыкмый.

— Көннәрдән бер көнне китәләр бит хуҗалар ашка. Өйдә аның яшь баласы белән карт инәсе генә кала. Су анасы да шунда. Бер ел элек тормышлары ярлы, ярым-йорты булган икән, әмма Су анасының тырыш хезмәте аркасында бар эшләре дә алга киткән. Баеп беткәннәр. Ә бай кешеләрдә бер дә иман юк инде ул. Оныталар, хәсрәтләре калмый.

— Хуҗалар ашка киткәндә дәү әниләренә теге чәчләр хакында белдереп калдырырга онытканнар. Карт кешенең дә хәтер юк инде. Ә яшь балалары берни белми. Уйнап тик йөри. Әти-әнисе янда булмагач, бөтенләй дә тузына бу. Йортны бетереп йөгерә. Шунда теге Су анасы эләктереп ала моны. Әйттем бит, Су аналары кеше кыяфәтенә керәләр дип. Бу да шулай үз кыяфәтен югалтып, адәм рәвешле икән. Матур ди әле җитмәсә, юмарт һәм миһербанлы булып кылана ди. Һич тә аны Су анасы дип әйтерлек түгел ди:

— Менә сиңа баллы прәннек! — Бу сүзләрен ишетүгә, малай уенынннан туктаган, кызыккан, телләрен ялап алган.

— Бир! — дип сорый бу.

— Ярар,— ди Су анасы.— Син элек миңа әнә теге китап эченнән ике чәч бөртеген алып, учыма сал, аннан соң бирермен!

— Теге ахмак малай тиз арада, аның кушканын үтәп, ала да бирә. Ул да түгел, Су анасы прәннек сузган кебек кыландырып, моны тотып, кайнап утырган казанга ташлый да юкка чыга, белдегезме?

Гамил шулай сүзен тәмамлый, без ул ахмак малайны кызганып утыра бирәбез. Сизеп торам, Айдар авыз ачарга да куркып калтырана, Җиһангирның да кикриге шиңгән.

## VI

— Була бит шундый ахмаклар!

— Нинди?

— Теге кешенең малае төсле!

Җиһангирның шушы нәтиҗәсеннән соң Гамил тагын дәвам итә, бу юлы сүзләре дәртләндерми, акылга сугып, күңелләрне генә суыта.

— Китә боларның дөньясы кирегә. Җыйган байлыклары җилгә оча, йортлары тәрәүгә кала. Бәлаләренең очы-кырые күренми...

— Бара бу ир тагын Су анасын эзләп, яр буйларын да йөри, күлләрне карый, чишмәләрне. Ник берсе күренсен. Ә бит ермакта да, су җыелган урында да, күлләр-елгаларда да Су аналары була икән. Әле аларның аталары да бар ди...

— Ничек кенә тырышмасын, кабат тота алмый шул. Очрамый Су анасы моңа. Елан мөгезе тапкан кебек ди ул. Әгәр дә кулыңа керсә, югалтырга ярамаган төсле, Су анасын да ычкындырмавың мәслихәт. Әгәр дә булдыра алмыйсың икән, нигә тырышырга!..

— Малайлар! — Җиһангир көтмәгәндә сикереп торды.— Киттек!

— Кайда?

— Су буена! Балык тоткан булып кыландырабыз! Берәрсен күрү мөмкинлеге килеп чыкмасмы? Әгәр дә шулай бар дип сөйлиләр икән, нигә бәхетне сынап карамаска!

— Кулдан килерме соң? Тотып ашасалар?

— Син, Айдар, һаман шулай куркак килеш йөрерсең микән инде? Ни булмаска мин чалбар каешымны ычкындырып куям. Бүтән нәрсә белән суктырырга ярамый дисең бит, Гамил!

Җиһангир тәвәккәлләгәч, без дә, батыраеп, артыннан иярдек. Әмма таллыкка килеп җиткәч, кармак сабы сындырыр өчен ешлык арасына керергә дә курсыбрак тордык. Бу юлы да Җиһангир булышты. Кычыткан төпләреннән чокып селәүчән җыйдык, Айдар исә берничә чикерткә дә тотты. Шуннан соң гына яр кырыена килеп бастык. Мин суга карамаска тырыштым: чыннан да, Су анасы күзләремне күреп алса, тартып төшерсә, көт Җиһангирның кайчан ярдәмгә килеп җитешкәнен, бөтенләй дә ташлап качмаса әле!

Ни хикмәт, балык яхшы чиртә иде. Беренче булып сөенеч Гамилне сайлады. Ул уртакул зурлыкта чабак тартып чыгаруга, минем дә калкавыч тынычлыгын югалтты. Менә-менә төшеп китә инде дип йөрәгем купты. Елга балыгын тотканда ашыкмаска кирәк икәнлеген белгәнлегем сәбәпле, калкавыч артыннан ияреп үк йөри идем. Бер чумып алды, ике, өч! Булды бу. Тартып чыгаруыма, Айдар аваз салды:

— Алмазга да капты! Кызылканат! Беләк юанлыгы бар!

Ул дөрес үлчәде. Чыннан да, миңа эләккән балык симез һәм олы иде. Аны кая куярга да белми аптырагач, Гамил киңәш бирергә өлгерде:

— Минеке янына ташлап тор, мин хәзер чиләк алып киләм!

Ерак барып йөрмәде. Бездән читтәрәк кенә мышный-мышный үләнен чәйнәштереп яткан бозау янындагы сулы чиләкне китерде:

— Әйдә, шушында гына тутыр!

— Хуҗасы нәрсә әйтер?

— Берни дә... Безнеке ул!

— Ә-ә, алай икән!

Гамил кармагын суга ташлаганда, Айдар тагын аваз бирде:

— Чиртә, чиртә, малайлар!

Җиһангирга аның болай кабалануы ошамады:

— Куркытасың бит, бөтен балыкларны качырып бетерәсең! Тавышланма!

Аңлашыла: үзенеке чиртми, шуңа ачуы килә монын!..

Яр буенда шактый озак әвәләндек. Мөгаен йолдызчылар телендә бу көн балык көне булып, малай-шалайга бәхет вә сөенеч килә торган сәгатьтер? Шулай шул, каникуллар, һичкая ашыгасы, һичнәрсә хакында кайгырасы түгел. Хәтта Су аналары турында да онытканбыз бит.

Көн кичкә авышып, иртәннән бирле юньле-башлы ашамаганлыгым да хәтеремә килгәч, ашказанында бүреләр улаганлыктан, балык тотуның кызыгы бетте. Инде хәзер юньләп чиртми дә иде булса кирәк.

Кайтырга кирәк. Кара бу өс-башны, тәмам пычранып, кызыл балчыкка буялып беткән. Шушы килеш кайтып керсәм, әбием нәрсә әйтәчәк?

Арада балыкны иң күп каптыручы Җиһангир иде. Әмма чиләкне миңа тоттырдылар.

— Алмаз, болар барысы да синеке! Кармаклар алып кайтканың өчен бездән рәхмәт билгесе булсын!

Иптәшләремнең болай юмартлануыннан башым җиденче күккә тиде. Әүвәле киреләнеп маташсам да, һай-ваема карамастан, Җиһангир:

— Шатландыр әле барысын да, әбиең дә сөенер! — дигәч, күнми калмадым.

Минем бер чиләк балык күтәреп кайтуымны күргәч, өйдәгеләр һәммәсе дә шаклар катты.

VII

Ул көнне, тәмам арыган булуым сәбәпле, кичтән үк ятып йокланылган. Иртән уянганда, кояш шактый югары үрмәләгән, иптәшләрем көтеп зарыкканнар иде. Аларның эти-әниләре һәммәсе эшкә китеп барганнар, җил сугарып йөрмәсеннәр өчен дөнья кадәр йомыш кушып калдырганнар. Шунлыктан, очрашып хәлләр белешкәннән соң, һәркайсыбыз үз юлы белән китте, мин исә капка төбендә калдым. Әүвәл аякларны болгап утырудан ямь таптым. Кызык та, рәхәт тә иде. Болай нишләргә белмичә ары-бире сугылып йөрүемне күреп, әбием чәйгә чакырды:

— Кер, улым, кер! Баллап-майлап сугарырмын үзеңне,— дигәч, тук карынымда бераз буш урын тапкандай, өстәл янына килдем. Урамнан кергән гадәтем белән аяк селкеп утыруда булдым. Шулай җайлы да, рәхәт тә иде.

— Улым, шайтан чакырып утырма! — диде әбием.

Бер әйтүеннән генә колакка кермәгән. Тагын-тагын кабатлагач кына аякларымны җыеп маташтым. Тик юкка! Тотып торып буламы соң аларны! Болганалар да болганалар. Әбиемне дә тыңламый каласым килми. Булмый гына бит.

— Өстәл артында аяк болгап утырсаң, шайтаннар килә ди. Арбасы белән авызыңа кереп китә!

— Ничек инде?

— Менә шулай! Шайтанның бер кулында таягы бар, икенчесендә — арбасы. Аны гел тартып йөри ул. «Шайтан таягы» дигән сүзне ишеткәнең бармы?

— Бар, әбием, су буенда үсә торган каклавыч, энәле үсемлек. Таягы да бар... Очында — кызыл чәчәге, хәтта анысы да энәле!

— Менә-менә, шайтан таягы да шундый инде ул. Кемнәр тәртипсез, шайтан шуларны гына карап йөри. Таягы белән башларына суга да арбасына салып китә, дузах дип аталган бер чокырга илтеп ташлый, утлы җәһәннәм чокыры инде ул, Аллаһ сакласын!

— Ә ул чокыр кайда була?

— Ни сорыйсың син, улым? — дип әбием аптырап миңа карады, аның ак йөзенә борчылу йөгерде, яшел күзләре төссезләнеп калгандай тоелды. Мин дә, оялып, башымны түбән салындырдым. Гаепне шушы соравымнан күрдем. Болай наданлыгымны күрсәтә торсам, әбием дә, беркем дә яратмас!

Әмма ялгышканмын. Әбием бөтенләй башка нәрсәләр хакында уйланган икән, шунлыктан кәефе киткәндәй тоелган. Ул минем чәчләремнән сыйпады, тыныч кына аңлатып алды:

— Ул чокыр шундый бер урын ул, улым, анда кәфер-динсезләрне генә кертәләр, тәртипле вә тәүфыйклыларга анда ишек бикле. Әгәр дә сүз тыңлаучан, яхшы бала булып үссәң, беркайчан да аны күрмәссең, җәннәтле ителерсең...

“Нәрсә соң ул җәннәт?”— дип сорарга батырчылыгым җитмәде, әмма әби-

ем наданлыгыма алдан ук инанып куйган икән. Үзе үк дәвам итте:

— Ә җәннәт дигәннәре шундый бакча аның, улым, анда барча матурлыклар вә рәхәтлекләр генә. Теләсәң ашарга, әйтик, җимештән, кулыңны да сузарга өлгермәссең, агачлар үзләре иелеп, җимешләре белән сыйларлар. Әгәр дә жаның су теләсә, чишмәләр үзләре йөгереп киләләр. Анда дүрт арык бар, аның берсеннән татлы сулысы ага, икенчесеннән сөт ага, өченчесеннән ширбәт кебеге, дүртенчесеннән безнең Зәмзәм коесының суы кебек елга ага. Шушы дүрт чишмәнең берсенең генә суын эчсәң дә һәртөрле кайгы-хәсрәтләрдән азат кылынасың, дошманнарыңнан өстен чыгасың, барча авыруларыңнан савыгасың, улым!

— Әбием, ә ул Зәмзәм коесы кайсы төштә? Моннан ерак түгелме? Безнең Зәмзәм коебыз бармыни?

— Бар, улым, бик бар! Бигрәкләр дә тәүфыйклы бала инде үзең! Безнең Зәмзәм коебыз моннан бик еракта, Мәккә шәһәрендә. Анда гомеренә бер тапкыр, әгәр байлыгы җитсә, һәркемгә барып, хаҗ кылу тиешле.

Мин инде олы мәгънәләргә төшенгән кеше шикелле белдекле кыяфәт чыгарып баш селкедем. Дөресен генә әйткәндә, һичнәрсә аңламадым. Болай еш колакка кереп тә, алар хакында сөйләнгәннәрне игътибарсыз калдыруым сәбәпле, миндә наданлык көчле иде. Әбием хәбәрләрен күңелемә киртләп, Мәккәне олуг бер җәннәт урыны дип күз алдына китердем. Аның тирә-юне гөлбакчалар икән дә, уртасында зур гына бер коесы булып, байлар шунда чиләк ташлыйлар һәм тутырып алалар, корсакларына суккалый-суккалый, мактанышып эчәләр: «Без сихәтләндек, без бәхетлеләр!»— дип сикерешәләр, мең бәлаләрдән котылалар кебек тоелды. Шулай итеп, минем каршыда дөнья әллә нинди аклы-күгелҗемяшел төсләргә кереп бетте. Әгәр дә берәрсе шайтан хакында телгә алса, шунда ук мин кулына чәнечкеле, башында кызыл чәчәкле таяк тоткан, икенче кулына арба таккан һәм аңа исерек, яманнарны тутырып, сөйрәп йөрүче бөкре бер картны уйлап куям. Имештер, ул аяк болгаучыларны карап кына йөри, күрә калса, авызына кереп, тагын да нindидер хикмәт белән аннан чыгып, арбасында җәһәннәмгә илтеп аудара.

## VIII

Әгәр дә мин иптәшләремнең болай көне-төне эш белән генә мәшгуль булып, урамга чыгып та тормаслыкларын алдан ук белсәм, бәлки авылга кайту түгел, борылып та карамаган булыр идем. Анда сеңлем белән әткәй-әнкәй Кара диңгез буенда, иң кимендә берәр комлы елга ярында сырт кыздыралардыр, дөнья рәхәтләрен гизәләрдер инде? Ә мин монда көннәр буена каңгырып, үземә нинди эш табарга белмичә аптырап йөрим. Булдыра алмасмын дип куркалардыр, бер генә йомыш та кушмыйлар. Кирәгем юк монда. Балыкка да ялгызым төшәргә шикләндерә. Әллә нинди Су аналары хакында сөйләп башымны әйләндерделәр дә, хәзер үзләре дә: Айдар, Гамил, Җиһангир — мич арасында качып ята торганнардыр? Булыр, булыр. Юри батыр кебек кыланалар ул авыл малайлары, ә үзләре Камиләдән дә куркалар. Теге көнне ташлап ук качтылар бит әле, табан аслары гына ялтырап калды...

Мин үземнең дусларыма үпкәлим дә, ачуланам да. Әмма һич файда юк. Гомерләре чөгендер басуында үтә, беләм. Кичкә арып кайталар да йоклыйлардыр

инде болар. Шәпләп яңгыры да явып китми бит аның, кырга чыга алмаслык итеп. Юк, ул гына туктата алмас аларны. Әнә юньле кешеләр җиләккә дә йөри башладылар инде. Бергә-бергә барыр идек. Әллә кайчан кайтып, урманнарын да бер менеп күргән юк. Кем белән йөрим ди мин, ялгыз башыма андый юлга чыгу ярыймы соң?

Башыма килгән уйны төшереп калдырмаска теләп, үзем белән тизрәк өйгә алып йөгердем. Гадәтенчә әбием, йорт эшләрен карап маташа иде. Аның итәгенә диярлек килеп ябыштым, тыңламаса, теңкәсен корытырга булдым:

— Әбкәм, әбекәем, алып бар мине урманга! Җиләк ашыйсым килә... Әби, дим, әбекәем...

— Абау, нинди песи баласы бу?

Юк инде, андый гына ялган үртәүләренә бирешеп тордым түгел. Белмиммени мин, аңламыйммы? Бала-чага хисабыннан күптин-күп элгәре чыктым инде. Алып барсын мине җиләккә, и бетте китте!

Әмма әбиемне күндерү бер дә җиңел эш булып чыкмады. «Хәзер, бу эшемне бетерим дә, монысын гына калдырмыйм!..»— дия-дия җитмеш төрле кырыкмаса-кырык нәрсәләрне башкарып та, алар янына бүтәннәрен таба торды. Артыннан бер адым да калмасам-калмадым, мин дә үземнекен тукый тордым. Барыбер файдасы тимәде. Ул әле җим болгатып тавыкларга бирде, каз бәбкәләрен ашатып кайттык, шул арада бозауга су төшерәсе, төшкелеккә абый-апага аш хәзерлисе, чәй куясы итте. Болар арасында идәннәрне сөртте. Инде генә бушады дигәндә тагын тавыкларга җим болгатты, кайтып кергән каз бәбкәләрен ашатып, кабат су буена куды, тегесе-бусы. Мин дә ияреп кенә йөрмәскә тырыштым, тизрәк эшләре бетсен дип булышырга алындым. Әмма җим болгатышканда аякларым йомшак әйбергә басу аркасында таеп китеп, сулы тагаракка артым белән утырдым, чалбарымны чайкап, кояшка эләргә кирәк булып чыкты. Ул гына кибәргә өлгергәч, бозауга ашлы чиләк төшерә киткән идем, тагын эшем кирәгенчә барып чыкмады. Ахмак бозау, башларын чайкап, өстемә ташланды. Үз-үземне белештерми, чиләкне аңа капладым да — әллүр өйгә таба. Ярый әле бәйләп куелган икән. Казыгы ныклы булып чыкты. Югыйсә маңгаена утыртып кайтып керәсе иде.

Минем уңмаганлыкны аңлап, әбием кул арасына кертергә кабат теләмәде булса кирәк. Тагын итәгенә тагылып йөрүдән башкасы калмады.

— Бүген соң бит инде, менә иртәгә барырбыз! — дип сүз биргәч кенә тынычландым. Әмма миңа инде болай да күңелле, әбиемнең куштаны булып йөрүнең үз яхшы яклары бар иде. Анда ул берәр кәнфит бирә, монда кура җиләге каптыра, тегендә берәр ашый торган үлән өзеп бирә, исемнәрен аңлата, серләр дөньясы белән таныштыра. Җайлап карасаң, кузгалагы-юасы да менә шушы болыныбызда гына үсә икән, ул кәҗә сакаллары дисеңме... Иренеңә тидерсәң, бетте инде, чабырта да чыгара, җаен белеп кенә ашарга кирәк!

## IX

Әмма бүген-иртәгә дип ышандырган әбием сүзендә тормады. Көн артыннан килгән көн үзләренә хас мәшәкатьләре белән үтә бирде. Мин инде ата каздан курыкмыйча, ояларын чыбык белән туздырып, йөгертеп кенә су буена куып тө-

шерәм, тавык-чебешләр арасында мәш киләм, тегесен-монысын эшлим, гел дә кул арасында йөрим. Ә уйныйсы килә. Ялгыз башыма балык каптыруы да күңелсез. Дөресрәге, Су анасы килеп чыгудан котларым оча. Яр кырыена килдем юк инде хәзер!

Урманга барсаң да инде, Шүрәле очрап, адаштыруы бар? Әбиемнең теңкәсен корытам. Бер-бер әкият ише нәрсә сөйләвен үтенәм. Сорап куям:

— “Шүрәле” диләр дә “Шүрәле” диләр... Күргәнең бармы, әбием? Безнең урманда юктыр ул?

— Нишләп булмасын ди?

Монысын ук көтмәгән идем. Колакларым үрә торып, тәнемә курку йөгерде. Шулай да минем өчен бу кызык иде. Сөйләтергә уйладым.

Әбиемнең әкияте «Нәкъ Казан артында...» дип башланырга тиеш иде. Миңа яхшы таныш ул. Тукай абыебыз язган бит аны, һәрбер мәктәп баласы белә. Әле бервакыт шулай әбием әллә нинди серле тавышлар белән бер көй көйләп җибәргән иде. Шунда ук ялгап киттем: «Йосыф-Зөләйха» иде ул. Җитмәсә бу әсәрне кайчан кем язганлыгын да хәбәр иткәч, әбиемнең аптырашлы күз карашларын күз алдыгызга китерсәгез иде. Хәйраннар гына калды. Бу бала үз акылындамы икән дип маңгаемнан да тотып карады, һе, әллә кем дип уйлагандыр инде ул мине... «Кыйссаи-Йосыф» поэмасын укып карамаган, дәресләрдә эчтәлеген сөйләп, сүзләрен ятлап аптырап бетмәгән берәр татар укучысы бар микән ул? Юктыр. Ә әбием шуны да уйламаган икән... Шәһәр малае дигәч тә, надан булырга тиеш микәнни ул? Беләбез, бик беләбез! Энәсеннән җебенә кадәр үк түгелдер дә, әмма...

Әбиемнең Шүрәлесе әллә нинди әкәмәт нәрсәкәй икән. Мин инде аны бүлдерергә дә уйлаган идем, онытылып кына киткәнмен. Ярый әле сабырлыгым җиткән, көлкегә каласы булганмын.

Әкиятен әбием болай башлап китте:

— Борын заманда бер синең төсле малай урманга киткән. Җиләк җыярга. Уңга барган, сулда йөргән, әмма бер дә җиләклек таба алмаган. Шулай да һаман эчкәрәк керә башлаган. Буш кул белән урман кадәрле урманнан әйләнеп кайтасы килмәгәндер инде...

Шулай итеп, бара икән бу, бара икән, бер яланга килеп чыккан. Караса, җиләклек, ди. Берсеннән-берсе кызыллар, эреләр, тәмлеләр икән. Тиз арада малай җыярга да керешкән. Угланның болай ашыгуын күргән кошлар бер-бер артлы киләләр дә:

— Моннан җиләк җыйма... Моннан җиләк җыйма... Бу болынга Шүрәле хуҗа...— дип, кат-кат әйтеп карыйлар ди, әмма углан аларның әйткәннәренә колак салмый икән.

Ул да түгел, урмандагы киек-җанварлар да килеп:

— Бу болыннан җиләк җыярга ярамый,— дип, акыл биреп карыйлар ди, әмма углан аларның сүзләренә дә колак салмаган.

Шул арада аның тырысы да тулган. Юлдан кире борылырга гына уйлаган, кайсы якка барыйм икән дип аптырашта да калган. Күзләренә кайнар яшьләр килгән. Тамагы да ачкан. Нишләргә дә белмәгән. Җиләк ашап тамак туя димени ул?

Шунда урман ешлыгыннан угланга әнисенеке төсле тавыш белән кемдер эндәшкән:

— Тырысыңны калдыр, балам, мин сиңа юлны күрсәтермен! — ди икән.

Әмма угланның тырысын калдырырга теләге юк шул... Нигә ташласын ди ул аны, көне буе йөреп, тәмлеләрен һәм кызылларын гына сайлап җыйды бит.

Тоткан да, бер сукмакны ниятләп, углан бу болыннан ераккарак китәргә уйлаган. Әмма артыннан теге тавыш тагын ишетелгән:

— Тырысыңны калдыр, балам, мин сиңа юлны күрсәтермен! — ди икән.

Углан йөгерә үк башлаган. Гүяки шушы сукмагының очы авылларына килеп чыга да — котылам дип уйлый икән бу.

Шулай шактый ара юл йөгергәч, аяклары арыган, тыны кысыла башлаган, утырып хәл алырга уйлаган. Әмма теге тавыш яңадан кабатланган. Углан тиз генә шул якка караган һәм анда тәнгә бик ябык, эре ак тешле, маңгаенда мөгезле, ишәкнеке төсле ике колаклы, әмма карап торуга адәм сурәтендәрәк бер затны күреп, күңеленә курку йөгергән.

— Син миннән курыкма,— дип әйтә икән бу зат,— һичбер явызлык кылмам. Яхшы иткәнсең, җиләгемне җыйгансың!

— Юк-к-к...— ди икән углан,— юк-к...

Әмма үзе торып йөгерергә тотынган. Ни дисә дә ул шунда Шүрәлене танып алган бит. Ә аның начар гадәтләрен дә ишетеп белә ди, кешеләрне кытыклап үтерүләрен...

— Качма, качма,— дип, артыннан йөгерә ди Шүрәле.— Мин сиңа һичбер зыян эшләмәмен, теләсә никадәрле җиләк ашатырмын, минеке бул, минем малай,— дип алдалый, ялганламакчы була икән үзе.

Углан бер аланга килеп чыккан. Янда гына чишмә челтерәп акканы ишетелә ди. Ә ул арада Шүрәле угланның каршысына ук килеп басмакчы була. Авызын тутырып елмая. Караңгы урманнан болынлыкка чыгып өлгергәненә сөенеп, углан да елмаймакчы. Әгәр дә авызы ерылса, Шүрәле аны әсир итеп алачак, үзенә буйсындырачак инде, ә угланның куркуы бетеп җитмәгән. Авызы ерылмый. Шүрәле исә җаен табып кына, үгетләп-үгетләп юатмакчы.

— И адәм улы, нинди тәүфыйклы син, нинди яхшы... Күп итеп җиләкләр дә җыйгансың... Әйдә безгә кунакка. Сине урман ризыклары белән сыйлармын, бәхеткә күмәрмен, алтын-көмештән бүләкләр бирермен,— дип әйтә икән.

Шунда угланның авызы кипкән. Йөгереп агучы чишмә аның авыр хәлдә калганлыгын күреп алган да үз янына чакыра икән:

— Ышанма син аңа, кил бире... Минем сыемнан авыз ит, тамагың сусыз улак кебек коргаксыган. Эч бер генә тамчы,— ди икән.

Углан уйлап-нитеп тормаган, чишмә янына таба чигенгән. Егылып китеп, чак кына суга мәтәлеп төшмәгән. Шулай да чишмәнең икенче ягына сикереп чыгарга өлгергән. Артыннан килгән Шүрәле аны сузылып кына тотып алмакчы да, буе җитми калган. Ә суны атлап чыга алмый икән бу. Кем-кем, әмма Шүрәле белән елан, уттан хасил кылынганнары өчен диләр, судан куркалар ди.

Углан ул арада Шүрәледән ераклаша башлаган. Мескен урман сарыгы уңга тартыла, сулга ашкына ди, әмма һичбер эш кыла алмый гаҗизләнә:

— И углан, кил бире, кил бире!—дип чакыра икән.— Мин сиңа татлы ур-

ман ризыклары бирермен! Миндә генә торырсың,— дип алдый икән. Ә исәбе ничек тә малайны тотарга, рәхәтләнеп аны кытыкларга, шулай хөкем йөртеп, рәхәтләнергә.

Әмма бу малай тинтәк түгел, Шүрәленең сүзләренә колак салып, ялганына буйсынырга уйламый ди. Тик кайвакыт күңеленә чит-ят уйлар килеп, әллә кунак төшәргәме дип тә ниятләргә теләге җайлана икән. Шулай да ышанып җитми бит. Бу явыз зат хакында ишеткәннәре бар.

— Аһ, ахмак малай, адәм улы,— дип ачуланырга да керешкән аны Шүрәле,— нинди тыңлаусыз бәндә син? Кил бире, кети-кети уйныйбыз!

— Улак ат янына килми, ат улак янына бара! Әгәр кирәгем бар икән, син бире атла! — дип үрти икән углан үзен.

— Бу чишмәнең башы кайда соң? — дип сорый икән Шүрәле.

— Әнә тегендә!— дип төртеп күрсәткән углан, чишмәнең агып киткән тарафына таба.

Ул да түгел, беркатлы Шүрәле шунда, углан күрсәткән якка таба торып та йөгергән. Көн йөгергән, төн чапкан, чишмә бер инешкә килеп кушылган, инеш исә елгага... Шунда гына Шүрәле үзенең алданганлыгын белеп алган. Кире кайтырга уйлаган, әмма инде соң булган. Шүрәле үз урманыннан чыкса, адаша ди. Бу Шүрәле дә шулай адашып, йортына кайта алмаган. Утырган да елаган...

Ә углан тыныч кына өенә киткән, Шүрәле болынлыгыннан җыйган җиләк белән рәхәтләнеп чәй эчкәннәр. Икенче көнне ул монда авылдашлары белән килгән, барысы да тырысларын тутырып җиләк чүпләгәннәр.

Ул яланны әле хәзер дә «Шүрәле болыны» дип йөртәләр. Анда җиләк бик күп була...

## X

Әкияте беткәннән соң, әбием мәгънәле итеп йөземә карап алды. Әмма минем куркуым узган, авызым ерык иде. Ялт кына сорау да ташладым:

— Ә нигә Шүрәле чишмәне сикереп кенә чыкмаган соң?

— Әйттем бит инде, Шүрәле, елан кебек үк судан курка, дидем!

— Юк, әбием, елан судан курыкмый. Минем күргәнем дә, укыганым да бар: елан сулы-сазлыклы җирләрдә яши. Ул әле суда йөзә дә ала...

— Син беләсеңдер инде, улым, син беләсеңдер...

Минем болай киреләнүем әбиемне үпкәләтте булса кирәк, ни дисәң дә, сүзен аяк астына салып таптадым бит! Юньсез дә инде үзем, ахмак та инде!

— Ә Шүрәле нигә тотып кытыкламаган соң аны, чишмәнең аргы ягына чыкканчы ук?

— Нигә дип,— әбиемнең тавышында арыганлыкмы, әллә инде кимсенүме сизелеп тора иде,— син укыган бала бит. Бөтенесен дә беләсең. Безнең вакытта әйтә иделәр: әгәр дә Шүрәлегә тешләреңне күрсәтсәң, ул сине кытыклый, әгәр дә күрсәтмәсәң, кытыклый алмый, курыкканнан курка, башта юатырга тырыша, диләр иде. Укыганың бар идеме?

— «Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк!» — дип укыганым бар. Ялган сүз болар барысы да...

— Мин алдакчы инде алай булса!

— Әйе!

Мин үземнең нәрсә әйткәнемне сизми дә калдым. Нәрсә тартып чыгарды икән ул сүзне авызымнан? Ахмаклыгымдыр инде!

Әбием миңа тәмам үпкәләде: «Кит моннан, йөрмә башымны бутап!»— дип, яныннан ук куып җибәрде. Мин барысына да үпкәләдем.

Баштарак аптырап калдым. Аннан соң сөмсерем коелып төште, ачуым кабарып, кая барганымны да белмичә, капкадан чыгып, урамга йөгердем. Нигә кайттым инде авылга? Монда миңа ни калган? Иптәш малайларым да юкка чыктылар. Әбием дә урманга минем белән җиләккә бармас өчен әллә нинди әкиятләр уйлап чыгарып сөйли. Юри ялганлыйлар барысы да. Әкият. Менә күрсәтәм әле үзегезгә, урманга берүзем барам да алып кайтам җиләкләрне. Тапканнар!..

Мин шулай бар дөньясына үпкә белдереп йөрдем-йөрдем дә урманга карап юнәлдем. «Бу малай шулай бик бәләкәй дип белдегезме әллә!» — дип, сукранасукрана килә идем, берәү эндәште:

— Нәрсә, балтаң суга төшкән кеше шикелле атлыйсың? Юлың ераккамы?

XI

Күтәрелеп карасам, сихерче кызы аякларын болгап, юл читендәге сыер кадәр зур таш өстендә утыра иде. Миңа ул эндәшкән икән. Сүз кайтарырга теләгем юклыктан күз кырыен гына аларттым да юлымны дәвам иттердем. Әмма артымнан кемнеңдер килгәнен сизеп алдым. Ялт кына әйләнеп каралым. Адымнарымны кабатлап, эзләремә үк басып-басып теге сихерче кызы килә икән. Тукталганымны сизмичә чак кына миңа килеп бәрелмәде.

— Нәрсәдән сихерлисең?

Камиләнең авызы ерылды, күзләрендә очкын ялтырап китте:

— Юлыңны сөртеп барам!

— Нәрсә?..— Ачуымны чак тыеп калдым.— Адаштырмакчы итәсеңме әллә?

— Әйе дисәм ни әйтерсең?

Сүзем юк иде. «Бәреп үтерәм!» — дип булмый бит инде! Әйтерлегем юклыктан кайнарланган ачуым чыгарга юл таба алмыйча аптырады. Ул арада ертык күңелемне Камилә ямап та куйды:

— Котың ботыңа җиттеме?

Кая ди ул, аяк бармагымнан чыгып, җиргә үк кереп качты бугай. Курыкмассың, бар, әллә нинди шайтаннар-җеннәр, су аналары, шүрәлеләр белән тулган авыл бит бу! Сихерчеләренә кадәр артыңнан ияреп йөри. Качып калыр җир дә тапмассың.

Шулай аптыраштa торганымны күреп, Камиләнең авызы тагын да ерылды:

— Әйдә, нигә тукталдың әле? Урманга барабыз түгелме соң?

— Барабыз түгел, барам!

Болай үчекләвеннән күңелемнең икенче бер почмагы үртәлеп, әүвәлге уйларымны оныттым да җәһәт кенә үз юлым белән атлап киттем. Артымнан әлбәттә Камилә иярергә тиеш иде.

Сукмагым олы юлдан борылып, калкулыклар аша текә таулыкка таба юнәлде. Яшел бүз үлән араларыннан вакыт-вакыт һәртөрле бөҗәкләр күренгәләп, кызгылт-сары булып каткан сукмакта тукталып, миңа күтәрелеп-күтәрелеп ка-

рыйлар төсле иде.

— Бу углан кая бара икән?..

Алдыма күтәрелеп карадым. Юл читендәге агач төбендә авызын ерып Камилә утыра иде. Кайчан монда килеп җиткән ул?

Мин туктап калдым.

XII

Бәлки кирәкмәгән дә булгандыр? Һәр сөйләгән сүзенә көлеп кенә караган вакытларымда күңелем тынычрак иде, ә хәзер ышанырга да, ышанмаска да белмим. Яки дөрес, чыннан да шулай булган, әллә инде ялган белән башымны катыра? Кем белсен!

— Безнең якларда борынгы заманнарда олы-олы гәүдәле Алыплар яшәгәннәр. Менә бу таулар, калкулыклар, таш-кыялар — һәммәсе дә аларның аяк эзләре, чабата каккан балчыклары. Күз алдыңа китерә аласыңмы?

Мин эндәшмим. Камилә сүзен дәвам итә, әллә нинди баһадирлар хакында сөйли, аның саен ныграк ышана һәм дөньяның серләренә төшенә баргандай хис итәм үземне.

— Бу тау — Бакыр батырның ятып калган җире. Әнә кара әле болайрак, күрәсеңме? Монысы — аның борыны, анда — кулы, аяклары...

— Чыннан да шулай!— дип килешергә ашыгам.— Монысы — башы, болайга таба сузылганы — буе, кулындагы калканы...

— Әүвәл заманнарда Бакыр батыр гаиләдә иң өлкән бала булып, иң көчле егет булып үсеп җитлеккән. Аның унике сеңлесе бар икән. Әнә теге тауның исемен беләсеңме? Уникеле тау дип атала ул!

Көннәрнең берендә Бакыр батыр сунарчылык эше белән чыгып киткән. Бу якларга үзенең Алпамша атына атланган Кузы батыр килеп чыккан. Ул, дөньяларны гизеп, галәмнәрнең серләренә төшенергә ниятләнгән икән. Әмма менә шушы урынга килергә булган. Кичен монда җитешкән. Атыннан иярләрен салдырып та тормастан, мондагы киң яланга ятып йоклаган. Күрәсеңме әнә ул түбәнлекне, кеше кыяфәтендәме?.. Әйе, әйе!.. Бу — Кузы батырның йоклаган җире. Гәүдәсе авырлыгыннан изелеп калган...

Шулай итеп, Кузы батыр йоклап киткән. Ул кичне Бакыр батыр сунарчылыктан кайтып җитешмәгән. Юл адашмасын дип сеңелләре зур итеп учак якканнар һәм моңланышып җырлый башлаганнар. Аларның сагышлары шулкадәр дә тирән булган ки, яткан җиреннән Кузы батыр аларның җырларын ишеткән һәм, йокысыннан айнып, күзләрен ачкан. Качып кына килгән. Кызларны күреп алган.

Арада иң кечкенәләре бар икән. Исеме Гөлбоек булган. Аның чибәрлеген каләм белән язып, сүз белән сөйләп бетерерлек түгел ди. Кузы батыр шушы сеңелне күргән дә, шунда ук гашыйк та булган. Күкрәгенә кадалган сөю угыннан хәтта күзләре төбеннән кайнар яшьләре дә бәреп чыккан. Егет үзен-үзе оныткан, хәтта йокысыз да калган.

Ул да түгел, урман ягыннан баһадир Бакыр батырның аваз салган тавышы ишетелгән:

— Миннән сезләргә сәлам ирешсен! Кайтып җитәм, сеңелләрем!— дип әйтә

икән ул.

— Бездән сиңа сәлам ирешсен, иң сөекле абзабыз! Илебезгә бүре төште, ни уйдадыр, белмибез! — дип җаваплаганнар батырның сеңелләре.

Кузы батыр үзенең мондалыгын сеңелләр белеп алганлыгын төшенгән һәм югалып калган. Хәзер, торып, Алпамшасына атланып качар иде дә, Гөлбоекка төшкән мәхәббәте аны монда гүяки бәйләп куйган шикелле иткән. Батыр ике ут арасында калган. Шулай да арадан ул ике утның берсен сайлап, тәвәккәлләргә уйлаган.

Менә Бакыр батыр белән Кузы баһадир йөзгә-йөз очрашканнар.

— Син минем илемә ни өчен кердең? — дигән Бакыр батыр, усалланып һәм ачу белән: — Кем сиңа рөхсәт бирде?

Сүзнең болай башланып китәсен алдан ук белгән Кузы баһадир, башын түбән иеп, үзенең сәламнәрен җиткергән һәм үтенеч белән җавап биргән:

— И бөекләрнең бөеге, батырларның батыры Бакыр баһадир! Мин дөнья гизеп, гыйлем эзләп йөрүче бер егет буламын. Белмәдем, ялгышып кергәнмен. Арып йокыга талганмын... Төн белән уянып киттем, синең сеңелләреңнең җырлаганын ишеттем. Арада берсе, күркәм йөзле, матур тавышлы Гөлбоекка күңелем төште! Син ага да, син ата да булсаң, бир аны миңа кияүгә? — дип тезләнгән Кузы баһадир.

Әмма Бакыр батырның моңа бик ачуы килгән һәм әйткән:

— Аһ, юньсезләрнең юньсезе, ахмакларның ахмагы! Гаиләдән олы кызлар китеп бетмичә, сеңелләре кияүгә чыгармы? Югал күз алдымнан!

Әмма Кузы баһадир китәргә бер дә уйламаган: «Әгәр дә миңа бирмәсәң, ул вакытта мин аны урлап алам!» — дигән.

Шунда алар кылычка тотынганнар һәм сугыша башлаганнар. Бакыр баһадир көчле булган. Бер селтәнеп суккан, Кузы батырның сул кулын өзеп алган. Әнә теге «Оча баш» дип аталган кызыл очлы яр читен күрәсеңме, ничек күтәрелеп тора, кул башы сыман! Ул менә шул Кузы баһадирның өзелеп калган сул кулы инде.

Моңа йөрәге әрнесә дә, Кузы батыр бирешергә уйламаган. Ярасына күз дә салмыйча, Бакыр баһадирга кылычын күтәргән, аның тездән югары җиренә, куәтле ботына чапкан. Җавабында Бакыр батыр сул кулы белән Кузының йөзенә суккан, ул чалышаеп киткән.

Көн сугышканнар, төн сугышканнар, ярасыз җирләре калмаган. Ахырда икесенең дә көче беткән. Шулай да хәл җыярга уйламаганнар. Аларның сугышканнарын кызлар ерактан күзәтеп торган, апалары исә Гөлбоекны ачуланганнар. Шунда ул чын йөрәктән әрнеп:

— И апаларым, егет күзе миңа төшкәннән ни гаебем бар! Болай чибәр булып туганчы, аккош кына булсамчы!—дигән.

Ул шулай дип әйткән, көтелмәгән хәл килеп чыккан. Нәкъ шул вакытта күктән Сәмруг кошы очып бара икән. Гөлбоекның сүзен ишеткән һәм аны аккошка әверелдергән. Апалары шаклар катканнар. Шунда Гөлбоек түзмәгән:

—Мин аккош булгач, сез каргалар булыгыз!— дигән.

Апалары шунда ук каркылдый башлаганнар һәм каргаларга әверелгәннәр!

Менә ни өчен каргалар тау башына җыелалар һәм сугышкан баһадирларны

карап торалар, белдеңме?

Мин: «Әйе!» — дияргә тиеш идем. Чыннан да, Камилә күрсәткән калкулык башында берничә карга очынып-кунып, нәрсәгәдер куанып каркылдыйлар. Әллә, чыннан да, дөрес инде дигән уй акыл биштәрендә урын таба алмыйча кайнашты.

— Күрәм, ышанмыйсың да үзең?

Камиләнең күз карашыннан артка чигенергә мәҗбүр ителдем. Хәзер берәр сүз белән мине кешелектән чыгарып ташлый инде бу?

Юк, Камилә алай эшләмәде, авызын гына ерды:

— Курыкма, мин сине ашамыйм, сихерче кызы дигәч тә...

XIII

Сихерчеләр адәм ите ашый икән дигәннәрен генә ишеткәләгәнем бар иде. Камиләнең сүзе җитә калды. Хәзер отыры чабып, авылыбызга таба шылачакмын инде.

Тартылдым, туктап калдым. Шушы гына җитмәгән иде: куркып кач, имеш! Соңыннан бөтен авылга таратыр, көт тә тор!

Шулай итеп шул: язмышымны сынарга булдым. Камилә янында куркак куян төсле калтыранган хәлемдә торып калдым. Менә хәзер ул еланга әверелер дә, ысылдый башлап, мине йотар инде...

Җылы ягымлы кояш болын-кырларны сыйпап күтәрелә бирде. Кайдадыр еракта дөнья гөжелдәп тора иде. Ә-ә, әнә ул, моннан, калкулыктан яхшы күренә, олы юл! Машиналар уңга-сулга йөгерешеп, кайларгадыр ашыгалар, кемнәрнедер алып китәләр, кайсыларын кабат илләренә кайтаралар.

Шулай дөньялыкка ихлас күзләремне салып торганда, бәрән һәм сарыкларның бәэлдәшкән тавышларыннан айнып киттем. Көтү йөри икән. Минем кебек бер малай озын чыбыркысын җилкә аша гына урап болгады да гөлтләтеп утларын чыгарды. Шартлаган тавышы бер калкулыкның маңгаеннан икенчесенә барып бәрелде, таулар йөткереп куйгандай булдылар. Камилә күрсәткән теге калкулыктан бер төркем каргалар күтәрелеп, чебеннәр төсле азыш-тузыш килделәр дә кабат утырыштылар.

Минем нинди уйлар кичерүемә игътибар да итмәстән, тормыш үз җае белән дәвам итә иде. Мөгаен шуны тою һәртөрле уйлардан азат итеп, Камиләгә: «Шаяртасың бит!» — дигәндәй, елмаеп каратты. Аның үзе дә, экияте дә ничектер көлке, ялган бернәрсә булып калды. Җай-җай гына исеп куйган җиләс җил, җәйге туфрак җылысы, хуш исле татлы һава, иртәнге чыклар белән юынганнан соң чистарынып-кипшеренеп калган үлән вә чәчәкләр — болар барсы да җәннәт хәбәреннән иделәр. Әгәр дә шушы көндә туфракка бер таяк тыгып, аны онытып калдырсаң, иртәгә ул, һичшиксез, яфрак ярган, берсекөнгә чәчәк аткан, бер атнадан җимешләнгән булыр иде.

Мин үзем нәкъ шул таяк сыйфатындагы хәлдәдер инде? Күңелдән юк-бар уйлар качып, гомеремдә беренче тапкыр үзгә бер кайнарлыкның тән буйлап йөгергәнен тойдым. Камиләнең шомырт кара күзләре, эре бөдрәләр белән җилдә тузынган чәчләре, кечтеки борыны, гел елмаеп тору өчен генә ярatылган бит очлары мин, шәһәр малаен, сихерләде. Әйе, әйе, сихерләде! Моның нәрсә икән-

леген аңламаган хәлдә җиңеләеп киттем. Хәзер минем йөрәктәге ят хис тойгысыннан шыта башлаган яшәеш чиясенең төше ярылып китеп, борын төртәчәк һәм ул арада, үрелеп-үрелеп, колаклардан яфраклары үсеп чыгачак та телемнән татлы җимешләре сүз булып коелачак иде. Юк, ул вакытта мин, болай ук уйлый алмый идем бугай? Әмма хәзер яхшы беләм: бу — мәхәббәт белән тәүге тапкыр очрашуым булган! Кешелеккә, дөньяга, яшәешкә мәхәббәт белән очрашуым. Нинди матурлыкларны тоярга өйрәткән ул мине!

Көннәрнең берендә моны һәркайсыбыз татыйдыр инде? Кемнәр туган туфракларыннан аерылгач, кемнәр якын кешеләрен югалткач һәм... Ә мин аның белән авылда очраштым. Моңа Камилә этәргеч ясады, һай, сихерче кызы!

Мин, чыннан да, сихерләнгән идем.

Хәзер Камиләнең әкиятләреннән мәгънә югалды. Ул сүз арканын иште дә иште, ә мин колак та салмадым. Теге баһадирлар белән вакыйгалар ничекләр генә булып беткәндер, белмим. Әмма шунысын яхшы аңлап калдым: мондагы һәр тау вә калкулык, агач вә куаклык, ермак һәм чишмә-сазлыкларның, тагын әллә нинди генә нәрсәләрнең үз исемнәре, серле гыйбрәтле хәлләре, төшенчә вә аңлатмалары бар икән. Әйе, шәһәр баласы өчен бигрәк тә: авыл — әкият дөньясы. Мич башында ятып тудырылган түгел, бәлки яшәешнең һәм тормышларының барышы дәвамында дөньялыкның үзеннән күчереп бар кылынган, һәркемнең иминлеген, сулышының иркенлеген тәэмин иткән, рухи көчне вә җаннарының камиллеген саклаган әкият дөньясы бу! Әгәр дә болар онытылса, атадан балага тапшырылып килмәсә, авылның коты качар, ул үләр иде.

Боларны да мин әле бүген генә аңладым. Ә ул вакытта тоеп калган гына булганмындыр?

Бөтенләй икенче кешегә әверелдем төсле. Минем дә теге авыл малае төсле җилкә аша чыбыркы болгап шартлатасым, ап-ак бәрәннәрне, вак вә йөгерек адымлы сарыкларны җәйләүләрдә сызгыргалап кугалыйсым һәм йөртәсем килеп китте. Көтүче булып...

Тынчу һәм ясанган шәһәр урамнарыннан йөземә буялып калган акшар шунда коелып төшкәндер дә әкият дөньясына аяк басканмындыр инде?

## XIV

Урман мине үз баласын каршы алган төсле кочагына кабул итте.

Бер җиләкле аланнан икенчесенә чыктык. Кып-кызыл, авызда эри торган каен җиләкләре белән сыйландык. Камилә монда һәр җирне, һәрбер куаклыкны диярлек белә иде. Аңа ияреп йөри торгач, дөньямны оныттым. Урман гөмбәгә һәм һәртөрле сыйларга бик бай иде. Кинәт күкләр тетрәп куйды. Күтәрелеп карасак, итәгебезгә диярлек басып, кара-кучкыл кургаш болытлар яшен ташларын уйната иделәр. Көн эсселеге җиләс һава белән алышынды, мин курка калдым. Яңгырда калсак, нишләрбез?

— Тоз түгел, эремәбез әле! — дип, Камиләнең исе дә китмәде.— Килми ул монда, тисә дә — итәк очы белән генә кагылып китәр.

— Каян беләсең?..

— Күрербез әле!

Әмма мин аңа ышанмадым, кайтып йөгерергә кыстый башладым:

— Бәлки, җитешербез?

— Һи-и, җүләр, җитештең ди, бар. Безнең авыл ягыннан килә бит ул!

Мин аптырап калдым. Юк, Камилә ялгыша, безнең авыл ул якта түгел, монда бугай?..

Җиләк җыюның кызыгы бетте. Кайтып китәсе килә башлады. Камиләгә ялынырга тотындым:

— Әйдә инде, өйгә кайтасы килә...

Хәлем сабый баланыкы төсле булгангадыр инде, Камилә мине җитәкләп алды һәм без бик тиз диярлек урман читенә килеп тә чыктык. Калкулык башыннан авылыбыз уч төбендәге төсле кечкенә булып күренде. Шырпы тартмасы кадәр өйләрнең кояш нурларына чумып утырулары мине гаҗәпләндерде. Яңгыр болыты көнчыгышка таба китеп барган, безгә куркынычы юк иде.

Минем нәрсә хакында уйлавымны сизептер, Камилә:

— Тагын әйләнеп килә әле бу яңгыр! — дип әйткәч, ышанмыйча киреләнмәкче идем дә, ярар инде, сүзен тыңларга булдым.

Юлдан ашыгып атладык. Камилә йөгерттерде генә. Һәм чыннан да, вакыт-вакыт җил, тугланып, яңгыр тамчыларын китерә иде. Урман өстендә, без җиләк җыйган турыдарак салават күпере пәйда булып, дөньяны тагын да серлерәк итеп җибәрде.

Без килә торган юл төгәл киселеп куелган төсле иде. Аның бу ягында тузанлы аяк эзләре, ә теге ягында юп-юеш. Минем әлегә мондый галәмәтне күргәнем юклыктан, сәеррәк булып китте. Алга таба аякларны салып барырга туры килде. Йомшак, юеш кара туфрак балтырларга-тезләргә кадәр күтәрелде. Кайтып җиткәндә, инеш аша чыгып, аякларны юдык. Камилә үз юлы белән китте, мин арыган кыяфәттә өйгә атладым.

## XV

Әле көн озын иде. Ашап-эчкәч, арыганлыклар бетеп, мин тагын урамга чыгып бастым. Шунда Камиләнең үзләренә чакырганлыгы искә төшеп, аларга таба юнәлдем. Мин инде аның сихерче түгел икәнлеген белә идем. Шунлыктан һичбер шик вә шөбһәсез алгы капкаларын ачтым. Авыл башында, берникадәр читтәрәк урнашкан тәбәнәк кенә йортлары агач һәм чәчәкләр уртасында куе буяулар белән ясанган хәлендә утыра иде.

Сукмак буйлап алга атладым. Уң якта, кызыл һәм ак гөлләр арасында алсу күлмәктән берәү нидер эшләп маташа иде. Аны күрүгә, туктап калдым.

Кечкенә генә, сөякчел куллар белән бу ханым яңгырдан егылган чәчәкләрнең сабакларын бастыра, аларны тегеләй-болай нygыткалый, нидер сөйләнә иде. Аның колакка ят һәм сәер сүзләре күңелгә шом йөгертеп, мине бераз артка таба чигенергә мәҗбүр иттеләр. Тузгыган чәчләрен җыештырып кигән эшләпәсе, киң һәм озын итәкле күлмәге, артыгы белән чибәр чалымнары бу ханымны беренче карашка күз алдымда борынгы мирзалар хакындагы кинолардагы бикәләргә охшаттырса, хыял дөньям аны изге бер фәрештә белән тиңләргә әзер иде.

Кайсын уйларга да белмичә басып тора калдым. Ханым мине күреп алды. Күзләребез очрашты һәм ул миңа таба килә башлады.

Чибәр йөзен кинәт сәер чалымнар басты. Туры караган күзләре ничектер ак-

сыл һәм куркыныч иделәр. Ул гүя:

— Бир җаныңны, миңа синең җаның кирәк! Минем җанымны Иблис алды!— дип әйтә иде төсле.

Куркуымнан мин артка чигендем һәм чыгып йөгердем. Артымнан ул сихерче карчык куып киләдер, менә хәзер тотып алачак, җанымны суырачак иде төсле...

XVI

Бүген мине калага алып китәргә кайттылар. Әти-әни һәм сеңелем Көньяк кояшының барлык рәхәтен һәм сихәтен тәннәренә җыеп, туйганчы ял итеп куанганнар. Үземне сагынганнар.

Ике-өч көннән китеп тә бардык. Авылда каласым килмәде. Ямьле урман-кырлары, сулары-чишмәләре, таулары-калкулыклары белән авыл әкият дөньясына күмелеп артта калды. Иптәш малайларым мине онытканга, мин дә алар белән саубуллашып тормадым. Үпкәләгәннәрдер инде? Нишләтим, соңгы вакытларда бөтенләй дә урамга чыкмый башладылар, кыр эшләреннән кайтып та кермиләр бит. Аңлыйм, җәен авыл бил тиңелте эштә шул. Минем кебек шәһәр малайларына гына ышаныч юк.

Ә сокландырган, инде яраттыра башлаган серле Камилә, хәзер уйласам, чыннан да, сихерче кызы кебек күз алдыма килә дә баса. Шулай да курыкмыйм мин аннан. Кайвакыт уйлап куям: теге көндә бакчаларында очраткан ханым кем иде икән ул? Нигә йөземә шулай туры каралы? Бәлки берәр сәер, авыр билге күргәндер?

Шулар хакында уйлыйм, тәнгә курку йөгерә. Үз-үземне тынычландырырга ашыгам: әкият илендә барысы да әкияттәгечә булырга тиеш, хәтта бер көнгә авыл күрергә кайткан шәһәр малайлары да, дим.

## ЯСАЛМА КЕШЕЛӘР, ЯКИ
## ХИКӘЯТ БАКЧАСЫ ҖИМЕШЛӘРЕ

*(Хикәятләр)*

### *ХИКӘЯТ, ЯИСӘ*
### *КАЙБЕР ХАЛЫКТА АНЫ “ПРИТЧА” ДА ДИЛӘР*
### *Сүз башы*

*Хикәят дигәндә, хәзерге гыйбарә буенча аны анекдот дип атарга булыр иде бәлки. Без анекдотларның кыска һәм гыйбрәтле көлкеле сөйләм әсәрләре икән-*

*леген беләбез. Әмма борынгы һәм урта гасырлар Шәрык әдәбиятларында, татар әдәбиятындагы кебек үк, алар хәтта роман киңлекләрен дә алганнар. Монда һичбер могҗиза һәм каршылык күренми. Анекдотның зурлыкка һәм киңлеккә хакы юкмыни? Әмма хикәятнең асылы анекдотча "кистерүдә" түгел, аның соңгы җөмләләре кискенлекне шомартып куя.*

*Безнең халыкта әкият дип аталган әсәрләр шулай ук, асыллары белән әлбәттә, хикәяткә барып тоташалар. "Хикәят" сүзенең халыкча әйтелеше "әкият" икәнлеген, галимнәребез генә түгел, укучыларыбыз да яхшы белә. Әмма, гасырлар үтү белән, алар бер-берсеннән аерымланганнар. Хикмәте шунда ки, күләмле хикәятләр дә күпмедер яктан әкият рухында корылалар. Ә менә төрки гыйбарәсе илә "әкият" сүзе ничек булды икән? Вакыйга? Хәбәр? Бәян? Кыйсса? Дастан? Юк, диярсез. Әйе, болар барысы да безгә гарәптән кергән сүзләр. "Әкият" гыйбарәсен алыштыра алмыйлар.*

*Хәер, хәзергә бу соравыбыз ачык калсын әле. Сүз башыбыз хикәят турында бит!*

*Әдәбиятның хикмәте — мәгънәдә, әмма да ләкин күпләр әдәптә дип белдермәкчеләр. Шунысы мәгълүм, мәгънә булмаган җирдә әдәпнең барлыгына кайсыбыз дәгъва кыла ала? Әдәп ул шул ук нәрсә, мәгънәнең җимеше. Мәгънәдән коры калынган әдәпне этикет, диләр. Кибеткә сатылырга чыгарылган кием-салымга, чүпрәк-чапракка тагылган "этикетка" сүзе белән һәм, гомумән, асылы белән тамырдаш алар. Бәс, шулай булгач, этикет әле ул әдәп дигән сүз түгел, аңа әдәп мәртәбәсенә ирешү өчен мәгънә җәүһәренең кабырчыгы хәленә керүе кирәк. Әдәбиятның да асылы мәгънәдән гыйбарәт.*

*Мәгънә! Синең ниндилегең, нәрсә булуың, кайларда яшеренеп ятуың кешелек өчен сер түгел, әмма сине күңелнең тирән коесы төпләреннән бик азлар гына эзләп табып, мәйданга чыгара ала. Ай да, кояш та, болай карап торуга, уч төбенә сыеп бетәрләр сыман. Ә дөньялыкны яктыртып торалар. Язучы әфәнделәрбез дә шулай, берләре — кояш, икенчеләре — шул кояштан нур алган ай хәлендәләр. Кояш буламын дисәгез, яшәгән заманагыз көн вакытына туры килсен, төнлә кояш чыкса, ул куркыныч булыр, аптырау, хәйран итү китерер иде.*

*Хикәят... Мин аны әүвәле Аврупа әдәбиятларына хас притча жанры белән буташтыргалый идем. Мәсьәләдә тирәнрәк казына башлагач, притчаларның тарих белән бәйләнеше барлыгын ачыкладым. Алар риваять сыманрак. Бу миңа кызыклы булып тоелды. Притчалар телдән сөйләнелә торган тарихчалар булып, алар "шулай итеп" дигән сүзләр белән, ягъни, иске телебезчә, "әл-кыйсса" диярәк башланып китәләр икән. "Әл-кыйсса" дип башланганга, борынгылар бездә притчаларны "кыйсса" дип атаганнар дигән фикергә килдем. Риваять төшенчәсе исә хәтердән китеп торды.*

*Хәер, безнең татар сүзлекләре притчаны гыйбрәтле хикәя, мәсәл буларак тәрҗемә итәләр. Әмма...*

*Притча дигән жанрның исемен хәзерге телебездә "тарихча" дип атасак, яңгырашлары да якын булачак, шуңардан чыгып, шул мәгънәсендә асылы җисеменә хилаф итмәгәнлеген дә төшендем. Ә риваять төшенчәсе һаман да хәтердән читтә кала бирде.*

*Тарихчалар, хикәят була алсалар да, хикәят жанрына карамаска тиешләр.*

*Аларның үз вазифалары бар, дидем, үз алдыма белдекле булып.*

*Шулай итеп, минем фикеремчә, хикәят һәм тарихча-притчалар икесе ике төрле жанр булып чыктылар.*

*Ә риваять хакында исемә дә алмавым аны тәмам әкият буларак күзаллауга бәйле булгандыр бәлки?*

*Хикәят жанрына мөнәсәбәтле кызыклар тагын да бар икән. Кайберәүләр хикәят белән Аврупа әдәбиятларына хас новеллаларны тәңгәл куялар. Мин дә әүвәле бу фикергә ышанырга булдым. Нинди генә яңа сүз, яңалык ишетсәм дә, татар гадәтенчә мәш килеп, миңа: "Юк!"— дип әйтергә Ходай насыйбыннан, ни галәмәттер, өлеш тимәгән икән.*

*Новелла — хикәят! Бу параллельне тану рәхәтлек бирә иде. Ул хакта сүз чыга калса, абзагыз "әйе", "шулай" сүзләрен эшкә җигәргә атлыгып торды. Әмма һәр ялган иртәме-соңмы ачыла, имеш. Инде мин дә новелла белән хикәятне тәңгәл куеп бетерә алмыйм, чөнки новелла дигәннәре татардагы хикәя икән бит, әмма хикәят түгел! Ә язучылар арасында каләмгә шундый да осталары бар, алар новелла-хикәяләрен нәкъ менә хикәяткә якын дәрәҗәдә итеп яза беләләр ки, ирексездә: "Бу бит бер дигән хикәят!"— дип дау куптарырга мөмкинсең. Тик, ни хикмәт, ул бары шул ук новелла-хикәя генә икән, хикәят түгел.*

*Әдәби жанрлар гомумән дә бер-берсенә тартым алар. Кайда хикәянең чикләре бетеп, хәтта повестьның башланып китүен билгеләү дә кыенлыклар тудыра. Ә мин, мәсәлән, повестьны озын хикәя дип атаучылардан көлеп йөрүчеләр исемлегеннән буламын. Югыйсә, әле кайчан гына повестьны үзем дә "озын хикәя" дип белә идем. Ә хәзер, повесть ул геройны "ә"сеннән "җә"сенә кадәр сөйләүче, — мәсәлән, тумыштан үлеменә кадәр дә булырга мөмкин,— матур бер әдәби жанр дип атыйм. Димәк, бусы да хикәят түгел.*

*Нәрсә соң ул хикәят? Аның табигатен белми-төшенми торып, менә бу "хикәят" дип әйтеп буламы соң? Адәм көләр!*

*Шулай да хикәятме?.. Аны чәчмә әсәр дип атасак, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр бине Мәхмүднең шигъри хикәятләрен кая куярга?*

*Хикмәт әсәрнең тезмә яки чәчмә булуында түгел, бәлки халыкның колагына барып ирешеп, күңелен һәм зиһенен нурландыруында, билгеле!*

*Без күбебез әдәбиятны "буш язмалар" дип уйлап гадәтләнгәнбез. Имеш, ул буш вакытны тагын да бушлык белән тутыру өчен генә языла. Бу бәлки махсус, үртәү һәм үртәлү өчен генә шулай әйтелә торгандыр? Хәер, әдәби әсәрләрнең бушлары да бар, элекләрне дә булганнар, киләчәктә дә андыйларны язмаслар дияргә урын юк. Шулай да чын әдәбият буш була алмый. Хыял белән генә тудырылган очракта да аңа никадәр өмет, никадәр белем, никадәр хикмәт салына.*

*Хикәят!.. Анда көлке булырга тиеш, диләр, ягъни ул көлдерергә, адәм баласы күңелендә тамаша хисен тойдыруга корылган булып чыга. Мин каршы түгел, көлдерсен. Әмма көлдереп кенә калу бер нәрсә дә түгеллеген яхшы белегез. Әгәр дә җаннарны сафландырыр куәте юк икән, ул көлүләрдән ни файда? Башкаларны мыскыллау безгә ләззәт китерә, билгеле. Ә син үзең мыскылланып кара. Җаның өшенсен. Өшесен һәм эсселәнсен! Моның өчен көлкедә зирәклек, акыл булырга тиеш!*

*Миннән әдәби уңышларымның серен сорыйлар. Кайберәүләр әйтә, дини темаларга язудан гына кеше булды ул, диләр. Бәхәсләшеп тормыйм. Дини темаларга язуым хак. Бик дөрес. Мондый белемнәре укучыларымда бар икән, бик яхшы, рәхмәт аларга. Әмма бер җитди укучым миңа бик яхшы итеп әйтте: “Әсәрләрегез әсәрләндерә!”— диде. Ә югыйсә аларны “җанга мунча” буларак караңгы төннәрдән үк “яга-яза” килдем. Җаннарны сафландыру көченә ия түгел икән, әдәби әсәрнең поты бер тиен. Җан чистарсын, җәмәгать, җан! Ул “изм”нарда (модернизм, романтизм, постмодернизм һәм башкаларының “изм”нары күздә тотыла) гынамыни хикмәт. Яңача язу булырга тиеш. Кабатлану ул алга бару түгел. Әмма “җанга мунчасыз” “изм”нар белән беркөнлек әдәбият кына яши ала.*

*Адәм баласы мунча кергәнендә үзен бер эссегә, бер салкынчага хушландырып газаплый, тәнен кайнар ләүкәдә себерке белән кыйный, шулай чистарына, сабын күбегенә батып, мунчала белән ышкына, коена. Шушы тән мунчасыннан соң ул җиңеләеп, рәхәтләнеп кала. Әдәби әсәрнең дә куәте шушындый. Әмма ул “җанга мунча”. Хәер, кешелеккә бу әллә кайчаннан билгеле. Борынгы фәлсәфәчеләр ул хакта азмы каләм тибрәтеп, адәм балаларының гыйлемнәрен теркәп калдырганнар?*

*Кайберәүләр әйтерләр, имеш, алар шундый талант ияләре ки, күкләргә менеп, Аллаһының сүзен ишетеп, фәрештәләрнең пышылдауларын тыңлаштыргалап язалар. Ышанмагыз, алар яки алдыйлар, яисә саташкан булырлар. Аллаһыны эзләр өчен әллә кайсы күкләргә мену кирәк тә түгел. Ул синең барлыгыңнан бирле күңел түреңдә тәхет корып, шул сараеңны нурландырып утыра. Күкләргә менеп йөрмә, үз күңелеңә үт һәм Аның белән рәхәтләнеп фикерләш.*

*Әмма, асылда, әдәби әсәрдәге мәгънәне бер энҗе бөртеге дип күз алдына китерсәк, аны күңел диңгезенең төбенә чумып, шуннан табып, кабырчыгын ачып, югары чыгарырга кирәк. Шунысы да бар, ул күңел диңгезе иләмсез зур да, куәтле дә, тирән дә булырга тиеш. Сай суда энҗе бөртекләре була алырмы? Хәер, алмаз һәм алтын юучылар киресен әйтерләр. Сай сулы елгалар читтән, ком белән бергә юып, ташыган вакытларында аларны алып киләләр. Ә менә энҗеләр исә читтән юылып түгел, диңгезнең үзендә, үз төбендә, тузан бөртеге кадәрледән алып зат сыйфатларыннача үсәләр.*

*Хикәят! Әгәр дә син шушы энҗе бөртеге түгел икәнсең, кадерең дә булмас. Тормышка күз сал, язучы әфәнде, тормышка! Адәм балалары күңел энҗеләрен яшәеш мәйданына чәчеп йөрмиләрмени?*

*02.12.05.*

*Хикәятләрнең шундый хикмәте бар, мәгәр кайсылары күңелегезгә ошамаса, аптырамагыз, икенче вакыт укып карагыз һәм моңарчы төшенелмәгән серләргә тап булырсыз!*

*12.04.06.*

## ТОРМЫШЫМ ХӘЛЛӘРЕННӘН

*Хикәят*

Мин үземне мескен дип белә идем, әмма танышларым:

— Гамәлләрең — изге, син — бөек!— диделәр.

Көлдем генә. Һаман да үземнең мескенлегемнән гарьләнеп йөри бирдем. Әмма миңа хәтта яңа танышларым:

— Син нинди бөек кеше икәнсең, белми генә йөргәнбез!— диделәр.

Көлдем генә. Һи, үземнең мескен икәнемне белмимме? Яшәешемә карагыз!

Әмма барыбер дә кешеләр:

— Менә ул нинди бөек!— диделәр.

Шуннан соң гына мин ул гыйбарәнең мыскыллау сүзе икәнлеген аңладым.

*09.11.05.*

## БАТЫРЛЫК ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Йорт кошлары җыелган ишек алдында бер Каз мактана икән:

— Ә сез беләсезме мин кем? Беләсезме мин нинди батыр? Беләсезме, минем борынгы бабаларым Рим шәһәрен дошманнарның мәкерле яулап алуыннан коткарып калганнар!..

Бөтен кош-корт, исләре китеп, аны тыңлап торалар, узып баручы Соры Мәче дә хәйран итеп тукталып калган. Шунда йорттан кулына үткен пычак тоткан хуҗа чыккан да, Казны, муеныннан тотып алып, сугымга алып киткән. Тамашадан гыйбрәт алган теге Соры Мәче әйткән ди:

— Римны коткаруыңнан ни файда, үзеңне бәладән йолып кала алмагач?

*30.10.05.*

## ГАЛИМ ИШӘК БУЛАМЫ?

*Хикәят*

Гомер буена үзен ахмак дип көлүләреннән гарьләнгән ишәк гыйлем өйрәнергә булган. Билгеле, тырышкан — кадак каккан, диләрме? Ишәк тә бик күп төрле фәннәргә тотынып караган, бик күп китап укыган, хәтта борыны өстенә күзлек тә утырткан. Һәм менә, аны галим дип белеп, кешеләр аңа балаларын укытырга китерә башлаганнар.

Бер ел узган. Аталары балаларыннан сорыйлар икән:

— Бу елда нинди гыйлем өйрәндегез?— дип.

— И-а, и-а!— диләр болар җавапларында.

Ул бик зур һәм галәмәт гыйлемдер инде дип, балаларын икенче елда да ишәккә укырга биргәннәр. Ел узган. Тагын сорыйлар икән:

— Нинди гыйлем өйрәндегез, инде икенче ел укыдыгыз?

— И-а, и-а!— диләр балалары.

Аталары аптырыйлар: бу нинди олуг гыйлем икән, икенче ел рәттән өйрән-

гәннәр дип.

Өченче елда да балаларын ишәккә укырга биргәннәр. Бу елда балалары, өйләренә кайткач та:

— И-а, и-а!— дип утыралар икән.

Шунда гына аталары аңлап алганнар: ишәк булу өчен өч ел укып йөрүнең кирәге юк түгелме?

## ҖӘННӘТЛЕ ДӘ ТӘМУГЛЫ

*Хикәят*

Бер хатынның ире бик тә ямьсез икән, җитмәсә үзен хәтдин артык сөя, ди.

Намаз укыйлар. Ул хатын иренең Аллаһтан ялынып дога укыганын ишетә: "И Ходаем, мине җәннәтле итсәң иде!"

Шуннан хатын үзе дә дога кылырга була: "И Ходаем, Син барсын да белеп торучысың, тәмугыңа гына кертсәң дә ярый, бары тик ул дөньяда да шушы хәшәрәт ирем авызына калдырма!"— дип.

Әмма халык усал телле, иренә ирештерәләр. Шунда ире:

— Аллага шөкер, догам кабул булган икән,— ди.— Ул дөньяда да карт хатын кочаклап ятмаммы дип гел шикләнә идем!

## ТЕШЛӘК МАКТАНЧЫК ЭТ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Бер Үгез, көне буе эшләп, тәмам арып-талып, абзарына кайтып бара икән, урамда аунаудан артыгын белмәгән мактанчык тешләк Эт аның арт сыйрагына килеп ябышкан. Үгез инде, бичара, авыртуына түземе бетеп, аны тибеп очырган, Этнең тешләре бер якка сибелгәннәр, үзе икенче якка барып төшкән. Шулай ята икән, иптәшләре килеп чыкканнар һәм:

— Нишлисең болай?— дип сорыйлар икән.

— Ятам әле,— дип сөйләнә аларга җавабында бу хәчтерүш.— Хуҗам үгез сыйрагы белән сыйлаган иде, тәменнән тешләремне дә йотканмын, корсагымны да шартлата язганмын. Күтәрелерлек тә хәлем калмаган.

## НИГӘ КЕЧКЕНӘЛӘР ИКӘН

*Хикәят*

Сания әби үзенә, кыйммәтле дип тормады, бар акчасын диярлек сарыф итеп, яхшы күннән кышкы читекләр алды. Моңа күңеле сөенде. Урамнан бер киеп узуы да җанына рәхәт бирәчәк иде. Әмма акчасы чыгу хәсрәтендә булуданмы, читекләрне алганда бераз кысанрак икәнлегенә игътибар итми калган.

Күршесе урыс Надя, аңарга юлыгып, сөйләшеп кайталар икән, Сания әби тукталып калган.

— Ни булды?— дип борчыла икән тегесе.

— Менә, кызым Алсу яңа кышкы читекләр бүләк итеп алып кайткан иде. Шуларны киеп чыктым. Әллә кысалар инде?— дип җавап биргән Сания әби, кызын яхшыга чыгарып.

— Яңалардыр,— дигән урыс Надя әби.— Кия торгач, киңәеп-зураеп китәләр алар.

Юлларын балаларына куана-куана мактанып дәвам иткәннәр.

Шулай Сания әби ничә көннәр кышкы яңа читекләрне киеп йөрсә дә, зураймаганнар, һаман кысанлана башлаган кебекләр икән. Бервакыт, өенә кайткач, ул аларны салган да, тотып карый-карый, үз алдына әйтә икән:

— Бу читекләрне алгач-алгач, кызым нигә бер үлчәмгә зурракларын алмады икән?— дип.

Шунда гына үз ялганына Хуҗа Насретдин кебек ышанып йөрүен аңлап, юләрлегенә аптырап киткән. Каян кызы алган ди әле?

*09.11.05.*

## ЭТЛӘР ТЕЛЕНЧӘ

*Хикәят*

Бервакыт урамдагы эскәмиягә барып утырдым. Әллә кайдан гына ике маэмай килеп чыктылар, ауный-тәгәрәшә бер-берсен яларга керештеләр. Мин аларның тамашаларына хәйран иттем.

Шунда берсе:

— Бу кеше нишләп монда эшсез утыра икән?— дип сорады.

— Ял итә торгандыр!— диде икенчесе.

— Бер дә арыган, эштән чыккан адәмгә ошамаган бит!

— Анысына исең китмәсен,— диде тагын да җавабында икенчесе,— ярый әле ул безне, нишлисез, хәшәрәтләр, дип ачуланмады!

Шунда гына тамашадан айнып киттем.

Мин, бичара, этләр телен белми идем, ничек болай аңладым икән? Гаҗәп хәл иде.

## СЫЕР-КӘҖӘ ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Кәҗәдән сорыйлар икән:

— Бер сыер биргән кадәр сөтең була аламы?— дип.

— Әйе,— дигән.

— Ә ике сыерныкы кадәр сөт бирә аласыңмы?

— Әйе!

— Ә өч сыерныкы кадәр?

— Хәтта ун сыер кадәр бирә алырмын, әгәр дә ун сыер булып туа алсам, ун сыер кадәр ашасам, ун сыер кадәр тәрбия күрсәм,— дип җавап биргән кәҗә.—

Әмма, ни кызганыч, кәҗә булып туганмын, ә шулай да бәтиләремне дә, хуҗаларымны да сөтемнән өзгәнем юк! Ә кайберәүләр чыннан да, кәҗә асрап, аннан сыер биргән кадәр сөт өметендә булалар.

## АЮ КАНУНЫ

*Хикәят*

Аюны, үзе бик теләгәнлек сәбәпле инде, хайваннар падишаһы итеп куйганнар. Бер ел хөкемдарлык итә бу, ике, өч. Аннары ил халкын җыя да фәрманын игълан итә:

— Моннан соң, канун буенча, бүреләр сарык ише хайваннарны ашамасыннар, төлкеләр куян кумасыннар, кош-корт тотмасыннар!..

Бу яңа канунны үлән ашаучылар хуплап, сөенеп кабул итәләр, “ура” да кычкыралар, берсен-берсе чөяләр. Тик ерткыч хайваннар гына телсез аптырап тора бирәләр. Шунда Арыслан:

— Аюларга нинди канун кертелер?— дип сорый.

Падишаһ исә:

— Аларга бу кануннар карамый!— диярәк җавап бирә.

## КӘКРЕ КАЕННЫ ТӨЗӘЙТҮ

*Хикәят*

Ике мескен, урман аланына чыгып, кәкре каен янында туктап калганнар. Берсе әйтә икән:

— Бу агачны мин төз итимме?

— Юк, үзем төзәйтәм!— ди икән икенчесе.

Шуннан, мескеннәр арасында булгалап торганча, “мин-син”, “син-мин” диярәк тарткалаша башлаганнар. Инде сугышып китмәкчеләр икән, урман кисүче килеп чыккан. Ни өчен талашуларын аңлагач:

— Бөкре каенны учак кына төзәйтә,— дип, “бөкрене кабер төзәтер” дигән татар мәкаленчә әйтеп, үз юлы белән китеп барган.

Теге ике мескен, урман кисүче киңәшенчә гамәл кылып, бөтен урманнан көл генә калдырганнар.

## ДИКТОР КАРГА

*Хикәят*

Карганы радиога диктор итеп чакырганнар. Микрофон артында каркылдап утыра икән бу. Халыкка бик ошап киткән, йоклаганнары да уянып, аның маһирлыгына аһ итә башлаганнар. Менә эш башына кемнәрне куярга кирәк дип, озакламый аңа биек кәнәфи тәкъдим иткәннәр, депутат та ясаганнар. Имеш, анда, югарыда, йоклап кына утыралар, уятмасмы!

Менә төп канун матдәләрен тикшерәләр. Каргага сүз бирәләр. Ул:

— Кар!— ди.

— Һо, ничек яхшы әйтте!— диләр.

Башка мәсьәләләрдә ул, чыгыш ясаган саен, һаман да бертөрле “кар” дип аваз сала бирә. Ә халык:

— Һо, ничек яхшы әйтте!— дип сөенә тора, Аллаһ рәхмәте!

## ТАВЫКЛАР КЕТӘКЛЕГЕ

*Хикәят*

Читәндә Әтәч:

— Мин — биек, кикрикүк!— дип кычкырып утыра икән, каен агачы башына килеп кунган Тилгән, аны үртәп:

— Анда — тәбәнәк, монда менеп кычкыр!— дигән.

Әтәч исә, акылы куәтләнеп:

— И юләрем,— дигән.— Мин каен башында утыра торган булсам, унбиш тавыкның ире исемен йөртә алмас идем! Аларны үзегез дә беләсез, һаман мактанышып, тарткалашып, әйтешеп аптырыйлар. Яннарыннан китүне генә көтеп алалар, күршеләргә дә хәзер йөгерергә генә торалар. Каен башы — сезгә, безгә — тавыклар кетәклеге дә ярар!

## КАРТЛЫКТАН КОТЫЛУ

*Хикәят*

Капка төбендә утырган бер бабай янына урамда уйнап йөргән малай килә. Аның янында урын ала, сорый:

— Бабай, нишләп утырасың?

— Үлем көтеп утырамын, улым,— ди аңа җавабында бабай.

— Ә ул кайсы яктан килергә тиеш иде соң? Югары очтан төшәрме, су буеннан менәрме? Үтеп кенә китсә?

— Килсә, үткәреп җибәрмәс идем әле, чабуына ябышыр идем!

— Ә нигә үлемне көтәсең соң, бабай?— ди малай.

— Картлыктан туйдым, картлык бит ул үтми. Ә үлем килсә, аны алып китәр иде!

Малай башын кашый:

— Аннары икәү бергә уйнар идек, әйеме, бабай!

## ДӨНЬЯНЫ БОЗЫП ЙӨРҮЧЕ ЭТ

*Хикәят*

Ике гыйбат акыл сата икән. Берсе, борын очын тартып, дөньялар бозылуыннан зарланмакчы итә:

— И-и, элекләрне яңгыр да вакытында ява иде, кыш та карлы-буранлы була иде...

Икенчесе, аны куәтләп, баш болгый, ай-вай-һай, сөйләнеп ала:

— Анысы нәрсә соң әле аның... Халык ялкауланды. Барысы да остардылар, эшләмичә генә баю ягын карыйлар!

— Юләрләр азайды шул хәзер,— ди икән беренче гыйбат,— хәтта этләр дә койрык болгап торырга иренәләр. Иртәннән бирле монда утырабыз, инде кич җитеп килә, әнә ул эт урамнан бишенче тапкыр узып бара! Җил сугарып йөрмәсә ни булган!

## ҖӘННӘТ-ТӘМУГ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Хикәят*

Ишәктән җәннәт хакында хәбәрдарлыгы барын-югын сораганнар. Ул:

— Беләм, бик беләм,— дип җавап биргән.— Җәннәт ул шул була, әгәр дә хуҗам көне буе эшләтеп, абзарыма кайтарып япса, алдыма башак салса. Ул вакытта таякласа да ярый, мин бары тик “ай-яй, ай-яй” дип кенә кычкырамын.

Моның болай сөйләвенә барысы да аптырап калганнар.

— Ишәк — ишәк инде, ул нәрсә белсен!— дигәннәр.

Әмма шунда берәү, акылына килеп:

— Ә ул вакытта тәмуг нәрсә булыр?— дип сораган.

Ишәк әйткән:

— Әгәр дә хуҗам мине эшкә алмаса, бу көне буе тик ятты дип абзарымнан куып чыгара. Мин андый вакытларда ашсыз да, тораксыз да калам. Өстемә кар да ява, яңгыр да. Тәнемне җил дә, буран да изалый. Хуҗам да урыныңа кер дип таякламый, “ай-яй, ай-яй” дип түгел, “и-а, и-а” кычкырсам да ишетүче булмый,— дип җавап биргән. Имеш, тәмуг шул була инде ул.

Тыңлап торучылар әйткән ди:

— И, бу Ишәк ахмак икән, хуҗасы таяклаганны җәннәт дип белә, эшсез ятуны тәмугка саный!

Әмма хикмәт таякта идеме икән?

*14.01.06.*

## БУЛДЫКЛЫ ӘТӘЧ

*Хикәят*

Әтәч армиягә китәргә “повестка” алган. Тавыклар, гадәтләренчә:

— Җибәрмибез, син китсәң, бер күкәй дә салмыйбыз!— дип аптыраталар икән. Шунда Әтәч түзмәгән, әйткән:

— Һе, минем алда гына шулай сөйлисез сез! Әгәр дә сизенми калсам, күрше йорт әтәчләренә таба итәк күтәреп йөгерергә генә тора идегез. Хәзер кайтып та кермәссез инде!

Тавыклар аның болай әйтүенә үпкәләгәннәр. Бигрәк тә Чуар Тавыкның кәе-

фе киткән. Моңаешып калганнар. Моннан соң әтәч әйткән, имеш:

— Ярый, җан кисәкләрем, армиядән мин “яныраль” булып кайтырмын, сез дә, “яныраль” хатыннары буларак, аштан-ашка гына йөрерсез,— дигән.

Тавыклар әле дә һаман аның “яныраль” булып кайтканын көтәләр, ди. Ә ул — юк та юк!

## САЕСКАН КИЯВЕ

*Хикәят*

Саескан кияүгә чыкмакчы булган. Моны Ала Карганың үзенә алу икән исәбендә. Әмма нәселен бик алай ошатып ук җиткерми.

— Икегез дә аклы-каралы, нигә исең киткән, ал, рәхәтләнеп яшә, балалар үстер,— ди икән иптәшләре, аның күңелен аулап.

— И, Саесканны һәр ялтыраганга кызыгучы буларак әйтәләр бит,— ди икән Ала Карга, һаман да күңеле ятып бетмәвен белдереп.

— Исең киткән икән,— диләр тагын моңа каршы иптәшләре,— инде хәзер синекенә тимәс, безнекенә генә кызыгыр!

— Әйе шул,— дигән Ала Карга.— Менә шуннан куркам да инде мин: сезнекенә кызыгып, мине бөтенләй онытып куймагае, дим!

Һәммәсе дә телсез калганнар.

## ЙОРТКА КЕРГӘН ЭТ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Кышкы төндә Төлке берәүнең тавык кетәклегенә төшкән. Ә анда хуҗаның Эте ияләнгән икән, салкыннан качып йоклап ята.

Төлке килеп тә төшә, Эт сикереп тә тора. Борынга-борын очрашалар. Тавык эләктерәм дә качам дигән Төлкегә үз койрыгын саклап калу хәсрәте генә кала. Ничек тә хәйлә итмәкче, әмма вакыт тар. Алай уйлый, болай: Этне ничек тә алдарга белми. Шунда:

— Кара әле, агай-эне,— ди бу,— әллә тавыкларга йортка кердеңме, бөтен өс-башыңны тавык тизәге каплаган? Моны халыкка сөйләми булмас!

Эт исә:

— Кая-кая?— дип, өс-башын әйләнә-тулгана карый башлый. Ә төлке, бер тавыкны эләктереп, ул арада чыгып та кача.

## АХМАК ЭТ ХӘЙЛӘСЕ

*Хикәят*

Этне хуҗасы тавык урлап ашауда гаепли. Берни эшләп булмый, акланыр чарасы да юк. Өсте-башы да тавык тизәгендә. Инде ничә көн кетәклектә суык-

тан качып ята бит. Ә Төлке, аны кызык итеп, тавыкны да урлап чыгып качты. Хуҗасы алдына барып акланыр иде: тегеләй дә, болай да оят. Эт тәмам аптырашта кала. Аннары уйлап чыгара: тавыклар янына кереп, кунакчага менеп утырсам, җитмәсә алар кебек кыткылдап та куйсам, хуҗам мине тавыкка санар, этемне юкка гаепләгәнмен дип белер, ди.

Һәм шулай эшли дә. Ә хуҗасы чыннан да кетәклеккә керә һәм бу хәлне күрә, Этне танып:

— Аһ син, юньсез! Менә ничек минем тавыкларымны аулыйсың икән әле!— дип, кунакчадан куып төшерә һәм, койрыгын балта белән чабып, йортыннан куып чыгара.

## ЧЕБИ ХӘСРӘТЕ

*Хикәят*

Кетәклектә кыртлый тавык утырып чебиләр чыгарган. Арадан берсе, күкәйдән башын тартүгә үк, сөйләшергә тотынган. Һич кенә дә тик тормый икән. Әнисенең башына ук менеп утырган. Шулай карап тора икән бу, ә тавыклар керәләр дә күкәй салып чыгалар, керәләр дә күкәй салып чыгалар. Бу чеби сорый ди:

— Әни, болар нишлиләр?

— Күкәй салалар,— ди икән әнисе.

— Ә алардан чебиләр чыгамы?

— Әйе, алардан сезнең кебек чебиләр чыга.

— Ә нигә соң аларны хуҗа хатын керә дә җыеп алып китә, керә дә җыеп алып китә, нәрсә, аларга утырып, ул үзе дә чебиләр чыгарамыни?— ди икән теге чеби.— Чиләк-чиләк җыеп ала тора бит. Бик күп булырбыз инде!

## КЕМ КЕМНӘН АКЫЛЛЫРАКТЫР ӘЛЕ?

*Хикәят*

Әтәч үз биләмәләренең тәртибен тикшереп йөргәндә, кетәклеккә килеп кергән. Күрә: кыртлый тавыгы һаман күкәйләр өстендә утыра, чебиләре чыга башлаганнар, ә берсе башына ук менеп баскан.

— Сәлам!— ди икән бу, шушы әтәчне күреп алып.

— Син нәрсә, малай актыгы,— ди икән аңа әтәч, акылга утыртырга теләп,— анаң башына менеп баскансың? Үзеңне мәче-фәлән эләктереп алмасын, канаты астына кереп кач!

— Син күрмәдеңмени?— дигән икән чеби, ике дә уйлап тормастан.— Хуҗа хатыны, пычак кайрап, сине эзләп йөри иде. Хәзер монда керер, көтеп торсагыз дип әйткән идем. Сак була күр!

Әтәчнең коты алынып, тизрәк урамга ук чыгып тайган.

## КАРАКНЫҢ ҮЗЕ НИ, СҮЗЕ НИ?

*Хикәят*

Күкәй урлау нияте белән бер Саескан тавык кетәклегенә кергән. Алай-болай каранган да, томшыгына бер олы күкәйне эләктермәкче икән, күптән ояда утырган Кыртлый тавык:

— Күрәм, барсын да күрәм! Саескан — карак!— дип кытаклый башлаган.

Саесканның коты очкан. Шулай да акылын җыеп әйтә икән бу:

— Күрдеңме, сезнең әтәч бөркетләр белән очып йөри?

— Алдама,— ди икән Кыртлый тавык,— безнең әтәчкә тагын!

— Ышанмасаң, чык та кара!

Кыртлый кетәклектән йөгереп чыкканында койма башыннан очып төшкән әтәчне күреп ала да мактарга керешә:

— Ничек шундый биеккә менә алдың, җан кисәккәем? Ничек курыкмадың, ханым-солтаным?

— И юләр тавык,— ди икән әтәч,— койма башымы биек җир? Минем әле өй кыегына кадәр дә менгәнем бар!

— Сине әле бөркетләр белән очып йөрисең дигән иделәр, мин шуны истә тотып әйткән идем,— ди икән Кыртлый тавык,— күрми генә калдым!

— Кайсы юләре җиткерде сиңа бу сүзне?— дип һаман да әтәч аны ачулана икән.

— Саескан кетәклеккә кергән иде, шул әйтте дә, мин йөгереп чыктым!— дигән кыртлый.

— И ахмак тавыгым минем,— дигән, аптыраулы әтәч,— каракның эше хәрәм, үзе хәрәм, сүзенә ышанырга ярыймы соң инде? Чебиләреңне эләктерер өчен ялган сөйләгән ул.

Кыртлый, бар дөньясын онытып, кетәклеккә йөгергән.

## КҮҢЕЛЕҢДӘ БУЛГАЧ

*Хикәят*

Кыртлый йоклап киткәч, оясыннан чеби егылып төшә. Ишек алдына чыга. Ә анда тавыклар җим чүпләп йөриләр, уртада Әтәч басып тора. Чеби, моның янына килә дә:

— Син минем әтиемме буласың?— дип сорый.

— Әйе, мин синең әтиең булам,— ди Әтәч, башын горур күтәреп.

— Ә болары кемнәр?— ди тагын да Чеби, йөгерешеп йөргән тавыкларга ишарәләп.

— Минем хатыннарым,— ди Әтәч, бу юлы да бик тә һаваланып.

— Әйтәм аны,— ди Чеби,— алар турында уйлап, балаларыңның хәлләрен дә белешмисең. Хатыннарың күп булгач, вакытың тимидер шул!

— Күңелдә бала уе булса, вакыты гына табылыр иде әле!— дип, башын кыңгыр салып, Әтәч читкәрәк китү җаен караган.

## ШУЛАЙ ИНДЕ , ЮГЫЙСӘ

*Хикәят*

Бер көн үтә, ике, өч... Кыртлый тавык һаман оясында утыра бирә. Бер чебие генә чыккан килеш. Башкалары да менә-менә борын төртерләр сыман. Теге чеби әнисеннән сорый:

— Мин әтәчме, әллә тавыкмы?— ди.

— Канатларың, кикрикләрең чыкмыйча әйтә алмыйм әле,— дип аңлата тавык,— чеби чагында без һәммәбез дә бертөрле булабыз!

— Син дә әүвәл чеби идеңме?

— Әйе, мин дә әүвәле чеби идем!

— Кайчан үсеп җиттең соң, әни?

— И, кем хәтерләп бетерә инде аларның барысын да! Исемдә, әүвәле бар күләгәдән, хәтта шәүләдән курка идек. Курыкмый башлагач, үсеп җиткән идем инде.

— И, бик җиңел икән,— ди Чеби,— мин бит инде хәзер үк курыкмый башладым, үсеп җиттеммени?

## ТАВЫК-ӘТӘЧ ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Чеби тагын да әнисеннән сорый икән:

— Әтәчтән тавыкның аермасы нәрсәдә?

— Әтәч ул,— дип әйтә икән Кыртлый тавык,— һаман тавыкларны хәтерләп кенә йөри.

— Ә нигә хәтерли соң ул аларны? Югалмасыннар дипме?

— Вакытында күкәй салсыннар дип инде!

— Ә, алай икән,— ди Чеби.— Безнең әти афәрин, әйеме?

— Нигә алай уйлыйсың?

— Әнә бит, тавыклар, әле берсе, әле икенчесе, кетәклеккә керәләр дә, ояларына күкәй салып чыгалар, керәләр дә салып чыгалар. Әгәр дә хәтерләп тормаса, бу кадәр тырышырлар идеме?

Чебинең бу сүзләрен ишеткәч, Кыртлый башка тавыклардан көнләшеп тә куйган ди әле.

## АКЫЛ ӨЙРӘТҮЕ ҖИҢЕЛ УЛ

*Хикәят*

Койма башында Әтәч кычкырып торганында күрә, бер чеби аның артыннан менмәкче булып маташа икән. Моңа бик ачуы килеп:

— Син нишлисең? Кая менәсең? Егылып төшсәң?— дип ачулана башлаган.

Әмма Чеби, колагына да элмичә, һаман менәргә маташа икән, тик максатына ирешә генә алмый.

— Әйттем бит инде мин сиңа, маташма, дидем!

Чебине Әтәч һаман ачулана икән. Ә тегенең шунда гына акылына кот килгән, ул:

— Анда, югарыда утырганда акыл өйрәтүе җиңел ул, эти, монда төшеп булышсаң, ничек яхшы булыр иде!— дигән.

## БАШСЫЗ АДӘМ ҺӘМ ДИЮ

*Хикәят*

Бер адәм урманга барган да утын кисеп ята икән, дию килеп чыккан. “Менә күптән кеше итен ашаганым юк иде!”— дип сөенә икән бу. Адәмне эләктереп алмакчы булган, ә теге моны күреп өлгергән. Эше харап икәнен аңлап, суга батканында саламга ябышкандай, хәйләгә тотынган:

— Бик яхшы булды әле синең килүең, ярдәмгә Ходай үзе җибәргән, ахрысы,— ди икән.— Тот пычкының бер башыннан, кисешерсең!

— Мин сиңа ярдәмгә түгел, башыңны ашарга килдем!— ди икән дию.

— Беләм-беләм,— дип әйтә адәм дә,— мин дә шулай дим бит инде. Син пычкының теге башыннан тотып кисә тор, ә мин, өйгә кайтып, башымны алып килим, юкса онытып калдырганмын.

— Бар,— дип әйтә икән дию,— тиз йөре, ә мин утыныңны кисә торырмын!

## ДИЮ АШАУЧЫ МАЛАЙ

*Хикәят*

Бер адәмнең йортына дию төшкән. Бишектәге баласын урламакчы икән. Ишектән эчкә узуы булган, бусагада адәм үзе күренгән. Хәлне шунда ук аңлап алган да әйтә икән бу:

— Сөбханаллаһ-машаллаһ! Рәхмәт, Ходаем! Мин инде ничә көн, бөтен урманны бетереп, дию эзләп йөрим, Син, булдыксыз булуымны аңлап, аның үзен монда китергәнсең. Улым ничә көннәр ашарга дию сыйрагын сорап ята иде, әнә дию үзе аның авызына кереп бара!

Бу вакытта дию бишек янына килеп җиткән, ә баланың йокы аралаш киң итеп авызын ачкан вакыты икән. Адәмнең сүзләрен чынга алып, исән чагында котылыйм диярәк, дию өйнең почмагын күтәреп чыгып качкан.

## БЕР САНДЫК ИТ

*Хикәят*

Бер арык адәмне урманда дию эләктереп алган, әмма аның сөякләре шалтырап торуын күргән дә әйтә икән бу:

— Синең итең кайда соң?

Адәм ике дә уйлап тормаган:

— Хатында!— дип җавап биргән.

— Бар, кайтып алып кил!— ди икән дию.— Көтеп торам!

Әмма адәм, акылы чамалырак булуданмы, әллә башка сәбәп аркасындамы, китмичә, кузгала алмыйча тора икән. Дию аптыраган:

— Нигә кайтып алып килмисең?— ди икән.

— Бик алып килер идем дә, әмма күтәреп йөри алмыйм, шуңа күрә итемне хатыныма калдырырга туры килә,— дигән адәм,— үзең алып килешсәң генә инде!

Ике дә уйлап тормаган дию, киткәннәр болар авылга төшеп. Урманнары тау башында, авыл исә аның итәгендә генә икән.

Барып кергәннәр өйләренә. Хатыны уклау белән камыр тәгәрәтеп маташа икән. Бик тә симез, ди. Диюнең хәтта күзләре майланып куйган.

— Мин,— дип әйтә икән адәм,— әнә теге буш сандыкның авызын ачып торам, ә син хатынның биленнән барып эләктер дә сандыкка сал, мин капкачын төшерермен дә бикләп куярмын, син сандыгы белән итемне алып китәрсең!— дигән.

Һәм дию ризалашкан. Хатынның биленә кулларын сузуы булган, теге, кинәт борылып, диюнең башына уклау таягы белән тондырган. Дию дөмбердәп сандыкка ауган, адәм исә, капкачын ябып, аны бикләп тә куйган, өстенә үк менеп утырган, ә үзе сөйләнә икән:

— Хатын, сиңа тансык дию итен алып кайттым әле, бер сандык тутырып!— дип.

Моның хатыны ахмак түгел, гомере буе һаман да иренең җаена торып, ни әйтсә дә күнегеп беткән булган.

— И ирем, ничек күтәрә алдың аны, әллә үз аягы белән килдеме?— дип, юха тел белән сөйли икән бу.— Бик яхшы булган, казан астына ягып, суын кайнатып куйдым. Менә токмач та баса идем. Бик вакытлы алып кайткансың. Хәзер балта китерәм, турый тор!

Дию сандыкта ишетеп ята икән: “Аһ, харап булды башларым, болар дию ите ашаучы адәмнәр икән!”— дип. Шулай уйлап бетергән һәм сандыкны ватып чыгып качкан. Шуннан бирле ул авылга дию төшкәне юк, ди.

## АШ ПЕШЕРҮ СЕРЛӘРЕ

*Хикәят*

Бер адәм, кыш көне буранда адашып, урман аланындагы диюләр яши торган йортка барып кергән. И куанганнар икән тегеләр, ашыйсы ризыгың авызыңны ертып килә дип. Берсе әйтә икән:

— Менә аш та булды!— диярәк.

Моны ишеткәч, адәм:

— И егетләр,— дигән, билендәге балтасын чыгарып,— мин дә ачыккан идем, әйдәгез, әүвәле балтадан аш пешерәбез, аннары миңа да чират җитәр.

— Нәрсә, безне ахмак дип белдеңме әллә?— дигән диюләрнең берсе.— Балтадан аш пешерәләр димени? Аны боткага салганда яхшы була. Китер монда! Ә үзең учакка утын алып кер!

## АДӘМНЕҢ ӨЧ ХӘСРӘТЕ

*Хикәят*

Дөнья йөзендә кешенең өч төрле хәсрәте бар, диләр. Беренчесе — ата-анасы белән бәйле, икенчесе — балалары белән, өченчесе — үзе белән.

Яхъя карттан сораганнар, аның кайсы артык та кайсы ким булыр, дип. Ул әйткән:

— Аның иң көчлесе бала хәсрәте булыр, иң кечкенәсе — ата-ана белән бәйле,— дигән.

— Аларның барлыгы-юклыгы, кайчангача барганы ничек беленер?— дигәннәр.

Ул әйткән:

— Мәхәббәт белән беленер. Ата-анабызга мәхәббәтебезнең зурлыгы аркасында без алар сагышын үлгәннәренәчә тартабыз, балаларныкын — аякларына басканча. Ә үзебез белән бәйлесе гомер буена барыр, кешенең үзенә булган мәхәббәте сүнгәнгә кадәр,— дип җавап биргән.

## ӨЧ ТӨРЛЕ ГАМӘЛ СЕРЕ

*Хикәят*

— Өч гамәлдә дөнья газабы бар, диләр, алар кайсылар?— дип сораганнар Казый Яхъядан.

Ул исә:

— Болар нәрсә һәм нинди икәнлеген белмәсәгез, сорап торыр идегезме?— дип җавап биргән.

Халыкның кәефе киткән. “Сер яшерә, сер яшерә!”— дип зарланышканнар.

— Ярый, алайса әйтим инде,— дигән Казый Яхъя,— өч гамәлдә дөнья газабы бар дигәндә: иртәгесе көн эше турында кайгыртсаң, үткән эш өчен хәсрәт чиксәң, бүгенге эшеңне уйламасаң — менә шулар күздә тотылалар. Әмма кайбер кешеләр, болар хакында уйламаска тиешбез икән диярәк фикер йөртәләр. Киресенчә, бу өч гамәлдә ният булганда — яхшыдыр,— дигән.

## ДӨНЬЯЛЫК БАКЧАЛАРЫ

*Хикәят*

Мөгаллим Тарикъ, география фәнен яхшы беләрәк, дөнья йөзендә җәннәткә тартым җирләр барлыгын сөйләп алган:

— Менә анда,— дигән,— агачлар чәчәк ата тора, җимеш бирә бара. Яфракларын коймыйлар. Бакчалар һәрдаим яшел утыралар. Мондый урыннар тау ара-

ларында, үзәнлекләрдә икән. Һәр кыйтгада да бар дип әйтә алмыйм. Әмма җылы якларда мондый бакчалар кешеләрне бик хушландыралар икән.

— Андый бакчаларда яшәүчеләр дөнья йөзендә үк җәннәткә ирешәләр булыр, шулаймы?— дип сораган халык.

— Дөнья йөзендә нинди генә җәннәткә тартым бакчалар булмасын, әмма аларда да эшләмичә генә яшәп булмый. Дөньялыкта бәндә гаме — хезмәттә!— дигән мөгаллим Тарикъ.

## БАЗАР АКЫЛЫ

*Хикәят*

Базарда бер бабайны күрдем. Ак җәймә җәйгән дә шуның өстенә ватык йозак, тишек иләк, сынык пычак, китек балта, кәкре кадак ишеләрне тезеп салган. Хәйран калып:

— Бабай, боларны кем алсын?— дип көлә башлаган идем, ул:

— Алай димә, улым! Сатар әйберең булса, алучысы табыла аның, борчылма!— диде.

— Ничек инде?

— Базарда ике төрле юләрләр була. Аларның берләре, кыйммәткә сатамын дип алдана, икенчеләре, очсызга алам дип уйлый!

Үземне бер дә юләргә санийсым килми иде. Әйләнеп йөредем-йөредем дә, вак-төяк әйберләрен сатып бетерергә өлгергән бабайга тагын игътибар иттем. Ул:

— Очсызгарак сатучыны эзлисеңме, улым?— диде, сорау катыш елмаеп.

## ЯШЬЛӘРНЕ ҮСТЕРҮ

*Хикәят*

Кош-корт халкы тиз картаючан бит инде ул. Чебиләр үсә тора, тавык булып китә. Әтәчләр дә шулай инде. Буыннар алмашын хәбәр итеп яшьләр килә тора.

Бер әтәч үсеп килүче яшь әтәчләрнең башларын гел чукып, аптыратып яши икән. Тавыклар түзмәгәннәр:

— Нигә аларга ирек бирмисең, матур гына үсеп килгәннәрендә башларын чукыйсың?— дигәннәр.

— Сез шулай инде, яшьләр үсәрләр дә безгә карарлар дип өметләнәсез. Әмма алар белән бергә үзләре кебек үк яшь тавыклар да үсеп килә. Урыннарыгызны алмаслар дип өметләнмәгез!— дип, әтәч аларны чукып ачуланган.

## БУЛДЫКЛЫЛЫК БИЛГЕСЕ

*Хикәят*

Берәүне мактыйлар икән:

— Аһ сез нинди булдыклы, үзегез — шагыйрь, үзегез — язучы, үзегез — драматург!— дип.— Зур талант иясе сез! Милләтебезнең горурлыгы, заманабызның маягы, күңелләрнең күрке!

Бу кеше, тыңлап-тыңлап торган да:

— Аһ, шулай булса иде,— дигән.— Сез мине талант иясе, дисез, шагыйрь, язучы, драматург, дисез. Әмма, юньле шагыйрь була алмагач, язучы булып булмасмы дип, юньле язучы да була алмагач, драматург чыкмасмы миннән дип тырышып-тырышып караудан гына шагыйрь дә, язучы да, драматург та булынган инде!

## АЧЛАР ХӘЛЕН ТУКЛАР БЕЛМИ

*Хикәят*

Адәм хәсрәтсез булмый, диләр.

Шулай бер кешенең хәле бик мөшкел икән. Кәефен күтәрергә дип дуслары төрле мәзәкләр сөйләп караганнар, ул һаман көлми, кәефе киткәннән-китә, ди. Дуслары тәмам гаҗизләнеп беткәннәр.

— Әллә җырлап-биеп карыйкмы?— дигәннәр һәм, ни уйлаган булсалар, шулай кыландырганнар.

Теге һаман көлми дә, уйнамый да икән. Дуслары тагын да хәйран иткәннәр. Арадан берсе сорарга булган:

— Нигә көлмисең? Җырламыйсың? Биемисең?— дигән.— Сәбәбе нәрсәдә?

— И дусларым, сез миңа бер ашарлык ризык бирсәгез иде! Нигә шушы кадәр интектерәсез?— дигән җавабын ишеткәч, дуслары:

— Белмәдек, гафу!— дигәннәр.— Күңелең сагышландымы дип уйлаган идек, ашыйсың гына килгән икән бит!

## АХИРӘТ КӨН РИЗЫГЫ

*Хикәят*

Бер мулладан сораганнар:

— Сез безгә җәннәттән мисал китерерсезме?— дип.

— Китерәмен!— дигән мулла.— Җәннәт мисалы шул булыр: кемнәр хәмер эчеп, тәмам канатланып, дөньяларын онытып җибәрерләр, шул халәт җәннәт мисалы бер хәл булыр.

— Ә тәмугтан мисал нәрсәдер?— дигәннәр.

— Анысы да бик гади,— дигән мулла,— үзен җәннәттә дип белеп, адәм баласы бик күп хәмер эчәр, ә аннары башын күтәрә алмыйча авырыр. Эче-тышы көяр, уена гөнаһларыннан артыгы килмәс, мәңге алай эшләмәм дип антлар итәр, әмма бу хәленнән котыла гына алмас. Шуңа да хәмер бу дөнья ризыкларыннан хәрәме, Ахирәтнең хәләле!— дигән.

## САНДУГАЧ ТЕЛЛЕ ТАТАР

*Хикәят*

Инглиз, урыс һәм татар бер поездда бер вагонда бер купега туры килгәннәр. Сөйләшеп баралар икән. Инглиз мактана ди:

— Минем инглиз теле шундый тел, аны дөньяның һәр кыйтгасында аңлыйлар һәм беләләр, шуңа күрә халкым да бөек халык!— дип.

Урыс та югалып калмаган:

— Синең телеңне бөтен дөньяда аңласалар, минем телемне ярты дөнья белә, башка бернинди телне аңламыйча да урысча сөйләшеп дөньяны гизеп була. Минем халык та бөек!— дигән, горурланып.

Ә татар эндәшми, мыштым гына утыра икән. "Син дә әйт инде!"— дигәндәй аңа төбәлгәннәр.

— Минем телемдә татарлар үзләре дә качып кына сөйләшәләр. Сандугач сайраган кебек, бөтен галәм тынычланып беткәч,— дигән ул.— Минем телем сандугач теледер инде!

## КӘБЕСТӘ ХӘСРӘТЕ

*Хикәят*

Агайлар сөйләшә:

— Кәбестәгә корт төште, ничек бетерергә белгән юк!— дип.

Арадан берсе:

— Агуларга кирәк, эзләре дә калмас!— дигән.

Әмма бу киңәшен башкалар өнәмәгәннәр. Арадан татар агае:

— Кәбестә кортын көн дә чүпләп торсаң, берсе дә калмый. Минем хатын шулай итә!— ди икән.

Боларны тыңлап торган яһүди:

— Нинди сүз сөйләшәсез сез?— дип аптыраган.— Мин кәбестәне кибеткә керәм дә алам, керәм дә алам, әмма бер генә дә кәбестәгә корт төшкәнен күргәнем юк иде әлегәчә,— дигән.

— И юньсез,— дип ачулана башлаганнар аны агайлар,— сөйләшергә сүзне бетердең. Әле без ярты сәгатьләп бәхәсләшәсе идек!

## ХИКМӘТЛЕ ТАБИП

*Хикәят*

Табип чиратында бер татар агае утыра. Авырулар кереп китәләр, әйләнеп тә чыгалар. Агайның кәефе бозыла һәм:

— Бу табип әллә шундый начармы, кешеләрне карап та тормый, бора да чыгара, бора да чыгара?— дип сорый, ризасыз ачуланып.

— Юк,— диләр аңа,— киресенчә, бик оста табип ул. Авыру кешенең бер күрүдә чирен билгели. Синең кайсы төшең авырта соң?

— Авырткан һәм авырган җирем дә юк сыман, кулым гына... сынмады микән дип борчылып килдем. Улымның машинасы юлда ватылгач, астына кереп китте, ә мин машинасын сәгать буе күтәреп торган идем,— дигән.

— Борчылма, агай,— дигәннәр ишек төбендә чиратта утыручылар.— Бу табип шундый оста, аягыңны себеркe суында тотарга киңәш итәр, кулыңның да авыруы бетәр.

## БАШСЫЗ ХАТЫН БӘЛАСЕ

*Хикәят*

— И башсыз!— дип ачулана икән улын бер ир. Малай аны-моны эндәшми тик тора, аннары әнисеннән сорый:

— Әни, мине син алып кайткан идеңме, әллә этиме?— дип.

— Мин әлбәттә, атаңа тагын!— ди икән әнисе.

— Ә син мине этидән алып кайттыңмы соң?

— Шул башсыздан булмый, кемнән алып кайтыйм инде?— дигән әнисе.

— Ә, шуңа күрә мин дә башсыз инде алайса, әйеме?— ди улы.

Әтисе тыңлап торган да:

— Әниең башлы булса, юньлерәк ирдән алып кайтыр иде сине, башсыз, шуны да аңламагач!— дип, улын тагын да ачулануын дәвам иткән.

## АКЫЛЛЫ ДУС КИҢӘШЕ

*Хикәят*

Бер татар драматургы хәтдин тыш баеп киткән. Чит ил машиналарында гына йөри, шәп киенә. Фатирын да, йорт җиһазларын да яңартып бетергән. Инде чират хатынына җиткән. Монысын да яңартса, бөтенләй дә бәхетле буласы, имеш! Тик эше барып кына чыкмый. Өенә хатыннар да алып кайтып карый, яшь кызлар да. Әмма хатыны һич тавыш чыгармый.

— Булдыра алсаң, афәрин!— дип кенә тора. Ә үзе чит-ят ирләргә бер дә кызыкмый, ирен ташлап китә белми.

Драматург тәмам акылдан шашар хәлгә җитә. Дуслары, моңа киңәш биреп, үзең ташла да кит син аны, диләр. Ә ирнең бер дә алай итәсе килми, фатиры кызганыч, байлыклары. Саран булмасаң, баеп китү мөмкин түгел шул ул.

Моның хәленә кергән бер кеше аңа мондый киңәш бирә:

— Син,— ди,— хатыныңа бер кашык су белән йотарлык берәр сөяркә табып бир. Эһ та итмәс, китәр дә барыр! Юкса синең хәлең “бүре дә тук булсын, сарык та исән калсын” дигән мәкальгә тартым,— дигән.

— Ә андый егет минем хатынга карармы соң?— ди икән драматург.

— И юләр, нишләп карамасын,— ди икән дусты.— Синең хатындай чибәр затны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый. Ул үзе дөнья байлыгы. Кыяфәте — затлы, кулы — татлы...

Аны тыңлап торган-торган да ир, базарга сыер сатарга чыккан мужик кебек әйтә икән:

— Мондый хатын үземә дә кирәк булыр, китми генә торсын әле!— дип.

## ЗАЯ ГОМЕР — ЗАР ГОМЕР

*Хикәят*

Гомер үткәненә берәү зарлана икән. Икенчесе:

— Хәере белән, хәере белән!— дип әйтә, ди.

— Аның үтүендә нәрсәсе инде хәерле?— дигән тегесе, һаман да зарланып.

Монысы аңа гаҗәпләнгән һәм әйткән:

— Гомернең һәр чорында үзенә күрә хәерле ягы бар. Яшьлектә чын егет булып, ирлектә исә ике кулыңнан җитмеш төрле эш килсә, менә шулар булыр инде ул гомернең хәерле узуы. Ә картлыкның үз шатлыклары бар. Анысы көздә бакчаларның җимешләнгәне кебек инде,— дигән.

Күпләр яшиләр, әмма гомер иткән кебек тә түгелләр, заяга елларын уздыралар да җибәрәләр, имеш. Ә аннары зарланып йөрергә генә кала.

## АКЧАДАМЫНИ ХИКМӘТ?

*Хикәят*

Бер адәм акчасызлыктан интегә икән. Нинди генә эшне башкарып чыкмасын, кереме үзен дә, гаиләсен дә туйдырырга чак җитеп бара. Бу хәле турында дустына зарлана икән:

— Эшлим-эшлим, бер файдасын да күрмим. Хезмәт хакым ашарыма да чак җитеп бара,— дип.

Ә моның дусты яһүди кавеменнән булган. Ул аны тыңлап торган да:

— И агай-эне,— дип әйтә икән,— син юкка күп эшләргә кирәк булган хезмәт сайлагансың. Моннан түбән аз эшләп, күп акча ала торган җиргә урнаш. Бернинди хәсрәтең дә булмас,— дигән.

Бу кеше, шундый эш эзләп йөреп, бөтенләй дә бөлгенлектә калган.

## МӘЗӘГЕ КЫЙММӘТ

*Хикәят*

— Мин — бөек шагыйрь, мин — бөек шагыйрь!— дип дау куптара икән бер каләм иясе. Моны тыңлап торган халык:

— Әйе, син — бөек шагыйрь, син — бөек шагыйрь!— диләр, афәрин кычкыралар. Теге һаман да үссенә бирә, үзенекен такылдый:

— Мин — бөек шагыйрь, мин — бөек шагыйрь!

Ә халык һаман да мактауда икән. Шуннан, болар янына яңа килеп кушылган бер әфәнде, аларга аптырап:

— Нинди бөек шагыйрь булсын бу, шигырьләре бигрәк буш бит, мәгънәсе юк,— дигән.

Шунда халык эченнән акыллысы:

— Анысын без дә беләбез, әмма котырткан саен аның сикерүе кызык бит. Ат кәмите сыман,— дип, әфәндегә хәлнең асылын аңлатып биргән.

## МИНКЕМЛЕК СЕРЕ

*Хикәят*

Адәмнең холкында ике начар як бар, диләр, берсе — мин-минлек, икенчесе — көнчелек. Акылы булган кеше менә шуларны бәйдә тотуны кодрәт итә, имеш.

Шулай бер адәм башкаларга һаман да үпкәләп кенә тора икән.

— Нишләп кәефең юк синең?— диләр.

Бу адәм исә:

— Бик булыр иде дә бит, әмма сез мине санламыйсыз, кемлегемне белмисез! Һаман да үзегез дә үзегез. Сез генә яхшы, башкаларны бер дә күрмисез,— дигән.

— Нишләп шулай булмасын,— дигәннәр моңа.— Үзебезнең кемлекне үзебез күрмәсәк һәм белдермәсәк, син күрер идеңме соң?

Теге кеше дә акылына килеп әйткән ди:

— Бик күрер идем, әгәр дә үземдә дә кемлек булса!— дип.

## КҮҢЕЛ КҮЗЕҢ БУЛМАСА

*Хикәят*

Бер кеше һаман да китап укый икән. Берсен бетерергә өлгерми, икенчесен башлый. Моны зур галим булыр дип көтәләр. Әмма юк та юк. Аптырагач:

— Нәрсә укыйсың соң син ул китаплардан?— дип сораганнар.

— Укуын күп укыдым инде,— дигән теге “китап корты”,— инде хәзер мәгънә эзләп укыйм!

— Таптыңмы соң?

— Әлегә юк!— дигән бу.

— И юләр,— дигәннәр моңа,— мәгънә бит ул китапта гына түгел, кешенең үзендә дә була. Әгәр дә укыган китабында алар очрашып кавышмасалар, бу кадәр күзеңне бетерүдән ни файда?

— Шуңа дип тырышам бит инде!— дигән теге кеше, җавабында елмаеп.

## САРАНЛЫК КОТКЫСЫ

*Хикәят*

Бер бай адәм бик саран икән. Әмма аны саран дип әйтмәсеннәр өчен, байлыгын яшереп, иске-москы гына киеп йөри бу. Менә бервакыт өйләнер чаклары җитә моның, хатын алып кайта. Йорты-җире белән таныштырып йөри. Хатыны боларның һәммәсен күрә дә:

— И-и,— ди,— мин синең болай ук бай икәнлегеңне белмәгән идем.

— Ә нәрсә, начармыни?— ди бу адәм.

— Начарын начар түгел дә,— дип әйтә икән хатыны,— әмма бу кадәр малтуарны, байлыкларны, йорт-җирләрне карап бетерергә дә кирәк бит әле. Мин бит сиңа хатын булырга дип кенә килгән идем, ә син мине хезмәтче итеп тә алгансың икән!

## ХӘЙЛӘСЕЗ ИР

*Хикәят*

Берәүләр фатир алырга җыенганнар. Мөгаен мөмкинлекләре шундыйрак булгандыр инде, гаилә башы ир, ашыкмый гына сөйләп, хатыны белән киңәшә икән:

— Дүрт бүлмәлене алыйкмы, әллә өчле генә дә җитәрме?— дип, һичбер хәйләсез.

Хатынының шунда йөрәгенә ут каба язган:

— Юк инде, ирем, өчле дә бик җиткән,— ди икән бу.— Ул бүлмәләрне әллә син җыештырасыңмы? Миңа төшәчәк бар авырлыгы. Дүрт бүлмәне җыештырып чыгарырга да аны күпме хезмәт кирәк, өчлене генә ал, өчлене генә!

— Ярар,— дигән ире,— бер бүлмәсен бикләп куярбыз, нәкъ өч бүлмәсе генә калыр, син дигәнчә булыр, бер дә борчылма!

## ИХЛАСЛЫК ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Кешедә иң яманы — тел, диләр. Әмма бер кеше шундый оста сөйләшә икән, хәтта әйткән сүзләрендә сандугач сагышлары бар булыр. Аны гел тыңлап кына торасы килә.

Шуннан, берәү килә дә моннан сорый:

— Кара әле, карендәш,— ди,— минем дә, югыйсә, тавышым да моңлы, җөмләләрем дә дөрес, диктор булып та эшлим, нигә соң халык мине мөкиббән китеп тыңламый? Киңәш бирмәссеңме икән?

— Бирәм,— дигән ул кеше.— Сере бик гади аның: сөйләгәндә сүз чиләген, җанның коесына төшереп, шуннан акыл ширбәтен тутырып алып, башкаларның күңел тустаганнарына бүлеп сала белеп сөйләшергә кирәк! Бары шул гына, бернинди авырлыгы да юк аның!

## ГАДЕЛЛЕК ӨЛГЕСЕ

*Хикәят*

Бәхетле тормышның нигезе гаделлеккә корылганын беләсез. Әмма аны “дөреслек” тә диләр әле.

Шулай бервакыт бер хөкемдар:

— Болай итсәм гадел булырмы, алай эшләсәм ярармы?— дип баш ватып утыра икән, өстәленә нурларын коеп торган кояшның йөзен шунда болыт каплаган. Бу хәлгә күңеле киткән хөкемдар:

— И хәерсез,— дип зарланган ачуланып.— Син, югыйсә, зәгыйфь, мескен бер болыт кисәге генә, әмма никадәр якты янган, Аллаһының шәме булган кояшны да капларга җөрьәт итәсең, ә мин монда бүрегә дә ярарга тырышып, аны да тук итмәкчемен, сарык та исән калсын дип баш ватам!

## БАШСЫЗ БАШ

*Хикәят*

Ике агай утын кисәләр икән. Аркылы пычкыны чаж да чож йөртәләр. Урамнан бер ташбаш малай үтеп бара. Болар янына туктый, карап тора. Аннары, юри шаяртыпмы:

— Нәрсә, агайлар, пычкы бүлешәсезме әллә? “Минеке дә минеке” дип тарткалашасыз?— ди.

Берсенең моңарга ачуы килә:

— Атаң башын бүлешәбез!— дип, усал итеп эндәшә.

Малай да аптырап калмый:

— Минем атайның башы сезгә тәтемәс шул,— ди.— Ул чанасын җәй ясый, арбасын кыштан майлап куя. Утынны да сезнең кебек кыш көне кисеп ятмый!

Һәм китеп бара.

Агайларның икенчесе беренчесенә:

— Бүлдеңме атасы башын?— дип әйтеп куя.

## ЗАТЛЫЛЫК ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Кешенең бәхете үзеннән алда йөри, диләр. Кая барса да, нишләсә дә көтеп ала. Әмма ләкин адәмдә тәкәбберлек дигән бәдбәхет бар, шуның аркасында ул үзен танып, көтеп алган бәхетен күрми үтеп китә, имеш.

Шулай берәү:

— Мин — булган, мин кулыма нинди эш алсам, шуны хәл итәм, гади таштан энҗе бөртеге ясыйм, тимерне алтынга әверелдерәм,— дип мактана икән.

Моны тыңлап торган икенче бер адәм:

— Болары бик яхшы, әмма үзеңне дә затлы итәргә онытма,— дигән, әллә бераз көнләшептерме, белмәссең.

Һәм аңардан мондый җавапны ишеткән:

— Хикмәт шунда шул менә, тәкәбберлегем аркасында бәхетемнән коры калдым мин!

## КӘЕФ БАЗАРЫНЫҢ СЕРЛӘРЕ

*Хикәят*

Бер кеше кәеф базарында бик тә оста телле икән. Һәркемнең күңел савытына затлы ширбәтен тутыра, әмма үзендә кәеф бер дә төкәнми, ди. Моның серен башкаларның беләселәре килгән. Хикмәтнең нәрсәдә булуын сораганнар. Ул:

— Бер дә әллә нәрсә түгел,— дип җавап биргән.— Мин һәрвакыт бары үземнән генә көлдем, шуңа күрә күңел савытымны ватарга теләүчене тапмадым.

— Ә без сине бик яхшы кешедер дип белә идек. Ялгышканбыз, бездән дә көлкерәк адәм икәнсең,— дигәннәр кабат та тегеләр аңа.

Бу юлы ул:

— Мин бит кылган яманлыгымнан түгел, кылырга мөмкин булган начарлыкларымнан көләм. Җаным сафлана да гөнаһлардан котылып калам,— дигән.

## БҮКСӘЛЕ ИР ГӨНАҺЫ

*Хикәят*

Арада телгә беткән кешеләр дә була. Алар янында сүз сөйләү үзе үк батырлыкка тиң, имеш.

Бервакыт ирләр җыелышып сөйләшеп тора икән. Арадан берәү, мактанып:

— Өйләнгәч, тормышлар җайланып китте әле. Хатын пешеккә бик оста, корсак үсә дә корсак үсә, бүксәм тау кадәр булды инде,— дигән.

— Ай-йой,— дигәннәр башкалар,— күрми дә торабыз, чыннан да Бакыр-тау кадәр булган!

Шунда берсе:

— Хатын да хатын, дисең, йоклаганда ут яндырып йоклыйсыңдыр әле, бүксә шуңарга үсә ул,— дигән.

## ИРЛЕК СЕРЕ

*Хикәят*

Бер ирнең хатыны кыз тапшый да кыз тапшый икән. Моның бу галәмәтләре ирләр теленә кереп китkән. Хатыны тагын буйга узгач, сорыйлар икән иреннән:

— Монысы да кыз булырмы, әллә малаймы?— дип.

— Аллаһы кемне бирсә, шул инде,— дигән ир, бер дә сер биреп торасы килмичә.

— Ә сез караватастыгызга балта-пычкы ишене куеп яткан идегезме соң?— диләр тагын да.

— Ни өчен?— дип аптырый ир.

— Соң,— дип аңлаталар моңарга,— карават астыгызны карарга кирәк, әгәр мунчала, табак-савыт ише аунап ятса, тагын кыз була инде, балта-пычкы ише икән, малай алып кайтмый калмассыз, иншаллаһ!

## БАШКАЛАРНЫ ТЫНЫЧЛАНДЫРА БЕЛҮ СЕРЕ

*Хикәят*

Адәмнең кәеф яхшылыгы сәламәтлегенә бәйле, диләр. Ә мин — табигатенә, дим!

Бер кеше авырып ята икән, күрше-тирәсе, таныш-белеше аның хәлен белешкәләргә кергәли. Һәммәсенең сораулары бер чамадарак бит инде:

— Хәлләрегез ничек соң?— диләр.

Бу да аларга һаман бер рәвешле җавап бирә тора:

— Әлегә ярыйсы иде әле, менә авырып киттем бит.

— Болай булса, торырсыз, Аллаһ насыйп итәр,— диләр моңа,— кәефегез яхшырадыр сыман.

— Яхшырыр ла, анысы,— ди бу, ишек якка күрсәтеп,— анда, аягыма басуыма, дөньялыгым көтеп тора, тагын үзен кудыртырга әле исәбе... Юк инде, рәхәтләнеп авырыйм! Ашыктырмагыз!

## ӘҖӘЛНЕҢ КУРКАКЛЫГЫ

*Хикәят*

Кеше катырак авырып китсә, газаплардан тәмам туеп, үлем килүен көтә башлый.

Шулай бер авыру хатынга сеңлесе хәл белешеп килә. Апасы аңардан:

— Күренмиме әле?— дип сорый.

Сеңлесе курка кала, әмма:

— Күренми әлегә,— ди.

— Юк сүз сөйлиләр икән,— ди апасы,— имеш, әҗәлең якында гына йөри дип. Ничә көн көтәм инде үзен, юлы ерак булды бугай, килеп җитә алмый интегә, бичаракаем!

— И-и,— ди сеңлесе,— апам-җаным, үлем ул аяктагы кешенең генә янында йөри, әҗәл чәнечкесен күтәреп. Әгәр дә аяктан егылсаң, моның үлемендә мине гаепли күрмәсеннәр дип, тизрәк качу җаен карый.

## МИЛЛИ ТАРИХ ЧИКЛӘРЕ

*Хикәят*

Татар, урыс, украин бер купеда баралар икән. Әүвәле татарны ачуланганнар:

— Син, татар,— дип,— безне ничә йөз еллар буена иза чиктердең, бездән ясак түләттең! Империя тоткан халык — хәерсез халык ул!

Аннары урыска күчкәннәр һәм:

— Син дә инде дүрт йөз еллап империя тоттың... Синең ирегең өчен сугыштык, синең бәхетең өчен тырыштык, бер дә безне рәхәт яшәтмәдең!— дип ачуланганнар.

Чират украинга җиткән.

— Нәрсә?— ди икән бу.— Минем империя тотканым юк! Исегез киткән... Татарның дегетенә буялып, урысның газын иснәп яшим икән, моның өчен миңа кайтарма-компенсация түләвегез тиешле!

## БЕЛЕП СӨЙЛИ

*Хикәят*

Бер урысның кызы татарга кияүгә чыгам дип әти-әнисенең котын алган. Болар аптырап утыралар, ди.

— Яратам дип әйтә бит!— ди икән әнисе.

— Шулай ди шул!— ди икән әтисе.

— Диннән дә язам, аның динен алам. Ислам дине — Аллаһының адәмнәргә тапшырган соңгы хакыйкате. Аңа күчүне дөреслеккә чыгара,— ди икән әнисе.

— Шулай ди шул!— дип җөпли әтисе.

— Аның өчен утка да керәм, суга да төшәм ди бит,— диярәк уфтана әнисе.

— Анысы инде,— дип әйтеп куя әтисе,— татарга чыккач, утка да төште, суга да батты дигән сүз! Белеп сөйләве.

## БУЛДЫКЛЫ РӘИС

*Хикәят*

Бер күмхуҗ рәисе, йөрәгенә кодрәт оялапмы шунда, авыл урамыннан җанфәрманга чабып барган тракторны туктата. Тагылган сабаны да бар икән моның. Тракторчыдан сорый рәис:

— Син кая барасың?— ди.— Өйлә җитеп килә бит инде!

— Эшкә барам, аргы басуны сөрергә,— ди тракторчы.

— Нинди эшкә бару,— ди рәис, ачуланырга итеп,— эштән кайтыр вакыт җиткәндә?

— И, белмәдем бит,— ди тракторчы, мин әле, кайтырга иртә дип, бирге басуны сөреп бетердем дә, аргысына күчеп маташа идем. Эштән кайтырга вакыт җиттемени, рәхмәт яугыры?!.

Тракторын бора да кайтып китә.

## ТЕЛЕФОН РӘХӘТЕ

*Хикәят*

Автобуста бер әби, теленә салына-салына, әле генә Маһруй дигәнен ачуланып ташлады, аннары Әнисә дигәненә дә эләкте. Ну, сүзләрне кызганмады да инде.

Уңыма-сулыма карыйм. Сөйләшкән-ачуланган кешеләре дә күренми. “Саташа торгандыр бу әби, акылы киткәндер, ахрысы!”— дип уйлап өлгермәдем, колагыннан кесә телефонын төшерде. Минем акылга да барып җитте: хәзерге технологияләр үсеше рәхәтләндерә халыкны!

Телефоны тәрәзәсеннән әби бик озак нәрсәдер эзләп аптырады. Аннары миннән сорады:

— Кем белән сөйләштем соң әле мин? Сәкинә белән бит? Тәрәзәсеннән карап кына әйт әле!

Карадым. Соңгы сөйләшкән кешесенең исеме чыкты.

— Маһруй әби белән сөйләшкәнсез!— дидем.

— И чукынгыры,— диде әби,— Сәкинә белән дип торам.

## ҮЗЕБЕЗНЕКЕНӘ — ЯРЫЙ

*Хикәят*

Кояшта кызынып йоклап яткан мәче янына килеп, чеби сорый икән:

— Син кем буласың?

Мәченең, әлбәттә, мыегы гына селкенеп куя. Чеби: “Әһә, бу моны тартырга кушты булса кирәк!”— дип, мәченең чыннан да мыегыннан тарта. Тегенең психы чыгып, сикереп тора, чебине эләктереп алмакчы була, әмма тавыклар патшасы әтәчнең монда гына йөрүен күреп ала да:

— Мин сезнең колыгыз булам, чеби туганым!— дип җавап бирә. Шулай да ачуыннан йоннары көеп чыгардай була, чеби исә утлы табага тагын да май өсти:

— Ә, ишәгебез инде, алайса, ул вакытта йокласаң да ярый!— дип үз юлы белән китеп бара.

## СҮЗ ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Адәмнең күңелендә ни булса, теленә шул чыга, имеш. Күңеле усалларның теле дә усаллык белән газаплый, күңеле йомшак затларның теле дә йомшаклык үрнәге була, ди.

Бер кеше бик тә усал икән, чит-ятларны гына түгел, үз гаиләсен дә шул теле белән “утта көйдерә” бу. Бервакыт хатыны түзми, моңарга әйтә:

— Син — җәһәннәми!— ди.

Адәм аңлап ала һәм:

— Аллаһы тәгалә бәндәләренең туры сүзле булуын сөя!— дип белдерә. Хатыны да югалып калмый:

— Туры сүзендә ни хикмәт, әгәр дә ул буш искән җил кебек сукыр, яңгырсыз кара болыт кебек игелексез булгач,— дип җавап бирә.— Сүз ул саф сулы чишмә кебек, әмма тәнне түгел, җанны сугарыр өчен бар кылынган.

## БЕР ЯВЫЗГА — БЕР ИПЛЕ

*Хикәят*

Бер иргә хатыны тынгы бирми аптырата:

— Синең кебеккә барганчы, коры таякка ябышып йөрүең мең артык!— ди.— Әнә кешеләрнең ирләре, матур итеп тә яшиләр инде. Ә синең ни кулыңнан, ни телеңнән килмәде!

Ире эндәшми. Хатыны һаман саен котыра бара:

— Син бит үзеңне яклап, акланып сүз дә әйтә алмыйсың. Бакча карачкысы сыман телсез бит син. Карга да күтәреп китми бит сине!— дип зәһәрләнә. Шунда гына ире:

— Аллаһы тәгалә, җаннарны бар кылганда, бер яхшыга — бер яман, бер чибәргә — бер ямьсез, бер уңганга — бер булдыксыз дип ясый торгач, син яхшы булсынга миңа яман атлы калырга туры килде инде,— дип җавап бирә.

## КҮҢЕЛ КҮЗЕҢ КҮРМӘСӘ

*Хикәят*

Бәрәңге әрчегәндә бер хатынның бармагы киселеп киткән. Бүлмә буйлап кан агызып йөгереп йөри икән бу. Аңа башкалар:

— Китер, бармагыңны бәйлик, авыртуы басылыр,— диләр.

Юк, ә бу һаман йөгереп йөри:

— Шул кирәк аңа,— ди,— авыртсын, пычакка башка вакытта күрә торып барып кермәс, җаена гына кыланыр!

— Нигә алай булгач үзең йөгереп йөрисең соң? Бармакны җәзалыйм дип үзеңне газаплыйсың,— диләр моңа.

— Бик шулай да бит,— ди бу хатын,— әмма бармакның, башы булса да, күзләре юк, ә күзләр маңгаемда иде, югыйсә. Менә шуңа күрә дә йөгереп йөрим инде мин. Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең — ботак тишеге, диләрме? Күңелем-җаным бармагыма төшеп, үз гаебен күреп менсен, дим!

## ҮТКЕН ПЫЧАК БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Бер хатын ирен ачулана:

— Пычакларны бик үткен кайрагансың, бармакларымны өзеп чыгарырга гына торалар!— дип.

— Соң,— ди ире, иреннәрен турсайтып,— сиңа үткенләсәң дә ярап булмый, үткенләмәсәң дә.

— Менә шул шул менә,— ди хатыны да,— аларны даими үткенләп торсаң, алай булмас иделәр. Мин бит синең үтмәс пычакларыңа күнегеп беткән.

— Ярый. Алайса,— ди ире, бер дә югалып калмыйча,— китер пычакларны, таш суеп керим, хәзер үтмәсләнерләр! Син дә элеккечә үтмәс пычаклар белән, курыкмыйча үз эшеңне башкарырсың!

— Бар-бар, шулай ит әле, ирем,— ди хатыны да, исе китмичә,— үзеңнән бәрәңге әрчетермен!

## НӘСИХӘТ ҖАЕ

*Хикәят*

Чебигә әтәч акыл сабагы өйрәтә икән:

— Сак була белергә кирәк. Әнә, күрәсеңме, күктә очып йөрүче каракош тилгән хәтерләп кенә тора. Ваемсыз чагыңда төшә дә тырнагына эләктереп алып китә, харап кына буласың!— дип.

Чеби сорый:

— Ул сине дә алып китәме соң?

— Юк,— ди әтәч,— мин олы бит, көче җитми аның миңа!

— Соң, алай булгач, бигрәк яхшы,— ди чеби.— Ул миңа тырнакларын суза башласа, син аның кирәген бирә аласың. Куып җибәрерсең!

— Һи, бик шулай итәр идем дә,— ди әтәч,— әмма ул каракош күренүгә — котым кача. Син инде минем нәсихәтемне тот, әмма, бәлагә тарсаң, ярдәмемне өмет итә күрмә.

## ЭТЛЕ-МӘЧЕЛЕ

*Хикәят*

Ике эт сугышканын бер мәче капка баганасы өстендә карап утыра, ә үзе тегеләргә дәрт бирә:

— Тунын ерт, борыныннан каптыр, койрыгын тешлә! Менә шулай, менә шулай!

Этләр сугышудан тәмам арып-алҗып туктыйлар. Бераздан берсе сорый:

— Без нәрсә өчен сугыштык соң әле?

— Әнә теге, капка баганасы өстендә утырган мәче аркасында бугай,— ди икенчесе.— Ул сиңа минем тунымны ертырга, борынымнан каптырырга, койрыгымнан тешләргә котыртып утырды.

— Менә нәрсә икән әле,— ди шунда беренчесе.— Ә мин аны синең яклы дигән идем. Кара әле икейөзлене, тотып ашарга кирәк үзен!

Һәм этләр шул мәчегә ташланганнар.

## РИЗЫК ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Бер эт кабырга кимереп ята. Аның янына икенчесе килә, иреннәрен ялый, селәгәйләре ага.

— Кара әле, әйе, агай-эне,— ди,— миңа да калдырырсыңмы?

— Кызык икәнсең син,— дип җавап бирә аңа кабырга кимерүчесе.— Моны миңа хуҗам тугыры хезмәтем өчен бирде. Беләсең бит аларга ялагайлануның нинди авыр гамәл икәнлеген!

— И-и,— ди теге селәгәй эт,— мин дә алай эшләп карадым, аяк табанына кадәр яладым. Әмма сыңар кисәк тә биргәне юк.

— Юләр,— ди аңа кабырга кимергәне,— авызыңа шундый сыйрак керергә маташкан, ә син ялап кына калгансың. Кабып йотарга кирәк иде адәме белән... Менә шуңа күрә кабырга да эләкми инде сиңа!

## МУЛЛЫК ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Этләрдә эт киңәше этләрчә булыр, диләр. Дөрестер инде, юкса телгә шулай дип кермәс иде.

Авыл мулласына бер агай тормыштан зарлана икән, ә аннары, ялгышып китеп, Аллаһыны да теленә алган:

— Нинди гөнаһларым өчен ул мине болай җәзалый икән?— дип.

Мулла аны тыңлап-тыңлап торган да, янындагы бер китапны ачып укып күрсәткәч, әйтә ди:

— Син зәкәт бирдеңме? Гашура тапшырдыңмы? Мәчеткә дип садака илттеңме? Ашка кунаклар чакырдыңмы?..

Һәм ул шулай тезеп-тезеп киткән. Агай тыңлап-тыңлап торган да:

— И тәре,— дип әйткән,— мин әле дөньямның авырлыгын ялгышлык белән сәрхушларга хәер бирүем аркасында дигән идем, баксам, сәбәбе бик аздан гына торган икән! Мулланы кайгыртырга кирәк булган!

## СӨЯКТӘМЕНИ ХИКМӘТ

*Хикәят*

Бүре, бер кәҗә артыннан чабып килә торгач, турыдан кистерим дип сикереп, абайламавы аркасында нәкъ арысланнар аранына барып төшкән.

— Менә,— ди икән ата арыслан,— Аллаһының кодрәте зур аның, бирим дисә колына, китереп сала алдыңа!

Шунда ук бер көтү бала-чагасы:

— Миңа сыйрагы, миңа майлы кабыргасы!— дип, йөгерешеп килеп тә житкәннәр. Бүренең коты тәненнән төшеп киткән, шулай да әйтә икән бу:

— Менә, Арысланым-падишаһым, сезгә рәхмәтем зур булды гомергә. Сез миңа үгездән соң татлы сөякләр калдырып, затлы өстәлләр кордырдыгыз. Шуларны исемә төшереп, сезгә дип бер кәҗәне куып килә идем, гаиләгез ишле булуны күреп, үгез китергәндә яхшы икән, дидем, кәҗәне кайтарып җибәрдем. Шулай да белешим, үзләре нәрсә әйтер икән диярәк каршыгызга килүем иде!

Арысланга моның сүзләре хуш килгән. Үзе уйлый икән: “Бүре — төлке түгел инде ул, алдый белми. Сүзе дөрестер!”— дип. Ә аннары әйткән:

— Ярый алай булгач, бар, башта үгезеңне алып кил, аннары синең хакта уйларбыз!

Бүре, исән-сау котылуына сөенеп, үз юлы белән китеп барган. Шулай да, коты урынына кайткач, уйлый икән бу: “Арыслан кадәр арысланны алдадым. Әмма ул мине моның өчен гафу итмәс. Әллә барып гафу үтенимме?”— дип.

Шунда юлына төлке очраган. Хәлне аңарга сөйләп биргән. Төлке әйткән:

— Һәм дөрес! Киттек, мин нәкъ аңа бара идем. Хәлеңне аңлатырмын, гафу итәр!

Китәләр. Арысланнар аранына барып керәләр. Тегеләр ажгырышып каршы ала. Төлке:

— Арысланым-падишаһым, менә, минем бурычым бар иде. Тере бүре алып килдем, итен ашарсыз, тунын аяк астыгызга салырсыз!— ди.

Бичара бүренең тагын коты оча. Үзен төлке нинди бәла авызына алып килгәнен аңлап, тизрәк моннан качып котылмакчы, таймакчы була. Әмма аны арыслан туктатырга өлгерә:

— Юк инде, төлке агай,— ди,— мин бу бүрене үгез алып килергә җибәргән идем. Син аны хәйләң белән юлыннан боргансың!

Төлке шунда ук акылына килә һәм:

— Шулайрак булды шул!— дип елмая.— Ул үз җилкәсенә сездән төшерелгән эшне зур авырлыкка санап, булдыра алмамын, үзен тотып ашавыгыз хәерлерәк дигәч, аның сүзенә ышанып, монда ияртеп алып килгән идем. Сүземдә ялган юк, үзеннән сорагыз!— ди.

Бүренең тагын да куркуыннан сөякләре тәненә тартылып торган тиресе эчендә капчыктагы кебек шалтыр-шолтыр киләләр. Арыслан бу хәлне күрә дә, бүрегә:

— Агай-эне, майлы калҗа ашарга кирәк, юкса, калдык-постык сөяк җыеп йөреп, эчең тәмам шулар белән генә тулган!— дип киңәшен бирә, аннары, алардан чирканып, икесен дә үз юлларына җибәрә.

## ҖӘННӘТЛЕ НӘСИХӘТ

*Хикәят*

Бер авыл мулласы озын-озак итеп хөтбә укырга, нәсихәтләр сөйләргә бик тә ярата икән. Илһамланып китеп, әллә кайлардагы тәмугларны һәм җәннәтләрне дә, Буракка атланган Мөхәммәд пәйгамбәребез белән бергә булып кайткандай,

бер дә аптырап тормыйча, сүзләрендә йөреп чыгучан, ди. Шулай бервакыт, авыл агайларын тәмам алҗытып бетергәч, арадан берсе бүлдереп сорый моңардан:

— Карагыз әле, хәзрәт, безнең сүз башы нәрсә иде соң әле?— дип.

— Сезнекен белмим,— дип җавап бирә ачуы килгән мулла,— әмма безнеке башыңа җитү белән тәмамланмагае! Җәннәткә кереп барганда гына, юлымнан туктатып, кире борып маташуыңны әйтер идем инде!

## НАДАНЛЫК КУРКЫНЫЧ ТҮГЕЛ

*Хикәят*

Дөянең мөфти булуы мәгълүм факт. Бервакыт бу ни сәбәпледер ишәкне казый итеп куярга тәкъдим иткән.

— Менә,— ди икән,— безнең ишәк кебек акыллы хайван юк. Бер эшкә дә катнашмый, бәхәсләрдә бүлдереп аптыратмый. Аңардан да дөрес затны атый алмыйм!

— Надан түгелме соң ул?— диләр моңа.

— Анысы да зыянсыз,— ди дөя,— мин үзем дә галим заттан түгел идем. Менә мөфтилек чалмасын киеп алгач, үземне надан дип атарга кайсыгызның башына килер? Бездә шулай бит ул, урынга бәйле һәммәсе дә! Биек урын наданны да галим ясау көченә ия. Шулаймы, ишәк?

— Әйе, һәм дөрес,— дигән ишәк.— Дөябезнең наданлыгы куркыныч түгел, тик менә ахмаклыгы гына куркыта!

## ИМАМЛЫК ТАЛӘПЛӘРЕ

*Хикәят*

Хайваннар дөньясы дингә керергә булган. Мәчет тә төзеткәннәр. Имам сайлыйлар икән. Шәригатьчә булсын дип өч таләпне алга чыгарганнар: беренчедән, имам мөлаем сүзле кирәк, икенчедән, имамның тавышы колакка ятышлы булу кирәк, өченчедән, имамның гадәтләре яхшыдан булу фарыз, ягъни аракы эчү, тәмәке тарту, чит-ят хатын-кызга хыялый күз салу кебек сыйфатлары күренмәсен!

Әтәчкә әйтәләр ди:

— Син мәзин булырсың, тавышың да көр, иртә уянасың! Бу урынга синнән дә яхшысы юк! Ә менә имамлыкка кемне дип торасыз?

— Үзебезне дип тора идек әле,— дигән әтәч, бер дә аптырап калмыйча.

— Ни өчен алай уйлаган идегез?

— Соң, минем бит хатыннарым ишле, ә сезнеке — берәр генә! Имамлыкка миннән дә кулай кем бар, шулай булгач?— дип әтәч аңлатып биргән.— Читятларга күз салырга да вакыт калмый.

## ТАВЫКЛАР ХӘЙЛӘСЕ
*Хикәят*

Бер тавыкның гадәтенә кыткылдап йөрү кергән. Моның белән ни булды икән дип аптырыйлар башкалары. Җавап кына таба алмыйлар. Шулай башлары каткач, үзеннән сорарга итәләр:

— И ахирәткәем, син нишләп болай туктаусыз кыткылдап йөрисең, бераз тынып тормассыңмы?

— Үзем дә болай йөреп аптырап беттем инде,— дигән бу тавык.— Әтәчебез миңа бер дә игътибар итми башлады, шуны гына кызыктыру иде теләгем!

Аның бу җавабын ишеткәч, һәммә тавыклар котырып “җырларга” керешкәннәр. Ә теге тавык инде шым гына йөри икән. Әтәч моңардан үз итеп кенә сораган ди:

— Ни булган боларга?

— Миннән көнләшүләре!— дип җавап биргән ул тавык.

## ТӨЛКЕНЕ АЛДАУ ҖАЕ
*Хикәят*

Куян артыннан төлке куып бара. Тәмам хәлдән китә, аннары:

— Карагыз әле, Куян дустым,— ди,— бераз туктап торсагызчы, сулышым кысылды, ял итеп алыйк!

Туктыйлар. Төлке тагын әйтә:

— Нәрсә дип шушы кадәр чабасыз?

— Сездән качам!— ди куян.

— Нигә?

— Тотсагыз, ашыйсыз бит!

— Ә әйе бит әле!— ди дә, төлке тагын куянны куа башлый. Урманны өч әйләнәләр. Дүртенчесендә төлкенең тагын хәле бетә. Туктарга, ял итеп алырга сорый.

— Юк әле,— ди куян,— миңа болай йөгереп йөрү бик ошады, тагын бер әйләнеп килим дә... Сез ял итә торыгыз!— дип китеп тә бара.

Төлке: “Әһә, моны әйләнеп килгәненә кадәр көтим. Авызыма үзе барып керер!”— ди, сөенеп.

Сөйләүләренә караганда, әле һаман да көтеп утыра икән.

## КӘҖӘ ЧОКЫРЫ
*Хикәят*

Хуҗаның бакчасына кәҗә кереп аптыраткач, баз казып, ялганчы чокыры ясап, өстенә кәбестә яфраклары ташлый бу. Кәҗә, гадәтенчә, аның бакчасына ияләнгән сукмагы буйлап керә һәм теге ялганчы чокырга төшә. Кычкырып ята башлый. Хуҗа килә дә:

— Әһә, эләктеңме, мур кыргыры!— дип сөенечен белдерә.

Әмма кәҗә чокыр төбендә нидер таба, иснәнә. Хуҗа:

— Нәрсә таптың анда?— ди.

Кәҗә:

— И Хуҗа, чокыр казып дөрес эшләгәнсез, әмма хәзинәгә җиткәч кенә туктагансыз. Монда никадәр энҗе-мәрҗән, шуларны чүплим!— дип сөйләнергә тотына.

— Тимә, калдыр, чокырны мин казыдым, хәзинәсе дә минеке!— дип, Хуҗа чокыр төбенә төшә. Ул да түгел, аның сыртына сикереп менеп, кәҗә чокырдан чыгып та кача.

Хуҗа алдануын чокыр төбендә генә белеп ала.

## ЧИБӘРЛЕК ХӘСРӘТЕ

*Хикәят*

Аккошлар суда йөзгәннәрендә, үзләренең күләгәләрен күреп, чибәрлекләренә аһ итәләр, шулай сурәтләренә сихерләнәләр. Гүзәл хатыннар да алар халәтендә, имеш. Көзгедән үзләрен күреп, бу матурлыктан аерыла алмыйча сәгатьләр-минутлар буе утыралар-утыралар һәм утыралар.

Шулай бер чибәр кыз көзгедән сорый:

— Мин гүзәл бит, әйеме?

Көзге эндәшми.

— Нәрсә,— ди кыз,— минем чибәрлектән телеңне йоттыңмы әллә?

— Анысы йотуын йотмадым,— дип җавап бирә көзге,— әмма көне буе сиңа карап утырудан гына туйдым. Бер дә ял иткәнем юк. Көндез дә, төнлә дә каршымнан китмисең. Башка эше юк микәнни бу кызның дип аптыравым!

## ЧӘЧ АЛУ ОСТАЛЫГЫ

*Хикәят*

Тавык чәчтараш-ханә ачкан. Бик тырышып, җиренә җиткереп эшли икән бу. Кискән чәчләр дә бик матур чыгалар. Әмма эше озак бара, бер дә мантый, баеп китә алмыйча изалана. Байлыкта һәм муллыкта яшәүче чәч кисүчеләрдән сораштырып карый, бер дә серләрен чишмиләр.

Һәм менә аңарга берәү мондый киңәш бирә:

— Син,— ди ул,— һәммә җире дә килерлек итеп кисә торгансыңдыр. Аның өчен бик күп вакыт сарыф ителә... Аны башкача да эшләп була бит: аннан-моннан гына кыркы да чыгар, кыркы да чыгар. Ханәңә килүчеләр дә күбәер, үзең дә баерсың!

Тавык аның бу киңәшен кабул итә. Хәзер акчаны ярма урынына чүпли, ди.

## АКЫЛЛЫ КӘҖӘ

*Хикәят*

Хуҗа үз кәҗәсеннән котылырга өлгермәгән, моның бакчасына күршеләрнең кәҗәсе сукмак салган. Бервакыт ул аны саклап торган да күсәк белән биленә биргән. Чамасы чамалы чак булганмы, әллә ачуы бик каты килгәнме, әмма дә кәҗә сузылган да яткан.

— Эләктеме үзеңә!— дип куанган Хуҗа әүвәле.

Ә кәҗә һаман хәрәкәтсез ята икән. “Их, харап иттем моны, күршеләргә ни әйтермен?”— диярәк инде Хуҗа кайгыда уфтанган, аннары акылына килгән, кәҗәне күтәреп, ишек алдына алып чыккан. Ә ул һаман да хәрәкәтсез икән.

— Булмады бу, суярга кирәк җәһәтрәк, итен булса да ашармын, акчасын түләрмен,— дип, өенә пычак алып чыгарга кереп киткән.

Пычак күтәреп килсә, кәҗә юк, чыгып шылган.

— Белдем,— дигән Хуҗа,— пычак исеннән кәҗә дә курка икән. Киткән җаны кайтып, гәүдәсен сөйрәп алып качарга өлгергән. Бу пычакны аның йөри торган сукмагына элеп куярга кирәк булыр!

Файдасы тигән, имеш.

## СЫЙРАК ЯЛАУЧЫ ЭТ

*Хикәят*

Сыер, татлы үләннәрне туйганчы ашаганнан соң, иренеп кенә чебен, кигәвен ишене койрык белән болгап куыштырып, үз алдына чәйнәштергәләп ята икән, моның каршысына эт килгән дә өрә башлаган.

— Нәрсә ди ул сиңа? Аңлыйсыңмы моның әйткәннәрен?— дип сорый арырак яткан сыер.

— Сыйрак сорый!— дип җавап бирә монысы.

— Сөзеп очыр шуны, үз сыйрагын үзе яласын!— ди тегесе.

— Торырга иренәм,— дип җавап бирә бусы.— Өрә торсын, якын килергә курка ул!

Эт боларның сөйләшкәннәрен ишетә дә бик мыскыллана. Өрүеннән туктый һәм:

— Мин бит сыйрак сорап өрмәгән идем, бары тик чебен-кигәвеннәрегезне генә куып маташуым иде,— дип җавап бирә.

## БИШ БУЛМАСМЫ?

*Хикәят*

Ике тинтәк мәктәптә укып йөриләр икән. Чалбар төпләрен шактый туздырырга өлгергәннәр болар.

Арифметика дәресе бара. Икегә икене кушып маташалар. Һәммәсе дә җавапны дүрт дип язып куйганнар. Боларныкы гына чыкмаган.

— Дүрт!— дип пышылдый янәшәдәге бер кыз.

Ә болар һаман да язып куя белмиләр.

— Дүрт!— ди, алгы яктан борылып киңәш биргән икенче бер түземсез кыз.

Болар һаман да язмый.

Аптырагач, укытучылары да:

— Дүрт!— дип кычкырып әйтә.

Шунда гына тинтәкләрнең берсе әйтеп куя:

— Дүрт икәнлеген үзебез дә беләбез, биш булмасмы дип көтеп утыра идек!

## КВАДРАТЛЫ МӘСЬӘЛӘ

*Хикәят*

Алгебра дәресе бара. Укытучы тактага язып, “а+в=с” квадратлы формуласын аңлата. Әмма укучыларның күңеленә барып җитә алмый. Шунда бер тинтәге сорау бирә:

— Апа, аларның квадраты нәрсәгә соң, ансыз гына булмыймыни?

Укытучылары аптырап кала. Ничек дип тә җавап бирергә белми.

Шуннан икенче бер тинтәге мондый киңәш бирә:

— Апа, сез аның башына китап белән тондырыгыз, ансыз гына булмаганын үзе дә аңлар!

— Әйе,— ди тинтәкнең тегесе,— бик суктырып тордым менә! Рус теле дәресендә синең авызың бер дә ябылмый иде. Апа китап белән суккач, “а” белән “в” кушылып укылганда “ав” була, “с” булмаганын да белмисең! Квадратлап та торасы түгел!

## ХУҖА НАСРЕТДИН

*Хикәят*

Укытучы үзенең дәрес уздыра торган сыйныфын эзләп йөри икән. Аңарга икенче бер укытучы очраган. Ул моңардан:

— Безнекеләрне күрмәдегезме?— дип сорый.

Тегесе:

— Хуҗа Насретдин булгансыз тәмам,— дип җавап биргән,— алар әле генә сезне эзләп йөриләр иде.

Нәрсә әйтергә белми, бусы китеп барган. Үзе бара, үзе уйлый, ди: “Эһ, рәхмәт әйтергә онытым!”

Дәресеннән соң эзләп табып, тегеңә:

— Дөрес әйткәнсез, рәхмәт!— дигән, бераз каушап.

Һәм аңардан:

— И-и, шулаймыни?— дигән сүзләрне ишеткән.— Сезне таптылармыни? Әле һаман да эзләп йөриләр иде түгелме?

— Табуын таптылар, әмма дәрес бетәргә өлгергән иде инде,— дигән бусы, бер дә аптырап бирмичә.— Мин аларны сезнең дәрескә җибәрдем.

## КУРКЫНЫЧ ЮК
*Хикәят*

Укытучы дәресен уздырыр өчен укучылары каршысына керергә куркып тора икән. Имеш, ничек теманы аңлатырмын, бигрәк тинтәкләр бит.

Шул хакта үзенең бер хезмәттәшенә әйткән. Ә тегесе аңарга бик тә яхшы киңәш биргән:

— Син сөйлә дә сөйлә, сөйлә дә сөйлә, үзләреннән бер нәрсә дә сорама!— дип.

— Аларның аңлау-аңламауларын кайдан белермен соң?— дигән бусы.

— И-и, шуңа да исегез киттеме?— дип елмайган тегесе.— Сезнең эшегез — гыйлем диңгезе булу, ә аларныкы — гыйлемегезне алу. Әгәр дә аңламасалар, борчылмагыз, гыйлемегез үзегезгә күбрәк калыр.

— Ә аңласалар?— дигән бусы.

— Ул вакытта сөенегез генә, батып үлмәсләр әле!— дигән тегесе.

## ИР ҺӘМ ХАТЫН АРАСЫ
*Хикәят*

Бер хатын үз иренә тора салып кычкыра, йорт эчендә тавыш чыгаруга бик тә маһирланып киткән икән.

Ире моңарга сабыр итеп йөргән-йөргән дә, хатынына болай дип әйтергә уйлаган:

— Хатын, синең белән нәрсә булды соң? Хәйран итәм!

— Хәйран итәсең юк!— дигән хатыны.— Бер нәрсә дә булмаганга шулай кычкырам да инде мин. Шуны да аңламагач!

Вакытлар үтә, моңарчы ефәк кебек назланган хатыны тагын чыгырыннан чыга башлый. Моны сизенеп алган ире:

— Хатын, миңа командировка-сәфәргә китәргә вакыт җитеп килә ахрысы,— ди.

Имеш, иренең тел төбен аңлап алган хатыны шунда ук шым булган.

## КӨЙСЕЗЛЕК СЕРЕ
*Хикәят*

Бер укытучының гаять тә үпкәләү хисе көчле икән. Үзе белән һични эшли алмый. Яныннан йөгереп узып баручы укучыларына да үпкәли хәтта, мине хөрмәт итмәүләре дип уйлый.

Моның бу гадәтсезлеген хезмәттәшләре дә сизенеп алалар. Коллективта андый кеше булса, җайсыз һәм уңайсыз бит инде ул, сак кына сөйләшергә, кирәгеннән артык аңарга гына хөрмәт күрсәтергә, гел дә җаена торырга туры килә.

Шуннан берсе түзми:

— Сезгә бу үпкәләү гадәтегезне ташларга кирәк,— дип, аңарга үгет-нәсихәтләрен бирергә була.— Юкса сезгә яшәве бик авыр булыр.

— Шулаен шулай да бит,— ди бу укытучы.— Әмма минем каршыда барчагыз да көемә генә торасыз, ефәк кебек булырга мәҗбүрсез. Мондый бәхеттән баш тарталар димени?

## ТАБИГАТЕНӘ КҮРӘ ГЕНӘ

*Хикәят*

Кешедә табигый сәләт булучан. Аны ул яки сизеп ала да үстерә, яисә, мөгаен ваемсызлыгы сәбәпледер, юкка чыгара һәм, файдалана алмыйча, гомере буе башкалардан көнләшеп яши.

— Син,— дип әйтә икән бер әтәчкә каз,— үзеңне әллә кемгә куеп, кикригеңне калкытып, күкрәгеңне киереп менәсең дә койма башыннан кычкырасың. Бер дә тыныч кына яшәргә бирмисең!

Әтәч моңарга карап торган да:

— Гафу итегез инде, каз әфәнде,— дигән.— Мин бит сезнең күлгә төшеп, анда чума-чума йөзмим. Хәтта бик теләр идем дә, әмма табигатемнән килмәгәнгә, коймадан да биеккә менә алмыйм шул!

## СӨЕНЕЧЛЕ ХӘБӘР

*Хикәят*

Кешедә сиземләү хисе бар.

Әмма акылы бутала башласа, бу көче тәмам томаланып кала.

Шулай бер гыйбат:

— Тиздән дөнья бетәргә тора. Әзерләнәсезме соң?— дип танышыннан сораган.

Теге исә:

— Дөнья бетәдерме-юкмы, анысын белмим. Әмма менә сезнең хәлегезне аңлыйм!— дип җавап биргән.

— И-и, минем өчен юкка борчыласыз,— дигән аңарга бусы,— көн дә фәрештәләр белән сөйләшәм. Килешенеп тә куйдык инде. Ул-бу була калса, алар мине канатларына алырга сүз бирделәр.

— Менә бит,— дигән тегесе,— дөньяны су басса да кайгырасыгыз юк, сөенеч кенә икән!

## КЕШЕ БУЛУ

*Хикәят*

Сөхбәтендә булган ирләр Яхъя казыйдан сорыйлар икән:

— Сез, хәзрәт, һаман да әйтәсез адәм баласын, әүвәле ата-анасы өчен яши, аннары калган гомерен балаларына багышлый дип. Моны ничек аңларга? Кеше үзе өчен яшәмимени?

— Нишләп яшәмәсен?— дигән Яхъя казый.— Адәм баласы бишектә чагында һаман да үзен генә кайгырта, әнкәсенең күкрәк сөтенә ябышып яши. Бишектән төшкәч тә шулай. Кулына эш алып, гамәл кылганчы... Адәм баласы эш эшли башлагач кына кешегә әверелә. Ата-ананың максаты — баланы мөмкин кадәр иртәрәк һөнәргә өйрәтү. Һөнәр адәмне кеше итә. Бала ата-ана хезмәтендә тырыша. Ата-ана өчен яшәү менә шул була да инде!

## ҺӨНӘРНЕҢ ӨЛЕШЛӘРЕ

*Хикәят*

Кеше булу өчен ике кулыңда эш уйнату да җитә, имеш.

— Ә гыйлемнең хикмәте нәрсәдә?— дигәннәр Яхъя казыйга.

— Гыйлемнең хикмәте — һөнәрдә!— дип җавап биргән ул.

— Ничек инде?

— Эш бар, һөнәр бар!— дип җавап биргән тагын да Казый Яхъя.— Һөнәрле эшне — хезмәт, диләр. Эш ул кешегә ияреп башкарыла, ә хезмәттә үзең башлап, үз уең, үз зиһенең, үз белемең, үз осталыгың белән эшлисең. Ә болар гыйлемнән башка мөмкин түгелләр. Шуңа күрә дә бер галимнән гыйлемгә өйрәнү тиешле. Күңелеңә ятканы һөнәрең булып әверелсен. Һөнәрнең җиде өлеше гыйлемнән гыйбарәт, ике өлеше — остарудан, бер өлеше — тырышудан!

## ТЫРЫШУДА ХИКМӘТ

*Хикәят*

Шулай бервакыт:

— Әгәр дә һөнәрнең асылы гыйлемнән торса, эшнең хикмәте нәрсәдә соң?— дип сораганнар Казый Яхъядан.

Ул исә:

— Эшнең хикмәте — бәндәнең тырышлыгы инде ул,— дип җавап биргән.— Шуңа күрә дә аның олысы һәм кечкенәсе бар.

— Ничек инде олысы һәм кечкенәсе?

— Эшнең көндәлек башкарыла торганы кечкенә булыр,— дигән Казый Яхъя.— Гомергә бер эшләнгәне бик олы сыман тоелыр. Ә сезнең күңелегез белән бәхәс кылып, юк, эшнең җиңеле һәм авыры гына бар дип, үзегезне сафсата утында саташтырып утыруыгыз исә эшнең куәт һәм көч таләп итүен башканы белүегезгә генә бәйле!

## ДУСЛЫКТАГЫ ГАМӘЛ

*Хикәят*

Дөньяда өч нәрсәдә исәп-хисап төгәл булырга тиеш: алган хезмәт өчен түләгәндә, алып торган акчаны вакытында кире кайтаруда, күршелек иткәндә. Ара өзек икән, дуслык та төзек була, диләр.

Әмма мин бер кешедән ишеттем, күршеләр арасында дуслык һәм татулык кына яши икән, бу бик яхшы. Шулай да ярты адымлы ызанны бүлешмәсәләр, ялгыш очып кергән тавык өчен талашмасалар, күршелек галәмәтендә хикмәт юк, имеш.

Дуслык ул бар яктан да күркәм. Тик күңелләр үзара ятышып торудан гына дуслык итүдә гамәл сыйфаты күренмәс. Күңелең ятмаган, дошманың итеп белгән кеше белән дуслык төзү исә — чын гамәл, диләр, хак булса!

## СӨЕК ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Үз кемлегеңне белү өчен яратам дип әйтүчеләр янына түгел, сөймим дигәннәр каршына барудан да яхшысы юклыгын белмәгән кеше бармы? Әмма бөтен кешенең дә үзенең кемлеген танып торасы килми. Шуңа күрә без сөям диючеләр янында йөрергә тырышабыз.

Яхъя казыйдан сораганнар:

— Дөньяда иң сөекле кешең кем?— дип.

Ул:

— Үзем!— дип җавап биргән.

— Ә иң сөексезең?

— Анысы да үзем!— дигән Казый Яхъя.

— Ничек алай?

— Гамәлемне башкалар дөрес дип тапса, үземнән дә сөеклерәк кеше юк, анда хата барлыгы күренсә, үземнән дә чиркангыч затны таба алмыйм,— дигән ул.

Ә аның сүзенә тегеләр ышанмаганнар.

## ИШ-ДОШМАН АЕРМАСЫ

*Хикәят*

Адәмгә хәсрәтен җиңәр өчен булышка дуслары килә. Шулай тиеш санала. Дөньяда моннан да олырак әдәп юк, диләр.

Бер кеше зур хәсрәткә төшүеннән башын салындырып утыра. Моның янына Шайтан килә дә, янәшәсендә урын алып:

— Нәрсә, хәсрәтеңне бүлешергә беркем дә килмәдеме?— дип сорый.

Бу кеше исә, авыр сулап:

— Килмәде дип, менә син янымда утырасың!— ди.

— Мине исәпкә кертмә!— диярәк, Шайтан көлеп куя.— Мин бит синең дошманың, ишең — адәм баласы түгел. Кайгыңны уртаклашырга үз ишләрең

килә, минем төслеләр исә, нәрсә, хәсрәт чигәсеңме дип, күреп куану өчен генә йөриләр.

## НЫКЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕ

*Хикәят*

Кешене кайгы кайчысы телемләп кисә.

Шулай бер кеше, авыр бәлагә таргач, чарасызлыктан үксеп елый да елый икән. Якыннарының да юатыр чамалары юк. Әйткән сүзләре моны тынычландыра алмый.

Шуннан берсе, киңәш биреп:

— Ул кадәр кайгыга бирелергә ярамый, олы сагыш, юкса, үзеннән дә куәтлерәген дәшеп китерүчән була,— дигән.

Аңа каршы бу кеше:

— Кайгының моңардан да олысы булмый торгандыр инде,— дигән.

Киңәш бирүче исә:

— Кайгының олысы-кечесе адәм баласының аларны ничек кабул итә белүләреннән тора,— дип аңлатып биргән.

Шуннан соң гына кайгылының хәсрәте киткән, диләр, хак булса.

## ХӘСРӘТ УРТАКЛАШУ

*Хикәят*

— Син алай ук кайгыга бирелмә. Вакыт савыктырыр, сабыр ит,— дигәннәр дуслары, хәсрәт газабының утында янучы адәмгә.

Ул үзе дә боларны гына белә, әмма сабыры сына да китә, сына да китә, бәгыре кайнар канлы яшь белән тула икән.

— Нигә соң ул шушы кадәр күп хәсрәтләнә?— дип, халык аңарга аптырый икән.— Сәламәтлегенә зыян китерүе бар!

Арадан берсе әйткән:

— Гамь–хәсрәт камчысын мөэминнәр җанының госеле дип беләләр. Тимәгез, аңа бары тик сабырлык кына теләгез. Ул арабызда иң саф күңелле затларның берсе булырга кирәк. Аның хәсрәте белән без дә гамь чигик, шулай хәле җиңеләймәсме, җаныбызга сафлык иңмәсме?

## ЕЛАННАР АРАСЫНДА

*Хикәят*

Бер яхшы кешенең гаме мең бәндәнең кайгысына әверелә, яманның хәсрәте һичкемне борчымый, имеш. Адәм балалары үзләренең яхшымы-яманмы булуларын шундый чакларында гына белә алалар.

Бер кеше кайгы чокырында ялгызы калган. Хәлен дә сораучылар юк икән. Бу үзенең кемлеген шунда гына аңлап алган. Хәсрәте тагын да арткан. Аның кайгысына таныш-белешләре сөенә, имеш.

Ә беркөнне аңа ерак карендәше килгән. Хәлен төшенеп:

— Ул гамең — гамь түгел икән, менә бу таныш-белешләрең эчендә йөрүең зур кайгы. Болар бит мыжгып торган елан оясы,— дип аңлатып биргән.— Синең кебек саф энҗене йотарлар иде, әмма тешләре үтми! Шунлык белән генә яшисең!

## ЧАРАСЫЗЛЫК ЧАРАСЫ

*Хикәят*

Бер сәях, юлда барганында адашып, чаяннар белән тулы чокырга егылып төшкән. Болар аны чолгап та алганнар. Тегенең кая барырга да чарасы юк икән. Урынында сикергәли башлаган. Шунда кесәсендә шырпы барлыгын аңлап алган да, кабы белән чыгарып, берәмләп кабызган һәм аяк астына ташлаган.

Чаяннар уттан куркалар, имеш.

Шунда моның чалбар балагы яна башлаган, тәне пешүдән шундый итеп кычкырып җибәргән ки, кинәт сикерүе булган, чокыр эченнән өскә атылган. Аннары чалбар балагына туфрак сибеп утны сүндергән дә әйткән:

— Бер чарасызлыктан икенче чарасызлык кына коткара ала икән, башка һичкайдан ярдәм килмәде!

## НИЧЕК ТӘ ЯРАП БУЛМЫЙ

*Хикәят*

Институтта укучылар имтиханда икән. Бик әшәке бер профессор рәттән диярлек һәммә студентка “Икеле” билгесе куеп бара. Соңарып кына ахыргы студент та килә. Кызыксына:

— Нәрсә сорады?— ди.

Елап торган бер студент кыз әйтә:

— Син кияүдәме?— диде.

— Ни дидең?

— Кияүдә, дидем!

— Ничәле куйды?

— “Икеле”!

— Ярар алайса, мин үземне кияүдә түгелмен дип әйтермен!

— Алай дип әйтеп караучылар да булды, әмма “Икеле”дән узмадылар!— ди теге студент кыз, аңлатып.

— Һе,— дия бусы,— аңарга без дә ярамагач, кем кирәк икән соң, мескенкәем?

## МИСАЛ ИШАРӘСЕ
*Хикәят*

Студент кыз имтихан бирергә профессор каршысына керә. Билет ала. Әзерләнергә утыра...

Менә моның да җавап бирү чираты килеп җитә. Профессорның зәһәр булуын белә, дулкынлануын яшерергә теләп ашыкмыйча гына сөйли. Бер сорауны үтә, икенчене, өченчене. Шулай җавап биреп бетерә. Профессор эндәшми. Билге куясы итә. Шунда бу студентка:

— Абый, сорамадыгыз бит әле!— дип әйтә.

Профессор исә, аптырап:

— Нәрсәне?— ди.

— Минем кияүдәме-юкмы икәнлегемне!

— Ә-ә,— дип көлә башлый профессор,— сездән сорап та торасы түгел.

— Ни өчен алай?— ди студент кыз.

— Чөнки предметны болай да яхшы беләсез. Мисал китереп ишарә итәсе дә юк!

## КОЛХОЗ КАЯ?
*Хикәят*

Юләрләр йортына бер колхозчыны алып килгәннәр. Табип сорый икән:

— Моны нәрсә дип китердегез? Монда бит Наполеоннар, Брежневлар, Сталиннар гына бар. Колхозчыларның булганы да юк иде!— дип.

Китерүчеләр әйтә ди:

— Бу агай бездән ничә ел инде колхозны таптыра. Кая куйдыгыз дип сорый. Минем бабам, колхозга кергәндә, дүрт тегермән, унбиш сыер, егерме биш баш сарык, өч җигүле ат белән кергән. Аларны кая куйдыгыз? Кайсыгыз аларны үзләштерде? Колхоз таркалды, дисез, нигә кайтарып бирмисез дип бәйләнә. Шуңа күрә китердек!— диләр.

## ӘТИГӘ ӘЙТӘМ
*Хикәят*

Мәктәптә укытучы бер томана балага “Икеле” утырта. Тегенең ачуы килә дә әйтә:

— Әти белсә, кирәгеңне бирә инде!

Укытучы да аптырап тормый:

— Килеп, биреп карасын әле!— ди.

Томана:

— Һе,— дип белдерә кабат,— бик сөенер идегез, әйеме?

Укытучы:

— Әйе шул,— ди,— Миңа нәрсә кирәген каян белдең?

Томана:

— Апа, күренеп тора бит!— ди.

Укытучы көтмәгәндә кып-кызыл була, буй-сынын төзәтә, итәкләрен сыпырып куя, басып торган җирен онытa. Шунда теге томана укучы:

— Юк әле, этигә әйтмим, болай интегүегез миңа күбрәк ошый!— дип әйтеп куя.

## БАШЫ ҖИТМӘС ИДЕ

*Хикәят*

Ике гыйбат сөйләшеп утыралар. Берсе, тормышка зарланып:

— Бу ил хуҗаларының бозылуы җитте, халыкны таякка калдырганчы талыйлар,— дип әйтеп куя.

Аңа икенчесе кушыла:

— Анысы гына әллә нәрсә түгел, менә безнең күрше ул, безнең күрше!— ди.

Тегесе, аптырап:

— Сезнең күршегә нәрсә булган? Әллә ил башыннан да өстенме?— дип сорый.

— Булыр-булыр, ил башыннан да өстен булыр,— дип зарлана тегесе,— атасыннан да уздырды әле ул, бик беләсең килсә. Бәрәңге бакчама ярты ызан кереп бәрәңге утырткан. Әйтеп карадым. Казып ал да күчер, диде генә. Менә бит малай, кеше нәрсәләр кылана. Ә син ил башы, дисең. Моңа аның башы җитмәс иде.

## САТЫЛУЧЫ КӘЕФ БӘЯСЕ

*Хикәят*

Бер адәм кәеф сатып утыра икән, янына икенче берәү гамь эчендә килә. Җәйге вакыт, көн кояшлы, эссе.

Беренчесе:

— Бүген кичкә кар яварга охшый,— дип әйтеп куя.

Икенчесе:

— Шул гына җитмәгән иде!— ди.

Беренчесе:

— Болытлар куера башлады да инде, суык җиле дә исеп куйды,— дип сөйләнә.

Икенчесе күккә карый, анда — чалт аяз, уңын-сулын бага, сөяккә үтәрлек эсселек. Шуннан:

— Нинди ахмак сүз әйтәсез. Кайдан болыт таптыгыз? Бу утыз градуслы эсседә нинди кар яусын, нинди суык җил? Әллә сез юләрме?— дип көлә башлый.

Шунда беренчесе:

— Юләрдерме-юктырмы, анысын ук белмим. Әмма сүзләрем берәүнең болытларын таратыр өчен җитте,— дип әйтеп куя.— Кәеф сата идем әле!

## ИШӘКНЕҢ ДОГАСЫ

*Хикәят*

Адәм балалары арасында шундый да акыллылары бар ки, алар үзләренең булдыклы, әдәпле, гыйлемле булулары белән таңга калдыралар.

Менә шундый берәүне дәүләт эшенә чиновник буларак чакырганнар. Ул баш тарткан. Әмма аның холкы нинди икәнлеген сизенеп өлгергән хуҗа кеше, гомерендә беренче тапкырдыр, мондый доганы укып, Аллаһы тәгаләгә рәхмәтен җиткергән:

— Йа Ходаем, минем ахмаклыгымны гафу ит, үзем теләп туфан суына чактан гына гарык булмыйча калдым!— дип.— Ярый әле Үзең миндәй мескен бәндәләрең ягында! Юкса шушы кадәр мәртәбәләргә ирешеп тә мизгел эчендә урындыгымнан колак кагасы идем. Ишәкләрең күбрәк буласы иде! Аларга дан һәм хөрмәт насыйп ит! Акыллылардан сакла!

## ЧИБӘР ХАТЫН БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Бер адәм үз бәхетенә үзе сөенеп бетә алмый икән:

— Йа Ходаем, рәхмәт яугыры, миңа шундый чибәр хатын бирдең! Сөеп тә туя алганым юк! Мине көнчелек утыннан сакла, күзләрем сукыр, колакларым саңгырау булсыннар!— дип.

Аңа дусты:

— Нигә үзеңә шушы кадәр яманлыклар телисең?— диярәк сорау белән мөрәҗәгать иткән.

Бу кеше исә:

— Үзең дә беләсең, чибәрлек — халык байлыгы. Хатыным бик чибәр, аңа һәркемнең күзе төшәр, кызыкмый калмаслар. Менә шул хакта уйлыйм да хәсрәт чигәм. Хатынымны башкалар кочсалар-үпсәләр дә күзем күрмәсен, колагым ишетмәсен дип тырышам. Юкса, сукыр да, саңгырау да буласым килми чынлыкта!— дип җавап биргән.

## ШАЙТАН ХОЛЫГЫ

*Хикәят*

Адәмгә тәкәбберлек чире йоккан. Һичкемне танымый һәм санламый башлаган. Хәтта аралашыр дуслары да калмаган. Аның болайга үзгәрешен күргән туганнары:

— Тәкәбберлегеңне ташла, юкса ул сине харап итәр!— дигәннәр.

Бу кеше исә:

— Бик ташлар идем дә, әмма бөтенләй дә буш калуымнан куркамын,— дип җавап биргән.

Хәленә керә алмаганнар. Туганнары һаман да ачулануларын дәвам иткәннәр:

— Шушы тәкәбберлегең аркасында кешелегең дә калмады бит инде!— дип.

— Әйе,— дигән бу адәм,— тәкәббер кеше — Шайтан ул. Бик яхшы беләм. Әмма Шайтан адәмнән курыкмый, Шайтанның котын Шайтан гына ала. Шуңа да мин Шайтан кебек кыланмакчымын!

## ХОЛЫК ЯМАНЛЫГЫННАН ФАЙДА АЛУ

*Хикәят*

Бер кешенең холкында авыру барлыкка килгән: бер дә галәмәт үпкәләүне гадәте иткән.

— Син нишләдең, нәрсә булды холкың белән?— диләр икән дуслары аңарга.

Бу, аңлап алып:

— Ә-ә, сез минем тора салып үпкәләү гадәтемне әйтәсезме?— дип сораган.

— Әйе,— дигәннәр.

— Һи, белмисез сез,— дип җавап биргән бу кеше,— хәтта юкка-барга үпкәләү дә саклыкка акча салып тору кебек файдалы бер гамәл ул. Моңа кадәр һичкем мине санга сукмый иде, менә хәзер барысы да, ниндилегемне белеп алгач, сак сөйләшүне кулайрак күрә башладылар, үпкәләвемнән куркалар. Сезгә дә шуны киңәш итәм. Сак күңел — саф холык кебек ул!

## АКЫЛ САТУ

*Хикәят*

— Безнең Хисмәт ага гел акыл сатарга ярата!— дип мактана бер бала, атасы каршында.

— Әйе шул,— ди әтисе,— бик дөрес әйтәсең. Үзенә кирәк булмаганга сата ул аны.

— Ә нигә?— дип аптырый малай.— Ул бит районда түрә булып эшли. Андый урында акыл кирәкмимени?

— Һе,— ди әтисе,— әгәр дә андый урында акыл кирәк икән, башкаларга аны сатып утырмас иде. Үзенә кирәк булган әйберне берәү дә базарга чыгармый, улым!

— Аңладым,— ди малай,— тагын да югарырак менү өчен Хисмәт агага акылы комачау итә торгандыр. Ул аны шуңарга күрә башкаларга сатарга булган, әйеме, әткәй?

## ЮЛӘРЛЕК ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Дөрес сүз — баш казасы, диләр...

Бер кеше дөресен сөйли, аны тыңлап торучылар гүяки егыла-егыла, тәгәрәшеп китеп көләләр икән. Бу адәм аптыраган:

— Сез нәрсә эшлисез? Мин бит бары тик дөресен генә сөйлим, дөресен! Моның өчен еларга кирәк! Ә сез — көләсез! Әллә ычкындыгызмы?— дип сораган.

— Анысы да бик булырга мөмкин,— дигәннәр аңа җавапларында башкалар,— син үзең дә бит “норма”га сыешлы түгел!

— Ни өчен?— дип аптыраган бу.— Мин бары тик дөресен генә сөйлим бит!

— Дөресен сөйләгән кеше,— дигәннәр аңа,— чын тиле, юләр була да инде ул. Без синнән шуның өчен көләбез. Ялган сөйләсәң, бик тә җитди булып тыңлар идек әле!

## СӘНГАТЬ КӨЧЕ

*Хикәят*

Тамашага бер байгура килгән. Карап утыра бу, хәсрәт чигеп сорый:

— Болар кемне күрсәтәләр соң?

Янындагылар эндәшми. Бу исә тагын сорый. Һаман җавап юк. Кабат әйтә:

— Болар мине күрсәтәләрме соң?

Берсе түзми:

— Нишләп сезне булсын?— ди.— Казан шәһәрендә бетмәгән бит башкалар да. Шуларның берәрсен күрсәтәләр инде.

— И,— дип белдерә бу байгура, кәефе тәмам бозылып.— Мин әле үземне күрсәтүләренә ышанып карап утыра идем. Тамашаның һичбер кызыгы калмады.

Янындагылар, аны ачуланып:

— Нәрсә, безнең турыда булгач, карыйсыгыз килмимени?— диләр.

Бу исә:

— Әйтәм җирле бу юләрләр бик тә таныш кебек күренәләр!— дип әйтеп, канәгатьлек белән авызын ера.

## КҮҢЕЛ КҮЗЕ АЧЫЛУ

*Хикәят*

Күңелендә ниләр барын кеше үзе дә белеп бетерми, имеш.

Казый Яхъядан сораганнар:

— Күңел күзе кайчан ачылыр?— дип.

Ул исә, ике дә уйлап тормыйча:

— Кайсы кешенеке бөтенләй дә ачылмый калырга мөмкин!— диярәк җавап биргән.

Тыңлап торган халык, бу безне күздә тотадыр инде дип үпкәләмәкче икән, арадан берсе:

— Минем күңел күземне нәрсә ачачак соң алай булгач?— дип сораган.

Казый Яхъя исә:

— Төгәл менә сезнең күңел күзегезне нәрсә ачар, анысын ук белмим, әмма минем күңел күземне яхшы гыйлем ачты, юк-бар сүз пәрәнҗәсе томана итте,— дип әйткән.— Сез дә, гыйлем эзләсәгез, буш эш белән шөгыльләнмәгез!

## ДӨЯ МИСАЛЛЫ

*Хикәят*

Бер шәкертен даими китап өстендә күргән Казый Яхъя, аны эшеннән бүлдереп:

— Бу китаптан нәрсә таптың?— дип сораган.

Теге исә болай дип сөйләп җавап биргән:

— Дөя турында укыдым. Су янына килгән дә сугарылмакчы булган, әмма бер этне күреп, бу минем эчә торган суымны нәҗесләде дип китеп барган.

— Моннан нәрсә аңладың соң?

— Моннан эт дигән хайванның суны нәҗесләвен аңладым,— дигән шәкерт.

— Алай икән,— дигән Казый Яхъя,— син үзең дә нәкъ шушы дөя сыйфатында икәнсең! Гыйлем дәрьясыннан җаныңны сугарасы урынга, иренеңә дә тидермичә, коры калгансың!

## КИТАП СЕРЕ

*Хикәят*

Кәтип димәктә борынгылар язучылык белән шөгыльләнгән адәмне күздә тотканнар.

Шулай бер кәтип китап бетекләп утыра икән, янына сәүдәгәр килеп:

— Язуың чибәр күренә, миңа да берәр китап сатмассыңмы?— дип сораган.

Кәтип аңа карап торган да бизәкләр белән чуарланган бер китапны киштәсеннән алып биргән. Сәүдәгәр исә, аны актарып чыккан да:

— Монда язулары бик аз икән бит,— дип канәгатьсезлек иткән.

— Сез бит үзегез,— дигән кәтип,— язуымның матурлыгын мактадыгыз. Шуңа күрә бу әфәндегә чәчәкле-чуклы китап кына ошыйдыр, миннән ул шундыйны гына сорыйдыр дип уйладым. Әгәр дә сүзләрнең мәгънәсен мактасагыз, андые да бар иде, шул китапны тәкъдим иткән булыр идем.

## БЕР ЯРАТУ — БЕР ГОМЕР

*Хикәят*

Яшьлектә мәхәббәт хисләрендә яну табигый хәл инде ул.

Шулай бер егет үлеп-бетеп гашыйк булган. Сөйгән ярын даими уйлап, саташып йөри икән бу. Халыкта гайбәте таралган. Моңардан мыскыллап көлүчеләр дә табылган.

Ә кыз башка берәүне ярата икән, шуңа кияүгә чыкмакчы, ди.

Туй итәргә җыеналар.

Егет, бу хакта ишеткәч, кызга мәхәббәтендә янып, хәсрәтеннән котылу өчен суга батарга дип бара икән, юлында аңарга бер бала очраган һәм:

— Кая киттегез, абый, болай?— дип сораган.

— Гарьлегемнән батып үлмәкче булып барам әле,— дигән дивана гашыйк.

— И абый,— дигән теге бала,— әти әйтә, бер ярату — бер гомер, ди. Сиңа — рәхәт! Минә минем атайга нишләргә? Яшәп тә карамадым әле, ди.

Егет боларны ишеткән, сүзләренең мәгънәсен аңлап алган да елмаеп җибәргән һәм өенә кайтып киткән. Әле һаман да авызы ерык хәлдә йөри, имеш.

## НАМУС КҮТӘРӘ АЛГАНЧА

*Хикәят*

Казый Яхъяны мәхәллә халкы аптырата:

— Менә син Аллаһыны гадел дип әйтәсең. Ни өчен соң, шушы кадәр гадел булгач, берәүләрнең тормышы янган учак эчендәге газап кебек, икенчеләрнеке гөлләр бакчасындагы күбәләкләрнекедәй хәсрәтсез?— дигәннәр.

Казый Яхъя исә:

— Аллаһының гаделлеге шунда,— дип җавап биргән.— Ул һәркемгә намусы күтәрә алган хәтле генә бирә!

— Газап белән намус арасында нинди бәйләнеш булсын?— дип, халык шаулаша башлаган.

Шунда Казый Яхъя:

— Ярлылар байлыкның нинди олы газап икәнлеген белсә, байлар ярлылык газабын аңласа, Аллаһыга гадел булуы кирәк тә булмас иде,— дигән.

## ДИН УЛ ГАДӘТ КЕНӘ

*Хикәят*

Мөэминнәр бәхәс кылалар:

— Мәгәр дөнья йөзендәге һәммә диннәр дә Аллаһының берлеген һәм барлыгын таныса, алар мөселманмы?— дип.

— Әлбәттә мөселман,— ди Казый Яхъя,— әмма Аллаһыга шәрик кушу белән иманнары төзек түгелдер, шуңа күрә җаннары да авыру.

— Без аларның җаннарын савыктыра алабызмы? Чарасы нәрсә?— дигәннәр мөэминнәр.

— Әлбәттә һәр авыруның дәвасы булмый калмый,— дигән Казый Яхъя,— әмма алар Аллаһыга шәрик кушып гадәтләнгәннәр. Барыгыз да беләсез, чөнки ул сезнең сүзегез: “Чир — китә, гадәт — кала!” Авыру узса да гадәте кала.

— Әйе,— дигәннәр мөэминнәр,— чыннан да шулай: чир — китә, гадәт — кала! Дин ул гадәт кенә!

## БҮЛМӘЛӘР СЕРЕ

*Хикәят*

— Адәм җанында өч бүлмә бар,— дигән Казый Яхъя.— Аның берсендә нур торыр, икенчесендә — караңгылык. Алар икесе дә бер-берсенә һичкайчан кушылмаслар һәм бер-берсеннән аерылмаслар. Караңгылыкның хикмәте гыйлемне сеңдерүдәдер, нурның хикмәте йөз аклыгында булыр. Әдәпсез кешеләрнең нур сарайлары җимеректер.

— Ә өченчесе нәрсә?— дип сораганнар сүзнең озынын яратмаучы кешеләр.

— Анысы,— дигән Казый Яхъя,— бушлыктыр. Ул нурдан да, караңгылыктан да мәхрүм. Анда мәхәббәт сандугачы да оя корырга мөмкин, нәфрәт ябалагы да кереп утыра ала. Әмма аны Аллаһы тәгалә үзе өчен махсус бар кылган. Аны иманың бүлмәсе итүдән дә яхшысы юк!

## СҮЗ ҺӘМ ГАМӘЛ

*Хикәят*

— Иманның нигезе ни өчен сүздә дип әйтәсез, хәзрәт? Сүз бит ул әйтелә дә бетә. Гамәлдә дияргә кирәк иде!— дигәннәр Казый Яхъяга халыкның акыллылары.

— Һәм дөрес,— дигән ул да.— Әмма адәм баласының хикмәте теленә чыга, сүзе нинди — күңеле дә шундый. Җаны адашучылар — сүздә дә туры булалар. Кеше дөнья йөзендәге һәммә җан ияләреннән сүз сөйләшә белүе белән аерыла. Һәммә зиһене барның күңелендә сурәт туа, әмма ул аны сүзгә әйләндерә алмый. Ә адәм моңарга бик тә маһир, шуның белән хәтта үзара да аерылып торалар. Ә гамәл исә иманның рәвеше ул! Ягъни сурәте гамәлдә күренер.

## ҖЫР ЧЫГАНАГЫ

*Хикәят*

Сандугачлы бакча табып, бер кеше үз җанын бик тә озак хушландырган. Дөньялыкның ямен тоя башлаган. Шунда, сандугачны күреп:

— Бу кадәр моң рәхәтлеген син кайдан аласың?— дип сораган.

— Күңел түремнән алам!— дигән сандугач.

— Чыннан да шулай булса,— дигән адәм, зарланып,— минем дә күңелем бар бит, буй-сыныма караганда, синекеннән күпкә зур күренә, әмма мондый җырлар чыгара алганым юк.

— И адәм,— дигән сандугач,— җыр бит күңелнең зурлыгына-кечкенәлегенә бәйле түгел. Күңел үзе кечкенә генә булса да, аңа менә бу, аңардан никадәр зуррак һәм олырак дөнья да сыеп бетә ала. Җыр исә күңел кылларының нечкәлегенә бәйле, шулай түгелме?

## МЕҢ САВАПЛЫ ГАМӘЛ

*Хикәят*

Адәм бер чишмә янына килеп туктаган. Шундый да челтерәп, суларын йөгертеп ага икән бу, дымыннан хуш исләр күтәрелеп тора.

Адәм түзмәгән, суны учларына алып эчкән. Җаны хушланган. Аннары әйткән:

— И чишмә, рәхмәт сиңа, мине сугардың!— дигән.

Шунда чишмә телгә килгән:

— Сез, кешеләр,— дигән ул,— бер коры рәхмәт белән генә котыласыз. Югыйсә мин сезгә ничә хезмәтне берьюлы күрсәттем: хуш исем белән борыннарыгызны сафландырдым, челтерик җырлы тавышым белән колакларыгызны, күркәмлегем белән күзләрегезне, суым белән зиһенегезне! Ә сез үзегез, бер гамәл башкарып, аңардан тау кадәрле файда өмет итәсез!

## АНА БЕЛӘН БАЛА

*Хикәят*

Уен уйнап йөргән баланы өйләренә әнкәсе чакыра.

Малай:

— Әни, хәзер кайтам!— дип вәгъдә итә, “бераз гына, бераз гына уйныйм да” дия-дия тагын онытылып китә.

Әнисе кабат чакыра.

Малай:

— Хәзер кайтам!— ди. Әмма тагын оныта.

Әнкәсе кабат аны чакыра чыга.

Улы:

— Хәзер-хәзер!— ди.

Шулай көн үтеп китә. Кичен улы, караңгы төшкәч кенә, өенә кайта. Ашарга сорый. Аның алдына әнкәсе салкын бәрәңге боламыгы китереп куя. Улы җылытып бирүне сорый.

Әнкәсе:

— Чакыргач та кайтсаң, җылы була иде,— ди.— Моннан ары соңга калып йөрмәссең!

Ә малай киреләнә:

— Ярар әни,— ди,— моңардан соң инде кайтып та тормамын!

— И улым,— дигән шунда аптырашлы әнкәсе,— рәхмәт яугыры, бигрәкләр дә акыллы икәнсең!

## КӨЛКЕ КАПЧЫГЫ

*Хикәят*

Бер кеше, төнлә кайтышлый, урман аша үтәргә мәҗбүр булган. Айлы, тыныч, җәйнең рәхәт вакыты бу.

Каршысына Шүрәле килеп чыккан һәм:

— Әйдә кети-кети уйныйбыз!— ди икән, бармакларын шалтыр-шолтыр китереп.

— Әйдә,— дип әйтә икән бу кеше, куркып калуын сиздермәскә теләп.— Әле генә бер Шүрәле белән кытыклашкан идем.

— Ничек?— дигән Шүрәле, аптырап,— нәрсә булды соң аның белән?

— Белмим, әллә көлә калды, әллә елый. Төгәл генә әйтә алмыйм. Әмма көлке капчыгымны өйдә онытып йөрүемә ачуланды,— дип, ул кеше, бер дә каршылык күрмичә, үз юлы белән китеп барган.

## ИКЕ “САРЫК”

*Хикәят*

Адәмдә сәер гадәтләр булучан. Шуларның берсе — җырлау, имеш.

Шулай бер агай атлы арбада урман аша бара икән, курыкмау өчен җыр сузып җибәрә. Ул да түгел, арбасына, нәкъ аның янына Шүрәле сикереп менеп утыра. Агайның өрәге кача. Шым була.

Шүрәле:

— Нигә җырыңны туктаттың?— дип сорый.

Агай эндәшми.

Шүрәле:

— Әйдә, җырла инде!— дип юмалап карый.

Әмма агай һаман да телсез.

— И-и, мин сине адәмгә санаган идем,— ди Шүрәле, хәйран итеп,— әмма син дә минем кебек сарык кына икәнсең!

Һәм арбадан төшеп кала.

Шунда гына, адәмнең коты кайтып:

— Мин сине Шүрәле дип уйлаган идем, дөрес әйтәсең, урман сарыгы гына икәнсең,— ди дә атын чыбыркылап йөгертә башлый.

## ГАЛИМНӘР МӘҖЛЕСЕНДӘ

*Хикәят*

Галимнәр мәҗлесе наданнар өчен газап урыны, имеш.

Шулай бер ишәкне галимнәр мәҗлесенә чакырганнар. Сыйланып кайтам әле диярәк, бу анда барырга була.

Мәҗлес башланып китә. Галимнәр әле берсе, әле икенчесе сөйлиләр дә сөйлиләр. Ишәк тә тыңлап утыра, боларның сүз мәгънәсенә генә төшенә алмый. Аптырагач:

— Сүз күп булды инде, саламны кайчан китерәләр?— дип сорый.

— Нишләр идегез салам белән?— дип, соравына сорау кайтаралар.

— Ашар идем дә ятып йоклар идем,— дип, ишәк ихластан сузылып һәм кирелеп куя.

## ИТАГАТЬ СӘБӘПЧЕСЕ

*Хикәят*

Казый Яхъяга мөэминнәр әйткәннәр:

— Аллаһы тәгалә безгә байлыкны намусыбыз күтәрә алган кадәр бирә, дидегез, күп итеп бирсә, күбен дә, бик күп итеп бирсә, аларын да күтәрә алыр идек әле!— дигәннәр.

Чөнки мөэминлекнең сәбәбе — киләчәктә аларга Аллаһы тәгаләнең чиксез байлыклар бирүе, намусларын шушыңа әзерләтүе, имеш.

Бу сораулыларны тыңлап торганнан соң, Казый Яхъя аптырап калган һәм, бераздан:

— Сезнең бу рәвешле намусыгыз түгел, нәфсегез сөйли,— дип җавап биргән.

Мөэминнәр ризасыз калганнар. Әмма араларыннан берсе:

— Нәфсебездән намусыбызның аермасы нәрсәдә соң?— дип сорагач:

— Аермалары шунда,— дигән Казый Яхъя,— нәфсе һәммә нәрсәгә кодрәтем җитә дип лаф орыр, намус исә итагать чикләреннән чыга алмас!

## БӘХЕТЛЕ БУЛЫЙМ ДИСӘҢ

*Хикәят*

Бер дус икенчесеннән бәхет сорап торырга булган. Тегесе аның гозерен тыңлап бетергән дә:

— Нишләр идең аның белән?— дип аптырап калган.

— Бәхетегезне биреп торсагызмы, нишләргә икәнлеген белер идем, анысы,— дигән бусы.— Иң әүвәл йортымның түбәсен төзәттерер идем, аннары яңа капка эшләттерер идем, аннары... Күп инде, озаккарак биреп торсагыз иде!

— Ярар,— дигән дусты,— биреп торырмын. Әмма минем, иң әүвәл, киңәшем бар. Шуны тотарсың!

— Әлбәттә тотармын,— дигән бусы.— Нинди киңәш ул?

— Һәммә кешедән иртәрәк торып, ике кулыңны да һәр көнне эшкә җигәрсең! Әйе дисәң, бәхетемне сиңа ышанып биреп торырмын! Юк исә, гафу ит, минем бәхеттән сиңа файда булмас!

## НАМУСНЫҢ КЕЧЕРӘЮ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Хакыйкатьтә адәмдә нәфсе белән намус ярыша алалар, имеш.

Шушы хәбәргә тап булган мөэминнәр Яхъя казыйдан сораганнар:

— Менә без, морадыбызны киң тотып, тагын да күбрәк байлыкка ирешү өчен көч куябыз. Инде генә байлыклар кулыбызга керде дигәнебездә, алар артыгы белән, гүяки элекке тапканнарыбызны да үзләренә ияртәләр дә, кулыбыздан агып кына чыгып китәләр. Хикмәт нәрсәдә?— дип.

— Сезнең эзләгән хикмәтегез нәрсә икәнлеген әйтә алмыйм,— дигән Казый Яхъя, туры җавап бирмәгәндәй аларның авызларын салындыртып.

Әмма бераздан сүзләрен дәвам иткән:

— Мин үземдә моны тәҗрибә кылып карадым. Байлыкка өметебезне тотып, нәфсебезне хәйран котыртабыз. Ә намусыбыз, нәфсе алга чыкса, кечерәеп кала. Ә байлыкны Ходай тәгалә намус күтәрә алганча гына бирә дидек бит, әйеме? Намус никадәр кечкенә, ул шул кадәр күпне күтәрә, ягъни, шул кадәр үк нәфсегә күбрәк юл куя. Бәс шулай икән, өстенә өелгән ул байлыкларны, көченнән килмәгәч, ташлап калдыруы бер дә сәер хәл түгел. Ә байлык белән намусны бастырып үтерүдән ни файда?

## БӘХЕТ СӘБӘПЧЕСЕ

*Хикәят*

Ике нәрсәдә бәхет юк, имеш. Берсе — өметең киселүдә, икенчесе — нәфсең тыела алмаудан.

Бу мәсьәләдә хәбәрдар булган мөэминнәр Казый Яхъядан сорыйлар:

— Бәндәдә бәхетнең артык калган вакыты бармы?— дип.

— Бәхетнең кемдә һәм кайчан артык булганы бар?— дигән ул, сорауларына сорау белән.

— Андый кешене очратканыбыз юк, әмма бәхетсезлектән зар-интизарлар күп,— дигәннәр аңарга.

— Ә тормыштан тую үзе үк бәхеттән тую түгелме соң?— дип тагын да сораган ул.

Мөэминнәр эндәшмәгәннәр.

— Тормыш корып яшәү үзе үк бәндә өчен бәхет түгелме?— дип, сорау белән сүзен тәмам иткән ул ахырда.

## БӘХЕТ МИКЪДАРЫ

*Хикәят*

Мөэминнәр бер көнне, Казый Яхъяга килгәннәр дә:

— Сине дөньяда бик гыйлемле зат дип әйтәләр. Соравыбыз бар. Бәхетнең үлчәү берәмлеге бармы?— диярәк сораганнар.

Казый Яхъя аларга җавап биргән:

— Бәхетнең берәүләр азы белән дә канәгать, икенчеләренә күбе дә аз сыман тоела. Димәк аның үлчәү берәмлеге азлыкта да, күплектә дә түгел, бәлки бәрәкәтендәдер!

— Алайса белик, бәкәрәкәтенең микъдары ничек?— дигәннәр тагын да мөэминнәр.

— Бәрәкәтенең микъдары теләкнең азлыгында, моратның зурлыгында,— дип җавап биргән Казый Яхъя.— Ягъни, болыттан төшкән яңгырдан соң кинәт җил чыгу яки кояш кыздыру бәласе килмичә, һава дымланып берничә сәгать тору мисалындадыр.

## ЭШНЕҢ ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Шөрепләре бушаган бер адәм табипка барган. Теге аның бөтен җирләрен тикшергән һәм вакытында йокларга, сәгате җиткәндә генә ашарга киңәш итеп кайтарган. Бу кеше әйтелгәнне үтәүчән икән. Нәкъ шулай эшләгән. Әмма шөрепләре ныгымаган. Зар белән Казый Яхъяга килгән. Барысын да сөйләп биргән.

— Табипның монда гаебе күренми,— дигән Казый Яхъя.— Сиңа тимерчегә барырга кирәк иде.

— Ни өчен?— дигән теге зар иясе, аптырап һәм ачуланып.— Мин бит тимердән түгел!

— Син аның нинди авыр хезмәт башкаруын күрер идең. Ул көне-төне эшли дә эшли. Шул кадәр авыр һәм күп эшләп тә гаиләсен көчкә-көчкә генә туйдыра. Шөрепләрен бушатып йөрергә вакыты да калмый,— дигән Казый Яхъя, зарлының сихәтенә юл күрсәтеп.

*03.03.06.*

## ХӘРӘМДӘГЕ ХӘЛӘЛ

*Хикәят*

— Дөньяда адәм балалары арасында бик начар гамәлләр бар. Шуларның берсе — әләк! Сез, хәзрәт,— дигәннәр Казый Яхъяга килгән мөэминнәр, зар кылып,— бар нәрсәне дә Аллаһы тәгалә генә бар кылганын, әмма яман гамәлләргә бәндәләрне Шайтан өйрәткәнен әйтәсез. Иманыбыз какшамасын, раслагыз: әләкне Шайтан бар кыла алмады, чөнки анда ул кодрәт юк! Аллаһы тәгалә ни өчен әләкне насыйп итте, әләк ни өчен бәндә өлешенә тиде?

— Әләкне дә Аллаһы тәгалә бар кылуда шик юк,— дигән, бераз уйдан соң Казый Яхъя.— Әләкчеләр алар урмандагы бүре сыйфатында, күктәге козгын мисалында. Үзләре үләксә ашарлар, әмма хәрәм ризык җыюларын белмәсләр. Әгәр дә алар болай эшләмәсә, кешеләр әллә кайчан тәмам бозылып, шакшыга чумып бетәрләр иде!

## "ШАЙТАН ЧЫБЫРКЫСЫ"

*Хикәят*

Мөхәммәд пәйгамбәребезнең хәдисләреннән булган: "Шигырь ул — Шайтан чыбыркысы!"— дигән сүзләренә тап килгән бер шагыйрь Яхъя казыйга килгән һәм сораган:

— Адәмгә илһамны Аллаһы тәгалә бирәме?

— Әйе,— дигән Казый Яхъя,— һәммә бәхетебез — Аңардан!

— Менә мин шагыйрьмен. Миңа бу илһамны Аллаһы тәгалә үзе биргәненә шигем юк. Әмма ни өчен пәйгамбәребез шигырьне "Шайтан чыбыркысы" дип атаган?

— Сәбәбе бик гади,— дигән Казый Яхъя.— Тарихын сөйләп тормыйм. Бары тик бер хикмәтен генә әйтәм: шагыйрьләр алар алмагач мисалында, ниндиlekләре алмаларының тәменнән беленер. Әгәр дә алмаларының тәме юк икән, ул алмагачның ботакларын сындырып алырга кирәк, кәҗә куарга ярар. Шунда чыннан да ул Шайтан чыбыркысы була да инде!

## ТӨПЛЕ КИҢӘШ

*Хикәят*

Шигырьнең заты — хисне кузгата алу куәтендә, тәме — мәгънәсендә, имеш.

Шулай бервакыт Казый Яхъяга бер коры шагыйрь үзенең иҗат җимешен китергән.

— Нигә укып чыктыгыз да кире кайтардыгыз? Әйтер сүзегез дә юкмыни?— дип үпкәләгән шагыйрь әфәнде.

— Минем хәзергә вакытым юк иде,— дип гафу үтенгән Казый Яхъя,— кичә сахрага чыккан идем. Бер алмагачка очрадым. Кызыгып алмаларын кактым. Әмма бик ачы иделәр. Мөгаен су җитмәгәндер, аны сугарып кайтырга тиешмен дип ният иткән идем. Шунда барырга кирәк!

— И-и,— дигән шагыйрь әфәнде,— сезнең кебек акыл иясе белмимени: алмагачның алмасы — затына күрә. Аны сугарудан гына җимешләре балланамы?

— Менә бит,— дигән Казый Яхъя,— серен үзегез дә беләсез икән!

## ФАСЫЙККА ХИСАП

*Хикәят*

Кешеләрдә өч төрле һөнәрдән фасыйк бар, имеш. Әүвәлгесе — зәргәрчедә, ягъни алтын вә көмеш белән эш итү бәласеннән, икенчесе — кеше малын саклауда. Мал тик торса — файдасыз, артса — вәсвәсәле. Һәм дә өченчесе — каләмдә, язсаң — шомарыр, әмма артык сүзгә кереп китәр, тик тотсаң — күгәрер, ягъни күңелгә тутыгы үтә торган булыр.

Бу мәсьәләдә бәхәс иткән мөэминнәр Казый Яхъядан сораганнар:

— Ул гамәлләрдә ничек итсәк уңарбыз? Уңга да ярамый, сулга да хуш түгел. Нишлик соң? Турыга йөрүне өйрәтегез!

Аларга Казый Яхъя әйткән:

— Һөнәрдә фасыйклык бар икән, ул һөнәрне бозыклык дип калдыру, ташлау зур хата булыр. Фасыйгы барын истә тотып гамәл итүдән дә дөресрәге юктыр,— дигән.

## ДИВАНАЛАР ДАРУЫ

*Хикәят*

Кайнар йөрәкле адәмнең хисендә Шайтан зат кылынган уттан өлеш барлыгы сер түгел. Гашыйкларның мәхәббәт кайнарыннан чыга алмыйча дивана хәлгә төшүләре дә билгеле.

Шулай бер мәҗнүн, зар булып, Казый Яхъяга килгән. Аңардан бер йотым су сораган. Бусы бирмәгән. Мәҗнүн хәйранлыкта әйткән:

— Йә хәзрәт, ни өчен мине болай инкарь иттегез?

Казый Яхъя исә җавап биргән:

— И Мәҗнүн, сезнең иреннәрнең сусавы су кирәк булудан түгел, мәгъшукагыз кочагына төшә алмавыгыздан икән дип белдем. Мәхәббәт — зәхмәт, имеш. Аның даруы сөекленең кызыл якут иреннәре, имеш. Вакытында шул даруга ирешсәгез, җаныгыз сихәтләнер. Ә сез сораган су — сезгә агу белән бер! Үлемегезне теләмәдем!— дигән.

## МӨЭМИННӘР ХӘЛЕ

*Хикәят*

— Йә хәсрәтә, йә хәсрәтә!— дип бер мөэмин көядер икән.

Адәмнәр Казый Яхъяга гариза белән килгәннәр:

— Бу кешенең нидән болай көйгәнен белмибез. Ул безнең тынычлыгыбызны ала. Аны ничек юненә кайтарыйк икән?

— Хәлен белештегезме?— дигән хәзрәт.

— Белешмәгән кая? Әмма әйтми шул. Һаман да сагышыннан узмый!

— Янында кешесе бармы соң? Аңардан сорадыгызмы?

— Янында кешесен тапмадык.

— Мөэминлек игълан иттегезме?— дип тә Казый Яхъя сораган.

— Ул болай да мөселман бит,— дигәннәр алар, хәзрәтнең тел төбен аңламыйча.

— Мөэминлек ул — дуслык-кардәшлек игълан итү, мин шул хакта әйтәм!— дип, Казый Яхъя боларны ачуланып куып ук чыгарган.

## ГАМЬ ВАКЫТЫ

*Хикәят*

Өч фасылда ямь бар, бер фасылда гамь күп, диләр.

Мөэминнәр бәхәс кылганнар:

— Кайсы фасыл икән ул? Җәйнең яме мул, язның рәхәте күп, кышның аклыгы күркәм. Көздер инде! Яңгырлы да, болытлы, караңгы, авыр да,— дигәннәр.

Әмма бу фикерләре күңелләренә тынычлык бирмәгән. Төгәлен белик дип Казый Яхъяга килгәннәр. Сөйләп биргәннәр, ул исә, елмая төшеп:

— Шул фасылда гамь күп — ул җәйдер!— дип җавап биргән.

Һәммәсе аптырашта калганнар.

— Ничек инде? Җәйнең яме, рәхәте үзегезгә дә мәгълүм түгелме?— диярәк зар иткәннәр.

— Мәгълүм. Әмма игътибар кылыгыз: җәйге көннәр бик озын булалар, чөнки бәндәнең көзгәчә өлгертәсе эшләре күп, шуңа күрә бу фасылның гаме дә күп,— дигән, аңлатып Казый Яхъя.

## ТАТАРЧАЛАУ

*Хикәят*

Татарның русча сөйләшүендә хикмәт бар, имеш. Аңа, үз телендә сөйләшсә, татарлыгын яшерүе мөмкин түгел, ә русча такылдаса, үз татарын сүгеп ташларга да аптырап тормый.

Шулай ике татар очрашканнар да, сөйләшеп торганнарында берсе катлы-катлы сүгенеп җибәргән.

— Син нәрсә эшлисең?— ди икән аңарга дусты.— Татарча сөйләшеп торганда ни өчен сүгенәсең?

— Һи,— дигән тегесе,— татарча сүгенәммени мин, русча әйтәм бит! Кайгырма, русча сүгенгәч, безне беркем дә болар татар икән дип уйламас.

— Бик шулай да бит,— дигән аңа каршы дусты,— әмма син рус сүзләре белән татарчалап сүгендең шул!

## БУТАЛУ ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Безнең татар хәйләкәр инде ул, эчә башласа — русча сөйләшә. Имеш, Ходай руслар бәйрәм итә дип белсен. Ә мөселманга эчеп исерергә ярамый, хәрәм, димәк ки — зыянлы!

Шулай ике татар исерешеп алганнар да җырлап кайтып киләләр икән, каршыларына урам эте очраган. Боларның янынннан узып китәргә шикләнеп, читкәрәк чыгып тора икән. Татарның берсе:

— Кара әле, агай-эне,— дип эткә төртеп күрсәткән,— без русча сөйләшеп, русчалатып җырлап кайткач, урам этләре дә хөрмәт итә башладылар. Әнә, юл биреп, читкә чыгып тора.

— Әйе шул!— ди икенчесе.— Татар этедер ул, руснык булса, өстән таптап үтеп китәр иде әле!

## ТАРИХ ХӨКЕМЕ

*Хикәят*

Акыллы кешеләр тарих фәнен ашханәдәге өстәл ябучы белән тиңлиләр һәм аны соралган ризыкны гына бирә дип беләләр.

Бу хакта мөэминнәр арасында сүз чыгып, Казый Яхъядан сораганнар:

— Ә тарих гыйлемендә хакыйкать бардырмы-юктырмы?— дип.

— Әлбәттә,— дигән ул,— һәммә гыйлемдә хакыйкать булган кебек, тарих фәнендә дә ул бар. Әмма тарих фәне даими рәвештә хакыйкатьне генә сөйләсә, сәясәткә хезмәт итмәсә, күптән яшәүдән туктар иде. Ул пешекче кебек, соралган ашны гына әзерли, ә аннары, тамагы туйганчы ашаган сәясәтнең артыннан табак-савытын, калдык-постыгын җыештыра да, аның гайбәтен сата-сата, яңаларга аш пешерә.

## ХӨКЕМДАРЛЫК УРЫНЫ

*Хикәят*

— Ялган хөкем белән дөрес хөкем арасында нинди аерма бар?— дип, Казый Яхъяга бер хөкемдар сорау биргән.

— Ул кадәресен белмим,— дигән казый,— әмма шуны әйтә алам: сезнең хөкемегез һәрвакыт гадел. Димәк ул — дөрес хөкем.

— Сезнең бу сүзләрегезне хөкем чыгаруыгыз дип аңларгамы, әллә башкачамы?— дигән хөкемдар, канәгать итеп.

— Әлбәттә хезмәт күрсәтү диярәк аңларга!— дигән Казый Яхъя.

— Әгәр дә минем урында булсагыз, ә мин — сезнең урында, ул вакытта нәрсә әйтер идегез?

— Мин ул вакытта хезмәт күрсәтүдән мәхрүм булып, бары тик хөкем генә чыгара алыр идем,— дигән Казый Яхъя.

## БЕРДӘМЛЕК СЕРЕ

*Хикәят*

Илне курку белән үч кенә берләштерә ала, диләр. Шуңа да хөкемдарлар халыкны илнең дошманнарыннан туктаусыз куркытып һәм үч алырга теләк хисләрен кайнатып тоталар, имеш. Халык моның асылын төшенми, әмма аңарга бер йодрык булуы бары тик рәхәтлек хисен генә бирә.

Яхъя казыйны чакыртып, хөкемдар аңарга сорау биргән:

— Сезнең акылыгызга хәйранмын. Инде әйтегез, дөньяда дошманнарым калмады, үч алыр кешеләремне кырып бетердем, инде ничек илне таркатмый берләштереп тотыйм?— дип.

— И хөкемдар, сез үзегез дә яхшы беләсез,— дигән җавабында Казый Яхъя,— киләчәктән куркып, үткәннән үч алып яшәгәндә, дошманнарыбыз хезмәтен шулар икесе үтәрләр. Ил дә алга барыр!

## ЧИКЛӘВЕКТӘ ИКӘН ХИКМӘТ

*Хикәят*

Адәм балалары арасында шундый кешеләр була, мәртәбә дәгъвасында йөреп, зур дәрәҗәләргә ирешәләр, ә үзләре коры елга үзәне мисалындадыр.

Шулай Казый Яхъяга мөэминнәр килгәннәр һәм:

— Сезнең хөкемегез нинди булыр? Арада шундый кешеләр бар, алар галимлек дәгъвасын тоталар, бик тә мәртәбә иясе күренәләр, ә үзләре эче куыш чикләвек сыманнар. Болар кемнәр? Хөкем кылыгыз!— дигәннәр.

Бераз уйлап торганнан соң Казый Яхъя әйткән:

— Мондый ялган галимнәрнең мәртәбә таләп итүенә рәхмәтлемен. Чөнки алар булмаса, чын галимнәр фәнгә мәртәбәлелек тә кирәк булуын башларына кертеп карамас иделәр.

## САРЫК ДӘГЪВАСЫ

*Хикәят*

Сарык белән Сыер сөйләшәләр. Сарык әйтә:

— Бер дә гадел түгел инде бу дөнья. Менә минем елына ике тапкыр туныmны салдырып алалар, кешеләрне бары мин генә җылы киемнәргә төрендереп йөртәм. Ә алар — рәхмәтсезләр, миңа ризыкны аз бирәләр, ә синең, югыйсә, туныңны да салдырмыйлар, әмма алдыңа азыкны китерәләр дә өяләр, китерәләр дә өяләр!— дигән.

Шуннан сыер әйткән:

— Соң, мин бит аларның үзләренә дә көненә ике тапкыр ашарга бирәм, иртән һәм кич белән. Ә тамак, үзең дә яхшы беләсең, ача тора. Тамаклары ачкан саен исләренә мине алалар. Шуңа да алдыма азык китереп өяләр. Алар да синең кебекләр түгелмени? Син киенеп йөргән киемнән йөргәннәренә күрә, дим?

## БАЛА КАДЕРЕ

*Хикәят*

Дөньяда ике нәрсәдә адәмнең хәсрәте юк, имеш. Берсе — дошманына килгән кайгыда, икенчесе — дустына килгән шатлыкта.

Әмма мөэминнәр Казый Яхъяга барганнар һәм:

— Ни өчен без балаларыбызга насыйп шатлыкка һәм аларга егылган кайгыга борчылабыз? Хәсрәтләренә көенүебез аңлашыла, ә менә шатлыкларына сөенә белмәвебез нәрсәдән?— дип сораганнар, аны уйга салып.

— Чөнки балаларыбыз — йөрәк җимешләребез,— дигән җавабында Казый Яхъя.— Без барчабыз да зур шатлыктан соң көенеч килүен, зур кайгыны шатлык алыштыруын беләбез. Шуңа күрә дә балаларыбызның кайгыда-сөенечтә сак булуларын телибез. Алдан ук, алар егыла калмасын дип, юлларына салам түшәргә ашыгабыз!

## НАСЫЙПМЫ — БӘХЕТМЕ?

*Хикәят*

Кешегә насыйбы килми калмый, имеш. Коры кашыкка утырып, авызын ертып булса да керә. Бәндәнең бәхете шул насыйбыннан, диләр.

Мөэминнәр Казый Яхъядан сораганнар:

— Насыйп белән бәхетнең үз аерым исемнәре бар. Димәк алар икесе ике нәрсә. Ә алар ни өчен янәшә йөриләр соң?

— Чөнки икесе дә үз вакытлары белән генә килергә җөрьәт иткәннәренә күрә!— дип җавап биргән Казый Яхъя.

— Ничек инде?

— Чөнки бәхеткә без тырыш хезмәтебез белән ирешәбез, ә насыйпны безгә Аллаһы тәгалә бирә. Әмма күпләр тырыш хезмәтләре белән дә насыйбы бәхетенә ирешә алмыйча җәфа чигә, чөнки насыйбына ирешергә комачаулык бар,— дип җавап биргән ул.

## ГЫЙЛЕММЕ, БЕЛЕММЕ?

*Хикәят*

Казый Яхъядан мөэминнәр:

— Гыйлем белән белем хакында ни әйтерсез?— дип сорагач, ул:

— Белем ул галимнәр тапкан һәм дәлилләп биргән гыйлемне үзләштерүдән хасил була, ә гыйлем ул галимнең үзе эзләп, тикшеренеп һәм дәлилләп тапкан хакыйкатьне аңлатуы,— диярәк җавап биргән.

— Димәк,— дигәннәр мөэминнәр,— галимнең белеме — гыйлем, безнең гыйлемебез — белем була, шулайдырмы?

— Юктыр,— дигән Казый Яхъя,— галим булу өчен әүвәле белем тупларга кирәк, аннары үзеңә дә гыйлем эстәү, хакыйкатьне тикшерү һәм ачыклау белән шөгыльләнү мәҗбүрияте бар!

## ГАЛИМНӘР МӘРТӘБӘСЕ

*Хикәят*

Вакытның үтүе һәрвакытта да хәтерне төзәтүдә хезмәттә, имеш.

Бервакыт Казый Яхъя:

— И мөэминнәр, сез нәрсә өчен галимнәр хакында сорадыгыз, сере бармы?— дип, сөхбәтенә килгәннәрдән үтенгән.

Алар:

— Бер гыйлемне өйрәнү мең еллык гыйбадәткә тора икән дип хәдистән укыдык. Галимнәрнең Ахирәттә җәннәткә кертелүләрен фараз кылдык. Шунлык белән генә зиһенебезне борчыдык,— диярәк җавап тотканнар.

— Анысы шулай,— дигән Казый Яхъя,— пәйгамбәребезнең сүзендә дә, гамәлендә дә хата юк. Әмма безнең фаразлауларда шик бар. Галимнән галимнәр аерылып торалар шул!

## ДӨНЬЯНЫҢ РӘВЕШЛӘРЕ

*Хикәят*

Дөньяның рәвеше хакында сүз кузгалгач, Бөркет әйткән:

— Җәмәгать, дөнья ул — түгәрәк, югарыдан ап-ачык күренеп тора!— дигән.

Әмма аңа бер Куян каршы төшкән:

— Юк,— дигән,— ул — шакмаклы, тик аның почмаклары гына безнең күзгә күренми!

— Алай түгел, яман сүз бу,— дигән аңа каршы чыгып Йомран,— дөнья ул иләк кебек тишек-тошык, аның шундый булуына мең дәлилем бар!

— Юк ла инде,— дигән Үрмәкүч,— дөнья ул — җил оясы. Һаман да йөреп тора, бер дә туктый белми!

— Алай икән!— дип әйткән боларга хәйран итеп утырган Ишәк.— Ә мин аны хуҗамның чыбыркысы суга торган урынга нисбәт иткән идем!

## КӨЛКЕ СЕРЕ

*Хикәят*

Балык башыннан чери икәнлеген белмәгән кеше юк, әмма да койрыгыннан кибә башлый, имеш.

Хайваннар мәҗлесендә бер Куян мәзәк сөйли дә көлә, сөйли дә көлә икән. Әмма тыңлап утыручылар аптыраудан уза алмыйлар. Ахырда түзмиләр, сорыйлар:

— Сез, әфәндем, сөйлисез дә көләсез, ә без — аптыраштa утырабыз. Әллә мәзәгегезне аңламыйбыз, әллә инде көләрлек урыны юк? Аңлый алмыйбыз, хикмәт нәрсәдә?

— И агай-эне,— ди аларга Куян,— әллә сез мин үзем сөйләгән мәзәгемнән көләмдер дип уйладыгызмы? Һич юк! Сезнең минем юк-бар сөйләүләремә хәйран итеп тыңлап утыруыгызга гаҗәпләнеп кенә көлдем. Бигайбә!

## ЯХШЫ МӘЗӘК

*Хикәят*

Мәзәкнең кыйммәте — андагы хакыйкатьнең инкарь итеп булмаслык дәрәҗәдә булуында, имеш!

Бервакыт төлкедән мәзәк сөйләвен үтенгәннәр. Ул берне сөйләп карый, көлүче юк, икене, өчне — бар да аптырашып кына утыра бирәләр. Шуннан соң ул:

— Булмый, егетләр, мин мәзәкче түгел, көлмисез дә!— дип зарланып ала.

Шунда тыныч кына утырган Куян:

— Син, туган, былтыр ничек Аюны алдаганыңны, быел бүрене хур итүеңне сөйлә. Бик тә көлкеле хәлләргә калганнар икән!— ди.

Төлке исә:

— Сөйләр идем дә, алардан бигрәк үземнән көләрсез дип куркам, чөнки андый хәлләрдән бик тә мыскылландым,— дигән.

Һәммә хайваннар да бу сүзләрдән соң көлешеп алганнар.

## БИТ ЮУ МӘСЛИХӘТ

*Хикәят*

Әкияттә дә хакыйкать барлыгы сер түгел, әмма аның хикмәте — мәгънәсендә, имеш, вакыйгасында түгел.

Шулай бервакыт чыпчыклар әкият сөйләшеп, чыркылдашып чыбыкта тезелешеп утыралар икән, урталарына Карга килеп кунган һәм:

— Инде кайсыгызның чираты? Тамагым бик ачты бит!— дип әйткән. Чыпчыклар сагаеп калганнар, ни очып китәргә кодрәтләреннән килми, ни сүз әйтергә җөрьәт итмиләр. Шунда бер Нәни Чыпчык әйткән:

— Минем чиратымдыр инде. Әмма сиңа ничек тәмле булыр, каурыйларым беләнме, шәрә килешме?

— Әлбәттә шәрә килеш!— дигән Карга.

— Алай булгач, син бар, битеңне агартып юып кил, ә мин чишенә торам,— дигән Чыпчык.

## БИЧАРАЛЫК
*Хикәят*

Әйтәләр, имештер, мәгънә бәндәнең күңелендә яши, акылында түгел дип.

Шулай бер Сандугач бик шәп әсәр язып, аны мөхәрриргә китергән. Аның бәхетсезлегенә, мөхәррирлектә Ишәк утыра икән. Сандугачның язмасын уңнан да, сулдан да, өстән дә, астан да укып чыккан һәм әйткән:

— Аңламадым, әсәреңнең мәгънәсе нидә соң, тозы юк күренә!— дигән.

Сандугач җавабында уйланып басып тора икән: “Тоз кирәк булса, кәгазь яламыйлар аны!”— дип, әмма кычкырып әйтергә базмаган, чөнки белә: мөхәррирнең ачуы килергә мөмкин бит!

Бераз гаҗизлектә торганнан соң Сандугач әйткән:

— Тозын гына түгел, печәнен дә онытып калдырганмын бит!— дип.

— И-а!— дигән Ишәк, Сандугачны киңәш бирә-бирә озатып:— Икенче юлы саламын да оныта күрмә!

## СӨЯРКӘ
*Хикәят*

Һәркемнең үз эше, имеш. Әмма аны яратып башкарганда гына үзеңне бәхетле итеп тоясың.

Бер Себерке шулай бервакыт Көрәккә зарлана икән:

— Телем белән ялаганчы себерәм, бер дә тик тотмыйлар, һаман миннән чүп җыйдыралар,— дип.

— Һи, шушымы борчылыр мәсьәлә,— дигән Көрәк,— мин әле Сәнәкне беләм. Менә аның эше, ичмасам, авыр, тешләре коелып беткәнче шулар белән тешли-тешли тирес түгә. Инде миңа кара!

— Ә сиңа нәрсә ярамый?— дип аптыраган Себерке.

— Ә мин тизәк көрим дә тизәк көрим, бер чиста җирем дә калмады, күрмисеңмени?

— Һи, алай икән!— дигән Себерке, Көрәкнең сүзләреннән соң куанып:— Ә мине хуҗам, хатыны белән бутап, кай вакытларда кочаклап йоклый да әле!

## ҖӘННӘТКӘ КЕРЕШЛИ
*Хикәят*

Адәм затында бәйрәмнән эт-баш сыер-аяк булып кайту гадәте бар, имеш.

Бер ир шулай булып кайткач, белештерми караватат астына кереп яткан. Төнлә уянып киткән. Аңлый алмый: кайда бу? Уйлаган да, караватат астын ләхет дигән фикергә килеп, шунда елап җибәргән. Үзе әйтә икән:

— И Ходаем-Ходаем, ярлыкый күр!

Хатыны уянып киткән һәм идәнгә шартлатып тибә-тибә “перәс-перәс” дип берничә кат кычкырган. Ире тынган. Аңлап алган. Хатыны йоклап киткәч, янына менеп яткан да аны караваттан төртеп төшергән. Моңа хатыны тавыш чыгарган.

Ире:

— И хатын,— ди икән,— төш күрдем. Имеш, җәннәткә дога укып кереп бара идем, артымнан бер песи ияреп килә бит. Аны тибеп очырган идем, син булдыңмыни ул? Гафу ит инде!

## ТАЛАНТ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Мөхәррирнең бар хәсрәте, журналда эшләсә, яхшы номер чыгару, имеш. Хактыр инде.

Шулай бер мөхәррир үзе чыгара торган журналның алгы битен әзерләп утыра. Басылырга китерелгән әсәрләрне укый. Ошаганнарын бер якка алып бара да:

— Болары алдагы саннарга яхшы булыр, ә монысына менә шушы начар дигәннәре дә ярар!— диярәк, машина урынына эшли бирә.

Һәм ул һаман-һаман шулай итә. Яхшы әсәрләрне калдыра бара.

Ә көннәрнең берендә журналы бөлгенлеккә төшә, ябыла. Шунда гына мөхәррир, аңына килеп, теге яхшы дигән әсәрләрне күтәреп ала да:

— Менә сезнең аркада гына бөлгенлеккә төштем! Сез генә мине харап иттегез!— дип, һәммәсен бергә чүплек савытына каһәрләп тондыра.

## КӨЗГЕ ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Маймыл көзге ярата, имеш. Үз сурәтен карап туя алмый, ди.

Шулай бер Маймыл көзгегә әсирләнеп һәм әсәрләнеп утыра икән, янына Ала Карга килеп кунган.

— Анда кемне күрдең?— дип сорый ул.

— Бик матур, бик чибәр бер зат утыра, шуңа хәйран иттем,— ди Маймыл.

— Миңа да күрсәт әле!— дип үтенә Карга.

Маймыл аңа көзгене бирә. Карга анда үзен күреп ала да:

— Моны минем кайдадыр очратканым бар бит,— ди,— тик менә хәтерли генә алмыйм. Бу төс, бу кыяфәт! Карап туймаслык!

— Шул шул менә!— ди Маймыл, көзгене үзенә кире алып. — Карап туймаслык, әйеме! Ә син, анда кемне күрдең дип, мине аптыратып сораган буласың! Шәпме абзагыз?!.

## ЧИБӘРЛЕК СЕРЕ

*Хикәят*

Хатын-кызның чибәрлеге кендегендә, имеш. Әмма болай дип әйтүне шулай ук бәхәсле санылар.

Бит очындагы миң хакында мөэминнәр арасында бәхәс купкан. Казый Яхъяга килгәннәр. Ул:

— Чибәрлектә тамаша, ләззәт һәм гауга бар!— дип җавап биргән.— Тамаша бар, чөнки чибәрне күреп туйган кеше юк, ләззәт бар, чөнки чибәрне күргән саен, аны үзеңнеке итү теләге уяныргa мөмкин, шунлык белән баштан акыл да китә.

— Болар яхшы бит инде!— дигәннәр мөэминнәр.

— Яхшысын яхшы да, әмма үзе чибәр булган кешегә бәласе күп төшә шул, һәркемнең аңа таба кулы үрелә!— дигән Казый Яхъя.— Моның гаугасы юкмыни?

## БАШКАЧА БУЛМЫЙ

*Хикәят*

Чибәрлектә кимлек бар, ямьсезлектә артыклык бар, имеш.

Бу хакта бәхәс купкач, бер-бер җавапка килә алмыйча, мөэминнәр Яхъя Казыйга барганнар. Ул исә:

— Чибәрлек үзе камиллек, ямьсезлек үзе үк артыклык!— дип җавап биргән.

— Аңламадык,— дигәннәр мөэминнәр,— аптырашып. Нинди мәгънәдә бу шушылай?

— Чөнки,— дигән Казый Яхъя,— чибәрлекне һәммә кеше тамаша итә. Ни өчен болар шушылай акаеп карыйлар икән дип адәм баласы шикләнергә мәҗбүр. Бу шик үзе үк кимлек тудыра. Ә ямьсезлеккә килгәндә, аңардан кешеләр йөз чөерә, бу исә кешедә артыклык хисе тудыра. Башкача мөмкин дә түгел!

## КҮҢЕЛ ТАРЛЫГЫ

*Хикәят*

Күңел тарлыгын канәгать бетерә, күңел киңлеген канәгатьсезлек китерә, имеш.

Ә нәрсә соң ул канәгать, нидән аңа шушы хикмәт бирелгән?

Бу хакта мөэминнәрнең соравына каршы Казый Яхъя:

— Канәгать ул күңелгә Аллаһыны бикләү!— дип җавап биргән.

— Ә ничек була соң ул?— дигәннәр аңарга.

— Кемнең күңеленә Аллаһы тәгалә сыйса, ул кешедә тарлык булмый,— дигән Казый Яхъя.

— Без дөрес аңладыкмы?— дигәннәр мөэминнәр.— Канәгать иткән кешедә Аллаһы тәгаләгә ышаныч бар, канәгатьсез адәмдә — Шайтан коткысы?

— Әйе!— дип белдергән Казый Яхъя.— Канәгать ул иманның сакчысы иде, канәгатьсезлек исә вәсвәсә тудырудан артыкка ярамый!

## ТУЙДАМЫНИ ХИКМӘТ!

*Хикәят*

Бу дөньяны мөэминнәр өчен зиндан, диләр.

Шул хакта бәхәс кылган ике адәм тәмам тарткалашып, йолкышып, бозылышып беткәннәр. Аннары Казый Яхъяга килгәннәр. Берсе әйткән:

— Бу дөнья мөэмин өчен зиндан дигәндә, монда яшәгәндә кайгы-сагыштан артыгын күрмисең, шул күздә тотыла,— дигән.

Икенчесе:

— Киресенчә, бу дөньяда бәйрәм һәм шатлык күп, аларга алданып, күңелебезне сагышка салабыз,— дигән.

Аларны тыңлап бетергәч, Казый Яхъя әйткән:

— Икегезнең дә хаталануына хәйранмын,— дигән.— Бу дөнья мөэминнәр өчен зиндан, чөнки мөэминнең күңеле тар дөнья кысаларына гына сыймый, ул галәм киңлекләренә чыгып фикер йөртергә сәләтле!

## БӘНДӘЛЕК ХӨКЕМЕ

*Хикәят*

— Хәрам ул Аллаһ тарафыннан мөэминнәр өчен тыелган һәммә нәрсә, хәләл булса — рөхсәт ителгән,— ди икән мөэминнәр.

Аларны тыңлап торган Яхъя Казый:

— И әһле-ислам, нигә алай уйладыгыз?— дип сораган.

Мөэминнәр:

— Изге китаб Коръән безләргә шулай өйрәтә,— дигәннәр.

— Анысы мин дә Коръәнне беләмдер дип йөри идем. Әмма хәрам дигәндә — бәндәнең сәламәтлегенә зыян китерә торган ризык һәм гамәлләр күз алдында тотыла, хәләл дигәнендә — андый каршылык юклыгын күзаллый идем!— дип белдергән, аларга каршы Казый Яхъя.— Чөнки Аллаһы тәгалә өйрәтүче һәм ирек бирүче, чикләүче һәм ким итүче түгел!

## ЯЛГАНЧЫ БӘНДӘЛЕК

*Хикәят*

Бәндәлек мәсьәләсе әһеле-дин өчен гаҗәеп әһәмияткә ия буларак, бу хакта бәхәсләр туктаусыз кузгатылып тора, имештер.

Шулай бервакыт мөэминнәр:

— Бәндәлек ул — коллык, ничек инде без ирекле була алыйк?— дип Казый Яхъядан сораганнар.

— Бөтен хикмәте дә шунда!— дигән Казый Яхъя.— Бәндәлекне Аллаһыга коллык итү буларак белсәгез, Аңардан гайрегә коллык итәр идегезме соң? Әл-

бәттә юк! Әмма Аллаһыга сезнең бәндәлегегез кирәкми, моның өчен Ул бары тик рәхмәтле генә. Ә без, кешеләр, Аллаһыга коллык итәбез дип, Аңардан гайреләргә бәндә булып йөрибез. Бу мөэминлек түгел, бәлки бәндәлекне инкарь итү галәмәте генә!

## ХАКЫЙКЫЙ БӘНДӘЛЕК

*Хикәят*

— И Казый Яхъя,— дигәннәр мөэминнәр,— ничек инде Аллаһыга безнең бәндәлек кирәк булмасын? Ул бит бездән Китабында шуны таләп итте!

— Ә нигә сез коллыкны гафиллек, ягъни томаналык буларак аңладыгыз ул вакытта?— дигән аларга казый, тамак кырып.— Китабында Ул томаналарны түгел, галимнәрне бәндәләре итеп күргәнлеген әйтте.

— Бәндәлектә томаналык бармыни?— дигәннәр тагын да алар.

— Сез аңлаганча бәндәлек икән, әлбәттә бар,— дигән Казый Яхъя.— Әгәр дә Аллаһыга коллык гыйлем, аң, танып белү, зиһен белән икән, ягъни сукыр бәндәлек булмаса, бу инде мөселманча коллык тоту була. Аның барча серләре хакыйкатькә яшерелгән!

## ГЫЙЛЕМЛЕ ЭШ

*Хикәят*

— Безнең һәр көнебез эш белән үтә, гыйлем эстәүгә вакытыбыз да калмый. Ничек инде гафил булмыйк?— дип зарланганнар мөэминнәр бервакыт Казый Яхъяга.

— Ә сез эшләрегезне белеп, аңлап башкарырсызмы, әллә кирәк булган өчен генәме?— дип, алардан кайтарып сораган ул.

— Тегесе дә бар, монысы да,— дигәннәр мөэминнәр җавапта.— Ни өчен алай сорадыгыз?

— Чөнки гамәлне-эшне аңлап, белеп башкаруда гыйлем бар, мәгәр, кирәк өчен генә, кушылганга күрә үтәүдә томаналыктан гайре һичнәрсә күренми,— дип аңлатып биргән ул аларга.— Шуңа күрә дә аталарыгыз, "үзегез белеп эшли башларга вакыт" дип, балигъ яшегезгә ирешүегезгә ачулана башламадылармыни?

## МӘҢГЕЛЕК ДӘЛИЛЕ

*Хикәят*

— Без бу дөньяда вакытлыча гына торабыз. Яшәеш шуның өчен дә вакытлы түгелмени?— дип мөэминнәрнең зар кылып сорауларына каршы Казый Яхъя:

— Иманыгыз камил булса, җаннарыгыз үлемсез булуга шик белдермәс идегез,— дигән.

— Ничек инде? Без бит алай әйтмәдек!— дигәннәр мөэминнәр.

— Әгәр дә җан үлемсез икән, димәк, яшәешнең дә чиге була алмый. Нәрсә, сыйфат алыштыруга карап кайсыгыз үлгәне бар? Бала идегез, үсмер булдыгыз, үсмер идегез, олылыкка ирештегез, инде картлык та килер! Болар бары тик сыйфатыгыз алышыну гынадыр! Кешене картлык үтерми, сыйфат үзгәреше бу дөньядан алып китә,— дигән Казый Яхъя.

## ГЫЙЛЕМНӘР БЕРЛЕГЕ

*Хикәят*

Табигатьнең, дөньялыкның серләренә Аллаһының сыйфатлары яшерелгән, диләр. Шул серләргә төшенү исә хакыйкатьне тануга, ягъни Аллаһыга ирешүгә китерә, имеш.

Бу хакта бәхәс таягын тоткан мөэминнәр:

— Илаһият гыйлемнәре өстенме, әллә табигать гыйлемнәреме?— дип Казый Яхъядан сораганнар.

Ул аларга:

— Чын гыйлемнең берсендә дә кимлек яки артыклык юк!— дип җавап биргән.— Шул ук вакытта алар тигез дә түгел. Моның сәбәбе үсешләренә бәйле. Ә үсешләре — баскычлардан тора. Һәр баскычы расланган дәлилләрдән төзелә. Әгәр дә дәлилләре расланмаган икән, андый юлга кереп кителгән фәннәрне буш гыйлем, гафиллеккә тиңләү дөресрәк булыр!

## ҮЗГӘРЕШНЕҢ ЮЛЫ — КАМИЛЛӘШҮ

*Хикәят*

— Табигать фәннәре дөньялык белән ярыша, аны үзгәртә. Бу исә Аллаһының иҗатын инкарь итү түгелме соң?— дип сораганнар мөэминнәр, тәмам вәсвәсәләнеп.

— Киресенчә,— дигән Казый Яхъя,— бу чын мөэминлек юлы. Хакыйкатькә ирешеп, шушы хакыйкатьнең чыннан да шушылай, башкача түгел икәнлеген раслау өчен бүтәнчә мөмкинме?

— Ә илаһият фәннәре? Алар бит табигатьне үзгәртми, үзгәртеп кормый!

— Ул шулай тоела гына, әмма бәндәнең күңеленә гыйлем нурын иңдереп, аны яктырта. Илаһият гыйлеме җанның табигатен яхшыга таба үзгәртеп кора һәм шушы хезмәте белән мактаулы,— дип аңлаткан Казый Яхъя.

— Белми идек!— дигәннәр мөэминнәр, хаталануларын төшенеп.

## ТАБИГАТЕҢНӘН УЗУ ЮЛЫ

*Хикәят*

Адәм баласы кайсы өлкәдә таланты булса, ул шул яктан сәләтле яки булдыксызларга бәя бирә ала, имеш. Һәм киресенчә, кемдә талант юк, ул кеше исә талантсызлыкка мәдхия укый, диләр. Хәтта халыклар да шулай.

Яңа фикер тудыру өчен талант кирәкме, әллә ул башка юл белән барлыкка китереләме — шул хакта мөэминнәр бәхәс кылганнар.

Яхъя Казый әйткән:

— Әгәр дә кешедә акыл, аң һәм фәһем, тормыш тәҗрибәсе бар икән, андыйлар дөньяга яңача карау сәләтенә ирешә алалар,— дигән.— Әмма яңа фикерне тудыручылар алар гайре табигый кебек булалар. Димәк, бу өлкәдә дә адәмдә уйлау, фикер йөртү сәләте булырга тиеш!

## МӨЭМИНЛЕК СЕРЕ

*Хикәят*

Мөэминлекнең нигезе иман, билгеле. Бу турыда бәхәскә урын юк. Әмма:

— Мөселман булган кешегә яшәүнең шарты бармы?— дигәннәр халык, Яхъя казыйдан бу мәсьәләдә туры җавап сорап.— Яшәеш шартларыбыз бертөсле үк түгелмени?

— Мөэминнең хикмәте шунда!— дигән ул.— Аның күңел түрендә иман шәме янса, ике кулында даими шөгыль һәм эш булырга тиеш. Әгәр дә гамәлдән аерылса, бәндә мөселманлыктан да китә.

— Без гомеребез буе хезмәттә изаланыйкмы инде?— дигәннәр, аңа каршы төшеп.

— Әгәр дә күңелегезгә сөенеч китерүче эштә булмасагыз, мөэминлегегезгә дә бу гамәлегез хилаф итәр,— дигән ул.

## ПУШКИНГА БАРЫШЛЫЙ

*Хикәят*

Дөнья буйлап сәяхәт иткәнемдә бер илнең президенты белән очраштым. Урам себерә иде. Хәлләрен сораштым. Ул миңа:

— Сезгә хәлем кирәкме, әллә бер-бер сорыйсы әйберегез бармы?— диде.

— Әйе,— дидем,— миңа Пушкин урамыгыз кирәк иде.

— Бар ул андый урам бездә,— дип, анда ничек барырга икәнлеген өйрәтеп бирде. Рәхмәт әйтеп, юлымны дәвам иттем.

“Нигә ул урам себерә иде икән?”— диярәк уйлап, Олы Корсак, Ташаяк, Яссы Тәлинкә, Сыйрак-Баһадур урамнарының кайсын буйлап, кайсын аркылыга уздым. “Бу Пушкин дигәннәре бу илне һәм халкын иҗатында бик мактаган булыр, шуңа аның истәлегенә урамга исем биргәннәрдер!”— дидем. Барып җиткәнче шакшылыкка хәйран иттем һәм президент әфәнденең ни өчен урам себерүен шунда гына төшенеп алдым.

## ҖИЗНИ КЕШЕ БУШ ЙӨРМИ

*Хикәят*

— Исәнмесез!— диде сарсаз җизни.

Очрашмавыбызга ярты еллар бар иде. Мин дә сөендем.

— Әссәламәгаләйкүм!— дип, авызны киң ачып, кочакны чама белеп кенә җәеп күрештем.

— Кичә “здрастуй” иде, бүген ничек “сәлам”гә күчелде?— диде ул, кызыксынып.

— Бер дә татар буласым килмәүдән инде ул,— дидем, дөресен яшермичә,— безнең халыкта гадәт шулай бит инде, чуаш булырга ризабыз, тик татар дип кенә атамасыннар.

Җизни сөенде:

— Атаң исән булса, ну каеш ашатыр иде инде үзеңә. Тәмам урыс булып беткән идең, инде гарәпкә әверелә баруыңны әйтәм: монысы да замана чире генәме соң? Кайчан савыгырсың икән? Авыру кешенең Ходай тәгалә хәлен белешүне мактаган, буш йөрмим икән әле, хәлең белешә килгәнмен!

## САРЫМСАК БАЗАРЫНА БАРАМ

*Хикәят*

Безнең Казанда сарымсак базары ачтылар. Ниндиләре генә юк анда: эресе, уртачасы, вагы, агы, карасы.

Кулыма бер эре сарымсакны алдым. Әллә кемнәр булып күземә күренде. Сатучысыннан сорадым:

— Бу ни атлы?

— Бу сарымсак Шәехмөхәммәдов атлы була,— дип аңлатып җавап бирде ул.— Бер тешләсәң, ни авыздан үтми, ни исе китми. Яныңа хәтта хатының да килеп карамый!

Булмый болай диярәк фикер йөртеп, бер кечкенәне кулыма алдым. Шулай ук кызыксындым.

— Бусы — Миңнуллаев атлысы,— диде сатучы.— Юкка аңа кагылдыгыз, хәзер бөтен дөньяны сасыта, күзгә кереп йөдәтә, чебен-черкине үз тирәсенә җыя инде бу!

Сарымсак алам дип барган идем, сарымсак базарыннан сарымсаксыз кайтып киттем.

## ИЛ САНДУГАЧЫ

*Хикәят*

Бер чыпчык, тырыша торгач, үзен сандугач дип таныткан. Аның чыркылдауларына һәммә хайванат таң-гаҗәеп итүдә икән. Хәтта махсус фәрман чыгарып, аңа “Хайванат җырчысы” исемен биргәннәр. Ул үзенең чын мәгънәсендә

сандугач булуына шикләнми башлаган, кош-киек халкы да шундый ук фикердә икән. Газеталар мактый моны, радио, телевидение. Китап арты китабы басылып чыга. Укып караган кеше дә юк, югыйсә.

Әмма адашыпмы бу илгә Сандугач килеп кергән. Сайрап җибәргән.

— Кит моннан!— дип, аны куа башлаганнар болар.— Безнең колакларыбыз синең җырыңа күнекмәгән, безгә чыркылдаган тавыш илһам бирә, син үзеңне сандугач дигәндә ялгышасың, адәм көлкесе!

Бу томана хайванатны калдырып, Сандугач очып китеп барган.

## ДИН МӘҖЛЕСЕ ТӘРТИПЛӘРЕ

*Хикәят*

Дин мәҗлесенә бардым. Хәзрәтебез бик тә олпат кеше иде. Мәҗлестәгеләргә алдан сүз биреп, Коръәннән аятьләр укырга сорады. Мондый рәвеш элекләрне миңа ошый торган иде. Халык арасында Коръәнне белүчеләр бар исә дә, бер күркәм бала “Әлхәмде” сурәсен укыгач, әйтергә тиешле таптым:

— Мәҗлесебезнең имамы дип, хәзрәт, сезне таныдык. Сезнең чакырылуыгыз шул сәбәп илә иде. Инде сезгә оедык!— дидем.

Дин мәҗлесе таләбе шушы булганлыктан, хәзрәт ниятендәге сурәләрне матур итеп укыды. Күңелләр хушланды. Әмма сүзләремә канәгатьсез итүчеләр табылганлыгы ахырда билгеле булды. Аларга аңлатырга мәҗбүрият күренде.

Мин:

— Имамнар — пәйгамбәребезнең эшен дәвам иттерүчеләр. Аларның эше — Коръән уку, безнеке — аңа ою!— дидем, кабатланып.

## СҮЗ ӨСТЕНЛЕГЕ

*Хикәят*

— Дин мәҗлесендә кемнең сүзе өстен?— диделәр.

Мин:

— Аллаһ сүзе өстен!— дидем.

— Нигә алай әйтәсез?— диделәр.

— Чөнки җәмәгать белән без имамга оедык, ул Коръән аятьләрен укыды. Без тыңлап кына утырдык, шуңа күрә Аллаһ сүзе өстен,— дип аңлатма бирдем.

— Без бит Коръән сүзләрен аңламыйбыз, укый гына беләбез!— дигән мөэминнәр дә табылды.

— Дөрес,— дидем,— чөнки ул гарәп телендә, пәйгамбәребез Мөхәммәд гарәп булган, шуңа да гарәпчә иңдерелгән. Әмма, гарәпчә булса да Коръәнне пәйгабәребез чорындагы гарәпләрдән шактыйлары аңламаганнар. Исламга каршы чыкканнар. Хәер, без дә әле, үз ана телебездә үзара сөйләшеп тә, бер-беребезне аңлап бетермибез. Фикер йөртүебез, күзаллавыбыз, тормыш тәҗрибәләребез төрлечә булудан ул шушылай. Хикмәт үзебездә, югыйсә. Әмма беребез-

гә икенчебез, дөресне аңлатырга тырышып, тавышланышудан артыкка үткәнебез бармы? Аллаһ сүзен тыңлаудан да хәзергә өстене безнең өчен юк сыман!

## КҮЗ КҮРЕП, КОЛАК ИШЕТЕП...

*Хикәят*

Су буена матур җәй көнне тугайга төштем. Аргы башында гөлбакча иде. Шунда күләгәлек табып утырдым. Әмма кошлар сайравына хәйран иттем. Бәлки вакыты шундыйдыр?

Уйлап бетермәдем, аклы-каралы, озын койрыклы бер кош күренде. Җәннәттәге тавис кошыдыр, имеш.

Аның тавышына гаҗәпләндем. Мин бит ул кошны матур итеп сайрый дип кешеләрдән ничәмә тапкырлар ишеткәнем бар иде.

Ул кош очкач, аның урынына бер кечкенә кош килде. Сайрап җибәрде. Аның тавышына һәм җырына күңелем хушланды. Сорадым:

— Теге, сездән алда сайраган кош тавис түгел идеме?

— Ә-ә, саесканны әйтәсезме?— диде ул миңа җавабында.— Ялгышучы бер сез генә түгел. Әмма шунысы гаҗәп: күз белән күреп, колак белән ишетеп торып, ничек алданмак кирәк икән?

## ИШӘКЛӘР СӨХБӘТЕ

*Хикәят*

Бер язучы әфәнде үзенең танышына, бик үтенгәчтер инде, китап бүләк иткән. Аның тышлыгына: “Хәзерге байлар китап сатып ала белми, шуңа да укымыйлар, ярлылар сатып алырлар иде, акчалары юк, шуңа да укый алмыйлар”,— дип башлап китеп, озын гына юллама да бетекләгән.

Дусты аның китабын укып чыккан һәм ахырына болай дип язып куйган: “Күзлеләр хәзерге заманда хәреф танымыйлар, сан гына күрәләр, күзсезләр исә укый алмыйлар. Бу китапны укып чыктым, аңламадым!”— дип.

Язучы әфәнде аларда кунакта икән. Шушы язуга юлыккан һәм аңарга өстәп язып куйган: “Ишәкнең дусты ишәк затыннан булмыйча, нинди заттан булсын ди инде?”

## БӘНДӘЛӘР ХӘВЕФЕ

*Хикәят*

Адәмдә, белмәсә дә, якынча гына хәбәрдар булып та, мәсьәләнең төбенә төшкән акыллы баш кебек сөйләшү галәмәте бар, имеш. Дөнья шуларга ияреп саташудан гыйбарәт, диләр.

Яхъя Казый бу мәсьәләдә болай дип әйткән:

— Адәм баласы гыйлемне дә, наданлыкны да үзе тудыра.

— Ә аларның кайсының чиге бар?— дип сораганнар мөэминнәр.

— Икесенең иге-чиге юк,— дип җавап биргән ул.— Алар дәрья кебек, адәм баласы яисә гыйлемгә чума, яки наданлыкка бата. Шунысы кызыклы, гарык булучыларның икесе дә нинди хәлләргә дучар булуларын аңламыйлар һәм үзләрен, дөрес эшлибез, бәхетебез камил, дип күз алларына китерәләр.

## КЫШТАН СОҢ ЯЗ

*Хикәят*

Дөнья буйлап йөргәнемдә бер шәһәргә юлым төште. Эче тулы халык иде. Һәммәсе дә шаулашалар, ризасызлар. Әйтешүчеләр һәм тарткалашучылардан читтә моңаеп кына бер бабай басып тора.

Аның янына җитеп:

— Боларга ни булды икән?— дип сорадым.

— И улым,— диде ул,— мин бу шәһәрдә гомерем буе яшәдем. Болар йокладылар да йокладылар. Кыш узып, яз җиткәч, сулар ничек боз астыннан ташып чыгалар, алар да шулар мисалында булдылар. Йокы никадәр озакка һәм озынга сузылмасын, барыбер дә бер уянасың икән аны. Боларның да йокыларыннан уянып маташу галәмәте генә бу!

## ЙОЗАКСЫЗ АВЫЗЛАР

*Хикәят*

Телдә дәрт булса, хакыйкатькә хыялны кушу көченә ия, имеш. Әмма ялган шулкадәр татлы ки, аның тәме саташтыру көченә ия, диләр.

Ирләр уен-көлке сөйләшеп, көлешеп мәш килгәндә, алар янына бер танышлары килеп:

— Нәрсә сөйли идегез?— дип кызыксынган.

Арадан берсе:

— И туган, сине мактый идем әле!— дигән.

— Һе,— дип ачуланган бу,— әгәр дә мактасагыз, болай көлешер идегезме соң?

— Әллә елар идекме,— дигән теге дә, югалып калмыйча.— Шатлыклы хәбәр — сөендерә, авыры — хәсрәткә батыра!

— Ярый алай булгач,— дигән бу,— сөйләгез, сөйлә! Авызларга йозак элеп куеп булмый.

## ҖӘЗА ХӨКЕМЕ

*Хикәят*

Дөньяда ахмаклыкны һәммә кеше дә булдыра, имеш. Әмма акыллы кешенең, аяклары таеп китеп, ахмак гамәл кыла калса, моңарга күңеле сыкрый, ул

шушылай гыйбрәт дәресе ала, ә акылсыз адәм, ахмаклык кылгына саен, моңарга бары тик сөенә генә, диләр.

— Кешеләр ахмак гамәлләреннән соң уфтаналар, әмма кабат шундый хәлләргә таралар. Бу нидән шулай?— дип сораган Тартар кошы Ала Каргадан.

— Әллә ояңны берәрсе бүстеме?— дигән аңа каршы Ала Карга.

— Әйе,— дип сыкранган Тартар,— минем ул ояда ничәмә чебешләрем чыгасы иде.

— Борчылма!— диярәк юаткан аны Ала Карга.— Ул чебешләрең булмагач, кешеләр аларга ау куя алмаслар. Өстәлләре ризыксыз калыр!

## ИЛ ХӘСРӘТЕ
*Хикәят*

Ни өчен берәүләргә дөнья ямьле, икенчеләргә ямьсез кебек күренә? Чөнки кәефләренә карап: кәеф яхшы чакта һәммә нәрсәгә сөенәбез, күңел тәрәзәләре бозылса, кояш нурлары да хәтер бүлмәсенә үтеп керә алмыйча гаҗизләнә.

Ил көнендә Һөдһөд кошының күңеле юкарып, онытылып елап утыра икән, янына Ала Карга төшеп кунаклаган, хәлен сорашкан. Бусы һичнәрсә җавап бирмәгән. Шунда Ала Карга:

— Күңел тәрәзәгез парланган, әфәндем! Сөртергә оныткан идегезме?— дигән.

— И Карга,— дигән аңарга Һөдһөд,— нинди күңел тәрәзәсе генә булсын, бөтен дөньям җимерелеп аяк астымда ята, шуны җыештырып, чүбен кая куярга белмичә аптыраулы идем әлегә, гафу итә күрегез!

## ТӘРБИЯ ХӘСРӘТЕ
*Хикәят*

Бер кеше үзенең хаталарыннан бик тә гаҗиз икән. Киңәш сорап Казый Яхъяга килгән. Ул, аны тыңлап бетергәч:

— Сезнең хаталанулар ахмаклыктан түгел, тәрбия җитмәүдән килә,— дип белдергән.

Сүзе хак булган, ахрысы.

— Дөрес инде анысы да,— дигән бу кеше.— Кайдан алыйм инде мин аны? Ярлы гаиләдә эш тә эш кенә күреп үстем.

— Менә бит,— дип сөенгән Казый Яхъя,— эш сезне акыллы иткән, тәрбияне дә шуңардан алырга кирәк иде.

— Ничек инде?— дип хәйран калган бу кеше.

— Бик гади,— дигән Казый Яхъя,— эш яраткан кешенең моңа кадәр ахмак та, тәрбиясез дә булганы юк иде. Гаеп үзеңдә түгел, яныңдагы кешеләрдәдер. Алар ниндиләр? Танып калуыгыз яхшы!

## ШАГЫЙРЬЛӘР МӘҖЛЕСЕ

*Хикәят*

Шагыйрьләр мәҗлесенә очраклы рәвештә бер гади кош очып кергән. Боларның сөйләшүенә колак салган. Кыш үтеп бара, тамчылар тама, яз башы икән. Бер шагыйрь әфәнде:

— Карлар елый башлады, кояш әрсезлеге белән сокландыра,— дип әйтүгә, икенчесе, дәртләнеп:

— Кар сулары көлә-көлә челтерәшеп йөгерешә башладылар,— дигән.

Өченчесе:

— Көннәр җырлый башлады, урамнар җәелделәр,— дип, аларның сүзләрен куәтләгән.

Боларны тыңлап торган кош:

— Мин мөгаен диваналар мәҗлесенә килеп кердем бугай, болар кешечә сөйләшә дә белмиләр,— диярәк, бу мәҗлестән очып чыгып китү җаен караган.

## ИҢ ЯХШЫ СЫЙФАТ

*Хикәят*

Кешедән иң яхшы сыйфатың нинди дип сорасалар, ул аның әлегәчә үзендә күрелмәгәнен һәм оешып җитмәгәнен, әмма һичшиксез киләчәктә алга чыгасын өмет иткәнен атаячак, имеш.

Бу хакта хәбәрдар булган мөэминнәр адәмдә кайсы сыйфатының яхшылыгы хакында бәхәс иткәннәр. Берсе эш сөючәнлекне атаган, икенчесе тугрылыкны данлаган, өченчесе — акылны.

Фикерләр төрле булып чыккан. Бәхәс киткән. Аларны тыңлап торган Яхъя казый исә:

— Кешедә иң күркәм сыйфат — гаделлек!— дип әйткән.

Аптыраганнар:

— Ни өчен алай?— дип сораганнар.

— Чөнки,— дигән ул,— без Аллаһыдан гаделлек өмет итәбез. Димәк, аңардан да мәртәбәлерәк һәм кадерлерәк сыйфат юк!

## НАСЫЙПТАН ЙӨЗ ЧӨЕРҮ

*Хикәят*

Читлеккә алтын каурыйлы кош очраклы рәвештә очып кергән. Мөгаен хуҗасын югалтып, әүвәрә килеп, дөнья йөзе буйлап очып йөргән, аптырашлы вакыты булгандыр. Андый чаклар да булгалый.

Читлек хуҗасы аны күреп алган, бикләп куясы иткән. Әмма кабат уйлаган: “Моны читлегемдә бикләсәм, үземнең кошыма урын калмый!”— дип.

Алтын каурыйлы кош очып чыгып киткән. Шунда гына читлек хуҗасы:

— И, бигрәкләр дә ахмак инде мин!— дип үкенә башлаган.— Аллаһы тәгалә миңа алтын каурыйлы кош бүләк итте. Ул минем читлегемә очып керде. Шунда күңелемне тарламасам иде, мин аның иясе була идем!

Әмма үкенергә дә соңга калган. Алтын каурыйлы кош бүтән күренмәгән.

## ШОМАЛЫК ШОМЫ

*Хикәят*

Кеше үзен эшлекле итеп тотарга ярата. Әгәр дә шундый булмаса, ул үзен харап итәр иде. Акылы да зәгыйфьләнеп, холкы да хәтәргә әверелер. Моны кем дә белә, шуңарга күрә туктаусыз хәрәкәтчән булырга тырыша.

Мөэминнәр мәҗлесенә бер шомарган таш тәгәрәп килеп керә. Ул Казый Яхъяның янына җитеп туктый. Мөэминнәр бу тамашадан өнсез калалар. Казый Яхъя шушы ташны кулына ала һәм:

— Шома булмасаң, ишектән дә уза алмас идең, әйеме?— дип әйтеп куя. Мөэминнәр көлешеп алалар.

Казый Яхъя тагын да болай ди:

— Шушы рәвешле көлкегә дә калмас идең!

Һәм ташны сыйпап, үз янына алып куя. Кирәк булуың бар, имеш!

## ФӘЛСӘФӘ НИГЕЗЛӘРЕ

*Хикәят*

Белемең төгәл булмаса, фикерләрең дә нигезсез, буталчык, имеш.

Бервакыт фәлсәфә мәҗлесенә бардым. Философ әфәнделәр, зурдан кубып, бик олы мәсьәләне чишүдә иделәр. Сүзләре “Кәлам гыйлеме” хакында.

Мәҗлесне оештырган данлыклы һәм мәртәбә иясе философ әфәндедән сорадым:

— Күп сөйләдегез, асылда Кәлам гыйлеме фәлсәфәсе нәрсәдән гыйбарәт соң, аны төгәл генә әйтеп булмыймы, чикләрен күрсәтеп?— дидем.

Ул миңа аптырап карап куйды да:

— Әгәр дә Кәлам гыйлеменең ни-нәрсә икәнлеген төгәл генә белсәм, әйтер дә идем,— диде, бер дә исе китмичә.— Әмма ул вакытта фәлсәфәгә урын калмас иде. Сезнең кайчан әле төгәл, конкрет белем вә гыйлем янында фәлсәфәгә урын барлыгын күргәнегез булды?

## БӨТЕННЕҢ КИСӘГЕ

*Хикәят*

Мин үземне белемле кешеләр хисабында йөртә идем, әмма...

Дуслар мәҗлесендә мондый хикмәт ишеттем: “Хакыйкать мәңгелек булса да, белем вакытлы күренеш!”

Бик тә гаҗәпсендем. Күңел чүлмәге, киштәлегеннән төшеп китеп, урталай ярылгандай булды.

— Ни сәбәпле шулай әйтәсез?— дидем.

— Чөнки,— диделәр миңа,— белем ул хакыйкатьнең бер мыскалын танып белүдән туа, мәгәр дә хакыйкатьне тәмам, тулысынча төшенүдән түгел.

— Кисәкне өйрәнеп, шуның ярдәмендә бөтенне белеп булмыймыни?— дидем, тагын да аптырап.

— Була,— диделәр.— Без дә шул хакта әйтәбез бит инде, мәңгелекнең үзе дә вакыт кисәкләреннән тора дип.

## САГЫШ СӘБӘПЛӘРЕ

*Хикәят*

Кешенең күңеле тулы сагыш, диләр. Моны тормыш хәсрәте тудыра, имеш.

Бу хакта сөхбәт кылган мөэминнәр Казый Яхъядан сораганнар:

— Хикмәт нәрсәдә? Ни өчен без ул гамьнән котыла алмыйбыз? Сагышның тууы сәбәбе нәрсәдән?— дип.

Ул исә:

— Кешедә кайгы нәфседән дә, Аллаһыдан да була. Шунлыктан хәсрәтсез кеше дөнья йөзендә була алмый!— дип җавап биргән.

— Аллаһыдан кайсылары килә?— дигәннәр, җавап үтенеп мөэминнәр.

— Һәммә төрле изге хисләр тудырганнары, ягъни мәхәббәт мисалындагылары!— дигән ул.

— Ә нәфседән безнең үз хисләребезнекеме?— дигәч:

— Әйе, ләззәттән килгәннәре дә!— дип җавап биргән.

## ДИН КӨНЕ ҺӘМ ДӨНЬЯЛЫК БЕРЛЕГЕ

*Хикәят*

Дин мәҗлесендә дөнья мәсьәләләре чишелми, имеш.

Бу хакта сүз кузгалып, мөэминнәр гасабилыкта калганнар. Шушы сагышларын чишеп бирүне Казый Яхъядан үтенгәннәр. Ул исә:

— Дин көне белән дөньялык көне арасында нинди каршылык күрдегез?— дип сораган.

— Соң,— дигәннәр алар,— үзегез дә беләсез, дин көне — мәңгелек, дөньялык исә — бер көнлек. Аларның икесен катыштырып һәм катнаштырып булмый бит!

— Була,— дигән Казый Яхъя,— чөнки бу дөньялык көне дин көненнән хәбәр бирә.

— Ничек инде?

— Дөньялыкта бәндә нинди гамәлләр башкарса һәм аларны ничек кылса, дин көнендә боларның хөкемен күрә. Шуңа да алар үзара бәйле!— дигән ул.

## МӨСЕЛМАННАР ФАЛЫ

*Хикәят*

Мөэмингә фал ачу гөнаһ, имеш.

Бу мәсьәләдә сүз чыгып, араларыннан берәү:

— Без әйтәбез, яхшы, кешелекле, үзара дустанә булыйк, болар өчен Аллаһы тәгалә рәхмәт ирештереп, җәннәтен насыйп итәчәк, дибез. Бу исә үзе үк киләчәкне фараз кылу, фал түгелмени?— дигән.

Мөэминнәр аптыраашта калганнар. Казый Яхъя исә:

— Сез монда сихердән бер-бер галәмәт күрдегезме соң?— дип сораган.

— Юк!— дигәннәр аңарга.

— Мәгәр шулай икән, ягъни фараз кылуда сихер галәмәте булмаса, аның гөнаһы юк, ул саваплы гамәлләрдән саналыр,— дигән ул.— Әгәр дә сихер һәм ялган белән бәйле икән, андый фалларда гына хәрам һәм гөнаһ бар. Җен башка, пәри башка. Һәммә мәсьәләне бер себерке белән себерү үзе үк гөнаһ булыр.

## ЯЗМЫШ ХАСИЛЫ

*Хикәят*

Бәхет төшенчәсе һәркемдә үзенчә булуы хакында бер фикергә килеп, мөэминнәр, әкбәр әйтеп, дога кылулары була, сөхбәт мәҗлесенә Казый Яхъя килеп керә.

Аны сынап карарга уйлыйлар. Арадан берсе:

— Без әйткәнне ул да дәлилләр,— диярәк соравын бирә.— Бәхет, әфәндебез, сезнеңчә ничектер? Әйтерсезме?

— Әйе,— ди Казый Яхъя,— бәхет ул безгә бирелгән язмыш.

Аның сүзләреннән соң мөэминнәр аптырап калалар. Аларның хәлен күреп алган Казый Яхъя исә:

— Нигә, сез бәхетне һәркем үзенчә аңлый димәдегезмени? Минем сүзләр дә моңарга дәлил. Һәркемнең язмышы үзенә, димәк, бәхет төшенчәсе дә үзенчә!— дип аңлатып биргән.

## АКЧА МӘСЬӘЛӘСЕ

*Хикәят*

Мөэминнәр утырышында бер юлчы Казый Яхъяга сорау биргән:

— Сез,— дигән ул,— күренеп тора, Аллаһы тарафыннан яхшы зиһен, яхшы акыл белән бүләкләнгән кеше, әйтегез әле, бу дөньяда акча кирәк булмаган кеше, ягъни дә аның барлыгына-юклыгына исе китмәгән адәм бармы?

— Әлхәмдүлиллаһ, бар!— дип җавап биргән Казый Яхъя.

— Ул кем?— дигәннәр мөэминнәр.

— Үзегез дә беләсез,— дигән Казый Яхъя,— акча һәрдаим ике кешегә кирәк. Аның берсе туктаусыз акча җыю, аларны сандыкка тутыру белән мәшгуль, икенчесе — сатып алу, ягъни мохтаҗлык һәм кирәклек өчен акча хәсрәтендә яши. Мохтаҗлыгы булмаса, яисә акча җыю белән мәшгуль түгел икән, ул кешегә акчаның да кирәге юк. Шулай түгелме?

## КАЙНАРЛЫКНЫҢ ПОТЫ БЕР ТИЕН

*Хикәят*

Холык базарында кайнарлыкмы-сабырлыкмы кыйммәт диярәк бәхәс кылып утырган мөэминнәр арасында, бәхәс төенен чишеп, берәү әйтеп куйган:

— Һәркайсының үз урыны бар, кирәк чагында кайнарлыкны сабырлык алыштыра алмый, сабырлыкны — кайнарлык!

— Кайчан кирәген кайдан белергә соң аның?— дигәннәр мөэминнәр.

— Тормыш үзе белдерә ул!— дигән теге кеше.

Барысы аннары Казый Яхъяга борылып караганнар. Күзләрендә: “Сез дә шулай уйлыйсызмы?”— дигән сорау энҗеләре ялтыраган.

— Әмма мин адәмдәге бер пот кайнарлыкны да бер мыскал сабырлыгы җиңү көченә ия дип белә идем. Ялгыштым микәнни?— диярәк, бераз шаяртыбрак җавап биргән Казый Яхъя аларга.

## СЫЙР БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Карга, сыйр кисәге эләктереп, агач ботагына килеп кунуга, койрыгын болгап Төлке дә килеп җитә. Ничек тә моның ризыгын урлап качу инде исәбе, ә тегесе, сыйрны томшыгына тешләгән килеш, ычкындырырга куркып утыра. Төлке, иреннәрен ялап:

— Мин бүген тавык ите ашадым,— ди.

Ә Карга барыбер сер бирми.

Төлке тагын да хәйлә итә:

— Әле дустым Аюга кунакка бара идем. Сине очратсам, алып килергә кушты. Барасыңмы?— ди.

Карга һаман сер бирми.

Төлке, башка хәйлә таба алмагач, китеп барганда, аңарга Карга:

— Мине көтмисеңмени?— дип сорый.

Шунда сыйры төшеп китә. Төлке шул сыйрны эләктереп ала да кабып йота һәм:

— Ә мин шаярткан гына идем бит,— дип китеп тә бара.

Бу хәлгә ачуы килгән Карга шунда Төлкене кызык итәргә уйлый. Очып бара да, үлгәндәй булып юл читенә ята. Төлке, аны күрүгә, сөенеченнән сикергәләп ала. Йөгереп тә килеп җитә, ә Карга, шунда ук арырак очып китеп, хәлсез егылгандай җиргә ава.

Төлке килеп җитә. Бу хәл тагын кабатлана. Төлке шунда гына үзеннән Карганың көлүен аңлап ала да:

— Бер сыйр кисәге бәласеннән никадәр җәфа чигәсең, мескенкәем!— дип әйтеп куя.

Аны ишетеп алган Карга да, үз юләрлеген аңлап:

— Әйе шул,— ди.— Сине көлкегә калдырыр өчен тагын үземне җәфаладым. Хәйлә синең юлдашың, ә минеке ахмаклык кына икән!

## КЕШЕНЕҢ ӨЧ ҖАЕ

*Хикәят*

Ирләр арасында бәхетлеләре зур байлыклар иясе булып, чибәр хатын кочагында гомерләрен хәсрәтсез уздыралар, диләр. Бу мәртәбәләргә башкалар да лаеклы исә дә, байлык та, чибәр хатын да, хәсрәтсез тормыш та һәммә иргә җитәрлек түгел, имеш.

Шушы хакта бәхәс утында көйгән мөэминнәргә Казый Яхъя әйткән:

— Байлык та, чибәр хатын да, хәсрәтсез тормыш та һәммәбезгә җитәрлек, чөнки чибәрлек турында да, байлык мәсьәләсендә дә, хәсрәтсез гомер хакында да төшенчәләребез төрлечә. Берәүләрнең бит очындагы кара миңе икенчеләргә ошамаска да мөмкин, әмма һәммә нәрсәдә хикмәт күреп, мәгънә тапсак, сайланып кына соклана белсәк, без барыбыз да шушы өч нәрсәнең хуҗасы булырбыз! Килешәсезме?

## КЫЙБЛАЛЫ АДӘМНӘР

*Хикәят*

Тырышкан кешеләр максатларына ирешми калмый, диләр. Әмма моның өчен аларга мөмкин кадәр сабыр булырга кирәк, имеш. Юлларында мең төрле каршылыклар тумый калмас. Аларны лаеклы узарга кирәк.

— Максатлы кешеләр дөньялыкта кыйбласы һәм иманы булган мөэминнәр кебек,— дигән Казый Яхъя, мөэминнәр белән сөхбәтендә.— Максатка ирешү — хаҗга бару кебек үк, кешене сыйфат үзгәрешенә китерә.

— Бу үзгәреш нинди дәрәҗәдә булыр?— дигәннәр мөэминнәр.

— Максатның мәртәбәсе кебек үк булыр,— дигән Казый Яхъя.— Максатың изге икән, сыйфат үзгәреше дә изгелек дәрәҗәсенә китерер. Юк икән, аны максат дип әйтеп булырмы?

## ИШӘК БЕЛӘН ЮРТАК АЕРМАСЫ

*Хикәят*

— Кешеләрнең кайсылары дөреслек белән өстен чыга, кайсылары ялагайлык белән. Нинди сыйфатка таянып дәрәҗә алсаң мөселманча була?— дип сораганнар мөэминнәр Казый Яхъядан. Ул исә:

— Кешелеклелеккә таянганда мөселманча була!— дип җавап биргән.

— Андыйлар аз бит,— дигәннәр аңа.

— Димәк,— дип белдергән ул,— дәрәҗә иясе кешеләр арасында мөселманнар да аз.

— Әмма алар үзләрен мөселман дип атыйлар бит. Мәчетләр салдыралар, имамнарны тәрбия итәләр, изге гамәлләр кылалар!— дигәннәр аңа.

— Әйе,— дигән Казый Яхъя,— ияр кидертелгән ишәкне дә юртак дип атаучылар бар. Әмма ул ишәк алашаны да алыштыра алмый!

## КЕМНЕҢ КИҢӘШЕ ДӨРЕС

*Хикәят*

— Кайсы һәм нинди кешегә киңәшкә бару дөрес: яшь һәм акыллы адәмгәме, әллә карт һәм дөнья күргән кешегәме?— дип сораганнар Казый Яхъядан.

Ә ул:

— Карт кешегә барыгыз!— дип җавап биргән.

— Ни өчен?— дигәннәр мөэминнәр, аптырашып.— Акыллы кешенең сүзе өстен түгелмени?

— Әлбәттә өстен!— дигән ул.— Әмма ләкин дөнья күргән кеше үз тәҗрибәсенә таянып киңәш бирер, акыллы бәндә фараздан чыгып эш итәр. Фаразга таянудан тәҗрибәгә нигезләнү мең өлеш артык. Аннары, яшьлек — кызулык белән, картлык — сабырлык белән. Ә мөэмингә сабырлар белән булырга кушылган, үзегез дә беләсез!

## БАШЫНА ТАЙ ТИПМӘСӘ

*Хикәят*

— Безнең шәһәребезнең яңа хуҗасы шулкадәр дә яхшы кеше булып чыкты,— дип сөйли икән мөэминнәр мәҗлесендә бер куштан,— ул үзенә унсигез мең генә хезмәт хакын билгеләде!

— Ә күпме тиешле иде соң?— дип аптырыйлар икән аңа колак салып утыручылар.

— Элеккеге башлык алтмыш меңнән артыграк алган булган, юньсез, хәерсез!— ди икән теге һаман да.

Аны тыңлап утырган Казый Яхъя елмаеп куйган һәм:

— Борчылмагыз,— дигән,— хәзерге башлык алтмыштан күбрәк алу юлын тапкандыр. Әмма халыкка бары унсигез меңен генә белдерүне хәерлегә санагандыр. Сезнең әле моңа кадәр кайсы этнең үз койрыгын үзе кискәнен күргәнегез булды? Башлыгыбызның башына тай типкән дип белдегезме әллә?

## БӘХӘССЕЗ РАСЛАУ

*Хикәят*

Физиканы Аллаһы тарафыннан тудырылган фән, диләр. Чөнки аның законнарын үзгәртеп булмый. Ә тел кануннары үзгәрүчән, чөнки телне кешеләр тудырган. Һәрхәлдә боларның шулай икәнлегендә бәхәс тә яши, имеш.

— Моның нәкъ әйткәнегезчә булуына дәлил китерегез?— дип үтенгәннәр мөэминнәр Казый Яхъядан.

Ул исә:

— Без төш күрәбез, әмма аны, мәсәлән, атка атланып йөрүебезне күрсәк, өндә дә атта йөриячәкбез дип түгел, бәлки мәртәбәгә ирешү хәбәре буларак юрыйбыз. Физиканы күргән төшебез мисалында дип белсәк, аны аңлату-юрабыбыз тел мисалында инде,— дигән.— Һәрхәлдә бәндәнең күрелә торган төше Аллаһыдан һәм физика гыйлеменең эчтәлегенә бәрабәр. Шулай түгелме?

## ИКЕ ТӨРЛЕ СӨЮ ТУРЫНДА

*Хикәят*

Кеше башында фикер даими үзгәрүчән түгелме? Менә шушы даими үзгәреше акылның даимилеген тәэмин итә, имеш. Шушы хакта сүз чыккач, боларның шулай икәнлегенә дәлил буларак Казый Яхъя:

— Адәм баласы чын йөрәктән, ягъни йөрәк белән гомерендә бер генә тапкыр гашыйк була, ә акылы-уе белән мәхәббәт диңгезенә туктаусыз чумгалап тора,— дип белдергән.

Мөэминнәр аптырашып калганнар һәм аңардан:

— Ничек инде акыл белән гашыйк булырга мөмкин?— дип сораганнар.

Ул исә, бераз елмаеп алган да:

— Безнең уйларыбыз-хыялларыбыз акыл эшчәнлеге галәмәте. Мәхәббәтне дә күп мәртәбәләр уйлап чыгара алуы сәләттән килә,— дип җавап биргән.— Ә йөрәкнең уйлау, хыял сәләте юк, шунлыктан бер тапкыр гашыйк була да шуны гомергә саклап яши.

## АЛЛАҺ СҮЗЕН АҢЛАУ ЮЛЫ

*Хикәят*

Аллаһының белдергән сүзе белән бәндәнең аны аңлавы һәм кабул итүе арасында көн һәм төн аермасы кебек каршылык бар, диләр. Бу чыннан да шулай, имеш.

Моны төшенгән мөэминнәр арасына бервакыт олы гауга төшеп, барысы да вәсвәсә эчендә калганнар һәм Казый Яхъяга килгәннәр дә, борчылып:

— Безгә нәрсә уйларга, ничек гамәл йөртергә?— дип сораганнар.

Ул исә:

— Гыйлем нигезендә!— дип җавап биргән.— Чөнки бары тик гыйлем генә Аллаһының хакыйкатенә төшенергә ярдәм итә. Башка төрле юл юк. Пәйгамбәребез дә мөэминлеккә гафиллекне каршы куйган. Томаналык ул — көферлек, иманның дошманы. Аллаһының сүзен бары тик гыйлем юлы белән генә аңларга мөмкин. Гыйлемне читкә куйган бәндә мөэминнәрдән була алмый. Үзегез дә беләсез!

## ИГЕНЧЕ ГЫЙЛЕМЕ

*Хикәят*

— Мин сабанда идем. Җир сөреп маташканымда бер юлаучы күренде. Эшемне карап торды да, син, үрләрне сөргәндә, сабаныңны яткырып бар, үзәнлекләрдә тирәннән алдыр, диде дә китте. Инде күңелемә гауга төште: игенем уңармы?— дип, Казый Яхъяга бер сабанчы килеп зарланган.

Казый Яхъя аңардан:

— Ул кеше игенең, Аллаһ бирсә, яхшы уңар дип әйттеме?— диярәк сораган.

— Әйе,— дигән сабанчы.

— Син аңардан кем икәнлеген, кайдан килүен сорадыңмы?— дигән.

— Әйе, ул үзен иген игеп гомер сөрүче икәнен әйтте,— дигән сабанчы.

— Алай булгач борчылма,— дигән Казый Яхъя.— Ул сиңа олы гыйлем биреп узган, аңарга рәхмәтле бул, игенең яхшы уңар!

## БӘБИЛӘГӘН АКЧА

*Хикәят*

Казый Яхъяга бер мөэмин килеп:

— Мин күршемә, сорагач, бер алтын акча биреп тордым. Өч көннән кертәм, диде, китермәде. Барып сорадым. Ә ул, миннән көлеп, алтының бәбиләде, әлегә баласын имезә, аннары кертермен дип әйтте. Мыскылландым. Аны хөкем итегез,— диярәк сөйләп, гозерлектә сораган.

Казый Яхъя исә:

— Имчәк баланы әнисеннән аеру хәрам гамәл. Сабыр ит, базар көне узсын, аннары килерсең,— дигән.

Бу кеше ни уйларга белмичә кайтып киткән.

Базар көне узган. Икенче көнне ул кеше Казый Яхъяга кабат килгән. Бу юлы йөзе балкый икән:

— Нәрсә?— дигән Казый Яхъя.— Ул кеше акчаңны керттеме?

— Берне түгел, икене,— дигән теге.

— Менә бит,— дигән Казый Яхъя,— баласын да үстереп биргән икән!

## КЕШЕСЕНӘ КАРАП

*Хикәят*

— И әфәндем, мин Аллаһы тәгаләдән ничә тапкырлар гозерләнеп, дога әйтеп сорадым, кабул булмады. Сәбәбен әйтсәгез иде?— дип зарланган бер мөэмин, Казый Яхъяга килеп.

— Нәрсә үтенгән идең соң?— дигән Казый Яхъя, аптырап.

Бу адәм исә:

— Әйтсәм — сүз, төртсәм — күз, дигәндәй. Күршем бик тә гүзәллек иясе хатын алды. Һаман-һаман тәмле исләр чыгарып пешеренеп кенә торучыны, буй-сыны да, килеш-килбәте дә илдә бер. Мин дә үземә шундыйны сораган идем,— дип белдергән.

— Ә аның ире бик тырыш кеше инде, шулай бит? Ике кулы даими эштә, аяклары эштә, зиһене эштә. Ә син үзең?— дип сораган Казый Яхъя тагын да.

— Анысы — дөрес! Мин исә әле эштә, әле юк! Хатынымнан да уңмадым,— дигән теге.

— Юк,— дип әйткән Казый Яхъя,— уңгансың, доган да кабул булган. Аллаһы тәгалә нәкъ чиләгенә күрә капкачын биргән. Бар, кайтып, “Әлхәмде”не укы, Хак тәгаләгә рәхмәтле бул!

## ШАЙТАН КОТКЫСЫ

*Хикәят*

— Без китаптан укыдык: “Аллаһы тәгалә ямьлегә — ямьлене, кыйтыга — кыйтыны насыйп итә. Әмма Шайтан бутап йөри, имеш: бер ямьлегә — бер ямьсез, бер кыйтыга — бер яхшы, дип. Шулай да ялгышып китеп: бер ямьлегә бер ямьле дия болгатып та куя икән!”— дип мөэминнәр сөйләгәч, Казый Яхъя көлемсерәп:

— Булыр да,— дигән.— Әмма Аллаһы тәгалә һәркемгә үз ишен бирә. Монысы хак сүз. Әллә нинди мең ят кешеләр дә, бер-берсен танып, кавышып, берсе икенчесенә охшап-охшашып бетәләр. Иш үзенең ишен тапмый калмый, менә шунда Шайтан нәрсә эшли икән?

— Беләбез, сүзегез дөрес!— дигәннәр мөэминнәр.— Халыкта ул сүз бар: “Иш ишен табар, Шайтан койрык астын кабар!” Укыганыбыз хакыйкать булырга кирәк!

## СҮЗСЕЗ ДӘ АҢЛАШЫЛА

*Хикәят*

Кеше казага сабыр итә, бәхеткә түзми, имеш.

Әлбәттә шулай, чөнки ул бәхетле генә булып яшәсә, бәхеткә дә түземле булыр иде. Бәхет аның күргән әйберемени?

Шул хакта бәхәс иткән мөэминнәрдән Казый Яхъя:

— Ә сез Аллаһы тәгалә сабырлар белән икәнен белми идегезмени?— дип сораган.

Алар:

— Белә идек, иманыбыз камил, Коръәндә бу хакта хәбәр бар!— дип җавап биргәннәр.

— Димәк, бәхеткә түзмәгәч, адәм сабырлыгын югалта дигән сүз түгелме?— диярәк тагын да сораган ул.

— Нәкъ шулай!— дигәннәр мөэминнәр.

Казый Яхъя кабат:

— Моның белән сезнең Аллаһы тәгалә бәхетле кешеләрне ташлый дип әйтәсегез килмидер бит?— диярәк кабат сораган.

Һәммәсе сүзсез калганнар.

## ЯМАН ИР ХОЛКЫ
*Хикәят*

Казый Яхъяга бер мөэмин килеп:

— Хатыным бик ямьсез кеше, мин аны талак кылсам, дөрес булырмы?— дип сораган.

Аны тыңлап бетергәч, Казый Яхъя бу бичараның зиһенен тикшереп, соравына сорау белән акылын барларга карар иткән.

— Хатыныңның ямьсезлегенә нәрсәләр дәлил?— дигән.

Ул кеше:

— Борыны — тукмак, авызы — иләк, теле — кайчы, йөреше — үрдәк,— дип санап киткән.

Аның сүзләрен тыңлап торучылар көлешә башлаганнар. Казый Яхъя тыныч кала биргән, аннары:

— Мин синнән хатының ямьсезлегенә дәлил сорадым, ә син эш кораллларын, кош-кортларны санадың. Инде дә килеп, уйда утырып төшендем: бар, холкыңны төзәт, хатыныңнан йөрәгең яралап көлүдән тукта. Аңа хөрмәт белән кара, сиңа талак дөрес түгел!— дип, бу мөэминне әрләп кайтарып җибәргән.

## ИШӘК АКЫЛЫ
*Хикәят*

Бер Ишәк, имчәкләре тулышып торган Сыерга кызыгып, аңардан:

— Нишләп минекеләр дә шулай түгелләр икән?— дип сораган.— Серен өйрәтсәгез иде, гомерем буе сезгә рәхмәтле булыр идем!

— И агай-эне,— дигән аңа Сыер,— аның сере бик тә гади: сез минем кибек мөгрәсәгез, имчәкләрегез дә тулышып торачаклар!

Ишәк шунда ук эшкә керешкән. Мөгрәмәкче булып кычкырып карый икән дә, әмма барып кына чыкмый бит моның.

Сыердан кабат сораган:

— Сез ничек мөгрәргә өйрәндегез соң? Бик авыр бит. Серен әйтмәссезме?— дип.

— Тумыштан мөгрәп туган идем!— дигән Сыер.

— И-и, булмады инде,— дигән Ишәк.— Ә мин әле сезнең теге сүзегезгә ышанган идем!

## ХӘЙРАН СӘҮДӘГӘР

*Хикәят*

Адәмнең җае да үзеннән, җайсызлыгы да холкыннан, имеш.

Шулай бер сәүдәгәр, Казый Яхъяга килеп, зарлык утында көйгәнлеген әйткән һәм:

— Хәзер заманалар бик авыр, ялгыз башка эш итә торган чор түгел, әмма мине һичбер сәүдә иясе дә үз төркеменә кертми, кире кагалар. Гаебем нидә, киңәш бирмәссезме?— дип үтенгән.

Казый Яхъя исә:

— Сезнең кеше малын үзләштергәнегез юк идеме?— дип сораган.

— Аллаһ сакласын!— дигән сәүдәгәр.

— Алган бурычыгызны кайтармый калганыгыз?

— Аллаһ сакласын! Юк!— дигән сәүдәгәр.

— Мирас алып баедыгызмы әллә?— дип сораган тагын да Казый Яхъя.

— Юк! Барысы да хәләл, үз көчем белән табылган байлыклар,— дигән сәүдәгәр.

— Мондый кешене үз араларына сәүдәгәрләрнең кертмәве бер дә гаҗәп түгел,— дигән ахырда Казый Яхъя.— Моңарчы бөлмәвегезгә мин дә хәйран иттем. Адәмгә көнчелек хас!

## ГАДЕЛ ҮЛЕМ

*Хикәят*

Бер түрә халык белән гаугага кергән. Аның үзен дә санга сукмый башлаганнар.

Бу, үзенең кемлеген күрсәтү өчен, халыкны изүнең яңадан-яңа чараларын уйлап тапкан. Әмма халык һаман баш бирми моңарга. Аптырагач, бу түрә мәйдан уртасына дар агачы ясатып куйдырган. Халыкка сабак өчен дип берәүне тотып астыртасы икән дә, лаеклы күрелгән кешене тапмаган. Шулай да ярый, куркырлар әле дип уйлаган. Ә халык, дар агачы яныннан узып-китеп йөресә дә, бу әкәмәткә игътибар итмәгән.

Түрә, моңарга ачуы килеп, дар агачы янына кабер казып куярга әмер биргән. Халыкның моңа да исе китмәгән.

Инде курыкмый калмаслар дип, дарга үзе барып асылынган.

Шунда гына халык:

— Моның да бер гадел гамәле булды!— дип хәйран иткән.

Казыткан каберенә салып, өстенә таш куйганнар һәм язу уйганнар: “Яманлык белән яшәп, гаделлек белән китте!”

## АКЫЛЛЫ КИҢӘШ

*Хикәят*

— Кешедә нинди сыйфат яхшы?— дип сораганнар Казый Яхъядан сөхбәт мәҗлесендәге мөэминнәр.

Ул:

— Сокландыргыч сыйфат яхшы!— дип җавап биргән.

Һәммәсе дә килешкәннәр. Әмма арадан берсе:

— Ә ул сокландыргыч сыйфат башка сыйфатлардан нәрсәсе белән аерылып тора?— дип сораган.

— Сокландыргыч сыйфат,— дигән Казый Яхъя, аңлатып,— адәм баласының һәммә сыйфатларыннан да өстен булыр һәм аларны үзенә буйсындырыр. Кешенең башкалар шул сыйфатына гына игътибар итәрләр, бүтәнен күрмәсләр.

— Ә миндә андый сыйфат бармы?— кызыксынган ул кеше тагын да.

— Әлегә юк,— дигән Казый Яхъя,— сез сорауларыгызга җавапны башкалардан эзләргә яратасыз. Үз башыгыздан түгел.

## ЯСАЛМА КЕШЕЛӘР

*Хикәят*

Андыйлар бармы соң, диярсез сез.

Дөньяда кешеләр ясалма яки табигый генә була, өченче төрлеләре юк, имеш. Адәм баласын — үз табигатенә хилаф итә алмый, диләр, югыйсә. Мәгәр дә шулай икән, ясалма кешеләр каян киләләр соң?

Бу хакта Казый Яхъя:

— Ясалмалык үзеңнең кемлегеңне оста итеп яшерә белүдән килә,— дип әйткән.

— Димәк бу — кешеләрнең хәйләсеннән бер сыйфаты булып чыга,— дигәннәр мөэминнәр.— Андый кешеләрне без акыллы дип беликме, әллә ялганчылар дипме?

— Ясалма кешеләр алар шундый булырлар,— дигән, аңлатып Казый Яхъя,— без чын йөзләрен күреп торырбыз, ягъни табигатьләрен сиземләрбез, әмма ясалмалыкларына алданырбыз. Чөнки шулай булуыбыз үзебез өчен уңайлырактыр.

## ХИСЛӘР АВЫРЛЫГЫ

*Хикәят*

Кешедә мәхәббәтме, нәфрәтме— кайсысы көчлерәк диярәк мөэминнәр бәхәс кыла икән, шунда сүзләренә Казый Яхъя колак салган һәм:

— Болар икесе дә хис төшенчәсенә карыйлар, димәк, аларның куәтләре дә чамада бертөрлеләрдән,— дип әйтеп куйган.

Аның белән башкалар да килешкәннәр. Шунда ул:

— Кешеләрдә мәхәббәт хисе күбрәкме, әллә нәфрәт хисеме?— дип сораган.

Аңарга:

— Кешесенә карап,— диярәк җавап биргәннәр.

Аларга Казый Яхъя әйткән:

— Әйе, сүзегез белән килешәм,— дигән,— Дөнья йөзендә төрле кеше бар. Әмма да ләкин бездә мәхәббәт хисе күбрәк булмаса, әллә кайчан Җир өстен канга батырып бетергән булырлар иде инде!

## РИЗЫК ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

— Аллаһы тәгалә барчабызга да үз өлешен, үз ризыгын бирүче дип беләбез. Моны ничек аңларга тиешбез?— дип, Казый Яхъяга килгән мөэминнәр сораганнар.— Ни өчен соң берәүләребезнең ризыклары өстәлләрен сыгып тора, икенчеләребезнең бер кабым ризык кисәкләре дә юк? Ул өстәлләре сыгылып торучылар нәрсә өчен шундый хөрмәткә лаек та, кисәксез калучылар нинди гөнаһлары өчен шундый җәза күрәләр?

— Әйе,— дигән Казый Яхъя,— берәүләр корсаклары шартлаудан үләләр, икенчеләр ачтан шешенеп җан тәслим кылалар. Һәммә кешенең үз өлеше. Әмма ул ризыкны нинди кул белән тотып ашыйсың бит әле: шакшы кул беләнме, әллә чиста кул беләнме — бөтен хикмәте шуңарда түгелме?

## ТЕАТР УЕНЫ

*Хикәят*

Адәм баласына юләр булуы рәхәт, имеш. Шуңа күрә дә ул туктаусыз кылана. Һәркемдә кылану галәмәте бар, диләр, әмма берәүләрнеке ул матур килеп чыга, икенчеләрнеке килешсез була.

— Ислам динендә ни өчен театр тыела?— дип сораганнар мөэминнәр Казый Яхъядан.

— Мин әле театр тыелганлыгын уйламый идем,— дип җавап биргән ул.— Башкаларча кыланып күрсәтү, кыландыру тыела икәнлеген генә белә идем. Мәгәр табигыйлек белән театр уены гыйбрәт өчен уйналса, ни өчен мондый да тормыш дәресе мөэмин өчен ярамас икән? Уен өчен генә уен икән, табигыйлек һәм гайрәт өчен булмаса, ул — буш уен. Шулар тыеладыр?

## БӘХЕТ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Бәхет көтеп, бәхеткә кенә таянып яшәгән кешене бәхетле дип әйтә күрмәгез, чөнки бәхеттә генә бәхетле кеше асылда чыннан да бәхетле була алмый. Бәхет ул үзеңне бәхетле дип тойганда гына чын бәхет була.

— Бәхет ул,— дигән Казый Яхъя,— бәндәгә тугыры түгел, туктаусыз үзгәрүчән, килүчән һәм китүчән. Мондый да вакытлы әйбергә таянырга ярыймы соң?

— Без гомеребез буена бәхет эзләдек, һәр таң-иртән: “Бу көнебез бәхет китерсен!”— диярәк догалар кылабыз. Безнең гамәлебез хатамыни?— дип хәйран иткәннәр мөэминнәр.

— Бәхет өметендә яшәүдә һәм аның рәхәтен күрүдә хата юк,— дип җавап биргән Казый Яхъя,— хата аңа таянуда һәм бәйле булуда.

## ХАРАБАТ ЮЛЫ

*Хикәят*

Һәркемнең үз акылы — үзенә, диләр. Ягъни кеше акылы белән яшәп булмый, үзеңнеке белән генә ерак та китә алмыйсың, имеш. Менә шуңа күрә дә кешеләр, файдасы булмасмы дип, бер-берсенә киңәш бирешеп яшиләр.

— Син Ләйләңне оныт, ул инде кияүгә чыкты, әгәр дә үзеңне яратса, ярың булуны өстен күрер иде,— дигәннәр мөэминнәр, Мәҗнүнне тынычландырырга тырышып. Ә ул, үпкәләп, алар яныннан китеп барган. Шуннан соң Казый Яхъя әйткән:

— Сез юкка болай эшләдегез. Мәрхәмәтсезлек бу!— дигән.— Аның да дөньяда таянычы Аллаһы тәгалә һәм Ләйләгә мәхәббәте иде. Өметсез — Шайтан, дигәндәй, нигә аның өметен кисеп, харабат юлына бастык? Ай хәлебез!

## АКЫЛ БИРҮ

*Хикәят*

— Юләргә акыл бирмәгез! Сезме моны белми идегез, и мөэминнәр?

— Без бит аның акылсыз икәнен белеп, аңарга киңәш кенә иткән идек!

— Киңәшегезне тоттымы соң?

— Юк, һаман да үзенекен әйтте, үзенчә гамәл итте!

— Гамәлендә хата күрдегезме?

— Хата дип, камиллек һәм ышанычлылык та күрмәдек.

— Ул сездән нәрсәсе белән аерыла, гамәле беләнме, акылы беләнме?

— Әлбәттә акылсызлыгы белән!

— Бәс шулай булгач,— дигән аларга Казый Яхъя,— гамәлендә ул сезләргә иярә икән, аңарга акыл бирәсегез килсә, гамәлләрегезне дөрес һәм күркәм итегез, аңа сүз катуның, сүз белән киңәш итүнең файдасы юк, үзегез дә беләсез!

## СҮЗЕ ХӘЙРАН ИТӘ

*Хикәят*

Мин бер кешене беләм. Аның телендә сандугач сайрый, әмма кулында, каләм йөгерү түгел, орчык та тәгәрәми.

Шундый икәнлеген таный торып, аңардан хәлен сорадым. Сандугачын сайратты. Фикер иттем һәм хәле мөгаен да искечәдер, әллә ни үзгәрешләре юктыр, көненә-көн чираты-чираты белән киләдер, дидем. Уем дөрескә чыкты.

Икенче юлы очрашканда башкача хәйран иттем: сандугачы оясын ташлап очкан икән! Әмма кулында орчык тәгәрәтә башлагандыр дип уема да кертеп карый алмадым. Фалым тагын дөрескә чыкты.

Өченче тапкыр очрашкач, аңардан кәефен сорадым. Ул исә:

— Гомеремне буш сүз тоткынлыгында уздырдым, гамәл белән кичкән булса идем!— дип җавап бирде.

## ӘДӘП СӘҮДӘСЕ

*Хикәят*

Кешеләр ничек, сиңа хөрмәтләре булмый торып, үзеңнән хөрмәт өмет итәргә мөмкиннәр икән? Бу хакта Казый Яхъядан сорадым. Ул миңа:

— Һәм дөрес эшлиләр!— дип җавап бирде.— Әгәр дә бер-бер кешегә аерым хөрмәт күрсәтәләр икән, димәк, белегез, аңарга адәмиләрнең мәхәббәтләре төшкән булыр. Ә калганнарыбыз үзара хөрмәт һәм ялагайлык белән генә алыш-биреш итәбез. Шушы инде әдәп сәүдәсе дип атала. Ә мәхәббәтебез төшкән кеше бу сәүдәдә катнашмый, безне яратуы яки хөрмәт итүе — аның үз эше. Шуның өчен дә хөрмәт яулаганнан мәхәббәт казану уңайлырак та, өстенрәк тә. Хәйран итмәү — хәсрәтлерәк. Әдәп сәүдәсенә йөгер!

## «ТЕЛСЕЗ КҮКЕ»ЛЕ МӘҖЛЕС

*Хикәят*

Юләрне кимсетү — хәрәм, аңарга авыр сүз дә әйтергә ярамый, диләр. Имеш, казасы була.

Мөэминнәр мәҗлесендә булдым. Анда иң күп сөйләгән кешеләрне күрдем. Надан иделәр. Хәйран иттем. Сорадым:

— Бу ни хәл? Ничек сез аларны тыңлап утыра һәм егылып алкышлый аласыз?— дидем.

Миңа серле һәм мәгънәле елмаеп җавап бирделәр. Уйланып алдым: болар аларны тыңлап, алар кебек ничек ахмак, надан һәм көлкеле булмаска өйрәнәләр икән бит, дидем. Шушы фикеремдә йөргәнемдә:

— Тагын нинди тамаша күрсәтерләр икән?— дип миннән сорадылар.

Җавабым гади булды:

— Инде телсезләргә дә сүз бирерләр!

## КУЛДАН ДА, ТЕЛДӘН ДӘ КИЛМӘГӘЧ

*Хикәят*

Берәүләр үзләре һәм тормышлары белән генә уйнап калмыйлар, бәлки башкаларның да язмышлары белән шаяралар. Моның өчен аларның уй-фикерләрен, хис-тойгыларын уйнатырга тырышалар. Шулай кемлеккә ирешәләр.

Бер түрәдән:

— Сәясәтнең башка юлы юкмыни?— дип сорадым.

Ул аптырап калды.

— Мин андый эш белән шөгыльләнмим. Сөйләгән сүзем хакыйкатьтән генә гыйбарәт,— диде.

Хәйран идем. Шунда сандугач булмакчы ишәк турында мәзәк исемә төшеп, көләсем килде.

Түрә:

— Нигә елмаясыз?— диде.

Мин исә: “Сандугач кебек сайрыйм, сезнең колагыгыз каты. Шуңа күрә сайраганымны кычкыруга тиңлисез, диярәк зарланган икән, имештер, ишәк!”— дип уйладым, әмма телемә сүз алып әйтеп бирә алмадым.

## ГАДЕЛЛЕК БИТЛЕГЕ

*Хикәят*

Дөньяда ни өчен ахмаклар күп икән дип уйланып-уйланып йөри идем, баксам, үзем дә шундыйлардан икәнмен. Бу хакта дустым белән киңәштем. Ул:

— Әллә белми идең?— дип сорады.

Күңелем кителде.

— Борчылма,— диде ул,— мин үзем дә шундый. Һаман кәкре каенга терәтеп калдыралар.

— Хикмәт нәрсәдә соң?— дидем.

— Җавабым бик гади: тормышта күпләр гаделлек уены уйныйлар. Әмма шунысы бар, гаделлек исеменнән яманлык эшләнелә.

— Ә без ничек алдан күрә алыйк соң?

— Бик гади,— диде ул,— мәнфәгать булган җирдә яманлык бар. Әмма яманлык үзен яшәтү өчен гаделлек битлеген киеп йөри.

## ЯШӘГӘННӘР БИТ ӘЛЕ

*Хикәят*

— Дөнья хәйләкәрләр, комсызлар һәм мәкер ияләре кулында,— дигән Казый Яхъя.— Сез моны үзегез дә беләсез. Әмма алар үзләрен иң акыллы, иң бул-

дыклы дип уйлыйлар. Халык шуларның күзенә ахмак, аңгыра, тинтәк сыман күренә.

Тыңлап торучы мөэминнәр хәйранга калганнар. Дөрес сүзне дошманың түгел, дустың да яратмый, диләр. Бәгырьгә төбәп атылган ук кебек килеп кадала, имеш. Шулай да бер мөэмин, бу хакта уйлап хәсрәт чигүеннән айнып сораган:

— Безгә нәрсә эшләргә соң?— дип.

— Йөрәгегез һәм куәтегез җитсә, дөньяның тәлинкәсен әйләндереп капларга,— дигән Казый Яхъя,— мәгәр юк икән, җитмәсә, сарык хәленә төшеп, аңгыраланып яшәргә! Моңарчы шулай яшәгәннәр бит әле!

## КАНУННАР ҮЗГӘРЕШЕ

*Хикәят*

Аллаһы тәгаләне мескеннәр ягында, диләр. Шуңа күрә дә аларга дөньяда яшәве җиңел, имеш, чөнки ишәкләрен бәйләп куйган чагында да аны Аллаһыга тапшыралар.

Яхъя казыйдан мөэминнәр сораганнар:

— Ни өчен Аллаһы тәгалә безне әрсез, комсыз, үзләре өчен генә яшәгән түрәләр кулына бирә?— дип.

— Чөнки,— дигән Казый Яхъя,— алар шушы сыйфатлары белән дә, акыл үсешләре белән дә мескеннәр. Шуның өчен!

— Димәк алардан котылу чарабыз юк, шулаймы?

— Әлегәчә булмаган. Инде сез мондый сорау биргәч, бәлки уйлана да башлагансыздыр? Мөгаен Илаһият кануннары да үзгәрешкә юл алганнардыр?— дип сүзен тәмамлаган Яхъя казый.

## ГАДЕЛЛЕК СӘБӘПЧЕСЕ

*Хикәят*

Халык мәнфәгатен уйлауны әгәр урынны саклау һәм мәртәбә арттыру хәсрәте алыштырса, түрәләр бозыла, имеш. Хикмәти Хода, адәм баласының бармаклары үзенә таба кәкре итеп яратылганнар шул. Бу хакта Казый Яхъя:

— Ишәкне түрә итеп куйсаң, ул дөньялыкны ишәк утары итеп аңлар, сарыкны куйсаң, көтүлектәй белер,— дигән, мөэминнәрнең хәтеренә тиеп.

Алар исә:

— Арыслан түрә булса, аңардан гаделлек көтү дөресме?— дип сораганнар.

— Гаделлекне көч һәм кодрәт иясе кешеләр үзләре урнаштырыр, мескеннәр исә башкалардан өмет итәр,— дип аңлатып биргән Казый Яхъя.— Менә шуңа күрә дә мескеннәр түрә булган илдә гаделлек юктыр!

## ЧАМАЛЫ БӘХЕТ

*Хикәят*

Яуган вакытында яңгыр: “Мин явам әле, явам әле!”— дип сөйләнеп ява, кояш, җир йөзен җылытканында: “Киптерәм әле, киптерәм!”— дип елмая, җил исә: “Исми торсам — туктармын, исәм әле, исәм!”— дия, имеш. Боларның тырышуларын күргән кешеләр яңгырны туктату, кояшны күләгәләү, җилне тыю өчен ниләр генә эшләмиләр. Әгәр дә алай итмәсәләр, начар булыр идемени? Һич юк.

Әмма Казый Яхъя исә:

— Без, кешеләр, канатлы булсак — җилгә, селәүчән икәнбез — яңгырга, ком булсак — кояшка сөенер идек,— дип белдергән.— Әмма безнең мөмкинлекләребез чикле. Шуңарга күрә дә яңгырны да, кояшны да, җилне дә юк чакларында гына сагынабыз. Килеп, озакка калсалар, алардан тәмам туеп бетәбез!

## КҮҢЕЛ БОЗЫЛУ

*Хикәят*

Кешене көй, мәхәббәт һәм табигать матурлыклары әсир итү көченә ия, әмма аларның ямьсезлеге адәмне азат итәме? Юк, диярсез, гайрәтен генә чигерер, күңелен генә бозар, диярсез.

— Синең нәрсәңне адәмиләр яраталар соң?— дип сораган Сандугачка очраган бер Чыпчык.— Миннән әллә ни аерманң да юк үзеңнең!

— Сайраганымны!— дип җавап биргән Сандугач.

— Анысы шулай, әмма мине ул сайрауларың бер дә хәйран итми,— дигән Чыпчык.— Ачуланма, бәлки зәвыгым гына шундыйдыр.

— Юк-юк,— дигән Сандугач,— һич ачуланмыйм. Мин дә синең кебек чыркылдый алмыйм бит.

— И юньсез,— дигән Чыпчык, ачуы килеп,— минем җырлавымны чыркылдауга тиңлесең! Минем кебек була алганың бармы?

Һәм моннан очып китү җаен караган.

## ЯЛГАНЛЫКНЫҢ ХӘРӘМЛЕГЕ

*Хикәят*

Ялганның хәрәм икәнлеген һәркем белә, ягъни ул адәм баласына зарарлы гамәлләрдән санала. Әмма риясыз, чын күңелдән, оста итеп ялганласалар, аннан да татлы һичнәрсә юк, имеш.

Яхъя Казый әйткән:

— Ялганның олысы-кечесе юк, аның бары тик татлысы һәм ачысы гына бар!— дигән.

— Ә ни өчен хәрәм, ни өчен зыяны бар?— дигәннәр мөэминнәр.

— Ялган ул никадәр татлы булса, шулкадәр исертүчән, бәндәнең акылын сәрхушландыра. Анысы гына ярый. Әмма хакыйкатьне төшенгәч, айнып кит-

кәндәй буласың, тик ялганның махмыры гына күңелдән китмичә, җанны укшытып тора. Шуңа да зыяны күп!— дигән Казый Яхъя.

## ГЫЙЛЕМ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Хикәят*

— Гыйлем өйрәнү, укуны бәндәгә хәләл, диләр. Ни сәбәптән?

Шушы сораулары белән мөэминнәр аптыраткач, аларга:

— Чөнки бәндәнең зиһененә, акылына, гамәленә файдалы!— дип җавап биргән Казый Яхъя.

— Буш гыйлемнәр буламы?— дигәннәр тагын да.

— Буш гыйлемнәр юк, буш башлар гына бар,— дигән аларга Казый Яхъя.

— Башлар буш булгач, нигә аларга гыйлемне җиңел генә салып булмый?— дигәннәр кабат.

— Чөнки гыйлем буш урынга ябышмый, буш урынга керми, буш урыннан чыкмый,— дип җавап биргән ул да.

— Моның мисалы бармы?— дип сораганнар аңардан.

— Бар!— дип җавап биргән ул.— Гыйлемнең мисалы — күңелнең нуры кебек!

## САЛАМ ҖӘЕП КУЙГАНЧЫ

*Хикәят*

Кеше ялганласа, хәрәмләмә, диләр, ягъни, зыян китерәсең дип әйтүләре бу. Ә кем инде кешегә зыян салудан үзенә файда килә дип өметләнми калмый? Һәм менә шунда ялгыша да. Башкаларга иткән зыян үзеңә бәла булып әйләнеп кайта.

— Бәладән котылу чарасы бармы?— дип сораганнар Казый Яхъядан.

— Әлбәттә бар,— дигән ул,— моның өчен дөрес яшәргә кирәк.

— Әмма яшәү-яшәмәвебезне ничек белик?— дигәннәр мөэминнәр.— Бәла шул ул ахырдан, эш узгач килә.

— Анысы шулай,— дигән Казый Яхъя,— алдан салам җәеп куеп булмый, әмма кая басканыңны карап йөрергә була!

*01.04.06.*

## ДӨРЕСЛЕК ТЕРӘГЕ

*Хикәят*

Гаделлек кенә аз, ул дөреслеккә таяна, шунда гына күзгә күренерлек була ала, диләр. Әмма дөреслекнең күрке төрлечәрәк, имеш.

— Түрәлектә дөреслек нинди була? Без андыйларны ничек таныйк?— дип сораганнар мөэминнәр.

Казый Яхъя аларга:

— Дөреслекнең күрке намус куәте белән билгеләнә,— дип җавап биргән.

— Моны ничек аңларга?— дигәннәр кабаттан.

— Әгәр дә кешенең күңелендә намус хисе бар икән, хатасын сизенеп, вөҗданы газапласа, ул кешедә намус оя кора башлаган булыр. Иртәме-соңмы анда намусы көч алыр. Намусы юк кешедән дөреслек эзли күрмәгез,— дип җавап биргән Казый Яхъя.

## ДӨРЕСЛЕК ӨМЕТЕНДӘ

*Хикәят*

Олылык, дәрәҗә һәм мәртәбә иясе бер кеше миннән үзенең дөреслек әһелеме-юкмы икәнлеген сорады. Аңа намус мәсьәләсендә сүз кузгатырга кыймадым. Әмма:

— Бу сорауны бирүегез бик яхшы. Һәр кешегә шушы дөньяда үзе эзләгәнне табу насыйп!— дип җавап бирдем.

Башсыз адәм түгел иде, үпкәләде. Моңарчы аңа минем сүзләрем һичбер төрле тәэсир итмиләр иде, дөньяга көлеп кенә карап яшәде. Ә бу юлы тойгыхисләренең яңаруын күрдем һәм: “Моның да вөҗданы уяна башлаган икән!”— дип уйлап алдым.

Ул миңа:

— Син мине дөрес кеше түгелсең дисең инде алайса?— диде.

Аны юатырга теләмәдем.

## БУАЛЫ БАЛАК

*Хикәят*

Электән күреп белгән кешеләрем төрледән-төрле булдылар. Арадан берсе, мәсәлән, үзен генә бар дип уйлый, башкаларны һич тә танымый иде. Юк, исәнләшү-күрешү хакында сүз бармый, кеше фикерен тыңлау, санга алу хакында әйтәм. Тормышта үз урынын таба алмыйча җәфа чигәр бу дигән идем, ялгыштым. Журналист булып эшкә урнашты. Гомере буена газетада шул ук бүлекне җитәкләде. Һаман бер үк булып кала бирде: башкаларның язмаларына юл бирмәде, үзенең киләчәктә бөек әсәр язачагын искәртә торды. Очрашкач, бик яхшы бер мәкалә укуымны аңарга әйттем. Мактадым. Ул балкып китте. Эчтәлеген искәрттем. Ул кара көйде. Юләрдән сорама диләр бит, әйтеп ташлады:

— Мин аңарга юл бирмәгән идем, кайда бастырган ул аны?

## ЯМАНМЫ-ЮКМЫ?

*Хикәят*

Улын сорап иптәшләре килгәч, Казый Яхъя аларга:

— Өйдә юк иде шул,— дип әйтеп, аларны үз юллары белән җибәргән.

Ишетеп торган хатыны:

— Нигә аларга ялганладың? Алдакчы булдыңмы әллә?— дип сорагач, Казый Яхъя:

— Юк, алдамадым, гадел гамәл кылдым!— дип җавап биргән.

Хатыны исә:

— Ялган сүз сөйләү кайчан гаделлек булды әле?— дип тавыш чыгаргач, ул:

— И хатын,— дигән,— үзең дә беләсең, улыбыз бүген талчыгып, инде бераз ял итеп алмакчы иде. Черем иткән җиреннән торып кына килгән чагы түгел идеме? Мондый вакытында аны өйдә юк дип әйтүдән яхшы чара бар идеме?

## КҮП СӨЙЛӘШҮ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Казый Яхъяның хатыны, юктан гына тавыш чыгарып, канәгатьсезлеген белдергән. Имеш, башка ирләр хатыннарына хатын дип эндәшми, башка төрле матур сүзләр табалар икән.

— И юлдашым,— дигән аңарга шунда Казый Яхъя,— син дә, мин дә белгән Коръән шулай куша түгелме? Хатын сүзен башкасы белән алыштыруда нинди файда күрәсең?

— Синең миңа мөнәсәбәтеңне белермен,— дигән хатыны, үз сүзендә торып.— Җанашым, дисәң, сөйгәнеңне белермен, иптәшем, дисәң, дуслыгыңны!

— И-и, алай булгач син минем күгәрченем инде, әйеме, хатын?— дигән Казый Яхъя.— Гү-гү итеп кенә торасың!

## БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

*Хикәят*

Гашыйклар сөхбәтендә сүз чыккан. Нәрсә ул беренче мәхәббәт? Ул кеше өчен кирәкме? Нинди мәгънәгә ия?

Бер мәҗнүн мәхәббәтне кояш белән тиңләгән. Имеш, аның яктысыннан һәм җылысыннан башка бер дә яшәп булмый, дигән.

Икенчесе янар таулар белән тәңгәл куйган.

Өченчесе чәчәкле, сайрар кошлар белән тулы бакча белән чагыштырган.

Бу сөхбәткә Казый Яхъя да килеп кереп, аларның сүзләренә колак куеп утыра икән. Фикерен әйтергә инде аңарга чират җитеп:

— Сез генә калдыгыз, беренче мәхәббәт ни-нәрсә, шуны сөйләрсезме?— дигәннәр сөхбәттәгеләр.

— Беренче мәхәббәт ул яналмыйча калган хис кенә,— дип җавап биргән аларга Казый Яхъя.— Чи утын кебек. Йөрәк мичендә көйрәп, төтенләп ята да ята. Ни җылытмый, ни сүнә белми.

## СӨЕКЛЕ ИЛ
*Хикәят*

Мөэминнәр дәүләт корылышы турында бәхәс кылганнар. Арадан берсе:

— Ни өчен ил берәүләрдән икенчеләрне таларга-талатырга мөмкинлек бирә?— дип, шунда беркатлы сорау биргәч, андагылар һәммәсе шым булып калганнар.

Шунда Казый Яхъя:

— Аннары аларның үзләреннән шуны ук җайлап кына суырып алу өчен,— дип җавап биргән.

— Ничек инде?— дип сорау биргәннәр алар.

— Бик гади,— дигән Казый Яхъя,— әгәр турыдан-туры халыкның үзеннән җыеп алса, мондый хөкүмәткә беркем чыдамас иде. Ә кеше көченә яшәүче байлардан малларын бүлешүне, ягъни бер өлешен үзенә алуны таләп иткәч, без моны дөрес һәм гадел эш, дибез. Асылда бу һаман шул ук, халыкның өлешен дәүләт белән байның бергә бүлешүеннән генә гыйбарәт. Әмма анда да тулы килеш һәм урталай түгел. Шуңа да байлар әнә шундый хөкүмәтне бик яраталар.

## ВАТАН ШУЛ УЛ
*Хикәят*

Ватанны сөю хисе адәмиләр өчен мөкатдәс, диләр. Шуңа да алар иленнән киткәннәрне яратмыйлар, имеш. Гүяки бәхетне эзләп табарга түгел, көтеп алырга кирәк.

— Ватанга нәфрәтләнеп буламы?— дип сөйләшеп утыралар икән мөэминнәр, араларына Казый Яхъя килеп кергән һәм, аларның сүзләрен тыңлап-тыңлап торган да:

— Ватаныңда яшәү тәмуг газапларына тиң икән, монда калуның мәгънәсе нәрсәдә?— дип сораган.

— Туган туфракны үзең белән күтәреп алып китеп булмый бит,— дип җавап биргәннәр аңарга.— Сагындыра!

— Шул шул менә!— дигән Казый Яхъя.— Ватанны ташлавы авыр, аңа яки үпкәләргә, яисә рәхмәтле генә булырга мөмкин. Нәфрәтләнү язмаган.

## ЧАМА ХИСЕ
*Хикәят*

Берәүнең мәртәбәсен юкка чыгарырга кирәк булса, кешеләр аның турында гайбәт тараталар. Гайбәтнең шундый хикмәте бар, имеш, ул адәмиләр күңелендә чүпрә кебек күперә, камыр кебек ташып чыга, зиһенгә зыян китерә.

Казый Яхъя әйткән:

— Гайбәтнең файдасы юк, зыяны гына күп!— дип.

— Ул вакытта ни өчен кешеләр аның белән авыз чайкыйлар соң?— дигәннәр мөэминнәр.

— Үз мәртәбәләрен күтәрү өчен,— дип җавап биргән Казый Яхъя.

— Алай булгач, аның файдасы бар түгелме?— дигәннәр мөэминнәр.

— Чама белән булганда агу да дару, әмма чамасы бозылганда агу үз көченә кире кайта,— дигән Казый Яхъя.— Ә гайбәтле сүздә чама хисен саклавы авыр.

## ТАВЫКЛЫ ТОРМЫШ

*Хикәят*

Адәмдә зарлану галәмәте бар, имеш.

Шундый сыйфатлы бер ир хатынынннан зарлана икән:

— Тавык күп асрый, аларны ашатып туйдырып бетерү мөмкин түгел,— дип, хәленә кергән башкаларның раслык белән баш болгап утыруларына куанып.

Шушы сөхбәттә булган Казый Яхъя:

— Сез, карендәш, табипларга да күренгәләп аласызмы?— дип сораган.

Теге кеше, аның сүзләренә бик тә гаҗәпсенеп:

— Нидән мине авыруга чыгарасыгыз килде? Бик сәламәт хис итәм үземне,— диярәк, аңарга үпкәләвен белдергән.

Шунда Казый Яхъя:

— Хәер, сезгә табипның кирәге калмаган булырга кирәк,— дигән,— тормыш бинагыз тавык күкәеннән салынганлыгын онытып җибәргәнмен, гафу итегез!

## ЭРЕДӘН КУБУ

*Хикәят*

Кайберәүләр тавыклар хуҗасы дип әтәчне, ишек алдына баш диярәк этне, йортка ия дип мәчене беләләр. Һәм ялгышмыйлар. Бәхәсләшеп тә торасы түгел.

Әмма тавыклар кетәклегенә Ата Казны хуҗа итеп куйганнар. Ул икенче көнне үк фәрман чыгарган:

— Моннан соң күкәйләрне казныкы кадәр эре итеп салырга!— дигән.

Моңа кадәрле көненә ике күкәй салучы тавыклар ике көнгә берне генә китерә башлаганнар. Тик күкәйләре барыбер дә казныкы кадәр түгел, һаман да тавыкныкы икән. Шуннан соң Ата Каз әйткән диләр, имеш:

— Нишләп хуҗабыз, бу тавыкларны бетереп, казлар гына асрамый икән?— дип.

## ИСЕМ АЛЫРГА ИДЕ

*Хикәят*

Мөэминнәр сөхбәтендә бер кеше үзенең аңсызлыгыннан зарлангач, Казый Яхъя аңарга:

— Нигә шушы кадәр борчылдыгыз? Академикларыбыз аңсыз булсалар да олуг галим исемен күтәреп йөрткәндә беребез дә сезне тинтәклектә ачуланырга җыенмаган идек,— дигән.

Бу кеше исә:

— И туган,— дигән,— минем ул академикларда эшем юк, алар тормышын мин яшисе түгел, аларга төшкән нәфрәтне күтәрү язмаган. Кайгырганым үзем өчен. Үземнеке — үземә!— дип каршы чыккан.

— Анысы аңлашыла,— дигән Казый Яхъя,— әмма сезнең бу көнгә кадәр академик булып танылмавыгыз гына сөендерә. Без шул хакта әйткән идек!

## ШАЙТАН ЯЛЧЫЛАРЫ

*Хикәят*

Кеше үзен бәхетле итеп тойсын өчен дөрес яшәргә тиеш, диләр. Дөреслек белән табылмаган байлык та, дан-дәрәҗә дә кешегә җан тынычлыгы бирми. Бу хакта бәхәс юк. Әмма дөреслек үзе байлык та, дан-дәрәҗә дә бирми, имеш.

— Аллаһыга таяну дөресме? Әллә дөреслеккә таяныргамы?— дип бәхәс кылган мөэминнәргә Казый Яхъя:

— Аллаһы тәгаләне хакыйкать дип беләбез түгелме? Ничек аны дөреслеккә каршы куярга мөмкин? Аллаһыга Аллаһының үзен каршы кую була түгелме?— дигән соравын куйган.

Алар өнсез калганнар. Шунда Казый Яхъя:

— Дөреслеккә таянмыйча торып, Аллаһыга дога күтәрүебез үзе үк көферлек,— дип белдергән.— Дөреслек тойгысын ташлаган бәндәне Аллаһы тәгалә дә калдыра! Алар — Шайтан ялчылары!

## КЕМ СОҢ БЕЗ?

*Хикәят*

Кешеләргә дуслыкта һәм хезмәттә кайсы хайванат данлыклы булуын сорасагыз, эт икәнлеген үзегез дә яхшы белүегезне генә искәртә алам.

Шулай бервакыт мөэминнәр:

— Ни өчен соң без, кешеләр, шундый да тугыры хайванны эт дип атыйбыз? Начар адәмнәрне дә эт, дибез? Тугыры дустыбызның алдына сөяк ыргытабыз? Эт күңеле — бер сөяк, имеш!— диярәк сөйләшеп утыралар икән, Казый Яхъя:

— Чөнки без, кешеләр, үзебезне бик акыллы, бик яхшы, афәрин дип беләбез. Шуңа күрә, әгәр дә кемдер тугрылык күрсәтсә, дуслык итсә, бу шулай тиеш, без моңа лаеклы дип уйлыйбыз,— дигән.— Ә яхшылык иткән затка табыныбызның калдыгын да кызганабыз.

## ЯСАЛМА КЕШЕЛӘР АРАСЫНДА

*Хикәят*

Башкаларның үзеңне сөюен теләсәң, әүвәле үзең аларны сөй, диләр. Әмма ул ясалма булмасын. Ясалмалык җанны өшетә, имеш. Тик кешеләрнең күбесе ясалма. Һичничек ихласлы була алмыйча интегәләр.

— Ихласлыкка нәрсә комачау итә?— дип сорау биргәннәр Казый Яхъяга мөэминнәр.

Ул исә:

— Акылсызлык!— дип җавап биргән.

— Ничек инде алай? Акылсызлыкның монда нинди катнашы бар?— дигән кешеләр дә табылган.

Ул тагын да:

— Чөнки акылсыз кешеләр асылда хәйләкәр булалар. Күпләр, акылларының көче җитмәгәч, хәйләгә керешәләр,— дип җавап биргән.— Ә хәйлә ул бары тик ясалмалык тудыруга гына сәләтле. Шулай түгелме?

## ЯЛГАНЧЫНЫ АЛДАЛАУ

*Хикәят*

Ялганчы кешеләрнең ясалма булулары һичкем өчен дә сер түгел. Андыйларны төз юлга кертү — кәкре агачны төзәйтү белән бер, имеш. Әмма кулдан гына килми.

— Ялганчыны ялганында тотудан ул кеше акыл сабагы аламы?— дип сорый икән бер мөэмин.

Аңарга икенчесе:

— Әлбәттә ала,— диярәк җавап биргән.— Бу ялганында тотылгач, икенче юлы оятлы булмасын өчен тагын да хикмәтлерәген уйлап таба.

— Димәк, ялганчыны туры юлга кертеп булмый!— дигән беренчесе.

Бераз уйлап торгач, икенчесе:

— Була,— дип җавап биргән.— Казый Яхъядан ишеттем. Ул, ялганчының ялганлаячагын белсәгез, “әйе” дип аның сүзен җөпләп торыгыз, юкса тагын да авыррак хәйлә корыр, шунда батырыр. “Әйе” һәм “ярар” белән сөхбәтегезне бетерсәгез, үзегезгә дә уңайлы булыр, ялганчы да остармас, диде. Мин дә шулай уйлыйм.

## АЛАЙ ДА БУЛАМЫ?

*Хикәят*

Иренә хатыны сөйли:

— Табипка күренергә барган идем...

— Нәрсә диде?

— Чишенергә кушты,— ди хатыны.

— Чишендеңме соң?— дип сорый ире.

— Юк инде, син нәрсә,— ди хатыны.— Мужик иде бит ул!

— Ә табип кайда иде соң?— ди ире, аптырап.

— Соң,— ди хатыны,— шул мужик иде бит инде. Син тагын бигрәк...

— Ярар... Чишенмәдең, тагын нәрсә диде соң?

— Синең белән килергә кушты.

— Анысы нигә тагын?

— Мин аңардан булышуын сораган идем. Ул, ирегез белән килегез, чишендереп бирер, диде. Аның чишендерәсе килмәде бит!

Ире аптырап кала:

— Алай да була микәнни?

— Була икән шул,— ди хатыны, мыскылланып.— Хатын-кызга кызыкмаган ирләр дә бар икән дөньяда.

## БАРНЫ ЮК ИТҮ

*Хикәят*

Тормышта кеше юкны бар итеп кенә калмый, барны да бик оста юк итә, диләр. Әлбәттә барны юк итү җиңел, имеш.

Бер кеше икенчесенә нәсихәт бирә иде. Аларны күргәч, уйлап куйдым: болар аталы-балалы, яисә туганнар булырга кирәк! Югыйсә нәсихәт бирү өчен кемендә ике шартның үтәлүе кирәк: беренчедән, нәсихәтче ак белән караны бутамасын, икенчедән, нәсихәтләнүче кешегә яхшылык теләсен!

Тегеләрнең берсе нәсихәтен бирә торды, икенчесе киреләнүендә булды. Берсенең киңәше икенчесенең күңеленә ябышмады диләрме әле? Нәкъ шулай булды. Ахырда нәсихәтчесе:

— И мин юләр, и мин ахмак!— диде.

Аңарга икенчесе:

— Акыл өйрәткән буласың әле җитмәсә!— дип әйтеп куйды.

## НИ ДИГӘН СҮЗ ИДЕ ИКӘН?

*Хикәят*

Үзеңне кеше итеп тоя башларга теләсәң, тәмәке тартуыңны ташла, әгәр тәмәке тартмагансың икән, башка бер кыйты дип тапкан гадәтеңнән арын. Әгәр дә моны да эшли алмасаң, син нинди кеше буласың инде?

Бер дустым очраган иде. Гомеренең сиздерми генә уза баруына зарланып сөйләде. Мин аңарга:

— Борчыласыгыз юк, матур яшисез,— дидем.— Көлкерәк чакларыгызны да күргәнем булмады.

— Рәхмәт,— диде ул.— Гомерем буена үзем белән көрәшеп яшәдем.

— Алай икән,— дидем мин.— Сезнең кебек батыр кешене мактарга гына тиешлебез!

— Юк,— диде ул.— Кешеләр алдында начар буларак күренергә курыккан кеше батыр була алмый.

Мин аптыраашта калдым, ул, юлын дәвам итеп, үз уйлары белән китеп барды.

## ДУСЛАР АРАСЫНДА

*Хикәят*

Бүтәннәргә карата хөрмәтле, кешегә кешечә мөнәсәбәтле кешенең дуслары да күп була, диләр. Моның шулай икәнлегенә бәхәс юк, имеш.

Бервакыт халыкта талант иясе сыйфатында танылган танышымны очраттым. Тормышы, яшәеше хакында сөйләде. Моңа кадәр аның кем турында яхшы сүз әйткәнен ишеткәнем юк иде. Ул миңа:

— Син бигрәк ялагай кеше инде,— диде, ачулануын сиздереп,— һәммә кешене мактап йөрүдән артыгын кылганың юк. Наданга әгәр, син надан, димәсәң, талантсызга буш куык икәнлеген әйтмәсәң, дөньялыкны җыен җәбәхәер каплаячак бит! Инде шулай булып бара.

Мин аңарга, бу сүзләреннән соң хөрмәт күрсәтеп:

— Әйе, дөрес әйтәсез!— дидем.

Бу юлы ул мине нигәдер ялагайлыкта гаепләмәде.

## МИЛЛӘТЧЕЛЕК

*Хикәят*

Милләтчелек кешенең рухында түгел, тәрбиясендә, имеш. Дөресрәге, тәрбиясезлегендә, диләр. Тәрбияле кешенең беренче сыйфаты — үзенең чын йөзен яшермәү һәм, икенчесе, башкаларның кемлеген тану икәнлеген төшендереп торасы түгел.

Ә бер танышым милләтче булуы белән аерылып торган кешеләрдән. Аның милләтчелеккә мөнәсәбәте нindидер сихри рухи көч белән сугарылган.

Мин аңарга бер якташыбыз һәм милләттәшебез хакында мактап сөйләдем. Әмма ул аны миңа караганда яхшырак та, күптәнрәк тә белә икән. Хурлый һәм начар гадәтләре хакында сөйли дә башлады. Сүзләре колагыма керсә дә күңелемә ятмадылар.

Шунда аңа:

— Сез чыннан да олуг милләтче икәнсез!— дидем.

## КЕШЕ ХАТАСЫ АРКАСЫНДА

*Хикәят*

Тел мәсьәләсендә ифрат та таләпчән бер галимә хатынны үпкәләттем.

Ул:

— Бик матур җөмлә укыдым, болай башланып китә: “Дөнья һаман да тәгәри...”— дип сөйләп алып китте.

Нотыгын дәвам иткәнендә мин тыелгысыз көлеп җибәрдем. Көнчелегем сәбәпледер дип беләм. Үземне мактамаулары аркасында булуы да бик мөмкин.

— Дөньяның тәгәрәми, ә бәлки әйләнгәне әллә кайчаннан мәгълүм бит инде,— диярәк башлап,— шушы да җөмлә булдымы?— дип өстәдем.

Мәҗлес гөж итте, гүяки шөпшә оясы урыныннан кузгалды. Һәммәсе дә йөземә ташланып, шушы минутта үземне аямый ашап бетерәчәкләр иде. Әмма десертка калдырдылар. Шунда уйлап куюны кирәк таптым:

— Күрә белү дә бәла түгел, күп ишетү дә зыянсыз, әмма кеше хатасын төзәтүдән яманы юк!

## МӘҖНҮНЛЕК

*Хикәят*

Мәхәббәт нәрсә ул?

Берәүләр аны бәла, диярләр, икенчеләр бәхеткә санарлар. Ә мин исә акыл белән йөрәкнең тарткалашуы, дим. Чынлап түгел, юри генә, үртәр өчен әйтәм һәм мәхәббәт миннән үч ала башлый, дөньялык үзенең чибәр кызларын матурдан-матур киендереп, аларны алларымнан уздырып, менә монысын күр, әнә анысына кара, алын ал, гөлен өз дип үрти башлый. Акыл исә һаман да үз көчендә:

— Егет, бирешә күрмә, башыңны ашыйлар!— дип нәсихәтен бирә.

Шушылай бер эсселе, бер суыклы булып йөри торгач, ахырда мин дә тынычланам һәм, мең сөенеп, дога укый башлыйм:

— Йа Ходаем, сынауларыңа сынаттырмый торган ихтыяр көче биргәнең өчен рәхмәт сиңа!

Аваз ишетәм:

— Юләр! Дивана! Ди-ва-на!

## ДӨНЬЯ ГАҖИЗЛЕГЕ

*Хикәят*

Дөнья сине гаҗизлим дисә, гел шулай аптырата инде ул.

Менә, театрга барган идем, урыным бер әби янына туры килде. Уенның башыннан ахырынача аның “өч тиенлек хезмәтчесе” булып, артистларның сүзләрен тәрҗемә итеп утырдым. Җитмәсә ул:

— Бу — Нәҗибәме?— дип сорый.

Мин:

— Юк, бусы — Гөлбикә!— дим.

Ул:

— Нинди Гөлбикә булсын? Нәҗибә Сафина бит,— ди.— Туфан Миңнуллинның хатыны! Мине милләтем белән кызыксынмаучыга санамагыз! Унбиш ел туктамыйча йөрим. Аны да танымагач!

Башкасын сорый.

Ни дияргә дә белмим: әллә артистны атарга, әллә аның уендагы ролен?

— Хөснуллин!— дим.

— Кем ул?— ди.

— Күмхуҗ рәисе!— дим.

Гаҗизли инде, гаҗизли дөнья, нишләтәсең!

## ДАН-ДӘРӘҖӘ ӨЧЕН

*Хикәят*

Усал эт сыйфатлы кеше ялагайланса, шундый итеп ялагайлана икән ул, бөтен җиреңне ялый-ялый, хәтта үз теле юкарып бетә.

Менә шундый тамашага дучар булдым да аптырап калдым. Акылым хәйран иде.

— Моңарга нәрсә булган?— дип сорадым танышларымнан.

Алар:

— Әллә белми идегез?— диделәр, акылымны аптыратып.— Ул бит дәүләт премиясе алмакчы иде. Ничә еллар рәттән үзен куйдырды. Теле аркасында гына бирмәделәр моңа, теле аркасында гына! Менә үзгәрде. Хәйләкәр бүре кебек иткән, телен чүкеткән!

— Әмма җыры гына ялган чыга, ноталары дөрес түгел, әйеме?

— Ул әле аны үзе сизми-сизенми, шулай да остарып бара. Менә бит кеше дан-дәрәҗә өчен тәнен, үзен, җанын сатарга әзер!

## БЕЗНЕҢ ДЕМОКРАТИЯ

*Хикәят*

Дөрес сүзне мин дә әйтмәсәм, аны кем сөйләр? Дан-дәрәҗә артыннан куган таныш-белешләрем, хәвеф утында көеп, җаннарын ялганчылык чокырына илтеп салдылар. Күп кешенең дөресне әйтергә түгел, сүз эндәшергә дә көченнән килми. Әйе, ә мин әйтим:

— Урамнарны себермиләр!

Карагыз әле, ишеттеләр. Барысы миңа борылып карадылар:

— Юк-юк, ул чүпне мин ташламадым!

Сүземне тагын ишеттеләр. Менә бит, мин дөресен әйтмәсәм, сүз сөйләшер, сүз әйтер кеше дә бетеп бара илдә.

— Җәмәгать, демократия заманы!

Әллә тагын ишеттеләр инде? Борылып карадылар.

Нигә болай сәерсенделәр икән?

## УҢАЙСЫЗЛЫКТА

*Хикәят*

Бервакыт миңа шулай тоела башлады: тормыш минем белән юри уйныйдыр сыман.

Элекләрне кешеләргә соклана идем. Нинди булганнар, нинди акыллылар кебек иде алар. Һәм миңа:

— Кеше танымыйсың!— диделәр.

Ә кешеләр арасында акылсызлары, мәгънәсезләре, ахмаклары шактый күп икән. Түрәләр арасында да андыйларның булуы сәер түгел, әмма галим-голамә арасында шундыйлар очрыйлар да йөрәк өшенеп куя. Нигә андыйлар үз кемлекләрен белмиләр икән? Миңа:

— Кешеләрне аерма!— диделәр.

Баксам, без барыбыз да бер үк төрле кешеләр икәнбез. Тик дөнья гына безне төрле хәлләргә куя түгелме?

Шушы соравымнан үземә үк уңайсыз булып китте.

## КӨЛКЕГӘ КАЛУ

*Хикәят*

Көлке хәлгә калган очракта нишләү хәерлерәк диярәк сүз чыгып, арадан беребез:

— Күтәрә алырга кирәк!— дип әйтеп куйды.

Икенчебез:

— Көлке хәлгә калудан үзеңне сакларга тиешле. Теләсә кем көлке хәлдә калмый. Җитди, горур кешене кем шаяртсын?— дип әйтеп куйды.

Өченчебез, елмаеп:

— Көлкесез, уен-шаяртусыз кеше яшиме инде?— дип, сораулы хәбәр белән әйтеп куйды.

Һәммәсе миңа карап алдылар, имеш, син нәрсә уйлыйсың?

— Көлкегә калган очракта хәлне төзәтергә ашыгудан да хәерсез гамәл юк! Иң яхшысы — шул көлкегә кушылып, аны үз өстеңнән җиңел генә уздырып җибәрүең!— дип, фикеремне әйттем.

Әмма бу вакытта сөйләшү темасы икенче үзәнгә кереп китәргә өлгерде, сүзләремә колак салучы да булмады.

## КӨЛКЕ ҺӘМ МЫСКЫЛ

*Хикәят*

— Көлке бар, мыскыл бар... Боларның кайсысы яхшы һәм кайсысы начар?— дип сорадылар. Мин исә:

— Көлке эткәләп-төрткәләп аптырата, мыскыл изеп үк китә!— дип җавап бирдем. Ә миңа:

— Юк,— диделәр.— Көлке — көлдерә, мыскыл — тәрбияли. Шуны да белмәскә инде!

Аларның бу сүзләреннән мәгънә алдым һәм:

— Көлкедән дә, мыскылдан да дәлилегез бардыр. Алдыбызга куйсагыз иде!— дип үтендем.

Алар исә:

— Акылыгыз кот икән,— диделәр.— Аңлатып бирү генә җитмәгән, чәйнәп тә каптыртырга әйтәсез!

— Әйе,— дидем,— чөнки изелеп киткән идем әле! Балаларча!

## КОЛАК ИШЕТМИ — КҮЗ КҮРМИ

*Хикәят*

Кайбер кешеләр үзләренең томана булуларын белмичә дә үлеп китәләр, имеш. Бәхетлеләр.

Әле бер олы дәрәҗә чиновникның махсус әзерләнелгән нотыгын тыңладым. Илдә зур үзгәрешләр буласы, диде. Яшәешнең гадел һәм дөрес буласына ышаныч тумакчы гына иде, хыялларны хәтер җимереп ташлады. Нинди акыллы баш үзе утырган урындыкның астына чокыр казысын икән?

Дустым шалтыратты:

— Тыңладыңмы?— дип сорады.

— Нәрсәне?

— Агайның нотыгын? Кара әле, чоңгылга ничек очып төшеп бара!

— Әйе,— дигән булдым һәм шунда гына теге нотыкчы агайның үз урындыгы астына чокыр гына түгел, кое казырга өлгергән булуын аңлап алдым.

Хәер, бу кое аның үзенә генә түгел, ил халкына да иде түгелме соң? Димәк, миңа да!

## АКЫЛГА УТЫРУ

*Хикәят*

Гомернең шушы кадәр күңелсез буласын белсәң, яшәп торуның мәгънәсе бармы диярәк аптыраучыларга исем китә. Әлбәттә яшәргә кирәк. Безнең үзебездән тормыймыни ул гомернең нинди булуы. Иренеп утырсаң, театрларга, киноларга, концертларга йөрмәсәң, кемдер килеп, синең көеңне көйләр, күңелеңне күтәрер дисеңме? Һич юк! Хәтта патшаларның да кирәге бер тиен икәнлеген кешелек тарихы гамәлләре белән раслады бит инде!

Мин шушы фәлсәфәдә рәхәтләнеп уйланып утыра идем, телефон шалтырады. Ашыкмыйча гына барып алдым.

Юк икән, мине сорамыйлар.

Куйдым. Шунда гына һичкемгә кирәгем юклыгын уйладым. Салымнарымны түләргә, бурычларымны кайтарып бирергә өлгергән кеше булуым да исемә төшкәч, моннан соң башкачарак яшәргә кирәклеге башыма килде.

## НӘРСӘ ХАКЫНДА ИДЕ ӘЛЕ?

*Хикәят*

Кешеләр дан-дәрәҗәгә ирешү өчен нинди генә хәйләләр кормыйлар, хәтта үзләренең конкурентларын ялган карьерачылыкта да гаеплиләр. Көчле кешеләр көчле илдә генә үсә, көчсез илдә көчсез кешеләргә генә түр бирелә. Моны гына кем дә белә.

Шушы хакта сөйләшеп утыра идек, безнең янга бер шагыйрь әфәнде килеп, кыска гына бер шигырь сөйләп китте. Әңгәмәбезгә бер дә катнашы юк сыман иде, янымдагы дус:

— Ничек дөрес әйтте!— дип, соклануын белдерде.

Мин дә:

— Әйе, тирән фикерле!— дидем.

Өченче әңгәмәдәшебез генә:

Шигыре ничек иде әле?— дип сорады.

Без, искә төшерә алмагач:

— Онытылды да инде!— дидек һәм... хәйранлыкта көлеп җибәрдек.

## КҮҢЕЛ УЧАКЛАРЫ

*Хикәят*

Күңелем тулы якты ут иде. Сөенеч, шатлык. Миннән учакларына ут сорап тордылар. Бирдем. Җылынсыннар. Көннәре якты булсын, дидем. Әмма әйтергә онытканмын:

— И кешеләр, күңел учакларыгызны сүндермәгез, юкса бәхетегездән мәхрүм калырсыз. Җаныгызны җылытырга яныгызда һәрвакытта да кирәкле кеше булсын!

Шунда миңа берсе әйтте:

— Син үзеңне шулкадәр бирдәнбер, бик кирәкле кеше дип белдеңме әллә? Синнән ут алгач та... Учакларыбызда коры утын булмаса, учак тергезә алыр идекме?— диде.

Ул хаклы иде. Күңелем сынмыйча кала алмады. Сүрелдем. Тынычландым. Күңелдәге моңа кадәр җылы биреп торган учагым да акрынлап сүнде. Мин хәзер сөенеч һәм шатлык белән балкыймын.

## МӘЗӘК СӘБӘБЕ

*Хикәят*

Мәзәк хакында, аның кирәклеге, ничек тууы турында әңгәмәдә идек. Беребез:

— Мәзәк ул — көлкеле вакыйга. Шунысы әһәмиятле, ул вакыйга башкача була да алмый,— диде.

Икенчебез:

— Юк, мәзәк ул — көлкеле кеше, гомумән дә көлке иясе,— диде.— Мәзәк бары тик шундый шәхес-зат аркасында гына туа. Мисалым да бар: Хуҗа Насретдин!

— Әйе, килешергә була,— диде өченчебез.— Әмма мәзәк ул көлкеле фикер дә! Вакыйга да, шәхес-зат көлдерми, әгәр көлкеле фикергә таянылмаса!

Миңа да сүз әйтергә чират җитте. Аптырагач, әйткәнем булсын дип, мин дә өстәп куйдым:

— Мәзәк ул — көлкене аңлаучы кеше,— дидем.— Чынлап менә!

Һәммәсе дә тәгәрәшеп көлделәр һәм, ни гаҗәп:

— Әйе шул!— дип ризалаштылар.

## ДӨНЬЯНЫҢ ХИКМӘТЕН ЭЗЛӘҮ

*Хикәят*

Бу дөньяның хикмәте нәрсәдән гыйбарәт? Дан-дәрәҗәдәнме, байлыктанмы, балалар бәхетен күрүдәнме?

Борынгылар утырышында булсагыз, алар сезгә:

— Болардан түгел, мәгънә асылына төшенүдән!— дип җавап бирерләр.

Әгәр дә: “Юк, башкача әйтерләр!”— дисәгез, үзегез борынгыларның китапларын укып карагыз. Сүзләремнең хакыйкать икәнлегенә төшенерсез!

Дан-дәрәҗәләргә омтылу начар гамәл түгел, әмма аларның зыяны да бар: алар кешене үтерә, харап итәләр. Дан-дәрәҗә иясе моны белми генә.

— Юк, дан-дәрәҗә белән кеше зур мөмкинлекләргә хуҗа була, исеме тарихларга керә!— диделәр миңа.

Тарих китапларын укыдым. Андыйларга халыкның бәддогасын күрдем.

Бу дөньяның хикмәте мөгаен байлыкта һәм балалар бәхетенә сөенүдер дип уйладым. Болары да хата фикер түгел идеме икән?

— Ә-ә,— дидем аннары,— белдем, җәмәгать, үзеңне табуда һәм үзеңне югалтмауда!

Әмма да көләсе килмәде.

## МӘҖЛЕСЛӘР ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Бөекләр мәҗлесендә булдым. Һаман да үзләрен мактауны, үзләрен зурлауны таләп иттеләр. Алар арасында мин кем идем? Әйе, үземне бик тә мескен итеп тойдым. Дөнья йөзендә каһәрләнгән кешеләр генә мин-кемлек белән саташкан бөекләр мәҗлесенә бара икән дип уйладым. Моның шулай булуын күңеле китек “фәкыйрь”ләр мәҗлесенә килеп эләккәч кенә аңладым. Монда беркем дә мин-кемлек чире белән авырмый иде. Әйттем: “Син болар арасында җаныңа саулык табарсың!”— дидем.

Менә ничәнче тапкыр мин алар мәҗлесенә киләм. Дан-дәрәҗә, мактау һәм зурлауларны сөймиләр. Монда хикмәт һәм хакыйкатьтән дә кыйммәтлерәк һәм өстенрәк һичнәрсә юк икәнлеген төшендем.

Мин чын мәгънәсендә бәхетле идем.

## АКСАК ЧАГЫШТЫРУ
*Хикәят*

Кыяр каракларын беләсезме? Алар, асылда, бала-чагалар булалар. Болай “этлек” итүләре кызык та, файдалы да, имеш. Ризыклы булалар бит!

Бу хакта кыяр бакчасы тоткан бабайдан белештем. “Андый балалар сезнең башыгызга төшкән бәладер”,— димәкче идем, ул, ярты сүземнән аңлап:

— Юк, алай әйтмәгез!— диде.— Киресенчә, алар кыярны күбрәк өзгән саен файда гына итәләр. Кыяр ул шундый үсемлек, әгәр аны җыеп тормасаң, уңышы кими, мәгәр гел өзеп торсаң, һаман үсә, уңышы күбрәк була!

— Кызык икән!— дидем һәм, рәхмәт әйтеп, үз юлым белән киттем. Бара торам, уйлый торам: “Галимнәр мисалында икән! Башкаларга күбрәк өләшкән саен галимнең дә гыйлеме арта гына бара!”

## ИРЛӘР СЕРЕ
*Хикәят*

Күңелем тулы күз яше. Еласам — күзләрем сукыраерлар сыман. Түгелеп китәргә торган чүлмәк кебек тулышып йөрдем. Хәлемә керерлек кеше табалмадым. Күз яшем тәнемә сеңде. Үземне җебек итеп тойдым. Һаман да бу бәладән арыну җаен тапмадым. Миңа хәзер табип та ярдәм итә алмаячак иде. Шунда Аллаһы тәгалә кайнар көннәр бүләк итте. Эш арты эш кулымнан узды, таулар күчерергә туры килде. Тәнем генә түгел, күңелем дә тәмам коргаксып бетүен тоймый да калганмын.

— Нишләп туктап калдың?— диделәр миңа.

Шунда:

— Ә беләсезме, дусларым,— дидем мин аларга.— Дөнья йөзендә ир кешенең бөтен бәхете — эш һәм эш икән бит!

## Ә КЕМ ГАФУ ИТКӘН ӘЛЕ?
*Хикәят*

Бик яшьли мин-кемнәр белән аралаша башлавым сәбәпледер, әлегә яшел һәм беркатлы булуымнан файдаланып, алар җанымны өзгәләргә, кискәләргә, изгәләргә күп тапкырлар өлгерделәр. Миңа карата кылган усаллыкларын гадәтләре иттеләр. Түздем. Үч алырга, чыгырымнан чыгарылырга тиеш идем. Әмма

сабыр санда калдым. Үзегез дә беләсез, агач яшел чагында җимешле була, саргайган агачның кайчан җимешләрен өзеп, тәмләп ашаганыгыз бар?

Бәлки хаталанганмындыр да?..

— Син нигә аларны гафу итәсең, измисең?— диделәр.

Елмаеп җавап бирдем:

— Аларга бу кыла торган яхшылыкларым һәммәсе дә хаталарын аңлаулары һәм үкенүләре өметендә,— дидем.— Үкенүдән дә авыррак газап бармы? Юк! Шушымы аларны гафу итү һәм измәү?

## КОЛЛЫКНЫҢ МӘГЪНӘСЕ

*Хикәят*

Халыкка кайвакыт зарларымны сөйләп алгалыйм. Әллә ишетмиләр, әллә ышанмыйлар — бер сүз дә әйтмиләр.

— Юатуларын өмет итәсеңме әллә?— диде бер танышым.

Нигә аңарга: “Әйе!”— дидем икән?

Өй почмагында үксеп җил елый. Тәрәзәмне ачсам, өлгеләрне ватып керәсен беләм.

Ишекне ачкан идем, каерып ыргыта язды. Җилне юатумы кулымнан, телемнән килә торган эш? Аның табигатендә түгелме соң ул елау?

Халыкка кайвакыт көлкеләремне сөйләп алгалыйм. Ишетәләр, ышаналар, әмма бер сүз дә әйтмиләр. Ә тәрәзәм каршында бүген кояш көлә. Күңелем шат, чөнки тагын бер хакыйкатьне аңладым: хезмәтчеләреннән кайчан хуҗаларның канәгать булганнары бар?

## МӨМКИН ИДЕ БИТ

*Хикәят*

Аның хакында нәрсә уйлаганнарыңны, күңел серләреңне нигә әле белдерергә кирәк? Менә мин сине яки аны кемнәр санында йөртәм дияр өченме? Шуннан соң ул кешенең сиңа карата мөнәсәбәте үзгәрерме соң?

Әйе, имеш, куркып калачак, уйланачак инде. Рәнҗеткән булса, юкка мыскыллаганмын моны дип борчылырмы? Һич юк, әлбәттә!

Ә өметләнәбез шул, и юләрләр!

Танышым очрап, мине үтереп-үтереп мактый башлады. Шикләнә калдым һәм, аны бүлдерергә теләмәсәм дә:

— Гафу итегез, сезнең алда нинди гаебем бар иде?— дип сорадым.

Ул аптырап калды. Бераздан елмайды. Аннары көлеп җибәрде.

Соравымны кабатламадым. Әмма аның купшы мактавыннан котылдым. Ә шулай да, дөресен әйтим, миңа аның ул сүзләрен ишетү рәхәт иде бит, әйткәннәре чын күңеленнән булырга мөмкин иде.

## ӘҮЛИЯЛЕК ИТКӘН БУЛЫП

*Хикәят*

Дусларның әңгәмәсенә колак салуда идем. Алар хөкемдарлык һәм хөкемдарыбыз хакында сөйләшүгә күчтеләр. Чөнки ил халкының бәхете һәм бәхетсезлеге хөкемдар белән бәйле, имеш. Шунлыктан халык аны бик еш искә ала.

— Ни өчен хөкүмәт тирәсенә җыен карьерист, әтрәк әләм, акылсыз кешеләр җыела, зур мәртәбәләр ала, беләсезме?— диде беребез.

— Әүвәле үз фикерегезне әйтегез!— дидек, чөнки бу мәсьәләгә, ул сөйләп өлгергәнче, җавапларыбыз әзер булачак иде.

— Шуңарга,— диде ул,— хөкемдарга үз тәхетен саклау, үз кемлегенә соклану өчен тирәсендә шундый кешеләр кирәк!

Мин көлеп куйдым. Дусларым сүзне миңа бирделәр.

— Әгәр хөкемдар үз тирәсенә сез әйткән кешеләрне җыйса, алар аны тиздән харап итәрләр!— дидем.

Сүзнең дәвамы өзелде. Әмма ул елның ахырында хөкемдарыбыз тәхетеннән куылды.

## МӨЭМИН БУЛЫЙМ ДИСӘҢ

*Хикәят*

— Байлык адәм баласына кирәкме?— дип сорадылар миннән.

— Әлбәттә кирәк!— дидем җавабымда.— Ул никадәр күбрәк булса һәм файда китерсә, керем бирсә, тагын да яхшырак!

— Без бит сине суфи, дин иясе дип белгән идек. Юк сүз сөйләмисеңме? Байлык кешене боза ул,— диделәр.

— Әйе, дөрес әйтәсез,— дидем.— Мин сезнең белән килешәм, байлык кешене бозу көченә ия. Әмма мине дин иясе, суфи түгел дигәнегезне аңламадым. Нәрсә, хаҗга бару өчен байлыгың, еллык кеременң җитәрлек булу шарт түгелме соң? Ул шарт үтәлми торып, бу фарызны башкару ярыймы? Мөэминнәр юмарт булабыз дисәләр, байлык хуҗасы түгелләр икән, моны эшли алырлармы?

## ХЕЗМӘТ ИТҮ НИ БИРӘ

*Хикәят*

Мәртәбәгә ирешү хакында дуслар белән сүз килеп чыкты. Алар:

— Ни өчен берәүләр үсә, икенчеләр бер урында таптанган кебек хәлдә булалар?— диделәр.

— Сәбәп бик гади,— дидем.— Кемнәр үзләренең хуҗаларына хезмәт итәләр һәм аларга тугрылыклы булалар, әлбәттә ышанычларын яулыйлар. Андый кешеләр үз дигәннәренә ирешми калалармы соң? Тугыры хезмәтчеләрен хуҗалары да бүләкләр белән куандырмый калдырмыйлар.

— Әмма ялагайлар белән дөнья тулы бит,— диделәр алар.

— Әйе,— дидем мин дә.— Әмма ялагайлыкта тугрылык түгел, ялган һәм мәкер бар. Ихлас була белергә кирәк. Ә анда даимилек табарсыз.

## МӘРТӘБӘ БИТ УЛ
*Хикәят*

Кешеләрнең мәртәбәсе үзләренең нинди булуларыннан тора, имеш.

— Кешенең акылы турында сүз барамы?— диделәр миңа.

— Мәртәбәнең кайчан акылга бәйле булуын күрдегез әле?— дидем мин дә.— Хәтта белем дә мәртәбәнең нигезе була алмый.

— Ә нәрсә соң ул вакытта?

— Әгәр дә мин-кемлек мәртәбә бирә дисәгез, шулай ук ялгышасыз. Мәртәбәнең бөтен асылы кушканны үтәүдән,— дидем.

— Әмма акылсыз һәм белемсез кеше кушкан эшне җиренә җиткереп башкара аламы соң?— диделәр.

— Бәлки аңа бу кушылган эшне башкаларга тапшыруы һәм алардан таләп итүе генә дә җитә торгандыр? Шуңа күрә дә мәртәбә бит инде ул!

## БЕР КАШЫК ДАРУ
*Хикәят*

Ялагайланмагыз, бу бик тә ямьсез күренеш. Күпләр шуның аркасында көлкегә калдылар һәм бәхетләрен дә югалттылар. Ялагайлык йөзгә-йөз калганда гына килешә, халык алдында чиркандыра.

Шулай бервакыт миңа:

— Сезне бик акыллы, башлы, аксакалларча гадел хөкемле кеше дип белә идек, әмма бер мәҗлестә түрәбезне котлап сүз әйткәнегездә бер мичкә балыгызга бер кашык дегет салдыгыз. Бер дә килешле тоелмады,— диделәр.

— Әйе, нәкъ шулай булды шул,— дидем,— чөнки тәбрик сүзләрем, хакыйкатьтән аерылып, ялганга таба авышты. Ялагайлыктан котым очып, хәлемне төзәтү ягын карадым. Сезгә ул бер кашык дегет кебек тоелса да, мәгәр үземә бер кашык дару иде.

## ЯРЫЙ ТОРГАН ЭШ ИДЕМЕ?
*Хикәят*

Җитмеш яшенә якынаеп баручы бер карт әфәнде, аларның каршысына барып керсәм, үзләренең түрә булуларын да онытып, минем белән сүзен шаяртырга тырышып сөйләшә башлагач, бу хәлләр кабатлана торгач, аларга инде үземә дә кырык яшьләр икәнлеген искәртеп, бервакыт шулай:

— Мине үзегезгә корма күрүегезгә бик зур рәхмәтлемен! Насыйп булса, сезнең яшькә барып җитәрмен кебек,— дидем.

Алар аптырап калдылар. Ник болай сөйләвемне аңлый алмыйча гаҗизләнделәр. Башкалар алдында үзләрен ахмак итеп тагын бер кат күрсәтәселәре килмәде, ахрысы, кабатлап, ни әйтергә теләгәнемне аңлатып бирүемне дә сорарга кыймадылар.

Хәлләренә кереп:

— Кешеләр үз кормалары белән сүзне шаяртып сөйләшәләр. Яшьләргә карата таләпчән булалар. Яшьрәкләргә шаяртып сүз әйтү алардан көлү кебек аңлашылмасын өчен рәхмәтемне сезгә юлладым,— дидем.

## ЯШЬЛӘР ТӘРТИБЕ

*Хикәят*

Яшьләргә карата таләпчән булу гына аз, аларны хөрмәт тә итә белергә кирәк, диләр. Әмма боларның икесен бергә, берьюлы башкару тиешле. Аерым-аерым эшләү күңелсез нәтиҗәләргә, сәер уйларга китерә. Моны кем дә белә.

Бер танышым үз улына карата бер генә дә хөрмәт хисе белән яшәмәде. Соңыннан аның хакында: “Башына улы җиткән!”— дип сөйләделәр. Исемә төште: аңарга ничә әйткән идем шушы хакта, колагына да элмәгән икән.

Бервакыт автобуста егетләрнең колак артын иснәп кайткан бер агайны күрдем. “И-и,— дидем үз алдыма,— “зәңгәр”!”

Шулай уйлап бетермәдем, яшь егетләр аны изеп тә ташладылар. Агайны акларга кемнең дә уенда юк иде. Артыкка киткән мәхәббәт тә килешми шул, артыкка киткән хөрмәт сыман.

## МИН КУРКАКМЫ ӘЛЛӘ?

*Хикәят*

Үземнең күп мәсьәләләрдә хәбәрдарлыгым камил булмавын истә тотып, әңгәмәләрдә катнашмый калуны мәслихәт күрүем кемнәргәдер ошамый да инде ул. Ачуланмасыннар, гафу үтенәм. Әмма миңа күп вакыт, бу хакта сезнең дә фикерегезне беләсебез килә дип түгел:

— Әйт сүзеңне!— дигән рәвештә, кырын күз белән карап куючы усаллар очрый.

Нәрсә әйтим инде? Эндәшми калам, билгеле. Аларның ачулары килә. Сүзләренең, колагыма элеп алганымда, никадәр ялган икәнлегенә җавап итеп елмаюларымны:

— Фикерегез асылы белән хата!— дип әйтеп, башкалар алдында бөек шәхесләрен мыскыллыйммыни инде? Юк, кирәкмәс! Болай да ачу ташлары эсселәп китте. Мин куркакмы әллә, кешеләрнең кемлеген йөзләренә бәргәләп йөрергә!

## УТЫРЫШ КОЯШЫ

*Хикәят*

Бүлегебезнең мөдире, куелган мәсьәләне искәртеп:

— Барыгызга да бу хакта фикерләрегезне туплап куярга тәкъдим ителгән иде. Әйдәгез, башлыйк. Беренче сүзне сезгә бирәм,— дип миңа төбәлде,— кояш чыгышыннан башлап китәбез дә рәттән барабыз.

Шунда кирелегем килде:

— Мин бит кояш баешы тарафында утырам,— дидем.

— Хөкемдарлар кайдан тели, кояш шуннан чыга!— диделәр ялагайланырга җай табучылар.

— Кояш чыгышы дигәндә, утырышыбызның кояшын чыгаручы булырсыз дип күз алдында тоткан идек,— диде мөдиребез.— Табигатьтәге кояш белән хәтта патшалар да идарә итә алмыйлар.

Утырышыбыз шушы рәвештә җылы башланып китеп, эшлекле һәм нәтиҗәле үтте.

## ХОЛЫК ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Бәндәнең холкы сүзләрендә һәм хәрәкәтләре-гамәлләрендә чагыла, ихтыяры белән идарә ителгәнен белдереп калдырган борынгы бөек хаким Аристотель. Шушы үлемсезгә үз арбамны тагарга теләп мин дә әйтәм: бәхетнең дә, бәхетсезлекнең дә сәбәпчесе шушы холык дигәннәре инде! Кыйты холык кемне бәхетле иткән дә, яхшы холык кайсыбызны сөендергән?

— Холыкны үзгәртеп буламы?— дип сорадылар миннән укучыларым.

— Холыкны үзгәртү — канны үзгәртү сыман ук инде ул,— диярәк аларга җавап бирдем.

— Димәк, бөтен хикмәт — канда,— диделәр алар кабат,— кайнар канлы кешенең холкы да шундый.

— Һәм шулай!— дип җавап бирдем аларга.— Кан утыргач, холык та утырып җитә!

## МӘХӘББӘТЛЕ МӘСЬӘЛӘ

*Хикәят*

— Әгәр дә кыз егеткә мәхәббәтен аңлатса, егет аны яратмаса, нишләргә тиеш? Ул егетнең ничек һәм нәрсә әйтүе, мәхәббәтен инкарь итүеме, кабул итүеме дөрес?— дип сорады миннән бер укучым.

Аңарга болай дип җавап бирдем:

— Әлбәттә ашка таш белән кайтару хата булыр!

— Яратмаган кешеңә, мин сине яратам дип әйтергәме инде?— диде укучым.

— Мин андый сүз әйттемме?— дип сорарга мәҗбүр булдым.

— Ашка таш белән җавап бирү хакын әле генә белдердегез бит,— диде ул, гаҗәпләнеп.

— Әлбәттә,— дидем мин,— шулай әйттем, әмма яратмаган кешеңә мин сине яратам дип әйтергә киңәш итмәдем!

## ШУШЫМЫ ДӨРЕСЛЕК

*Хикәят*

Ил эчендә халык хөкүмәт белән уйнарга ярата, диләр.

Хөкемдарлар яки үзләре белән уйнарга мөмкинлек бирәләр, яисә — юк. “Тилене тиле дигән саен, тигәнәк буе сикергән!”— дигәннәре шушы, имеш.

— Ни өчен соң ул вакытта хөкемдарлар байлыкта һәм муллыкта яшиләр, ә халыкка мохтаҗлык һәм авырлыкларны күтәрергә кала?— дип сорадылар миннән.

— Берәүләр тук булсын өчен икенчеләр үз авызларыннан өзеп бирергә тиешләр,— дидем аларга, сүзне шаяртуга борып.— Бирми карасыннар, кычкыртып, талап алырлар.

— Болай дөрес буламы инде?— диделәр, тәмам аптырашып.

— Ә кем әле шушылай дөрес була дип әйткән?

Сүзләрем һәммәсен аптырашта калдырды.

## ТҮЗЕМЛЕ БӘХЕТ

*Хикәят*

Муса пәйгамбәрнең дошманнары арасында иң куәтлесе Фиргавен булганлыгын белмәгән кешеләр аз, диләр.

Бу хакта сүз чыгып, дусларым:

— Фиргавенгә дуслык игълан итсә, Муса пәйгамбәрнең кавеменә яшәве рәхәт булмас идеме? Никадәр газап чиккәннәр!— диделәр.

Сүзләре җитди иде. Мин:

— Асылларында үзара дошманлык бар икән, андый кешеләр ничек дус була алалар?— дидем.— Андыйлар солых хәлендә генә яшәргә мөмкиннәр, һич әшнәлек итмиләр.

— Солых белән дуслык бер түгелмени?— диделәр тагын да.

— Үзегез дә беләсез, солых килешүе ике дошман як арасында була торган күренеш,— дидем, бәхәсләшергә теләмичә.— Әмма солыхта дуслык рәхәтлеге юк, сабырлык, түзем, игътибарсызлык газаплары гына бар.

## АЛЛАҺЫНЫҢ УРЫННАРЫ

*Хикәят*

Бервакыт миннән хәдисләр турында бәхәс кылырга яратучы бер әфәнде сорады:

— Аллаһы тәгаләне сабырлар белән, диләр. Моның сере нәрсәдә?

— Җавабын үзегез дә беләсез, ахрысы. Тыңлыйм,— дидем мин аңарга, күңел кояшын йөзенә чыгарырга мәҗбүр итеп.

— Кемнәр авыр тормышта, фәкыйрьлектә, мескенлектә яшиләр, алар — сабыр, Аллаһы алар белән!— диде ул.

— Алай...— дидем мин, бераз аптырап.— Белмәгән идем. Юкса бу сүзне башка мәсьәләдә әйтелгән дип йөрегәнмен.

— Сезнеңчә нәрсәгә бәйле?— диде ул әфәнде.

— Хата миндә, ахрысы. Кемнәр кайнарлана, алар әдәпне оныта, кемнәр сабырлык белән эш йөртә, алар әдәп киртәләрен сикерми. Әдәпсез җирдә Аллаһ та юк дип белә идем,— дидем.

## КЕШЕ ТҮГЕЛ

*Хикәят*

Кешедә аң һәм акыл арасында бәйләнеш барлыгын тәҗрибә ярдәмендә төшенергә була. Аң тереклеккә бәйле, ягъни җан һәм тән берлеген хасил итүче көч, акыл исә аңлы эшчәнлекнең нәтиҗәсеннән гыйбарәт. Аңында булган кеше акылсыз гамәл кылмый, акылында калучы аңсызлык белән җәфаланмый. Акыллары саташучылар аңсызлык кылмый калмыйлар, шуңа да куркынычлар.

— Хайваннарда акыл бармы?— дип бәхәс кылды дусларым.

Мин исә аларга катнашып киттем һәм сорадым:

— Дивана, мәҗнүннәрдә бармы соң? Кайсыгыз юләрне акыллы һәм аңлы дип әйтә ала?

— Һе,— диярәк көлешеп алдылар алар,— бу юлы да сез хаклы шул. ДиванаНы кеше дип әйтеп буламы?

## ДӨРЕС ЯШӘГӘНДӘ

*Хикәят*

Күңелең сагыш белән тулы булса, артыгы белән моңланса, болардан котылуы мөмкинме? Әлбәттә адәм кулыннан килмәгән эш юк. Шулай да һәр көнеңне бәйрәм белән үткәрүгә караганда, ара-тирә уйларыңа бирелеп алу комачау итми. Һәр нәрсәнең үз мәртәбәсе гаме белән булганда, бәрәкәте дә бар.

Миннән:

— Кешеләр дөнья йөзендә бәйрәм белән яшәгәннәрендә дөресме, әллә сагышка бирелгәннәрендәме?— дип сорадылар.

Моңарга җавап бирә алмый идем. Шулай да:

— Дөнья йөзе — тырыш хезмәт урыны, ял иткәнеңдә бәйрәмнән дә яхшырагы юк,— дигән җавап бирдем.

Әмма тыңлап торучылар сүземне боздылар һәм:

— Димәк, бәйрәм белән яшәгәннәрендә дөрес, әйеме?— диделәр.

## ЗИННӘТЛЕ ХАНЫМНАР

*Хикәят*

Мөселман хатыннарының яулык бөркәнеп йөрүләре һич тә сер түгел.

Моның сәбәбе Коръәннән, имеш. Анда чыннан да ике урында, хатын-кызларга атап: “Зиннәтләрегезне каплап йөрегез!”— диелгән.

— Бу зиннәтләрне йөз һәм күркәм күкрәк буларак аңлау көнче ирләрдән киләме?— дип сорадылар, мине аптыратып.

— Юк,— дидем,— Бу — хатыннарның үзләреннән килә! Кайбер ирләр үз хатыннарына “зиннәтлем” дип әйтергә телләрен кызгану, сүздә саранлыклары сәбәпле, күркәм хатыннары үзләрен “зиннәтле” тип атауны теләгәннәр. Аннары, уйлап карагыз, безнең кайсыбыз кайчан хатын-кызларыбызга китереп яулык бөркәгәне бар? Монысын да хатыннар үзләре эшли. Безгә килешергә генә кала. Зиннәтләрен саклыйлар.

*04.05.06.*

## МӘХӘББӘТ СЕРЕ

*Хикәят*

Хатын-кызларның колак белән яратулары яхшы мәгълүм. Хәер, ирләр дә корсак белән яраталар, имеш.

Ә йөрәк?

— Йөрәк — гайрәт чыганагы,— диделәр миңа.

Бу сүзләрен нигезгә алып фикер йөрттем: “Димәк, адәм баласының батырлыгы аның үз йөрәгенә бәйле!”

— Беләк — көч инде ул, әйеме?— дидем.

Риза булдылар.

Шулай итеп һәр әгъзага бер вазифа йөкләп чыктык һәм сүз башына әйләнеп кайттык. Шунда мин:

— Әйе,— дидем,— хатын-кызның колагы — алкалы, ирләрнең күзен җәлеп итәр өчен, әмма шул алкалы колак — төпсез капчык шикелле, ни ишетсә, шуны тутырып бара. Ирләрнең дә корсагында бирән галәмәте бар. Әйтәм аны чибәр хатыннарның ирләрендә корсак тау кадәрле була!

## ГАРЬЛЕК

*Хикәят*

Миннән затлылык турында сорадылар. Табигатьтәнме, әллә инде бәндәнең үзеннәнме, диделәр.

Җавап бирдем:

— Бәндәнең үзеннән!

— Дәлилегез бармы?— диделәр.

— Әлбәттә бар,— дидем,— әмма гади җирлеккә затлы таш утыртып куелса, бу купшылык буларак аталыр иде, ясалмалыгы йөзгә бәреп торыр иде. Шуның кебек, бәндәнең үзе алтын булмый торып, тажы энҗе-мәрҗәннән булуда мәгънә юк!

— Димәк, бу — бәндәнең табигате белән бәйле, шулай түгелме?— дип миңа карата ризасызлык белдерделәр, барыбер сүзләремне колакларына элмичә.

— Алай булгач сез нигә табигатьтәнме, әллә җәмгыятьтәнме дип сорамадыгыз?— дидем мин дә аларга, аңламамышка сабышып.

## ЯНАР УЧАК ЯННАРЫНДА

*Хикәят*

Яшьләр арасында идем. Сүз мәхәббәт хакында булды. Мин аларның берсеннән:

— Мәхәббәт дигәнегез ул ни-нәрсә?— диярәк сорадым һәм аның:

— Ут!— дигән җавабын ишеттем.

Аңладым.

Икенчесеннән сорадым. Анысы исә:

— Төтен, чөнки ул кешене миңгерәүләтә!— диде.

Аптырадым.

Өченчесенә мөрәҗәгать иттем. Ул миңа:

— У-у, мәхәббәтме?— диде.— Шундый нәрсә буладыр мәхәббәт, ул көч, дәрт, шатлык, сөенеч бирә!

— Алай икән!— дидем.

Яшьләр арасыннан чыктым. Кич иде. Һава суынды. Шунда ут күреп, учак янына килдем. Җылындым. Күңелем сөенде. Яшьләрнең җаваплары исемә төшеп: “Мәхәббәт ул янар учак икән!”— дидем.

## БЕРДӘН МЕҢНЕ ТАБУ

*Хикәят*

Илнең гаделсез булуына сәбәп хакында сүз чыккач, арадан беребез:

— Халкы нинди — хөкемдары да шундый!— дигән фикерне әйтте.— Халкы яман икән, ил башлыгына да шундый булырга кала.

Башкалар да аның белән килештеләр. Аларның фикерләрен дәвам иттереп мин дә әйтеп куйдым:

— Әйе, нәкъ шулай! Моны тарих гыйлеме дә дәлил итә. Кайсы падишаһ хөлыкта һәм гамәлдә нинди булса, без аның сыйфатларын, кемлеген тикшереп, шул вакытта ил халкының үзенең дә үзенчәлекләрен беләбез. Бу шул ук берне төшенү аша меңне аңлау юлы белән гыйлемлек итү, ягъни аңлы булу дигән сүз!

## ИЛНЕҢ БУТАЛУ СӘБӘБЕ

*Хикәят*

— Ни өчен илнең халкы соңгы вакытларда ямманланды? Кеше ни кадәр юньсез булса, шул кадәр үк әллә кемлеккә иреште, әйеме?— дип сорадылар.

Бу хәлләрне үзем дә хәтерләп йөрим, әмма җавабын гына таба алмыйча гаҗиз идем.

— Чөнки хөкүмәтебездә юнь бетте,— диде арадан беребез, минем авызымнан сүз кошы очып чыгарга өлгергәнче җитешеп. Әмма сорау аңа аталмаганлыктан, әңгәмә әһеле күзләремә карап тора бирде.

Ә мин исә:

— Хәлебезне эре-вак ташлар тутырылган тартманың әйләндерелеп каплануына охшатам,— дип җавап бирдем.— Төпкә вак ташлар җыелучан. Вакыты үтеп, эреләре өскә иләнеп чыгарлар. Әйләндереп каплаучы да хөкүмәт үзе иде!

## АҢ БУЛУ СӘБӘБЕ

*Хикәят*

— Кешеләр арасында иң авыры кайсылары була?— дип сорадылар.

— Дошманнарымның дусты,— дип җавап бирдем.

— Ни өчен дошманнар үзләре түгел?— диделәр.

— Чөнки дошманнарсыз кеше булмый. Дошман безне һәрдаим уяу калырга мәҗбүр итә. Аның нинди һәм ничек булганы, буласы мәгълүм. Әмма дошманның дустында хәйлә еланы яши. Ул сине ни өчен яратмаганын белми, дусты дошман күргән өчен генә дошман итә. Аңардан саклану чарасы да бары тик дошманыңнан саклану чарасы кебек кенә була ала. Дошманның дусты уяу түгел, шуның белән ул сине дә саташтыруга ирешә,— дип аңлатып бирдем.

## ХӘТӘРДӘН КИТҮ ЮЛЫ

*Хикәят*

Тормышта икеләнеп калган вакытлар булгалап тора. Ничек гамәл кылырга белми аптырыйсың, шул сәбәп белән үзеңне картайтасың. Мондый чакта икенең берсен эшләү гадел була. Һәрхәлдә хәрәкәт итәргә кирәк.

— Эшеңнең ахыры начар буласын белә торыпмы?— диделәр миңа.

— Әйе,— дидем,— әмма онытмыйк: хәрәкәттә — бәрәкәт!

— Анысы шулай, икеләнгәндә нияттән баш тартып тору яхшырак түгелме?

— Мәсьәләне чишүне вакытка йөкләүдән җиңеле юк, әлбәттә. Тик моның белән бәндәгә ни файда? Тормыш мәйданы — гамәл урыныдыр, ике юл чатында туктап калудан да хәтәррәк хәлне хәтерлисезме?— дип сорадым.

Җавап бирүче булмады.

## КЫЕНЛЫКТАГЫ ХАЛӘТ

*Хикәят*

Кеше кыенлыкны ничек җиңә ала? Буйсынырга тиешме, әллә бирешмәскәме?

— Сабыр итүдән дә яхшысы юк!— диделәр миңа.

Килештем, әмма сорау бирдем:

— Сез бу сабырлыкны ничек итеп күз алдыгызга китерәсез?

Соравымны аңламадылар, әллә инде, сабырлык — сабырлык ул, түзәргә кирәк дияселәре килдеме? Шулай да арадан берәү:

— Ә үзегез нәрсә әйтерсез?— диде.

Җавабым әзер булганлыктан:

— Монда һичшиксез сабырлык терәк итәр,— дидем,— чөнки ул адәмгә кыенлык алдында югалып калмаска һәм уңга-сулга бәргәләнмәскә ярдәм итә!

## ИЛНЕҢ БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Берәүләрнең дәрәҗәсе икенчеләрнең көнчелеген уята. Мондый вакытта ике якка да кыенга туры килә. Аңлашылмаучылык килеп чыга. Нишләргә? Кешеләр бер-берсен “кисә” башлыйлар. Ахыры ике якның да файдасы белән бетми. Ә шулай да дәрәҗә ияләренең ахмаклыгыннан, көнчеләрнең башбаштаклыгыннан котылу юлы бармы?

Бу хакта миннән сорадылар. Җавап бирдем:

— Көнчелекләреннән куркып, башбаштакларны дәрәҗәгә мендерә күрмәгез, моннан да ахмаграк эш булмас!— дидем.— Гамәлләрен акыл белән кылмаслар, ахмаклар акылга юл бирә белмиләр. Акыл юк җирдә гаделлек тә юк!

## АКЫЛ ДӘРЕСЕ

*Хикәят*

Кешеләргә ышану аркасында күп бәлаләр чиккән бер танышыма акыл бирергә исәп иттем:

— Дөньялыкны ак һәм карага гына аерып карау, төсләрне танымау — тормышның бәхетен татуга комачаулык тудыра,— дидем.

Һәм ул миңа:

— Сез моны әле яңа аңлый башлагансыз икән,— диде.— Ә мин аның җәфасын күптәннән тартам. Үз файдалары өчен кешеләр нинди генә хәйләләргә бармыйлар, бер-берсен батыралар, яманга алып сөйлиләр, ахырда үзләре дә шул ялганнарына ышанып бетәләр. Менә шушы чуарлыкка хәйранмын! Ә, югыйсә, бөтен төсләр дә ак һәм кара катнашудан гына барлыкка килә, шуларга әйләнеп кайта.

## ХЕЗМӘТТӘШЛӘР БӘЛАСЕ

*Хикәят*

Бервакыт хезмәттәшләрем миңа олуг зыян ясадылар. Оятларына көч килмәсме дип көттем. Харап булуымнан бердәнбер дару — сабырлыгым иде. Үч итмәдем. Гомер уза торды. Гафу үтенерләр дигән өметтә калдым.

— Бу вакыйга күптән булдымы?— дип сорадылар дусларым.

— Әйе,— дидем,— инде алар олыгаеп беттеләр, чәчләре-сакаллары агарды.

— Зиһеннәре сау чакта намуслары тотмагач, инде хәзер, акыллары тарткала барганда гафу үтенерләр дисезме?

— Бөтен бәла дә шунда,— дидем мин аларга.— Менә хәзер гафу үтенсәләр, ярлыкар өчен көчем җитәрме дип куркам. Ояты ни тора!

## ХАКЫЙКАТЬ ТӘМЕ

*Хикәят*

Ялганга ышану — гөнаһ. Әмма ничек чынмы-түгелме икәнлеген аерырга?

Бу хакта дусларымнан сорадым. Арадан берсе, сүз алып:

— Табигатенә, сыйфатына карап,— диде,— ягъни ялган сүзнең дәлиле булмый!

Аннары өстәп куйды:

— Хак сүзнең дәлил өчен китерелгән мисалы куәтледер!— диде.

— Монысы белән килешәм, әмма хакыйкать сыйфатлы ялганнан хата сыйфатлы чынлыкны ничек аерырга?— дип, соравымны кабат яңарттым.

Ул исә шунда ук җавап та бирде:

— Мондый вакытта тәменә карарга кирәк булыр: ялган һәрвакыт татлы тоела, хакыйкать — тоз кебек. Шуңа күрә дә хакыйкать ачысы диләр бит! Сез дә моны белмәгәч...— диде, йөземне кызартып.

## КӘЕФКӘ ТИЮ

*Хикәят*

— Кәефне нәрсә төзәтә?— дип сорадылар миннән.— Чибәр хатынмы, моңлы яки дәртле җыр-көйме, әллә затлы эчемлекме?

— Чибәр хатын йөрәккә шифа бирә, яхшы җыр уйларны тарата, затлы эчемлек акылны кайната,— дидем мин аларга,— әмма кәефне акыллы киңәш, мәгънәле сүз, галимнәр мәҗлесе генә төзәтә ала.

— Ә галимнәр мәҗлесендә бары тик акыл тантанасы һәм мәгънәле сүз генә буламы әллә?— диделәр, аптырашып.

— Чын галимнәр мәҗлесендә әлбәттә шулар гына булыр, әмма ялган галимнәр мәҗлесендә чибәр хатын, көй һәм җыр, исерткеч эчемлек алда торыр,— дидем, мәҗлес өстәленә ишарә итми генә.

## ТАБИГАТЕҢӘ КҮРӘ

*Хикәят*

Бер әфәнде, бик тә дәрәҗә иясе булырга теләвен яшермичә, моңа ничек һәм ни рәвешле ирешергә мөмкинлеге хакында сорады. Аның кемлеген һәм ниндилеген белгәнемә күрә:

— Бу дөньяда һәммә әйбер кебек, дәрәҗә дә сатыла һәм сатып алына,— дидем аңарга, киңәшемне тотачагын белеп.

Икенче юлы очрашканыбызда ул бик зур чиновник мәртәбәсенә ирешкән иде инде. Ул миннән:

— Берәүләрнең дан-дәрәҗәсе үзләре белән бергә үлә, икенчеләрнеке үлгәннәреннән соң да арта бара. Бу нилектән?— дип сорады.

— Үз табигатьләренә, акылларына, сәләтләренә күрә табылган дан-дәрәҗә һичвакыт кимеми һәм урын биләүгә бәйле түгел,— дидем мин аңарга, әмма үпкәләтүемне башыма да китермәдем.

Ул мине танымас булды.

## ТУТЫК КАЛӘМ КӨЛКЕСЕ

*Хикәят*

Язучылар хакында сүз чыккач, фикер сукмагында адашкан танышларымнан берсе:

— Язучылык үзе бер һөнәр генә ул, язмый торсаң — каләмең тутыга, күп язсаң — караң бетә,— дип әйтеп куйды. Моңа кадәр бу хәтле көлгәнем юк иде. Тынычлангач, дусларымның икенчесе:

— Кайсы җенегез шулай котырды? Шушы кадәр ишелгәнегезне күргәнем юк иде,— диде.

Оят булып китте, шулай да:

— Җенем котырмады,— дип аңлатырга өлгердем,— зәгыйфь күңелемнең мыскылга калуыннан акылым шашынып алды.

— И-и,— диде теге танышым,— болай булса, сезгә каләм белән кара турында гына сөйләргә кирәк икән, авызыгызны җыя да алмассыз!

## БӘЙРӘМ ИРТӘСЕ ИДЕ

*Хикәят*

Яшь чагымда гает иртәсендә бер төш күргән идем: кояш минем күкрәк турыма иңде, шул кояш эчендә ак сакаллы, чалмадан бик тә мөхтәбәр зат алтын медальгә ясалган сурәттәге сыман иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд икән дип уйладым. Ә ул миңа:

— Тор, балам, сиңа уянырга вакыт!— диде.

Уянып киттем. Күкрәк турымдагы кояш исә тәрәзәдән күз салган кояш янына китте. Алар кушылып, бер булып яна башладылар.

Тордым, юындым...

Әле хәзер дә уйлыйм: ә уяндыммы соң? Югыйсә бу кадәр газаплар чигеп тормыш арбасын тартыр идемме? Әллә ул мине шуның өчен дип уяттымы?

## ТУГАН ИЛ ЯМЕ

*Хикәят*

Бәхетнең тәме дә була икән ул. Озак вакытлар шул тәме иренеңнән китми. Һаман-һаман татыйсыңдыр сыман. Менә сөенеч кайда ул! Бәхет тә насыйп эше икән.

— Бәхетнең тәме нинди?— дип сорадылар миннән. Белмиләр идеме?

— Әлбәттә татлы!— дидем мин.

— Их егетләр!— диде арадан беребез.— Мин иртәнге таң чыгы тәмендәге бәхет татыганым бар, әле дә шуңа хәйран итеп йөрим.

— Беләбез,— дидек без.— Ул — сөекле яр! Әйеме?

— Юк!— диде ул.

— Затлы ризык тәме!

— Юк ла инде,— диде ул кабат,— бөтенләй башка: читләрдә йөргәндә ишеткән милли җыр! Татар көенең матурлыгына хәйран калган идем мин ул чагында!

## БУШ СӨЙЛӘШҮ

*Хикәят*

Һәркем әллә кем. Шул кемлекләре өчен аларны хөрмәт итә белсәң, синнән дә яхшы кеше юк инде ул. Әмма һәр адәм баласы үз кемлегенә тиңлек тота алмый. Кемлек тә югалу галәмәте белән бәйле.

— Дәрәҗәне ничек саклап була?— дип сорадылар миннән.

— Үз кемлегеңне хөрмәт итеп!— дидем мин аларга.

— Ә куштаннар алай итмиләр бит. Ялагайлык белән дөньяны кулларына алалар,— диделәр миңа.

— Анысы шулай, әмма үз кемлегең булмаган килеш дәрәҗә белән ни файда? Ул — коры кашык кебек, гомернең бушка узуы белән бер!— дип җавап бирдем.

Барыбер килешмәделәр. Ахырдан:

— Бу сорауга үзем дә җавабын белмим икән,— дидем.

## КУШТАННАР БОЛАМЫГЫ

*Хикәят*

Куштаннар ике яклы үткен пычак кебек алар, бер яктан халыкны бутап йөриләр, икенче яктан — түрәләрне. Ике як та аларга ышана. Әмма иң җаваплы вакытта болар халыкны да, түрәләрне дә кәкре каенга терәтеп куялар.

— Куштаннарның астыртын эш йөртүен һәркем белеп тора, әмма ни өчен аларның сүзенә колак сала, аларга ияреләр соң?— дип сораганнары соңында:

— Чөнки куштаннарда араларны, уйларны, күңелләрне бутау сәләте бар,— дидем дусларыма.

— Һи-и,— диде арадан берсе,— дөрес шул. Мин әле аларны башсызлар, шуңа күрә буталалар дип уйлый идем. Ә алар юри, махсус, белә торып бутыйлар икән!

## ГАФИЛЛЕК БӘЛАСЕ

*Хикәят*

— Кешеләрне бутаудан ни файда? Чөнки буталчык судан балык тоту җиңел, әмма кармак белән түгел, ятьмә салып сөзеп кенә аласың. Бу — метафора, билгеле. “Балык тоту” дигәндә үзеңә файда эшләп калу хакында сүз бара. Акылыгыз булса, дөньяны үзегез түгел, куштаннар ярдәмендә бутагыз, әмма ятьмәгезне файда күленә салып куярга өлгерегез!— дидем бервакыт халыкка.

Әмма алар миңа:

— Файда һәммәбезгә дә бердәй булырмы соң?— дигән сорау бирделәр.

— Булыр,— дидем,— әгәр дә һәммәгез акылда, зиһендә, тырышлыкта һәм өлгерлектә тигез булсагыз. Әмма гафил калудан да яманрагы юк. Тормышны болай да гел бутап торалар!

## КУШТАННЫ СЫНДЫРУ

*Хикәят*

Дөньяны сез акыллы кешеләр бутыйлардыр дип уйлыйсызмы? Юк, аны куштаннар болгата, тик боламыгын баш бирмәүчеләр ашый. Берүк куштаннарны тыңламагыз, сүзләрен тотмагыз, алардан курыкмагыз, үзләрен санга алмагыз!

— Әмма алар зыян итәләр шул,— диделәр миңа.

— Әлбәттә шулай, әгәр дә аларның сүзенә колак салып торсагыз, алар белән сер сөйләшсәгез, ахыры үзегезгә кыенга килер!— дидем.

— Ничек булыйк соң ул вакытта?— дип, минем сүзләремә колак тотучылар аптырашларын белдерделәр.

— Әйе һәм юк мәртәбәсендә булыгыз!— дидем, шул халыкка киңәш биреп.— Уегызны йөзегезгә чыгармагыз, аның ни-нәрсә уйлаганын да белергә тырышмагыз. Хәтта үзен һәм сүзләрен игътибардан читтә калдырыгыз. Куштанның азау теше сынар!

## УТЫРЫШ ГЫЙЛӘҖЕ

*Хикәят*

Бер утырышта сүз биргәннәреннән соң, мактап әйтергәме, тешләп тә куяргамы дигән уй килде. Иң яхшысы — әүвәле тешләп, аннары сыпырып, “дарулап” куярга кирәктер, дидем. Нәкъ шулай эшләдем.

Чыгышым кыска һәм төгәл булды сыман. Ахырдан, утырыш беткәч, бер танышым килеп:

— Усал әйттегез,— диде.— Тәннәр чымырдап куйды.

— Ә мактавым файда итмәдеме?— дип сорадым.

Ул:

— Юк шул,— диде,— тешләнгән урынны өф итү кебек кенә тоелды.

— Бәлки шулайдыр да, әмма,— дидем, аның дикъкатенә көч итеп,— даруның файдасы мизгел эчендә түгел, тора-тора, вакыты җитү белән сиземләнер!

## “КИРӘКЛЕ КИТАП”

*Хикәят*

Бер галимнең китабын укыдым. Нинди ачыш, нинди яңа сүз әйтте икән дип беләсем килгән иде. Башланып киткәндә үз хезмәте алдына бик күп сораулар куйган бу, әмма китабында берсенә дә җавап бирмәгән.

Галим мәртәбәсен күтәреп йөргәненә аптырап калдым. Әйттем:

— Бу китапны укып чыгыгыз әле, күзегез ачылмасмы?

Арадан берәү аның белән таныш икән. Ул, бик аптырап:

— Нигә сез шул галимне безгә өлге итеп куйдыгыз?— дип сорады.— Бу китапны язган кешенең ни акылы, ни белеме урынындамы икән? Галим аталуы оят!— диде.

— Рәхмәт!— дидем мин аңарга.— Нәкъ менә акылны юләрлектән, белемне наданлыктан, галимлекне галим булмаудан аерырга өйрәнү өчен бу — кирәкле китап!

## ТОРМЫШ ЯМЕ

*Хикәят*

Танышымнан, очрашкач, хәлен белештем. Ул миңа:

— Начар икәнлеген каян белдегез?— диде.

Уңайсызрак булып китте. Шулай да:

— Сөмсерегез коелган,— дидем.

Ул шунда үз хәлен озаклап сөйләп, тормышның гаделсезлегеннән зарланды. Сүзенең ахырында:

— Акча биреп тормассызмы?— дип үтенде.

Бирдем.

Шунда йөзенә кояш чыкты. Баш төзәтү мәсьәләсе белән аптыраган икән.

Кичен юлыма кабат очрап, тормыш яме, үзенең булдыклы булуы хакында озын-озак нотык сөйләде.

Әйттем:

— Кечкенә генә авыру да тормышның чын йөзен күрергә ярдәм итә дип белми идем!

## МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘ

*Хикәят*

Милләтләрнең кайберләре безгә холыкта авыр кебек тоелалар, ә кайсылары шундый да үз сыманнар. Моның сәбәбе хакында сөйләгәндә бер агай:

— Һәр халыкта яхшы һәм яман кешеләр бар,— диде.— Шунлыктан берсен дә өстен дияргә ярамый.

Сүзе белән килештем. Әмма мин:

— Милләтләрнең шундыйлары безгә авыр кебек тоелалар, кайсыларының гореф вә гадәтләрен белмибез, шулары җиңел булалар, кемнәрнең горефтә һәм гадәттә көн күрешләре безнекенә тартым,— дидем.

Агай минем сүзләремне тыңлап торды да:

— Бик шулай,— диде,— гореф һәм гадәт халыкларның холкы-фигыленә генә түгел, табигатьнең дә гореф вә гадәткә тәэсире бар,— дип, тагын хәйран итте.

## МӘХӘББӘТСЕЗ БӘХЕТ ИЯСЕ

*Хикәят*

— Сине яратмауларын белсәң, нәрсә эшләргә кала?— дип сорадылар миннән.

— Әлбәттә мәхәббәт изге хис,— дидем мин, уйга калып,— әмма яратмауларын белү, сине яраталар дип алданып йөрүдән күпкә хәерлерәк! Берни дә калмый: ризалашырга кирәк. Мәхәббәттә көчләү юк. Яратмыйлар икән, яратмыйлар. Ул сөю хисе бит, яуланып һәм дауланып алына торган байлык сыман түгел. Тырыштырудан мәгънә чыкмый.

Сүз шушының белән бетәргә тиеш иде. Әмма сорау биргән егетнең күзләренә яшьләр килде. Аны кызгандым һәм:

— Энем,— дидем,— сез үзегезнең нинди бәхетле булуыгызны аңламыйсыз шул әле!

## ЙӨРӘКНЕ ҖЫЛЫТЫР УТ

*Хикәят*

Мәхәббәт кешене мәгъруур һәм акылсыз иткәнлеген беләм, шунлыктан бу хискә бирелмәүдән дә өстенрәге юк икәнлеген аңлап яши идем. Кем дә булса: “Мин сине яратам!”— дип әйтсә, котларым оча.

Ә бервакыт дусларым арасында мәхәббәт хакында сүз чыгып, аның изгедән дә изгерәк хис икәнлеген яшерми тәкрарлый башладылар. Фикеремне сорадылар. Мин аптырап калдым, ахырда:

— Сез ул соравыгыз карт кешедән яшьлек нәрсә икәнлеген сөйләвен үтенгәнегез кебек тоелды,— дидем,— Онытылганны күңелендә яңартып, яшьлек — юләрлек, дияр иде. Мин дә моңардан артыгын әйтә алмыйм. Йөрәгем ташка әверелгән, аны мәхәббәт уты түгел, тәмуг та кыздыра алмас тәгаен!

## АДӘМ ТАБИГАТЕНӘ ДӘВА
*Хикәят*

Кайбер кешеләр ныклык белән кирелекне бер үк сыйфат дип аңлап, табигатьләрендә кирелек саклап сантыйлananалар. Андыйларга хәтта яхшы, йомшак сүз дә үтми башлый. Моңа, иң әүвәл, бер дә аптырамаска кирәк. Кешене танып калудан да яхшысы юк.

— Кирелекне ничек китәрергә була, бигрәкләр дә оятка илтүче сыйфат бит?— дип сорадылар миннән.

Үз тәҗрибәмне искә төшерергә һәм әйтеп бирергә туры килде:

— Кирелегеңне бетерү өчен аңардан, ягъни шул кирелектән көлүеңнән дә хәерлерәге юк,— дидем мин.— Мыскылга калу табигый сыйфатларны авыру, чир дәрәҗәсенә төшерә, әмма көлүдән дә яхшырак һәм үтемлерәк дәва әлегә уйлап табылмаган!

## ТАБИГАТЬ АЛЫШТЫРУ
*Хикәят*

Байлыкны хәерчелектән эзләмәгез. Яратмаган кешедән мәхәббәт таләп итү кебек үк юләрлек ул. Иң яхшысы — хәзинәченең киемен кагыгыз, алтын-көмешнең дә тузаны була. Мөгаен киеменә утырмый калмагандыр!

— Гомерем буе саулыкка туена алмый яшәдем. Минем авыруыма дәва беләсезме?— дип бер агай бик үтенгәч, табип сезгә нәрсә әйтте диярәк башын катыруның мәгънәсе юклыгын аңлап, мин аңа:

— И агай, күрәм, сезгә дәва табудан да хәерсезрәк агу юк,— дидем.

Ул миңа бик тә үпкәләде. Сөмсере коелды, шуңар күрә аны юатып:

— Табигатегезне алыштыру хәерле булыр!— дип әйттем.

Шуннан бирле аны күргәнем булмады. Танышымнан сорадым. Ул башка шәһәргә күченеп китте, диделәр.

## ХОДАЙ САБАГЫ

*Хикәят*

Кыен мәсьәләне чишкәндә орылып бәрелүнең файдасы юк, сабырлыктан да яхшысын белмим.

Шулай бервакыт хыялым күз алдымда җимерелеп төште. Күңелне авыр уйлар, чарасызлык хәсрәте биләп алды. Мин шунда үз алдыма: “Аллаһыга шөкер, буш теләкләремнән котылдым!”— дип әйттем.

Әмма күңелем нурланмады. Хыялымның тормышка ашмавына эчем поша торды. Мин шунда: “Баламның хыялына насыйп сәгатьләрен ачсаң иде, Ходаем!”— дип дога кылдым.

Менә шунда күңелемә шатлык хисләре тулганын тоеп, сөенечем тау булды. Әйттем: “Рәхмәт, Аллаһы тәгалә! Синең бу сабагыңнан да яхшырак сабак алганым юк иде әлегә!”— дидем.

## КҮҢЕЛ ВАТЫЛУ

*Хикәят*

— Күңел катылыгын җиңеп буламы?— дип сорадылар миннән.

— Әлбәттә,— дидем.— Аның өчен йомшак сүз бар. Ничек тамчы бөртекләп тама-тама ташны тишсә, йомшак сүз дә әүвәле каты күңелгә йокмый аптырар, диварга бәрелгән борчак кебек чәчрәр, ә аннары, һаман-һаман әйтелеп торган саен, кешене үзенә күндерә барыр һәм аның бәгыренә үтеп керер.

— Анысы шулай,— диделәр, әмма миңа каршы килеп әйттеләр:— Шушы кадәр эш өчен никадәр вакыт, никадәр көч сарыф ителә түгелме?

— Хәер,— дидем мин аларга кабат,— башка юлы да бар: авыр хезмәт адәм баласының тегермән ташыдай каты бәгырен дә ватып ташлаучан, әмма бу — күңеле йомшарды дигән сүз түгел шул!

## ХЕЗМӘТ ДӘВАСЫ

*Хикәят*

— Күңел муртайса, дәвасын каян, ничек табарга?— дип сорады бер агай.

— Әллә берәр хәсрәт диңгезен кичәргә туры килгән идеме?— дидем сорау белән мин дә аңарга.

— Юк,— диде ул,— мин үзем ныклы кеше, әмма улымның күңеле буталып алгалый.

— Сәбәбе билгелеме, алай да?— дидем тагын да.

— Меңенең береннән дә файда табылмады,— дип, хәсрәтендә калды ул.— Бөтенләй дә чарасыз яшәүдәмен.

— И агай,— дидем аңарга,— авыруның сәбәбе беленмәсә, дәвалаудан файда юк. Анысын беләсездер инде. Әмма улыгызга бер киңәш бар: нәрсәгә тотынса, шуны олы күңел салып эшләсен, дәвасын да табар. Гафил калмагыз!

## СҮЗНЕ ҖАЕНА ҖИЛГӘРҮ

*Хикәят*

Күңелгә борчылу тиктән генә килә тормый, аның сәбәбе була. Әмма шушы сәбәп дигәне үзеңә генә бәйле икән, бер хәл, мәгәр төзәтелер мөмкинлегеннән узылса нишләргә?

Шул хакта сөйләшеп утырганда бер дустым:

—Борчылу астында калганчы, аңардан өстен чыгуың хәерлерәк,— диде.

Аның бу сүзләре сәер тоелдылар.

— Нигә авыз читегез белән мыскыллап елмайдыгыз?— дип сорады ул миннән.

Тизрәк аның борчылуын китәрү җаен карадым:

— Минем дә исемә төште,— дидем,— тагын бер җаен беләм: тормышның бәхетле минутларын уйлап юанганда күңелдән хәсрәт китеп торучан була. Шуны уйладым.

## ИКЕ АХМАКНЫҢ СӨЙЛӘШҮЕ

*Хикәят*

Бер ахмак кеше үзенең бар нәрсәдән дә курыкканлыгы турында әйтте. Мин аңардан:

— Барча гамәлләрегезне дөрес эшләргә исәплисез, әйеме?— дип сорадым.

— Һичшиксез!— диде ул, тәмам балкып китеп.

— Юлыгыздан бер генә адашканыгыз да булмадымы?

— Юк, угрылык та кылмадым, чит хатыннарга да күз салмадым,— диде ул.

— Алай булгач сез — фәрештә икәнсез!— дидем мин аңарга.— Кешеләр арасында йөрүегез үзе үк адашу түгелмени?

— И-и,— диде ул миңа,— сезне гадел кеше буларак сөйлиләр иде, бер дә акылыгыз юк икән!

## СҮЗ УМЫРТКАСЫН СЫНДЫРУ

*Хикәят*

Сүз — койрык тоттыра торганнардан түгел. Әмма аның асылсыз, ялган булуы — күп, дөрес чагы гына аз.

Шул хакта сүз чыккач:

— Сүзнең дөресендә умыртка сөяге була, ялганында...— дип әйтә генә башлаган идем, дустым бүлдерде:

— Аның умырткасы барлыгын ничек белеп була соң?

— Сындырып карап,— дидем мин.

— Һи,— диярәк көлде ул,— сүз сына торган җенестән икән, авыздан түгел, башка җирдән чыгар иде. Сез дә әйттегез!

— Әйе, әйтәбез,— мин дә аңарга елмаеп җавап бирдем.— Менә үзегез дә, ничә тапкыр сүз башлавыма карамастан, умырткасын сындырып-сындырып аптыраттыгыз!

## ЯШӘРЕП АЛУ
*Хикәят*

Кеше үзенең хатасын соңыннан гына аңлый, әмма танырга теләми аптыраган чаклары да була.

Дустыма шул хакта әйткән идем, Ходайныңмы язмыш пәкесе тиеп китү сәбәпле пеләш калган башыннан тир бөртекләрен сөртеп:

— Тәмам бабайларга әйләнеп беткәнсез, шулар сүзен сөйлисез!— дип әйтеп куйды.

Ә мин: “Әллә каракның бүреге яна инде?”— дидем, уемны хәтеремә киртләп, аңарга исә, ачуын китермәс өчен:

— Картаела барыла шул,— дигән булдым.— Яшь чагында мондый уйлар башыма керсәләр иде, хәзер “акыл сатып” йөрмәс идем, үзегез дә беләсез!

— Менә бит,— диде ул,— күз алдымда яшәреп киттегез!

## БАЙЛЫК ҺӘМ КЕШЕ
*Хикәят*

— Байлыкның хикмәте — тормышыңны иркен үтүдә!— диде миңа дустым.

— Байлык тирәсенә эте дә, бете дә җыелучан, шулмы иркенлек!— дидем, аңарга каршы төшеп.

— Анысы шулай,— диде ул.— Әмма да бай кеше күзгә чалынучан була, аңа хөрмәт тә явып кына тора.

— Болар бит байлыктан өлеш каптыру хәсрәтендә йөрүчеләрнең генә эше!

— Сыйсыз хөрмәт булмый, үзегез дә беләсез,— диде ул, бу юлы да үз сүзендә калып.

— Ә байлыкның башка файдалары юкмыни соң?— дияргә мәҗбүр идем.

Ул исә, елмаеп:

— Бар,— диде.— Әмма алары байлык галәмәтеннән түгел, кешенең кемлегенә һәм нindилегенә бәйле!

## ШУЛАЙ ТҮГЕЛМЕНИ?
*Хикәят*

Бәхетле кеше булсаң, үз илеңнән китәр идеңме соң?

Дөрес, кайда да тормыш бар. Андамыни хикмәт! Бәхетле дә буласы килә.

— Бәхетле кешенең күңеле тыныч аның!— дигәч, сүземә каршы чыгып:

— Ваемсыз кешенең дә күңеле тыныч була. Димәк, сезнеңчә, бәхет ул — ваемсызлык!— диделәр.

Аптырап калдым. Ваемсызлыкның томаналыктан килгәнлеген исемә төшердем. Хәер, бәхетле кешедә дә ваемсызлык хикмәте күзәтелә. Анысын да уйладым. Тагын да күңелсезрәк булып китте. Ахырда:

— Табигатьтә ак белән кара һәрвакыт янәшә йөри. Кайвакыт алар үзара шулкадәр катнашып китәләр, берсенең сыйфатын икенчесенеке буларак күзаллый башлыйбыз,— дидем.

## САБЫРЛЫК ҺӘМ ТЫРЫШЛЫК

*Хикәят*

Тормыш авырлыгы бер хәл, аны күтәрә дә белергә кирәк. Үзебездән гайреләрдән кемгәдер җиңелдер кебек тоела гына ул, һәркайсыбыз аның арбасына җигелгән.

— Тормыш авырлыгын күтәрә белү нәрсәдән тора?— дип сорадылар, гадәттәгечә җавап бирдем:

— Сабырлыктан һәм тырышлыктан!

— Болар икесе үзара капма-каршы түгелләрме соң?— диделәр аптыраушта.

— Тырышлыкта сабырлык булырга тиеш!— дидем мин.— Әмма сабырлыкта да тырышлык комачау итмәс иде, әгәр андый мәртәбә була калса. Без бары тик сабыр итәргә тырышабыз гына, тырышта сабырлык та бик авыр бирелә. Болар арасында каршылык бар дигәндә мөгаен шуларны күздә тоткан булырсыз?

## БУЛДЫКЛЫ ЕГЕТЛӘР

*Хикәят*

Имеш, мәхәббәт уенында хикмәт бар: бер сөю икенче сөюне йөрәк сараеннан куып чыгару көченә ия. Ягъни, бер мәхәббәтеңне онытырга теләсәң, икенче мәхәббәт учагын тергезеп җибәрергә кирәк.

— Чөйне чөй белән бәреп чыгаралар,— дип, олыдан кубып, яшьләр сөйләшеп утыралар иде, мин алардан:

— Ә чөйгә нәрсә белән сугасыз?— дип сорадым.

— Теләк куәте белән орабыз!— диярәк җавап бирделәр.

— Алай икән,— дидем мин аларга,— бу гамәлләрегездән соң ахырда чәрдәкләнеп, сугылып, кыйналып беткән йөрәк кенә каламы? Аның белән алга таба ничек яшәрсез соң? Рухыгызны ныгытасы урынга, аны ватудан ни мәгънә бар?

## МОДА ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Кешеләрнең яхшылыгы гамәлләрендә һәм сүзләрендә чагыла. Моны белмәүче юк.

Әмма сүз кием хакында чыкты. Яхшы кием модага бәйлеме, әллә пөхтәлеккәме? Бәхәс китте.

Миннән дә фикеремне сорадылар. Бераз тынып торгач:

— Киемнең яхшылыгы кылына торган гамәлләргә һәм аларның сыйфатына бәйле,— дидем.

— Ничек инде?— дип аптырадылар.— Ташчының киеме тетелеп беткән була, сугымчыныкы — канлы, башканыкы — бүтәнчә. Шушымы?

— Сүзегез бик дөрес,— дидем аларга.— Егет аулаган кыз киемнең итәксезен кия, намазлы әби яулык һәм озын итәкле күлмәк белән йөри.

## КҮҢЕЛ КҮЗЕ ЙОМЫКЛАРГА

*Хикәят*

Мәхәббәткә күңеле суынган бер егет миннән:

— Тормышта сөекле нәрсә бармы?— дип сорады.

“Ил-ватан, туган туфрак, гаилә, ата-ана, туганнар” димәкче идем дә, җавабымны кабул итәргә әзер түгеллеген аңлап:

— Күңел күзен ачу куәтенә ия нәрсә бар, шулар сөекле,— дип җавап бирдем.

— Нәрсәләр соң алар?— диде ул.

— Зиһене куәтле кеше өчен — гыйлем, күңеле сынык яки зиһене таркау кешеләргә — уен, тамаша, театр,— дип, берәм-берәм санап киттем.

Ә ул миңа:

— И-и, бигрәк кызык икән,— диде.— Боларны вакыт әрәме буларак әһәмиятсезгә саный идем.

## УЙНЫҢ УЕНЫ

*Хикәят*

Уйда уен була, имеш. Шуңа күрә телдә дә уен катнаш уйлап сөйләшү була, диләр. Хәтта кистереп әйтү дә уен галәмәте булмый калмый.

Шушы хакта җәмәгать әһеле сөйләшеп утыралар иде, мин алардан:

— Уен булгач, аның уртак бер тәртибе, җае күренми калмас. Уйдагы уенның тәртибе-җае нинди икән?— дип сорадым.

— Кешенең табигатенә карап,— диделәр, миңа аңлатып,— хәйләкәр — хәйлә белән уй кылыр, тәвәккәл — кистерү белән, сабыр — сабырлык белән!

— Алай булгач, акыллы кеше — акыл белән уйнар, гыйлем кеше — гыйлем белән уйнар, ахмаклар — ахмаклык белән дисез инде, әйеме?— дидем мин аларга.

## “БАСУРМАНИН”

*Хикәят*

Милләт мәсьәләсе четерекле булуы белән аерылып тора. Кешеләр үзләренең кемлекләрен милләтләренең бөек булуларын аңлату, тәкрарлау белән дәлилләү юлында торалар. Моны мин милли аңның өстенлек алуына бәйле дип белә идем. Әмма кешеләр, шушы юл белән китеп, тарткалашып-сугышып бетәргә мөмкиннәр һәм шулай эшлиләр дә.

Бу мәсьәлә хакында сүз чыккач, мин, бераз елмаеп:

— Киләчәктә милли аң мәртәбәсе һәм куәте үз милләтеңне бүтәннәр авызыннан яманлап сөйләнелә торган сүзләрне көлкегә әверелдереп раслаулардан гыйбарәт булыр,— дидем.

Аңламадылар. Шунда аларга:

— Ачуланмагыз, мин бит “поганый татарин, басурманин”,— дип әйтә куйдым.

Барсы да курка калдылар.

## ДАН БУЛСЫН

*Хикәят*

“Хатыны бер ирне талкый икән:

— Нигә ул хатыннарга багасың? Үзең минем белән барасың, ә алардан күзләреңне алмыйсың!

— И матурым,— дип аклана икән ире,— мин аларга карыйм да, йа Ходаем, рәхмәт, ярый әле минем “бәгырем” болар кебек ямьсез түгел, диям!”

Җәмәгать шушыны сөйләшеп, рәхәтлектә көлешеп утыралар иде, колагыма кергән ул сүзләреннән соң:

— Сөбхан Аллаһ!— дип әйтеп куйдым.

Миңа борылып:

— Ни өчен алай сүз каттыгыз?— дип сорадылар.

— Беренчедән, бу ирнең акылына хәйран иттем, икенчедән, сүз сөйли белүенә,— дидем аларга.— Әмма, өченчедән, мактанчык булуы да Аллаһыны данлауга мәҗбүр итте.

## АЧУНЫ КИТЕРМӘГЕЗ

*Хикәят*

Татарда хәтәр бер гадәт бар: кинәт ачуы кабарып китүчән. Дөрес, мондый сыйфат башка халыкларда да, һәр кешедә дә диярлек күзәтелә, анысы. Әмма татарда ул бөтенләй башкача, ачуы килсә, акылы да китә, итагате дә бозыла; тешләп өзә, чабып ташлый.

— Менә шушы гадәтемне өнәмим һәм аңардан котыла да алмыйм,— дидем мин дусларыма.

Ә алар, киңәш итеп:

— Җилне дә яхшы эшкә — тегермән канатларын әйләндерер өчен җигәргә файдаланып була, башкасына да. Син шулай ит, файдалы эшкә сарыф кыл бу кыйты гадәтеңне,— диделәр.

— Бик шулай итәсе иде,— дип акландым мин.— Әмма ачу килгәндә акылым киткән вакыт була, белешми калам.

## АКЫЛ САТАШУЫ

*Хикәят*

Тормышның җае булсын өчен әүвәле аны үзең җайлап җибәрергә кирәк. Хәер, туганнарың, әти-әниең булышып, җаена кертергә дә мөмкин. Җиңелгәрәк туры килә.

Әмма шунысы бар: тормыш һаман да үзгәреп торучан, чөнки вакыт — үтүчән, замана — бозылучан, дигәндәй, үзең һаман-һаман тормышыңны җайлап тора белмәсәң, тарала да төшә инде менә!

Шулай бервакыт бер яшь җилкенчәк:

— Ничек яшәгәндә дөрес була?— дип, әллә шаяртып, әллә чынлап сорады.

Мин аңарга:

— Бүгенге белән яшәргә кирәк,— дидем.— Иртәгә нәрсә буласы билгесез, үткәнне төзәтү мөмкин түгел, бүгенгенең җаен бозмаска тырышырга кирәк!

Шуннан соң гына исемә төште: яшьлектә киләчәк турында хыялланып яшәгәндә көннәр мәгънәлерәк була түгелме?

## АҢЛАША АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ

*Хикәят*

Минем ике мәсьәләдә фикерем гади: берсе — акчага бәйле, аны кысып тотканда дөрес булыр, икенчесе — нәфсегә карата, аны һаман саен кисәкләп тору яхшы!

Бу хакта сүзем телемнән төшкәч, бер әфәнде:

— Сез, мөгаен, гомерегезне мохтаҗлык белән уздыручылар исәбендәдер!— дип әйтте.— Мин, мәсәлән, акчаны гел чыгара торуны мәслихәт күрәм, шул вакытта ул үзе дә кире кайтыр урынын табучан була. Нәфсегә килгәндә, ул бит бәндәнең төп сыйфаты. Үзеңне бөлдерүдән ни файда?

— Әйе, сез хаклы,— дидем, сүзләреннән соң акылымны җыеп,— бай белән ярлының аермасы зур шул. Бер-берсен аңламаска да мөмкиннәр.

## ЧЫГЫМЛЫ ФАЙДА

*Хикәят*

— Акчаң күл булуга караганда, күлең акча булу хәерлерәк,— дигән идем, бер дустым:

— Аларның аермасы нәрсәдә соң?— диде.— Акча күл булганда яхшы түгелмени: байлыкка чумып яшисең дә яшисең!

— Анысы шулай,— дидем мин,— әмма акчаң күл булса да кибеп бетәргә мөмкин, ә менә күлең акча булганда, ул һаман табыш китереп тора, гомер буена җитә, балаларыңа да кала.

— Һи,— диде ул,— күл корымыймы әллә?

— Корый, әлбәттә,— дип җавап бирергә мәҗбүр идем.— Әгәр дә ул күлнең файдасын үзең өчен генә тотсаң, ә аның үзенә дә бер-бер файда итү ягын карамасаң!

## КҮҢЕЛ КҮЗЕ КҮРГӘНДӘ

*Хикәят*

— Киләчәкне юрауның ни өчен зыяны күп, гөнаһы бар?— дип сорадылар.

— Чөнки,— дидем мин,— ул — кешенең күңел күзен сукырайта.

— Әгәр дә нияте белән юравы туры килсәләр? Мондый вакытта балкып китмибезмени?

— Ниятең барда юрап маташуның кирәге нәрсәдә соң?— дидем мин дә, беразга аптырап.

— Соң,— диделәр,— хыялың буш булып калырга мөмкин бит!

— Хыял — бер, ният — башка,— дияргә мәҗбүр булдым.— Хыялны аны бушлык өстенә дә корырга була. Ә ният иткәндә, максатлы эш белән мәшгуль булмый җаең юк. Ниятне бушлыкка кору мөмкин түгел, күңел күзе, туры карап, моңаргa җай бирми.

## САТАШУ ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Дөрес сүздән ялганны ничек аерырга? Һәр сөйләнгәнгә ышанмаска кирәк, диярсез бәлки? Ә хаталы сүз ялганга тиң түгелме?

Шулар хакында уйланып утыра идем, телефон шалтырады. Дустым икән. Сөйләштек: килеп чыга, имеш. Йомышы төшкән. Кирәгем чыккан.

Озак көтәргә туры килде аны. Әмма ни үз уемның очына чыга алмадым, ни ул килеп җитмәде. Күңел тынычлыгы югалган иде. Аның кесә телефоны барлыгын белмәдем, ул да кабат шалтыратып торуны кирәк тапмады.

Икенче көнне юлыма очрады бу.

— Килеп җитә алмадыгыз, юлыгызны кара мәче кисте, ахрысы,— дидем, көткәнлегемне белдерергә теләп.

— Гафу итегез,— диде ул,— ялган сүз булды бугай. Юлымны, дуслар очрап, оныттырганнар.

## АКЫЛГА ТУЙМАУ

*Хикәят*

Сер түгел, акылның да төрлесе була. Әйтик, практик акыл тормыш өчен зур байлык инде ул: ашыккан чагында кайнар ашыңны да өрдереп каптыра, пешми каласың.

Без татарларның арасында андыйлар сирәктер, ахрысы. Юкса, “татар акылы — төштән соң” дип әйтмәсләр иде.

Практик акылны бездә тәҗрибә белән килә, диләр. Кайберәүләр бик яшьли, ә кемнәрдер бишектән үк булыр — акылга утыралар.

— Беркатлы булсаң, акылга бик тиз утырталар,— дигән идем, сүзләремә колак куйган дусларым килешеп алдылар. Бу аларның, үз тәҗрибәсен сөйли, дигәннәре кебек үк иде.

— Сез хаклы,— дидем мин аларга,— бары тик акылдан хәбәрдар булмаучыларга гына моның катнашы юк.

## КАЙЧАН АЕРЫРГА ӨЙРӘНЕРБЕЗ?

*Хикәят*

Йөрәгегезгә басып үтә күрмәсеннәр, үзегезне саклый күрегез! Бар авырлыкларны да күтәреп була, сабырлык һәм тырышлык ярдәм итә, әмма йөрәгеңә басып үтсәләр, егыласың икән ул.

— Мыскылланууда кеше үзе гаепле буламы?— дип сорадылар шаярту белән мыскыллауны буталучылар.

— Көнчелектән гайре нәрсә гаепле булсын?— дидем мин аларга.

— Мескеннәрдән көнләшмиләр түгелме соң?— диделәр.

— Сүзегез дөрес, мескеннәрне шаярту — килешә, әмма анда да чама кирәк, мыскыллауга әверелмәсен!

— Димәк, мыскыллау көнчелектән булмый түгелме соң?— диделәр.— Ялгыштыгыз!

— Әмма өстеннәрдән көлеп булмый,— дидем мин дә.

## ГӨНАҺ ЗАМАНЫ

*Хикәят*

Чишмә суын чиста, диләр. Әмма анда балык яшәми, бака йөзсә генә инде.

Күңеле саф дип йөргән кешенең дә буш булуына хәйран иткәнем юк идеме соң? Хәер:

— Дөньябыз гөнаһ белән тулды,— диделәр миңа бервакыт.

Алардан:

— Нәрсәләрне күздә тотасыз?— дип сорадым.

— Уйнаш-муйнаш күбәйде,— диделәр.

— Ә, анысын әйтәсезме?— дидем мин.— Әмма ул хакта кайдан белеп әйтәсез?

— Күзләребез сукырмы, колакларыбыз саңгыраумы?— дип лаф ордылар алар.

— Алай икән,— дидем, бераз аптырап,— ә болай сөйләнеп утыруны гөнаһка санамыйсызмы?

## БӘРӘН ХӘЛЕНӘ КАЛДЫРЫП

*Хикәят*

Бер төркем носарилар мөселманнарны телләре белән или һәм талкый башладылар. Араларында, асылда, Ислам динендә булучылардан бер мин генә идем. Алар:

— Безне сугыш белән җәберлиләр, диннәре дөрес түгел!— диделәр.

— Шул гынамы?— дидем.

— Шушысы да җиткән!— диделәр.

— Алай икән,— дип хәйран итүемне белдердем.— Мөселманнар, сезнеңчә, сарык бәрәннәре булырга тиеш иделәр, әйеме? Сез аларның иленә бәреп кересез, анда үз тәртипләрегезне урнаштырырга маташасыз, ә алар бирешмиләр, үз бәхетләре өчен көрәшәләр. Шулаймы?

— Юк, дөрес әйтмисез,— диделәр алар, үз туксаннарында калып.— Без, киресенчә, аларны дөрес юлга кертеп, бәхетле итәсебез килә.

## КИТТЕМ ӘЛЕ ЮЛ БУЙЛАП

*Хикәят*

Ике юл чатында калганда, ниятеңне барлап, икенең берсен тәвәккәлләү фарыз. Язмышың сиңа сайлау мөмкинлеген биргән икән, сөенү тиешле, чөнки Аллаһының фатихасына юл ачыла.

— Мондый вакытта башка юл белән китмәвең өчен үкенү тиешлеме?— дип сорадылар миннән.

— Куркыныч алдында куркып калу аркасында үкенү — тинтәклек, әмма гамәлләреңне хата белән башкару галәмәте беленсә, моңарга үкенү тиешле. Авырлыкка түгел, гөнаһка үкенәләр,— дидем.

— Әмма хаталы юлдан китү үзе үк гөнаһ түгелмени?— дип тагын да сорыйсы иттеләр.

— Юлның авыры, җиңеле һәм турысы, әйләнече бар,— дидем.— Аны гөнаһсыз узу исә кешенең ихтыярыннан тора. Нияттә хәрам юк, гамәлдә — бар. Күңел сафлыгыннан да зуррак бәхет бармы?

## ТАБИГАТЬ БЕЛӘН СУГЫШУ

*Хикәят*

Мин тормышта өч мәсьәләдә авырлык күрәм: берсе — холкым йомшаклыктан, чыпчык та чукып китәргә күп сорап тормый; икенчесе — күзләрем еракны яхшы күрүдән, якынны аермаудан, чөнки туганнарыма файдалы кеше була алмадым; өченчесе — ачуым кабаручан, рәттән яманны-яхшыны аермый кисеп үтәргә мөмкинмен.

— Без сездә бу хаталарны күрмәдек,— диделәр миңа.

— Чөнки табигатемдәге шушы дошманнарым белән сугыша-сугыша арыпталып яшим,— дидем аларга.— Бер дә хәйран итмәгез!

— Менә үзегезне йомшак та, усал да буларак атадыгыз. Моны ничек аңларга? Кайдан күренәләр?

— Йомшаклыгым кешеләргә зыянлы, усаллыгым — үземә. Менә шулардан күренәләр,— дидем.

## СҮЗНЕҢ ХАТАСЫ

*Хикәят*

— Сүзнең хәрәм һәм хәләл булуын һәммәбез беләбез. Әмма кайчан ул гөнаһка әверелә, ә кайчан саваплы?— дип сораганнары соңында:

— Хикмәт сүзнең мәгънәсендә,— дидем әңгәмәдәшләремә, һич аптырамыйча.

— Әмма без, кешене бәладән йолып алу өчен, аны яклап сөйләү галәмәтенә ия. Куркабыз, бу эшебез — гөнаһ, сүзебез — хәрәм дип. Шул ук вакытта, әгәр яклап сөйләмәсәк, дустыбызга зыян китерүебез бар. Нишлик?— диделәр.

— Якламый хакыгыз юк!— дидем мин аларга.— Дуслар — дусларына терәк. Әмма яманлыкны яклаудан мәгънә бармы? Хаксызны яклаудан олырак гөнаһ булырмы? Сүзнең хәрәме хәләлдән шулай аерыла дип беләидем.

## ЯШӘЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ КАЙДА ДА БЕР

*Хикәят*

— Ни өчен Мөхәммәд пәйгамбәребезне ике дөньяның да солтаны дип атыйлар? Бу дөньяны ул бит кулында тотмаган, Ахирәт көненә дә хуҗа булмады!— диделәр.

— Бу әйтемдә,— дидем мин ул вәсвәсәчеләргә,— шул күздә тотыла: әгәр Мөхәммәд пәйгамбәребез Җирдә дөрес яшәү рәвешен өйрәтеп калдырмаса, без тәмам усаллыкка һәм комсызлыкка батып, бер-беребезне ашар дәрәҗәдә яшәр идек һәм дә, үзегез дә беләсез, Ахирәт рәхәтләрен бу дөньяда дөрес яшәвебез аркасында табабыз. Шулай булгач, чын солтанлык шушы түгелмени? Монда ук җәннәттә яшәү кагыйдәләрен үзләштермәсәк, анда көчеңү белән генә җаныбыз төзекләнерме? Җирне җәннәт итү төп ниятебез түгелмени? Шуны Аллаһы тәгалә теләмәдеме?

## КҮП СӨЙЛӘШҮ ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Күп сөйләшү гадәтеннән котылып буламы?

— Мөмкин түгел эш юк! Барысы да кешенең кәефеннән һәм табигатеннән тора. Телне яшерерлек, сөйләшмәслек булгач, нигә авызында йөртергә?

Шушы әйтелгәннәремне ишеткәч, кайберәүләр, сүзләремне ошатмыйча:

— Күп такылдап, колакларны ардырунымы дөрес саныйсыз?— диделәр.

— Юк,— дидем,— мәгънә белән, акыл һәм гыйлем кушылган сөйләшүне күркәм дип саныйм. Моны күп сөйләшүгә кертмим.

— Димәк,— диделәр,— ике-өч сүз генә булса да буш әйтелсә, шуны күп сөйләшү дип атыйсыз, әйеме?

— Нәкъ шулай! Мәгънәле сөйләшү озакка сузылганда да күп сөйләшү дигән сүз түгел.

## КЕШЕНЕҢ КУӘТЕ

*Хикәят*

Галәмдә һәм Җир йөзендә һәр җан иясенең үз үзенчәлеге бар. Гөнаһсызларны фәрештә, диләр. Бозыклыкны шайтанлык белән бәйлиләр.

— Ә менә кеше башкалардан нәрсәдә аерыла?— дип сораганнар иде, мин:

— Аң һәм гыйлем таба белүләре белән адәм балалары куәтле,— дип җавап бирдем.— Хикмәт — танып белүдә! Фәрештә булып йөргән кешедә кешелек бармы? Кеше кайчан фәрештә була алды? Әллә шайтанга әверелдеме? Ә менә танып белү белән гыйлемнән баш чөергән кеше җәннәтле буламы?

— Ә нигә бездән әдәп-әхлак таләп ителә, шуңардан чыгып кешеләрне дә бәялибез?— диделәр, минем белән ризалашмыйча.

— Алай уңайлырак бит,— дидем аларга, бер дә хәйран итмичә.

## ДӨРЕС КЕШЕЛӘР

*Хикәят*

Телдә ике начар як бар: берсе — буш сүз сөйләшү, икенчесе — усал итеп әйтү. Аларның икесе дә рух тәрбиясенең җитешсезлегеннән, зиһеннең чуарлыгыннан, холыкның затсызлыгыннан килә.

— Сөйләшүнең-сөхбәтнең кайсы яхшы?— дип сорадылар миннән.

Аларга:

— Мөлаем сөйләшү!— дип җавап бирдем.

— Әмма бер вакытта да мөлаем генә сөйләшеп булмый бит! Төрле очракларда төрлечәрәк килеп чыга,— диделәр.

— Ә сез тырышып карадыгызмы соң?

— Исәптә — бар, гамәлдә — юк диләрме әле?..

— Ә үзебезне дөрес кеше буларак белеп-атап йөртәбез, әйеме?— дидем аларга.

## САЙРАП КАРА ӘЛЕ

*Хикәят*

Ирләрнең әгәр дә күп сөйләшә торганнарын ишетсәгез, аптырамагыз. Аларны, мондый вакытларында, сайрый ул, диләр. Димәк, янында күзе төшкән бер яшь җилкенчәк булыр.

— Сайраганда буш сөйләшү нәрсә бирә?

— Әлбәттә башны әйләндерү чарасы бу,— дидем, елмаеп сораган дусларыма.— Буш сүзнең хикмәте — башны әйләндерүдә. Әмма бу сайрау тупас булмасын, җайга җае китерелсен.

— Сайрауга бирешеп торалар димени?— дигәннәр иде, мин дә көлеп куйдым һәм әйттем:

— Сайраганда һичшиксез сандугач була алуың шарт, чыпчык кебек чыркылдаудан ни мәгънә чыксын!

## ҖИТЕШЛЕК СӘБӘПЛӘРЕ

*Хикәят*

— Адәмнең дөньяда нинди булуы хәерле?— дип сорадылар миннән изгелек юлында йөрүчеләр, хәйран итеп.

— Байлыкта, сүздә, гамәлдә, кыяфәттә кешене көнләштермәслек, бәлки сокландырырлык булуы яхшы,— дидем мин аларга.

— Ә аларга ничек ирешеп була?— диделәр тагын да.

— Байлыкта — җитеш, сүздә — хикмәтле, гамәлдә — гадәти, кыяфәттә — пөхтә калу белән,— дидем.

— Әмма болар өчен барыбызда да мөмкинлек юк бит,— диделәр алар, зар кылып.

— Һәрхәлдә киемнәрегезне пөхтә, кыяфәтләрегезне тәртиптә, гамәлләрегезне гадәт бозмый йөртә аласыз. Ул вакытта сүзегез дә хикмәтле, байлыгыгыз да җитеш булыр. Шулай түгелме?— дидем.

## КЕШЕЛЕК БАЙЛЫГЫ

*Хикәят*

Көнчелек сәбәпләре хакында сүз чыккач, мин аны тәрбиясезлектән килә дип белдердем. Без табигатьтән бик күп нәрсәләрне мирасыбыз иткәнбез. Көнчелек дәртебезгә хезмәт итә. Әмма тәрбияле кавемнәр табигатьләрен тәртипкә салу белән мәшгульләр.

Шул хакта сөйләдем.

— Мин,— диде хикмәтле сүз һәм яхшы зиһен иясе бер әфәнде,— дошманнарым көнчелегеннән бәлаләр күп күрдем. Алардан котылу чарасын да уйлап таптым.

— Ул нинди чара?— дип сорадым.

— Хәйран итмәү, көнчелеккә үч белән җавап бирмәү,— диде ул.— Гомумән, көнчелеккә сабыр кешемен.

— Дөрес сүз, килешәм,— дип, мин дә сөенечемне белдердем.— Сабырлык кебек олы байлык кешене бәхетле итү көченә ия шул!

## ШОМЛАНУ

*Хикәят*

Миннән кәефне-хәлне сорадылар. Начар дип әйтергә телем бармады. Шулай да:

— Бүген болытлар салынып торалар әле,— дидем. Ни өчендер һәммәсе дә күккә карадылар. “Әллә минем кәефемне белешеп күкләргә мөрәҗәгать итәләр инде?”— дип уйлап куйдым, йөземә елмаю чыкты. Аннары төшендем: көн аяз иде, мине саташкан кешегә чыгардылар.

Икенче юлы тагын хәлемне сораганнарында:

— Көн буранлап тора әле,— дидем.

Вакытның бәрәкәте җәй рәхәтендә иде. Буран — кыш галәмәте. Ничек аларга табигатемнең саташуы, ачуым килгән чак икәнен башкача әйтәсең?

Әмма дә бик гаҗәпләнделәр. Үзем дә аларның хәленнән шомга калдым.

## ГАЛИМ БЕЛӘН СҮЗ

*Хикәят*

Фән ул ахмак кешеләргә аң бирә алу көченә ия булса да, белемгә һәвәсе юк кешеләргә гыйлем өсти алмый.

Бер вакыт миңа бер шагыйрь әфәнде зарланды:

— Галимгә барган идем. Үзенә китабының сәхифәләрен ача-ача күрсәттем, боларганиләр язганыгызны аңлый алмадым, дидем. Ул аларны карап чыкты да, фәнни әсәр шулай аңлаешсыз була инде дип, китабын япты да алып куйды. Аңлаешсыз итеп язгач, нинди галим була инде ул?

— Ярый әле, мондый олы гыйлемгә төшенү өчен сезнең башыгызда урын юк дип әйтмәгән,— дидем мин аңарга.

Шагыйребез хәйран һәм телсез калды.

## БИЕК БАШ ИЯСЕ

*Хикәят*

— Бу кешенең башы яхшы эшли булырга кирәк,— диделәр, бер әфәндене яныма китереп.

— Нәрсә өчен алай әйтәсез?— дип сорадым.

— Маңгае бик биек күренә,— диделәр алар.

— Башның яхшы эшләве маңгайның биеклегендәмени?— дип мин хәйран иттем.— Башның олылыгы күзләр белән колак арасы ераклыктан диярәк белә идем, хикмәт аның биеклегендә икән!

— Кешеләр шулай диләр бит!

— Ә сез үзегез ниләр әйтерсез? Кайсы сорауларыгызга ничек җавап бирде?— дип сорадым.

— Ул сөйләшә белми,— диделәр.

— Алай булгач бик тә башлы икән!— дип, соклануымны белдердем.

## СЕЗГӘ, КЕШЕЛӘР!

*Хикәят*

— Син бәхетле!— диделәр таулар.

— Әйе!— дидем мин.

— Син бәхетле!— диделәр йолдызлар.

— Әйе!

— Син бәхетле!— диделәр таңнар.

— Әйе!

— Син бәхетле!— диделәр ак болытлар.

— Әйе!

— Син бәхетле, син бәхетле, син бәхетле!

—Әйе! Әйе! Әйе!

Мин бәхетле, чөнки ул көнне минем иңемдә канатлар иде. Аларны җилпим дә очып китәм, җилпим дә очып китәм. Күз алдыгызга китерәсезме? Канатлар! Оча торган!

Ә нигә сорамыйсыз: “Адәм баласының иңендә канатлар буламыни ул?”— димисез?

Була икән шул ул, була икән. Бары тик аларны сындырмагыз гына!

## МӘХӘББӘТ ЛӘЗЗӘТЕ

*Хикәят*

Мәхәббәттә газап бар, диләр. Әмма ул газапны татлы дип әйтәләр. Аны гашыйк булган кеше генә татый, башкаларга авырлык кебек тоела, имеш.

Шулай бервакыт мәхәббәт диваналары хакында сүз чыккач, мин:

— Мәхәббәттән ләззәт тату өчен күңелең киң булу кирәк!— дигән сүз әйттем.

— Күңел киңлеге нәрсә белән үлчәнә?— дип сорадылар әңгәмәдә колак тотучылар.

— Башкаларга күрсәткән хөрмәт белән!— дип җавап бирдем.— Аның иң мәртәбәлесе — мәхәббәт, билгеле. Сайлаган ярларыбызны мәхәббәтебез белән шулкадәр зурлыйбыз, алар моның өчен үзләре дә безгә йөрәкләрен багышлыйлар.

## ӘҖӘЛ ДАРУЫ

*Хикәят*

Кешегә үлем сиздерми һәм белдерми килүчән.

— Авыру, сырхау үлемнең хәбәре түгелмени?— дип сорадылар миннән, дөньяда чир дә барын искәртеп, сәламәтлекне югалтудан гүргә кергән адәмнәрне хәтергә китереп.

Әмма мин:

— Юк,— дип җавап бирдем.— Авыру, сырхау үлемнең хәбәрчесе була алмый, ул яшәеш бәласе генә.

Килешмәделәр. Дәлилләр сорадылар. Әйттем:

— Кайсыгызның авырудан үлеп киткәнегез бар? Чир китүчән түгелмени?— дидем.

— Авырып үлгән меңнәрне беләбез,— диделәр алар.

— Һәм шулар без авырудан үлдек дип әйттеләрме сезгә?— дидем, тәмам ачуларын китереп.

## ИДИОТ ИКӘНЛЕК

*Хикәят*

Моңа кадәр ул кешегә карата мөнәсәбәтем бик яхшы иде. Олуг премия алды. Дуслары белән әңгәмә корып торганнарында очратып, форсаттан файда буларак аны тәбрик иттем. “Зур уңышларыгыз алга таба да булсын!”— дип теләдем. Котлавымны күтәрә алмадымы:

— Дошманнарыма шалтыратып әйтегез, үтләре сытылмасмы!— диде. Кемгә икәнен тәгаен белдерде.

Ул атаган кеше миңа да шундый ук нисбәттәге кеше иде. Хәйран иттем. Башымны салындырып китеп барышлый, авызын җәеп көлгәнен ишеттем дә:

— Ярар, идиот икәнлегегезне әйтермен!— дидем, колагы ишетерлек итеп.

Үз юлым белән атлауда идем.

## АКЫЛЛЫЛЫК БӘЛАСЕ

*Хикәят*

— Соңгы вакытларда хатынымның чибәрлеге күземә күбрәк чалына башлады,— дип берәү сөйләнеп тора иде, аңарга:

— Әллә акылына кызыгып өйләнгән идегезме?— диярәк сорау бирдем.

Ул, сәерсенеп:

— Минем хатынны белә идегезме әллә?— диде.— Шулай булды шул. Дөрес әйттегез!

— Белә идем түгел,— дидем мин дә аны тынычландырып.— Сезнең яшегезгә һәм акылыгызга караганда, хатыныгыз да шактый гомер сөргән булырга кирәк. Бу яшьтә зиһен китә бару бер дә сәер түгел. Шушылардан чыгып кына әйткән идем. Акылы куәтле кешенең тышкы чибәрлеге күзгә төртеп тормый ул!

## ИЛНЕҢ БАЙЛЫГЫ СЕРЕ

*Хикәят*

— Кайсы илдә халык бай яши һәм кайда адәм балалары мохтаҗлыкта иза чигәләр?— дип миннән сорадылар.

Моңа җавапны белә идем инде.

— Борынгы бер китапта күрдем: “Әгәр дә илдә кануннар өстен булса — байлыклардан ишелер барча тупса!” Шушы сүзне дөрес дип беләм. Җавабым да шушы!— дидем.

— Тупсалар ишелү яхшымы инде?— диделәр тагын да.

— Монда сүз байлыкның тупсалардан агып чыгуы хакында бара!— дип аңлатып бирергә мәҗбүр булдым.— Ил халкы бай яшәсен өчен илдәге кануннар һәркемгә дә бертөрле, һәркемнән дә өстен, һәркемне дә үзенә буйсындыручы булырга тиеш. Шулай түгелме?

## АХМАКЛЫК ДАРУЫ

*Хикәят*

Дөнья йөзендә һәммә авыруга каршы дәва табыла, әмма акылсызлыктан гына коткаручы чара юк, диләр. Хәер, моның шулай икәнлеген белә идем. Миннән бер дивана киңәш сорап килгәч, аптыраушта калдым. Шулай да, хәтеремне җыеп:

— Бу эшнең ахыры хәерле булмас, уегыздан чыгарыгыз,— дидем аңарга.

Ул бик тә борчулы йөз белән янымнан китте. Шунда, мин аны кабат дәшеп алып:

— Гафу итегез мин ахмакны!— дидем.— Сезгә акыллы кеше белән киңәшергә кирәк иде!

— Әйе, шулай шул,— диде ул, елмаеп җибәреп.

Мин дә:

— Ахмаклыкның үлемнән гайре бүтән даруы юк инде,— дидем, саубуллашып.

## АКЫЛ ЧАРЛАНГАН БУЛСА

*Хикәят*

Галим исемен күтәреп йөрүчеләр арасында вакчыл һәм җиңелчә кешеләрне очратсам, курка кала торган гадәтем бар. Бу гадәтемне күреп алган дустым:

— Сәбәбе нәрсәдә?— дип сорады.

— Бик гади,— дидем мин аңарга.— гыйлем нурының куәте вакчыллыкны һәм акылдагы җиңеллекне бетерү көченә ия.

— Галимнәр холыкта авыр булырга тиешләрме соң?— диде ул, аптырап.

— Һич юк,— дидем мин, килешергә теләмичә,— акыл авырлыгы холыкка чыкса да, галим кеше күп нәрсәгә көлеп кенә карарга тиеш. Юкса акылының үткенлеге бетәр!

## АЛАР ҺӘРКАЙСЫ БӘЙДӘ ШУЛ

*Хикәят*

Кайсыбер шундый кешеләр бар, алар намусның ни-нәрсә икәнлеген белмиләр, күз алларына да китерә алмыйлар. Андыйларның намусларына һичкайчан көч тә килми.

Шул хакта сүз китеп, фикеремне сорадылар. Җавап бирдем:

— Башыңда уй, зиһенеңдә акыл билгеләре юк икән, күңелеңнән намус тойгысын эзләп аптырау бер дә файда бирмәс.

— Акылсыз, ахмак кешеләрдә намус булмыймыни?— диде халык.

— Әйе,— дидем мин,— әгәр дә намуссыз кешене очратсагыз, бер дә аптырамагыз, ул кешенең акылы да, гыйлеме дә булмас. Акыл һәм аң намуссыз адәмдә тормыйлар!

## ГЫЙЛЕМДӘГЕ БОГАУЛАР

*Хикәят*

— Гыйлемнең хикмәтен, өстенлеген беләбез, әмма аның кире яклары да буламы?— дип, бәхәс үлчәвенә үз фикерләребезне салдык.

Шунда:

— Белем ул — аяк-кулларны бәйләп тотучы богау кебек,— дидем мин, дусларымны сәерсендереп. Алар куркышып куйдылар. Саташмадымы диделәр булса кирәк.

— Чөнки гыйлем безне томаналыктан саклап тора. Гыйлемле кешенең намусы куәт алып, аңа хаталы юл буйлап китәргә бирми,— дип аңлата башладым.

Алар:

— Бу яктан да гыйлем үз өстенлеген дәлилли түгелме соң? Димәк, аңардан бары яхшылык кына көтеп була!— диделәр.

## ХИКМӘТ УСАЛЛЫКТА ТҮГЕЛМЕ?

*Хикәят*

Усаллык белән намусның бергә сыешмавын белгән кешеләр миңа:

— Усаллык көч билгесе түгелмени?— диделәр.

— Юк,— дидем мин.— Кешенең куәте — гыйлемдә, гыйлемнең рәхәте — намусны көчләләндерүдә. Ә намуслы кеше хөрмәтле һәм башкалар алдында дәрәҗәле була.

— Намуслы кеше хөкемдардан да дәрәҗәлерәкме?— диделәр, хәйран итеп.

— Әйе,— дидем.— Намусы бозык хөкемдарның дәрәҗәсе бармы?

— Юк!— диделәр.

— Ә дәрәҗәсе юк намус иясен күргәнегез бармы?

Җавап бирүче кеше табылмады. “Ә нәрсә ул дәрәҗә?”— дип сорыйсы итмәдем.

## КИСӘРГӘ КАЙЧАН ДА СОҢ ТҮГЕЛ

*Хикәят*

Усал кешеләр әүвәле гамәл кылучан, аннары үкенүчән булалар. Ачу белән эшне башкарып ташлау өлгерлек саналмый. Кызып китүчән кеше коры салам кебек, кинәт янып, үзен генә харап итә.

— Усаллык — кешеләрнең рухын сындыра. Әмма кызмачалык үз жаныңны һәлакәткә алып бара,— дигән идем, миңа каршы чыгып:

— Йоклап маташуга караганда, терекөмеш булуың хәерлерәк,— диделәр.

Мин исә:

— Әмма кулыгыз кылырга, телегез сөйләргә өлгергәнче, акылыгыз уйлап, үлчәп житешсен! Кисәргә кайчан да соң түгел,— дип әйтүдән уза алмадым.

## ӨЛГЕ ХӨКЕМДАРЛАР

*Хикәят*

— Хуҗалар ай һәм кояш кебек якты, ачык йөзле булганнарында хәерледер,— дигән идем, кеше холкын тануда гыйлем ияләре:

— Халык көтүчесенең кулында чыбыркы, телендә әмер булу яхшырак түгелме соң?— диделәр.

Сәерсендем.

— Ә халыкны сарык булырга тиеш дисезме? Көтүнең көтүчесе кебекме?— дидем.

— Әйе!— диделәр.

— Кояш һәм ай без яшәгән җир белән идарә итмиләрме? Алар елның фасылларын китерәләр, агачларны, үләннәрне үстерәләр. Кайчан йөзләрен сыткаңнарын, чыбыркылап йөргәннәрен күргәнегез бар? Аллаһы тәгалә аларны, башкача булсалар, хуҗа итәр идеме?— дидем.

## СҮЗ ИЯСЕ БЕЛӘН ЙӨРМИ, ДИСӘЛӘР

*Хикәят*

Хикмәт һәм зирәклек иясе бер ир белән очраштым. Ул бер дә җитди сөйләшмидер сыман иде. Әмма һәр сүзе күңел сандыгыма акыл энҗеләре булып коела торды. Зиһенемнең нурлануына хәйран иттем, сорадым:

— Бу сүзләрегезне җитди рәвештә әйтсәгез нәрсә булыр иде?— дидем.

— Ул вакытта алар нәсихәт буларак ишетелер, каеш яки чыбыркы кебек сугар һәм котларны ала торган булырлар иде,— дип тагын да шаяртып куйды.— Нәсихәт ул мөгаллим авызыннан чыкканда гына татлы була.

Уйга калдым. Аннары, сүзләремне үлчәгәч:

— Сез чыннан да хикмәт һәм зирәклек иясе ир икәнсез!— дидем.

## КИМЛЕКТӘ ДӘ ХУРЛЫК, АРТЫКЛЫК ТА

*Хикәят*

Гамәлдә кимлек һәм артыклык бар. Кайбер кешеләр артыклыкны яхшырак күрәләр. Әмма акыл ияләре кимлекне дә, артыклыкны да хурлыклы саныйлар. Монымы белми идем?

Миңа мөэминнәр:

— Без гамәлләрегезне, хурлыкка калмас өчен, артыклык белән кылабыз,— дип мактандылар.

— Ә сез Аллаһы тәгаләне акылсыз буларак белдегезме әллә?— дидем аларга.

— Нинди көфер сүз әйттегез!— дип ачуланып, миңа инкарь күзләрен салдылар.

— Ул вакытта ни өчен үзегездән таләп ителгәнне генә кылмыйча, гамәлләрегезгә артыклык кушасыз соң?— дидем, хәйранлыгымны белдереп.

## ТАТАР ФӘЛСӘФӘСЕ

*Хикәят*

Кешедәге өч төрле сыйфатны татарларда мактыйлар: үз-үзеңне тота белүне, кыюлыкны һәм үткенлекне. Әмма берәүләр, үткенмен дигәндә, сизгерлекне күздә тоталар, икенчеләр исә — кискенлекне.

Миннән бу хакта сораганнарга:

— Татарлар йоклаган кешеләрне сөймиләр, моны бичаралык буларак беләләр. Димәк, үткенлек ул кискенлек кебек бер сыйфат дип беләм. Әмма сизгерлек юкта кискенлек бармы?— дидем.

Ризалаштылар. Моңа сөенеп:

— Үзеңне тота белүне сабырлыктан, кыюлыкны егетлектән, үткенлекне елгырлыктан килә торган сыйфатлар буларак беләм,— диярәк, фәлсәфә кылып алгандай иттем.

## АКЫЛ БЕЛӘН ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНҮ
*Хикәят*

— Миңа нишләргә?— дип бардым акыл иясенә, киңәшен үтенеп.

Сүзләремне тыңлап бетерде дә:

— Аларның электән шундый икәнлекләрен белә идегезме? Сүздә берне сөйләп, гамәлдә икенчене кылып җавап бирмәделәрме?— дип сорады.

— Белми идем,— дидем.

— Акыллы кешеләр җылымса ашны да өреп кабалар. Тәҗрибә дә кылмадыгызмы? Кешедән дә ишетмәдегезме?— дип кабат сорады ул.

— Кешеләргә ышану, аларны яхшыга санау гадәтем бар шул минем,— дидем җавабымда.

Аннары ул, бераз уйлап-уйланып алды да:

— Сезнең акылыгыз бер дә минекеннән калышмый. Акылыгыз белән киңәшегез, нәрсә эшләргә белерсез, ул әйтер,— диде, сүзен бетереп.

## УСАЛЛАР АРАСЫНДА
*Хикәят*

Кешедә өч төрле усаллык бар: беренчесе — теле усал, икенчесе — гамәлендә усал, өченчесе — уенда усал. Боларның кайсы яхшы һәм кайсы начар?

— Урынына карап!— диделәр күпләр.

Шунда мин:

— Уенда усал булган кешедән дә авыррак адәмне белмим, шул кеше начар!— дидем.

— Теле белән усал кешедән күңелебез ватыла, гамәле белән усаллык кылган кешедән гарипләнеп калабыз. Әмма уенда усаллык булган кешедән безгә ни зыян?— диделәр сүземне аста калдыручылар.

— Анысы шулай,— дидем мин дә аларга.— Уенда усаллык булган кеше яхшыдан сөйләгәндәй, яхшыдан гамәл кылгандай, әмма асылда боларның киресен башкара. Хәтерләрегезне яңартыгыз, күзегез ачылыр!

## РУХИ БӘРӘКӘТ
*Хикәят*

Түбән җанлы кешенең сүзендә һәм гамәлендә дөреслек булмый, диләр. Әгәр дә кемнедер ялганында сизсәң, аның рухы югары түгеллегенә фал итүең дөрес санала. Бу хакта кем белми!

Бервакыт дуслар:

— Мөселманлыкның эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт?— дип сорадылар.

Әйе, нигезе иман икәнлеген кем дә белә. Ә менә эчтәлеге?..

— Үзеңнең наданлыгыңнан хурланудa!— дидем мин. Коръәннән гафилләргә җәннәт ишегенең бикле булуы хакындагы аятьне дәлилгә китердем.

Алар:

— Без гыйбадәт дип белә идек. Нинди наданлык ул тагын?— диделәр.

Мин аларның Аллаһы тәгаләнең Хак һәм Хакыйкать булуын тануларына шикләнә калдым.

## БАҺАДИР ИРЛӘР ГАЛӘМӘТЕ

*Хикәят*

Дөньяда куәтле ирләрне күп очраттым. Араларында батырлар да бар иде. Әмма баһадир дип аталырдаен тапмадым. Һәм, шундый ирнең барлыгы хакында ишеткәч, тупсасына килдем.

— Йомышыгыз ни иде?— дип сорады ул.

— Баһадир адәмне күрәсем килде. Нидирәк кеше ул?— дидем.

— Әгәр дә монда андый ир юкмы дип эзләп килгән булсагыз, ялгышкансыз,— диде җавабында ул.— Баһадир адәмдә, куәт һәм батырлыктан тыш, мәртәбә һәм зәвык була. Ә минем күңелем тар, чөнки сандугач сайравын тыңларга яратам, таң атканда кояш чыгуына сокланам. Башкаларга исем китми.

Күңелемә сөенеч тулды, рәхмәт әйтеп чыгып киттем.

## БАШЛЫ ХӨКЕМДАРГА КИҢӘШЧЕ

*Хикәят*

Башың олылыкта бер бәла бар: кигән бүрегең авыр була! Әмма телнең тинтәклеге аны җиңеләйтә.

Бер хөкемдар үзенә киңәшче итеп чакырган иде, алардан:

— Өч сорау бирергә мөмкинме?— дип сорадым.

— Өчесе бергә ничек?— диде алар.

— Минем кебек акылы сай, гыйлеме тар, күңеле суык кешегә нинди мохтаҗлыгыгыз төште?— дип сорадым.

Алар исә:

— Акылыбыз да, гыйлемебез дә үзебездә җитәрлек, рухыбыз да кайнар, әмма киңәшкә болардан мәхрүм кеше кирәк иде!— диделәр.

Мин җавап бирдем:

— Әгәр шулай булса, сезнең сайлавыгыз дөрес. Ризамын!— дидем.

## ҺӘЙКӘЛ БЕЛӘН ОЧРАШУ

*Хикәят*

Үз бөеклеген элекләрне даулап йөргән бер әфәнде белән очраштык. Әүвәле ул мине хәйран итте, аннары аңарга сорау бирергә мәҗбүр булдым:

— Бер-бер нәрсәгә кәефегез китмәдеме? Бигрәк сагышлы күренәсез,— дидем.

— Күптән уңыма-сулыма карап киләм. Дөнья шундый үзгәргән. Үземнең кечкенә икәнлегемне тойдым,— диде ул.

— Сезнең кебек бөек кеше дә болай әйткәч инде,— дидем мин,— безнең ишегә ни-нәрсә кала?

— Ул кадәр үк мыскыл итмәсәгез дә ярар иде,— диде ул.— Нинди бөек булыйм ди мин!

Аңарга сынап карап куйдым да:

— Менә хәзер сез чыннан да бөек булгансыз!— дидем.— Сөенегез!

Ул һәйкәлгә әверелә калды, мин юлымны дәвам иттердем.

## ЗАМАНА ШИГЪРИЯТЕ

*Хикәят*

Бер артист әфәндедән шагыйрь агасының бер шигырен укуын үтендем. Риза булды. Онытылып тыңладым, аннары:

— Бу — даһи шигырь!— дидем.

Әүвәле югалып калды, аннары:

— Ни өчен алай әйттегез?— дип сорады, миннән дәлил көтеп.

— Бу шигырьдә,— дидем мин аңарга,— мәхәббәт тә, нәфрәт тә, гыйлем дә, гафиллек тә, хис тә, акыл да, фәлсәфә дә, сәясәт тә, тузан бөртеге дә, галәм дә һәм башкалары да бар!

— Әмма алар хакында бер генә сүз дә юк бит анда,— диде ул.

— Әйе, юк кебек, әмма алар һәммәсе дә анда бар. Үзегез дә бик яхшы тоясыз, шуңа да бу шигырьне яттан беләсез,— дидем, хәтта үзем дә яттан сөйләп күрсәтеп.

## ХӨКЕМДАРЛАР БӘЛАСЕ

*Хикәят*

— Сез нишләп хөкемдарларны, урын ияләрен бер дә сөймисез?— дип сорадылар миннән.

— Кайдан белдегез, кем әйтте?— дидем аларга.

— Кемнән дә сорыйсы юк. Аларны күрсәгез, яки борылып китәсез, яисә игътибарыгыздан читкә этәрәсез, күрмәмешкә салынасыз,— диделәр.— Хикмәт нәрсәдә?

— Ярый, әйтим инде алай булгач,— дидем,— чөнки алар белән исәнләшсәң, туры килсәң, сөйләшергә дә кирәк була. Ә андый сүздә сәясәт катнаштырмый мөмкин түгел. Сәясәт бар җирдә мәнфәгатьсез булмый. Мәнфәгатьтә исә хәйлә кирәк. Хәйләне ялган кушмый йөртү мөмкин түгел. Минем намусым ялганнан курка.

## ФАЙДАСЫЗ АКЫЛ

*Хикәят*

Сер сөйләшкәндә, аны бүлешәләр, имеш. Хакыйкатьне сөйләгәндә — аңа өйрәтәләр. Ә акыл сатканда нишлиләр икән?

— Сезнең кайчан булса да акыл сатканыгыз бармы?— диделәр.

— Юк,— дидем,— минем хәлемне үзегез дә күреп торасыз, акыл сатып алаала, җыя-җыя шушы мескен хәлгә калдым инде: йөзләрем җыерчыкланды, чәчләрем агарды, гомеремнең кыйммәтле чорлары исраф булдылар. Әмма һаман да дивана калдым.

— Ә без сезне хикмәт, акыл, зирәклек иясе буларак беләбез,— диделәр, мөгаен да миннән көлеп.

— Картайгач кына кергән акыл юләрлекнең бер билгесе инде ул,— дидем, аларга аңлатып,— чөнки аның инде үзеңә файдасы юк, башкаларга бирсәң генә! Әмма кирәк табарлармы?

## ГЫЙЛЕМНЕҢ ХИКМӘТЕ

*Хикәят*

Өч төрле гыйлем иясе очраштылар да һәркайсы үз фәнен мактый башладылар. Мин алардан:

— Гыйлемнән гыйлем аерыламы?— дип сорадым.

Җавап бирә алмый тордылар. Шуңарга күрәдер:

— Хакыйкатьне төшенүгә, яшерен серләрне төгәл итеп ачыклауга корылмаса, гыйлем буламы соң ул?— дидем тагын да.

Шунда берсе:

— Хикмәт анда гына түгел, гыйлемнең нәтиҗәсе дөньяны үзгәртү көченә ия булырга тиеш!— диде.

— Ә кешене үзгәртү көченә ия булган гыйлемне фәнгә санамыйсыз инде, әйеме?— дидем аңарга, күңелен вәсвәсәләп.

## СҮЗ АХЫРЫ

*Хикәят*

— Сүзеңне тавык-чебешләрдән башлаган идең, әллә нинди фәлсәфәләр белән бетердең,— дип бер әфәнде китабымны хурларга итте.

Аңа җавабым әзер иде:

— И дустым,— дидем, җененә тиеп,— нинди яхшы һәм серле гыйлем булган математиканы да сан санарга өйрәтүдән башлыйлар. Язу-уку гыйлемен дә хәреф танудан... Ә хикмәт өйрәнүне ничек тавык-чебештән башламыйсың инде?

Һәм ул:

— Менә зирәк сүз!— диде, куандырып.

*Казан, 26 нчы май, 2006 нчы ел.*

xxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxxx

## Э Ч Т Ә Л Е К

Ак әбиләр догасы. *Хикәя* .......... 3
Соңарган остаз. *Тарихи хикәя* .......... 5
Шаһзадә Сөһәйл. *Тарихи хикәя* .......... 8
Һомай кошы. *Хикәя* ..........21
Аккош моңы. *Хикәя* ..........26
Авыл мөгаллимнәре. *Хикәя* .......... 36
Тиңсезләр гыйшкы. *Хикәя* .......... 59
Кош баласы. *Хикәя* ..........64
Үле елга буенда авыл бар. *Хикәя* .......... 69
Мәхәббәт кыңгыравы, яки сөйләнеп бетмәгән хатирә. *Хикәя* .......... 75
Һәркемнең үз эше. *Хикәя* .......... 87
Зәңгәр күктә ак болыт. *Хикәя* .......... 88
Кечкенә чыпчык малае. *Хикәя* .......... 88
Чыпчык малае һәм ачы. *Хикәя* .......... 89
Мин үзем беләм. *Хикәя* .......... 90
Тимер төрәннәр. *Повесть* .......... 92
Гади замана. *Повесть* .......... 117
Без дә монда бар идек. *Роман* .......... 156
Әнием, Коръән чыгарсың. *Повесть* .......... 203
Тәкъдир хөкеме. *Повесть* .......... 234
Илаһи канун. *Повесть* .......... 258

Сихерче кызы. *Повесть* ........................................................................................................ 302
Ясалма кешеләр, яки хикәят бакчасы җимешләре *(Хикәятләр)*............................................ 329

***Яхин Фарит Закизянович***

**ИЗБРАННЫЕ ПРОЗАИЧЕСКИЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

**Том I.**